*Язучының 90 еллыгына багышлана*

ГАРИФ АХУНОВ

# ХӘЗИНӘЛЕ ГОМЕР

Казан
«Рухият» нәшрияты
2015

ББК 84(2Рос=Тат)-5
А96

Төзүчеләре:
*Наилә Ахунова, Наилә Ганиева*

Мөхәррире
*Наилә Ганиева*

А96 Гариф Ахунов: хәзинәле гомер. – Казан: Рухият, 2015. – 376 б.

ISBN 978-5-89706-171-6

Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахуновның тормыш һәм иҗат юлына багышланган яңа җыентыкта замандашларының, шәкертләренең һәм якын кешеләренең истәлек-хатирәләре, төрле чорларны чагылдыручы фоторәсемнәр урын алды. Шулай ук әдипнең автобиографик очерклары һәм хикәяләре дә тәкъдим ителә.

Гариф Ахуновның Әлмәт чоры әдәби иҗат өлкәсендәге уңышлары белән генә түгел, иҗтимагый активлыгы белән дә игътибарга лаек. Шуңа күрә дә Татарстан нефтьчеләрен Бөтенсоюз аренасына алып чыккан «Хәзинә» романы персонажлары прототиплары, әлеге әсәр буенча Свердловск киностудиясендә төшерелгән нәфис фильм турында да язмалар кертелде.

Җыентык әдәбият белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-89706-171-6

© «Рухият» фонды, 2015
© Ахунов Г.А., 2015
© Ахунова Н.Г., Ганиева Н.М., төзү, 2015

# Якты-көннән-илһам-алып...

Гариф Ахунов минем өчен Татарстан Язучылар берлеге эшчәнлеген оештыруда үзенә бер өлге, үрнәк булып торган фигура. Ун ел буена берлеккә җитәкчелек итү дәверендә бу постта ул башкарган хезмәт, башка рәисләр хезмәте белән чагыштырганда, бер башка югары, өстен булып гәүдәләнә. Ул җитәкчелек иткән 1974–1984 елларда берлектә язучыларның исәбе бүгенгедән бермә-бер кимрәк булса да, аларның һәрберсе үзенә бер шәхес, колоритлы бер фигура булып күз алдына килеп баса. Һәм менә шул халык белән җитәкчелек итү, аларның мәнфәгатьләрен кайгырту никадәр мәртәбәле дә, җаваплы да булгандыр кебек.



Гариф Ахунов Яр Чаллыда. 1980

Шәхсән минем үземә Гариф Ахунов белән аралашып, аның эшләү рәвешен күреп яшәргә туры килмәде. Аның әдәбият йөген тәртә арасында җигелеп тарткан елларында берлекнең Бауман урамындагы бинасында кайнаган әдәби тормыш казаны тирәсендә яшь язучылар буларак инде еш күренсәк тә, үземне Гариф ага белән якыннан аралаштым дип әйтә алмыйм. Алай да Татарстан радиосында эшләгән чагымда Гариф ага белән берничә тапкыр очрашып, әңгәмәләшеп утырганым булды. Шуларның берсе – радиода «Таныш моңнар» дигән тапшыру әзерләгәндә. Кемдер Гариф Ахуновның халкыбызның «Тулпар атым» җырын яратуы, мәҗлесләрдә булсынмы, кичәләрдәме, дөньясын онытып, җилбәгәй китеп әнә шул җырны җырлавы турында сөйләгән иде. Һәм мин Гариф ага янына аның Новаторлар урамындагы квартирасына барып, шушы җыр белән бәйле истәлекләрен сөйләвен үтендем. Кысан гына, тап-тар кухнялы хрущевка фатирларында Шәһидә апа белән бергәләп алар мине коймак белән сыйлый-сыйлый кунак иттеләр. Гариф ага дәртләнә-дәртләнә шушы җыр турында сөйләде, «тулпар» урынына «чулпар атым» дип җырлап та күрсәтте. Икенче очрашуыбыз да радиотапшыру әзерләү белән бәйле булды. Монысында, шагыйрь Мансур Шиһаповның «Туй күлмәге» дигән җырлар китабы чыгу уңаеннан әзерләнгән радиотапшыруда сөйләтер өчен, шулай ук өйләренә барып, магнитофонга яздырып алдым Гариф аганың чыгышын.

Гариф ага җырларга бик ярата торган кеше булып күңелдә калды. Аның композитор Фасил Әхмәтов белән бергә иҗат иткән «Якты көн» дигән җыры да бар. «Якты көн, илһам бир миңа көн буена җитәрлек...» дигән юллары бар ул җырның. Гариф ага, әнә шул җырдагыча, һәр яңа көннән тәм табып, матурлык күреп, тормышка мәхәббәт белән гомер



Яшь талантларга Г. Ахунов премиясен тапшыру тантанасы. Арча, 2013

иткән кеше иде. Аны чордашлары, замандашлары, бүгенге өлкән буын дип исәпләгән әдипләребез бик хисле, мавыгучан, дәртле, омтылучан, тырыш, тынгысыз җанлы кеше итеп хәтерләрендә саклый. Ул һәр туган яңа көнен мәгънәсезгә, бушка уздырмаска тырыша иде. Иртә таңнан торып язу өстәле артына утырыр, үткән көндә булган хәлләрне көндәлегенә төшерер, яңа хикәяләрен башлап яисә тәмамлап, дөньяга чыгар, Язучылар берлегенә каләмдәшләре янына ашыгыр. Аның иҗат гомере әнә шундый мәшәкатьле көннәрдән торган булыр. Һәм ул гаять тә нәтиҗәле, биш роман, егермегә якын повесть, күпләгән хикәя һәм мәкаләләр язып, биш дистәдән артык китап чыгарып, татар әдәбиятында үз эзен калдырган мәртәбәле әдибебез, күренекле язучыбыз, җәмәгать эшлеклесе булып күңелләрдә яши.

Тууына 90 ел тулу уңаеннан нәшер ителә торган бу җыентыктагы язмаларда Гариф ага Ахунов әнә шундый тынгысыз гомер һәм иҗат юлы үткән зур әдибебез булып гәүдәләнә. Язмамны Әлмәт төбәгендә язучылар оешмасын төзүче һәм аңа җитәкчелек иткән күренекле әдибебезнең 90 еллыгы уңаеннан бу саллы басманы дөньяга чыгарулары өчен «Рухият» фондына зур рәхмәт сүзләре белән тәгәллисе килә.

*Рафис Корбан,*
Татарстан Язучылар берлеге рәисе,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

# Балкып-яшәде

Гариф Ахунов... Шушы ике сүзне яздым да тукталып калдым. Мин әлеге исем-фамилияне йөрткән шәхес һәм күренекле әдип, Татарстанның халык язучысы турында сүз әйтергә алынам түгелме? Дөрес, бу әдибебезнең иҗаты мине байтак еллардан бирле кызыксындырып килә, аның һәр язганын укып барам, хәтта уй-фикерләрем белән матбугатта да чыгыш ясарга туры килгәләде.

Нәрсәсе, кайсы ягы белән игътибарны җәлеп итте бу иҗатчы? Моңа бер вакыйга сәбәп булды, ахры. 1975 елда Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укучы яшьләр, нindидер җаен табып, Г. Ахуновны очрашуга чакырганнар иде. Әдип бер әйтүдә вәгъдә биргән, яшьләр чакырган җиргә ничек бармыйсың инде, бик барам, дигән. Андый вакытта, үзегез беләсез, мәхшәр куба, тыз-быз киленә, йөзгә кызыллык китермәслек итеп хәзерләнергә тырышыла. Бу юлы да бинаны өр-яңадан юып чыктылар, очрашу буласы аудиторияне әллә ниләр кыландырып бетерделәр. Карап торган кешегә үзе бер тамаша инде. Ник дисәң, инде ул вакытта Г. Ахунов – җөмһүриятебезнең Г. Тукай бүләге иясе, ил парламентының депутаты, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе. Кыскасы, студент халкын каушатырлык нәрсәләр юк түгел.

Менә, ниһаять, Г. Ахунов килде. Зур гына дип исәпләп йөргән аудиториябез тап-тар булып калды, чөнки язучының сүзен тыңларга теләүчеләр күп иде. Дөресен әйтим, студентлардан бигрәк мин дулкынланам. Чөнки миңа язучының иҗаты турында кереш сүз әйтү бурычы тапшырылган.

Гадәттә, андый зур урыннарга сайланган кешеләр олпат кыяфәтле, үтә җитди булалар, сүзләрен дә, утыз ике теш арасыннан чыкканчы, баш миенең әллә кай төшләреннән сайлап кына алалар. Г. Ахунов исә бөтенләй андый түгел икән. Аудиториягә килеп керде дә: «И-и, күпме яшьләр җыелган, болын чәчәкләре кебек нинди матурлар!» – дип әйтеп куйды. Яшьләр исә моңа көлешеп алу белән җавап бирделәр. Гариф абый, аудиториянең шактый бөркүләнгәнен чамалап, пиджәген урындык артына элде, ак күлмәктән генә калды, галстугын бераз бушаткандай итте.

Без җиңел сулап куйдык. Чөнки беләбез, рәсми кешеләр, битеннән тире чишмә булып акса ага, тиешле кыяфәтне саклар өчен, пешеп-янып утырса утыра, әмма халык алдында болай «туарылып» ташлауны башына да китерми. Гариф абыйның мондый «прастуйлыгы» бездәге киеренкелекне дә юып алгандай булды. Очрашу гади генә башланып китте. Бу кичәдән без Г. Ахуновны тәмам үз итеп таралыштык. Сихерләде безне бу җор телле язучы.

Моның белән әйтәсе килгән сүз шул: Гариф Ахунов – гади кеше, самими кеше, ачык кеше. Ул – кешеләрне яратучы җан. Кешеләрне ярату һәркемгә дә кирәкле сыйфат, язучы исә шуннан башка кәгазьгә ике сүз дә төшерә алмый. Чөнки аның төп сурәтләгәне – кеше. Үзең сокланмаган, олылап карамаган нәрсә турында илһамланып язып буламы? Юк, мең тапкыр юк. Аның барлык каһарманнары иң әүвәл автор үзе сокланган кешеләр. «Хәзинә», «Хуҗалар», «Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Идел кызы» һ.б. әсәрләре белән таныш кешеләр моның шулай икәнен әйтмәсәң дә беләләр. Әйтик, «Яшьлек яме»ндәге профессор Мохтаров образын иҗат итүгә күренекле галимебез Латыйф Җәләй илһам бирсә, ан-



К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Г. Ахуновның 80 еллыгына багышланган юбилей кичәсе. Язучылар М. Хәбибуллин, Ф. Галимуллин, Г. Рәхим чыгыш ясыйлар. Казан. 2005, 12 декабрь

дагы Гөлнур исә Гариф абыйның сабакташы, соңыннан хатыны Шәһидә апаны күздә тотып язылган. Таһир дигән егеттә Гариф Ахуновның үз чалымнарын күрәбез.

Г. Ахунов турында байтак авторларның мәкаләләрен укырга туры килгәне бар. Алар арасында аның холкына бәрабәр итеп язылганнары күп түгел, шуларның берсе – аның иң якын каләмдәшләреннән булган Мөхәммәт Мәһдиевнең «Замандашым турында бер сүз» дип аталганы («Азат хатын», 1975, № 9). *«Без аның белән бер төбәктә туып үстек, авылларыбыз арасында йә күк чәчәкле җитен басуы, йә җилдә бөтерелеп утырган бодай басуы гына иде. Безнең авылдан чыгып, басу түбәсенә күтәрелсәң, тәгәрәшеп дулкынланган иген басуын кичсәң, Гарифлар авылы – безнең өчен кечкенәлеге белән мәңгелек сер булып калган алты өйле генә Өчиле авылы күренә иде. Шуның өстенә авылыбызда без бала вакытта ук Өчиле Ахун дигән кеше турында сөйлиләр иде, чөнки Өчиле Ахун безнең авыл кызы Бибинур апаның кияве булган икән»*. Юбилей мәкаләсен (бу мәкалә Г. Ахуновның 50 яшьлегенә язылган) 1975 елгы шартларда әнә шулай гади генә итеп язу М. Мәһдиевнең егетлеге иде. Шуның өстенә болай язу өчен ихласлык һәм, әлбәттә, Г. Ахуновны үз күрү кирәк. Әйе, Г. Ахуновның үзенең дә нindидер сөйкемле сөяге бар, аны якын итмәү гайре табигый булыр кебек. Әйдәгез, замандашы турында М. Мәһдиевнең гади генә иттереп тагынниләр язганын укыйк әле: *«Авыр вакыт иде, әмма Ахуновның борын салындырып йөргән, зарланган чагын күрмәдек. Аның белән сөйләшкәндә, аралашканда, тамак ачлыгы да, авырлык та онытыла иде, аның тирәсендә тормыш кайный иде. Чөнки Гариф тик торуны, бушка вакыт уздыруны белмәде. Ул гел хәрәкәттә, гел шау-шу эчендә иде, күңел төшенкелегенә бирелергә*

*аның вакыты калмый иде. Ул вакытта кемнең кем буласын шайтан белгәнме? Гариф әдәбиятны ярата, ул фәннән гел «бишле» ала. Җор телле Яхъя Халитов белән дус иде. Алар әдәби темаларга бәхәсләшкәндә, тулай торакның начар ягылган салкын бүлмәсе җылынып киткәндәй, карточкага алган биш йөз грамм ипи бер килога әйләнгәндәй була, дөньялар ямьләнеп китә иде»*. Әгәр М. Мәһдиев якташы Г. Ахуновның әлеге бәйрәменә кадәр яши алса, бүген аны тагын да гадирәк, табигыйрәк сурәтләп, матбугатта чыгыш ясамый калмас иде. Аның каләменнән моннан егерме ел элек төшкән сүзләрне шактый мул китерәбез, рухы шат булсын. Алар Г. Ахуновның бүгенге шәхесен аңлауга да ачкыч булып хезмәт итәләр. *«Мин флоттан хезмәт срогын тутырып кайтканда,*– ди М. Мәһдиев,– *Гариф инде күтәрелеп килә торган язучы, өметле яшь тәнкыйтьче иде. Аның Федосеевская урамындагы тар бүлмәсен хәтерлим: бердәнбер чөйгә аның кырשылган пальтосын, минем кара шинель белән фуражканы элдек тә идәнгә тәгәрәдек. Гариф миңа үзенең беренче әсәре – «Яшьлек яме» повестеның ничек язылуы турында сөйләде. Соры одеял ябылган тимер караватка, какшау аяклы иске өстәл өстенә 20–30 блокнотын чәчеп ташлады да, повестена материалны, сүзне, геройны каян алганын, ничә еллар җыйганын сөйләде. Озак сөйләде, керосинка өстендә кыздырырга куйган вермишелебез яна башлаган иде. Шунда, әдәбият дөньясыннан бик еракта гомер уздырган кеше буларак, мин уйлап алдым: бу кеше тормышта үзенең юлын тапкан, үзен шуңа багышлаган. Чөнки әдәбияттан башка ул берни дә сөйләмәде, зәңгәр төтен чыга башлаган табасын да, мин әйткәч кенә, читкә алып куйды, аны да аңлап түгел, болай гына...»*

Г. Ахуновның «Соңарып килгән бәхет» дигән хикәясе бар. Аның каһарманы Рәхим Сөбханкулов – гомер буе сәнгатьтә үз сүзен әйтә алмаган биюче. Инде лаеклы ялга да чыккан. Әмма очраклы рәвештә генә ул нефтьче яшьләр белән бер күмәк бию иҗат итә, анда әлеге егет-кызларның хезмәтен, хис-кичерешләрен моңа кадәр беркем дә эшли алмаганча гәүдәләндерүгә ирешә. Бу исә аны чиксез бәхетле итә. Әсәрдә шундый сүзләр бар: «Бик соң килгән бәхет түгелме бу? Сәнгатьтә дөрес юлны яшьрәк чакта тапкан булса, ниләр генә эшләмәс иде әле ул». М. Мәһдиев мәкаләсен укыгач, менә шушы сүзләр хәтеремә төште. Дөрес, М. Мәһдиев тә үзенең әдәбияттагы урынын алай соңарып алмады, аның караваы, бер тапкач, халкыбызга әнә нинди энҗе-гәүһәрләр бирде. Г. Ахунов исә әдәбияттагы урынын иртә тапты һәм бу юлда «ниләр генә эшләмәде»! Үз гомерендә илле биш китап кына чыгарды, аларның унҗидесе – урыс, унбише башка халыклар телләрендә. Хәзер исә мәгълүм тәрҗемәче М. Өнәр аның «Идел кызы» романын «Габбас хәзрәт» исеме белән төрек теленә тәрҗемә итә. Димәк, ул озакламый кардәш ил укучыларына барып ирешер. Җитмеш ел гомернең кырык өче иҗат белән үткән икән, димәк, кайбер елларга икешәр китап туры килә дигән сүз. Әйтергә генә ансат, китап чыгарып караган кеше белә, аның берсен генә укучы кулына ирештерү никадәр күп хезмәт һәм киеренке эш сорый. Аның янына газета-журналларга чәчелгән йөзләрчә мәкаләләрне өстә. Ул – иҗат эшчәнлеген тәнкыйтьче булып башлаган кеше. Б. Брайнина, А. Тарасенков аны тәнкыйтьче буларак югары бәялиләр. Татарстанның яшь язучылары семинарында М. Максуд Г. Ахуновны әдәбиятка зур әзерлек белән килүчеләр арасында атый, аңа өмет баглавын белдерә. Ләкин кулланылышта, нигездә, «язучы Гариф Ахунов» дигән төшенчә генә бар, аны «тәнкыйтьче» дип атаучыны сирәк очратырга туры килә. Ә бит бу каләм әһеле бервзлексез соңгы илле елдагы әдәбият тарихын, аның эстетик үсеш кануннарын күзәтеп-күрсәтеп, шуларга үз карашын белдереп бара. Ул хезмәтләрнең байтагы «Чишмәләр белән сөйләшү» дигән калын китапта бергә тупланып дөнья күрде.

Алай гына да түгел, без «шагыйрь Г. Ахунов» дип тә әйтмибез. Аның бүгенге көндә ике том әзер шигырьләр җыентыгы бар. Дөрес, алар әлегә басылмаган. Әмма көндәлек

матбугатта дөнья күргәннәре дә җитәрлек. Үткен күзле, нечкә хисле композиторларыбыз безгә караганда сизгеррәк. Алар Г. Ахуновның унбиштән артык шигыренә көй яздылар. Ф. Әхмәт язган «Якты көн» җыры дога булып яңгырый. Безнең борынгы бабаларыбыз иртән Кояшны сәҗдә кылып каршы алганнар. Г. Ахунов та бу җыры белән ил-көнебезгә тынычлык, бәхет, җимешле хезмәт тели. Р. Дәминов, З. Сәхәбиевалар башкаруында бу әсәр безнең күңел түрләребезгә үтеп керә. С. Ибраһимовның «Һәйкәл салыйк Сәйдәшкә», М. Имашевның «Ил сагында калды шагыйрьләр», «Башым салыйм таңда кемнәргә» җырлары белән дә шул ук хәл. «Утлар яна учакта» әсәре буенча куелган спектакльгә җыр текстларын язуны Г. Ахунов Әлмәттә яшәүче шагыйрә С. Сөләймановадан үтенә. М. Имашев аларны музыкага сала. Әнә шулай өч кешенең иҗат дуслыгы белән туган «Гүзәлия», «Сәләхи җыры», «Нефтьчеләр маршы» ничә еллар инде безнең яшәешебезне матурлап яңгырыйлар.

Без «драматург Г. Ахунов» та димибез. Ә «Утлар яна учакта» әсәре үз вакытында нинди зур уңыш казанды. Г. Ахунов Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен сәхнәдә кую өчен нинди күркәм итеп эшләде! Ул байтак еллар буе театр сәнгатебезнең иң абруйлы сәхнәсендә – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйналды. Шунысы кызык: «Хәзинә» әсәренең сәхнә вариантын язу бурычы алга килеп баскач, Г. Ахунов – роман авторы – моны башкарып чыгуда кыенлыкларга очрады, каләме аңа буйсынырга теләмәде. Аның каравы бу эшне Мансур Шиһапов әйбәт эшләп чыкты. 1983 елда Татар дәүләт драма һәм комедия театры (хәзер К. Тинчурин исемен йөртә) Ташкенттагы гастрольләрен шушы әсәр белән башлап җибәрде. Спектакль «Кошның да үз канаты була» дип исемләнде. Шәвәли образын башкарган Наил Шәйхетдинов аеруча югары бәя алды. СССРның халык артисты А. Талипов әсәр һәм аны сәхнәләштерүчеләргә соклануын белдерде. Шулар өстенә без «мемуарчы Г. Ахунов» дияргә дә яңа гына күнегеп киләбез. Дөрес, «Йолдызлар калка» китабын укып, без инде моңа байтак еллар элек инанган идек. Хәзер бу китапның икенче кисәге матбугатка әзерләнде дип ишетәбез. Без аннан Г. Ахунов тормышындагы аеруча катлаулы бер чор белән танышырбыз дип өметләнәбез.

Г. Ахуновның каләм байлыгы турында сүз алып барганда, тагын бер зур катлам бар. Яшь чагында ук Гомәр ага Бәширов аңа амбар кенәгәсе ачарга һәм шунда көндәлекләр язып барырга киңәш иткән икән. Бу шөгыль тора-бара Г. Ахуновның көндәлек бер мәҗбүри үтәлергә тиешле эшенә әверелгән. Чыннан да, кая гына барса да, сез Г. Ахуновны әлеге амбар кенәгәсеннән башка күрмәссез. Ул җыелышта катнашамы, әллә берәр очрашудамы, күргәннәрен-ишеткәннәрен язып утыра. Юк, хәтере начар булганнан түгел. Анысы, Аллага шөкер, яхшы, хәтта бик яхшы! Әллә кайчангы хәл-әхвәлләрне нечкәлекләр белән түкми-чәчми сөйләп бирә. Хикмәт каләм эшенә үтә җаваплылык белән карауда. Чөнки әлеге амбар кенәгәсе тора-бара әсәрләргә, мәкаләләргә ризык бирәчәк, анда теркәлгәннәр әдәби образлар, детальләр булып әвереләчәк.

Амбар кенәгәләренең кайберләрен минем дә кулыма тотып караганым бар, күпме хәзинә теркәлгән ул саргаеп беткән кәгазь битләрендә. Г. Ахунов анда үзе турында язмый бит. Ул башка кешеләр хакындагы каләмгә әләгердәй нәрсәләрне бөртекләп туплап бара. Әгәр дә бу язмаларның авторы ун ел Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, «Казан утлары» журналы мөхәррире, Әлмәт Язучылар оешмасының беренче җитәкчесе, зур җәмәгать эшлеклесе икәнен исәпкә алсак, аларда никадәр бай мәгълүмат тупланганлыгын күз алдына китерү кыен түгел. Дөресен әйткәндә, Г. Ахунов кырык биш-илле еллык тарихыбызны кәгазьгә беркетеп барган. Шуңа күрә бу язмаларның дөнья күрүе әдәбиятыбыз һәм, гомумән, мәдәниятебез, тулаем җәмгыятебез тарихына күпме ачыклык кертер иде.

Татар кино сәнгатен күпмедер дәрәҗәдә урыныннан кузгатып җибәрүгә дә аның өлеше керде. Свердловск киностудиясендә «Хәзинә» романы буенча нәфис фильм төшерелде. О. Воронцов режиссерлыгында эшләнгән бу фильмда Г. Шамуков (Шәвәли), Ш. Биктимеров (Нуришанов), В. Минкина (Мәгыйшә), Д. Ильясов (Габбасов), Р. Шәрәфиев (шаян нефтьче) кебек артистларыбыз катнашкан иде. Ул гына да түгел, кино сәнгате белән шулай турыдан-туры очрашкач, безнең артистларыбыз тагын да яңадан-яңа образлар тудыру уе белән яна башладылар. Г. Шамуков, мәсәлән, болай диде: «Мин татар әдәбияты классигы Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының экранлаштырылуын күрергә хыялланам». Бу урында шуны әйтәсе килә: и мәрхүм Габдулла агай, Сезнең бу уйларыгыз әле хәзер дә хыял гына булып кала шул. Татарстан киносы һаман да тәпи атлап китә алмыйча азаплана.

Аның каравы Казан телевидениесе студиясе бу яктан уңышлы гына адымнар ясады. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхтәм Зариповның «Идел кызы» әсәре буенча 1989 елда фильм-спектакль әзерләве үзе генә дә зур вакыйга булды.

«Идел кызы» турында сүз чыккан икән, шунысын да ассызыклыйк: әлеге әсәр күп яктан Г. Ахуновның новатор язучы булуын раслады. Ул совет хакимияте елларында бездә кешеләрнең гаять авыр язмышларга таруларын күрсәткән беренче әсәрләрдән булды. А. Гыйләҗев, Ә. Еники юл салган бу мәүзугъның яңа катламнарын ачуга Г. Ахунов җитди өлеш кертте.

Социалистик реализм теориясе коммунизм идеаллары өчен көрәшчене генә уңай каһарман дип таныды һәм аны гына әсәр үзәгенә куеп сурәтләүне таләп итте. Г. Ахунов исә бу романында бөтенләй башка юлдан китте. Әсәрнең беренче кисәгендә бөтен вакыйгаларны Габбас мулла тирәсенә җыеп бирде. Ходай Тәгаләнең изге бер бәндәсе булган Габбас үзе мулла гаиләсенә ничарадан бичара гына килеп керә. Ул – бөтен барлыгы белән җир кешесе. 1917 елгы вакыйгалардан соң Габбас, мулла булуы сәбәпле, йортсызҗирсез, мал-туарсыз калдырыла. Кызы Нурия аның фаҗигасен тагын да тирәнәйтү өчен кертелгән образ. Югары уку йортында укучы Нурия, үзен университеттан чыгармасыннар өчен, мулла дип аталучы әтисеннән, ягъни Габбастан баш тарта. Димәк, Габбас иң якыннарыннан да мәхрүм кала. Мондый хәлдәге кеше төрле хәлиткеч адымнарга сәләтле буладыр. Шулай килеп чыга да. Яңа дип атлаган кешелексез җәмгыятьнең аны читкә этәрүен, ихтимал, ул әле, авыр булса да, күтәрә дә алган булыр иде. Әмма газиз баласының атасыннан баш тартуы аны үз-үзен һәлак итүгә китерә.

Беренче кисәк Габбас мулла фаҗигасен күрсәтүгә багышланган. Ул аның исеме белән аталырга тиеш иде дә. 1978 елда «Ил язмышы» дигән мәкаләмдә мин әнә шулайрак дип язып чыккан да идем. Гариф абый, мәкаләне кисеп алып, аның кырыена болай дип язып куйган: *«Идел кызы»на журналда басылганнан соң бер ел тулгач, рецензия чыкты. Соң булса да, уң булсын. Әсәрне тәнкыйтьче дөрес аңлаган. Рәхмәт аңа. Г. Ахунов. 15.X.1978»*. Бу үзе өчен генә дип язып куелган берничә җөмләдә Г. Ахунов шәхес буларак та ачыла. Шундый киң күңелле, сүзен кызганмыйча, мул итеп әйтә белә торган әдип ул. Бу ягы аның иҗат үзенчәлегендә дә билгеле. Образларны сурәтләүдә дә ул аларның үзләренә «ирек бирә», гамәлләрен-сүзләрен тыеп тормый. Менә шул хасият аның каһарманнарының әсәр мәйданында «үзаллы» яшәүләрен тәэмин итә дә. Аның Халикъ Саматов («Чикләвек төше») һәм Галинур Айтуганов («Гомер юлы») образларын гына алыйк. Аларның иҗат ителүләре арасында егерме еллап вакыт аралыгы ятса да, автор, нигездә, бер үк мәсьәләне, ягъни тоталитар тәртипләр вакытында коммунизм фиркасе һәм җитәкче кеше язмышы мәүзугын яктырта. Юк, бу кабатлану түгел, бәлки төрле чорларда бер үк эш стиленең (катып калганлыкның) бөтенләй башка нәтиҗәләргә китергәнлеген тормышның үзеннән чыгып сурәтләү. Әйе, Г. Ахунов-

ны, язучы буларак, тормышның барометры дип атап булыр иде. Ә бу язучы өчен гаять кирәкле сыйфат.

Партиянең кадрлар мәсьәләсендәге төп хаталарыннан берсе, Г. Ахунов әйтмешли, аңа «тырышып ярамый кеше, койрык болгап ярый». Әгәр дә партиягә күпчелекнең карьера, түрә булып үрмәләү өчен кергәнлеген искә алсаң, бик куркыныч әйбер иде бит ул. Алар, эшнең рәтенә төшенү, кешеләргә игелекле булу, үзләре җитәкләгән коллективларны үрчемле эшкә оештыру урынына, «болай итсәм, райком, обком нәрсә әйтер икән?» дигән үлчәм белән эш иттеләр. Төп тырышлык партия түрәләре алдында яхшатлы булып күренүгә юнәлде. Моның бәрабәренә гомуми эшкә бармак аша карау алар өчен берни дә тормады.

Г. Ахунов ике әсәрендә дә, шушы мәүзугъны тирәнәйтеп, әлеге хәлнең афәтле якларын ачуга язучылык сәләтен туплый. Язучы белә: «Чикләвек төше»ндә, дүрт мең центнер ашлыкны күгәрткән дигән сылтау белән, райком секретаре Байназаров колхоз рәисе Саматовны эшеннән алу мәсьәләсен куя һәм моңа ирешә дә. «Гомер юлы»нда да шул ук хәл. Утыз җиде яшьлек колхоз рәисе Галинур Айтуганов ашлыкны райком таләп иткән вакытта чәчмәве (җир өлгерүгә карап эш итүе), икмәкне дәүләткә тапшыруга (чи тапшырсаң, план үтәү өчен бермә-бер артык бирергә кирәк) сәбәпле, районның планны үз вакытында үтәвен өзгән булып чыга. Гомумән, аның үз акылы үзендә, шуңа күрә колхоз елдан-ел ныгый бара. Болар, әлбәттә, «райкомга бар, җирдә дә партия җитәкчелек итә» дип катып калган райком секретарьлары Байназаров, Тимергалиев ишеләр өчен гадәттән тыш хәлләр. Халикъ, Галинурлар мондыйларга тамак төбенә утырган балык кылчыгы иде.

Г. Ахунов исемен телгә алдыңмы, әлбәттә, аның «Хәзинә» романы хәтергә килә. Соңгы вакытта завод-фабрика эшчеләре, нефтьчеләр тормышыннан алып язылган әсәрләргә ясалма рәвештә ниндидер бер өнәмичәрәк карау кебек нәрсә сизелә башлады. Ләкин барлык әсәрләрне дә бер чыбыктан гына сөрү ярап бетмәс. «Хәзинә» – кешеләр һәм аларның язмышлары турындагы әсәр. Дөрес, әсәр эпик колачлылык белән башланып китеп тә, сюжет сызыкларының тараеп калуы, аерым образларның камиллеге җитмәве турында үз вакытында сүз булды. Аның каравы, «Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Идел кызы» әсәрләре инде бу яктан да тел-теш тидерерлек түгел. Алар – безнең прозабызның үсешен, камилләшүен күрсәткән әсәрләр булдылар. Мәрхүм И. Нуруллин да иң соңгы язмаларының берсендә *«Гариф Ахунов булу да кечкенә дәрәҗә түгел. Аның «Идел кызы» романы һәм андагы Габбас мулла образы Ахуновның үз яктысы белән яктыртырга сәләтле язучы икәнен күрсәтте. Мәгълүм булганча, русларда алдынгы карашлы дворян яшьләре башкарган эшне татарларда руханиларның намуслы һәм талантлы өлеше башкарды. Кайбер галимнәр курка-курка гына, теш арасыннан чыгарып кына әлеге хәл турында сүз кузгата башласалар да, бу закончалыкка Гариф Ахуновка һәм аның Габбас мулласына чаклы әдәбиятыбызның игътибары булмады. Гариф Ахунов әлеге закончалыкны җанлы образларда тормышчан итеп гәүдәләндерде һәм укучыга тарихыбызның үзенчәлеген аңларга ярдәм итте. Димәк, Гариф Ахуновның үз яктысы белән балкырга сәләте һәм мөмкинлеге бар»*. Каләмдәшләренә уңай сүзне бик талымлап кына әйткән мәрхүм Ибраһим Зиннәт улының бу фикерләренә игътибар итмичә һич мөмкин түгел.

Гомәр ага Бәширов Г. Ахуновның бу сыйфатларын әле 1968 елда ук билгеләгән иде. *«Китабында (сүз «Хуҗалар» романы турында бара) тагын бер нәрсә ачык сизелә: фикер хөрлеге. Бу кыюлык кына, вакытлы батыраю гына түгел, бәлки туган илеңне, халкыңны сөюдән килеп туа торган, догмаларга буйсынмаска көче җитә торган гражданлык сыйфатларыннан берсе»*. Менә ничә дистә еллар инде Г. Ахунов шушы сүзләргә лаеклы булып иҗат итә.

Гариф абыйның гаиләсен дә язучылардан тора дип әйтергә мөмкин. Хатыны Шәһидә апа – «Минем кала алуым» повестеның авторы, байтак кына әсәрләрне татарчага тәрҗемә иткән каләм әһеле. Ул – Гариф абыйның әсәрләрен иң беренче булып укучы һәм аусыз «өй» тәнкыйтьчесе. Улы Рәшит исә татарчадан урысчага тәрҗемә итү буенча байтак хезмәт куйган кеше. Ш. Маннурның «Муса» романын «Современник» нәшриятында чыгаруда аның хезмәте зур булды. Р. Ахуновның «Әдәби тәрҗемәдә компенсация методы» дигән мәкаләсе тәрҗемә теориясенә кертелгән әйбәт өлеш дип карала ала. Кызы Наилә – шагыйрә, драматург. Язу эшенең кадерен белгән шундый гаиләдә иҗатның үрчемле һәм җимешле булуы бик табигый. Кеше өчен иң мөһиме аны гаиләдәгеләрнең аңлавы, аңа теләктәшлек итүләре бит. Хәер, гаиләдәге мохитне дә кеше үзе барлыкка китерә. Гариф абыйның кечкенә генә язу бүлмәсендә иң абруйлы урында ике татар карчыгының портретлары эленеп тора. Берсе – Гариф абыйның әнисе Бибинурныкы, икенчесе – Шәһидә апаның әнисе Йөзлекәйнеке. Шәһидә апаның әнисе байтак еллар биредә яшәгән. Шәһидә апа кинәнеп болай ди:

– Гарифҗан белән әни бик дуслар иде.

Шушы урында Шәһидә апа мәхәббәт тулы күзләре белән иренә карап куя. Үз әниеңне хөрмәт итеп яшәгән кеше белән гомер кичерү аңа бик рәхәт икәнлеге әллә каян күренеп тора. «Ә мин, – ди Шәһидә апа, – Гарифҗанның әнисе белән сердәш идем. Гарифҗан берәр ярамаганрак эш эшләсә, «хәзер әнигә әйтәм» дип куркыта идем». Шулай дигәч, ирле-хатынлы Гариф абый белән Шәһидә апа рәхәтләнеп көлешәләр.

Гариф абыйны минем төрле шартларда күзәткәнем бар. Идарә утырышында ул – бик таләпчән кеше. Фикерен кистереп әйтеп чыгышлар ясый. Өендә ул – йомшак күңелле ир, ата һәм оныкларын өзелеп яратучы бабай. Язудан арыса, кулына пумала алып, табигатьнең матур күренешләрен киндергә төшерүче рәссам. Әңгәмә вакытында җор телле сүз остасы. Аның туйларда, күңелле мәҗлесләрдә тамадалык итүе үзе бер сәнгать. Бу шәхеснең күпкырлылыгын В. Распутин да әйтми кала алмый: *«Еллар уза, мин әле һаман төньякка сәяхәт кылуыбызны оныта алмыйм. Мин табын янындагы шат күңелле, мәзәкчән тамаданы, президиум өстәле һәм чыгыш ясаучылар өчен куелган мөнбәрдәге җитди (тик сүз өчен кесәгә тыгыла торган җитдилек дип әйтмим) дәүләт эшлеклесен гел искә төшерәм»*. Г. Ахунов белән бер очрашып сөйләшкән кешеләрнең күбесе аны яратмый калмыйдыр. Шуннан соң аны хатлар белән күмәләр. Аның архивында язучыларның гына меңнән артык хаты саклана. Ярый, боларның байтагы ниндидер йомыш төшеп язылган булсын ди. Әмма Г. Ахунов аларның һәрберсенә җавап биргән, җавапларның күбесе ике-өч биттән алып алты-җиде биткә кадәр сузыла. Димәк, аның хатлары гына да томнар тәшкил итәрлек. Ә укучылардан килгән ун меңнән артык хат! Болары инде, әсәрләрен укыгач, күңел кузгалу нәтиҗәсендә язылганнар. Г. Ахунов аларны бик кадерләп саклый, кат-кат укый. Шулардан иҗатына илһам ала. Үзең кешеләрне яратсаң, мәхәббәттән мәхрүм калмассың, диләр бит. Хәсән Туфан сүзләре бу фикерне тагын да ныгытып куя: *«Өметебез, Шатлыгыбыз булуың өчен яратам мин сине, Гариф: гүзәл һәм бай йөрәгеңне әдәбиятыбыз эшләренә фидакарьләрчә багышлап, балкып яшәвең сөендерә мине»*.

...Әйе, Г. Ахуновның үз уты, башкаларга охшамаган үз яктысы бар иде. Аның Казансуга карап торган иҗат бүлмәсенең тәрәзәләрендә һәр көнне иртәнге биштә балкып ут кабынган. Димәк, бу якты тәрәзә артында яңа әсәрләр туган. Ул утның яктысы әдәби сәхифәләр ярдәмендә аның меңнәрчә укучыларының күңеленә төшкән. Аның җылы нурлары бүген дә шифа, ләззәт бирә.

*Фоат Галимуллин,*
профессор, әдәбият галиме, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре
*2000*

# Истәлеген-кадерләп-саклыйбыз

Арча районы – борынгы болгар бабаларыбыз гомер иткән, гүзәл табигатьле, табыннарыбызны сый-нигъмәтләр белән баетучы алтын куллы игенчеләре, татар халкының әдәбиятын, мәдәниятен, күркәм гореф-гадәтләрен үстерүгә зур өлеш керткән бөек Тукайны, Мәрҗанине, халык язучыларыбыз Гомәр Бәшировны, Гариф Ахуновны, Мөхәммәт Мәһдиевне һәм башка искиткеч олы шәхесләрне үстергән тарихи төбәк.

Быел талантлы һәм сөекле якташыбыз, Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гариф ага Ахуновның тууына 90 ел тула.

Гариф Ахунов – түбәннән күтәрелгән шәхес. Ятим балачак, ач-ялангач сугыш еллары һәм аннан соңгы авыр чорга туры килгән яшьлек.

«Бер дә бер көнне педучилище директоры укырга яңа кергәннәрне зур коридорга җыйды да, барыбызның аякларын карап чыккач:

– Педучилищега чабата киеп йөрү тыела. Әти-әниләрегезнең ботинка алырлык кына рәте бардыр, – диде.






Арчаның Язучылар аллеясында
Г. Ахуновка һәйкәл




Арчаның әдәбият һәм сәнгать музеенда
Г. Ахунов почмагы

Минем, әтисез малайның, ботинка алырлык рәтем юк иде. Әнигә ул хакта әйтеп, күз яше белән ялварсам да, ул миңа хәзер үк ботинка алырга вәгъдә итмәде, җирләр туңып, бер сарыкны суеп саткач кына ала алырбыз, диде.

Мин, чабатаны салып ташлап, җир туңдырганчы яланаяк йөрдем училищега, миңа берәү дә «чабата белән килгәнсең» дип бәйләнә алмый иде хәзер...»

Гариф аганың «Без бит Арча яклары» дигән повестендагы әлеге юлларны тыныч кына укып та булмый.

Менә шундый сынаулар үтеп, олы тормышка юл ярган Гариф Ахунов XX гасырның күренекле язучысы булып үсте, татарның иң затлы улларының берсенә әверелде. Ул иҗат иткән әсәрләр аны классик язучы итеп таныттылар. Якташыбыз 1971–1974 елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, 1974 елдан 1984 елга кадәр Татарстан Язучылары берлеге рәисе булды. Аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге дә күпкырлы. Ул 1974–1984 елларда – СССР Югары Советы депутаты.

Гариф аганы күреп белүчеләр аны, гаять тыйнак, кешелекле, ярдәмчел шәхес иде, дип искә алалар. Ул туган ягын – Арчабызны бик яраткан, моның шулай икәнлеген аның үлемсез әсәрләрен укыганда яхшы тоясың.

Арчалылар да Гариф аганың истәлеген кадерләп саклыйлар. Музейларыбызда язучыга багышланган бай материаллар тупланган, китапханәләрдә аның әсәрләрен уку, өйрәнү буенча кичәләр үткәрелә. Районда Гариф Ахунов исемендәге әдәбият премиясе булдырылды, ул ел саен яшь талантларга бирелә.

*Илшат Нуриев,*
Арча муниципаль районы башлыгы

# О его трудолюбии и остроумии ходили легенды




Гариф Ахунов кызы Наилә белән. Казан, 1995

18 сентября – день рождения Гарифа Ахунова (1925–2000), народного писателя РТ, почётного академика АН РТ, лауреата Государственной премии им. Г. Тукая, видного государственного и общественного деятеля.

Гариф Ахунов оставил большое творческое наследие: более 50 книг, изданных тиражом более 6 млн. экземпляров, а также тысячи статей, очерков, пьесы, сценарии, переводы…

О трудолюбии и остроумии отца ходили легенды, он каждый день вставал с петухами и проводил за письменным столом заветные утренние часы до службы. Отец был центром любой компании, дружил с Расулом Гамзатовым, Джанни Родари, Чингизом Айтматовым, Мустаем Каримом, Давидом Кугультиновым; и в то же время очень любил общаться с земляками, с сельчанами; часто ему доверялась роль тамады на застольях любого уровня. Он жил и работал за троих, наверно… Поэтому и ушёл раньше, чем мог, с его-то жизнелюбием…

Отцу в 2015 году исполнилось бы 90 лет. Он был счастливый человек, считал своим главным успехом семью, любил и уважал маму, считал её своим первым другом и единомышленником, прожил сложную, драматичную, яркую, созидательную жизнь и оставил о себе светлую память. Он жил для людей, и они его любили… В Татарстане пять улиц носят имя Гарифа Ахунова: в Казани (в микрорайоне «Солнечный город», там недавно открыли на ней школу № 35), в Альметьевске, в Арске, в деревне Губерчак Арского района, в Кукморе. В Арском музее литературы и искусства есть его мемориальный уголок со знаменитым письменным столом, который ему подарили в Альметьевске на юбилей коллеги-писатели, за которым он написал многие свои известные произведения, и отец прощался с ним как с родным, есть даже его прощальное письмо – «Саубуллашу»… Похоронен он вместе с мамой на тихом татарском кладбище, рядом с мечетью на станции в Арске – в окружении рябин, которые так любил…

*Наиля Ахунова*
*2015*



# I-бүлек.-ЮЛ-БАШЫ

# Тормыш-юлы-һәм-иҗаты


Прозаик, драматург, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахунов (Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов) 1925 елның 18 сентябрендә Татарстанның Арча районы Өчиле авылында (хәзерге вакытта ул авыл юк) крестьян гаиләсендә туа. Аның әтисе Ахунҗан абзый, авылның беренче совет активистларыннан булып, күмәкләшү чорында ярлы крестьяннар арасында зур оештыру эшләре алып бара һәм шул эшләре өчен 1931 елда кулаклар тарафыннан үтерелә. Әтисез калган дүрт баланы әниләре карап үстерә. Күрше Казанбаш авылы мәктәбендә җиде сыйныф белем алганнан соң, Гариф 1940 елда Арча педагогия училищесына укырга керә. Һәм 1947 елда аны тәмамлап чыга. Аннары, Казанга килеп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Г. Ахуновның язучы буларак беренче иҗат тәҗрибәләре дә нәкъ менә шушы студент елларына туры килә. 1951 елда «Үсү юлы» альманахында яшь авторның «Галләм сорау бирә» исемле тәүге хикәясе басылып чыга. Ул шулай ук газета-журналларда очерклары, рецензия һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән күренә башлый. Шул ук 1951 елда, университетның соңгы курсында укыган чагында, аны




Г.Ахуновның әтисе каберендәге һәйкәл. Арча районы Казанбаш авылы



Гариф Ахуновның әнисе Бибинур Ахунова



Наилә Ахунова әтисе Гариф Ахуновның Арча районы Кечкенә Өчиле авылында әти-әнисе яшәгән йорт урынында. 2015

«Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясенә әдәби хезмәткәр итеп эшкә алалар. Мондагы хезмәтен ул университетны тәмамлап чыкканнан соң да дәвам иттерә – алты ел буе анда әдәби хезмәткәр, проза бүлеге мөдире һәм журналның җаваплы сәркатибе вазифаларын башкара. Журналда эшләү яшь каләмченең иҗади сәләтен ачып җибәрүдә һәм әдәби осталыкка өйрәнүдә үзенә күрә бер мәктәп ролен үти. Бу елларда ул күп кенә хикәяләрен, беренче күләмле әсәре булган «Яшьлек яме» (1955) повестен иҗат итә. И. Гази, Г. Әпсәләмов, Ә. Давыдов, Г. Бәширов, Ш. Маннур, С. Баттал кебек танылган язучылар турында әдәби тәнкыйть мәкаләләрен һәм иҗат портретларын бастыра. 1956 елның көзендә Гариф Ахунов Татарстан Язучылар берлеге идарәсе тәкъдиме белән республиканың нефть үзәге Әлмәт шәһәрендә берьеллык иҗади командировкада була, ә 1957 елдан гаиләсе белән бөтенләй шунда күчеп китеп, ун елдан артык нефтьчеләр арасында яши, аларның хезмәт казанышларын һәм көндәлек тормышларын өйрәнә. Шул җанлы тормыш материалы нигезендә әүвәл күпсанлы очерклар, публицистик мәкаләләр, хикәяләр, кечкенә повестьларын яза (җыентыклар: «Еллар чатында», 1959; «Хыялый Хәйрүш егетләре», 1965; повестьлар: «Артышлы тау буенда», 1960; «Канатлар кая илтә?», 1967), аннары зур күләмле әдәби әсәрләреннән «Хәзинә» (1963) һәм «Хуҗалар» (1968) исемле романнарын иҗат итә. Татарстан төбәгендә нефть хәзинәсе табылудан татар халкының яшәешенә, көнкүрешенә килгән үзгәрешләрне, шул яңача шартларда төрле буын һәм төрле кәсеп ияләре арасында күзәтелгән катлаулы социаль һәм әхлакый мөнәсәбәтләрне реалистик буяуларда сәнгатьчә гәүдәләндергән бу дилогия әдәби җәмәгатьчелектә алтмышынчы еллар татар прозасына яңалык алып килгән, аны яңа тормыш материалы һәм яңа геройлар белән баеткан әсәр итеп бәяләнә.

Тиздән роман рус теленә дә тәрҗемә ителә һәм, Казан, Мәскәү нәшриятларында кат-кат басылып, Татарстан нефтьчеләрен бөтенсоюз аренасына алып чыга. Дилогиянең аеруча беренчесе – «Хәзинә» романы – популярлык казана. 1977 елда бу роман буенча Свердловск (Екатеринбург) киностудиясендә шул исемдәге нәфис фильм да эшләнә, ә соңрак, 1983 елда, «Кояшның да үз оясы була» дип исемләнгән инсценировка рәвешендә (авторы – М. Шиһапов) К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә куела.

Г. Ахуновның Әлмәт чоры әдәби иҗат өлкәсендәге уңышлары белән генә түгел, иҗтимагый активлыгы белән дә игътибарга лаек. 1963 елның мартында Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге рәсмиләштерелеп, ул оешманың беренче җаваплы җитәкчесе буларак (1963–1965 һәм 1967–1968), Г. Ахунов нефть төбәгендә яшәүче язучыларны иҗади коллективка туплау, яңа яшь әдәби көчләрне эзләп табу һәм тәрбияләп үстерү юнәлешендә мөһим эшләр башкара, шул чорда ике тапкыр Әлмәт шәһәр Советына депутат итеп сайлана.

Татарстан әдипләренең VII корылтаеннан соң республика Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе итеп сайлануы сәбәпле, Г. Ахунов 1968 елда Казанга кайта. 1972–1974 елларда ул «Казан утлары» журналының баш мөхәррире булып эшли. 1974 елның май аенда узган VIII корылтайда исә каләмдәшләре аны Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе итеп сайлыйлар. Идарә рәисе булып Г. Ахунов IX корылтайда да (1979) сайлана һәм бу хезмәтен 1984 елның маена кадәр дәвам иттерә. 1974–1984 елларда ул шулай ук СССР Югары Советында Татарстаннан сайланган депутат вазифаларын башкара.

Күптөрле административ һәм җәмәгать эшләре белән даими мәшгуль булуына карамастан, Г. Ахунов үзенең иҗат активлыгын да киметми. Җитмешенче еллар дәвамында



Арча районы Казанбаш авылында Г.Ахуновның әтисе кабере янында. 2005

аның бер-бер артлы «И кадерле туган як» (1968–1970) исемле тарихи-публицистик китабы (М. Зарипов белән бергә язылган), «Чикләвек төше» (1971), «Олы юлга сәяхәт» (1974), «Ардуан батыр» (1975), «Без бит Арча яклары» (1978), «Йолдызлар калка» (1979) кебек әдәби, документаль һәм автобиографик китаплары нәшер ителә. Алтмышынчы еллар авылы тормышы материалына нигезләнеп язылган һәм җитәкче урында эшләүче хакимият кешесенең рухи ныклыгын, кыю, принципиаль характерын сәнгатьчә калку итеп, ышандырырлык итеп сурәтләгән «Чикләвек төше» повесте һәм элегрәк язылган «Хәзинә» романы өчен Г. Ахунов 1973 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1978, 1986 елларда әдипнең өч кисәкле роман итеп уйланылган «Идел кызы» исемле трилогиясенең беренче ике китабы басылып чыга. Әсәрдә автор катлаулы тормыш юлы үткән төп каһарманнарының язмышы аша 1900–1930 еллар эчендә Урта Идел төбәкләрендә булып узган зур тарихи вакыйгаларның һәм иҗтимагый-социаль процессларның җанлы картинасын күз алдына китереп бастыра. Кызганычка каршы, язучы иҗат мирасының төп әсәрләреннән булган һәм тарихи үткәнне яңача, чын объектив күзлектән чыгып яктыртуны максат итеп куйган бу трилогиянең өченче кисәге язылмыйча кала.

Сиксәненче елларның икенче яртысында һәм туксанынчы еллар дәвамында әдип, илдә барган демократик үзгәрешләр белән рухланып, үзе кичергән тормыш материаллары нигезендә авылда үзгәртеп кору чоры вакыйгаларына багышланган «Гомер юлы» романын, «Эт патша», «Соңарган мәхәббәт» исемле кече күләмле ике повестен һәм өч кисәктән торган «Тимерханның күргән-кичергәннәре» дигән документаль әсәрен иҗат итә

Г. Ахуновның әдәби мирасында, Казанда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Әлмәт, Минзәлә драма театрлары сәхнәләрендә кат-кат куелып, заманында тамашачының игътибарын җәлеп иткән берничә пьесасы да бар: «Чулпы җыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк» (Ф. Мостафин белән бергә язылган), «Чикләвек төше», «Ардуан батыр» (шул исемнәрдәге повестьлар буенча инсценировкалар), «Акчарлаклар» (Ш. Камалның шул исемдәге повесте буенча инсценировка) һ.б. Әдип шулай ук күпсанлы әдәби һәм истәлек язмалары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре («Әдәби язмышлар», 1970, «Чишмәләр белән сөйләшү», 1985 исемле җыентыклар) һәм әдәби тәрҗемә китаплары белән дә укучылар арасында киң танылa. Аерым алганда, ул татар теленә В. Закруткинның «Плавучая станица» («Йөзмә станица», 1953) романын, А. Макаренконың «Педагогик поэма»сын (1957), Рабиндранат Тагор хикәяләрен («Хикәяләр», 1960), М. Шолоховның «Тихий Дон» («Тын Дон») эпопеясының икенче, дүртенче китапларын (1964, 1965), Татар дәүләт академия театры өчен Н. Погодин, А. Островский һәм башка драматургларның пьесаларын тәрҗемә итә. Г. Ахуновның проза әсәрләреннән күбесе русчага тәрҗемә ителә, хикәя һәм повестьлары украин, үзбәк, кыргыз, мари, чуваш, якут һ.б. телләрдә басыла, «Хәзинә» романы казахча һәм төрекмәнчә тәрҗемәдә нәшер ителә.

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары һәм иҗтимагый тормыштагы актив эшчәнлеге өчен Г. Ахунов 1975 елда Хезмәт Кызыл Байрагы, 1981 елда Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнә, 1972 елда аңа «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, ә 1993 елда Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев Указы белән ул «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мәртәбәле исемгә лаек була. Әдип шулай ук 1998 елдан Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы дигән мактаулы исем йөртә.

Гариф Ахунов 2000 елның 4 июнендә Казанда вафат була һәм туган ягы Арча зиратына җирләнә.

Г. Ахунов – 1957 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

# Гариф Ахунов: «Главный успех в жизни — семья»

Говорят, что на таких, как он, земля держится. С ним всегда было интересно. Отец был жизнелюбивым, весёлым, добрым. Искренним человеком. Человеком слова. И – дела: трудолюбие Гарифа Ахунова вошло в поговорку среди коллег-литераторов. И эти же качества он ценил в других. Всё это видно из короткого блиц-интервью с ним, которое было взято мною у него незадолго до его кончины...

*Знаки зодиака*: Дева, Вол.
*Кредо*: «Во всём дойти до самой сути» и добиваться совершенства.
*Главный успех в жизни*: семья.
*Любимое занятие*: писать книги и рисовать.
*Любимый вид отдыха*: работа в саду с женой Шаидой.
*Любимый поэт*: Габдулла Тукай.
*Любимый писатель*: Михаил Шолохов.
*Любимый певец*: Ильгам Шакиров.
*Любимый актёр*: Шаукат Биктимиров.
*Любимые имена*: моих близких.
*Любимый цвет*: белый.
*Любимый цветок*: ромашка – из полевых, герань – из комнатных, роза – из садовых.
*Любимое блюдо*: картошка в любом виде.
*Человек, который вызывает наибольшее восхищение*: Расул Гамзатов.
*Наиболее огорчительная черта в людях*: потребительское отношение к жизни, зависть.
*Черта, наиболее ценная в друзьях*: искренность.
*Наибольшее счастье*: добиться признания своих книг, своего труда народом.
*Что внушает наибольший страх*: я уже ничего не боюсь, даже смерти.

*Наиля Ахунова*,
заслуженный работник культуры Республики Татарстан,
руководитель ЛИТО «Белая ворона»


## «Чишмәләрең-өмет-итә »

Кечкенә Өчиле авылы белән танышуым Яңа Кишет мәктәбендә уку елларыннан ук башланды. Әдәбият дәреслекләренә Гариф Ахуновның 1925 елның 18 сентябрендә Арча районы Өчиле авылында туу турында язылган. Укытучыбыз Гөлфания апа Җәләлетдинова бу авылның бөек шагыйрь Габдулла Тукай яшәгән Өчиле түгеллеген, хәзерге вакытта Г. Ахунов туган Өчиле авылының юкка чыккан икәнлеге турында мәгълүмат бирде. Шулай итеп, бөек әдипне биргән Өчиле минем күңелдә Казансу буенда урнашкан «өч йортлы» кечкенә генә бер авыл булып кереп калды.

Бу авыл урнашкан урынны беренче мәртәбә барып күрүем дә очраклы гына булды. Соңгы елларда Арчага күченеп яши башлагач, җәйге челләдә 12 чакрым ераклыкта урнашкан Казанбаш буасына су коенырга йөри башладык. Табигатькә хозурланып, дөнья мәшәкатьләреннән арынып Казансуда су керәбез. Буадан өстә, калкулыкта зират урнашкан. Зират бар, каберлекләр, кабер ташлары бар. Соңгы мәрхүм дә 2009 елда гына җирләнгән. Ә авыл юк! Кыр уртасында авылсыз зират... Зират янында гына читтә сыер көтүе утлап йөри. Көтүчедән әлеге күренешне аңлатып бирүен сорадым. Ул миңа тирәяктагы ташландык нигезләрне төртеп күрсәтте... Әлеге авылның Гариф Ахунов туган Өчиле икәнлеген әйтте...



Кайчандыр Г. Ахуновның туган җире – Кечкенә Өчиле авылы булган урын. Арча районы, 2015




Гариф Ахуновның нәсел шәҗәрәсе

Кечкенә Өчиле авылы – Гариф Ахуновның җан җәрәхәте. Бу турыда аның истәлекләрен укыйк: *«Мин туып үскән авыл – Арча районының Кечкенә Өчиле авылы иде. Өч йөз ел буе яшәп тә унөч йорттан артмаганга күрә, аны тирә-яктагы авыллар, шүрәле каргаган, дип йөртәләр иде. Мин бәләкәй чакта, мәктәптә укып йөргән елларда, ул гел кими барды. Урта хәлле крестьянны кулак дип исәпләп, Себергә сөргәч, ул тугыз йортлы булып калды. Сугыштан соң тагын да кимеп, алты йортлы бәп-бәләкәй авылга әйләнде. Аннары... Алтмышынчы елдан башлап, ике-өч ел эчендә ул бөтенләй юкка чыкты – Казанга, Арчага, күрше авылларга күченде авылдашларым. Авыл һәлак булды – йөрәктә моң утырып калды. Нинди матур, күз явыңны алырлык авыл иде бит ул. Тау башына урнашкан иде ул. Ә тау итәгеннән ун чишмә агып ята иде. Мин бәләкәй чакларда Кечкенә Өчилегә тирә-як авыллардан кунаклар килеп тула торган иде. Ул сабан туйлары, ул Калатау җыеннары! Ул шлея-чуклы, шөлдерле-кыңгыраулы атлар! Ул печән өстендәге тамашалар! Бар иде матур заманнар...*

*Кечкенә Өчиледән, нибары унөч йортлы Өчиледән 12 егет һәм кыз югары белем алып чыктылар. Профессор, Совет Армиясе полковнигы, врач-табиб, агроном, укытучы, язучы, механизаторлар, колхоз рәисләре булып җитештеләр дә дөньяның төрле якларына таралып киттеләр...»*

Әдип үзенең «Йолдызлар калка» исемле әсәрендә: *«Мин мәктәпкә кергән елларны авыл хәлләре бик кискен үзгәреп китте. Кара-каршы ике йортлы, ике атлы булган кешеләрне кулак санап авылдан сөргәч, унөч йортлы Кечкенә Өчиле тугыз гына йорт-*

*лы булып калды»*, – дип яза. Шулай итеп, Өчиле, Каенлык һәм Көтек авыллары бергә кушылып, «Кызыл Көтек» колхозы ясала.

Гариф Ахунов үзенең туган авылы Өчилегә еш кайткан. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә» исемле истәлекләр китабында авторның якташ әдипләр Сибгат Хәким, Гариф Ахунов белән Өчилегә сәфәре турында кызыклы гына мәгълүмат бар. Әдипләр *«коры елгалы, берничә агачлы сәеррәк бер урында»* туктала. Бу елларда инде СССР Югары Советы депутаты дәрәҗәсенә ирешкән Гариф Ахунов: *«Сибгат абый, менә монысы безнең өй урыны. Сибгат абый, менә безнең өй почмагындагы таш. Менә икенчесе... Сибгат абый, әнә теге карт шомыртны күрәсезме? Әнә тегесе, әнә түбәндә кәҗәләр җыелып ятканы? Менә балалык шушында үтте инде минем»*, – дип әйтә. Алга таба М. Мәһдиев дәвам итеп: *«Шулвакыт мин Гарифҗанның күзләрендә яшь күрдем. Сибгат абый берсүзсез нигез ташы янында басып тора иде. Авыр тынлык урнашты. Йөрәгем кысылды, чын йөрәктән Гарифны кызгандым. Югыйсә – депутат, делегат, лауреат һәм кайдадыр абруйлы әгъза, секретарь, рәис һ.б.»* – дип яза.

М. Мәһдиев тасвирлаган коры елга әле дә бар, сыер-сарык көтүе әле дә утлап йөри, бушап калган нигезләрдә төрле куаклар үсә, чишмәләрнең берничәсе, буа астында калмаганнары әле дә челтерәп ага. *«Безнең авылда ун чишмә бар иде. С. Хәким бервакыт кайткач таң калды. «Бер тауда ун чишмә» дигән шигыренең эчтәлеген бәлки шуннан алгандыр, мин шулай дип уйлыйм. Бу чишмә шулкадәр саф сулы, көмеш сулы, минем, мәсәлән, шушы чишмә суын эчеп үскәнгәдер инде, 50 яшемә җиткәнче беркайчан да тешем сызламады. Бу чишмә бөтен авылны бик матур итеп, әйбәт холыклы итеп яшәтте»*, – дип искә ала Г. Ахунов. Буа ясалганчы, чишмәләрне камыштай биек, хуш исле бөтнек чолгап алган. Заманында авыл халкы салкын чишмә суына чиләк белән сөт, ит, май, каймак куйган.

Буа астында калган болыннарда заманында печән мул үскән. Авыл халкы сугышка кадәр, печәнгә төшәр алдыннан, тәкә суйган, мич башларына мичкә белән бал куйган, болын тугаенда зур кара казанда аш пешергән. *«Ул болындагы уен-көлкене, яшь киленнәрнең, кияүгә барасы кызларның киенүләрен күрсәң, исләрең китәр, тугызлы итеп үрелгән сап-сары чабатадан, сарык йонынnan бәйләнгән ап-ак оекбаштан, чигүле алъяпкыч, чытыр ак яулыклардан, бизәкле тырмалардан һәм арысландай егетләрнең яңгыратып чалгы янауларыннан Казан суы буйлары гү килә иде»*, – дип яза Г. Ахунов. Иртәрәк, яз айларында тугыз авылның халкы атлы олаулар белән җыелган, болын зур бәйрәмнәрдәге кебек гөрләп торган. Шунда ук, тау астында, 1920 елларда Ахунҗан колхоз рәисе булганда төзеткән ике рәт абзарлар булган. 20–30 метр озынлыгындагы бик дәү лапасларда арба-чаналар, ат дирбияләре саклаnган.

Читтәрәк авылның амбар урыннары... 1931 елны колхоз рәисе Ахунҗан үтерелү уңаеннан авылда чуалыш була, *«елау-сыктау, тиргәү-каргау белән тирә-як тула»*. Өчиле авылының барлык ир-атларын да җыеп шушы амбарга ябалар...

Кечкенә Өчиле авылы турында Сибгат Хәкимнең «Нигез» исемле шигыре бар. Бу әсәр, һичшиксез, якташ әдипләрнең (С. Хәким, М. Мәһдиев, Г. Ахунов) сәфәре нәтиҗәсе буларак, 1983 елда язылган. Шигырьнең лирик герое хуҗасын югалткан җирдә эчпошыргыч бушлыктан сызлана.

Авылын төшләрендә күреп газапланган Г. Ахунов та «Авылым сагышы» исемле җыр иҗат итә. Әлеге җырның тексты автор кулъязмасында Арча шәһәрендәге әдәбият-сәнгать музеенда саклана. Аңа көйне Әнвәр Шәрәфиев язган. Дөрес, хәзер, әдип язганча, «Зиратларың тапталды» дип әйтеп булмый, С. Хәким язганча, каберлекләрне аяклы маллар да таптап йөрми – зират тимер киртә белән уратып алынган. Бу изге гамәлне кылган шәхесләргә мең рәхмәт.



Соңрак мин әдип туган нигезнең төгәл урыны белән кызыксына башладым, чөнки биредә ташландык нигезләр берничә. Моны фәкать шул авылда туып үскән һәм хәзер күрше-тирә авылларда яшәүче кешеләр генә белергә мөмкин. Шулай итеп, Казанбаш авылында яшәүче Фәнис абый белән яңадан Өчилегә юнәлдек.

Фәнис Әлтәф улы безгә менә нәрсәләр сөйләде: *«Без авылның урамында басып торабыз. Биредән ат юлы уза иде. Менә Гариф Ахуновның туган, үскән нигезе шушы. Бу урында безне төшергән карточкасы бар аның. Анда өйләре күренмиме икән? Беренче өйләре менә монда, икенче өйләре әнә тегендә. Тоташ бер түбә астында иде алар. Беренчесе – ак өйләре. Ә монысы – кара өй. Әнә тегендәге чокыр – аларның бәрәңге базы. Гариф Ахуновның өе – искиткеч матур йорт, югарыда, елгага таба карап тора иде. Мин үземне белгән вакыттан Өчиледә алты гаилә яшәде. Ахуновлардан сул як күршедә Шәйхетдин ага белән хатыны Камилә, уллары Шамил, Дәүли, кызлары Мәрьям, уң як күршедә бригадир, соңрак умартачы, Ахунҗанның якын дусты Салих абый, хатыны Фатыймәттәй, аларның малайлары Шәкүр, Мансур, Гариф, кызы Зәйнәп яшәгән. Болар барысы да искиткеч көчле гаиләләр иде. Түбәндәрәк исә Мәмдүһә апалар, Абдулла абыйлар йорты. Искиткеч талантлы кешеләр! Аларның Арчада балалары яши. Гариф абыйлар нигезе каршында, түбәндә безнең йорт. Ә биредә, түбәндәрәк рус гаиләсе яши иде. Алар – Павлов Константиннар. Авыл халкы аны Күчте абзый дип йөрткән. Ул авылда тегермән тоткан кеше. Сугышка кадәр үк авылның ашлык сугу машиналарын Казансу елгасы буенда су көче белән эшли торган итеп көйләгәннәр. Константин абзый чип-чиста татарча сөйләшкән, татар егетләре белән урам әйләнеп, татар җырларын җырлап йөргән. Бик борынгы заманда ук бирегә күчерелеп утыртылмадылармы икән алар? Казанбашында тимерче Степан Мельниковлар бар иде, ә алар шул Константинның туганнары. Константин абзый сугышта һәлак булган. Иван дигән малайлары Арчада моннан 7–8 ел элек кенә үлде.*

*Өчиле авылы тарихы турында әби-бабалардан берни дә ишеткәнем булмады. 1982 елда, Казан дәүләт университетыннан килеп, удмурт зиратларын эзләп йөрделәр. Шунда гына иске картадан Өчиленең Янали, ягъни Яңа авыл дип теркәлгәнен белдем. Авылдан соңгы гаилә 1970 елларда күченде.*

*Бу авылдан профессор, физика-математика фәннәре докторы Мансур Салих улы Ибатуллин чыккан. Ул водород бомбасын сынаган вакытта минем дә хезмәтләрем булды, дип сөйли торган иде. Аның кабере шушы зиратта. Аларның бертуганнары Нәҗип абый Киевта генерал. Хәзер исәндерме-юктырмы, белмим. Масра авылында гомере буе медсестра булып эшләгән Радыя апа да шушы авылдан. Ул хәзер картлар йортында,*

*кызганыч, аның балалары булмады. Ибатуллиннар нәселенең күбесе югары белем алды, алар үз көчләре белән укыган, барын да булдыра ала торган кешеләр. Кайсы укытучы, кайсы агроном, кайсы экономист...*

*Элек бирездә чишмәләр күп, бер унбишләп иде. Аларның күбесе, 1990 елларда буа төзелгәч, буа астында калды. Араларында бик көчле чишмәләр бар иде. Су астында искиткеч матур болыннар да калды. Без анда, атларга утырып, печәнгә еш төштек. Мин бу авылның үз сабан туе булганын хәтерләмим. Шулай ук, алда телгә алынган русларның нигезе дә хәзер су астында. Әни русча белмәс иде, Татьяна апа татарча белми. Әмма берсен-берсен аңлашып, гомер буе дус-тату яшәделәр.*

*Малай вакытта Рәшит Ахунов та бирегә кайтты. Без аның белән бергә уйнап үскән малайлар. Гарифҗан абыйга килгәндә, ул гел нәрсәдер язып утыра торган иде. Аңа еш кына Шәһидә апа ниләрдер әйтеп яздыра иде. Алар икәүләшеп иҗат иттеләр. Язудан туктаган арада Казансу буена төшеп, балык тотарга ярата иде. Безнең кармакларга иң беренче кылны да Гариф абый алып кайтып бирде. Шулай итеп, Гарифҗан абый, җәй саен бирегә кайтып, әнисе Бибинур янында шактый вакыт яшәп, иҗат итә иде. Кышын кайтканын күрмәдем. Әниләре 1963–1964 елларда гына Өчиледән Арчага, Ризван исемле улы гаиләсенә күченде. Ризван исә Бибинур апаның икенче иреннән туган улы була».*

Теләсә кайсы әдип туган үскән нигезне төгәл белү мөһим. Бу язучы биографиясе, иҗат лабораториясе белән кызыксынучыларга да, мәктәп укучыларына да, читтән килгән туристларга да кызыклы. Әтнә районы Мәрҗан авылында танылган мәгърифәтче, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани туган нигезне бер әбинең әйтүе буенча якынча гына билгеләп, истәлек билгесе куйдылар, нигезне чылбыр белән урап алдылар. Танылган кайбер рус әдипләре, сәясәтчеләре кереп чыккан җирләренә кадәр музей ачып бетерделәр! Әлеге нигездә моннан 90 ел элек – 1925 елның 18 сентябрендә, авыр ачлык елларыннан соң дүрт ел вакыт үткәч, бәрәңге алганда, нәни Гарифҗан дөньяга килә. Әтисе Ахунҗан ир баласы туу шатлыгыннан әйләнә-тирәдәге туган-тумачаларны чакырып, зур бәйрәм ясый, сабыйга ак күлмәк киертеп, аны курчак-бәби итеп йөрткәннәр. Шунысын да онытмыйк: әлеге нигездә бәләкәй Гарифҗан бер генә түгел, ике мәртәбә туа. Әнисе Бибинур ханымның, баласы җиде айлык булып туып, яшәү һәм үлем арасында калганда, йөзьяшәр Хәдичәттәй әби киңәшен истә тотып, мичне кызу итеп ягып күмерен алгач, исен чыгарып бетереп, кечкенә Гарифны зур агач көрәккә утыртып, тастымал белән бәйләп мичтә җылытып алганлыгы, һәм шуның нәтиҗәсе буларак, бәләкәчнең исән калуы турындагы сюжетны барыгыз да белә дип уйлыйм.

Әдип туган нигез... Әлеге нигездә, Гарифҗаннан кала, аның кан кардәшләре – Гайшә белән Саҗидә, Марат, Бибинурның икенче ире Нурулладан Ризван белән Рамазан туа. Кызганыч, Марат белән Рамазан яшьли вафат була. Ә калган балалары үсеп җитеп, милләткә, илебезгә намуслы хезмәт итә.

Нәкъ менә шушы нигездәге йортта бәләкәй Гарифҗан кичләрен чабата үреп утыра, китап җене кагылганлыктан, төннәрен сукыр лампа астында, «керәчин мае бетереп» китаплар укый, бишенче сыйныфта укыганда, әтисенең үлеменә багышлап, беренче хикәясен язарга омтыла...

Сугыш башлангач, Гарифҗанның яшьтәшләре авылда төп көч булып кала. Гарифҗан 1941 елның җәендә лабогрейка тартучы атларны әйди, шыбын белән салам тарттыра, кыз туганнары Гайшә һәм Саҗидәләр белән өй артындагы 25 сутый бәрәңге бакчасын көрәк белән казып чыгалар, өчәүләшеп чүбен утыйлар, төбенә өяләр. Булачак язучы Өчиле тирәсендәге болыннарда көтү көткән. Язларын ат, соңрак үгез җигеп, сукага, чәчүгә чыккан. 1942 елның июненнән исә «яланаяклы бригадир» булып сайлана, чабатасына туфрак керү сәбәпле, яланак басуларда җир кишәрлекләре үлчәп йөри...

Колхозлашу елларына кадәр Ахуновларның кара-каршы ике йорт, келәт, ике амбар, мунча, торыклы лапас, сыер һәм ат асрар өчен бура абзарлары, сарыклар араны булган. Колхозлашу елларында Ахунҗан ага каралты-кураны шактый кечерәйткән, югары бакча яныннан түбәнгәрәк төшергән. Г. Ахуновның истәлекләреннән һәм замандашларының сөйләвенә караганда, кечерәйтүләргә дә карамастан, Өчиледә аларның йорты иң биеге һәм иң төзеге булган. Бүгенге көндә йортларның нигез ташлары әле дә саклана, анда төрле куаклар үсеп утыра, ә нигез төбендә иске савыт-саба калдыкларын табарга мөмкин. Әлеге салкын таш кисәкләре күпмедер дәрәҗәдә шул чорның рухын саклый кебек.

Фәнис абый сөйләгән урам, йортларны Г. Ахунов ясап калдырган рәсемнән күрергә мөмкин. Әлеге рәсем дә Арча шәһәрендәге «Казан арты» тарих-этнография музееның әдәбият-сәнгать бүлегендә саклана.

Казанбаш буасына су коеныргa, ялларын күңел ачарга, шашлык кыздырырга килүчеләр тирә-якта чокыр-чакырлар, ташландык нигезләр бар икәнлеген чамаласалар да, аның Өчиле авылы икәнлеген, анда бөек әдип Гариф Ахунов туган йортның нигез ташлары барлыгын белмиләр. Һичшиксез, әдип туган нигез чылбыр белән уратып алынырга, анда әдипнең иң яраткан агачы – миләш үсәргә тиеш... Истәлек тактасына да әдипнең үз шигъри сүзләре язылсын иде:

*Өч гасырлык тарихың ла*
*Бар иде бит, авылым,*
*Нинди җилләр алып килде*
*Замананың давылын?*



Гариф Ахунов хатыны Шәһидә һәм туганнары белән. Казан, 1970 еллар

Кечкенә Өчиледә әдипнең иң яраткан чәчәкләре – ромашкалар үсеп утыра. Ә авылдан түбәндә берничә чишмә челтерәп ага. Гүя алар нидер өмет итәләр кебек... Авылның чынга ашмас яңаруын, чиләк тавышларын, кызлар серләшүен көтәләр сыман. Г. Ахунов та заманында авылның яңаруын өмет иткән: *«Өчиленең ерак офыклар күренеп торган тау башына, саф сулы салкын чишмәләре янына, болыннарына, Казансу буена Казанбаштан, Көтектән, Көек һәм Төрнәледән, Тылаңгырдан яшьләр күчеп утырыр. Кабатланмас бу гүзәллеккә сокланып яшәр. Тау астыннан аккан чишмәләргә улаклар куелыр. Бу чишмәләрнең суын эчкән балалар баһадир булып үсәрләр»*, – дип яза әдип.

***

Кечкенә Өчиленең тирә-ягында да Гариф Ахуновның аяк эзләре саклана. Казанбаш авылыннан ерак түгел коммунистлар каберлеге бар. 1931 елны кулаклар яллаган бандит тарафыннан колхоз рәисе Ахунҗан үтерелә. Яңгыр сибәләп торган көнне Ахунҗанны, кара костюм кидереп, табутка салып, җирләргә алып баралар. Табут яныннан беләкләренә кызыл тасмалар бәйләгән, атка атланган кешеләр бара. Җиз торбалардан кычкырталар, барабан кагалар, мылтыктан аталар... Ярым ятим калган Гарифҗан җиргә утырып үкси. Кәрим Тинчурин аны күтәреп алып, җилкәсенә утыртып, кабер янына алып килә. Әлеге вакыйганы үзенең яңа әсәрендә чагылдырыр өчен, драматург Өчилегә махсус килә һәм Ахунҗанның үтерелү эпизоды аның бер пьесасындагы эпизод нигезенә ята. Кабер өстендә Гариф Ахуновны *«ничәмә-ничә мәртәбәләр дулкынландырган, зур калаларга озатып калган, кайчандыр талчыбык кына булган, инде зурайган, картайган өянке»* әле дә утыра. Дөрес, хәзер бу өянке шактый корыган.

Авылга бик якын булса да, әлеге каберлекне хәтта авылда яшәгән кешегә дә табу авыр, ул тирес, сазлык, баткаклык эчендә калган. Бирдә кызыл коммунистлар җирләнгән... Дөрес, хәзер алар идеологиясе хөкем сөрми. Әмма вакыйгаларның даими кабатлануын, тарихи процессның бөҗра буенча хәрәкәтен онытырга ярамый... Төбәк тарихында зур роль уйнаган шәхесләрне хәзерге һәм киләчәк буын өйрәнергә, белергә тиеш.

Югары Пошалым авылы... Агач эшкәртү, арба-чаналар ясау белән дан тоткан әлеге авылда Гарифҗан бер ел чамасы әтисе Ахунҗанның бертуганы Фаизә түтәйдә яши. Аның мөнәҗәтләрен, кышкы озын кичләрдә куркынычлы хикәяләрен тыңлый, аннан байтак кына догалар укырга, әдәп-әхлак кагыйдәләренә өйрәнә. Тукай үзенең дөньяга күзе ачылган җире дип Кырлайны санаса, Г. Ахунов: *«...үзең яшәгәннән бүтәнчәрәк дөнья тудыру ягыннан Алма апаның үзе дә сизмәстән эшләгән эше – минем әдәбият дөньясына якынаюымда юл башы булмадымы икән»*, – дип яза. Фаизә түтәйнең улы Хәкимулла исә, агачтан төрле уенчыклар ясап биреп, Гарифҗанның күңелен күрә...

Әдип ике класс белемне күршеләрендәге Көтек авылында ала. Мәктәпкә баруы турында: *«Үзебез ясаган имән чаңгыларда иртән кырга чыгып чабабыз»*, – дип яза. Зәки Галиев – булачак әдипнең беренче мөгаллиме. Кечкенә Гариф биредә, уку-язу өстенә, плакатлар язарга, стена газетасы чыгарырга, рәсем ясарга өйрәнә. Танылган әдип 40 елдан соң беренче мөгаллиме турында: *«...балаларга яшелчә үстертә, куян карата белүе белән, кыш буена үзебез үстергән яшелчәдән кайнар аш ашата белүе белән, ниһаять, үзе укыткан балаларның уңышына башы күккә тияр дәрәҗәдә сөенә белүе белән бик еракта калган беренче укытучым, изге күңелле бер зат булып, онытылмый хәтердә саклана»*, – дип искә ала. Көтекнең клубында исә Гарифҗан әнисе Бибинурны Тукай, Такташ, Пушкиннарның шигырьләрен сөйләп шатландыра...

Әдип тормышында иң зур роль уйнаган авылларның янә берсе – Казанбаш. Гариф Ахунов Казанбаш җидееллык мәктәбендә белем ала. Биредә ул Рәхим Нәҗмиев, Күлтәс егете Һидият Зыятдинов, Хәнифә Абдуллина, Габделхәй Абдуллин, Хәмзә Закиров кебек

атаклы мөгаллимнәрдә укый. Тырышып укуы өстенә, стена газетасы, кулъязма әдәби журналлар чыгару, рәсем ясау, шигырь язу белән мавыга, төрле спектаклькичәләрдә катнаша. Тәүге мәртәбә Казаннан килгән «тере» язучы белән очраша.

Әдип гомеренең азагына кадәр Казанбаш авылы кешеләре белән үзенең мөнәсәбәтен өзми. Бүген исә Казанбаш мәктәбенең төбәкне өйрәнү музеенда Гариф Ахуновка багышланган аерым почмак бар. Анда әдипнең шәхси әйберләре, фоторәсемнәре, документ-кулъязмалары, басылып чыккан китаплары урын алган.


Гариф Ахунов Арча якларында. 1980 еллар

Арча районында Гариф Ахунов истәлекләрен саклаучы тагын берничә урын бар. Аның берсе – Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте. Ул тәүге тапкыр 1940 елның сентябрендә чабата белән укырга килеп, директор чабата киюне тыйгач, ботинка алырга мөмкинлеге булмау сәбәпле, җир туңдырганчы яланаяк укырга йөри. Бу елларда ул, Рәмзия Вәлитовадан, күренекле әдәбият тәнкыйтьчесе Гали Халиттан белем алып, педучилищеның әдәбият түгәрәгенә йөри, үзе язганча, *«әдәбият кебек серле дөньяны икенче мәртәбә ачып карарга талпынып»* карый. Педучилище күләмендә чыга торган газетаның редакторы була. 1941 елның көзендә уку йорты Үрнәккә күчә. Студентларны салкын баракларда яшәткәне, суык классларда укытканы, шул сәбәпле авырулар саны артуы өчен директорга Мәгариф халык комиссариаты тарафыннан шелтә белдерелә. Г. Ахунов стена газетасында әлеге вакыйга турында мәзәк чыгара, шулай итеп, Гарифҗанның эшләре «кәегеп китә» һәм укуны ташларга мәҗбүр була. Авылда бригадир булып эшли, колхоз кырыннан өенә рөхсәтсез бер күтәрәм бәрәңге алып кайтканы өчен, өч елын Ерак Көнчыгышта хезмәт белән төзәтү лагеренда уздыра. Шулай итеп, Гариф Ахунов Арча педагогика училищесын сугыштан соң, 1946–1947 елларда гына укып тәмамлый.

«Казан арты» тарих-этнография музееның әдәбият-сәнгать бүлегендә исә әдипкә багышланган тулы бер экспозиция эшли. Музей фондында язучы шәхесе һәм иҗатына кагылышлы бай чыганаклар бар. Әдип белән бәйләнешле өченче урын – Арча шәһәренең мөселман зираты. Биредә Гариф Ахуновның, аның хатыны Шәһидә ханымның, әнисе Бибинур һәм башка якын туган-тумачаларының җәсәдләре җирләнгән.

Гомумән, Арча төбәге, аеруча аның Казансу буендагы авыллары, халкы, гореф-гадәтләре Г. Ахуновка шәхес буларак формалашуга зур йогынты ясаган. Язучының әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәте шушы җирдә, шушы туфракта барлыкка килгән.

*Ленар Гобәйдуллин*,
«Безнең мирас» журналының бүлек мөхәррире,
төбәкне өйрәнүче

***Гариф Ахунов***

# Первый-подарок

Где-то там, за разлётом поля и толщей леса, высилась она, выстраивалась каменными домами, непонятно почему белолицая, толстостенная,– поднималась как мираж, в стеклянном мареве зноя. Впрочем, в разное время года менялось и освещение: белый камень серел, прикрывался листьями и ветошью, сумеречными облаками. Сочная синева неба обливала весенние влажные крыши. Зима блестела льдом на ребристых карнизах.

Электрическая лампочка завоевывала пространство. Еще и провода с телеграфными столбами были новинкой, еще едва шепелявило радио. А она всегда была столицей, не древней старухой, а самой древностью, изборожденной морщинами: столица – значит, сто лиц. С зеленого пятачка земли деревни ее лик казался не множеством лиц, не улицами-площадями, но –крепостью, окруженной водой. Трудно передать видение, если оно тебя преследует, подрастает вместе с тобой, о чем все говорят, к чему возвращаются мыслями среди обыкновенных дел, и ты понимаешь: видение принадлежит всем без исключения, не одно твое воображение преображает даль. Столица присутствует в сердце каждого. И ты прислушиваешься, ловишь случайные слова о ней, тем самым оживляешь представимое, беседуешь совершенно безотчетно с будущим, которое за полем и лесом, за глубью небес. Оно осуществимо, теплокровно, только надо чуть-чуть поднапрячься, пересечь долину – и тогда... А что тогда, так ли уж важно знать, лучше –догадываться.

Впервые я приехал в Казань десятилетним мальчиком. Окончил второй класс сельской школы и собрался в путь. Это – необычное путешествие, и готовился я к нему основательно. С утра до вечера одна бесконечная дума, одно опасение, занимала меня: не заблужусь ли я там среди пересыпающихся над тропой огней? Дело в том, что моя старшая сестра Айша уже побывала в Казани у родственников, точнее сказать – погостила, и поделилась со мной кое-какими секретами. У нее их было полно.

–Ты мне скажи, Казань большая? Красивая? – теребил я ее.

Айша маленько была артистка, с завихрениями. Ее подтолкни –она и полетит, в любой момент готовая закружиться, расплеснуться, засмеяться.

– Ой, какая! – воскликнула она. – Там огни в воздухе висят!

– И не падают? – не унимался я.

– Висят, как шары. Ужас сколько их, со всех сторон огни, огни. И ни за что не цепляются. Кругленькие, яркие!

Это уж совсем было восхитительно.

– Плавают, значит? – уточнил я.

– Передвигаются, как гуси,– сказала убежденно Айша. – Воздух там горячий. Они в нем сами подталкивают друг друга. Понимать надо!

Понимать надо, ага! – повторил я про себя, – беспонятливый какой, на невидимых нитках держатся и всё, кумекать пора бы, город все-таки. Хоть сейчас в путь-дорогу, такое желание невозможное для терпения.



Г. Ахуновның әнисе Бибинур Ахунова оныгы Рәшит белән. Кечкенә Өчиле, 1955

Теперь-то я гляжу на себя издали и вижу, как блестят глаза, как горят мои лопушки-уши, как подпрыгивает в груди сердце, – вижу и чувствую давнее неудержимое желание бежать-скакать-ехать. Поглядеть на белый свет так хотелось, пощупать свою мечту, как диковинную ветку с ворсистыми листьями.

Мечтать я начал рано, с шести лет. Отца схоронили, и я задумался: не пошагать ли мне куда глаза глядят. А отца убил ударом ножа нанятый кулаками бандит. Осталось нас у подола матери Бибинур четверо детей. Проживи-ка на тридцать рублей в месяц. Легче бы, наверное, умереть, но дышали мы жадно,– слава богу, воздуха хватало, потому и выжили. Налоги попросту душили: три центнера картошки – отдай, двадцать килограммов мяса – отдай, двести литров молока – отдай, шерсть – отдай... От этого «отдай» – ай! – звенит в ушах, жжет-плачет. Для детской памяти многовато, пожалуй, а вот запомнила как проклятое заклинание: отдай! Страховка – добровольная, а заем – принудительный. Не хочешь, не живи, твоя воля.

Для коровы мы тащили сено со всех лужаек. Стыдно говорить, и овечье молоко забирали. Какие лыжи-коньки-санки?! С каких остатков? Отсюда и зависть палящая, отсюда и обида горькая к более удачливым сверстникам, с расписными санками возвращающимся с базара. Чем же мне-то похвалиться?..

Вот тут как раз и подфартило –в Казань! на летние каникулы! ох, и замечательно! на тысячи висячих огней глянуть! Ну и повезло, ну и одарил бог, услышал мечту мою, никому не рассказанную.

В подкрепление вдруг пожаловал из Казани Фарид, мой двоюродный брат. Отец его Асат-абый, крестьянин-середняк, вовремя сообразил уехать из деревни, иначе отобрали бы у него и дом, и землю. Хотя и так взяли чуть позже. Асат-абый стремглав сбежал в город и устроился конюхом на алебастровый завод, подальше от греха. Ведь очень ему была памятна смерть моего отца: семечко от семечка близко падает.

Фарид заявился в самый раз к поспевшей малине. Насобирали мы её скоренько целых два ведра: не с пустыми же руками ехать в гости –лучше с полными ведрами и с витающей в облаках душой!

Никаких огней поначалу я не увидел. С головой ушли в дело. Город, оказалось, тоже не сливки пьет. Подбирали уголь, оставшийся после обжига извести. О малине быстро позабыли. С разгону я наловчился грести и подхватывать: туда-сюда, туда-сюда. Не согнулся, не ойкнул. Нагрузили тачку и свезли на базар слободы Бишбалта. Посчитали денежки. На свою долю я купил игрушечный барабан. Надо бы чего понужнее – сандалии, к примеру, тапочки, на худой случай, ботинки, вроде бы покрасивше и потверже. Но в деревне барабану удивятся больше. Как забарабаню, сразу станет видно, кто из Казани приехал. Пусть и босиком, зато при музыке.

Один насмешливый остряк еще в поезде посмотрел на мои покрытые цыпками ноги и расплылся, как блин по сковороде, такой вредный-вредный:

– Э-ээ, браток, неважнецкие твои дела. Поржавел. В Казани тебе сделают обрезание – укоротят ноги. Бесполезно их чистить. Готовься!

Ботинки справить, ясное дело, – красота! Но душа не устояла перед барабаном. И – ладно, жизнь впереди бесконечная, невообразимая, подошв на нее сызмала не напасешься. У меня было правило: решил –действуй и не оглядывайся на остряков-балагуров, они вечно в замызганных сапожищах.

Фарид одобрил мой чрезвычайный поступок:

– Без башмаков проживем с барабанным боем!

Мы отправились к берегу Волги: Учия, так называлось это место – Устье. Тут я и ахнул – на меня выплыл пароход. Отродясь такого не испытывал! Белый, вздыхающий, он причаливал к горбатой пристани, как большая корова, мычал и вздрагивал, хлопал почем зря крылатым колесом по воде. А посерёдке реки шла тёмная, покорная баржа за плюгавым буксирчиком, тихая, крадущаяся, увешанная бельем на веревках, как самый настоящий дом на волнах. Кричали, нет, тонко повизгивали чайки. Вода гладко бросалась на берег и шипела. Над всем этим огромным хозяйством переговаривались гудки и гудочки. Суета на берегу была какой-то праздничной, люди как будто показывали друг дружке зубы: погляди, зубы мои могут и проволоку перекусить, я всегда веселый и ни на что не жалуюсь! Бочки, канаты, тросы, бревна, прогибающиеся доски, – все это двигалось, смещалось, звучало голосом, скрежетом, пересвистом... Потом всем этим разноголосьем наполнятся мои книги, в них войдут и птицы с густыми крыльями, и ржавые цепи лодок, и нескончаемый гомон-перекличка, и снующие люди в неописуемых одеждах –грузчики, рыбаки, ротозеи. Подброшенная охапкой вся живописная картина берега! Жарко дышащая волна побережья бежит перед глазами –и как поместилась! – текучая взблескивающая, как битое стекло, одушевленная могучим горловым голосом, широкогрудая, с крепким запахом, принадлежащим только Волге, ее крутому замесу жизни... И рядышком я со своим красующимся цветным лаком барабаном!

Поразила меня вереница корзин на коромыслах, точно зависшая на сходнях – тяжелеющая на глазах череда хлопочущих, раскрыливших руки женщин, издающих странные звуки гусынь. Они плыли и плыли, выплывали, возникали из трюма, переваливались на сходни семенящими шажками, – их принимал берег, но они, не ломая цепочки, продвигались дальше вглубь, обтекая ряды бочек, в безостановочном движении сохранить целенькими корзины до трамвайной остановки, а там уж отдышаться, успокоиться. – Корзин-то! Коленки подгибаются. Куда столько?

– На базар, – сказал Фарид. – Помидоры, огурцы, яблоки, ягоды. Ешь не хочу! И цыплят везут, и несушек с яйцами. Оглохнешь!

– Откуда везут?

– Деревень по реке не пересчитаешь. Ле-ето! – пропел Фарид. – Теперь каждый день – лето. Складывай в корзины и тащи. Бабам всегда тяжело, – по-взрослому сказал Фарид. – По Волге больше русских. Опустошат корзины и опять на пароход. Часа за два управятся и отдохнут заодно.

– Продадут?

– Чего же еще. Не зыркать по сторонам. От вишни разве откажешься?

– Я бы таз съел!

– Значит, корзину.

– Вдвоем бы и с ней сладили.

Мы стояли у самой кромки воды с красивым барабаном, счастливые, голодные, босые,

надышавшиеся свежим ветром, который у Волги необычайно пахнет рыбой. Я сжимал в кулаке палочки, запасные были спрятаны под ремнем.

Я прочитал про великую реку множество книг, но в грудь мою, в глаза мои, в уши мои она входила в первый раз. Так вот ты какая, матушка-река! От берега до берега глазом пройдешь, как посуху, а руками ослабеешь, если представишь, как пересилить ее волну заносчивыми саженками.

Много я успел прочитать – и про чаек, живущих между небом и рекой, и про ласточек-береговушек, не уносимых ветром от обрыва, и про клады зарытые – поди их отыщи! – и про Каспий, к которому тянется через тысячелетия эта голубая жила, и про бурлаков, бредущих с песней-стоном. Читал, но не видел ее в работе. Она то сжимала, то разжимала руки.



Пейзаж. Гариф Ахунов рәсеме

С четвертого класса я уже писал стихи, составляя слова лесенкой. Рисовал акварельными красками родную деревню Училе с ее взбалмошными собаками, злыми гусаками, вытягивающими шеи, чтобы ущипнуть клювом за штаны. Рисовал все подряд, что подхватывал взглядом, и волновался при этом необыкновенно – зимой и летом, на весенних проталинах и под осенними листьями. Снежные бабы на моих листках не таяли, собаки навечно оставались с задранными хвостами. Я привык помаленьку опережать время... Но вот к удивительно маленькой, всего-то в чертову дюжину домов, деревеньке Кечкене Училе (крошечной Училе) подошла близко, будто приобняла рукой, огромная, из камня и дерева, Казань, задребезжала красным трамваем, подкатилась волжской волной к ногам, аукнула по лесам-долам бархатистым басом парохода, повела по длинному ряду магазинов, где столько замечательных вещей, для каждого пришельца хватит обуться-одеться, позабавиться, – чего один барабан стоит, разрисованный такой краской, что ее лизнуть хочется... Вот какой ураган пронесся перед моим зачарованным взором, подхватил, подбросил меня на ладошке вихрем так, что я зажмурился...



Г. Ахунов рәсеме

– Пора возвращаться, Гарифзян! – Кто это сказал? Ах да, Фарид! – Отец рассердится. Где шляетесь, бездельники, закричит. Вот и вечер наступил. Солнце на Маркиз-остров садится. Коней с лугов пригонять надо.

И когда день успел остыть? –

Подожди малость,– попросил я.

– Ты что! –вскинулся Фарид, глаза его стали круглыми.– С голодухи живот провалился. Везде тебе надо сунуть свой нос. У меня уже ноги отваливаются. Еще насмотришься, успеешь.

Тогда и я почувствовал, что под ремешком пустота.


«Кояш баеганда». Г. Ахунов рәсеме

Напрямую, ускоряя шаг, между Устьем и алебастровым заводом – мы вышли на луг к пасущимся лошадям. Я их насчитал штук двадцать – обычных, ничем не отличающихся от деревенских, лошадок, и городских –ломовиков, у которых одно кольцо величиной с тарелку. Тяжелое кольцо, и от земли-то оторвать, как гирю, трудновато, наверное.

– Зачем заводу лошади? – спросил я Фарида.– Не скакать же?

– Известь возить,– сказал он просто, будто отмахнулся от мухи. Всего на год старше, а то-то же зазнается, вот дела: городской.

Пришлось побегать, погикать, пока не загнали лошадей в конюшни при заводе. От них шел сытный пар. Легонький барабан мало-помалу натер шею. Брат отца, Асат-абый, тут был хозяином при копытах. Он раскладывал по кормушкам мягкое сено, не торопился, был немногословен... Если задуматься, у него в деревне был светлый дом из смолистого соснового дерева, с резьбой, с просторным двором, где помещались и лошади, и коровы, каждая побольше телеги, а уж кур-гусей сразу и не заметишь, мелькают по углам, и пускай. При дворе хозяюшка-жена, ловкая, быстрая, опрятная, всегда при белом платке. Как ни посмотришь, все домашние чем-то заняты. И это хозяйство одним махом разграбила деревенская беднота: дескать, кулак – и поделом тебе. Наиболее сноровистый старший сын Габдулла, почуяв неладное, первым сорвался в Казань и прилепился к пекарне. Потом, застолбив место, перевез к себе целиком куст семьи до малого корешка. Дети оказались упорными, цепкими: Сарвар устроилась на скотобойню, средний сын приторговывал из-под полы. Не голодали больно-то, не нищенствовали. На всех хватало то коровьей головы, то потрохов, то свеженького каравая с мельничный жернов. Нужда сплачивала, а не отталкивала друг от дружки – за столом было тепло, сытно. И для деревенских гостей находилась постель... Тем и распахивалась передо мной Казань то Волгой, то семейным ладом. С одной стороны – гляди на белый пароход, оплескивайся незатихающим шумом-гулом пристаней, с другой – восхищайся спокойным лицом семьи, ровным ее дыханием. Не отбросила громадная столица обиженных детей, дала приют, обогрела, защитила стенами. Я слышал, как вечерами люди нашей деревни, что постарше, пели:

*Город Казань – каменный город.*
*Голова городов.*
*После отца сильный сын*
*подрастает в работе.*

Мне так и казалось, что это поется о нашей семье и дорогом родственнике Асат-абые… Асат-абый лет через пять умер, но дети уже были закреплены на земле, а не раскиданы по свету. Прижились в слободах, построили свои дома. Но мне еще предстояло, только предстояло совершить настоящий свой путь по Казани, приобрести походку. Пока же я лишь наведался, стал ее гостем. И все-таки первое воспоминание-причащение самое драгоценное.

На другой день Фарид обещал показать мне город. Почистили себя, как могли, и двинулись. А перед этим Минзифа-джинги заговорщицки подманила нас пальчиком и сказала певуче, с расстановочкой:

– Вот тебе три рубля, раз! Вот тебе три рубля, два!

Прямо-таки песня сложилась, потому и запомнилась на долгую жизнь. Почаще бы слышать ласковое напутствие. А потом добавила:

– За вкусные сладкие ягоды, которые вы собрали в нашем училинском лесу. Таких ягод нигде больше нет, на языке тают.

Всю дорогу щекотали ухо ее слова, никуда не уходили.

Сели мы в трамвай № 1, покатили на колхозный базар: шел трамвай от Устья до вокзала. У алебастрового завода люди «голосовали», и трамвай со звонком останавливался. Это был какой-то торжественный ритуал – приглашение к путешествию, уважительный поклон рабочему человеку. Остановка «До востребования»,– сообщил мне Фарид.– Зря ты барабан оставил дома, постучал бы палочками.

Я понял происшествие так: везде, стоит только поднять руку, всплеснуть ладошкой – и трамвай обязательно плавно прекратит свой разбег. И вот мы на рынке, как раз среди тех бесконечных корзин, которые «всплывали» из трюма парохода под крыльями рук, прикрытые тряпицами. Теперь они были открыты. Фарид купил два крупных красных яблока, душистых, блестящих на солнце кожицей. Если в наш дом попадало яблоко, мать резала его на кусочки и раскладывала по чашкам. А тут мне одному яблоко в два кулака – не жалей зубов, Гарифзян! Я рассмеялся.

Базар был праздником, скороговоркой, гостинцем.

Насладившись зрелищем –топ-топ, топ-топ! – мы вышли на улицу Баумана. Где мы только не побывали! По-хозяйски обошли магазины, посмотрели в кинотеатре «Унион» какой-то фильм. Я и прежде раза два смотрел кинокартины, но здесь всё было по-другому – чистенько и аккуратно, никто не крутил ручку аппарата, да и лента не обрывалась. Зрители сидели примолкшие, сразу было ясно, какие в городе воспитанные люди.

Впечатления распирали меня: я всех-всех любил, сердце моё увеличилось, щеки горели, в голове стоял звон. Пока мы поднимались в гору, я говорил, говорил, говорил, как заведенный, а наверху даже задохнулся и беспомощно-тихо хватал воздух ртом, словно по кусочку откусывал от неба. Далеко-далеко за крышами виднелась Волга.

Подошли к белым колоннам.

– Это – университет,– сказал Фарид.– Здесь учатся тысячи студентов. И как они там помещаются? Но толкаться здесь нельзя.

Я ему поверил. Ведь всего одна девушка из казанбашской школы «протиснулась» в химико-технологический институт. Весь Казанбаш переволновался из-за этого грандиозного события, целую зиму под печными дымами, заваленный по уши снегом, обсуждал-рядил, как такое случилось.

Не помню, где мы еще плутали: голова человека – дырявый мешок, чтобы получить повое –теряет старое, сбереженное только до поры. Конечно, больно ценным не кидается направо-налево, но протухнуть «товару» не дает.

Перемигнулся я с повисшими в воздухе огнями за трамвайной линией – город как буд-

то подбросил их, а поймать забыл –забрал свой роскошный барабан, связал бечевкой палочки, попрощался с родственниками и рано утречком поехал на вокзал, предвкушая встречу в Кечкена Училе. Я уже тогда понимал, что от встречи к встрече складывается жизнь, точно так же, как кирпич к кирпичу растет печь. Ах, с каким барабаном я возвращался в деревню!..

Через два года я снова ступил на непотускневшие следы проторенной тропки. На сей раз я сам был поводырем. А произошло это так. В деревне Казанка, совсем поблизости от нас, у истока речки Казанки, жила сестра моего отца Малика-апа. Что ее отличало от других? Она была подвижная, как веретено, насколько сухая, настолько же скупая –пообещает сто раз, но ни разу не одарит безделицей. Детское сердце тут и трепыхнется, а взрослому – пустяк.

Так скупилась-то она, наверное, оттого, что вся сила ее ушла в бицепсы: вот какая я сильная, об обещанном помнить не хочу! – стучала мысль, на мужичий колхоз одна бабья управа! Двадцать лет с ней никто не мог сладить на колхозных соревнованиях. Поглядят на ее мускулы и тут же сдаются: жилы да яблоки вздувались под ее кожей. Через это она и забывчивая на всякие обещалки, прохудилась память. Убей, не вспомнит дороги в Казань, по которой бегала-перебегала к брату своему Асату. Все ручьи из головы утекли в мышцы. Ну, и упросила мою мать отпустить меня в Казань как сопровождающего. А у меня глаз что алмаз: один раз был в городе, а каждый поворот запомнил накрепко. Я Малику-апу не то чтобы довез, а быстренько довел до знакомых ворот по трамвайной линии. «Красный дилижанс» не ходил, вот какая штука! Показал я рукой на завод «Известь-алебастр»: пожалуйста! Махнул другой – и ворота на виду! Малика-



Алар бер төркемдә укыганнар: Гариф Ахунов – өченче рәттә уңнан дүртенче, Шәһидә Максудова – икенче рәттә өченче, Аяз Гыйләҗев – беренче рәттә икенче. Казан дәүләт университеты, татар филологиясе бүлеге. Казан, 1950



Гариф Ахунов әдәби түгәрәк утырышында (уңнан кырыйда утырган). Казан дәүләт университеты. Казан, 1951

апа, конечно, ах-ах, сама, мол, догадывалась, с паутиной сомнений боролась... В городе у нее были дела наиважнейшие, и потому везла она десять фунтов масла и ведро яиц. Я помог ей спровориться с грузом, за что она пообещала, не знаю в который раз, напоить меня «красной водичкой» –морсом. И ведь опять не исполнила своего слова! Я уж и рот вытирал старательно, чтобы она приметила, за чаем. Намекал, так сказать. Впустую! Ох, я и обиделся, с ходу губу прикусил от досады, чтобы не крикнуть: выполняй, и точка! Стыдился я просить у людей, а тем более покрикивать на таких беспросветно забывчивых... О другом я, о другом. Малика-апа только присказка.

К тому времени я прочитал «Неотосланные письма» Аделя Кутуя, «Сплав» Гумера Баширова, «Агидель» Мирсая Амира, пьесы Тази Гиззата. Увидеть бы кого-нибудь из них, писателей, людей совершенно особенных – ух, здорово было бы! Невероятно сильным было желание глянуть хоть краешком глаза на Мирсая Амира. Судьба его героев пересеклась с моей судьбой, пусть пока ещё не до конца осознанной, – однако главная косточка уже хрустнула. Я плакал, не спеша переворачивая страницы. Не все слезы вытекают, горчайшие остаются под веками. Уж я бы нашел что сказать писателю, уж я поведал бы ему о сокровенном, о чем и ночью-то проговаривал шепотом, прожигая глазами мрак –молился ли я, давился ли вздохом, кому знать об этом.

А тут вдруг старшеклассник Рамазан Салихов, круглый пятерышник, притянул меня к выпуску стенгазеты. И откуда прознал о тайных муках – и стишки-то я пописываю, над рассказами задумываюсь, к тому же я красками малюю что-то неописуемое... Словом, клад, находка, не находящая применения, сирота училинская, которой по окончании четверти то кепку подарят, то рубашку, то акварельные краски с цветными каран-

дашами – мажься на здоровье! Однажды встретились на улице в деревне Кетек, где жил Рамазан,– он пригласил меня в дом, посидим, мол, за чайком, потолкуем... Он тоже без отца, четверо детей при матери. Нет, пятеро – три девочки, два мальчика. А дома нищета с бедой на лавке. Зато на стене самосколоченная полка с книгами и портреты писателей – Тукай, Такташ. Еще один с носом-клювом, как у синицы, с маленькими глазками. Так и просверливает насквозь, так и просверливает.

– Этот на птицу похож,– сказал я.– Кто такой?

– Поэт Шайхи Маннур. Я с ним повстречался в городе, как с тобой и Кетеке. Говорю: – Вы поэт? Он удивился:

– Откуда тебе это известно? Я ему отвечаю, не моргнув: – Я ваш портрет три раза рисовал! Повел он меня в книжный магазин, подарил свою книгу. Потолковали мы с ним запросто. Из каких я мест, зачем приехал. Я малость вспотел, но ничего, не ударил лицом в грязь перед орденоносным поэтом,– рассказывал Рамазан.– Он из длинного мундштука курит, долго курит. Пока дымил, разговаривали. В Казани поэты по главной улице ходят с утра до вечера.

– Ходят, ходят, а когда пишут? –изумился я.

– Ночью! –твердо сказал Рамазан.– Вдохновение у них по ночам.

– Мне бы Мирсая Амира повидать,– размечтался я.

И что же вы думаете?! Доставил я Малику-апу с маслом и яйцами к брату, и тут выясняется, не надо мне искать-рыскать на главной улице. Здесь он, скоро появится под этой самой крышей, где пригрелся в уголке я. Он, муж дочери Асата абый Сарнар – Мирзаянов Амир! Разве мог я додуматься, что яблоки с неба скатываются. Трогательная у нас вышла беседа.

– Вы Мирсай-абый Амир? – захлебнулся я.

– А ты что же, не спишь, не ешь, а тоже хочешь стать писателем?

– Получилось бы,– сказал я скромно.

– Тогда трудись, сынок.


Пошли и мы в книжный магазин. Штук пять подаренных книг я привез в Училе с сильно забившимся сердцем. Неужто мог я, распалившийся, знать, что и шайтан иногда усмехается жалеючи, шутит... Седой человек не был писателем, но он был мудрецом, поддерживающим огонь перед наступающими холодами. Мальчишка! Где мне было присматриваться да прислушиваться! Я бы в один момент понял – передо мной сидит, не пряча темных рабочих рук, крестьянин-землепашец-скотовод, кто угодно, а прежде всего – спокойный добрый человек Мирзаянов Амир. Он глядел в потрескавшееся зеркало моей души, тайно любуясь моим невозможным желанием, наслаждаясь жаром детского порыва. И... чуть-чуть слукавил, подправил фитилек, чтобы выпрямить пламя...

А с подлинным Мирсаем Амиром я познакомился, когда стал студентом Казанского университета. Много позже моя жена подарила писателю гладиолусы – принял их в руки, окунулся лицом в соцветия и сказал:

– Шагида, с цветами человек не помнит о старости. Дай мне, пожалуйста, еще несколько штучек для жены. И ей будет радость.

Как хорошо умеют люди улыбаться! Пожалуй, улыбка, как всплывающая из глубины рыба, освещает озеро жизни...

Торопится мое перо опередить время. Сколько событий проносится перед моим взором, обжигая веки. Серые осенние эшелоны. Лица, лица, лица. Их заносит жестким снегом, поглощает, покрывает холодом забвенья. Но вихри и смерчи сходят клубами, рассеиваются, расшибаются вдребезги, оставляя бугры могил, руины, печные остовы на месте домов, скелеты церквей, мечетей, потоки людей-беженцев повергаются в прах.



Гариф Ахунов ял вакытында: яраткан шөгыле – рәсем ясау. Казан, 1998

Человеческое море волнуется постоянно. Редко тишь да гладь охватывают простор, услаждают слух и зрение. На то и жизнь, на то и жизнь! – звучит рефреном... Я умышленно миную череду оврагов, омутов. О каждом надо отдельно, обстоятельно, по канве опаленной жизни. Но я словно неожиданно оказался на спине скакуна –и понеслось, замелькало. Я хочу осмыслить, как я стал казанцем, как разомкнулось для меня кольцо города, впустило и откинуло, приветило и омрачило. Нет, душа не знала черного омрачения, она рвалась куда-то за пределы, через горести и печали. И я выстраиваю лишь тонкую, легко разрываемую цепочку на поверхностный взгляд малозначительных приключений мальчика-подростка-мужчины. Ибо здесь лежат глубинные концы узлов, в замкнутом клубке, казалось бы, нерасторжимом. И они видны мне, эти концы, за гибкими переплетениями, перехлестами. Тесно увязаны жизненные тропы, не оборвешь опрометчиво.

От повисших в воздухе огней, от незамысловатого счастья быть обладателем барабана с гладкими круглыми палочками, от раскатанной по земле тяжелой воды Волги – я выхожу, возвращаюсь непременно к полю, лугам. От белых стен Кремля и красного многоярусного силуэта башни Сююмбике мой взгляд притягивает тихо убегающее к горизонту раздолье.

Тяжесть жизни ощущает сидящий, идущий же – обретает легкость, распрямляя тело. Он несет на себе луч солнца, как вестник. Да, была нужда, было лихолетье, много нужды, горы лихолетья, буреломы, завалы, отчаянье. Скажи: пройди снова! А ну-ка, попробуй!.. Искренне отвечу – покажется, не осилю, да и невозможно осилить, не стожилен

человек. А по правде-то говоря, хотелось бы окунуться с головой в невероятное. Не повторить, а – возвратиться. Прежняя, былая сила потрачена без сожаления, потому и приметен где-нибудь на свободном предзимнем берегу вывороченный, вздыбленный корнями кряж...



Гариф Ахунов һәм Шәһидә Максудова. 1996

Поспевая к молодости, мы – тридцать три студента – кончали Арское педучилище. Жили в колхозных бараках совхоза «Урняк». Шел сорок седьмой, трудный, послевоенный год. Освободилось помещение госпиталя для немецких военнопленных – переехали туда, в Арск. Ели мерзлую картошку, несколько капустных листков плавало в супе. Хлеб прилипал к пальцам. Деньги были дешевле нынешних. Пятидесятиграммовый кусок волжской рыбы стоил на станции восемьдесят рублей. Нас готовили учителями для начальных сельских школ. Сухопарые, звонкие, мы не имели того, что мешало бы в пути. Лишний вес нам был противопоказан. Джигит держится за воздух, так смеялись мы, принимая дипломы. Куда податься дальше? В университет? Но прежде надо было написать хотя бы на тройку изложение по-русски. Из 33 студентов 6 получили двойки. Это произошло до получения диплома. На сером фоне Яхья Халитов и я выглядели молодцами-ударниками, и, слегка посомневавшись в выборе; пединститут, худучилище? – в окончательный срок ступили на мраморные ступени университета...

Студенческие годы – лучшие годы, принято говорить. Но розовым бочком время не торопилось к нам поворачиваться. Куда спешит путник, знает дорога. Изворотливым я был, а иначе – плюнь да утрись. Выписывал на картине гибкошеих лебедей, озера с камышами. «Творения» продавал на базаре. Летом возвращался в Арск и трудился маляром, чтобы и самому приодеться, и помочь матери, работавшей за «дырявые сотки». С четырнадцати лет я обеспечивал себя сам – вот он, мой путь в Казань. Пахал, сеял, художничал. И – постигал.

Мировая, ни меньше ни больше, литература открывала передо мной свои кованые сундуки. А своя, родная, терпела бедствие.

Нас обрубали, отесывали, и это становилось нормой – укоротить со всех сторон. Да, живучесть была такой силой, которая вышибала любые пробки.

С того давнего дня, с моего первого подарка большого города деревенскому мальчику – барабана, я, теперь уже казанец, берегу в душе хрупкие палочки. Ах, как он звучал, мой барабан, в зеленом Училе. И посейчас я слышу дробный бой на краю поля.

И в минуты-часы угнетенного настроения я беру за руку десятилетнего барабанщика, и мы совершаем спасительную прогулку по казанским взбегающим улицам. Жизнь, потерявшая было звуки и краски, вновь обретает чистый тон и акварельные цвета.

*Перевел с татарского Рустем Кутуй*

***Гариф Ахунов***

# Беренче-тойгылар

Мин мәхәббәтемне университетта таптым. Ул заманаҥың авыр елларына туры килде. Никадәр генә кыенлыклар кичермик, без беркайчан да борын салып йөрмәдек, мең төрле хыял, мең төрле ашкыну белән янып, ялкынланып яшәдек. Ә хыялый ашкынулар, сагыш һәм өметләр күңелеңә ятышлы берәрсе булганда гына була бит ул.

...Университетка керү өчен имтиханнар тапшырып йөргән чагында, минем күземә дулкынланып торган кара чәчле, шәрык кешеләренәрәк охшаш түгәрәк каратут йөзле, күперенке алсу иренле бер кыз чагылды. Мин аның чәчрәп дулкынланганын да, кайгырып «аһ» органын да күрмәдем. Имтиханнарын тигез генә биреп бара, үзен сабыр-тыныч тота, әмма аның бераз шешмәгрәк кабаклы коңгыртмы-яшькелтме күзләрендә йөрәккә ут сала торган бер көч тә бар иде.

Имтихан тапшырачак аудитория ишеге төбендә күренүгә үк, ул минем күңелемне кузгатты. Мин, әлбәттә, аңар бу хакта бер генә сүз дә әйтмәдем. Әйтә дә алмый идем. Аның зифа гәүдәсенә ятышып торган көрәнсу-кызгылт төстәге путалы күлмәге дә, иңнәренә сибелеп киткән куе кара чәче дә, матур төз аяклары да, үзен искиткеч сабыр һәм тыйнак тотуы да – авылдан килгән тотанаксыз бер малай өчен түгел, шәһәрдә үскән зыялы кешеләр өчен яратылган кебек иде.

Дөресен әйткәндә, мин аңар нәфсемне сузарга батырчылык та итә алмадым. Аннары ул мине бик әллә ни санга да сукмады шикелле. Ләкин җанны бимазалап торган газаплы-татлы тойгы әле һаман миндә яши иде. Мин әлеге кызның – Шәһидә Максудованың Чернышевский урамыннан (хәзерге Кремль урамы) барганын, зур матур бер йортның парадныеннан кереп киткәнен ике-өч мәртәбә күреп калдым.

Күңелдә бик азга гына: «Әллә, Ходаем, ул да мине күзәтеп йөриме?» – дигән ымсыну сыман бер тойгы уянып алды.

Тик тагын бер атнадан, мин аны очраткач, әлеге тойгы челпәрәмә килеп, җилгә очты.

Мин, карточкага алган ипигә һәм студентлар ашханәсендә ашаган ашка гына риза булмыйча, кибеткә кереп, бер ярты кило прәннек сатып алдым. (Арча педучилищесын тәмамлагач, шул ук училищены буяган өчен, җәен бераз акча эшләп алган идем.) Беренче прәннекне авыз тутырып чәйнәп кайта идем, әлеге кыз парадныйдан чыгып килә. Чәйнәлеп бетмәгән прәннекне көч-хәл белән йотып җибәрдем дә сүз куштым:

– Нәрсә, Максудова, китапханәгә барасың мәллә?

– Ийе шул, – диде кызый, мөлдерәп кенә миңа карап алды. – Университет китапханәсенә барам, әйдәгез, минем белән барасызмы?

Сөенечемнән: «Барам!» – дип чак кына кычкырып җибәрмәдем.

Киттем мин моңа ияреп. Кердек университет ишегалдындагы китапханәгә. Максудова анда беренче көннән үк язылган икән инде. Миңа язылу тәртибен өйрәтте, һәм без, аның белән икебез, кирәкле китапларны алып, өстәл янына чүмәштек.



Гариф Ахунов белән Шәһидә Максудова. 1951

Утыру белән, ул китабына кадалды. Мин дә бераз вакыт укыган сыман кыландым. Минем күңелем китапта түгел иде шул. Яннан кызның профиле матур булып күренә: кара тутлы, алсуланыбрак киткән битләре, китапка төбәлгән күз карашлары мине яндыра иде. И дә теләп карадым соң мин аның миңа сүз кушуын. Ләкин ул китабына багынды да калды. Күтәрелеп тә карамый, сүз дә кушмый. Ахырда мин түзмәдем:

– Нәрсә, Максудова, әллә бик кызык җире туры килдеме? – дидем.

Бик беркатлы, үтә дә беркатлы, «ата казың күкәй саламы?» дигән сымаграк сорау иде бу. Кызый минем сорауны колагына да элмәде, сәерсенеп бер күтәрелеп карады да тагын үз дөньясына чумды.

Минем дә үз горурлыгым үзем белән иде. Тәмәке тартып керәм әле дигән сылтау белән мин аның яныннан кузгалдым да бүтән әйләнеп кермәдем.

Ул елны мин дүрт-биш ай китапханәгә бармадым. Аның очравыннан, арттан йөри бит, мәнсез, дип әйтүеннән курыктым. Өченче курска җиткәнче, без аның белән аңлаша алмадык.

Һәр елны без Октябрь бәйрәмен, Яңа елны, Беренче Майны группабыз белән җыелып, бергәләп бәйрәм итәбез. Шул бәйрәмнәргә дип, мин бер ак күлмәгемне саклап тотам, олтаны куба башлаган ботинкамны стипендиямнең соңгы тиеннәренә яматып алам, ә җанның иң ачыттырганы – бәйрәм саен Максудованың җылы карашын таймый кайтып китү.

Без группада сигез егет, биш кыз. Миңа калса, биш кызның бишесе дә бер егеткә – Уфадан килгән, урысчаны да, немецчаны да су кебек эчә торган, тик татарчаны гына сакаурак сукалый торган кара бөдрә чәчле, горур табигатьле Роберт Бикмөхәммәтовка гашыйк иделәр. Ул үзен бәйсез итеп тотуы белән дә, имтиханнарын гел «бишле»гә



Шәһидә Максудова. 1944

генә биреп, исемле стипендиат дәрәҗәсенә күтәрелүе белән дә безнең кызларыбызның күз явын алып тора иде. Хәер, Максудова да имтиханнарын «бишле»гә бирә, Тукай стипендиясе ала иде.

Бәйрәмнәр искә төшсә, гел тынычлыгымны җуям мин. И матур да була иде соң ул бәйрәмнәр! Без, бер-беребездән күрмәкче, рәхәтләнеп җырлыйбыз, рәхәтләнеп биибез, гадәттә аз сүзле Шәһидә дә мәҗлес барышында җанланып китә. Шуннан без «Галиябану»ны, «Сарман»ны, «Зөләйха»ны, Гамир Насрыйның «Алтын көз» музыкаль драмасыннан кайсыдыр арияләрне, тагын бик күп, бик күп җырларны җырлап чыгабыз.

Безнең кызлар – Шәһидә, Сания, Розалина, Резеда, Әлфия – тәмле-тәмле ризыклар пешерергә, табын әзерләргә, безгә фатирларын ышанып калдырган хуҗаларның өен матур итеп җыештырырга сәләтле, кыскасы, «кулларыннан гөл тама торган» кызлар иде.

Мине озак вакытлар санга сукмый йөргән Шәһидә Максудованың да көннәрдән бер көнне күңел гөле бөреләрен ачты. Ул хәл өченче курсны тәмамлагандарак булды шикелле. Май бәйрәменә атап үткәрелгән мәҗлесебездә Шәһидә фронтта һәлак булган шагыйрь Фатих Кәримнең «Кемгә сөйлим серләремне?» дигән шигырен укыды. Шактый ук каушап, дулкынланып укыды ул аны. Ө без фәкыйрегез:

*Кемгә сөйлим серләремне,*
*Йөрәгем ялкын кебек,*
*Ялкынланган йөрәгемә*
*Берәү бик якын кебек,* –

дигән сүзләрне үз исәбенә алып куймасынмы!

Кичен, мәҗлестән таралгач, тулай торакның аулак бер почмагында, тәрәзә буена сөялеп, чын ахмаклар хәленә калып каушап, Гариф дигән егетебез үзенең кайчандыр Шәһидә дигән кызга муеннан гашыйк булганын, шул хисне әле дә җанында саклап йөргәнен әйтеп салды да, өстеннән таулар төшкән кебек, тирән итеп сулыш алды.

Әнә шуннан башланды аларның бер-берсен күргәч каушаулары, семинарларда сөйләгән чакта, бер-берсе өчен ут йотып утырулары...

1951 елның сентябрендә без өйләнештек. Икебезнең дә әтиләр юк. Минем әтине, колхоз рәисен, кулаклар яллаган бандит пычак белән кадап үтергән, Шәһидәнең әтисе, мулла кеше, Совет хакимиятенең мыскыллауларына түзә алмыйча, балаларын Себергә сөрүдән саклап, үз-үзенә кул салган. Шунлыктан без өйләнешергә рөхсәтне иң әүвәле Шәһидәне карап-багып үстергән җизнәсе Хәсән абый белән апасы Маһирәдән алдык, аннары Арча ягына – Кечкенә Өчилегә кайтып, минем әни Бибинурның фатихасын сорадык.

Инде менә, шөкер, 47 ел бергә яшибез. Бер малай, бер кыз үстердек, өч оныгыбыз бар. Гаиләдә табак-савыт шалтырамый тормый – андый чакта бер-беребезгә юл куярга тырышабыз.

Халыкның бик акыллы мәкале бар: ирне ир иткән дә, җир иткән дә хатын, ди ул. Мин язучылыкта кырык елдан артык эшлим инде, бик күп җитәкче урыннарга сайландым, дәрәҗәле исемнәр алдым. Шуларның яртысы үз хезмәтем булса, яртысы – Шәһидәнеке. Җәмәгать эшлеклесе буларак, ярты гомерем читтә узды. Балаларны да Шәһидә карап үстерде, оныклар да аңа сыена. Минем каләмдәш дусларым Шәһидәнең дә дуслары булды. Өйгә кайчан гына, күпме генә дусларымны алып кайтсам да, ул караңгы чырай күрсәтмәде, берсүзсез табынны әзерләп бирде.



Гариф Ахунов. Эрот Зарипов рәсеме

Менә шуңа күрә мин үземне бәхетле кеше дип саныйм.

Яшьлек – кеше гомеренең иң матур, иң кадерле чагы, һәркем яшьлеген яшьлеге узгач сагына. Әйтергә теләгәнем – яшьлекне һәркемгә дә матур итеп сагынырга язсын иде. Моның өчен адәм баласына тик бер генә нәрсә кирәк – гомер юлдашыңны дөрес сайлый белү.

Озакламый, тагын өч елдан, без алтын туебызны үткәрергә тиеш. Ул заманда да икебез дә исән булып, тигезлек белән, муллык белән, каләмдәш дусларыбызны чакырып, гөрләтеп туй ясасак иде, яшьлегебезне бергәләп искә алсак иде.

Тормышта без Шәһидә белән авырлыкны күп күрдек, әмма дөнья малына кызыкмадык, зиннәтле фатирларда яшәмәдек, авырлыкларны бергәләп җиңдек. Хатыныңның фикердәш тә булуы – икенче бәхеттер. Безнең гаиләдә биш язучы бар – мин, Шәһидә, улыбыз Рәшит, кызыбыз Наилә, киявебез Борис. Бу – сирәк очрый торган уникаль күренеш. Мин моны өченче бәхетебез дип саныйм.

Мин халык җырларының кәттәләрен җыярга яратам. Узган гомеребезне искә төшергәндә, күңелемнән шул җырны көйләп йөрим:

*Урманнарга керсәң, сызгырып кер –*
*Сискәнмәгән кошлар калмасын!*
*Дөньяларда шундый итеп яшә –*
*Сокланмаган дуслар калмасын!*

*1998, март*

***Гариф Ахунов***

# Автобиографик-хикәяләр

Әдәби кичәләрдә, китап укучылар конференцияләрендә яки матур әдәбиятны яраткан аерым укучы белән очрашкан чакта, бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган берничә сорау бирәләр:

– Кайда, кайчан, ни өчен тудың?

– Ничек язучы булдың?

– Язучылык һөнәренә өйрәнеп буламы?

Зур сораулар. Бер генә язучының, бәлки, җавап биреп бетерүе дә мөмкин түгелдер. Аннан соң, бер язучының әдәбиятка килү юлы икенче язучыныкына охшамый да бит әле. Мин байтактан бирле каләмдәш иптәшләрем һәм өлкән язучылар турында язмалар алып барам. Кулыма каләм алганга егерме биш ел тулган көннәрдә әнә шул язмалардан берничә бүлекне укучыларга күрсәтеп карарга җөрьәт иттем. Әгәр бу язмалардан югарыда куелган сорауларга берәрсе азмы-күпме җавап таба алса, шат булыр идем.



# *Җуелмас яра*

Татарстанда Тукай Казан арты дип билгеләгән бер як бар. Себер тимер юлы белән Казаннан алтмыш чакрымнар киткәч, Арча булыр. Автобуска утырып, шул чама баргач, Кенәрләр, Әтнәләр булыр. Әнә шул инде ул Казан арты. Дан булып җырларга кергән Иделләре, Агыйделләре, Чулманнары да юк аның, көмеш күлләре дә күренми. Әмма урманнары бик матур, кешеләре киң күңелле. Булдыклылык, тырышлык дисәң, аларга тиң бар микән?! Нәкъ Казан артында, Арча белән Балтач арасында, тау башына менеп кунаклаган унөч кенә йортлы Кечкенә Өчиле авылы бар иде. Өч йөз ел буе яшәп тә унөч өйдән артмаганга, кешеләр аны «шүрәле каргаган» дип йөртәләр иде. Әнә шул Кечкенә Өчиленең урта хәлле крестьяны Ахунҗан гаиләсендә өченче бала булып мин дөньяга килгәнмен.

«Ачлык елдан соң дүрт ел үткәч, бәрәңге алганда тудың син, балам. Әтиең, син тугач, ак күлмәкләр тектерде», – ди торган иде әни. Бәрәңге алганда дигәне 1925 елның 18 сентябре булып чыкты.

Әти-әнием минем дөньяга ир малай булып тууыма сөенгәннәр сөенүен, ак күлмәкләр киертеп, курчак-бәби итеп тә йөрткәннәр, ләкин мин үзем әти-әниемне сөендерергә ашыкмаганмын. Нечкә сыйраклы, дәү корсаклы чирләшкә бер малай булып үсәм икән. Бер ел тулар-тулмастан сеңлем Саҗидә тугач, мине имидән аерганнар. Сөтсез яшәүдән мин бөтенләй кәеккәнмен. Үлем фәрештәсе минем баш өстендә канат кагып тора башлаган. Күрсәтмәгән врач, өшкертмәгән ырымчы калмаган – берсенең дә файдасы тимәгән. Шуннан әни үзе тотынган. Дөньяда бик күпне күргән, авыру ирен үләннәр белән дәвалап аякка бастырган күрше карчыгының киңәше буенча, бик кызу мич яккан, күмерен алып, мичне томалаган да мине, ипи көрәгенә утыртып, мичкә тыгып «җылытып» алган, аннары сеңлем белән икебезне ике тезенә утыртып имезә башлаган. Ана кулыннан да шифалы, ана күңеленнән дә җылы тагын нәрсә булуы мөмкин? Шуннан мин тернәкләнеп киткәнмен. Һәм менә бүген, хөрмәтле укучылар, сезгә шушы сүзләрне сөйләр өчен исән калганмын.

Боларын мин ишетеп беләм.

Дөньяны аңлый башлагач алган беренче ярам – әтисез калу. Әтиемне авыл кешеләре әле дә сагынып сөйлиләр. Тәбәнәк буйлы булса да, төптән нык булып үскән бик гайрәтле кеше иде, диләр. Авылда ул беренче коммунист була, Өчиледә колхоз оештыра. Аның, урта хәлле крестьянның, коммун булып китүе Сукыр Аптул белән бәйле. Бездән өч кенә чакрымда Казанбаш исемле авылның «ата пролетары» Габдулла Заһидуллин Донбасс шахталарын айкап, дөньяның кая таба барганын тоеп кайта. Минем әтине үз юлыннан әнә шул кеше алып китә. Әти председатель булып эшләгәндә, шкафтан алып, ниндидер сары кенәгә ертканымны хәтерлим. Хәтерләвемнең сәбәбе – әти минем арт чүмечкә кизәнми генә берне салды һәм мин, егылып, борынымны канаттым.

Алтынчы яшем белән барганда, аны кулаклар үтерде. Өчиледә Җыен-Сабантуй чаклары. Бездә – өй тулы кунак. Әти, кара-туры айгырны җигеп, иртүк Төрнәле авылына чапты. Мин күрше малае Мансур белән урамда, шырпы тартмасына бал корты ябып, умарталы уйнап йөри идек, безнең йөрәк кагып чаба торган кара-туры айгыр гөрселдәп авылга килеп керде.

Тарантаста әти юк. Тарантаста – җиңнәренә кызыл бәйләгән чит кешеләр. Айгыр ак күбеккә баткан.

Әни ишегалдына утын алырга чыккан иде. Кызыл тасмалы кешеләрнең, тарантастан сикереп төшеп, аңа нидер әйтүләре булды, әнинең кочагына күтәргән утыны, дөбердәп, җиргә коелды. Кызыл тасмалылар, аны тарантаска утыртып, киредән чаптылар.

Аннары авыл купты. Аннары бөтен авылның ир-атын, җыеп, безнең амбарга яба башладылар. Җылау-сыкрау, тиргәү һәм каргану белән тирә-як тулды. Мансур белән мин ак күбеккә баткан айгырны кызганып йөрдем.

Безгә әтине юып, киендереп, табутка салгач кына күрсәттеләр. Кара костюмнан, көл кебек ак йөзле, көрәктәй дәү кулын күкрәк өстенә куеп, күзләрен йомган иде ул. Мин аның үлгәненә ышанмадым. Аның йөрәгенә пычак белән кадаганнар, ул йөрәк ярасын кулы белән каплап кына ята кебек тоелды.

Әтине бездән өч чакрым ары Казанбаш дигән авылга, авылның Арча ягыннан керә торган башына япа-ялгызын күмделәр. Байтак еллар үткәч кенә, мин бу зиратның авыл коммунистларын хөрмәтләп күмә торган аерым зират икәнен белдем.

Әтине күмгәндә яңгыр сибәли иде. Бик күп, бик күп булып халык агыла, табут яныннан атка атланган кешеләр бара, җиз торба кычкырталар, «параман» кагалар иде.

Өч мәртәбә мылтыктан гөрселдәттеләр.

Мин, куркып, җиргә утырдым, җылый башладым. Кемдер мине күтәреп алды, җилкәсенә утыртып, кабер янына алып китте. Актыктан Габдулла агай Заһидуллин мине күтәргән кешенең драматург Кәрим Тинчурин булганын әйтте. Тере язучы белән минем беренче мәртәбә очрашуым әнә шулай булды. Кәрим Тинчурин әсәрләрен укыган кешеләр хәтерлидер: «Кандыр буе» пьесасында кулаклар тарафыннан үтерелгән Ахунҗан эпизоды да бар. Әтиемнең үтерелү вакыйгасы да, Кечкенә Өчиле авылы да – барысы да тормыштагыча, үз исеме белән алынган. Соңыннан, үзем әдәбият белән шөгыльләнә башлагач, мин Кәрим Тинчуринның безнең авылларга ничек эләккәнен аңладым: «Кандыр буе» пьесасына материал туплап йөргән заманы булган икән.

## Юл башы

Беренче класстан мин күчми калдым.

Хәер, аны сөйләп тормасаң да ярар иде, ләкин минем тормышымда бик тирән эз калдырган бер ягы бар аның. Сөйләми булмый.

Әни кулында без дүрт бала өелешеп калдык: ике кыз, ике малай. Әти үлгәннән соң бер ел узар-узмас, иң кечкенәбез – бер яшьлек Марат үлде; төерчек кенә булса да, ир заты иде, минем иптәш иде, ул үлгәч, миңа, алты яшьлек сабыйга, аеруча күңелсез булып китте: кызлар икәү, апалы-сеңелле, ә мин япа-ялгызым. Юк, болай булмый, болай ярамый. Бездән тугыз чакрымнар ары Югары Пошалым дигән авылда әти белән бертуган түтәй яши иде. Без аны Алма апа дип йөртә идек. Аның кияүгә чыккан олы кызы, унбиш яшьләрендәге үсмер улы бар иде. И дә оста иде соң әнә шул унбиш яшьләрендәге Хәкимулла абый уенчык ясарга! Ул канатларын чәп-чәп сугып йөрүче күбәләк-арба дисеңме! Ул тәгәрмәч өстендә тәгәрмәч әйләнүче күз иярмәс бөтерчекләр дисеңме? Югары Пошалымнар, гомумән, авыллары белән бик оста һөнәрчеләр иде. Әтием булмагач, миңа уенчык алып бирүче дә юк, башка малайлар кебек, миңа чана, чаңгы, тимераяк ише нәрсәләр дә эләкми – шулай булгач, нигә мин өйдә әрәм булып ятыйм ди әле. Киттем Хәкимулла абыйларга!

Мине бигрәк тә өзелеп чакырган кеше Алма апа үзе булды.

Соңыннан, бер ел чамасы аларда яшәгәч, мин моны аңлап та алдым. Алма апа колхозга кермәгән, аның ялгыз хуҗалыклы җир кишәрлекләрендә эшлисе бар, ә мин өй саклап утырырга тиеш икәнмен. Алма апаның сандыгында беләзек ише, хәситә ише бизәнү әйберләре күп; әлбәттә, җитмеш яшендәге карчыкка аларның инде берсенең дә кирәге юк, ләкин ул аларны көн саен диярлек актарып, пар атлар белән кияүгә чыккан заманнарын сагынып, мөнәҗәтләр укып утыра торган иде. Әнә шул мөнәҗәтләрнең

җанны актарып ала торган моң-сагышы мине әйтеп бетергесез тәэсирләндерә. Кышкы озын кичләрдә, җиделе лампа яктысында Алма апа куркыныч әкиятләр сөйләргә ярата. Әкиятләре янына солдат ире Гыйбадулланың ярман сугышында үлеп калуын китереп куша. Шунлыктан мөнәҗәт һәм әкиятләр солдатның җан өшеткеч үлем хәбәре белән бергә үрелеп, минем нәни күңелемдә әллә ниткән шомлы-сихерле дөньялар тудырырга җитә кала иде.

Серле, томанлы, моңлы бер дөнья, үзең яшәгәннән бүтәнчәрәк дөнья тудыру ягыннан Алма апаның үзе дә сизмәстән эшләгән эше – минем әдәбиятка якынаюымда юл башы булмадымы икән, дип уйлыйм мин. Алма апа мине байтак кына догалар укырга, ашаганда авызны чәпелдәтмәскә, өстәл астында аякны селкеп, «шайтан чакырмаска», ипине бер генә куллап сындырып, фәрештәләрнең канатын каермаска, олылар сөйләгәндә тыңлап утыра белергә өйрәтте. Утыз еллар чамасы узгач, Алма апаны миңа тагын бер мәртәбә күрергә туры килде. Олы кош кебек дәү гәүдәле, керфекләре коелып бетеп, керфек төпләре алсуланып торган йөзьяшәр бер карчык иде инде. Әмма тавышындагы, сөйләү рәвешендәге дәһшәт, ягъни куркыныч вакыйгаларны куркыныч итеп сөйли белү аңарда таң калырлык көчле иде.

Минем балалык тормышымны бизәүче икенче кеше – Хәкимулла абый. Уйлап табу, нәрсәдер оештыру, көн саен нәрсәдәндер кызык эзләү аерылгысыз сыйфаты иде аның. Әле ул, беркемнең дә башы җитмәгән уенчык ясап, безнең урамны шаккатыра, ул да түгел, ун чакрымнар ераклыктагы Чиканас авылына мәктәпкә барган җиреннән үзеннән олы малайларны кыйнап кайтып дан ала. Алма апа тарафыннан каргыш алмаган бер генә көне дә юк иде аның. Ләкин минем өчен ул аерылгысыз дус, иптәш, сыеныр абый һәм беркем тота һәм гаепли алмастай шулер, артист, баш бирмәс, боекмас бер могҗиза иясе иде. Уйлап чыгарасы нәрсәләрнең барысы уйланып бетеп, алынасы җәзаларның барысын алгач, каргалгач һәм тиргәлгәч, ул көннәрдән бер көнне сулышлары кабып, ах-ух килеп кайтып керде:

– Әни, беттек, харап булабыз! Алтын-көмешне җыялар. Кемнең дә кемнең ике килодан арта, башын Себер җибәрәчәкләр икән, ди!

– Китсәнә! Ай Аллам, менә син тамаша, нишләек, кайларга яшерик? Утка атар иең, утта янмый, кешегә бирсәң, дус бар, дошман бар. Ай Аллам, менә син тамаша... – дип, Алма апа үзенең тумыштан килгән хәвефле тавышы белән безнең өскә ябырылган кайгыны тагын да арттырып җибәрде.

Төнге уникеләр тирәсендә мине йокларга салып, фонарь тотып, өйалдына чыгып киттеләр. Йокылы-уяулы килеш, мин ишек ярыгыннан ут шәүләләрен күреп, өзек-тәтек сүзләрне ишетеп яттым.

Бер елдан соң өйдә гауга купты. Алтын-көмешне, Алма апага күпме мөнәҗәт көйләткән чулпыларны, йөзек-беләзек ише кыз малларын урлап киткәннәр.

Тагын бик күп еллар узганнан соң, мин ул хәзинәне Хәкимулла абыйның юри яшертеп куюын, берәм-берәм алып сата барганын белдем. Акча аңа Казанга китәргә кирәк булган икән. Башында көн саен мең төрле кызыклы уй, хыял туып тора торган егеткә Алма апа белән ялгыз хуҗалыкчы булып, үз яшьтәшләре – комсомоллардан көлдереп йөрү туйдырган. Казанга барып, ул заводка эшкә урнашты. Гомерендә бик күп мактау кәгазьләре алып, дөньяда үзе теләгәнчә яшәп, заводка рационализаторлык тәкъдимнәре биреп, үзе төсле үк шаян-шук, эчкерсез хатыны белән гөр килеп яшәде, ике шәп егет үстерде. Ә авылдагы гөнаһысын – чулпы-беләзек саткан акчаны ул, мөгаен, әнисенә бишле белән кайтарып биргәндер инде. Алма апа соңгы сулышына тикле авылдан купмады...

Минем беренче класстан күчми калуым әнә шул Хәкимулла абый белән бәйле. Алты яшемдә ул мине тирги-тирги укырга өйрәтте. Мин әз генә төртелеп тордыммы, шундук

кызарып-бүртенеп кычкыра башлый торган иде. Педагогик такт дигән нәрсә бер дә булмаган, күрәсең, үзендә.

Ул кычкыра. «Баланың йөрәген аласың бит, юньсез! Сабакны шулай укыталармыни?!» – дип, Алма апа аны тирги. Көннәрдән бер көнне Хәкимулла абый миңа бик каты янап әйтте:

– Бел аны, малай актыгы, әгәр классыңнан күчми калсаң, урамга алып чыгам да, бүрәнә башына бастырып: «Бу малай классыннан күчмәде!» – дип, бөтен урамга кычкырам, – диде.

Бик куркытып әйтелгән сүз булса да, мин ул елны классымнан күчми калдым.

## *Беренче укытучым*

Күчми калу белән мин бернәрсә дә оттырмадым. Ул елларны укырга сигез яшьтән алалар иде. Ә күчми калганда, миңа җиде яшь тә тулмаган иде әле. Күчмичә генә букча күтәреп йөргән әнә шул бер ел минем өчен хәзерлек курслары кебек бер нәрсә булып чыкты. 1933 елны мин, Югары Пошалымнан үз авылыбызга кайтып, күршедәге Көтек авылына укырга кердем. Кергәндә үк укый-яза белү, ун эчендә исәп-хисап йөртү ул чакта мәктәпкә кермәс борын тәтегән нәрсәмени?! Китте минем эшләр хутка! Җиденче классны тәмамлаганчы, мин яхшы укучылар исемлегеннән төшмәдем.

Мин мәктәпкә кергән елларны авыл хәлләре бик кискен үзгәреп китте. Кара-каршы ике йорты, ике аты булган кешеләрне авылдан сөргәч, унөч йортлы кечкенә Өчиле тугыз гына йортлы булып калды. Бездән ярты гына чакрым ары Каенлык дигән авыл бар иде, кулаклардан тазарткач, ул бөтенләй дә алты гына йортлы булып чыкты. Икесен бергә кушканның соңында да алар аерым колхоз булып яшәрлек түгелләр иде, шуңа күрә Өчилене, Каенлыкны күршедәге алтмыш йортлы Көтек белән кушып, бер колхоз ясадылар да «Кызыл Көтек» дип исем бирделәр.

Без, Өчиле, Каенлык балалары, «Кызыл Көтек»кә беренче сыйныфтан башлап мәктәпкә йөрдек. Турыдан исәпләсәң «Кызыл Көтек»кә барып кайту өч чакрым булыр иде, ләкин без турыдан йөрми торган идек. Үзебез ясаган имән чаңгыларда иртән кырга чыгып чабабыз. Кар өсте каты, дулкын-дулкын, чаңгылар таеп-таеп китә, без аңа-моңа карамый бара бирәбез, кем беренче булып кар дулкыннары арасыннан куян куркытып чыгара – ул иң бәхетле кеше. Ә без үскәндә куян бик күп иде, кыр тулы иде куян. Шуңа микән «Куян, син кайда? Кара урманда» дигән шигырь юллары безнең иң яратып кабатлаган шигыребез иде. Көтек белән Өчиле – Каенлык арасындагы очсыз-кырыйсыз кар даласы, кояш нурыннан балкып, күзләрне камаштырып ята. Чыңлап торган музыкасы, колакларны чеметтереп искән җилләре, яктылыгы, пакьлеге белән гомерлеккә безнең хәтергә сеңеп калды ул. Колак төбендә әле дә булса яңгырап торган икенче музыка – мәктәп үзе. Өчиле белән Каенлык малайлары, ягъни без ташбашлар, көн саен диярлек ун-унбиш минутка соңга калып киләбез. Коридор тын, сыйныф бүлмәсеннән кайсыдыр бер малайның: «а-ыр-бы-а, арба» дип көйләп-көйләп укыган тавышы ишетелә, без, соңга калганнар, ишек төбенә өелеп, аны тыңлыйбыз. Кар даласының моңы минем күңелемдә әнә шул көйләп укыган китаплар белән дә, башлангыч мәктәпнең сыйныф бүлмәләре һәм коридорлары белән дә авваздаш булып яши. Карлы яланнарны яки самолётта очканда ак болыт өемнәрен күрү белән, үзәкләрне өзеп, мәктәп еллары искә төшә...

Беренче укытучым минем Зәки абый булды. Заманында ул мулла булган, совет чорында, муллалыгын ташлап, балалар укытырга керешкән. Зур борынлы, шуңа күрә авылда Тукран кушаматы алган бу кеше безне, башлангыч сыйныф балаларын, җәй буе мәктәп янындагы яшелчә бакчасында кыяр, кишер, чөгендер, бәрәңге үстертә, куян ка-

рата, ә кышын безгә итле, яшелчәле кайнар аш ашата иде. Эш яратырга, тырыш булырга, гаделлеккә беренче мәртәбә ул өйрәтте. Юморга да бай булган булса кирәк, мин уен уйнаганда яки китаптан дәресне укып биргәндә катырак кычкырып җибәрсәм:

– Гарифҗан, ул хәтле кычкырма, тәрәзәне ватасың! – ди торган иде.

Зәки абый мине, икенче сыйныфтан башлап, плакат язарга, стена газетасы чыгарырга, рәсем ясарга өйрәтте. Дәрестән соң икәү калып, без аның белән сәгатьләр буе рәсем ясыйбыз, май бәйрәменә мәктәпне бизәр өчен плакат язабыз, аннары, икәү кара-каршы утырып, аш җылытып ашый торган идек. Ятим бала боегып йөрмәсен, кеше булсын дигәндерме, ул минем укуымны гел кайгыртып тора торган иде. Көтек мәктәбендә дүрт сыйныф. Ике сыйныфны Зәки абый укыта, ике сыйныфны җиденчене бетергән яшь кенә бер үсмер укыта торган иде. Үсмер егетебез үсеп җитеп, аны Кызыл Армия сафына алгач, Зәки абыйның берүзенә дүрт сыйныф өелеп калды, шунлыктан безгә – өченче, дүртенче сыйныфтагыларга – Өчиледән өч чакрым ераклыктагы Казанбаш урта мәктәбенә йөреп укырга туры килде. Без өченче чиректә Казанбашка төшкән идек, мин ул чиректне бик әллә ни элдертеп китә алмадым (укытучысы ияләнмәгән кеше бит!). Дүртенче чиректә шулхәтле дә тырыштым, Зәки абыйның йөзенә кызыллык китерәсем килмәде, тырыша торгач, тәки үземнекен иттем, дүртенче классны тоташ отличнога тәмамладым. Хәтеремдә әле, Каеанбашта Сабан туе иде, мин, елны әйбәт тәмамлаган өчен мәктәптән бүләк итеп бирелгән кара сатин күлмәгемне, бүләк итеп бирелгән өр-яңа кепкамны киеп, яланаяк Сабан туена төштем. Тактадан кормаштырып куйган кибет янында кәнфит алучыларга кызыгып карап тора идем, Зәки абый килеп чыкты.

Мине, үз иптәше кебек итеп, җилкәмнән бер кулы белән кочаклап, мәйдан кырыеннан әйләндереп алып килде, хәлләремне сорашты, көрәктәй дәү кулы белән минем кулларны учына алып:

– Молодец, энем, йөзгә кызыллык китермәдең. Әтиең исән булса, нишләргә белми сөенер иде, – дип, мине такта кибет янына алып килде һәм, кепкамны тутырып, кәнфитпрәннек алып бирде.

Үз гомеремдә бик күп бүләкләр алганым бар, әмма Зәки абыйдан алган бүләк кебек кадерле бүләкне күргәнем юк.

Аннары, озак та тормый, без аерылдык. Сугыш алды елларында ул каядыр китеп югалды, аның кая киткәнен белүче булмады. Авылның иң усал, иң гайрәтле бер егете нindидер мәҗлестә: «Мин башына җиттем аның», – дип мактанып сөйләгәнен генә әйттеләр.

Бу хәлләргә инде кырык еллап вакыт узган, хәтер күгеннән бик күп фаҗигаләр, кайгы-шатлыклар, тагын әллә ниләр узган. Ә менә Зәки абый: «Кычкырма, Гарифҗан, тәрәзәне ватасың!» дигән сүзе белән, балаларга яшелчә үстертә, куян карата белүе белән, кыш буена үзебез үстергән яшелчәдән кайнар аш ашата белүе белән, ниһаять, үзе укыткан балаларның уңышына башы күккә тияр дәрәҗәдә сөенә белүе белән бик еракта калган беренче укытучым, изге күңелле бер кеше булып, онытылмый күңелдә саклана. Чыңгыз Айтматовның «Беренче мөгаллим» хикәясен укыганда, мин гел Зәки абыйны искә төшерәм.

## *Икенче укытучым*

Икенче укытучым – Һидият Зыятдинов – Арча районының Күлтәс авылы егете. Без дүртенчегә җиткәнче укытучыларыбызга абый дип дәшә идек, дүртенче сыйныфта исеме, әтисенең исеме белән дәшәргә куша башладылар. Шулай итеп, Һидият абый Һиди Зиатович булып китте. Ләкин ул, аңа карап, минем өчен абый булудан тук-

тамады, Һиди Зиатович белән дә без дәрестән соң стена газетасы чыгара идек, плакатлар яза торган идек. Ләкин инде хәзер безнең бергәләп эшләгән эшләребез аның белән генә бетми иде. Һиди Зиатович мәктәптә кулъязма әдәби журнал чыгара башлады. Инша язарга, рәсем ясарга сәләтле булган укучыларны ул үз янына җыеп алды. Беренче журналның тышлыгына без каен рәсеме белән сыерчык оясы ясадык. Төрнәле авылының Исмәгыйлев белән мин, бер-беребездән уздырып, шигырь яза башладык. Бу хәл дүртенче сыйныфта укыганда булды. Көн саен бер дәфтәр шигырь язып киләбез, аны утыз минутлык озын тәнәфестә, балалар әйлән-бәйлән уйнаган чакта, уртага басып укыйбыз. Шигырь язгы гөрләвекләр турында, чаңгы шуу турында, шомырт урлау турында була, безнең шигырьләрдә кәккүк кычкыра, сандугач сайрый, куяннар чабыша, болыннарда сыер-сарыклар йөри... Тыңлаучыларга рәхәт, алар көлә-көлә кул чаба, безнең башлар җиденче кат күк артында.

Дүртенче сыйныфны тәмамлаганда бугай, безгә Казаннан тере язучы килде: Әхмәт Гыймадов. Кап-кара татар. Һиди Зиатович шигырь язучы бала-чаганы аның янына җыеп алды. Хәзер нинди киңәшләр биргәнен аермачык кына хәтерләмим, әмма шигырь һәм хикәя яза торган, аларны бастырып та чыгара торган тере язучы белән очрашу бездә бик зур тойгы калдырган иде. Шуңа күрә хәзер дә мин язучылар мәктәпләргә баргангда аеруча җитди әзерләнеп, җаваплылыкны нык тоеп барырга тиешләр дип уйлыйм. Шушы очрашудан соң язгы гөрләвекләр турындагы бер шигыремне «Яшь ленинчы» газетасына җибәрдем. Әминә апа Бикчәнтәевадан: «Гарифҗан энем, каләмең өметле күренә, бер куплетың шигырь була язган, шундый куплетларың күбрәк булса, басып та чыгарырга булыр», – дигән хат алгач, сөенечемне, тере тиен тоткандай, бөтен мәктәпкә кычкырып йөргән идем.

Һиди Зиатович минем шигырь чыгаруымны хуплый, шул эштән туктамасын дип, мине дәфтәр белән тәэмин итеп тора иде. Ул чорда дәфтәр бик санаулы, бала саен билгеләнеп кенә бирелә; шуның өстәвенә минем кебек ятим малайның дәфтәр-китап алырга акчасы да булмый бит әле аның. Җиденче класска җиткәнче, мин Һиди Зиатович дәфтәрләренә язып, ул бүләк иткән китаплардан укып бардым. Барысы өчен дә рәхмәтем итеп мин аның өлгереш ведомостьларын күчереп бирә торган идем. Хәтта бер елны тарих укытасы дәфтәрләрен дә күчереп биргәнем хәтердә. Анысы җәйге каникул вакытында булды.

Һидият абыйны мин дөньяга педагог булып туган кеше дип исәплим. Мин бу фикергә кырык елдан соң килдем. Җиденче класста укып йөргән чакларымда мин ул хакта уйлый алмый идем әле. Ул минем укытучым, Өчиледә, Каенлыкта, Көтектә, Казанбашта иң олы кеше иде. Мин аны ярата идем. Ул пөхтә киенеп йөри, ул без исәнләшкән чакта, ник исәнләшкәнеңә үкенмәслек итеп, бөтен йөзе белән балкып елмая, ул менә дигән спортсмен: турникта атына, бик җитез йөри, укытучылардан аның берүзендә велосипед, шул велосипедына атландырып, ул мине Казанбаштан Өчилегә алып менә, үзе белән Казанка елгасы буена балыкка алып төшә. Мондый икәүдән-икәү генә калулар атнасына ике яки өч тапкыр була, чөнки Һиди Зиатович Каенлык авылында олыларны укыта, аларга газета хәбәрләрен укый, ил турында сөйли, хәзерге термин белән әйткәндә, ул агитатор, пропагандист иде бугай. Юл уңаенда ул мине велосипедына атландырып алып менә, мин аның үз җилкәм аша руль тоткан көчле кулын тоям.

– Йә, Гарифҗан, хәзер куян килеп чыкса, без нишлибез? – ди ул.

– Велосипедтан егылып төшәбез! – дим мин.

Ул рәхәтләнеп көлә.

– Дөрес бит, әй... – ди ул, минем белән килешеп.

Без, велосипедтан төшеп, чирәмле тау өстенә чүмәшәбез, Һиди Зиатович Төрнәле буе ягыннан узган баганалы олы юлга, офык буендагы ак мамык болытларга карап уты-

ра. Әллә сагышы бар инде аның? Күзләре моңсу, коңгырт чәчләре колак янына сибелгән, ул көтмәгәндә мине чандыр җилкәмнән коча.

– Әйт әле, Гарифҗан, сиңа Рәшидә апаң ошыймы?

– Ә нигә?

– Башта син минем сорауга җавап бир.

Мин сүз белән җавап бирмим, озак кына тастымал сумкамны актарам, китапларым эченнән унлап рәсем алам. Алар безнең авыл күренешләре: урам, өйләр, болын буендагы әрәмәләр, өй арты бакчабыздагы шомыртларның чәчәк аткан чагы. Мин, шигырь язу белән бергә, рәсем ясарга ярата идем. Ат, сарык, каз рәсеме түгел, гел табигать күренешләре. Үзебезнең авылны мин гомеремдә йөз мәртәбә рәсемгә төшергәнмендер. Мин хәтта апам Гайшә белән сеңлем Саҗидәнең бер генә мәртәбә дә рәсем ясарга омтылып карамауларына сәерсенеп йөри идем. Мин Өчиле күренешләрен Һиди Зиатович алдына тезеп куям.




Гариф Ахунов рәсеме. 1947

– Сезгә боларның кайсысы бик тә ошый, Һидият абый? – дим.

Ул минем рәсемнәремне озаклап карый, арадан берсен – Өчиленең кояш чыккан чактагы күренешен аеруча ошата.

– Алыгыз, сезгә бүләк булсын, – дим.

Мин моны берәр төрле мәгънә салып эшлимме, юкмы икәнне белү өчен булса кирәк, ул минем күзләремә карый, кинәт дулкынланып:

– Рәхмәт, Гарифҗан, син минем чын дустым, – ди. Каты итеп кулымны кыса.

Алар, мин җиденчедә укыган чакта, Рәшидә апа белән өйләнештеләр. Ул мине ниндидер йомыш белән өйләренә чакырды. Мин стена сәгате янында Өчиле авылының кояш чыккан чактагы рәсемен күрдем.

Озак та үтми, аны Кызыл Армия сафына алдылар.

Ул миңа, үзенең укучысына һәм дустына, ике хат язарга өлгерде. Беренчесендә миңа Казан художество училищесына укырга керергә киңәш иткән иде. Ләкин мин Казанны белмим, художество училищесына керү тәртипләрен дә белмим, аннары минем кебек әтисез малайны анда кем асрасын, кем аның тамагын туйдырсын! Мин, җиденчене Мактау кәгазе белән тәмамлаган үсмер малай, Арча педучилищесына барып кердем. Анда керүемнең бер сәбәбе – Арчаның безгә унике генә чакрымда булуы булса, икенче сәбәбе – Һиди Зиатовичның үзенең дә Арча педучилищесын тәмамлаган укытучы икәнен белә идем.

Укытучымның икенче хаты мин Арча педучилищесына кергәч килде. Бу вакытта аның улымы, кызымы туган, һәм ул миңа, элекке укучысына һәм дустына: «Шул бәләкәчемне кайтып күрер көннәр насыйп булыр микән?» – дип язган иде.

Аңа сабыен кайтып күрергә насыйп булмады. Тиздән Бөек Ватан сугышы башланды. Август аенда Күлтәс авылы егете Һидият Зыятдинов сугышчан корабта һәлак булды. Шул ук көнне, аның энесе самолётта һәлак булганын әйтеп, кара язулы конверт килгән.

Җир йөзендә, минем язмышка дучар булып, тагын бер ятим бала һәм ике улын берьюлы югалткан хәсрәтле ана торып калды...

# *Ике капчык бәрәңге һәм ак чалбар*

Күтек һәм Казанбаш мәктәпләрендә Зәки абый белән Һидият абый үз канатлары астына сыендырып, минем язмышымны күздән ычкындырмый саклап килгән булсалар, Хәнифә апа Абдуллина мине әдәбият юлына турыдан-туры этәрүче булды. Ул бишенче-алтынчы сыйныфта татар әдәбияты укыта иде. Кагыйдә ятлаткан байтак укытучыларны беләм мин, әмма Хәнифә апаны кагыйдә ятлатучылар рәтенә түгел, матур әдәбиятны яратырга өйрәтүчеләр рәтенә кертәм. Хәнифә апа Сибгат Хәкимнәр, Гали Халитлар белән бергә Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаган, аннары Казанбаш мәктәбенә укыту эшенә килгән. Ул безгә олы булып күренә, ләкин ул бик яшь булган, биология укытучысы Абдуллин белән тормышларын башлап кына җибәргән икән. Алар икесе дә балаларны яраталар, дәресләренә бөтен күңелләрен салалар, Абдуллин абыйның күгәрченгә операция ясап, аның эчке әгъзаларын безгә бик җентекләп күрсәткәне хәтеремдә. Операция вакытында ул никтер гел иренен кыймылдатып торды, миңа ул күгәрченгә ясин чыгадыр кебек тоелды. Югары Пошалымның Алма апа биргән дин тәрбиясен мин җиденче



Гариф Ахунов рәсеме. 1947




сыйныфка кадәр саклап килдем. Хәнифә апа – чем-кара чәчле, алсу йөзле, күперенкерәк иренле, гаять тыныч табигатьле һәм матур тавышлы кеше – бишенче сыйныф балаларына озын тәнәфестә дә, кайвакыт дәресләр беткәннән соң да русча китаплар кычкырып укый, шундук татарчага тәрҗемә итеп тә бара иде. Алтынчы-җиденче сыйныфларда укыган елларны без, сыйныфыбыз белән җыелып, утызлап китап укып чыкканбыздыр. Жюль Вернны, Пушкин хикәяләрен, «Доктор Айболит»ны без русчадан башладык, аннары аларның татарча тәрҗемәләре басылды. Хәнифә апаларның шактый зур китапханәләре бар иде, мин мәктәп китапханәсендәге китапларны укып бетергәч, әдәбият укытучымнан атна саен бер китап сорап алып укый торган булдым.

Хәнифә апа кушуы буенча, мин иң беренче хикәямне яздым. Ул әтиемнең үлеме турында иде. Хәнифә апа миңа күңел юатырдай сүзләр әйтсә дә, кулъязма минем үземне канәгатьләндермәде. Мин ул чакта Галимҗан Ибраһимовның «Яз башы», «Кызыл чәчәкләр», Мирсәй Әмирнең

«Агыйдел» әсәрләрен укып бик әсәрләнгән идем, үзем язганы бер тиен тормаслык булып тоелды. Мин аны ертып ташладым. Хәзерге тәҗрибәмнән чыгып, мин менә нәрсә әйтә алам: шактый ук таза хәлле крестьянның нилектән коммунистлар партиясенә керүен, кулакларның аны нилектән кеше яллап үтертүләрен мин әле аңларлык та, аңлатып бирерлек тә булмаганмын. Миңа белем алырга, ак белән караны аера белергә, хикәя язуның серләренә төшенергә кирәк булган.

Хәер, алтынчы сыйныфта укып йөргәндә, мин ак белән караны аера башлаган идем инде. Әтисез үскән балаларга хас сыйфаттыр дип беләм, ел әйләнәсе өскә җүнле-рәтле кием, тау шуарга матур чана эләкмәгәнгә, мин, тора торып бер йөрәксенеп, дөньяда булмаган бер нәрсә уйлап чыгарырга, шуның белән башкаларны узып китәргә ярсына башлый торган идем. Казанбаш кибетенә ак чалбар кайткан. Ак чалбарны бездә авыл кешеләре кими, Сабантуй вакытында бик пөхтә киенүләре белән дан алган бер-ике укытучы кия дә, шаукымлы булганга Чәпүр дип ат алган балта остасы гына кия иде. Кинәт минем дә ак чалбар киясем килде. Моның өчен миңа унбиш сум акча табарга кирәк. Җәй буе урманнан кура җиләге җыеп, Арча базарына илтеп сатсам да, биш-алты сумнан арттыра алмадым. Көзен колхоз кырыннан бәрәңге алып бетергәч, без, балалык дустым Мансур белән икәүләп, атна буе кырдан бәрәңге җыйдык. Миңа ун сум акча табу өчен ике капчык бәрәңге җыярга кирәк иде. Шул бәрәңгене җыю өчен без Мансур белән икәүләп кимендә ике гектар җир актарып чыкканбыздыр. Хәзер инде шуны сатып җибәрергә кирәк. Мин аны, әлбәттә, Арча базарына алып бара алмыйм. Ике капчык бәрәңгене унике чакрымга кечкенә арба белән тартып барулары – ай-һай! Ат бирмиләр, ат колхозның үзенә кирәк, чөнки бу вакытта егермешәр-утызар олау Арча стансасына бәрәңге ташый. Шулай булгач, бер генә юл кала: Казанбашка кул арбасы белән тартып барып, төшеп, укытучыларга сату. Тәвәккәлләдем.

Тимерче Ычтапаннарда укытучы апалар тора. Ычтапан абыйлар, бердән, авыл башында, икенчедән, укытучы апаларның бәрәңге бакчалары юк. Минем белән аларның өлкәне – география укыта торганы сөйләште. Бәрәңге эре. Мин кырдан җыйганны үзебезнең бакча бәрәңгесенә алыштырып алган идем. (Сыерга ашатырга ярар, дип, әни риза булды!) Бәрәңгене ошатты укытучы. Бәясенә мин артык та, ким дә түгел, төп-төгәл ун тәңкә сорадым. География укытучысы сары бөдрә чәчләрен җилкәсеннән артка чөеп җибәрде, якты күзләрен балкытып, миңа карады:

– Ике капчыкка сигез сум булыр, үскәнем.

– Юк, апа, миңа ун сум кирәк.

– Ни өчен?

– Кибеттә ак чалбар саталар. Унбиш тәңкә. Минем биш тәңкә бар. Тагын ун тәңкә кирәк.

– Ак чалбар белән нишлисең син, Ахунов? Син бит аны бер көн эчендә каралтып, чирәмгә буяп бетерерсең.

«Бетерәмме, бетермимме – анысы минем эш», – дип гарьләнеп уйладым, ләкин гарьлегемне сүз белән әйтмәдем, сүз белән дә әйткән булыр идем, җылак тавыш белән әйтермен дип курыктым, шунлыктан, тукран кебек, бер генә нәрсәне тукылдаттым:

– Миңа ун тәңкә акча кирәк.

– Ярар, бушат, Ахунов, – диде география укытучысы.

Өч потлы бәрәңге капчыгын күтәрер өчен мин гадәттән тыш чандыр идем, капчыкларны чērәшә-чērәшә өйгә сөйрәп алып кердем, авызларын чишеп, өй асты чокырына аудардым: бәрәңгеләр бер-берсенә бәрелә-бәрелә, дыбыр-дыбыр сөйләшеп төшеп киттеләр. Кулга ун тәңкә акча керер минутны мин өзелеп көтеп алдым.

– Менә сиңа, Ахунов, ике капчыкка сигез сум акча, менә тагын егерме тиен, сукыр карта сатып алырсың, – диде география укытучысы.

Күрәсең, минем чыраем көл кебек агаргандыр, укытучы, куркынып:

– Ни булды сиңа, Ахунов? – дип сорарга мәҗбүр булды.

Мин, җылап җибәрмәс өчен иренемне тешләп:

– Миңа ун тәңкә кирәк, – дидем.

– Сигез тәңкә дә бик зур акча бит.

– Миңа ун тәңкә кирәк.

– Сигез сумга бирмисеңме?

– Миңа ун тәңкә кирәк.

– О, киребеткән малай! – диде география укытучысы, авыз эченнән ботка пешерә-пешерә, өй астына төшеп китте. Ул анда, өзлексез сукранып, миңа унике чиләк бәрәңгене киредән тутырып бирде, һәм мин, ике капчык бәрәңгемне кул арбасына салып, Хәнифә апаларга юнәлдем.

Хәнифә апа мине бик яктырып каршы алды, чәй эчертте, соңгы көннәрдә нинди китаплар укыганымны сорашты, сорашуы шуңа: мин алардан китап алмый башлаган идем.

Китап укырга вакыт юк. Сентябрь тоташы белән бакча бәрәңгесе казып узды. Бәрәңгене ишегалды чирәмендә киптереп, эресен – базга, ваграгын малга ашатырга сайлап куйдык. Ә бу ике капчык бәрәңгене кырдан җыйганымны һәм миңа ун тәңкә акча кирәклеген сөйләп бирдем.

Хәнифә апа миңа, сатулашмый-нитми, ун тәңкә акча тоттырды, шуңа өстәп тагын бер бишлекне сузды.

– Ә монысы нигә? – дидем мин.

– Монысына ботинка алырсың.

Каршы сүз әйтмәдем. Язын-көзен яланаяк пычрак ерып, аяклар чебиләп бетә иде. Ботинкалы булу уен эшмени! Укытучы апам үзе белә торгандыр.

Мин Хәнифә апага Казанбаштан Өчилегә менеп җиткәнче рәхмәт укып мендем, шул биш тәңкә өчен тагын ике капчык бәрәңге җыеп бирергә күңелемне беркеттем. Әмма көндәлек мәшәкатьләр миңа вәгъдәмне үтәргә ирек бирмәде. Ул бурыч шушы көнгә тикле минем өстемдә асылынып тора.

Казанбаш мәктәбендә җиденче сыйныфны бетергәнче бик яхшы билгеләренә генә укып барган булсам да, ул елны минем эшләр географиядән кәегәеп китте. Башта мин «яхшы» билгесенә төштем, аннары «уртача»га тәгәрәдем. Мине директор бүлмәсенә чакырып озак кына сораштылар, мин чын дөресен әйтергә теләмәдем, бүлмәдәгеләр моның төп сәбәбен белми калдылар. Озакламый география укытучысын эшеннән бушаттылар. Шуннан соң гына мин «отлично» билгеләре ала башладым.

Ләкин миңа ак чалбар насыйп булмаган икән, мин аяк киенгәләгәнче ул беткән, ботинканың миңа яраклысы юк иде. Акчаны кыш буе берәүгә дә бирмичә саклап чыксам да, ак чалбар белән ботинка язын да булмады. Апрель ахырларында, язгы сулар ташып тынгач, мин Арча базарына барган җирдән ике кило чамасы майлы буяу алып кайттым. (Төрле төсен сайлап алдым.) Ул минем гомерлек хыялым иде. Иске фанер кисәкләрен, ташландык мич капкачы калаен зур бер агач рамга кадакладым да җирлеген күк йөзе төсле ачык зәңгәргә буяп, аңа җилфердәп торган кызыл байрак ясадым. «Яшәсен Май бәйрәме!» дип, җете ак буяу белән плакат яздым. Плакатның биеклеге метр ярымнар булгандыр. Мин аны үзебезнең капка түбәсенә менгереп кадакладым.

Минем плакатны Өчиледән, Каенлыктан карамаган бер генә кеше дә калмагандыр. Башны кыек салып, тел шартлатып тордылар, мактадылар. Әнинең генә минем иҗатка исе китмәде:

– Йөри шунда акча бетереп, – диде.

# *Чабатасыз студент*

Казанбаш урта мәктәбендә җиденчене мин гел «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлап, Мактау кәгазе алып чыктым. Ул миңа техникумнарга сынаусыз керергә хокук бирә иде.

Миңа укытучыларым булачак рәссам итеп карыйлар, бик зур өмет баглыйлар иде. Моның сәбәпләре бар. Мәктәптә укыган елларымда мин икенче класстан башлап стена газетасы чыгарып килдем. Яраткан язучыларымны: Тукайны, Такташны, Пушкинны дәфтәргә кара кара белән күчереп ясадым. Авылыбызны, сыер-сарык, ат-этләрне, каз-үрдәкне, агачларның төрле төрен, коймаларны, сыерчык ояларын төсле буяу белән дәфтәргә төшердем. Рәсем белән мавыгу шулкадәргә барып җитте, мин, дәрестән соң мәктәптә калып, рәсем укытучысы Хәмзә Закировның рамга тарттырылган ак материягә портрет ясаганын сәгатьләр буе карап тора башладым. Күз бәйләнә башлагач кына кайтырга кирәклек исемә төшеп чыгып йөгерәм дә Казанбаш белән Өчиле арасын – өч чакрымны ярты сәгатьтә узам, мышкылдап өйгә кайтып керәм. Әни мине: «Кайдадыр тырай тибеп йөрисең, гамьсез, өйгә булышмыйсың», – дип гаепли, мин аңа каршы сүз әйтмим, шуның белән гаебем йомыла иде.

Ләкин мин рәссам булырга кайда укытуларын белми идем. Кешедән нәрсәнедер сорарга уңайсызлану гадәтем минем гомер буе сакланды, ул миңа вакыт-вакыт бик зур зыян китерә, бик кыен хәлләрдә калдыра, әмма, ни хәл итим, кешегә, бигрәк тә чит кешегә сүз катудан мин яшеннән курыккан кебек куркам, үземә тиешлене газетадан, белдерүләрдән укып, кешеләр сөйләшкәнгә колак салып йөреп беләм; холкымдагы бу кыен сыйфатның азактан миңа бик күп файда китергән чаклары да булды: мин күзәтүчән, кызыксынучан, читтән карап торып, күргәннәремне хәтеремдә калдыручан булып киттем. Ә бу минем кебек язу-сызу эше белән шөгыльләнгән кеше өчен бик тә кирәкле, хәтта файдалы сыйфат булып чыкты. Тик ул елларны чамадан тыш оялу сыйфаты мине рәссамнар мәктәбенә керттерми калдырды, мин, үземә кирәкне район газетасында басылып чыккан белдерүдән укып, Арча педагогия училищесына документларымны илтеп бирдем.

Бая әйткән Мактау кәгазем булганга, мине имтихансыз алдылар. Ул елларны махсус уку йортларына керә алган кеше иң бәхетле кеше санала иде. Рәсем мәктәбенә керә алмасам да, мин педагогия училищесына эләгүемә бик тә канәгать идем, мөгаен, үзебезнең Кечкенә Өчиле авылына кайтып, дусларым Мансур, Гариф, Шәкүр, Шамилләр алдында мактанып та йөргәнмендер әле...

Күңелдә берәүгә дә әйтми торган эчке бер сөенеч тә бар иде: шушы училищеда минем яраткан укытучым Һиди Зиятович укыган. Ул инде Кызыл Армия сафында хезмәт итә иде, мин аңа, шатлыгымны әйтеп, хат яздым. Хәтеремдә: Һидият абыйдан озак та тормый хат килде, ул мине мактаган, студент булуым белән котлаган, мине сагынуын, миңа уңышлар теләвен әйткән, кыскасы, мин айлар буе шатланып йөрерлек хат язган иде.

Тик озакламый минем шатлыгыма корт төште.

Бер дә бер көнне педучилище директоры укырга яңа кергәннәрне зур коридорга җыйды да, барыбызның аякларын карап чыккач:

– Педучилищега чабата киеп йөрү тыела. Әти-әниләрегезнең ботинка алырлык кына рәте бардыр, – диде.

Минем, әтисез малайның, ботинка алырлык рәтем юк иде. Әнигә ул хакта әйтеп, күз яше белән ялварсам да, ул миңа хәзер үк ботинка алырга вәгъдә итмәде, җирләр туңып, бер сарыкны суеп саткач кына ала алырбыз, диде.

Мин, чабатаны салып ташлап, җир туңдырганчы яланаяк йөрдем училищега, миңа берәү дә «чабата белән килгәнсең» дип бәйләнә алмый иде хәзер...



Гариф Ахунов белән Шәһидә Максудова. 1954

## *Чишмә белән әлифба*

Минем өчен тормышта ике нәрсә гомер буе могҗиза булып сакланып килә: берсе – Чишмә, икенчесе – Әлифба. Аларны бер генә кеше дә уйлап чыгара алмый, алар дөньяга үзләреннән-үзләре туалар һәм шулай гомер буе яшиләрдер кебек тоела иде миңа. Өстәвенә алар икесе дә сусауны басу өчен яратылган: Чишмә – суга сусаганны, Әлифба – белемгә сусаганны.

Чишмә белән Әлифба турындагы уйлар миңа Арча педучилищесында безгә татар телен укыткан укытучыбыз Рәмзия апа Вәлитова турында уйлагач тудылар. Педагог һәм Әлифба авторы булганчы, Рәмзия апа зур юл узган. «1922 елның пионеры мин», – дип бик тә горурланып әйтергә ярата иде Рәмзия апа безне укыткан елларны. Бу очракта да Чишмә сүзе Рәмзия апага туры килә: Бөтенсоюз яшь ленинчылар оешмасы оешкан елны ук пионерга кергән ул. Ул моның белән үзен бик тә бәхетле саный, без тормышыбызны Чишмә башыннан башладык, ди. Әмма аның бәләкәйдән үк саклап йөрткән кайгысы да бар: 1921 елгы ачлыктан аның әти-әнисе үлә. Совет власте сигез яшьлек баланы ятимнәр йортына ала, муенына кызыл галстук тага, белем алырга, бәхетле булырга ирек бирә.

Боларның барысы Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә була. 1928–1931 елларны үсмер кыз Рәмзия, педагогия техникумын тәмамлап, Стәрлебаш авылында балалар укыта башлый. Анда пионер оешмасы оештыра. Ул чагында «Коммунистик балалар оешмасы» дип исемләнгән оешманың рәисе, ягъни председателе була. Татарстанда чыга торган «Яшь ленинчы» газетасын үзенең пионерлары арасында тарата.

1934–1937 елларда Рәмзия Вәлитова, Казан педагогия институтын тәмамлап, Арча педагогия училищесына татар теле, әдәбияты укытучысы итеп җибәрелә.

Әнә шул көннән башлап пенсиягә чыкканчы, ягъни 1969 елга чаклы, ул Арча педагогия училищесында булачак укытучыларны тәрбияли. Утыз ике ел буена әзерли ул аларны. Бу үзе генә дә һәркемне сокландырырдай озын гомер, һәркемне таң калдырырдай зур хезмәт! Мин аның нинди әйбәт укытучы булганлыгын ак кәгазь бите янына утырган саен искә төшерәм. Ул бездә туган телебезгә, Тукай мирас итеп калдырган телгә мәхәббәт уятты. Телнең грамматикасына, синтаксисына өйрәтергә мөмкин, дөрес итеп нокталы өтер куярга өйрәтергә мөмкин, әмма туган телгә карата мәхәббәт тәрбияли алмасаң, өйрәтеп йөргәннәрем бушка китте дип исәплә. Теле булмаган язучыны, телгә битараф калган язучыны мин начар педагогтан, телгә үзе дә формаль караган, битараф караган педагогтан белем алган язучы дип саныйм.

Туган телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли алган укытучы – бәхетле укытучы ул. Кеше рухын тәрбияли алган укытучы ул. Рәмзия апаны мин әнә нәкъ шундый укытучы дип саныйм һәм шуңа күрә дә без, аның шәкертләре, аңа карата күңелебездә рәхмәт хисе саклап йөрибез. Аны хөрмәтләп баш иябез.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы, Рәмзия Гыйлаҗ кызы Вәлитовага «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән данлы исем биреп, аның утыз елдан артыкка сузылган педагоглык хезмәтен зурлады.

Сүзне мин «Чишмә белән Әлифба» дип башлаган идем.

Чишмә турында инде сөйләдем. Рәмзия апаның тау-ташлар актарып чыккан саф сулы чишмә шикелле гел яктыга омтылуы, илебез биргән белемне үзендә генә калдырмыйча, меңләгән балага күчерүе – бу үзе үк инде саф суы белән кешеләрнең сусынын баскан Чишмә образын хәтерләтә.

Рәмзия апаның хезмәте балаларга белем бирү белән генә чикләнми. Шул хезмәте белән бергә ул мәктәпләргә кирәкле күп кенә дәреслекләр язды. Арча педагогия училищесы укытучысы, гомер юлдашы Сәләй ага Вагыйзов белән бергәләп Рәмзия Вәлитова сигез китап иҗат итте. Аларның бу эшкә никадәр җаваплы караганлыгын бер мисал белән исбатлый алам. Моннан берничә ел элек балалар әдәбияты һәм сәнгатенә багышланган берләштерелгән пленумда мин башлангыч мәктәпләр өчен чыгарыла торган кайбер дәреслекләрдә әдәби әсәрләрдән өзекләр югары таләптән чыгып сайланмаганлыгын әйтеп узган идем, ул хакта пленум отчёты газетада да басылган иде. Берничә көн узуга, Сәләй ага белән Рәмзия апа, гаять дәрәҗәдә борчылып, минем янга килеп җиттеләр. Нәрсә турында сүз барганлыгын кат-кат, төпченеп-төпченеп сораштылар, мин сүзнең алар әзерләгән китаплар турында түгеллеген әйтсәм дә, тынычлана алмыйча, Арчага кайтып киттеләр. Шуннан соңгы чыккан китапларда мин аларның тагын да зуррак таләпләр куеп эшләгәннәрен күрдем. Менә бу ичмасам хезмәт! Моңардан барыбызга да үрнәк аласы бар.

Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вагыйзов чыгарган китаплар арасында минем үземне иң нык дулкынландырганы – Әлифба.

Әлифбаны кулга тоту белән, мин кояш нурында җемелдәп яткан карлы яланнарны, капка-коймаларны күмеп киткән бураннарны, язгы гөрләвекләрне, мәктәп коридорына килеп керү белән көйләп-көйләп китап укыган балаларның класстан ишетелгән тавышларын искә төшерәм. Бала чагым, мәктәп елларым, газиз укытучыларым мәңге онытылмаслык булып күңелемдә яңара.

Бала чагымның якты көннәрен кабат искә төшергәннәре өчен дә Әлифба авторларына мең-мең рәхмәт әйтәсем килә минем. Шушы Әлифбаны укып күзләре ачылган меңләгән, ун меңләгән бала, еллар узгач, зиһеннәре арта төшкәч, Рәмзия апа белән Сәләй агага, минем кебек үк, рәхмәт әйтерләр әле дип ышанам.

Эшләгән эшең өчен рәхмәт ишетүдән дә зуррак бәхет бармыни дөньяда?!

*1975–1978*



# II-бүлек.-ӘЛМӘТ-УТЛАРЫ

***Гариф Ахунов***

# Нефть-шәһәреннән-хатлар

## *Әлмәт утлары*

Бөгелмәдән Әлмәткә иң соңгы автобус төнге сәгать уннарда килеп төшә. Моннан алты-җиде ел элек бәләкәй генә район үзәге булган Әлмәттән чыгып киткән кеше менә хәзер үзенең туган якларына шушы төнге автобус белән кайтып төшсә, үз күзләренә үзе ышанмыйча, исе китеп, шаккатып калыр иде. Туктале, дияр иде, нинди могҗиза белән монда шундый зур, шундый матур шәһәр үсеп чыккан? Соң бит әле алты-җиде ел элек кенә боларның эзе дә юк иде, Әлмәт Татарстанның иң аргы, иң эчкәреге районнарыннан берсе иде; кая ул кышкы бураннарда, җәйге аяз көннәрдә дә монда үтеп чыгуы ансат эш түгел иде. Әле 1950 елда гына монда шулкадәр йортлар да, шундый төз урамнар да, йортлар арасыннан күккә сузылган котельный морҗалары да юк иде.

Ә утлар! Күпме ут яна монда: Яңа ел бәйрәмнәрендә чыршыларга элеп куя торган елтыравык ука сыман, аларның бер ишесе бик ерактан җемелдәп-җемелдәп кенә күренә, бер ишесе ак металл баганалар буйлап тезелеп китә дә каядыр бер чат борылышында күздән югала; ә шәһәр аръягында, исәпсез-хисапсыз баганалар, чыбыклар аралашып беткән урында, кинәт бик зур булып, ялкын шәүләсе сыман куе кызыл утлар килеп чыга, болары – факел утлары, болары, төнге күренешкә аеруча бер серлелек биреп, тетрәнә-тетрәнә яналар. Күптән түгел генә алар бик ишле иде, хәзер сирәгәйделәр. Кешеләр нефть газын җир асты юллары буйлап кирәкле урыннарына – торак йортларга, клубларга, мәктәпләргә үткәрәләр, алар анда ничектер тыйнакланып калдылар, дуламыйча, шашынмыйча, сабыр гына кешеләргә хезмәт итәләр.

Бу яңа күренешләрнең барысын Әлмәт якларына нефть алып килде, бу могҗизаларның барысын нефть тудырган.

Өч ел эчендә, рәсми рәвештә шәһәр дип аталганнан соң, Әлмәттә биш йөздән артык торак йорты салынган. Биш йөз йорт! Бер йөз җитмеш мең квадрат метр дигән сүз бу. Бик иркен итеп өчәр бүлмәле квартираларга гына урнаштырганда да, дүрт меңнән артык нефтьче семьясын урнаштырып була монда. Ихтыярсыздан Татарстанның башкаласы Казанны күз алдына китерәсең. Казандагы төзелеш темпы белән Әлмәттәге темпны чагыштырып карыйсың да, үз алдыңа елмаеп куясың. Әгәр Казанның берәр урамында төзек бер кварталның ансамблен бозып торучы, җиргә чүгеп беткән борынгы купец йортын сүтеп ташлап, аның урынында тракторлар, экскаваторлар җир казырга тотынса, Казан кешеләре моны шундук күреп алалар.

– Болак буенда яңа йорт салалар!

– Алты катлы буласы, ди!

Төзелеш күрмәгән шәһәрмени Казан?! Кайчандыр йөгәнсез җилләр генә дулап йөргән, алабута белән әрем генә үскән Кәҗә бистәсе ягында совет власте елларында гаять зур яңа шәһәр үсеп чыкты, һәм аны Казан кешеләре, яңа чор хөрмәтенә, Социалистик шәһәр дип




Әлмәт, 1963

атадылар. Казанның үзәк урамнарында да әллә никадәр үзгәреш булды, Казан бөтенләй йөзен үзгәртте. Ләкин шуңа да карамастан, Казанда яңа йортлар салыну – игътибарга лаеклы вакыйга. Ә Әлмәттә яңа йортлар салынуга шулкадәр күнеккәннәр, алар аны иң гади күренеш итеп карыйлар. Чөнки салынып ята торган яңа йортлар монда урам саен, ялгыз-ялгыз гына да түгел, кварталы-кварталы белән. Бер-ике төзек квартал узып, бередә кешеләр яшәвенең матур бер билгесе булган ал-яшел абажурларга, ак челтәрле тәрәзә пәрдәләренә куанырга өлгермисең, тагын кварталы-кварталы белән таш тартмалар килеп чыга? Һәммәсенең стеналары өелеп беткән, бүлмәләре штукатурланган, әмма түбәләре ябылмаган, тәрәзә-ишекләр куелмаган. Нигә болай соң бу? Унлаган йортның берьюлы стеналарын өеп тә, түбәсен япмыйча, тәрәзә-ишекләр куймыйча тик торгызганчы, берәр йортлап салып булмый микәнни? Алай итсәң, тизрәк эше бетеп, квартирасыз нефтьчеләрне тизрәк квартиралы итәргә булыр иде бит?

Өй эшләүнең ние бар: мүклисе дә чутлыйсы, дигәннәр борынгылар. Кайбер булдыксыз осталардан көлеп әйтелгән сүз инде бу. Монда да шул мәкальне кулланырга туры килә. Яшь нефтьчеләр шәһәренең үсү авырлыкларын да, үсү авырлыклары сылтавы белән узып китә торган кайбер башбаштаклыкларны да белгән бер ташчы абзый, өлкән яшьләрдәге кеше, яңа Әлмәтнең беренче нигез ташын салучыларның берсе, әле югарыда әйтелгән сораулар хуҗасының беркатлылыгыннан елмаеп, ләкин шулай да әңгәмәдәшенең хәтерен калдырмас өчен елмаюны бик тиз яшереп, мәсьәләнең асылын аңлатып бирде:

– Ул бит, агай-эне, яңа йортның стенасын күтәреп, түбәләрен ябу белән генә эш бетми бит әле, аңа су китерергә, җылыту торбалары үткәрергә кирәк. Ә болай, кварталы белән төзегәч, ул нәрсәләр барысы берьюлы эшләнә: арзанрак та, ансатрак та. Ә элегрәк, чынлап та, берәр йортлап салалар иде. Тик алай төзүнең бик күп мәшәкате килеп чыкты. Моннан бер-ике ел элек төзелгән яңа йортлар яныннан узганда игътибар иттең микән – курчак кебек чибәр йорт, ә стенасы уем-уем булып кара янган, балчыкка батып, пычранып беткән. Төзүчеләрнең, эшлисе эшләрен уйлап җиткермичә, өй эшләүнең ние бар: мүклисе дә чутлыйсы принцибы белән эшләүләре нәтиҗәсе ул. Мисал өчен әйтик, бер яңа йортны салып бетерәләр, штукатурлыйлар, ялт итеп буяп агартып китәләр, курчак та курчак, йорт та курчак – карап торырга соклангыч! Менә берзаман, ломнар, көрәкләр күтәреп, җир казучылар килә, йортка җылыту торбасы үткәрү өчен канау казырга тотыналар. Канауның балчыгын, аны-моны уйлап тормыйча, өй стенасына чыгарып өяләр.

Ул гынамы! Рәхимсез ломнар белән күз явыңны алырлык чиста стенаны дөбер-шатыр тишеп, торба үткәрергә тотыналар иде...

Төзүче абыйның сүзләре мине уйга калдырды. Чыннан да, бездә шулай кирле-мырлы эшләп, берең ясаганны икенчең ватып йөрү кебек нәрсәләр бар бит әле. Мин моны музейларга куела торган сәнгать әсәрләрен бозу белән чагыштырыр идем. Күз алдына китерегез: картина ясалып беткән, зәңгәр һавасы, бөдрә болытлары белән ул сине чакырып, сихерләп тора. Әгәр менә шушы картинаның нindидер җөе килеп җитмәгән дип, кабат сүтеп тетә башласалар, ни булыр иде? Художник каравыл кычкырыр иде.

Менә кайда икән ул хикмәт! Менә ни өчен Әлмәттә йортларны кварталлап сала башлаганнар! Ул чагында канализация дә, җылыту торбалары да йортларның барысы өчен берьюлы эшләнә икән.

– Ә менә бу таш плитәләрне каян алалар? – дип сорадым мин ташчы бабайдан.

– Чупай ташы ул, – дип җавап бирде абзый, – моннан унбиш чакрымнар ары шундый бер тау бар. Тау комбайннары аның ташын гади кирпечтән дүрт-биш тапкыр зуррак итеп кисеп тора, машиналар шәһәргә ташып тора, ә без – ташчылар төзеп торабыз.

Карт останың соңгы сүзләре кинәт күңелдә матур уйлар кузгатып узды. Мин көне буе Чупай ташыннан салынган шәһәр турында уйланып йөрдем. Чыннан да кызык бит: гасырлар буена кымшанмыйча, селкенмичә таш тавы ята, ә менә нефть дигән баһадир, үзе ике чакрым тирәндә ятса да, шушы мәгърур тауны да урыныннан кучәргә мәҗбүр итә.

Табигать мул итеп өеп куйган шушы ак таштан һәм шәһәрнең үзендә әзерләнгән кирпечтән Әлмәт төзүчеләре ике-өч ел эчендә, баягынак әйткән биш йөз торак йорттан тыш, өч йөз кеше сыешлы «Россия» кинотеатры, ике клуб, илледән артык магазин, дистәгә якын мәктәп, яслеләр, икмәк заводлары, мунчалар салганнар. Менә бит, байлык гел аяк атсында ята икән, билләһи!

Күңел күзе белән карасаң, Әлмәттә моннан башка да бик күп матур нәрсәләр күрергә мөмкин. Үзенең амбулаториясе, ярдәмче хуҗалыгы һәм башка уңай яклары бул-



Гариф Ахунов һәм башка язучылар нефтьчеләр белән очрашуда

ган больница шәһәрчеге салынып бетеп килә; таш баганалы койма-рәшәткә белән әйләндереп алынган иркен ишегалдында өч катлы зур йорт ерактан ук күренеп тора. Болар инде капитальный йортлар, шәһәрнең үзәге шушы тирәләрдән башлана. Больница шәһәрчеге янынннан гына уналты гектар җирне әйләндереп алган тагын бер рәшәткә-койма уза: анда парк булачак, парк белән янәшә культура сарае салына, аның инде стеналары эшләнгән, аны эшләүне тизләтәләр, чөнки зуррак җыелышлар, слётлар булган саен, яшь нефтьчеләр, комсомол активистлары, ул сарайның тизрәк эшләнеп бетүен һәм яшьләр өчен алты мең урынлы стадион салынуын таләп итеп, управление җитәкчесенең күзен ачтырмыйлар.

Нефть районнарында үскән шәһәрләрнең Казан кебек борынгы шәһәрләрдән аерылып торган икенче ягы да бар. Шәһәр күз алдында берничә яруска бүленә: нефтьчеләр беренче тапкыр килеп, вакытлыча тору өчен куышлар корып җибәргән җирләрдә, ул – бер катлы, шуның белән янәшә урам ук инде ике катлы, шәһәрнең үзәге булачак урынга җиткәндә инде нык фундаментка куелган, Чупай ташыннан нык итеп, стеналары калын итеп салынган өч-дүрт катлы йортлар да күренә башлый. Ә шушыларның барысын, гөрләп үсеп килгән яңа нефть шәһәренең колачын иске Әлмәт белән чагыштырып карaганда, район үзәгенең бәләкәй өйләре ничектер бик кечерәеп кала, гүя алар, кинәт үсеп чыккан девон шәһәренең зурлыгыннан куркып, җиргә сыеналар.

Әйе, нефть могҗизалар тудыра. Әле күптәнмени Татарстанда нефть чыга башлауга! Бик күп булса ун ел. Шушы аз гына вакыт эчендә нефть Әлмәт, Лениногорск кебек илле-алтмыш мең халкы булган зур-зур шәһәрләр, Баулы, Азнакай, Актүбә кебек эшчеләр посёлоклары үстереп чыгарды.

Бу шәһәрләр хәзер таң вакытын завод гудоклары белән каршы алалар. Әйе, девон нефте үзе генә көчле фонтан булып бәреп чыкмады, үзе белән бергә Татарстанның бу эчкәреге районнарына кайнар чишмәдәй ярсу тормыш та алып килде.

## *Карт мастер бригадасында*

Әлмәттә нефтьчеләрнең иң күп очраша торган урыны – автовокзал. Иртәнге җидедән алып төнге дүрткә кадәр – тәүлек буена дияргә мөмкин – бирегә вахта машиналары бертуктаусыз килеп-китеп торалар. Алар нефтьчеләрне вахталардан алып кайталар, шәһәрдән утыз-кырык чакрым ары урнашкан ерак буровойларга алып китәләр.

Март аеның аяз бер иртәсендә автовокзал каршында ундүрт-унбиш кеше башкалардан читтәрәк, иренеп кенә, тегене-моны сөйләшеп торалар иде. Громкоговорительдән Закир Гарипов исемен ишетү белән, алар кинәт җанланып, шау-гөр килеп, кыяфәте бик үк өметле булмаган автобус эченә тула башладылар. Бик үк өметле булмаган дип шуңа әйтәм, чөнки буровикларны алып барырга тиешле әлеге автобус зур шәһәр урамнарында көязләнеп йөри торган кызыл итәкле, бил турысыннан өске ягы аксыл-сары төскә буялган өр-яңа автобуслар кебек чибәр түгел, ә инде яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган, кайчандыр матур булган буяулары инде уңып, төссезләнеп, бөтен җире корымга, майлы тузанга, мазут сөременә буялып беткән; тәрәзә пыялалары кылтыр-кылтыр килеп тора, ә кайбер өлгеләренең аскы-өске читләре ватылып-кителеп төшкән, алгы өлешендә купкалаган калайлары мотор гөрелтесеннән кош канаты кебек җилпенә. Кыскасы, бу машина нефтьчеләрне дүрт-биш чакрымга да алып барып җитә алмас, үзе дә ишелеп төшәр. Нефтьчеләрне дә коеп бетерер кебек тоела иде.

Ләкин нефтьче егетләр аны-моны уйлап тормадылар, әллә ни арада автобус эченә кереп тулдылар. Соңгы кеше булып менгән егерме биш яшьләрдәге чибәр йөзле кара егет шапылдатып ишекне ябуга, автобус бәйге кѳтеп ярсыган чаптар кебек кисәк кенә бер йолкынып алды да, кузгалып та китте.

Вахта машинасына читтән килеп кергән кеше нефтьчеләрнең киемнәре буенча әле беренче карауда бернәрсә дә аера алмас. Алар аңа барысы да бертѳсле, барысы бер калыпка суккандай тоелыр иде: барысының ѳстендә майланып шомарып беткән брезентовка, барысының җилкәләрендә колхоз бригадирлары тагып йѳри торган тѳсле кыр сумкасы, барысының да бүрек колакчыннары куян колагы кебек тырпаеп тора. Аерылса бары бер кеше аерыла: шофер янында утырган, күрер күзгә илле яшьләрендәге агайның гына бүрек колакчыннары тѳшерелгән, ѳстенә кигән киеме дә брезентовка түгел, дубка суккан кара тун, ѳстеннән билен кызыл пута белән буып куйган, ә тун изүеннән башкаларныкы кебек чылбыр изүле свитер яки чуар ковбойка күренми, бәлки бик пѳхтә итеп уралган, авыл кешеләре чорнап йѳри торган йомшак ак шарф күренеп тора. Аның бѳтен кыяфәте «мин авыл кешесе, мин әле авыл гадәтләрен ихтирам итәм» дип әйтә кебек. Бу – бораулау остасы Закир Гарипов, яше белән дә, эшләгән эше белән дә бригаданың иң ѳлкән кешесе. Бүген ул үзенең нефтьче егетләренә игътибар итәргә оныткан, тәрәзәгә тѳбәлеп, үзалдына уйланып бара: бәлки, ул бирегә, Татарстан җиренә, туган-үскән якларына кайтып, бораулаларга тотынган чакларын, 1950 елгы авырлыкларны исенә тѳшергәндер. Ул чакта вахталарга барганда, күбесенчә җәяүләп яки тракторга утырып, ташбака адымы белән йѳргәннәр. Берәр-икешәр атна культбудкада кунып эшләргә туры килгән чаклар да булган. Кем белә, бәлки, аның күңеле аннан да арырак вакытларга, беренче мәртәбә нефть эшенә тотынган 1931 елларга әйләнеп кайткандыр.

1931 елда ул Урал тауларында, Верхнечусовские Городкида яши иде. Үзенә күрә бер һѳнәре дә бар: олаучы булып эшли иде. Зур гына, таза гына гәүдәле, ягымлы итеп елмаеп сѳйләшә торган Абдулла Сабирҗанов – ир уртасы кеше – аның якын күршесе, киңәшчесе һәм дусты иде. Урал якларына Татарстанның Чүпрәле районыннан килеп чыккан бу абзый 1923 елдан бирле нефть эшендә эшләп, җир бораулау буенча байтак кына гыйлемлек җыйган иде. Әйтә бу берзаман Закирга: карале, дустым, ташла син бу дилбегәңне, күч син минем буровойга. Мин сине җир куенында яткан серләрне ачарга ѳйрәтермен, ди. Закир ул чагында яшь әле, типсә тимер ѳзәрлек таза егет – егерменең теге ягына күптән түгел генә аяк баскан. Җитә калды моңа бу сүз, семьясы да ул кадәр ишле түгел, гел чыркылдап кѳлеп йѳри торган хатыны Сәрби бар да бер сабый баласы – кызы бар. Абдулланың үзенә карата гел яхшылык кына эшләп торганын белгәнгә һәм үзенең дә шундый кызыклы дѳньяларны карыйсы килгәнгә күрә риза булды бит, әй, Закир. Риза булды да эшкә кереште.

Нефть эшендә кешеләр кадерле ул чагында, бик дәү ындыр табагы кадәр буровойның тѳрле-тѳрле җиһазлары белән таныштырып, дѳбердәү-шатырдауларына күнектереп берәр атна йѳрткәннән соң әйттеләр, әйдә инде син, дустым, җиләсрәк җиргә мен, диделәр, верховой итеп вышка түбәсенә менгезеп җибәрделәр. Ташкүмерне тирән-тирән шахталарга тѳшеп чыгарырга кирәк, дип әйтәләр иде. Нефть дигәннәрен дә бик тирәндә, бик аста, диләр иде, әмма аның монысын чыгару ѳчен караңгы базларга тѳшәргә һич кирәк түгел икән, җир ѳстеннән торып кына да чыгарып була икән нефтьне. Алай гына да түгел, нефтьне әле җил оясына менеп урнашып, җәен рәхимсез кояш кыздыруына, кышын ачы бураннарга чыдап чыгарырга кирәк икән.

Гап-гади крестьян малаеның мондый хәлләрне күргәне бар идемени?! Юк иде. Революциягә кадәр крестьян малаена дѳньяда яшәү ѳчен ике юл бар иде: әгәр инде бәхетең булып, аз-маз җиргә тиенсәң, атың-сыерың булса, син тешең-тырнагың белән



Фәнни китапханәдә. Сулдан уңга: Риза Ишморат, Фазыл Мостафин, Шамил Бикчурин, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов; Шәһидә Максудова (сулдан икенче). Әлмәт, 1960

шул җиреңә ябыша идең, әгәр инде алары булмаса, тамак ялына байларга бил бөгә идең яки, бәхет эзләп, зимагур булып, Урал, Себер, Донбасс якларына чыгып китә идең. Ләкин кара сакалың, кая барсаң да, артыңнан калмый йөри иде.

Ул чагында беркем дә бәхет менә шушында, үзебезнең ата-бабаларның маңгай тире тамган, ата-бабалар каны түгелгән җирдә, аяк астында ятадыр дип уйламаган...

Автобус чаба да чаба. Иртән иртүк бульдозерлар көрәп киткән асфальт юл кара тасма булып артка йөгерә. Юл чатларында, борылмаларда резервуарлар, промысел вышкалары күзгә чалынгалап кала. Тау буйларында, уйсурак җирләргә тезелгән факеллар ялкын телләрен суза-суза каршы алып, яулык болгый-болгый озатып калалар. Шофёр, яхшы атка атланып чабуның рәхәтен белгән чабышчы кебек, руль өстенә иелә төшеп, машинаны җил иркенә җибәргән. Машина, үз тизлегенә үзе куангандай, тигез юлдан элдерә генә.

Закир агай, тәрәзәдән йөзен алып, нефтьчеләргә таба борыла, аларның чырайларына карап, уйларын белмәкче була. Нефтьче егетләр буровой юлларында йөрүгә күнегеп беткәннәр инде, алар машинага утырып алу белән, дөньяларын онытып гәп сугарга, уенкөлке сөйләшергә тотыналар, аларның күбесе яшьләр: егерме биш белән утыз арасындагы кешеләр. Алар, Закир Гарипов белән Абдулла Сабирҗанов кебек, бораулауның беренче примитив ысулларын да, авыр сугыш елларында тәүлекләр буе эшләүне дә, еллар буена бер скважина белән азаплануны да күрмәгәннәр. Ә бит андый чаклар да бар иде. Күптәнмени әле, Гариповлар вышкаларны да үзләре монтажлыйлар иде. Ставропольдә разведка өчен бораулаганда гел шулай булды бит. Хәзерге яшьләргә рәхәт аларга! Аларның күбесе хәтта ротор белән бораулауны да, колак тондыргыч ротор үкерүен дә күрмәде, буровойларда турбобур эшли башлагач килде.

Автобус ниндидер бер сикәлтәгә туры килде бугай, бик каты сикертеп җибәрде. Арткы скамьяда утырган төп кебек таза егет – Савинов вахтасының верховое Борис Жарков – чак кына йөзтүбән килеп төшми калды. Аңардан шаулап көләргә, үртәргә тотындылар. Бу көлүнең сәбәбен Гарипов бик тиз төшенеп алды, чөнки Борис, үзара сүз чыкканда, бөтен бәхетсезлек минем башыма ябырыла, мин бу фани дөньяга каргышлы сәгатьтә туганмын, ахрысы, дип «зарланып» йөри иде.

Егет бу юлы да үзенең егыла язып калуын шул бәхетсезлегенә юрады, алгы утыргычның терәгенә ныграк тотынып алгач:

– Иртән генә хатын белән тиргәшеп чыккан идем. Шуның каргышы төшкәндер, – дигән булды.

Нефтьчеләрнең күбесе, мәзәк ишетергә җыенып, кызыксынулы йөзләрен Бориска таба бордылар, тегесе, гомуми игътибардан үсенеп китеп, җәелеп сөйләргә тотынды:

– Дөньяда рәхәт яшим дисәң, өйдәшләр белән яшә икән. Бер квартирада өч семья торабыз: һәркайсыбызда икешәрдән генә дә алты бала, көненә өчәр мәртәбә генә кечкенә йомыш белән чыгып керсәләр, утыз алты тапкыр ишек ачылып ябыла дигән сүз. Аннары дөньяның астын өскә китерә торган, бер-беренә юл куйгысыз өч хатын; кухняга унар тапкыр чыга, унар тапкыр керә дип исәпләсәң дә, өчесенекен бергә кушкач, ул буладыр алтмыш, баштагы утыз алтыны да китереп ялгасаң, аның барысы буладыр туксан алты! Инде шуларның барысы тыныч шартларда түгел, бер-беребезгә үпкәләшкән, даулашкан, нервлар бер өч мәртәбә киеренкерәк вакытта эшләнә дип исәпләсәк, ягъни бу санны тагын өчкә тапкырласак, ул буладыр... буладыр тәүлегенә ике йөз сиксән сигез мәртәбә! Шулай итеп, безнең бүлмә ишеге, семья башлыкларының кайту-китүләрен исәпләмәгәндә дә, тәүлегенә ике йөз сиксән сигез мәртәбә ачылып ябыла булып чыга.

Автобус эчен тутырып кинәт яңгыраган көлү мотор гөрелдесен күмеп китте. Борис үзе көләргә уйламады да, авыз кырыен гына кыймылдатып алды да, сүзен дәвам иттерде:

– Анысы әле нервлар яшь безнең. Утыз яшеңдә әле ул тәүлегенә йөз түгел, мең мәртәбә ишек ачылуга да түзәргә була. Аннары, күршедә салынып ята торган өч катлы йортның чарлагыннан үземә бик шәп бер квартира бирәбез дип торалар. Түзмимме соң, түзәм, ике дә уйламыйм, тик менә шунысы начар: кайчагында өч семьяның әйберләре саташып куйгалый. Бар курыкканым шул: хатыннар гына саташмаса ярар иде, дим. Җенем сөймәгәне күрше белән күршенең даулашып яшәве. Кичә төнлә шулай төнге вахтадан кайтып кердем. Һәммәкәй җирдә тынычлык, тынлык, шылт иткән тавыш та юк. Аллага шөкер, мин әйтәм, ул-бу юк икән әле, иминлек икән әле, дим. Мәшәкатьләмим әле боларны, мин әйтәм, ут яндырмыйча гына тамак ялгап алыйм әле, дим. Өстәл астыннан бер кастрюль эзләп таптым, капшап карыйм: җылы, кашык белән эченә разведка ясап алам: калҗасы шәп – бер кило булыр. Ничек әле, мин әйтәм, хатын алай бик юмартланып киткән минем, дим, нинди яхшылык өчен шулай сыйларга уйлады икән, дим. Ярый, хуш. Эшкә тотындым: вахтадан соң арылган, ачыгылган, бер утыруда бер килолы калҗаны, бер кастрюль ашны ялтыраттым да корсакны сыпырып йокларга яттым. Хатын, гадәтенчә, йокы аралаш: «Фу, шул бензин исеңне, тегендәрәк кит әле!» – дип мыгырданып карады, аңар да исем китмәде, нәрсә – тамак тук, күңел хуш дигәндәй, урынга башны төртү белән, мәрткә киттем дә бардым. Шундый тыныч йокладым, шундый рәхәт йокладым, башка чакта иртәгесен мендәрдән башны ала алмыйча тилмерә торган идем, бу юлы хатыннарның быдыр-быдыр сөйләшүенә уянып киттем. Шуннан, ярар, юрганның кырыен гына кузгатып, күзнең берсен генә ачып карыйм, ни күрәм: минем хатын белән күрше хатыны өстәл буена басканнар, гаҗәпкә калып, кулларын кушырганнар, өстәл өстендә торган кастрюльнең капкачын әле берсе ача, әле икенчесе...

Көлү өянәге тагын автобусны дер селкетте. Бу юлы Закир агай да көлми булдыра алмады:

– Нәрсә, Борис, әллә күршеңнең ашын ашап куйгансыңмы? – диде ул, елмаеп.

– Менә шунда да шул бәла, Закир Гарипович, кеше ашын ашап куйганмын, каһәр. Ә хатыннар мин ашагандыр дип башларына да китермиләр, мәчегә сылтыйлар.

«Ничек бер кило итне ашап бетерде икән, ничек шартламады икән, бәдбәхет?!» – ди күрше хатыны.

«Ите ит инде аның, күрше, – ди минем хатын, – шундый бер чиләк сыешлы кастрюль белән ашны ничек ашап бетергән диген син».

Минем инде моңа түзәр хәлем калмады, дөресен әйтеп бирми булдыра алмадым. Әй хатыннар ябырылды, әй хатыннар чәбәләнде – чыдап кына тор! Ярый әле буровойга барыр вакыт җиткән иде. Аннан-моннан гына киен дә сыз мин тизрәк! Ашаган ит ашалган инде, үлгән артыннан үлеп булмый, базардан алып бирермен әле...

Борис сөйләп бетергәч, егетләр әллә ничек моңсуланып киттеләр.

Закир агай верховой егетнең төп кебек таза гәүдәсенә, бик тырышып кырганнан соң да сакал урыннары зәңгәрләнеп калган йомры иякләренә, бит урталары алсуланып, сәламәтлеге ташып торган чибәр йөзенә эчке бер соклану, ярату белән карады. Үзе басынкы табигатьле, аз сүзле булса да, шат күңелле егетләрне ярата иде мастер. Алар ничектер коллективны яшәртеп торалар, авыргарак туры килгән чакларда да боегырга ирек бирмиләр. Борисның, чыннан да, шәхси тормышы көйләнеп җитмәгән әле, ул армиядән моннан берәр ел элек кенә кайтты, запастагы офицер ул; кайткач та, кая барып сугылыйм икән дип аптырап йөрмәде. Буровиклар мәктәбен тәмамлап чыкты да буровойга эшкә килде. Әнә аның белән янәшә утыручы бораулаучы Сафиуллин Гафиятнең дә квартира ягы бик үк мактанырлык түгел: хатыны, үзе, ике баласы – дүрт җан – баракның кечерәк кенә бер бүлмәсендә яшиләр. Менә авызын бөребрәк, кара күзләрендә очкыннар уйнатып, гел елмаеп сөйләшә торган слесарь Ваһап Галләмов квартирадан да, эшеннән дә зарланмый. Ләкин аның семьясында да бер кыйты як бар – балалары юк. Зәңгәр күзле юаш помбур Гафан Төхфәтовның үз йорты бар, тәгәрәшеп өч баласы үсеп килә; башкаларның таза базык гәүдәләре янында бөтенләй малай гына кебек тоелган, очлы борынлы һәм үткен карашлы Мөгаллим Саяховның да үз өе бар, ул да балаларым аз дип зарлана алмый.

Гафият бригадада күптәннән, аның беренче көннәреннән диярлек. Аңа әйбәт уңай квартира алып бирү турында Гарипов мастер буларак та, шәһәр Советы депутаты буларак та сөйләште, даулашты да. Аңа, бәлкем, тиздән булыр, ә Бориска бераз түзәргә туры килер әле, син ашыгу белән генә түгел шул. Татарстанның нефть районнарында эшләүче 24 мең нефтьченең барысын да берьюлы квартиралы итү җиңел эш түгел ул. Бу якларда йортлар никадәр тиз, никадәр күп салынмасын, барыбер нефтьчеләргә төткәзеп булмый, һәр көн нефть кешеләрне күбрәк таләп итә, һәр көн нефть колачын киңрәк җәя. Ә йорт салучылар төзелеш планын елның-елында үтәп җиткермиләр, нефтьчеләр каршында әле һаман бурычлы булып кала бирәләр.

...Автобус, асфальттан чыгып, тар гына урман юлына борылды һәм ике ягына да биек итеп эскертләп өелгән кар көртләре эченнән бара башлады. Юлның тигезлеге бетте, адым саен тирән казылмалар, чокыр-чакырлар очрады, андый казылмалардан узганда, автобус арткы скамьяда утыручыларны рәхимсез рәвештә чөяргә кереште.

Бер казылмада кинәт мотор сүнеп китте. Шофер кабинадан кар өстенә сикереп төште, аның артыннан нефтьчеләр дә коелдылар. Шофер секретный йозак белән бикләп куйган капот капкачын ачты да, башы белән эчкә таба сузылды, аның артыннан тагын өчдүрт егет мотор янына «кереп киттеләр». Берсе – аннан, берсе моннан карады, «әйдәле,

танкист, әйдәле, дизелист!» дип шаярышып, көлешеп, машинаның авыру җирен эзләп таптылар, шофер өскә менеп газ бирде, астан көпчәк яныннан берсе кәкре ручка белән терсәкле валны әйләндереп җибәрде, мотор гөрт итеп кабынып китте. Ул арада көпчәкләр шактый ук утырган булып чыкты. Таза-таза егетләр – унбиш-уналты кеше – барысы берьюлы җыйнаулашып этеп җибәргәч, машина көпчәкләр өзлексез әйләнүдән җылынып эрегән карны сиптереп кузгалып китте.

Барыр җир дә әллә ни ерак калмаган иде инде. Бераздан буровойлар гөрелтесе ишетелә башлады, автобус һәр буровой янында өчәр-дүртәр кешене коеп калдыра барды.

Соңгы буровой янына җиткәндә, машинада биш-алты кеше генә – Гарипов бригадасының бер вахтасы гына калды.

***

Егерме биш ел нефтьче булып эшләү дәверендә Закир Гарипов буровойга йөзләрчә, меңнәрчә тапкыр килгәндер, бу аның өчен иң гадәти, иң күнегелгән бер эш иде, әмма шул ук вакытта ул, һәрбер килгәндә, яңа, башкача, беренчесенә охшамаганча була иде. Вахта машинасы буровойга якынлаша башлау белән, ул үзендә эчке бер дулкынлану, каушау кичерә иде.

«Буровой әйбәт эшләде микән, ул-бу булмады микән, бәла-казага очрамадылар микән?» – дигән уй бу юлы да аның күңелен кузгатып узды.

Буровой нишләптер дәшми иде.

Егетләр культбудкага сумкаларын, артык-портык әйберләрен куйгалаганчы, ул, төнге вахтаның эшен карарга дип, буровойга йөгерде.

Бораулаучы Василий Гречановский, бөтен битен кара төк баскан, озын борынлы, грузин кыяфәтле кеше, буровой капкасыннан арып-алҗып килеп чыкты, ротор тирәсендә кайнашучы башка егетләрнең дә өстеннән пар күтәрелә иде.

– Ну, ничек?

Мастерның беренче сүзе шул булды, һәм ул, артык бер сүз дә дәшмичә, бораулаучының йөзенә төбәлде.

– Ярыйсы, – диде Гречановский, бик үк җәелеп китмичә, – проходканы өч йөз егерме бишкә җиткердек, әлерәк кенә кондуктор төшерә башладык... бораулаган чакта суны өзеп куйдылар, юкса кондукторны төшереп бетерергә исәп иде.

Мастерның эченә җылы йөгерде, индикатор янына китте:

– Каяле, провокатор нәрсә күрсәтә?

Диаграмма сызып, вахтаның ничек эшләвен күрсәтүче бу приборны бораулаучылар шулай дип атыйлар.

Ул арада Сафиуллин вахтасы да буровойга килеп керде, күз карашлары белән, берике сүз белән төнге вахтаның хәлен сорашып белгәч, егетләр, иркен сулап, вахтага басарга әзерләнделәр. Авария-мазар булмауга барысы да шатландылар.

Слесарь Ваһап вышка түбәсенә винтларны карарга, ныкмы икәннәрен тикшерергә менеп китте, юкса кайвакыт вышка түбәсеннән төшкән кечкенә генә бер кадак та кешене имгәтергә җитә кала.

Гафият үз урынына килеп басты һәм сабыр гына иптәшләренә карап алды. Йөзе аның чын татар малайларына охшаган: табигый кара-кучкыл, күзләре кара, кашлары да кара һәм ул куе кашлар бераз борын турысына тартылып торулары белән аның кыяфәтенә кырыслык бирәләр, ләкин кабарынкы бите һәм табигать бер дә кызганмыйча ике кешелек итеп биргән калын юаш иреннәре әлеге кырыслыкны алып ташлыйлар.

Гафият буровойга илле беренче елны, бернинди тәҗрибәсез, берни белмәгән килеш килгән иде. Ул да Закир ага узган юлны узды: верховой булды, помбур булды, инде менә

бораулаучы булып күчте. Буровой белән бер вахта буена җитәкчелек итү, миллион сумлык җиһазга һәм кешеләрнең исән-сау эшләүләренә бер вахта буена җаваплы булу аның өстенә йөкләнде. Җир асты «капризларын» да күзәтеп барырга тиеш әле ул. Тормоз рычагы янына баскан бораулаучы – ул ике мең метрга якын тирәнлектә әйләнүче турбинаның холкын күңел күзе белән күреп торучы кеше. Менә шундый бораулаучыларының күз карашына буйсынып эшләүче бердәм коллективың булганда, үзеңә һич тә көне-төне буровой сагалап ятуның кирәге юк, әгәр инде егетләрең төпле түгел икән, син аларда акыл белән эш итү, һәрбер хәрәкәтең, һәрбер кыланышың өчен үзеңне җаваплы итеп тою хисе тәрбияләмәгәнсең икән, синең кадерең шулкадәр генә. Ул чагында мастер исемен күтәреп тә йөрмә. Ул чагында син, каккан казык кебек буровойда көне-төне басып торсаң да, берни дә тоҗыра алмыйсың.

Ихтимал, Закир агайның сөенеп искә алырлык зур бер эше менә шушыдыр. Авыр чагында җебеп төшми торган, бердәм эшли белә торган, акыллы, дисциплиналы коллектив тәрбияләүдер...

Гафият, тормоз рычагын күтәреп, механизмнарны ходка җибәрде, идарә пультларына кагылып алды, һәм шулвакыт бөтен буровой эчен тутырган, астан караганда тегәрҗеп калынлыгы булып күренгән дистәләрчә корыч арканнар хәрәкәткә килде, кыймылдашырга, чайкалырга тотынды. Ике егет – помбур белән буровой эшчесе – корыч арканнарның берсенең башына беркетелгән ике җәпле кармак белән бүрәнә юанлыгы кара торбаның биленнән эләктереп алдылар. Корыч аркан киерелеп тартылды һәм ярты тонналы торбаны җиңел генә, җай гына буровой капкасыннан алып кереп китте.

Егетләр аның башына элеваторны киертеп, чаңгылдатып бикләп алдылар, әкиятләрдәге коточкыч зур кыслага охшаган тали блогы, кармавычлары белән эләктереп, торбаның аргы башын югары күтәрде, ул турайды, аягүрә басты, аның эченнән яньчелмәгәнме яисә башка берәр хәл булмаганмы икәнен билгеләү өчен салынган шаблон – бер пот чамасындагы дүрт аяклы тимер – чаңгылдап җиргә килеп төште. Егетләр торбаның аскы башын буровой капкасына бәйләп куйган сүс аркан белән тотып алдылар, бауны кулдан ычкындырмаган хәлдә, һавада асылынып, чайкалып торган торбаны ипләп кенә, әкрен генә скважинадагы торба турысына китереп туктаттылар һәм торбаны торбага ялгарга керештеләр.

Машина белән кеше арасында калган корыч торба, буровикларның акыллы хәрәкәтләренә буйсынып, астагы торбага борылып керде. Сафиуллин янә тиешле рычагына, идарә пультларына китереп басты. Хәрәкәт кискенрәк булды бугай, торба ротор авызына чыкырдап керә башлады.

Ул да түгел, югарыда тали блогы чайкалып китте, тимергә тимер зыңгылдап бәрелгәне ишетелде, вышка атламаларыннан бозланып каткан кар шыбырдап коелып төште.

– Әкренрәк сез, егетләр, чамалап, – диде вахта эшен карап торган мастер, шелтәле дә, киңәш тә биргән тавыш белән.

Сафиуллин чыгырның хәрәкәтен киметте, тали блогына тагылган торба әкрен генә, тавышсыз гына забойга сеңә барды һәм бераздан ул бөтенләй ротор авызына төшеп утырды.

Егетләр тали блогының «кармавычларын» элеватордан ычкындырдылар. Гафият кранны япты, кайдадыр эчкәре кысылып яткан һава бик каты чыжылдап куйды, әйтерсең бөтен буровой «Ах, бу да булды!» дигән сыман уфылдап тын калды.

***

Һәрбер буровойның үз тарихы, үз сәхифәсе бар. Бер караганда, барысы да бертөсле булырга тиеш иде кебек: бер үк тирәнлектә, бер үк горизонтта яткан нефть катла-

вын бораулыйсың, инструменты да, кешеләре дә бер үк, ләкин бер генә скважина да икенчесенә охшамаган.

1950 елны Азнакай районы Мәлбагыш авылы янында 37 нче номерлы скважинаны – Татарстанга килгәч, беренче скважинаны – тиз бораулап бетерделәр, әмма үзләштерү канга тоз салды. Каротажчылар бөтен эшне боздылар да куйдылар. Инде менә нефть килер дип пулемёт-перфораторлардан аттырдылар – юк кына бит нефть: торба йә өстәнрәк, йә нефть катлавының астыннанрак тишелгән була; күзләрен бәгрәйтеп нефть көтәләр, зарыгып көтүдән йөрәк сулкылдап сызлый башлый, – кая ул нефть! – тозлы су атыла да килеп чыга. Нефть фонтанын аттыра алмыйча ике ай буе азапландылар.

Ә бит әле ул чакта, хәзерге төсле, авырлыкларга түзәргә өйрәнгән ныклы бригада юк иде; егетләр яшь, тәҗрибәсез иде, чыдамлылык дигән сыйфат чамалы, нервланалар, сүгенәләр, аларның көйсезләнүе мастерның йөрәген тырный иде. Өстәвенә, өйгә кайткач, Сәрби апаң да җанны ашый: гомерем үтте, юньле-рәтле тормыш күрмәдем, ди, чегән төсле, гомер буе күченеп йөрергә язган, ахрысы, ди. Хатынының сүзләрендә дә хаклык бар иде. Чөнки байтак күченеп йөргәннән соң, ниһаять, алар Куйбышевта, унике ел нефтьче булып эшләү дәверендә, әйбәт кенә төпләнеп алганнар, иркен генә квартиралары бар, йорт кирәк-ярагын да булдырганнар иде. Татарстанга күчә башлагач, кайсын сатып, кайсын күршеләргә биреп калдырырга туры килде. Ишле семья белән, төенчекләрен күтәреп, буш далага килеп төштеләр. Ни дисәң дә, өйдәге авырлык хатын-кыз өстенә өелә: берсеннән-берсе кечкенә җиде бала, бораулаучы егетләр килгәч чыгып тезеләләр, агай: кечесен олырагы күтәргән, олырагы аннан да олырагын күтәргән. Боларны ашату, боларны йоклату, сугышсалар, елашсалар аеру – барысы да Сәрби апа өстендә. Ә икенче семья, монысыннан ишлерәк һәм монысыннан көйсезрәк семья – бораулаучылар семьясы – Закир агай өстендә. Куйбышевтагы бораулаучыларын бирмәделәр аңа, Татарстанга килгәч, яңа бригада җыярга туры килде. Егетләр яшь иде, аларны өйрәтергә, аларны эшләгән эшеңнең һичшиксез барып чыгачагына ышандырырга, буран-кыҗан вакытларда күңелләрен сүрелдермичә, рухларын төшермичә сакларга кирәк иде. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, икенче скважина бик авыр булып чыкты, катлауланулар башланды, аны бораулау нәкъ бер елга сузылды. Егетләр менә кайда чыныктылар; чыныкмаганнарын, ыңгырашучыларны, тәртип бозучыларны мастер рәхимсез рәвештә куды. Бригадада кем калды? Ваһап Галләмов – Үзбәкстанны, Памир тауларын гизгән дизелист; Николай Ветров – элекке сугышчы, солдат; Гафият Сафиуллин – элеккеге шахтёр; Гафан Төхфәтов белән Әнвәр Кашапов – Совет Армиясе мәктәбен узып чыныккан егетләр. Шулар тирәсенә башка малайлар – нык характерлы, эшкә җаптәш авыл малайлары тупланды. Болар бригаданың ныклы тоткасы булып кына калмады, бәлки шушы ныклы бригада Әлмәт ягына, Миңлебайга күчеп килгәч, башка бригадаларның да үрчеп китүенә сәбәп булды. 1952 елда инде Закир агай, яңа бригада оештыру өчен, үз бригадасыннан ике бораулаучы, ике помбур бүлеп бирә алды.

Дөрес, бригаданы бүлгәләүгә мастер ике кулын җәеп, рәхим итегез, дип тормады. Ни дисәң дә, бригада үзе дә яңарак кына көч җыйнап, яңарак кына тернәкләнеп килә иде әле. Әгәр берәр дорфа начальник әйткән булса, бригадаңны икегә бүлик, безнең кешеләр җитми, дисә, эш приказ тәртибендә барса, Закир агай якын да килмәгән булыр иде, әмма сораучысы сорый белеп сорагач, юл куймый булдыра алмады. Яшь кенә булса да бик ихтирамлы, кешеләрнең хезмәтен күрә белүче, тәмле теле белән җаныңны эретеп җибәрә торган инженер Рафыйк Миңгәрәев, ул чагында бораулау конторасы начальнигы, бригадага үзе килде, аларның һәрберсе белән әйбәтләп сөйләште, хәлнең авырлыгын аңлатып бирде һәм Закир агайның шулкадәр якын итеп килгән кешегә каршы әйтергә теле әйләнмәде. Аның каравы, Миңгәрәев үзе дә ярдәм итте инде: мастерга квартира

кирәк булгач, буровойдан кайтмый яткан Гариповны эзләп үзе килде дә, ай-ваена карамый, Әлмәткә куып җибәрде; хәзер үк чап, диде, машинасын бирде, синең урыныңда үзем карап торам, юкса квартирасыз каласың, диде. Күрәсең, яхшылыкка яхшылык белән кайтарасы килгәндер. Тагын шунысы да бар, инженер дөрес әйткән икән, бригада икегә бүленгәннән соң көчсезләнмәде, киресенчә, ничектер яшәреп, яңарып китте. Картлачлар урынына яшьрәк бораулаучылар басты һәм бригада үз дәрәҗәсен саклау өчен көрәшә башлады.

1952 елны, 516 нчы номерлы скважинаны бораулаганда, моңарчы күрелмәгән уңышка ирештеләр. План буенча йөз ундүрт көн бирелгән иде, керн алып, бик мәшәкатьләнеп бораууларга кирәк иде. Шуңа карамастан алтмыш ике көнгә алдан бетерделәр. Егетләргә премия рәвешендә мул гына акча да эләкте.

Китте шуннан егетләр дәртләнеп!

Бригадалар арасында барган ярышка да килеп кушылдылар, вахта белән вахта ярыша башлады.

Татарстан җире рекордчыларга ярлы түгел, Гарипов Әлмәт якларына кайтып эшкә тотынганда ук инде, аның Мөгаллим Гыймазов, Газим Гайфуллин, Юдин кебек атаклы кешеләре бар иде, алар янына тагын бераз соңрак Мотаһар Нургалиев, Михаил Белоглазов, Иван Моржавин кебек кыю йөрәкле яшьләр өстәлде.

Бораулау тизлеге аена 400–500 метрдан 2000–3000 метрга кадәр сикерде! Әле күптән түгел генә ел буена бораулана торган скважина бер ай эчендә, хәтта кайбер очракларда аннан да тизрәк бораулана башлады.

Гарипов беркайчан да рекорд артыннан кумады, әмма аның бригадасы намуслы эше белән, алган йөкләмәсен, әйткән сүзен җилгә очырмавы белән хөрмәт казанып килде. Узган елны аның бригадасы һавалар торышы бик әшәке туры килгән, буровой юллары ерып чыккысыз баткакка әйләнгән чакта да, рекордчыларның байтагысы вәгъдәләрен үтәмәгән чакта да, сүзен сүз итте, коммунист-мастер ил-көн каршында йөзенә кызыллык китермәде. Унбер мең метрын җиренә җиткереп бораулап бетерде.

Билгеле, тормыш булгач, төрле чак була: шатлыклы чагың да, кайгылы чагың да. Закир агайның егерме биш ел нефть эшендә эшләве дәверендә кайгылы-борчулы чаклары булмады түгел – булды. Ләкин аларның инде күбесе онытылган, күбесен болай хәтергә төшерәсе килми, ә менә шатлыклы чаклары күңелдән китми саклана. Быел март аенда аның өчен ике түгәрәк дата бергә туры килде: быел аңа илле яшь тулды һәм шушы вакытка ул илле мең метр җир куенын бораулады. Шуның барысы турында уйласаң, күңелдә бераз моңсу да, сөенечле дә булып китә. Моңсу шуңар: чөнки гомернең инде арыслан тотардай гайрәтле чаклары узып киткән, сөенечле шуңар: чөнки ул гайрәтле чаклар җилгә очмаган. Илле мең метрның вышкалары, эшләгән эшнең истәлеге булып, җир өстендә, илнең төрле өлкәләрендә утырып калганнар. Ул вышкалардан җир астына, нефть ятмаларына туры юллар сузылган, ул юллар буйлап илгә нефть килә, байлык килә.

Бүген культбудкада, буровойның эшләве күренеп торган түр тәрәзә каршына утырып, бер тәүлек эчендә эшләнгән эшне нарядка теркәгәндә, Закир агай әнә шуларны күңеленнән кичерде.

***

Сафиуллин вахтасы көндезге сәгать икеләргә кадәр әйбәт эшләде, егетләр эш белән шулкадәр мавыгып киткәннәр, хәтта ашауларын да онытканнар иде. Яшерен-батырын түгел, эш алга барган чакта, һәрбер вахтаның күбрәк эшләп, күбрәк бораулап каласы килә. Материаль кызыксындыру принцибы әле күп кенә механизмнарны хәрәкәткә

китерә. Кондукторны төшереп бетерсәләр, бораулый башларга иде исәпләре. Ләкин аяк астыннан көтелмәгән бәла килеп чыкты.

Мастер буровойның тигез генә гөрелдәп эшләвен, ара-тирә элеватор белән шаблонның чаңгылдап куюын һәм бер торбаны ялгап бетергәннән соң, буровойның, авыр сулап, гыжылдап тын алуын тыңлый-тыңлый, язу-сызу эшләре белән утырды, аннары, язулары беткәч, буровой хуҗалыгын барларга дип, ишегалдына чыкты. Берничә көн инде аның су саклый торган җир амбарга эче пошып йөри иде. Бульдозерлар бу амбарны бик уңайлы итеп казымаганнар, аның суны бик иркен әйләндереп йөртер чамасы күренми иде. «Егетләр бушрак арада канау казыйсы булыр»,– дип уйлады мастер. Әкрен генә пар бөркеп яткан буровой белән насос бүлеген тоташтырган манифольд торбалары яныннан узып, балчык измәсе хәзерләүче машина янына туктады. Слесарь Галләмов ул машинаның моторы янына өелгән карны, тирләп-пешеп, көрәп ята иде. Мастер егетләрнең эшне үзләре белеп эшләүләренә сөенде. «Тиздән балчык измәсе ясый башларга кирәк, су белән бораулап бетерүгә, измәгә күчәрлек булсын»,– дип уйлады. Измә өчен балчык алып килгән машинаны кабул итте. Балчыкның яртысы гел кар гына иде, аңа бик каты кәефе китте, анысыннан тынычланып өлгермәде, кайдандыр токны өзделәр. Ни барысы биш-алты торба калгач, кондукторны төшереп бетереп булмады.

Мастер телефоннан бөтен нокталарны әйләнеп чыкты, сорады, гозерләнде, таләп итте, ләкин токның нәрсәдән бетүен дә, кайчанрак җайланачагын да әйтә алмадылар.

Мастер, бөтенләй кәефе китеп, буровой күперен күтәрелде: буровойның көчле механизмнары энергиядән мәхрүм иткәнгә үпкәләгән сыман тынып калган иде.

Гафият вахтасы, ток юклыктан файдаланып тамак ялгап алгач, егетләре белән су амбарын рәтләргә чыкты, тиздән дүрт егетнең балталары, ломнары туң җирне зыңгылдатып ватарга, канау казырга тотындылар.

Токны вахта ахырына кадәр бирмәделәр.

Бораулаучы Николай Ветров вахтасы килгәндә дә, буровойда тын иде әле. Мастер, яңа вахтаның күңелен төшермәс өчен, борчылганын күрсәтмәде. Ветровны яктырып каршы алды һәм, беренче эш итеп, аңа – бригаданың иң яхшы бораулаучысына, ВЦСПС Президиумының почёт грамотасын тапшырды. Карарны тантаналы шартларда, ике вахтаны бергә җыеп укыдылар.

Ничектер сүрән йөзләр ачылып, төшенке күңелләр күтәрелеп китте. Мастер кызлар кебек юаш, басынкы, оялчан бораулаучының кулын кысты, ә башкалар бу вакытта күңел кузгаткыч, тантаналы бу минутларның шаһиты булып тын гына тордылар, соңыннан, барысы берьюлы шаулашып, Ветровны котларга, тәбрикләргә тотындылар.

Закир агай Ветровка үзенә ышанганнан да болайрак ышана һәм аны күптән инде мастер булырга лаеклы кеше дип йөри иде. Бүген буровойдагы катлаулы эшләрнең барысын да ул аңа тапшырып калдырды.

– Тырыша күр инде, Николай Иванович,– диде,– мин үзем дә калган булыр идем, иртәгә безнең шәһәр Советы сессиясе башлана,– диде.

Гафият вахтасы кайтып киткәннән соң да, мастер байтак вакыт Ветровка торбаларны күрсәтеп, яңаларын китерсәләр, инвентарь кенәгәсенә теркәп барырга, ток мәсьәләсендә начальствога тынгылык бирмәскә, дип киңәшләр әйтеп йөрде, аннары, кызыл балчык китергән соңгы грузовикның кабинасына утырып, шәһәргә кайтырга чыкты. Бер ун чакрымны сөйләшми генә кайттылар. Җир өстенә эңгер инде, кар өсләре зәңгәрләнде, агачлар ачык сызыкларын югалта бардылар, шул мәлне кинәт ялт итеп урман эчендәге бер буровойда утлар кабынды. Карт мастерның шундук күңеле яктырып, тынычланып калды, бу Гариповлар буровое иде.

# *Яңа эшләр, яңа кешеләр*

Башка елларга караганда аязрак та, җылырак та булып килгән быелгы көз нефть шәһәрендә әллә ни гомер яшеллекне саклады. Коттеджлар алдына үсеп чыккан бөдрә өрәңгеләр, озын урамнарның ике ягына тезелгән яшь юкәләр һәм сәрби куаклары, әле сентябрь аенда да җәй белән саубуллашырга теләмичә, яшәреп, тулышып утырдылар. Фәкать октябрь башында гына аларга көзнең үзенә бер төрле матур бизәге – сары тут төште, бераздан куакларның яшел итәкләре җирдән учак ягып көйдергән төсле алсуланды, кызарды, аннары көз ялкыны аларны бөтенләе белән чолгап алды.

Кичләрен аяз күк йөзенә җидегән йолдыз калыкты, ничектер биегәеп киткән караңгы күк гөмбәзенә томанлы тасма булып Аккош юлы сузылды. Әле җир асты юллары буйлап китәргә өлгермәгән нефть газыннан, шәһәр читләрендә янып калган факеллардан йолдызлар өстенә нәфис алсу шәүлә сирпелде.

Көннәрнең шулай аяз торуына нефтьчеләр сөенеп бетә алмыйлар иде. Узган елгы яңгырлар, юлларны өзеп, аларның үзәк бәгыренә үткән иде. Ә быел автовокзаллар алдында иртәнге вахтага җыелган кыштырдавык киемле кешеләрнең көр тавышларын еш ишетергә була:

– Матур килде быел көз! Шәп килде!

– Болай булгачыннан, йөкләмәне үтибез инде, туган!

Алар, чираттагы машинаны көткән арада, «Беломор» кабызып җибәреп, озак-озак юллар өстенә карап торалар. Ә юлларның быел асфальт бөркәнмәгәннәре дә тигез, аратирә генә, онытылганда бер генә сибәләп узган көзге яңгырлардан соң алар ялтырап, каешланып калганнар. Әгәр бу көзге шома юллар буйлап төрле тарафларга кереп китсәң, нефть шәһәренең төрле оешмаларына килеп чыгарга мөмкин. Үзәк магистральләр тау буйларына, урман әчләренә килеп җиткәч, агач ботаклары кебек тармакланып, нефтьнең чыккан җирләренә – буровойларга килеп тоташалар. Назлы кыз сыман көязләнеп яткан нефтьне җир өстенә шушында күтәрәләр. Николай Македонов, Михаил Белоглазов кебек кыю егетләрнең бөтен илебезне шаулаткан рекордлары шушында туды.

Ләкин «нефтьне бораулаучылар гына чыгара икән» дип уйласак, без ялгышкан булырбыз. Үзе нефтьче булмаган кеше колагы өчен сәеррәк тоела торган монтажчылар, вышка төзүчеләр, каротажчылар дигән сүзләр бар. Болар – аерым һөнәр ияләре. Болар – бораулаучыларның аерылгысыз юлдашлары. Әгәр болар үз вакытында урман аланына вышка китереп куймасалар, үз вакытында буровойга су һәм ток үткәрмәсәләр, бораулаучылар үзләре генә берни дә эшли алмыйлар.

Нефть үзе белән бик күп яңа эшләр алып килде, ә яңа эшләр үз нәүбәтендә яңа кешеләр үстереп чыгардылар.

Күз алдына китерегез: ачык ялан өстеннән кырык метр биеклегендәге тимер вышка күчеп бара. Һәрберсе сиксән ат көченә ия булган сигез трактор киерелеп тартылган корыч арканнар белән вышканың тигезлеген саклап алып киләләр.

Гаҗәеп бу йөкнең барыр юлы озын әле: ул ун чакрым юл узарга – тау менәргә, тау төшәргә, елгалар-инешләр аркылы кичәргә тиеш. Елгаларны кичкәндә, вышка төзүчеләр аның өчен махсус күперләр салалар, елганы кичкәч, ул күперләрне тагын сүтеп алалар. Бер вышканы күчергәндә генә дә никадәр мәшәкать, никадәр күңел борчуы! Азнакай эшчеләр посёлогында яшәүче уникe кешелек Ваһапов бригадасы быел шундый мәшәкатьле йөк белән инде ике йөз чакрым юл узды.

Намус белән, көчен аямыйча эшләгән кешеләргә һәркайда юл ачык. Әле күптән түгел генә институт яки техникум бетергән яшь белгечләр тормыш биографияләрен буровойларда, промыселларда, төзелеш мәйданнарында эшләүдән башлыйлар. Вышка монтаж-

лау конторасында производство участокларының командирлары, яшь инженерлар һәм техниклар. Гаять зур материаль байлыклар өчен, үз кул астында эшләүче кешеләрнең хезмәттәге уңышы, укуы, үсүе өчен, бәхетле матур яшәве өчен җаваплылыкны алар үз өсләренә алганнар.

Нефтьченең үз эшен уңышлы башкаруы аның тормыш шартлары әйбәт булу белән бик нык бәйләнгән. Бораулау эшендә егерме биш елдан артык эшләп, нефтьчеләрнең ихтирамын казанган өлкән кеше, бораулау остасы Закир абзый Гарипов Әлмәт якларына беренче мәртәбә күчеп килгән көннәрен авыр көрсенү белән искә ала. Ул чагында нефть шәһәре ватман кәгазьләрдә яки төзүче инженерларның күңелендә план рәвешендә генә өлгергән әле. Шулай булгач, үзеннән-үзе билгеле, бораулау остасына, көне-төне буровойда эшләү белән бергә үзеңнең бригада членнарыңны квартираларга урнаштыру, утынын-мазарын кайгырту кебек эшләр артыннан да йөрергә туры килә. Закир абзый, бөтен бригадасы белән дәррәү килеп, Миңлебай авылында посташ торган ярым җимерек йортның тәрәзәләрен куйган, идәнен җәйгән, бер көн эчендә морҗасын чыгарып кергән. Әйе, девон нефтенә юл иң элек шулай башланган. Уйлап карасаң, әле аңа әллә ни күп вакыт та узмаган, күп дигәндә биш-алты ел әле. Ләкин инде ул көннәр, нефть шәһәрен салу буенча башкарылган чамасыз күп эшләр һәм мәшәкатьләр арасына күмелеп, әллә кайчан булган, бик ерак заманнар кебек тоелалар.

Чөнки бу вакыт эчендә инде Зәй елгасы буенда дулкынланып торган шифер түбәле бик матур ак шәһәр үсеп чыкты. Шәһәр белән бергә гаять зур төзүчеләр отряды – ташчылар, штукатурчылар, буяучылар, тагын әллә кемнәр җитеште.

Без Әлмәтнең үзәк урамы – Ленин проспекты буйлап барабыз. Салынып бетеп килә торган өч катлы зур таш йортның кыегында ташчылар кайнаша. Шуның белән янәшә үк икенче бер йортның инде бүлмәләрен штукатуркалый башлаганнар. Йорт алдында измә ящиклары тора, ком таулары, шакмаклап кискән ак ташлар өелеп ята. Транспортёрлар, чыңлап-гүләп, эре бөртекле сары комны югары катларга алып менеп китәләр. Транспортёр алдында бер кыз эшли. Ул көрәге белән-җай гына ком тавына иелә, җай гына күтәрелә, эшли; транспортёр тасмасына карап ала, маңгаена төшеп азаплаган чәч тәлгәшен кул сырты белән җай гына сыпырып куя. Үз эше белән мавыгудан бит алмалары алсуланган бу кызыйны юк-бар сорау белән эшеннән бүләсе килми. Без арырак китәбез. Колонналары белән проспектны бизәп торган «Россия» кинотеатры артта кала. Урамның уң ягындагы беренче йортка керәбез. Монда яшьләр торагы булачак, йорт әйләнәсендә инде измә ящиклары да, транспортёрлар да юк; бина эчендә соңгы эшләр бара. Монда буяучылар бригадасы эшли. Каерып ачып куелган бер тәрәзәдән – югарыгы каттан – кемнеңдер, әлбәттә, кыз кешенең, яңгыравыклы чиста тавыш белән көлгәне ишетелә.

Көлгән тавышларны эзләп, баскычлар буенча өченче катка күтәреләбез. Бүлмәләрдән яңа акшар исе, майлы буяу исе аңкый. Кулларына буяу пумалалары тоткан яшь кенә кызлар идән буйыйлар, панельләр үткәрәләр, сөйләшәләр, көлешәләр.

– Миңлегаян Галиуллинаны күрергә мөмкин булмасмы икән?

Кулына буяу савыты тоткан бер кыз бинаның аргы башына йөгерә. Менә безгә таба өстенә җылы фуфайка кигән, башына шакмаклы шәл бөркәнгән уртача буйлы бер кыз килә. Килгән уңайга ул, майлы буяуга буялган бәләкәй кулларын кая куярга белмичә, уңайсызланып туктап кала һәм аның озынча ягымлы битендәге буяу тапларын хәтерләткән сары сипкелләре күбәебрәк киткәндәй була, чөнки уңайсызланудан ул комач кебек кызара.

Почёт тактасындагы рәсеменә һәм икенче төзелеш районы конторасының стенгазетасында язылган мәкаләгә караганда, Миңлегаян безгә олырак яшьтәге апа сыман тоелган иде. Ул әнә бөтенләй яшь кеше икән.

Без сөйләшеп китәбез.

Миңлегаян 1951 елны Бондюг районында унынчы классны тәмамлаган. Аннары бер ел Удмуртиядә таш шахтасында эшләгән. 1953 елда Әлмәткә күчеп килгән һәм биш ел эчендә гади бер буяучыдан егерме алты кешелек комплекслы бригаданың җитәкчесе булып күтәрелгән.

Нефтьчеләрнең эше уңышлы баруда менә шушы сипкел битле оялчан кызның да, аның бригадасында эшләүче егермедән артык башка егетләр һәм кызларның да өлеше бар. Алар, белемебез бар, дип, безгә кара эш кирәкми, дип, җайлы, җылы урын эзләп йөрмиләр, үзләренә тапшырылган эшне иренмичә, намус белән башкарып киләләр. Алай гына да түгел, алар һәрбер яңа нәрсәнең серенә төшенергә тырышалар.

Әлмәттә быел төзелеш эшендә яңа прогрессив наряд дигән яңа метод кертелде. Мәсәлән, әйтик, унбиш көндә бетерәсе эшне ун көн эчендә бетерсәң, бермә-бер күбрәк хезмәт хакы түләнә. Бу метод дәүләт өчен дә, эшчеләрнең үзләре өчен дә файдалы, йорт тизрәк эшләнеп бетсә, тизрәк нефтьчеләр квартиралы була. Буяучылар үзләре дә ул чагында көнлек хезмәт хакын утыз сум түгел, илле сум алалар.

Миңлегаян бригадасы өченче прораблыкта бер йортны унбер көн эчендә буяп бетереп, көненә илле җиде сум хезмәт хакы алуга ирешә. Моннан тыш бу бригада, икмәк заводын буяганда, стеналарны яңа төр кушылма (известь, алебастр, клей һәм сабын кушылмасы) белән грунтлап, ике йөз килограммнан артык олифка экономия ясый.

Нефть районнарында эшләүче мондый хезмәт алдынгыларын хәзер күпләп очратырга мөмкин.

***

Әлмәт кешеләре көзге урамнар буйлап ашыкмыйча гына атлап йөрүче бер картны күрергә күнеккәннәр. Олысы да, кечесе дә аны әллә каян танып алалар.

– Исәнме, Мортаза бабай!

– Сәламәтлегең ничек?

Бабай кулларын артына куеп барган җиреннән бер мәлгә туктый, сәлам бирүченең кем икәнен танып алгач, якты зәңгәр күзләре белән елмая; ак сакалы, ак мыегы арасында тәүге төсен җуймый саклаган куе кара кашлары очынгалап куя.

– Шәһәрне карарга чыктым,– ди ул, хәл-әхвәл сораганга кәефе килеп.– Үзгәрде безнең яклар, үзгәрде... Менә бу төштә элек басу капкасы иде, бу ягында сыңар күзле янтык йортлар бар иде...

Әйе, җитмеш биш яшьлек бу карт, коммунист һәм пенсионер, туган-үскән якларындагы үзгәрешне безнең барыбызга караганда да күбрәк аңлый, күбрәк тоя. Чөнки ул алпавыт властен кешедән ишетеп түгел, үз җилкәсендә татып белә. Совет власте өчен барган авыр көрәш елларын китаптан укып түгел, үз күзе белән күреп, җаны белән тоеп белә. Әле кечкенә малай чагыннан ук Бөгелмә өязенең Павловка авылында ул ун ел буена алпавыт Елатчка бил бөккән. Аннары солдат хезмәтенә алынып, унөч ел флотта хезмәт иткән. Рус-япон сугышы дәһшәтләрен гомердә онытасы юк аның. Курск ягыннан килгән матрос Яшинның татар крестьяннары турында сәгатьләр буе сорашып утыруы да хәтергә сеңеп калган. Октябрь революциясе җиңгәннән соң, совет власте казанышларын саклап калу өчен барган кискен көрәш вакытында Мортаза Ибраһимов җитәкче постка баса: Әлмәт һәм Урсалы волостьларында волость башкарма комитеты председателе булып эшли, кулак хуҗалыкларыннан контрибуция җыя. Шуның өчен Колчак бандалары аның йортын туздырып, семьясын урамга чыгарып ташлыйлар. Икенче бер вакыт ак бандитлар аның үзен ат янына, тәртәгә бәйләп йөртәләр. Мортаза бабай җәза урынына алып барганда, бу үлемнән Карабаш урманына качып котыла. Качып өлгермәгәннәрне

Туймазыга алып китеп аталар...

Әлмәт зиратында гади генә бер кабер бар. Ак ташка чокып, гарәп хәрефләре белән «Комиссар Әнвәр» дип язылган. Мәрхүмнең исеме алдына өстәлгән «комиссар» сүзе үзе үк бик күп нәрсә турында сөйли. Әнвәр – шушы якның Бигәш авылы кешесе, хәрби комиссар, авыр көрәш елларында аны ак бандитлар җәзалап үтергәннәр. Андый гади таш астында комиссар яки революционер дигән исем белән йоклаучы исемсез батырларны Татарстан авылларының һәрбер зиратында диярлек очратып була. Безнең әтиләребез купшы тирадалар сөйләргә, бигрәк тә кабер ташларына күп сүз язарга күнекмәгәннәр. Алар өчен «комиссар» яки «революционер» дигән кыска бер сүз башка барлык сүзләрдән кадерлерәк булган, чөнки ул сүзләр аларның яшәү мәгънәсен аңлатып биргән.



Әдип Маликов, Наилә Закирова, Үзбәк Саттаров, Шәһидә Максудова, Гариф Ахунов, Шәһит Таипов. Әлмәт, 1975

Алар башкарган эшнең, Октябрь казанышларының зурлыгын, ул дәһшәтле көннәр ерагая барган саен ныграк сизәсең.

Элек буш дала яки кечкенә бер авыл булган урыннарда куәтле нефть шәһәрләре үсеп чыкты. Әлбәттә, сүз белән генә әйткәндә, моның бөтен эчке мәгънәсен аңлап җиткермәскә мөмкин, чөнки без илебездә барган мондый гигант төзелешләргә чамадан тыш күнектек инде. Әмма Зәй буена, тын авыллар буена беренче яшел палаткалар төзелүен, юл кожаныннан, авыр күн итекләрдән, хуҗаларча нык басып, беренче геолог узуын күргән кешеләр яңа төзелешләргә совет кешесенең никадәр көче кергәнен бик яхшы аңлыйлар.

Һәрбер яңа эш яңа кешеләрен дә тудыра. Авылга беренче трактор килгән көнне искә алыгыз. Корыч төрәннәр гомерлек ызаннарны җимереп ташлап, бәрәкәтле кара туфракны гайрәт белән әйләндереп салганда, күңелләрдә шатлык өермәсе кузгалды. Боларны гади бер авыл егетенең башкаруы аеруча сокландыргыч иде. Аннан соң инде күп гомер узды. Хәзерге яшьләр өчен дырылдавык торбалы фордзон тракторлары түгел, алтмыш ат көчле чылбырлы тракторлар да гади бер нәрсәгә әйләнде. Үзе бер завод кадәрле буровойда эшләүче бораулау остасы өчен аның шулай булуы табигый дә. Чөнки ул хәзер җир куенын трактор әйләндереп салган утыз сантиметрлы буразна тирәнлегендә генә түгел, ике чакрым тирәнлегендә күреп тора, аның ихтыярына берьюлы дистәләрчә катлаулы механизмнар буйсына...

Тормышның бүгенге сулышы шундый. Канлы көрәшләр белән яулап алынган Октябрь революциясенең бүгенге казанышлары шундый.

*Әлмәт*
*1957*

# Хатлар

*1954, 27 август*

«Рафаил дус!

Хатыңны кичегеп укыдым. Авылга чыккан идем – командировкага.

Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә балык үстерү буенча катнашучы бер колхоз турында очерк сыман бернәрсә яздым. Кичегеп булса да, җавап язам. Хатың бик шатландырды. Хезмәт кешеләре арасында яшәгәч, материал табыла шул. Давай, син аны тизрәк төгәллә дә Казанга кил. Укырбыз. Тик, малай, шунысы бар: Гомәр абый ялдан кайтмады әле. Ике айсыз да кайтмый.

Аннары син минем заданиене һаман онытасың. МТС турында безгә бер очерк яз әле, үтенеп сорыйм. Журналда бернәрсә юк ул турыда. Повестеңның хәле ничек? Аны да бик сузма инде син.

Конкурска бирүең белән, тешне кысып булса да килешәм. Журнал кешесе ул ягын карый бит инде!

«Җәйге челләдә»ң 9 нчы санга керә. Габдрахман абый белән Кашшаф абый укыдылар, яраттылар. Гази абыйның бер замечаниесе бар: Хөббениса карчык җәзасыз кала, ди. Менә шул. «Аннары хикәя сузыла, сюжетны боза бит ул», – дип җавап бирдем мин.

Ярый, хәзергә хуш. Килгәч сөйләшербез.

Кайнар сәлам белән Г. Ахунов
27.08.1954».

*1954, 3 сентябрь*

«Рафаил дус!

Хатыңны куанып укыдым. Бик шатландырдың, малай. Минем теләк үтәлде, болай булгач: синең бит безне ярата торган гадәтең бар. Какой-нибудь ярты ел эчендә бездә өченче хикәяң басыла. «Яңа магазин»ыңны бик яратканнар. Санияләр, Гөлшатлар бик сөйләп тордылар. Димәк, бу хикәяң безгә. Мин аны хәзер укырга утырам. Ләкин шуңарчы хат язмыйча сабырлыгым җитмәде.

Мин сиңа, дус кеше, хат язган идем, син әйткән «кош теле»н. Күрәсең, бу хатка чаклы барып җитмәгәндер. Ярый, анысын алгансыңдыр инде. Андагы хәбәрләрне язып тормыйм. Шуны гына әйтмәкче булам: хикәяңнең газетка китүен бер дә теләмәгән идем.

Семья хәлләре турындагы кайгыңны бик уртаклашам, туганкай. Үземдә шул ук хәл – ике ай инде прописать итмиләр. Әллә нинди бер бюрократка туры килдем. Повестьны ике ай кулга тота алмадым. Хәзер, синең кебек үк, утын артыннан йөрим. Тәрәзәләрне сыласы бар. Карчык эшкә урнашмакчы була, баланы яслегәме, нәнкегәме бирергә кирәк.

Ләкин мин һаман Макаренко сүзен истә тотам. Ул акыллы абзый: шәхси борчуларга күңел төшереп, борынны салып йөрергә кушмаган. Язарга, язарга! Гомер уза бит ул, күрми дә каласың.

Повестеңны цикл итеп эшләүгә мин риза, чөнки син хикәядә әйбәтрәк йөзәсең. Ә бит хикәя язучылар бездә аз (әйбәт хикәя, дим). Мирсәй Әмир менә хикәя мастеры, ә романы

бик сузынкы, сүлпән килеп чыкты. Аннары хикәяне укучы да бик ярата, чөнки әйбәт хикәя кыска, образлы, төгәл эшләнгән була. Аны су эчкән кебек укып чыгасың – сразу. Болай матур башланган. Омтылдыра.

Хикәяңне укып чыккач, тагын күбрәк язармын. Хәзергә хуш. Карчыгыңа бик күп итеп сәлам әйт. Борыныңны салындырма. Безгә бер очерк та язып җибәр әле. МТС кешеләре турында, кабат үтенеп сорыйм.

Иң яхшы теләктә калам.

Сәлам белән Г. Ахунов, «С. ә.» редакциясе
3.09.1954».

*1954, 17 ноябрь*

«Рафаил дус!

Озак кына сиңа хат язып булмады. Редакция ыгы-зыгысы белән көн үтә дә китә. Бүген-иртәгә, бүген-иртәгә дип, хат кала бирә.

Ярый, кыскача – мин синең хатыңны алдым, бик куанып укып чыктым. Син, малай, минем очерк сыман нәрсәне яраттым дигәч, күңел булды әле. Мин синең искренний кеше икәнеңне беләм инде. Замечаниеләрең белән тулысынча килешәм – читтән күбрәк күренә шул ул, дус! Чыннан да, «чык кунган» булырга мөмкин чәчәккә, кечкенә күләмле әйбергә. Аннары «ярсу, дәртле, шашкын» һ.б. шундый сүзләрне бит аны кайчакта шул шашкынлыкның үзен күрсәтеп бирә алмаганда, көчсезлектән кулланасың.


Син, дус кеше, шундый кимчелекләрне күбрәк, ешрак күрсәтә торсаң, бик шәп булыр иде, чөнки мин инде хәзер, әнә ул «ярсуларны» кулланганда, синең замечаниеңне гел искә төшерәчәкмен!

Бер-беребез турында кайгыртмасак, олылар әллә ни кайгыртмас безнең турыда.

Хәзер синең турыда. Фатих абзаңның ачык хатын укыгансыңдыр. Үзе болай бик җылы, яхшы теләк белән язылган. Сиңа ничек тәэсир иткәндер, белмим. Миңа шулай тоелды. Ләкин ул «Магазин» белән ялгыша. Бу аның чираттагы бер дуамаллыгы, үзенчә әйтсәк, «очып кунуы». Сиңа бик ялгыш нәрсә тәкъдим иткән бит ул: имеш, Галия егетенә әйттерсә булмыймы? Хикәя нәкъ шул алдан әйтеп куюларга, итәк астыннан сатучыларга каршы язылган да.

Күптән түгел Союзда (Язучылар союзында)«Совет әдәбияты» журналына багышланган җыелыш булды. Сине анда бик күтәрделәр, Гази Кашшаф, Салих Баттал һ.б. синең «Магазин»ыңны как раз яклап чыктылар. Хөсни абзаңның хаклы булмавын әйттеләр. Так что, аптырап калма, дип әйтүем. «Фатих Хөсни үзенең авторитеты белән яшь язучыны ялгыш юлга да кертергә мөмкин», – диделәр анда. Менә шул.

Тагын шуны әйтим: без уникенчене төшердек, яңа ел номерын әзерлибез. 1955 ел-



Шәһидә Максудова улы Рәшит һәм кызы Наилә белән. Әлмәт, 1960

да син нәрсәләр (конкрет) бирергә уйлыйсың, язып җибәр. Планга кертергә кирәк ул. Быел безнең материал күп. Ике роман, ике повесть портфельдә инде. Мин пока сине «Авыл турында хикәяләр» дип планга керттем. Кайчангарак конкрет нәрсә тәкъдим итә аласың?

Үзем повестьны бетердем диярлек. Машинкада бастырып ятам. Съезддан соң (Мәскәү съездыннан) тикшерүгә бирергә уйлап торам. Бәйрәмне яхшы иттек дип әйтергә була. Сез ничек? Яхъя белән Сания анда иде бәйрәм вакытында, ләкин Яхъя сине күрмәгән. Мин бик аптырадым.

Пока, хуш. Карчыгыңа бик күп сәлам әйт. Хат яз!

Сагынып, сәлам белән Гариф Ахунов
17.11.1954

P.S. Бүген университетның 150 еллыгы. Бик зур тантана. Тантанага – кичәгә – абзаң да бер билет эләктерде. Бөтен Союздан кунаклар була, дип сөйлиләр. Ничек булыр».

*1959, 23 февраль*

«Рафаил дус!

Хатыңны алдым. Ниятең бик яхшы. Хәзер конкрет эшкә керешергә кирәк.

Сиңа квартира мәсьәләсен сөйләштергәнче, безнең кулда синең гаризаң булырга тиеш. «Әлмәт шәһәре Советы председателе Закиров Усман Закировичка, диген, фәлән-фәлән язучыдан (СССР Язучылар союзы членыннан), диген, гариза, диген. Гаризада



Сулдан уңга: Гариф Ахунов, Шәһидә Максудова, ..., Саҗидә Сөләйманова, Нәби Дәүли, Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин. Әлмәт, 1967

хәзер кайда булуыңны, кайчан кайтасыңны, гаиләңдә ничә кеше бар – шуларның барысын әйтеп яз. Үзең беләсең, андый нәрсәләр рәсми рәвештә эшләнә бит.

Ярый, хатның рәсми өлеше бетте бугай, инде үзеңә, Рәшиткә, безне сораган башка иптәшләргә бик күп сәлам. Үзем утырган тавык кебек өйдә, эш муеннан. Синең хатың килеп төшкәч, әллә ничек бик күңелле булып китте. Кайтырга чынлап торып уйлавың тагын да шәбрәк. Әлмәт хәзер бик күңелле, бөтен-бөтен нәрсә бар, шәһәр туктаусыз үсә, йортларны дүртәр катлы итеп сала башладылар. Эш мәсьәләсендә – кайда эшләрсең, ул кадәресен әйтә алмыйм әле. Шәһәр газетасы редакциясенең штаты тулы. Көзгә таба Культура сарае төзелеп бетәчәк. Безнең әдәби берләшмәгә шуннан аерым бүлмә бирергә уйлыйлар. Мин үзем беркая да эшкә кермәдем, язу-сызу белән тамак туйдырып барам. Бер яктан, бу кыен, эшләмәгәч, ай саен акча килеп тормый, ләкин тырай тибеп йөрмәсәң, гадәти генә яшәргә була. Язу өчен вакыт та күп кала. Бәлкем, карчыгың эшкә урнашса, шуның белән риза булып торыр идең. Гомумән, ул ягын күз күрер әле. Кайту фикереннән ваз кичә күрмә. Биредә Сәет Кальметов, Әдип Маликов, Фазыл Мостафин һ.б. иптәшләр бар. Минем үземнең, мәсәлән, Казанны искә дә кертеп чыгарганым юк.

Синең семья ишле, өч бүлмәле квартира алып булыр дип ышанам.

Ниләр җимерәсең? Иркенрәк итеп хат яз.

Кабат сәлам белән Гариф Ахунов
23.02.1959».

*1959, 8 апрель*

«Рафаил дус, исәнме!

Миннән хат көтә-көтә, күзләрең күгәргәндер инде. Кайбер объектив сәбәпләр аркасында тиз генә хат яза алмадым, гафу ит. Хикмәт менә нәрсәдә: синнән хат килеп төшкән көнне Закиров (горсовет председателе) Казанга Тат. Верх. Советы сессиясенә киткән иде. Биш көннән соң үземә чыгып китәргә туры килде. Казанда унбиш көн торып кайттым. Шулай итеп, без аймылыш булдык.

Квартира мәсьәләсендә борчылма, гаризаңны бирдем, Усман абзый (Закиров) караган, җәйгә обязательно бирербез, диде. Обкомнан Булат Гыйззәтуллин да бар иде (ул хәзер бүлек мөдире анда), Булат алдында вәгъдә бирде. Укып бетереп кайткач, бер ай көтәргә туры килер, ди. Квартира өч бүлмәле булачак. Шуңа канәгатьме син, әллә дүрт бүлмәле кирәкме?!

Укуыңны бетерү белән, Әлмәткә килерсең, пока ялгызың. Минем квартирада торып торырсың. Квартир хәзер бик иркенәйде минем – өч бүлмәле, алтмыш кв. метр чамасы. 4 апрельдә яңа квартира бирделәр, элек ике бүлмәле иде. Мин дә, квартира алганчы, бер ай Мостафиннарда торып тордым.

Бездә туры абзыйлар вәгъдәле, әйткән сүзләрендә торалар.

Афзал абый синең турыда обкомда сөйләшкән (скорее всего Афзал Шамов – предс. Правления СП Татарстана, 1958–1961 гг.). Промышленность бүлеге мөдире Князев синең Әлмәткә кайтуыңны хуплаган.

Союз үзе сине башта: «Чаллыга күчерү әйбәтрәк булмасмы?» – дип тора иде. Анда бик зур химкомбинат төзелә, Әлмәт кебек зур шәһәр салына. Алар, янәсе, анда тагын бер әдәби үзәк оештырмакчылар иде.

Мин әйттем, башта бер үзәкне ныгытып җиткерик әле, дидем. Афзал абый минем белән килеште. Фазыл Мостафин да, Сәет Кальметов та, Әдип Маликов та синең Әлмәткә күчү ниятеңә бик сөенделәр. Фикереңнән кире кайта күрмә.

Кстати, Әдипне Союзга алдылар, хәзер без икәү Союз члены. Син кайткач, өчәү булабыз. Май айларында Сәетне алырга торалар – менә булабыз дүртәү. Аннары сентябрь

аенда РСФСР Язучылар союзы алдында мәсьәлә куялар – Әлмәттә бүлекчә ачу турында (1960 ел башыннан). Аның бер кешелек штаты – правление секретаре булачак.

Бик зур сәхнәле, бик матур Культура сарае төзелеп бетеп килә бездә. Язучыларга шуннан бер бүлмә бирергә ниятләре.

Гөрләп яшәрбез, дустым.

Бу баруымда Казанны яратмыйча кайттым. Бик чуар, тар һәм кысан кебек тоелды. Һавасы да исән түгел. Бездә ул яклар – иркенлек, табигать искиткеч бит!

Инде иҗат турында. Хикәягә («Юллар чатында») карата әйткән җылы сүзең өчен бик зур рәхмәт! Сөендердең, дус кеше. Мин синең зәвыгыңа бик ышанам бит.

«Күлләр» очеркына карата шундый бер җылы сүз әйткән идең заманында, дөресрәге, озын бер хат язып куандырган идең. Русчага тәрҗемә иттерү турында әйткәнсең. Мин үзем, русча чыгарып караган булмагач, ул нәрсәнең барып чыгарына бик үк ышанып җитмим. Бер җиргә дә биргәнем дә, әйткәнем дә юк. Гомумән, ул хикәяне Казанда да яратканнар. И. Гази белән Ә. Еники махсус килеп котладылар. Алар мине моңарчы хикәяче дип танымыйлар иде әле һәм танымауларын үземә туп-туры әйтәләр иде.

«Хазбулатның яңа гадәтләре» дигән яңа хикәя яздым. Яраттылар. «С. ә.»ның 4 санында чыгар кебек әйттеләр, производствога төште. Җыентыгым да редакцияләнен бетте. Сания редакцияләде, җанымны алды, ун табактан алты табакка калдырдык. Бик таләпчән килде. Редакторлар усалландылар, малай, хәзер.

«Чулпы җыры» дигән драма язуым турында әйткән идем бугай, Казанда Культура министрлыгында укыячак. Уңай бәя бирделәр: М. Әмир, Р. Ишморат, Ш. Сарымсаков, Н. Гайнуллин һ.б. катнашты. Барысының да фикере уңай. Сибгать абый җыр текстларын язды, Заһид Хәбибуллин көйләрен язды, Әлмәт театры куярга әзерләнә.

Менә миндә шундый хәлләр.

Фазыл Мостафин белән икәү бергә язган драмабызны 15 апрельләргә чыгарырга җыеналар. Академиядән әйттеләр, премьерага чыгарырбыз, диделәр.

Үзем турында яздым да яздым, бу бик мактану булып чыкмыймы инде?

Хәер, син дус кеше, гаеп итмәссең әле. Бу әйберләр белән бик озак йөрергә туры килде. «Юллар...» бер ел да өч айдан соң гына басылды, Академия театрында драмабыз ике ел чамасы ятты – менә шундый зарыгып көткәннән соң җылы җилләр исә башлагач, куанычымны язмый булдыра алмадым.

Хатында «Инша» хикәясе турында әйткәнсең. Миңа таныш исем бит ул. Син аны бер сөйләшүдә әйткән идең. Ничек бара? Бетермәдеңме әле? Повестеңны да бик көтәм. Ә безгә кайткач, хикәя өчен материал тау кадәр булачак. Юк, нефть турында дип кенә уйлама. Искиткеч вакыйгалар, искиткеч кешеләр бар монда. Осталык кына җитми, малай. Аннары мин хәзер язуны бик авырдан яза башладым. Бастырыр өчен генә язасы килми. Әкренләп сихеренә төшенә барам кебек. Исән-сау кайтып урнашсаң, сөйләшер идек бер туйганчы. Әле бит әсәреңне рәсми рәвештә укучылардан тыш, дусларча, чын күңелдән, таләпчан килеп укучылар була. Менә шуңа күрә мин сине зарыгып көтәм. Укыр идек бер-беребезнең әсәрләрен. Сәхраларга чыгып китәр идек. Бик матур яшәр идек шикелле.

Квартира мәсьәләсендә мин гел белешеп торырмын. Булачагына ышанып калам!

Ярый, дус, ардырдым бугай сине.

Укуында, иҗатында уңышлар телим.

Сәлам белән Гариф Ахунов
8.04.1959

Шәһидәдән бик күп сәлам сиңа. Фазыл, Әдип һәм Сәет дуслардан шулай ук бик күп сәлам. Хатыңны бик тиз яз әле, мөмкин булса. Мине сораучылар булса, сәлам әйтерсең».



Гариф Ахунов хатыны Шәһидә Максудова, улы Рәшит һәм кызы Наилә белән. Әлмәт, 1963

*1960, 15 июль*

«Кадерле дуслар Рафаил һәм Рәзинә!

Әлмәт каласыннан, безнең барыбыздан сезгә бик күп сәлам. Бала-чагаларга, әти-әниләрегезгә шулай ук миннән һәм Шәһидәдән күп итеп сәлам тапшырырсыз.

Рафаил, хатыңны алдым, дус кеше. Якын итеп хат язуың өчен рәхмәт! Авыруыңны ишетеп борчылдым, мин инде сине повестеңны бетереп киләсеңдер дип торам. Алгы көндә исән-сау булып, иҗат илһамнары бирсен.

Үзебез авылда егерме биш көн ял итеп, кояшта каралып, 28 июньдә кайтып төштек. Авылда бер юл да язмадым һәм бер юл да укымадым (Аллага шөкер!).

Әниләргә койма тоттым, свежий (яңа сауган сөттән) түгәрүк ашадым, бик килеште: ябыкмадым да, тазармадым да. Ләкин кәеф әйбәт, өйгә кайткач та үземне сәламәт сизәм. Җиң сызганып эшкә утырдым. «Тын Дон» белән утырам, бик хутлы бара, язуны сагынганмын, сентябрь башына бетерермендер. Йөз илле битләр чамасы калып бара. Аннары син миңа, шаять, бер «нәмәкәй» дә алдырмассыңдыр инде. Сезне сагындым. Монда хәзер, Сәетне чутка тыкмаганда, берәү дә юк. Әдипләр Өфе ягында, Фазыллар – Беренче майда ял итәләр. Хәмит абый гастрольдә. Берәү дә килми. Шәһидә – редакциядә, өйдә япа-ялгызым.

Синең йомышны почтага кереп әйтеп чыктым, хәзергә перевод-фәлән күренми; ялдан кайту белән үк Мәскәүдән наложенным платежом җибәргән китапларыңны алып чык-

кан идем (ике төргәк), тумбочка өстендә тора. «Акча килсә, августка тикле җибәрмәгез, үзе кайта», – дидем. Менә шул.

Сентябрь башында безне – Әлмәт язучыларын – Казанга чакыралар, имеш. Хат килде. «Без яшибез Әлмәттә» җыентыгын һәм башкаларны тикшерү өчен, диелгән. Хәзергә менә шулар.

Аюдай тазарып, чуендай каралып, шау-гөр килеп кайтып төшүегезне көтәм.

Кабат сагынычлы сәлам белән Гарифҗан Ахун хәзрәтләре

15.07.1960».

*1960, 31 октябрь*

«Рафаил дус!

Үзеңә, Рәзинәгә һәм бала-чагаларыңа бик күп сәлам.

Мин әйбәт кенә килеп урнаштым. «Переделкино» дигәннәре матур урында икән. Көн саен ике-өч сәгать урманда йөрибез. Аппетит бик әйбәт, ашатуын да бик әйбәт ашаталар, так что күңел көр, тамак тук; үземне айлар буе ял иткәндәй сизә башладым. Язу эшем дә бик әйбәт бара: көн саен өч биттән дә ким язганым юк. Өйгә кайтканда үземнең язу белән илле биттән дә ким булмастыр, машинкада җитмеш биш бит дигән сүз.

Монда халыкның күбесе зур борынлы, тик ятучы юк. Тыныч. Монда килүемә бик сөенәм.

Үзегез ни хәлдә? Повесть нишли, повесть? Рөстәм энекәш тереләме? Безнекеләрне күргәнең бармы? Аларга бик күп итеп сәлам әйтерсең.

Иң изге теләкләр белән Гариф Ахунов

Мәскәү, Переделкино

31.10.1960

Рафаил дус!


P. S. Кумык язучысы Солтанов, лак язучысы Юсупов (балалар шагыйре) сиңа бик күп итеп сәлам әйтергә куштылар. Алар сине беләләр, бергә укыдык, диләр».

*1961, 14 июль*

«Әлмәт хәлләре турында парчалар.

1. Рафаил энекәш!

Үзеңә, Рәзинә кодагыйга, Рөстәм белән Мансур энекәшкә вә һәм дә Фәридә сеңелкәшкә безнең гаиләдән сагынычлы кайнар сәламнәр.




Әдип Маликовның Гариф Ахуновка Гаградан язган открыткасы. Әлмәт, 1962

Хатыңны алдым. Минем беренче парчага карата әйткән тәнкыйтеңне икенче парчага тулысынча искә алырга тырыштым («Ни өчен дип әйткәндә!» дип язмадым). Күрерсең. Анысының исеме «Әсмагөл» булыр. Ул парчадан инде икенче төрлерәк кимчелекләр эзләрсең. Шулай итеп, минем бишенче парча идеальный булып чыгар. Мине «на-

чар сөйләүче», җүнлерәк язучы итеп чыгаруыңа өстәл кырыеннан егылып төшеп китә яздым, куанычым эчемә сыймады. Шундыйрак мактау сүзләре әйтеп торсаң, мин гел үсәрмен, кабарырмын һәм... көннәрдән бер көнне шартлап китәрмен (мактанчык бака кебек!) Ә хәзергә шатлыклы сүзләрең өчен үзеңә яңа хәбәрләр әйтәм:

Режиссер Габдулла абый Йосыпов «Йолдызым»ны бик мактаган (монысын әйткән идем бугай, виноват).

Р. Галимнең рецензиясе чыкты – шәп (монысын укыгансыңдыр, виноват).

Әдипләрнең әниләре кунакка килде (Әдип безне дә чакырып сыйлады, мин эчмәдем!).

Фазылның энесе Назыйм белән минем балдыз Наилә Әлмәттә бер кич кунып китте (хатын, акча бетте, дип тиргәнеп йөри!). Мин Казанга барып кайткач, без, имеш, Ялхавайга барып кайтасы, туйга. Инде бүләкләр алып куйдык (хатын миңа бәйләнә алмый, әллә-ли, әллә-ли!).

Сезнең бакча исән-сау, су сибәбез (помидорлар, кыяр түтәлләре сезгә сәлам җибәрә!).

Сәет Кәлмәдигә Минзәлә договор буенча акча җибәргән (Сәет миңа фәлән-фәлән көнне нәкъ сәгать 12 гә киләм дигән иде, шаяртты, шайтан!).

«Др. Нар.» минем рецензияне баса икән, гранкасын җибәрде. Ә мин аны, сәгатеминуты белән укып, кире җибәрдем.

Дәвамы киләсе санда.

Г. Ахунов
Әлмәт
14.07.1961».

*1961, 24 ноябрь*

«Рафаил дус!

Үзеңә, Рәзинәгә һәм балаларга миннән бик күп сәлам. Мәскәүдән бер хатыңны алган булсам да, Казан белән Әлмәт арасында буталып йөри торгач, хат язарга өлгерә алмый калдым, семинар уздырып йөрдек бит.

Октябрь бәйрәмендә биш көн хатынымны көттем, шул мәшәкать белән бәйрәмдә сезне котлап булмады, үзең җибәргән котлау телеграммасын алганнан соң, бик-бик каты сөенеп, сөенечемнән нишләргә белми йөрдем, дип әйтә алмыйм. Юлда тоткарланды булса кирәк, килеп җитмәде.

Сине бик матурланып, гадәттәгечә, ял йортыннан яшәреп кайткан дип ишеттем. Синең өчен күңелләр бик сөенде, дус кеше.

Инде үземә килгәндә, служба камытын тартам. Романны бетереп, редакциягә тапшырдым. Ике егет укып чыктылар (проза бүлеге мөдире һәм Мәлик Хәмитов). Бик әйбәт укыла, диләр. Күңел күтәрелде. Синең замечаниеләрдән хәзергә бер зур нәрсәне – крәстиян вәкиле Шәвәли абзыйны уңай якка төзәттем. Бүген кулъязмаларны Ф. Хөсни алды, бер-ике көннән Сибгат абый ала.

Ләкин... без өйләнгәч, төн кыска булды дигәндәй, Гомәр абый белән И. Гази романнары өлгерде. Мин ике КИТ арасында. Сизденме? Түз генә, брат!

Калганын кайткач сөйләшербез.

1 декабрьдә Шәһидәнең туган көне. Үткәрергә кайтам дип җиң сызганып йөрим.

Тагын бик күп сәламнәр язып, изге теләкләр белән калам.

Гариф Ахунов
Казан
24.11.1961».



Сулдан уңга: Мәсгут Имашев, Вазыйх Исхаковның кызы Венера, Вазыйх Исхаков, Рафаил Төхфәтуллин, Вазыйх Исхаков хатыны Зимфира, Шәһидә Максудова, Гариф Ахунов, Сания белән Фазыл Мостафиннар, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов. Әлмәт, 1965, сентябрь

*1964, 22 март*

«Рафаил дус!

Үзеңә, Рәзинәгә, Әдип белән Саҗидәгә, Фазыл белән Саниягә, Сәетләргә, Фәүзиягә күп итеп сәлам җибәрәм.

Синең хатыңны алдым мин. Переделкинога килеп төшүгә килде – аптырап киттем.

Язучылар союзында булдым. Икенче көнне үк бардым. Семинарга булса, рәхәтләнеп җибәрер идем, очрашу өчен булмый, акчалы итегез очрашуны, диләр. «Это же некрасиво, нефтяники обидятся!» – дидем. Алар миңа пропаганда бюросына (Воровскийдагы) барырга тәкъдим иттеләр. Шушы арада барам. Телеграмма сугармын.

Бу хатны Марсель аркылы ашыгыч кына җибәрәм. Эшләрем әйбәт. Әдәби бит белән барыгызны да котлыйм. Марсель белән безгә монда да йөгереп йөрергә туры килде. Үзеңнең эшләрең көйлеме?

Миңнурга күп сәлам, Әзһәргә шулай ук.

Кулыгызны кысып, Гариф Ахунов
22.03.1964
Переделкино».

*1965, 26 октябрь*

«Рафаил!

Хатыңны алдым.

Күп язарга вакыт юк. Эш болай тора:

«Еллар авазы» редакцияләнгән. Гайнанова Фәния әйтте, карточкасы кирәк, тиз генә җибәрсен, диде. Сүз башы кирәк: ике-өч битле, анысын мин язам. «Кунак егет», «Яңа

магазинда», «Абый» хикәяләренең әзрәк төзәтәсе җирләре бар икән. Аларны сиңа җибәрергә булдылар.

Нәшриятта бүген үк акча юк. Ноябрь башында обязательно җибәрәбез, диләр.


«Тамчылар...» булса, алып кайтырмын. Хәзергә татар бүлегендә исәп-хисап.

Үзем ярыйсы. Тамак тагын бер шешеп алды, аяк өсте үткәрдем. Анысын безнекеләргә әйтмәсәң дә ярый.

Барлык дусларга сәлам.

Күрсәң, Шәһидәгә сәлам әйтерсең.

Гариф
26.10.1965».




*1974, 14 гыйнвар*

«Кадерле дуслар Рафаил һәм Рәзинә!

Без Казанга исән-сау кайтып җиттек. Күңелдә әле һаман Әлмәт хисе яши.

Йокы туйды инде, арыганнар бетте. Эшкә тотынасы килә башлады.

Әнә шуңа тикле уй-тойгыларыбызны әйтеп, ике-өч кенә сүз белән хат языйк дидек. Бәйрәм бик ямьле тойгы калдырды. Сый-хөрмәтегез, якты йөзегез, кунакчыллыгыгыз өчен бик зур рәхмәт!

1974 ел сезгә һәм балаларга гел яхшылык кына алып килсен.

Кочаклап, Шәһидә, Гариф.
Казан
14.01.1974».

*1987, 14 март*

«Кадерле дустым Рафаил!

«Идел кызы»ның икенче китабы хакында язган хатың, романга биргән бәяң мине бик шатландырды. Рәхмәт сиңа битараф булмаганың өчен! Теләгеңне дә аңладым. Әгәр минем бу озак еллар язган төп китабым, «Хәзинә» төсле, озын гомерле булса, төзәтергә кирәкле урыннарын төзәтермен (теләктәш каләмдәшләрем ярдәме белән!).

«Хәзинә» узган елны миңа тагын бик зур шатлык китерде бит әле: казах һәм төрекмән телләрендә басылып чыкты. Ә бит ул – безнең Әлмәт елларының җимеше. Шуның белән ул миңа ифрат кадерле. Барлык чыкканын исәпләсәң, бу – «Хәзинә»нең ундүртенче басмасы (русча гына да ул биш мәртәбә дөнья күрде инде).

Миңа «Идел кызы» (ике китап) хакында укучылардан уннан артык хат килде инде. Һәммәсе дә рәхмәт укып, авыр елларыбызны хәтердә яңарттың, дип язалар. Фикерләре синеке белән туры килә.

Хат язып, романга бәя биреп, мине шатландырган өчен, сине Ходай Тәгалә шатландырсын. Рәхмәт сиңа тагын бер мәртәбә!

Гамилләр, Әдипләр гаиләсенә, Әхәткә күп итеп сәламнәр әйт. Хәмит абыйларга. Калганын үзең белеп әйтерсең. Шәһидә күп итеп сәлам әйтә сиңа, Рәзинәгә, балаларга. Исән-сау бул.

Ихтирам белән Гарифҗан
Казан
14.03.1987».

«Исәнме, Гариф дус!

Бу хатны «язасы иде, язарга кирәк!» дип йөри-йөри көннәр, атналар узып китте. Сәбәбе эт корсагына сары май килешми дигәндәй, юбилеемның гаҗәп матур үтүе (көткәннәрдән күп мәртәбә артык!) булды. Адәм баласына әрнүгә караганда да чиктән тыш мактау, хөрмәтләү һич килешми икән, ул тантана көннәреннән соң авырып киттем бит, әй, кулга каләм алырлыгым да калмады.

Бүген, Аллага шөкер, өстәл янына утырдым.

Әйтер сүзне әйтмәскә хакым юк, сүзем шул: синең юбилейга килүең, карт сөякләреңне элекке күк егетләрчә җиңел йөртеп килеп төшүең, нур өстенә нур булды. Шатлык-куанычы чиксез булды.

Мең-мең рәхмәтләрем яусын сиңа моның өчен, Гариф малай!

Уйлап-уйлап карыйм да, мондый көннәр дә кичерермен, дип башыма да килми иде. Гаҗәп бит, кырык дүртнең октябрендә дөнья белән саубуллашкан кеше идем инде мин. Башыма күсәк белән китереп суккандай, снаряд ярчыгы килеп тигәч, тирә-юньгә күз салып, «менә кай җирдә икән әҗәлең» дип уйлап куйганым гомер буена истән чыкмый. Шуннан соң, санбат палаткасында аңыма килгәч, «юк, үлмәгәнмен икән ич әле» дип уемны очлап куюым да һич истән чыкмый. Шуннан соң да шулай ук «менә, әҗәлем», «юк, исәнмен икән ич» дигән мизгелләремне санап бетерерлек түгел. Ходайга мең шөкер, инде менә бу көннәрне дә күрергә насыйп кылдың, Аллаһы Тәгаләм! Бәрәкалла-иншалла.

Иң матур, изге теләкләрем ирешсен сиңа, Гарифҗан! Һаман да шулай егетләрчә җитез, җор-шаян килеш мең яшә! Ходай сәламәтлектән аермасын.

Шәһидә ханымга күптин-күп сәламнәрем, иң матур теләкләрем ирешсен! Рәшит әфәндегә, Наилә ханымга, кияүгә дә чуктин-чук сәламнәр! (Хәтерләсәләр, без алар белән Малеевкада бер очрашкан идек.)

Шушы хатны язып утырганда, ишек шакыдылар. Барып ачсам, берсеннән-берсе чибәррәк, берсеннән-берсе сылурак өч кыз басып тора. «Абый, Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз!» – дип, үзләре чиккән сөлге бүләк итеп киттеләр. «Әйдәгез, кызлар, шул уңайдан берәр стакан чәй эчәбез», – дип каушап кабаланып йөргәндә, ни арада фәрештәдәй кызларым бүлмәдән гаип та булдылар. «Их, Гариф булса, ничек тә җаен табар, чәй эчермичә һич җибәрмәс иде мондый гүзәлкәйләрне», – дип, башымны кашып басып калдым.

Нишлисең, миңа Ходай бирмәгәндер инде андый иплелек-тапкырлыкны.


Шушыңа ялганып тагын бер үкенечле хәл хәтердә яңара. Сез Ринат белән Әлмәткә килеп төшкәч, Рәзим өйгә шалтыратты. Рәзинә бу хәбәрне ишеткәч, эчен уып йөри башлады. «Их, чәйгә алырга иде үзләрен, камырым кабармый бит, пәрәмәч пешермәкче идем», – дип йөри башлады. Ишектән чыгып киткәндә сорадым: «Кабарамы камырың, алып кайтыйммы кунакларны?» – дим. «Юк, кабарырга исәбе дә юк, хур итә күрмә мине», – дип ялварып калды Рәзинә. Шунда соң, карчык сүзен ишетмәскә сабышып, өчәүләп килеп керсәк соң, ни булыр иде. Камыр кабармаса да, җае чыгар, истәлеккә кызык итеп сөйләрлек ниндидер хатирә калыр иде бит. Мин, тишек баш, моны эшли алмадым. Менә шул үкенечкә калды, малай.

Ярар, озынга суза башладым бугай, шушында нокта куйыйм да, тагын бер хат язасым бар, шуны башлыйм. Анысын да байтактан сузып киләм. Юбилей алдыннан Аяздан хат килеп төшкән иде. Бик дустанә, ихлас хат. Шуны җаваплыйсы бар.

Кабат сәламнәр, изге теләкләр белән Р. Төхфәтуллин
23.02.1994».

# Хәзинә-ул—кешеләр

Әлмәттә «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» романын язу өчен мин унике ел гомеремне шунда үткәрдем. Кунып-төнеп буровойларда яттым. Нефтьчеләр белән бергә пычракта, бураннарда буровой машиналары этеп йөрдем. Бик күп нефтьчеләр белән дуслаштым, кунак булдым, сөйләштем. Лотфулла Дияров – Заһир Гарипов дигән кеше ул. Советлар Союзын әйләнеп чыккан, йөз илле скважинасы нефть атып утыра. Сәрвиҗамал апа аның артыннан энәгә тагылган җеп кебек йөреп, сигез бала тәрбияләп үстергәннәр. Аларның күбесе ир балалар һәм нефтьчеләр.


Гариф Ахунов эш вакытында. Әлмәт, 1967

Миңа: «Старомодный, иске исем куйгансың», – диючеләр дә булды. Бөтен хикмәт шунда: хәзинә ул – кешеләр. Шуның өчен язылды да ул роман. Әгәр дә кешеләр исән булмаса, җир астындагы хәзинәне беркем дә чыгара алмый.

Ә менә хезмәт кешесенә кадер булмаганга күрә, Русия бөлгенлеккә төште. Автор буларак, шуңа күрә мин күрәкарау тәнкыйтьчеләрнең хезмәтне тасвирлаган романнарны юкка чыгаруы белән килешмим. Рафаэль Мостафин «Язучы тапкан хәзинә» мәкаләсендә романның тормышчан булуын әйтеп чыккан иде. Мин үзем әсәрнең сюжетлы булуын яратам. «Хәзинә» романын Арслан Гобәйдуллин белән Мөнәвәрәнең мәхәббәте тотып тора. Мин бер нәрсәне дә ялганлап язмадым, кат-кат чыкса да үзгәртмәдем. Чөнки ул – чынбарлык.

Свердловск нәфис фильмнар студиясенә татарның егерме романы тәкъдим ителгән иде. Шулар арасыннан «Хәзинә» сайлап алынды.

Нефтьче хезмәте – зур һәм авыр хезмәт. Татар нефтьчеләре Себер нефтен чыгаруда булыштылар, чит илләрдә эшләделәр. Татарстанга мөстәкыйльлек алган чакта да нефтьчеләр хезмәте булышты.

*Гариф Ахунов,*
Татарстанның халык язучысы,
шәрәфле академик

# Гариф-Ахунов:-писатель,-нашедший-«Клад»

4 июня 2000 г. в Казани, не дожив до 75 лет, умер Гариф Ахунов – народный писатель Республики Татарстан, заслуженный работник культуры РСФСР, видный государственный и общественный деятель, лауреат Государственной премии РТ им. Габдуллы Тукая, лауреат премии им. Гаяза Исхаки, почетный член Академии наук РТ.

## *Увековечивая память*

Похоронили Гарифа Ахунова 6 июня 2000 г. в Арске на татарском кладбище рядом с могилой матери. Вскоре на Центральной площади Арска, на Аллее писателей, ему был поставлен бронзовый памятник-бюст, именем знаменитого земляка были названы одна из новых улиц города и парк, в Арском музее литературы и искусства создана большая экспозиция, посвященная жизни и творчеству Г. Ахунова. Также в музее Казанбашской школы Арского района, в которой учился Ахунов, появился уголок памяти писателя. В рамках увековечения памяти Ахунова в Казани на д. № 4А по ул. Новаторов, в котором проживал писатель, установлена мемориальная доска; памятная доска была открыта в 2006 г. в Альметьевске на д. № 20 по ул. Радищева, где писатель прожил более 10 лет. Кроме того, в честь Гарифа Ахунова названа улица в Приволжском районе Казани.

Один из известнейших писателей Татарстана Диас Валеев (1938–2010) сказал о Г. Ахунове: «По глубине подхода к теме, по широте панорамного охвата народной жизни, включающей в себя десятки и сотни разноплановых событий, Гариф Ахунов в татарской литературе не имеет, наверное, себе равных».





Казанның 17 нче китапханәсендә Г. Ахунов китаплары


# *Визит в Елабугу*

В определенный момент своей биографии титулованный татарский советский писатель Гариф Ахунов посетил Елабугу. Произошло это летом 1977 г. В Книге отзывов Дома-музея И. И. Шишкина есть следующая запись, датированная 1 июля 1977 г.: «Мы очень благодарны людям, которые бережно и заботливо сохраняют все, что связано с жизнью и творчеством их земляка, художника с мировым именем Ивана Ивановича Шишкина, который всю жизнь посвятил воспеванию родной природы».

Под этим текстом стоит «сухая» подпись «Писатели Москвы и Казани», под которой в свою очередь – «живые» автографы 13 писателей, среди которых и Гариф Ахунов (приведенная выше запись в Книге отзывов сделана рукой Г. Ахунова).

*Андрей Иванов,*
заведующий издательским отделом Елабужского государственного музея-заповедника
«Вечер Елабуги». 2011. № 663(22). 1 июня




Автографлы китаплар

# Ул Әлмәтне һәрчак якын күрде

Гариф Ахунов Әлмәт татар дәүләт драма театрының иң якын дусларыннан берсе булды. Ул, очерк-хикәя, повесть-романнар язудан тыш, драма әсәрләре дә иҗат итте. 1959 елда театрыбызда аның «Чулпы җыры» дигән драмасы куелды. Спектакльнең режиссеры – Г. Ильясов, рәссамы – М. Абдуллин. Миңа режиссер Банат ролен бирде. Бик яратып башкардым мин бу ролемне. Мин генә түгел, башкалар да. Тамашачылар да бик яратып кабул итте. Татар тамашачысы, билгеле булганча, элек-электән җырлы тамашаларны ярата. Бу спектакльгә җыр сүзләрен күренекле татар шагыйре Сибгат Хәким, ә көен композитор Заһит Хәбибуллин иҗат итте.

Спектакль сәхнәгә куелганчы, Гариф Ахунов, автор буларак, безнең һәрбер репетициядә булырга тырыша, үзенең киңәшләрен бирә иде.

«Чулпы җыры»нда Рәисә Гобәйдуллина (Татарстанның атказанган артисткасы), Камилә Игъламова, Хәлимә Маннурова, Әхмәт Галиәкбәров, Зәки Газимҗанов (ул әле оста баянчы да) кебек театрыбызның бик күп талантлы артистлары катнашты. Театрда план дигән нәрсә бар. Шуңа күрә труппа, берничә төркемгә бүленеп, гастрольләргә чыгарга мәҗбүр. Әйткәнемчә, «Чулпы җыры» – бик күп актер катнашындагы спектакль. Шуңа күрә, бик уңышлы булса да, соңрак ул репертуардан төшеп калды.


1963 елда театрыбызга баш режиссер булып Академия театрыннан Габдулла Йосыпов килде. Бу шәхеснең Әлмәт театрына китергән игелеге спектакльләр кую белән генә чикләнми. Коллективны яңа яшь көчләр белән тулыландыру, аларга махсус белем бирү, яшьләрне актерлык осталыгына өйрәтүдә аның өлеше зур. Артистлар составын тагын да киңәйтү максаты белән ул Әлмәт театры каршында, җәмәгать эше тәртибендә, студия оештыра. Бу мөһим эш өчен кечкенә генә шәһәрдә шартлар җитеп бетмәсә дә, Габдулла Йосыпов күпләрне мавыктыра. Мине дә, Әлмәттә яшәп иҗат итүче язучы Гариф Ахуновны да ул укытучылык эшенә җәлеп итте. Баш режиссер үзе театр тарихы һәм драматургия буенча дәрес алып барса, мин актер осталыгы, ә Гариф Ахунов әдәбият дәресләре алып бардык.



Гариф Ахунов, Зәкия Туешева театр коллективы белән. Әлмәт

Габдулла Йосыпов миндә режиссерлык сәләте дә күреп алган. Мин роль өстендә эшләгәндә, режиссер

әйткәннән белән генә чикләнеп калмыйча, образларга үземнән нәрсә дә булса өсти идем. Бервакыт ул мине чакырып алды да, образны аның трактовкасы буенча уйнамаганым хакында әйтте. Ә мин исә, гафу үтенеп, миңа шулай тоелды, дидем. Ә Габдулла абый, мине мактап, образны үзенчә ачуың бик әйбәт, димәк, синдә режиссерлык сәләте бар, диде.



Зәкия Туешева Банат ролендә. Әлмәт

Бу сөйләшүдән соң бераз вакыт узгач, Габдулла абый: «Менә бу спектакльне икәү куеп карыйк әле», – дип, кулыма бер пьеса тоттырды. Бу Константин Финның «Ошибка Анны» дигән әсәре иде. Аны Гариф Ахунов тәрҗемә итте. 1964 елда ул «Мәхәббәт хакына» дигән исем белән куелды.

Ә инде икенче сезонда, ягъни 1965 елда, без бергәләп Гариф Ахуновның нефтьчеләр арасындагы дуслыкка багышланган «Утлар яна учакта» драмасын сәхнәләштердек. Бу спектакль халык һәм театр белгечләре теленә бик тиз үтеп керде. Аны республикабызның байтак кына авыл-шәһәрләрендәге, шулай ук Уфадагы тамашачыларга да күрсәттек. «Театр коллективы әсәрне дулкынландыргыч итеп эшләгән. Бигрәк тә нефтьчеләр рольләре: бораулаучылар бригадиры Хәйрулла ролендә Зәкәрия Гыйлемов, Гүзәлия – Луиза Солтанова, Азамат – Рамазан Ихсанов, Николай – Кави Барыев, Шәйхаттар – Җәүдәт Исмәгыйлов, Сәлахи – Рафаил Сабиров үз рольләрендә тормыш сөюче, дәртле йөрәкле яшь эшчеләрне тулы ачып бирә алдылар. Режиссерлар: ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла Йосыпов, ТАССРның атказанган артисткасы Зәкия Туешева бигрәк тә масса сәхнәләрен җанлы, дәртле эшләп, җитез ритм, уңайлы мезансценалар таба алулары белән тиешле эффектка ирешә алганнар. Бу спектакльнең гомуми уңышы», – дип яза аны, карагач, Башкорт дәүләт драма театры директоры Фәиз Вахитов «Кызыл таң» газетасында (1965 ел, 11 июнь). Кыскасы, дуслык, бердәмлек турындагы әлеге спектакль һәр җирдә шаулап, зур уңыш белән бара.

Гариф Ахунов яшь иҗатчыларга карата һәрчак игътибарлы булды. Ул минем хәтеремдә, күңелемдә һәрвакыт яшьләр тирәсендә булуы, ачык, көләч йөзле, яхшылыклар гына эшләргә омтылучы буларак саклана.

1968 елда Казанга күчеп киткәч тә, аның Әлмәт белән, Әлмәт театры белән аралары өзелмәде. Шәһәребездә әдәбият атналыклары яки әдәбиятка кагылышлы башка чаралар оештырылганда, үз тирәсенә яшь авторларны җыеп, килмичә калмый иде. Нефтьчеләрнең дә ул яраткан кунагы булды. Ә инде театрыбыз башкалабыз Казанга гастрольләргә бара икән, Гариф беренче көнне үк килеп җитә, гримеркаларга кереп, һәрбер артист белән исәнләшеп чыга. «Үзебезнең әлмәтлеләр килгән, киләм, бер спектаклегезне дә карамыйча калдырмыйм» дия торган иде. Ул Әлмәт белән, әлмәтлеләр белән горурланып, безнең кечкенә генә уңышларыбызга да сөенеп яшәде.

*Зәкия Туешева,*
ТАССРның халык артисты, режиссёр

# Десант-культуры-иискусства



Г. Ахунов җитәкчелегендәге мәдәният әһелләре десанты нефтьчеләрдә кунакта. Әлмәт, 1976

В сентябре 1975 г. свое 50-летие отметил писатель Гариф Ахунов, автор романа о нефтяниках Татарии «Хәзинә» («Клад»), за который писатель был удостоен Государственной премии ТАССР имени Г. Тукая. В то время Гариф Ахунов жил в нефтяной столице, возглавлял местное отделение Союза писателей.

Было принято решение отметить юбилей писателя в коллективе нефтяников. Руководством производственного объединения «Татнефть», партийными комитетами города и НГДУ «Альметьевнефть» для такого торжественного мероприятия была выбрана РИТС-2 во главе с молодым инженером Шагитом Таиповым, которая заняла 1-е место во Всесоюзном соревновании (нефтепромыслы в те годы назывались РИТС – районными инженерно-технологическими службами).

Коллектив цеха единогласно поддержал предложение об избрании Гарифа Ахунова почетным оператором РИТС-2, и под бурные аплодисменты зала (торжество провели в формате профсоюзного собрания коллектива нефтепромысла) Ш. Таипов вручил главному писателю Татарии специально подготовленное удостоверение.

Растроганный юбиляр горячо поблагодарил промысловиков, был очень доволен оказанной честью. И высказал предложение:

– Не только писатели, но и деятели других видов искусств были бы рады встрече с нефтяниками. Если согласитесь принять, я могу привезти большую делегацию.

Предложение было принято с радостью.

Гариф Ахунов, уже председатель правления Союза писателей Татарии, сдержал свое слово: 10 июня 1976 г. в нефтяной столице высадился большой десант писателей, композиторов, художников, мастеров сцены. Знакомили гостей с нефтяным делом, водили по объектам заместитель генерального директора объединения «Татнефть» Узбек Саттаров и начальник технического отдела НГДУ «Альметьевнефть» Рафик Амирханов.

*Ирек Бадретдинов,*
журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

# Кеше—үзе-зур-хәзинә

Тормыш каршылыкларын өйрәнми, булачак геройларың белән катнашмый торып, тулы канлы әсәрләр иҗат итеп булмый. Студент елларында ук каләм тибрәтә башлаган Г. Ахуновта да әдәби иҗат өчен тормышны өйрәнү ихтыяҗы туа һәм ул Әлмәткә күчеп китә. Биредә, ун ел нефтьчеләр арасында яшәп, кара алтын чыгаручыларның бөтен эш, тормыш нечкәлекләрен өйрәнә, алай гына да түгел, аларның җанын аңларга омтыла.

Авторның әлеге темага килүендә социаль заказның да роле юк түгел. Сәяси пропаганда рәвешендә бирелгән социаль заказ үз эшен эшли. Әмма шуны әйтергә кирәк: талантлы әдипләр социаль заказ тәэсирендә дә сәнгатьчә эшләнеше югары булган әсәрләр тудыралар. «Хәзинә» романы да шундыйлардан.

«Хәзинә» романы – заман сулышын тоеп язылган әсәр. Аның үзәгендә нефтьчеләр тормышы, аларның хезмәте яктыртыла. Әсәрдә, нефть табылу вакыйгасы белән бәйле төстә, күп кенә проблемалар күтәрелә. Әлеге проблемалар геройлар, алар белән бәйле вакыйгалар, үзара мөнәсәбәтләре, каршылыклары аша тәкъдим ителә.

Яңа төр хезмәт процессының геройлар тормышына һәм язмышына йогынтысын ачыграк күрсәтү өчен, Г. Ахунов башта тарихи үткәнгә мөрәҗәгать итә. Роман йөзьяшәр Йөзлекәй карчык турында сөйләү белән башланып китә. Автор аның «татар авылларында сирәк очрый торган озын гомерле һәм кайгы-хәсрәтне батыр күтәрә алган чыдам кешеләрнең берсе» булуын ассызыклый. Үз гомерендә күпне күреп, күпне кичергән бу карчыкның озын тормышы, әйтерсең, Кәлимәт җиренең авыр үткәнен күз алдыннан уздыра.

Йөзлекәй – кешелекле матур сыйфатларга ия булган һәм язучы концепциясенең үзәгендә торган төп герой. Бу геройның фәлсәфи мәгънәсе бар һәм сәнгатьчә дә әһәмиятле, чөнки ул, барыннан да бигрәк, үткәнгә, халыкка һәм туган илгә мөнәсәбәт белән бәйләнгән. Язучы шул мөнәсәбәтләрнең бүгенге көнгә дә килеп җитүен күрсәтә. Өлкән буыннардагы яхшы сыйфатлар яшьләргә күчә. Арслан, Фәйрүзәләрдәге ныклык, сабырлык, физик һәм рухи сәламәтлек шул нык холыклы йөзьяшәр элгәреләребезгә барып тоташа. Йөзлекәй образының романдагы идея-эстетик вазифасы шуннан гыйбарәт.

Хәзинәнең чын асылын ачуда да Йөзлекәй карчыкка әһәмиятле роль бирелә. Ул – гади крестьян кызы, намуслы хезмәт белән көн күргән. Саулык-сәламәтлекне иң олы байлык, ягъни хәзинә дип инанган. Килене Мәгыйшәне язучы аңа капма-каршы куя. Автор матди байлыкның рухи хәзинә белән тиңләшә алмавын күрсәтә. Килен белән кайнана арасындагы зур упкынның да шуның нәтиҗәсендә килеп чыгуын ассызыклый. Ул бер хакыйкатьне искәртә: малның милләте дә, дине дә, кардәше дә, әхлагы да юк, шуңа күрә ул бик хәтәр җимергеч көчкә ия, ди. Мисалы күз алдында: килен белән кайнана тыныша алмый, бер-берсеннән ерак яшиләр, бер нигездә кала алмыйлар. Сәбәбе – Мәгыйшәнең байлыкка табынуында, ә Йөзлекәй карчыкның, киресенчә, малга кызыкмавында. Мәгыйшә, көрәшсә дә, җиңелә. Хәтта баласы аны ташлап, әбисе янына күчә. Алай гына да түгел, байлыкка табыну Мәгыйшәнең иң кирәкле сыйфатын – кешелеклелеген юкка чыгара.

Табигатькә карата битараф булу ул – кешеләр язмышына да битараф булу. Йөзлекәй әби бу хакта да борчыла. «Нифте мае, диме, керәчинме – белмәссең хәзергене. Үлмәсәң, әллә ниләр ишетерсең әле. Һәммәкәй төшне тишеп, җир маен суыртасылар, ди. Анысы тагын ниемә кирәк инде? Чишмә суларын былчыратып, үләннәрне корытып бетермәсәләр ярарые», – ди ул.

Йөзлекәй карчык белән бәйле вакыйгалар – әсәрнең төп сюжет линиясе. Шушы сюжетка бәйле рәвештә төп проблема калкып чыга. Ул – кешеләрнең үзара мөнәсәбәте. Беренче карашка, әсәрнең төп кычкырып торган темасы – хезмәт, ә проблемасы – хезмәткә мөнәсәбәт кебек. Әмма язучы әхлак мәсьәләсен подтекст кебек саклык белән генә, кадерләп кенә хезмәт темасы белән үреп бара. Язучының композицион өлешләрне үрә белү осталыгы менә шунда чагыла.

Татар халкының борын-борыннан килгән, аның милләт буларак йөзен билгели торган сыйфатлары – әхлаклылык, намуслылык, үзара мөнәсәбәтләрнең эчкерсезлеге, өлкән буынга ихтирам, гаделлек. Аның да беренче урындагысы – олыларга хөрмәт. Әсәрнең Йөзлекәй карчыкка бәйле вакыйгалардан башлануы безнең милли гадәтебез, әхлагыбызның йөзе – олыларга хөрмәттә икәнлекне искәртә һәм укучыларның игътибарын да шунда юнәлтә.

Ни өчен Шәвәли тормышта таянычын югалта, ни өчен аның нигезе какшый? Бу какшау да әхлак нигезе какшаудан башлана. Моның сәбәпләрен ачу юлы белән автор безне тагын уйланырга мәҗбүр итә. Бер гаилә эчендәге вакыйгалар белән бәйле рәвештә сюжет линияләре дә тармаклана, вакыйгалар катлаулана, моның белән язучы милләтебезнең ныклыгы, нигезе булган әхлаклылык мәсьәләләрен тагын да үстереп җибәрә. Ахырдан моны ил күләмендәге проблема дәрәҗәсенә күтәреп, кешеләр арасындагы мөнәсәбәт һәм кешеләрнең табигатькә булган мөнәсәбәте белән бәйләп, шундый фикергә китерә: әхлак нигезе какшаган милләтнең яшәве куркыныч астында.

Әсәрнең төп конфликты гаилә эчендә башлану да юкка гына түгел, чөнки гаилә – җәмгыятьнең төп нигезе. Һәм, күргәнебезчә, әсәрдәге гаилә конфликты иҗтимагый конфликтка барып тоташа.

Үткәнгә шундый караш ташлаганнан соң, автор хәзерге заманга борыла һәм реаль тормышның каршылыклы вакыйгаларына алып кереп китә.

Романда конфликт кара алтын чыгарганда, табигатькә мөнәсәбәт һәм, гомумән, нефтьче һөнәренә мөнәсәбәт җирлегендә туа һәм ул, беренче чиратта, Шәвәли карт гаиләсе язмышында чагыла. Нефть табылу нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңа тормыш җилләре кичәге крестьяннардан торган бу гаиләнең һәрбер вәкиленә барып кагыла. Әмма геройларның шәхси характер үзенчәлекләре белән бәйле рәвештә, аларның төрлесенә төрлечә тәэсир итә.

Шәвәли заманында Кәлимәтнең күренекле кешеләреннән исәпләнгән һәм үз-үзенә, булдыклылыгына нык ышанып яшәгән. Әмма вакыт җилләре Шәвәлинең хуҗалыгын да, үзен дә нык кына селкеткән: нигез инде тузып-искереп бара, элекке бердәм гаиләсе дә таркала. Фәйрүзәсе белән Арсланы ата нигезен ташлап чыгып китәләр. Быел унынчыны бетергән Мәрзиясе дә йортка бик күңел салмый: телендә гел шәһәр. Төпчеге Габделхәйдән исә бер дә рәт чыгарлык түгел. Шулай итеп, балалары аталары юлыннан китми, яңа тормыш аларны башка юлдан алып китә. Балалар белән ата арасында шул нигездә конфликт туа.

Шәвәлинең олы улы Арслан – әсәрдә үзәк герой. Ул – Ватан сугышында катнашкан, партизан отрядларында утлар-сулар кичкән, разведкада чыныккан кеше. Хәзер исә зур коллективта үз урынын тапкан алдынгы нефтьче. Автор аны тагын бер герой – Кәрим Тимбиков белән чагыштырып сурәтли, ягъни әсәрдә Арслан һәм Кәрим образлары аша яңа сюжет линиясе ачыла һәм алар арасында шәхси һәм иҗтимагый конфликт туа.

Кәрим һәм Арслан үзләренең эшкә һәм тормышка мөнәсәбәтләре ягыннан капма-каршы торалар. Ике төрле караш, ике төрле эш принцибы конфликтка керә. Алар арасындагы каршылык нефть эшендәге бәхәстә генә түгел, ә әхлакый нигездәге каршылык. Бу каршылык Арслан һәм Кәрим характерлары, тормышны аңлау, җәмгыятьтәге урыныңны ачыклау, бөтенесе өчен шәхси җаваплылык хисе тою проблемалары белән тыгыз бәйләнгән. Ә төп каршылык аларның кешеләргә мөнәсәбәтендә күренә: Кәрим кешеләрнең фикере һәм тормышы белән исәпләшмичә эш итә, ә Арслан, кешеләрнең тормышын куркыныч астына куеп, тыелган алым белән бораулауга каршы чыга, Кәримнең мондый илтифатсызлыгы белән килешә алмый. Романның төп көчен шушы ике образ билгели.

Әсәрнең үзәгендә торган калган геройлар: Лотфулла Дияров, Фәйрүзә, Мөнәвәрә дә үзенчәлекле һәм кызыклы итеп бирелгәннәр. Язучы аларның һәркайсының теләк-омтылышларын, эчке дөньяларын ачып бирә. Бу геройларның шәхси тормышларын производство эшләре белән табигый тыгыз бәйләнештә чагылдыра, хезмәт процессында, коллективта үсүләрен күрсәтә.

Г. Ахунов эпизодик образларны үзенчәлекле итеп эшләүгә дә игътибар бирә. Шундыйлардан: Нәҗип Корбанов, Митрофан Зозуля, башкорт егете Атнабай, Тәүфика апа, Кара Җәмилләр бар. Бу образлар романны бизәп торалар, аны көчәйтәләр.

Әсәрнең исеменә килик. Ни өчен Г. Ахунов аны «Хәзинә» дип атаган? «Хәзинә»не язучы дүрт мәгънәдә күрсәтә. Беренчедән, ул – җир астында яткан байлык; икенчедән, сандыктагы мал (Мәгыйшә өчен); өченчедән, саулык-сәламәтлек һәм җирдә дөрес яшәү (Йөзлекәй карчык һәм аның тарафдарлары өчен); дүртенчедән, нефть чыгаручы тырыш, көр күңелле кешеләр.

Белгәнебезчә, татар әдәбиятының үзәгендә борын-борыннан ук кеше торган. Бу традиция Г. Ахуновта да дәвам иттерелә, чөнки язучы үзәккә нефтьне түгел, ә үзәкләштерелгән кеше образын куя. Димәк, әсәрнең нигезендә халык турында кайгырту ята һәм шуның белән аның гуманистик әсәр икәнлеге исбатлана.

Шулай ук романда борынгы чор әдәбиятыннан ук килгән традицияләр: әхлаклылык, гаделлек, намуслылык, хезмәт сөю дәвам иттерелә. Шулар белән бергә автор бүгенге көннең, XXI гасырның дөньякүләм проблемасын – табигатьне саклау мәсьәләсен дә хәл итә. Алтмышынчы елларда ук инде язучы бу мәсьәләне күз алдында тотып, яшь буынга чаң суга. Яңалык, үзгәрешләр нәрсәгә китерә? Фән-техниканы, дөньяны үзгәртүдә акыл белән эш итү кирәклеккә!

Күргәнебезчә, Г. Ахунов тормышның кайсы якка үзгәрә баруын дистә еллар алдан сиземләп, талант көче белән тоеп язган. Роман моннан илле ел элек язылып, төрлечә бәя алган булса да, бүгенге көндә дә анда күтәрелгән төп проблемалар яңа шартларда (экономик формацияләр алышыну чорында да) актуаль булып кала. Ә геройларның эшкыланышларын язучының фәлсәфи фикер йөртүләре белән оста итеп үрү нәтиҗәсендә, әсәрнең сюжетын мавыктыргыч итеп коруга, әсәрнең фикерен тирәнәйтүгә китерә; укучыны уйланырга, язучы артыннан иярергә мәҗбүр итә. Әсәрнең яшәүчәнлеге һәм әһәмияте дә шуның белән билгеләнә.

*Фәридә Гайфуллина,*
филология фәннәре кандидаты,
Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте укытучысы

# Нефтьче-образлары – экранда

*(«Хәзинә» фильмын төшерү турында истәлекләр)*

## *Дияровка әйләнгән Гарипов*

Аның кайберләре бәрхет тышлы, икенчеләре күн белән тышланган...
Элегрәк альбом аш өстәле әзерләгән арада кунакларга бирелә иде. Ул чакларда фотога да бик сирәк төшелгәндер. Шуңа күрә кунаклар аңа бик зур игътибар күрсәтәләр, озаклап һәр фото турында сөйләшеп утыралар. Хәер, ул заманнарда фотога төшү үзе дә бер вакыйгага әйләнә иде бит.

Фотоаппарат объективыннан «кош очып чыккач», бергәләп гаилә белән туңдырма ашарга яки газлы су эчәргә юнәләсең. Бөтен кеше, бигрәк тә бала-чага өчен бәйрәм була. Вакытлар узганнан соң, һәр фото тарихи вакыйганы искә төшерү өчен зур истәлеккә әйләнә.

Менә мин дә Гариповларның гаилә альбомын карап утырам. Гаилә башлыгы Закир Гарипов «Бөгелмәнефть» трестының икенче бораулау конторасында мастер. Ул – Хезмәт Кызыл Байрагы, Ленин орденнарына лаек булган күренекле нефтьче. Шуның өстәвенә Гариповларның гаиләсе бөтен тирә-юньгә үрнәк гаилә. Анда ун бала үсә. Ләкин болар гына атаклы итми әле аларны. Закир аганы тарихи шәхескә әйләндерүнең сәбәбе башка. Ул күренекле язучы Гариф Ахуновның «Хәзинә» романындагы Дияровның прототибы. Һәммәбезгә дә билгеле, «Хәзинә» – Татарстан нефтьчеләре турындагы иң шөһрәтле әсәрләрнең беренчесе. Ул 1957–1961 еллар арасында иҗат ителә. Гариф ага борынгы Кәлимәт (Әлмәт белән охшашлыгын тоясызмы?) авылы тирәсендә ачылган бай нефть ятмаларының авыл кешеләре язмышын ничек үзгәртүен әдәби чаралар аша тасвирлап бирә. Роман тормышка шулкадәр якын булып чыга ки, нефтьчеләр, андагы әдәби образларда үзләрен, дусларын һәм күршеләрен танып, китапны чын мәгънәсендә халык китабы дип таныйлар.

Язучы романда Лотфулла Дияров исеме белән тасвирланган Закир Гариповны якыннан белә. Аның янына буровойга килеп, гаиләсе, тормышы турында озак-озак сөйләшеп утыра. Аның хатыны – тәмле бәлеш пешерү остасы Сәрвиҗамал ханымны (романда ул – Тәүфика) да бик хөрмәт итә. Аларның җирән чәчле балалары да романда урын ала.

Гариф Ахунов әлеге гаилә белән соңыннан да озак вакытлар аралашып яши. Шундый бер кызыклы вакыйга да булып ала. Республика телевидениесендә «Хәзинә» авторы белән очрашуга әзерләнәләр. Анда ирле-хатынлы Гариповларны да чакыралар. Бөтенесе дә алдан уйланылган сценарий буенча бара. Тик уйламаганда Сәрвиҗамал апа сүз ала һәм Гариф Ахуновны сүзеннән бүлә: «Тыңлап торам да мин сине, Гариф улым, шаклар катам. Бик оста сөйлисең син. Минем турыда нәрсә генә язсаң да үпкәләмим. Тик менә нигә соң минем исемне үзгәрттең, нәрсәсе ошамады аның сиңа?»



Гариф Ахунов Социалистик хезмәт геройлары белән

Мондый көтмәгән сорауга тапкыр язучы бик аптырап кала. Аннан соң: «Сәрвиҗамал апа, сиңа охшаган яхшы апалар бик күп шул бу тормышта. Синең исемне куйсам, алар үпкәләр дип уйладым», – дип шаяртып котыла ул.

Белгәнебезчә, Гариф Ахуновның «Хәзинә»се бәхетле язмышка ия. 1973 елда язучы ул романы өчен республиканың Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә ия була. Тик язучы үзе өчен иң зур танылу дип аңа «Татнефть» берләшмәсенең мактаулы нефтьчесе» исеме бирелүне саный. Свердловск киностудиясе «Хәзинә» исемле фильм төшерә, Кәрим Тинчурин исемендәге театр әлеге роман буенча «Кошның да үз оясы була» (1983) дигән спектакль куя.

Киң экранлы фильмны төшерүдә Вахтангов исемендәге Мәскәү театры, Кабарда-Балкар республикасы артистлары һәм шулай ук Татарстан артистлары да катнашалар. Анда безнекеләрдән Габдулла Шамуков, Вера Минкина, Дэлюс Ильясов, Шәүкәт Биктимеров, Равил Шәрәфиев уйный. 1977 елда «Татнефть» берләшмәсе бинасында әлеге фильмның премьерасы күрсәтелә. Аны караганда, күп кенә нефтьчеләр үзләрен һәм якыннарын танып, фильм геройларының кайгы һәм шатлыкларын уртаклашып, яшь коеп утыралар.

P. S. Гариповларның улы Рәкыйп тә данлыклы нефтьче, танылган рационализатор. Ул торба бораулагычларга урнаштырган ярыммуфта «Гарипов муфтасы» дип йөртелә.

*Сафия Гарифуллина,*
журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

# Тарихка-кереп-калдык

Авылда яшен тизлеге белән хәбәр таралды: «Кино төшерергә киләләр!» Күрше күршедән тулырак мәгълүмат белеште. Ниһаять, Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча фильм төшерүчеләр үзләре дә килеп җиттеләр. Әлмәт районы Тайсуган авылына бәйрәм төсе керде. «Бер төркем таныш түгел кешеләр авыл буйлап үзләре өчен кулай өй эзләп йөриләр икән»,– дигән сүз китте. Минем туган йортыма өч кеше килеп керде. Хәлне аңлаткач, ризалыкны курку катыш аптырау аша гына бирде әти-әни. Күргән-ишеткән хәлмени?

Икенче көнне, исәнлек-саулык сорашып, өебезгә Вера Минкина, Габдулла Шамуков, Арслан ролендә уйнарга тиешле Александр Филиппенко һәм бөтен төшерүчеләр килеп тулды. Ишегалды төшерү мәйданына әйләнде. Авыл гөрли, бала-чага койма башларыннан һәрнәрсәне күрә, сөйләшергә дә, тын алырга да курыккандай, безнең ишегалдын күзли.

Артистлар өйдә тиешле киемнәрен киеп, чәйләп алгач, төшерү башланды. Ишегалдына җайлап әтинең ат арбасы куелды. Безерактарак торабыз, нәрсә сөйләшкәннәре бик ишетелми. Берзаман Арсланны әтисе ачулана-орыша башлады. Арбага иеп, чыбыркы белән кыйнады, сукты. Әнисе якламакчы була, тик әтисе кызганнан-кыза барды. Ә сеңлем, бу күренешне төшергәнче, тавыкларыбызны алар яныннан җибәрмәскә тырышып куып торды. Аңа бу эшне йөкләп куйдылар. Чын дөресе: ул кадрда күренгән тавыклар да безнеке, дип горурланып йөрим әле һаман да.

Кызымның дүрт-биш яшьлек чагы. Кино төшерергә килгәч, безнең өйдә дә булгач, эләксен әле диеп, матур күлмәген кидереп чыгарган идем, бөтен каткан күлмәкле бала-чага төште, кызымны төшермәделәр. «Что за девочка современный күлмәкле?» – диделәр. Менә шулай да була икән ул. Ә андагы малай-шалайлар, әби-бабайлар – авылыбыз кешеләре.

Икенче кадр – Арслан кире туган авылына кайткач, үзләренең капка тактасын алыштыру күренеше. Нәкъ безнең өйнең алгы ягы, чияләре, иске бәләкәй капкабыз күренә.

Шуннан соң әтидән бигрәк әниебез бик читенсенеп яши башлады. Ул чактагы акчасызлык белән дүрт бала үстерүче колхозчы өе нинди булсын соң инде? «Авылда безнекеннән дә искерәк өй булмаган икән», – дип, бик озак оныта алмады әни бу хәлне. Әти белән киңәшкәннән соң, агач юнәтеп, зур матур бура бураттырып, өй җиткезделәр. Шуннан соң гына тынычланды әни.

Ә фильмның башланып киткән өлешендә дә ат өстендә безнең авыл яшьләре. Алар – Гөлфия Бадыйкова һәм Алмаз Кәримовлар. Аларны бер төркем бала-чага су кергән җирдән сайлап алган булганнар. Хәзерге көндә исән-саулар. Икесе дә матур тормышта яшиләр. Ә әби-бабайларның күбесе мәрхүмнәр инде. Авыр туфраклары җиңел булсын!

Олуг бәйрәмнәрдә нефтьчеләребезгә багышланган бердәнбер фильмның экраннарда күренмәве генә бик сәер. Аннан соң килгән яшь буын нефтьчеләребезгә дә тарихи бүләк булыр иде ул «Хәзинә». Күңел түребездә ул чактагы вакыйгалар яңарыр иде. Минем өчен аеруча кадерле бит ул.

*Зәлидә Зарипова,*
«Татнефть газ эшкәртү» идарәсе ветераны,
Әлмәт, Тайсуган

# Без дә кинога төшкән идек

Мондый бәхет моннан 20 ел элек Тайсуган авылы халкына тәтегән иде. Шактый вакыт узса да, тайсуганлылар ул вакыйганы бер дә онытмыйлар, горурланып, «без дә кинога төшкән идек» дип, балаларына, оныкларына сөйлиләр.

Нинди кино соң ул һәм ни өчен аны Әлмәт районында төшерергә уйлаганнар? Күренекле язучыбыз Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча төшерелгән фильм ул. Ә «Хәзинә» романының Әлмәт шәһәрендә иҗат ителгәне һәм төп геройлары Әлмәт нефтьчеләре икәне күп кешегә мәгълүм. Шуңа күрә дә Свердловск киностудиясе Әлмәт районын сайлаган да. Тайсуган авылының гүзәл табигате, мөлаем кешеләре дә иҗади группаның күңеленә хуш килгән. Авыл халкы төрле күренешләрдә бик теләп катнашкан. Кинога төшү беренче карашка кызык тоелса да, артист тормышы җиңел күренсә дә, тайсуганлылар бу хезмәтнең үтә дә авыр икәнлеген үз башларыннан кичергәч аңлыйлар. Бер үк хәрәкәтне ничә тапкыр кабатларга кушкан режиссёр, кайберләрен бу бик ялыктырган да.

Зариповлар гаиләсе дә гомуми күренешләрдә катнашкан. Шул вакытта төшерелгән фотосурәттә алар илленче еллар башында киелгән киемнәрдә. Гаиләдә иң өлкәне – Галимә әби. Гадәти әби генә түгел ул. «Киногероиня» булу өстенә озын гомерле дә. Кавказ халкында 100 яшьне узган кешеләр булуы гадәти хәл булса, безнең якларда ул – сирәк хәл.

– Мин бу йортка 1972 елда килен булып төштем, – ди Галимә әби кызының килене Гөлсирин ханым. – 100 яше тулган иде инде, аңа яңадан теш чыкты, 108 дән дә ким яшәмәде ул. Бергә кинога төштек. Иске киемнәр кияргә куштылар үзебезгә. Бик күп кадрлар ясадылар. Фотоларның күбесе сакланмаган. Кызым Гөлчәчәк белән улым Илфат та теләп төштеләр. Песи белән шактый интегергә туры килде. Әби кулындагы песи кыргый иде, утырырга бер дә теләми, кача да китә. Кибеттән нindидер бер консерв алып чыгып, шуның белән бераз сыйлагач кына утырды.

Бик кызык булды безгә кинога төшү. Иң гаҗәпләндергәне – шуның өчен акча да түләделәр үзебезгә. Өч сум бер кешегә шактый зур сумма иде ул чагында. Аннан фильмның экранга чыкканын түземсезлек белән көттек. Бер елдан соң аның премьерасы булды, бөтен гаилә белән клубка барып карадык.

Бу вакыйгалардан соң 20 ел узды. Галимә әби күптән вафат. Гөлсирин ханым үзе әби булды. Кызы Гөлчәчәк кыз үстерә. Гөлсирин ханым ире Нәсыйх белән Миңлебай газ эшкәртү заводында бер цехта эшлиләр, Түбән Мактама посёлогында яшиләр.

Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы илленче елларда язылган, «Татнефть» акционерлык җәмгыятендә чыга торган һәм нефтьчеләрнең тормышын яктыртучы газета да шулай атала. Икенче «Хәзинә»нең туган елы – 1994 ел. Фильмның да, газетаның да туган җире – Әлмәт төбәге.

*Наилә Ганиева*
«Хәзинә». – 1995. – 21 июль

## «Хәзинә»-фильмы-турында-уйланулар,-хатирәләр

Уйлар, эшләр нефть белән сугарылган.

Күпне күргән бу җир. Ил картлары йөзе кебек, сүзсез, мәгънә белән тулы җир... Тын Кәлимәт урамында ташландык арба. Әйтерсең лә сугыштан соңгы дөнья. «Инде кая барырга, кем килеп җигә мине?» дигән шикелле, үзен алга этәрдәй бер көч көтеп тора.

Фильм бу урында ак-кара итеп төшерелгән һәм кинәт, болыттан соң җылы кояш чыккан шикелле, бу урамга күпне күргән «полуторка» машинасында ир-егетләр, бу якларның булачак хуҗалары килеп керә. Мезозойлардан бирле Шәвәли картларның аталары хыялындагы алтын хәзинә нефть елгасы булып ташып чыга.

«Хәзинә» фильмында бер генә тапкыр да нефтьнең үзе күрсәтелми. Әмма Кәлимәт халкының, Гариф Ахунов геройларының аңнары, уйлары, эшләре, яшәүләре шул нефть белән сугарылган кебек. Нефть кешеләр психологиясенә катлаулы багланышлар алып килә.

*Әхәт Гаффар,*
язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе



# «Безгә-генә-күчеп-кил!»

Фильм төшерү кызыклы, гыйбрәтле хәлләрсез булмый инде ул. «Хәзинә» фильмында шундый бер урын бар: яңгыр коя да коя, буровойны туктатырга ярамый. Мине, Нуришановны, «Цемент!» – дип, якадан алалар. Ә Әлмәттә яңгырның әсәре дә юк. Су белән бөтен янгын машиналарын җыеп китерделәр. Эпизод төнлә, прожекторлар яктысында, шул «коеп яуган яңгырда» төшерелә. Теге су запасы бер дигәнче бетте. Хәзер җир астыннан турыдан-туры суыртып, безнең өскә яудыралар. Су салкын, өстә плащ кына. Съёмка җиде сәгать барды. Киемнәрне алмаштырып, аз гына җылынабыз да, тагын лачма су. Бик туңдык. Ул Громадский – Кәрим Тимбиковның үлемгә барган, әмма рекорд куйган төне.

Бу кадәр газапларны күреп торган бурильщиклар: «Сезгә күпме түлиләр соң?» – дип сорыйлар. Роль өчен алты йөз сум, килешүдә шулай каралган. «Алты йөз сум өчен ике ел йөрергә, без бит аны бер көндә алабыз. Күчеп кил безгә. Әллә нәрсә эшләмәссең, безнең тирәдә булырсың, акчалы булырсың!» – диләр.

Хөкүмәт, өлкә комитеты фильмны төшерүгә бик зур әһәмият бирде. Свердловск киностудиясенә спектакльдән буш көннәрдә самолётта очабыз, бер-ике минут өчен дә очабыз. Һичбер тоткарлык юк.

Фильмның урталары иде. Әти авырып ята. «Әти, мин китим инде, рөхсәт ит, безнең шулай, шулай съемкалар бара», – дип аңлаттым да Свердловскига очтым.

Беркөнне нигәдер бар игътибарны миңа юнәлттеләр: гел минем эпизодларны төшерәләр, аптырый башладым. Ялга дип менгергәннәр иде, кинәт звонок, әни шалтырата. «Әтиең вафат, кайт!» – ди. Ул көнне миңа телеграмманы күрсәтмәгәннәр икән. Режиссёр съемканы өзәргә теләмәгән инде. Кочетков Владивостоктан ук килеп йөри. Безнең мәҗлес, тантана, Кәримне бүләклиләр, эчәләр, җырлыйлар. Ә минем әти кадәр әти дөньядан киткән. «Син тырыш инде яме», – ди режиссёр.

Барысын да бик әйбәт оештырдылар, самолёттан төшүгә, машина көтеп тора. Төнлә кайтып җитеп, иртән әтине җирләдек.

Аннары фильмны тамашачыга тәкъдир итү булды. Нефтьчеләр турында беренче фильм, нефтьчеләр үзләре карыйлар. Әйбәт кабул иттеләр. Безнең актёрлар икенчелрәк рольләрдә булсалар да, бу вакыйга иде. Вера Минкина, Габдулла Шамуковларның рольләре уңышлы иде.

Татарстан нефтенең тарихы бик бай һәм данлыклы. Ул сәнгать үсешенә дә зур этәргеч ясады. Әлмәт күпме язучыларны чакырып китерде. Анда тагын кайчан Язучылар берлеге, шундый театр булыр иде.

*Шәүкәт Биктимеров,*
ТАССР, РСФСР, СССРның халык артисты

# Чудные-были-времена

После окончания Щукинского театрального училища была я принята на работу в Кабардинский государственный драматический театр и с головой окунулась в работу. Предложение сниматься в фильме «Клад», да еще в главной роли, для меня было большой неожиданностью: почему именно я, как на меня вышли? Предложение, безусловно, заманчивое. Увы, была вынуждена отказаться, ведь уже была занята в шести спектаклях из семи, которые шли тогда в театре. Если я буду выезжать на съёмки, то сорву спектакли. А в студенческие годы нам всегда твердили, что театр должен быть на первом месте.

После того как я отказала, эту роль предложили актрисе из Театра Советской Армии. Полтора месяца она снималась, но худсовет забраковал. Дело в том, что нужно было играть и 16-летнюю героиню, и 28-летнюю, и 50-летнюю. Где-то у нее получалось убедительно, а где-то нет. А вскоре в Нальчик приехали помощник режиссёра, ассистент режиссёра, меня сфотографировали. Через некоторое время позвонили и сообщили, что я утверждена на главную роль. Отправилась в Свердловскую киностудию – меня загримировали, дали примерить костюмы.

Чудные были моменты. Там встретилась со своими преподавателями. Ларису Алексеевну Пашкову я просто обожала. Это, оказывается, она меня рекомендовала на главную роль. А в фильме «Клад» она играет роль Файрузы. С исполнителем главной роли – Александром Филиппенко я была знакома, я проходила практику в театре имени Вахтангова. С ним было очень легко и комфортно.

Съемки проходили и в Свердловске, и в Альметьевске. Например, сцены встречи Мунавиры и Арслана снимали в берёзовой роще под Свердловском, застолье в честь очередного рекорда – в павильоне киностудии, а пруд – в Альметьевске. В Альметьевске мы находились в прекрасное летнее время, нас разместили в гостинице «Нефтяник». Вечерами было очень весело: народ собирался на большой площадке перед Домом техники, там звучала музыка, и люди танцевали под эту музыку.




Гариф Ахунов романы буенча «Клад» («Хәзинә») фильмы афишасы. Свердловск киностудиясе. Төп рольләрдә: А.Филиппенко, Ж.Хамукова



Илфак Ибраһимов, Наилә Ахунова һәм актер Александр Филиппенко «Кояшлы шәһәр» микрорайонында Гариф Ахунов урамын ачу тантанасында. Казан. 2008, 4 июнь

Хотя и уставали после съемок, но всей съёмочной группой тоже ходили туда и вальсировали.

Мне очень понравились татарские мужские имена. Когда вернулась со съёмок, всем своим подругам, у которых в то время родились дети, предложила дать им татарские имена. Теперь у нас, в Кабардино-Балкарии, живут Дамиры, Анвары, Ильнары...

Меня везде принимают за свою. И в Альметьевске тоже приняли за татарочку, а также моего педагога Ларису Пашкову.

К сожалению, из-за сильной занятости я не смогла поехать ни на премьеру, ни на IX Всесоюзный кинофестиваль, куда была приглашена в составе Уральской делегации как исполнительница главной роли в фильме «Клад».

Премьера фильма состоялась в Альметьевске. В это время в городе в командировке находился мой родственник. Он звонит мне: «Жанна, тут везде твои портреты висят. Я говорю коллегам, что это – моя родственница, а мне никто не верит».

Честно говоря, я ненавидела себя на экране. Но работать тогда было безумно приятно. С теплотой вспоминаю своих партнёров по фильму, к сожалению, уже нет в живых Ларисы Пашковой. Сегодня работаю в Кабардинском государственном театре имени Али Шогенцукова, а также преподаю сценическую речь в Северо-Кавказском государственном институте искусств.


*Жанна Хамукова,*
заслуженная артистка Кабардино-Балкарии

# Клад — это человек

*Александр Филиппенко,*
народный артист России:

«Я счастлив, что мне удалось сыграть в фильме, снятом по очень хорошей книге. Роман «Клад» был посвящен развитию нефтяной отрасли Татарстана, но ведь на самом деле настоящий клад – это человек. Тем более такой, каким был Гариф Ахунов».

*(Из выступления А. Филиппенко на открытии ул. Гарифа Ахунова в Казани 4 июня 2008 г.)*



«Хәзинә» фильмында нефтьче Арслан ролен уйнаган театр һәм кино артисты Александр Филиппенко 2008 елның 4 июнендә Казанда Гариф Ахунов урамын ачканда

pr-marka.ru›action/ahunov.php

https://www.facebook.com/photo.php?fbid=529841723760018&set=pcb.529842797093244&type=1&theater

Библиография*:

Клад: Роман / Авториз. пер. с татар. 1963. 270 с., ил. 65000. В. Харчева. М.: Мол. гвардия, 1963. – 270 с., ил. 65 000.

То же. Изд. 2-е, исправл. Казань: Таткнигоиздат, 1967. – 240 с. 100000.

То же / Авториз. пер. с татар. Р. Ахунова. М.: Современник, 1976. 463 с. 50 000. Кроме заглав.: «Ардуан-батыр».

То же / Пер. с татар. Р. Ахунова. М.: Сов. Россия, 1978. 302 с. 50000.

То же. – М.: Современник, 1981. 302 с. 10000. Рец.: Бикчентаев А. Люди нефтяной земли // Лит. газ. 1964. 27 февр.; Мустафин Р. Клад писательский // В мире книг. 1964. № 3. С. 26; Брусиловская Т. // Нефтяник. 1967. № 12. С. 33–34; Мустафин Я. О красоте человеческой // Сов. Татария. 1967. 19 сент.; Ахунзянов И. Нефтяная тема Гарифа Ахунова. (На соиск. премии им. Г. Тукая) // Сов. Татария. 1973. 19 апр.; Валеев Д. Размышления вокруг перевода // Комсомолец Татарии. 1977.

* Здесь приведена (фрагментарно) библиография Г. Ахунова по роману «Клад» (из Татарской электронной библиотеки).

8 июня; Шагалов А. Вглядываясь в современность (Нравственный поиск современной прозы о рабочем классе). – М., 1979. 431 с. О романе. С. 286–289; Асташенков Б. Судьбы калиматовцев // Лит. газ. 1979. 12 сент. С. 5; Авдеев А. Радость новой встречи (О кинофильме «Клад») // Сов. Татария. 1977. 20 февр.; Алешечкин В., Манасыпов Ф. «Клад» – фильм о нефтяниках Татарии // Нефтяник. 1977. № 9. С. 37–38; Егоров Н. «Клад», который нам дорог // Сов. Татария. 1977. 19 февр.

КЛАД (1975)

«КЛАД», СССР, Свердловская киностудия, 1975, цв., 94 мин.

Кинороман.

По мотивам романа Гарифа Ахунова.

Фильм, прослеживающий историю освоения татарской нефти с 50-х годов, рассказывает о династии нефтяников Губайдуллиных.

В ролях: Александр Филиппенко (см. ФИЛИППЕНКО Александр Георгиевич), Роман Громадский (см. ГРОМАДСКИЙ Роман Борисович), Лариса Пашкова (см. ПАШКОВА Лариса Алексеевна), Шаукат Бектимиров, Марианна Вертинская (см. ВЕРТИНСКАЯ Марианна Александровна), Афанасий Кочетков (см. КОЧЕТКОВ Афанасий Иванович).

Режиссер: Ольгерд Воронцов (см. ВОРОНЦОВ Ольгерд Риксович).

Автор сценария: Владимир Потоцкий.

Оператор: Анатолий Лесников (см. ЛЕСНИКОВ Анатолий Егорович).


Художник-постановщик: Владислав Расторгуев (см. РАСТОРГУЕВ Владислав).

Композитор: София Губайдулина (см. ГУБАЙДУЛИНА София Асгатовна).

Текст песен: С. Хаким, М. Тазетдинов.

Звукорежиссер: Лилия Винокур (см. ВИНОКУР Лилия).

Монтаж: Луиза Садовская.



*Почетный нефтяник акционерного общества «Татнефть»*

Решением администрации и профсоюзного комитета акционерного общества «Татнефть»

от 18/IX 1995 г. №

ПРИСВОЕНО ЗВАНИЕ

*Почетный нефтяник акционерного общества «Татнефть»*

тов. Гарифу АХУНОВУ (Гарифзяну Ахунзяновичу Ахунову) писателю за большой вклад в развитие нефтяной промышленности Республики Татарстан, нравственно-эстетическое воспитание жителей нефтяного края, многолетнее и плодотворное сотрудничество с нефтяниками

Генеральный директор Р.Г.Галеев

Председатель профсоюзного комитета М.Ф.Матдеев

# Танышу

1959 елның ноябрь ахырлары. Актүбә читендә генә яңа скважина бораулый башладык. Вахта машинасына утырып, кырык-илле чакрымдагы буровойларга чыгып чапкан вакытлар булды, ә монда... Тулай торактан өч-дүрт минутлык җирдә эшлибез. Тик менә көннәр озын тора, төньяк җиле үзәкләргә үтә. Ноябрь ахырлары елның-елында чатнама суыклар алып килә безнең якларга.

Буровойны тәмамлап киләбез – алда метрлар. Эшне бүләбез дә балчык измәсе ясыйбыз.

Көтмәгәндә без йөри торган урман сукмагыннан буровойга ике ир якынлашты. Үзебезнең бистә кешеләре түгел – ятлар, безгә таныш түгелләр. Чатнама суыкта икесе дә язгы-көзге пәлтәдән, шуның өстенә берсе генә башына сарык мехыннан тегелгән ыспай кара бүрек кигән, ә олырак яшьтәгесе кепкадан. Армиядән кайтканнан соң, мин дә кыш буе кепка киеп йөрдем, ә солдат бүреген эшкә кия идем. Хәзер исә минем башта да сарык мехыннан тегелгән кара бүрек. Ә менә абзыйның башында...



Сулдан уңга: Әсгать Салах, Хәсән Туфан, Гариф Ахунов

Ике тиң килеп, безнең белән кул биреп күрештеләр.

– Без – язучылар, – диде кара бүреклесе. – Менә бу абыегыз – күренекле татар шагыйре Хәсән ага Туфан, ә мин – язучы Гариф Ахунов. Сезнең бригаданың чиксез уңышлары турында ишетеп, танышырга килдек әле...

Минем гаҗәпләнүемнең чиге булмады шул мизгелдә. Тәүге тапкыр тере язучылар белән очрашу иде бу. Менә алар каршыбызда гына, тыйнак кына елмаеп, безнең янда басып торалар.

Кунакларны каршыларга культбудкадан безнең бригаданың җитәкчесе – остазыбыз, Социалистик Хезмәт Герое Мөгаллим абый Гыймазов та чыкты. Ул аларның килүе турында хәбәрдар икән. Барыбыз да, суыктан качып, тизрәк җылы культбудкага кереп утырдык. Кайнар электр пиче өстендәге табада колбаса кыздыра

башладык, үзебез белән алып килгән башка ризык-нигъмәтләрне чыгардык, чәй кайнарладык һәм, күңелле итеп сөйләшә-сөйләшә, кунаклар белән ашап-эчеп алдык.

Ундүрт яшьтән район газетасында мәкаләләр бастыра башлаган, соңрак шигырьләр дә язгалагангадыр, мин һәрвакыт әдәбият белән кызыксынып, язгалап-сызгалап яшәдем. Һәм шул халәтем кунаклар белән очрашканда да үзен сиздерде булса кирәк, Гариф абый Ахунов:

– Син, малай, үзең дә язгалыйсың, ахры, – дип куйды.

Без кабат измә ясарга чыктык, ә кунаклар остазыбыз белән сөйләшә калдылар. Соңыннан алар вышка башына менеп төштеләр. Киткәндә, мин аларның кайда урнашуларын сораштым.

– Кер, әйдә, кер, Әсгать. Сөйләшеп утырырбыз, – диде Хәсән ага. Аның белән Гариф абый да килеште.

Эш ахырында мин, верховой сәндерәсенә менеп (ул вакытта мин верховой булып эшли идем), армиядә бүләк иткән көмеш портсигарымны алдым. Тартуны сирәгәйткән, ташларга йөргән чак. Портсигар эченә минем санаулы «Север» папирослары янына Хәсән ага өч данә «Любительские» папирослары куеп калдырган булып чыкты. Ул гел шул сыйфатлы, затлы папиросны гына тарта торган иде.

Кич белән мин, кучтәнәчләр тотып, алар янына кердем. Актүбәдә ике тулай торак кына бар, кунакханә юк иде. Ир-атлар тулай торагы янындагы ике катлы «щитовой» йортның икенче катындагы бер фатир кунакханә ролен үти иде. Хәсән ага Туфан һәм Гариф абый Ахунов нәкъ әнә шунда өч көн яшәп, Актүбә бистәсе халкы, бораулаучылар, нефть чыгаручылар һәм төзүчеләр белән «Буровик» клубында, укучылар белән бердәнбер урта мәктәптә очрашулар үткәреп йөрделәр. Чыгышлар ясау, шигырьләрен уку, үзе турында сөйләү Хәсән ага өлешенә тиде, чөнки ул утызынчы еллар ахырында котырынган репрессия корбаны, бер гаепсез килеш «халык дошманы» буларак атарга хөкем ителгән, «всесоюзный староста» Михаил Калининга язган үтенеч хатыннан соң гына исән кала алган, 17 ел утырып, ниһаять, акланган һәм 1956 елда сөргеннән азат ителгән шагыйрьне халык белән очраштыру-таныштыру кирәк иде, һәм бу вазифа Әлмәттә әле оешырга тиешле Язучылар оешмасының булачак җитәкчесе, яшь прозаик Гариф Ахуновка йөкләнгән иде.

Бәхеткә каршы, ул көннәрдә безнең вахта көндез эшләде һәм өч көндә дә мин Актүбәнең олы кунаклары янында булуга ирештем. Язучылар аракы эчми торганнардыр дип, беренче керүемдә шампан шәрабе белән генә сыйланган идек. Соңыннан минем караш үзгәрде. Беренче көнне үк Гариф абый белән без күбрәк Хәсән аганы тыңладык. Аның сөйләгәннәре йөрәк өзгеч иде. Тикшерүдә яткан чорда аның хәләл җефете – Луиза Салиәскарова һәр көн ашарга алып килә. Бу вакытта танылган актрисаның үзен дә, «халык дошманы» дип, эштән куган булалар.

– Каян акча табасың соң син бу тәмле пәрәмәчләрне пешерер өчен? – дип сорый шагыйрь.

– Сорама, табам инде, – ди хатыны.

Баксаң, ул һәр көнне кан тапшыра икән, шул акчага ире өчен ризык хәстәрли.

Актүбәдән киткән иртәнге кунакларны бораулаучы дустым Фәрәсәт Әсхапов белән үзебезнең бораулау конторасына чаклы озата бардык. Анда аларны озатырга автобус бирделәр. Китәр алдыннан Хәсән ага: «Казанга килеп чыксаң, безгә дә керерсең», – дип, адресын язып калдырды. Аның үрнәгендә Гариф абый да адресын бирде. Контора каршында Фәрәсәт безне фотога төшерде. Ул сурәт бүген дә минем альбомда саклана.

Моңа өстәп мин шуны гына әйтә алам. Хәсән агаларда – Казанда Маяковский урамындагы ике бүлмәле, кызы (Хәсән ага аңа Гуля дип эндәшә иде) белән яшәгән фатирда

өч-дүрт мәртәбә булырга, озаклап сөйләшеп утырырга туры килде. Алтмышынчы ел башында мин Гариф абый киңәше белән Казан университетының журналистика бүлегенә читтән торып укырга кергәч һәм кышкы сессияләргә баргач, яшь шагыйрь Марс Шабаев үтенече белән без тагын икәү Хәсән агаларда кунакта булдык.

1967 елның ноябрендә Әлмәттә уздырылган язучылар семинарыннан соң Хәсән ага һәм аның белән бергә танылган әдип, тәнкыйтьче, университет укытучысы, остазым Гази Кашшаф, Туфан кебек үк репрессия корбаны, язучы Сөббух Рәфыйков һәм минем Азнакайда яшәгән чорда ук якын дустыма әверелгән шагыйрь, язучы Рахмай Хисмәтуллин бездә кич утырып, кунак булып киттеләр. Ә мондый садә очрашулар хәтердән һич җуелмый.

Халкыбызның күренекле шагыйре Х. Туфан белән якыннан танышып, дуслашып йөрү елларын мин тормышының илаһи сәхифәсе итеп саныйм.

Ә Гариф абый белән без Азнакайдан Әлмәткә күчкәч тагын да ныграк аралашып, дуслашып яшәдек, чөнки «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» романнарын язган чорда аңа нефть сәнгатен, буровой эшләрен әйбәт белгән кешеләр киңәше, аларның фикерләре, уйлары бик кадерле иде. Ул очрашуларын Гариф абый кайчак телефоннан гына бирә, кайчак кичен урамга һава суларга чакыра да шунда иркенләп сөйләшә иде.

Аның шулай үз итеп аралашуы бер рәхәт иде.

Миндә Гариф абыйның автограф белән язып калдырган китаплары саклана. 1974 елда басылган «Хәзинә»сенә ул «Әсгать дустыма – бәхетнең зурысы, хезмәтнең олысы. Дусларча: Гариф Ахунов. 19.09.75» дип язган. Гомумән, яңадан Казанга кайтып киткәч, Гариф абый очрашкан вакытта минем буровой эшчесеннән журналист, аннары мөхәррир булып җитешүем, хәтта язучы булып китүем турында әңгәмәдәшләренә сөенеп сөйли торган иде.

Күз алдымда еш кына Актүбә эшчеләр бистәсе янындагы урман эчендә шау-гөр килеп эшләп торган буровой, урман сукмагында шул буровойга таба килүче ике кеше – Хәсән ага Туфан һәм Гариф Ахунов...

Минем өчен аяклары төпле булды бу ике олуг шәхеснең. Язмыш мине соңыннан берсе икенчесеннән талантлырак бик күп мәшһүр әдипләр белән очраштырды, таныштырды, аралаштырды һәм хәтта дуслаштырды да...

*Әсгать Салах,*
язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

# Долг-памяти

Писатели, как и все другие люди, есть всякие. Прозаики, драматурги, поэты, критики, живущие в потустороннем мире-фантасты, и те, кто предпочитает писать правдивые очерки. В свою очередь среди них, старых и молодых, есть маститые, вкусившие плоды собственной славы, и начинающие сочинители, жаждущие найти себя на, увы, непредсказуемом литературном поприще, на котором разочарований бывает куда больше, чем случается удач. Однако всю писательскую рать можно поделить на две большие половины: на счастливых и несчастливых. Счастливые радуются каждой удачной книге, каждому удачному слову, неожиданному эпитету, новой мысли, необычному сюжету в сочинениях товарищей по перу. Чужим удачам они радуются больше, чем своим. Несчастливые в чужих книгах ищут просчеты, чтобы споткнуться о невнимательно написанные строчки, увидеть вывод, не подтвержденный изложенными фактами, и, довольные своим открытием, спешат позлорадствовать над автором. Такова природа писательского ремесла: похвала подбадривает творчество, принуждает искать, как умножить число удач, из которых стежками буковок плетутся волшебные книжные страницы. И, наоборот, упреки убивают литературную страсть.

Гариф Ахунов, как профессиональный литератор, один во многих лицах: прозаик, правдолюбец-очеркист, критик, драматург, не гнушается он побаловаться стихами, которые, правда, отдельной книгой не выходили, но на музыку положены, звучат по радио, поются в народе. По общей классификации, по моему мнению, он относится к счастливым писателям, которые больше, чем собственным литературным достижениям, радуются удачам других. Долго летят мгновения, как быстро, словно птицы, летят годы! Давным-давно я, репортер-побегушечник городской газеты, показал Ахунову свой литературный опус начинающего писателя, в котором рассказывал о нефтяных буднях мастеров, добывающих черное золото. Был готов к разному, но все-таки ожидал похвал. Ахунов, только что приехавший в черный мазутный край поднимать литературную целину, с отзывом не затянул. Он вернул рукопись буквально на другой день. Страницы были черными от горбатых вопросительных знаков, среди них одинокими былинками травинок стояли жалкие палочки восклицаний. И не убил, а похвалил: «Ты, молодец! Гений – не гений, но талант»! Я что-то невразумительно вякнул: «Талант, а страницы – сплошная чернота. Должно быть наоборот».

– В литературе бывает и так. Если ты среди тысячи слов написал одно талантливое, значит, в силах найти и другие. Надо лишь пересилить себя, собственную лень, которая родилась раньше дела. Без труда талант – лишь дерево, которое не одарит плодами, родник, который не добежит до воды большого океана. Долг таланта – не загубить собственное дарование простой ленью, не захоронить в пустых словопрениях о собственном литературном предназначении, а украсить это каждодневными усилиями. К сожалению, первое случается часто, второе, увы, редко!

Наверное, этот явно преждевременный комплимент, пожелание добра приободрили меня продолжить литературные опыты. Я, по самую макушку загруженный газетной

беготней, отважился пробовать свои силы во многих литературных формах, в сочинении очерков, рассказов, повестей, сценариев к телефильмам, написал несколько документальных книжек. Одну из них – «Мы с Волги, из Казани» мы написали с Ахуновым вместе, и я на практике убедился, что похвала действует сильнее, чем профессиональные разносы. Творить вдвоем много труднее, чем кропать в одиночестве. Не потому, что приходится делиться славой, гонораром, а от того, что еще до рецензентов, редакторов написанное оценивает соавтор. Ахунов читал придирчиво, но просчеты пробегал, не задерживаясь, больше отмечал достоинства. Причем его суждения были такими, что мне становилось неловко, что удачных мест в рукописи куда меньше, чем слабых. Сгорая от стыда, я принимался переписывать страницы заново, совсем не уверенный, что эта правка – последняя.

Литературная судьба крестьянского отрока Гарифа Ахунова из маленького татарского аула Учили, несколько дворов которого потерялись под обломками бесконечных преобразований суматошной эпохи, складывалась накатанно и счастливо. Судьба словно искупила свою вину за годы его горького сиротства (отца, агитировавшего мужиков вступить в сельскохозяйственную коммуну и вставшего во главе тех, кто хотел хозяйствовать на земле по-новому, убили кулаки) и, кроме таланта, осчастливила редкостным трудолюбием, упорством, сознанием, что все препятствия преодолеваются одним – работой. Детство – это работа в поле, уход за скотиной, семь классов сельской школы. Затем – педагогическое училище, университет, еще в студенческие годы первые рецензии, рассказы, повесть «Краса юности», приглашение работать в редакцию литературного журнала «Совет әдәбияты»: сначала литсотрудником, затем – зав. отделом прозы, ответственным секретарем.



Султан уңга: Марсель Зарипов, Джанни Родари һәм Гариф Ахунов. Кокушкино, 1969

Кто из молодых не жаждет зацепиться в толстом журнале, крутиться среди столичной литературной богемы, творить самому и судить других? Однако натуру Ахунова не удовлетворял триумф кабинетных удач. Как раз началась славная нефтяная эпопея. Вместе с мастерами черного золота загорались новыми замыслами и писатели, редко какой из сочинителей не побывал в краю нефти и вышек, в гуще жизни не «выпачкался» в жирном мазуте.

Поехал к нефтяникам и Ахунов. Думал – в короткую командировку, чтобы набраться эмоций, впечатлений, без которых не пишутся ни роман, ни повесть, ни простенькая деловая корреспонденция, а вышло – за своей литературной судьбой. Дорога еще никого не обездолила! В «нефтяные» годы своей жизни Ахунов написал книгу очерков, повести «За горой Артыш», «На перекрестке путей», в театрах шли его пьесы «Песня монист», «Горит очаг», «Беспокойное сердце», наконец, один за другим, как с конвейера, он вы-

дал романы «Клад» и «Хозяева». В те годы большой нефти романы рождались в результате писательских поездок за сбором материала, а писались они в уединении столичных кабинетов. Ахунову одних наблюдений было мало, он десять лет прожил среди своих героев; старался понять, чем озабочены и чему радуются люди нефтяного края. Поэтому его «жила» оказалась богаче, продуктивнее, оттого в его художественных сочинениях угадываются реалии бытия, видны характеры, списанные с живых людей.

Наверное, нет другой сферы деятельности, о которой не высказывалось бы столько противоречивых суждений, как литературное творчество. Лев Толстой, например, предсказывал, что придет время, когда писателям незачем будет живописать воображаемые события, материал для своих сочинений они будут черпать исключительно из фактов окружающей действительности. Многомудрый Мишель Монтень учил литераторов обратному: они должны описывать не текущую жизнь, а воображаемые события, которые могли бы произойти. Вольному – воля, счастливому – рай! Все зависит от автора, пристрастий его пера. Ахунов был одинаково силен и в описаниях действительных фактов, и в предвидении будущих картин. В романе «Хозяева», который продолжает темы, начатые еще в предыдущей книге его дилогии – романе «Клад», Ахунов описывает фантастические для того времени заботы о расчетливом, бережливом обращении с главным богатством республики – черным золотом…

Писательское слово – что семя, упавшее в землю: оно дожидается своего часа, чтобы одарить пахаря урожаем. Гарифа Ахунова природа не обидела талантом, но еще больше она вознаградила его могучим трудолюбием, сопротивление белого листа бумаги он преодолевал единственно возможным приемом – трудом. Обычно писатели представляются большими жизнелюбами, страстными мастерами ужения рыбы, охотниками, любителями ходить в лес по грибы, которые в таком общении с природой находят материал для



Сулдан уңга: Наилә Ахунова, Фәһимә Хисамова һәм Марсель Зарипов. Әлмәт юлында, 2006

литературного самовыражения. В отечественной литературе часто так разрабатывали темы Некрасов, Тургенев, в советские годы Пришвин, Паустовский, Нагибин, Солоухин. Среди татарских писателей большим знатоком этих тем показал себя Мирсай Амир, написав книгу «Рыбацкие байки». Ахунов не увлекался рыбалкой, не тешил душу охотой, он не загонял в ствол смертоносный заряд дроби, которая оборвет жизнь какой-нибудь беззащитной твари. Время, потраченное на эти увлекательные занятия – именно так представляют охоту, рыбалку, грибную страсть любители подобных форм общения с природой, – Ахунов считал похищенным у литературы. И таких трат драгоценного времени себе не позволял.

Вспомним, в каких обстоятельствах творил свои сочинения Ахунов. Излишков ресурсов времени у него не оставалось. Литературным творчеством он занимался в часы, которые у него выдавались свободными от других суетных и хлопотных нагрузок. В будни, в праздники и выходные спозаранку, когда другие еще видели сладкие утренние сны, по ночам, когда весь мир отходил от забот текущего дня. Это сейчас птенцы нефтяного литературного цеха – Мусагит Хабибуллин, Клара Булатова, Энже Мукминова, Сажида Сулейманова, Альберт Хасанов, Марсель Галиев, Фоат Садриев, Нур Ахмадиев, Дамир Гарифуллин, Разим Валиуллин – называть все имена, фамилии не хватит книжной страницы – убеленные сединами мэтры, признанные читателями поэты, прозаики, драматурги, критики. В те годы, когда Ахунов собирал писателей нефтяной округи в дружную артель профессионалов литературного объединения, под началом у него была лишь единица бухгалтера-кассира. Как прикованный к столу литкаторжанин, он корпел над горами рукописей начинающих сочинителей, в кипах бумаги выискивая редкие камни-самоцветы таланта.



Гариф Ахунов белән Клара Булатова

После десятилетней отлучки возвратившись в Казань, Ахунов два срока возглавлял писательский союз, дважды избирался делегатом съезда партии. Нагрузки не свадебного генерала, восседающего в креслах почетных президиумов, а рабочей ломовой лошади. В писательской практике стали нормой ежегодные подведения итогов литературного творчества, комиссии по работе с молодыми авторами, по изданию книг татарских писателей в столичных издательствах, через русский язык – выход на майдан многонациональной литературы братских народов. На жарких литературных разборках больше всего доставалось, как правило, председателю, «не причастному» к удачам, но обязательно «повинному» в недочетах. Кроме того, на председателе творческого союза было много других житейских забот: приходилось хлопотать о квартирах, о путевках в Дома творчества... А собрания, съезды, конференции, симпозиумы, «круглые столы», другие бесконечные сборища, на которых помногу и подолгу переливали из пустого в порожнее...

В Москве мы не раз оказывались с Ахуновым под крышей одной гостиницы, селились в общий двухместный номер. С утра, наскоро перекусив в толкучке гостиничного буфета, Ахунов отправлялся в поход по издательствам: сначала мчался на худсовет в «Современник», днем был в «Советской России», вечер заканчивал в «Совписе». В гостиницу он возвращался измотанный, но довольный, счастливый итогом своих хождений по московским канцеляриям, доставал из портфеля прихваченный по пути полуштоф, сообщал, что несколько позиций в издательских планах застолбил. Предлагал: «Давай отметим удачу! Пожелаем, чтобы татарские фамилии не вылетели из списка». В последние годы, которые преподносятся как время преобразований, в результате которых выход книг татарских писателей за пределами республики стал такой же редкостью, как июльский снег и январский зной, период ахуновского руководства союзом надо признать золотым.

Даже на пенсии он снова впрягся в хомут общих литературных забот. Когда пошла кутерьма перестройки, которую суровый на характеристики народ точно назвал крахостройкой бездарных реформаторов, в Союзе писателей тоже пошли по общему руслу – жанровые тенденции заменили художественными мастерскими и одну из них «нагрузили» на Ахунова.

Оказывается, как много можно сделать, даже если творить только «на досуге», в перерывах между другими занятиями! Учившийся в татарской школе, на факультете татарского языка и литературы, Ахунов понимал, что татарские читатели должны знать хотя бы лучшие образцы других литератур, и, не зная устали, занимался переводами, находя в этом занятии не только громадное нравственное удовлетворение, но и постигал писательскую кухню творчества других мастеров. Он перевел на татарский язык «Плавучую станицу» Закруткина, «Педагогическую поэму» Макаренко, «Быстроногого оленя» Шундика, сборник рассказов Рабиндраната Тагора. Вместе с Яхъей Халитовым они перевели все четыре книги «Тихого Дона», и герои великой шолоховской эпопеи заговорили на татарском языке. Долг платежом красен! Много переводил Ахунов, немало переводили и его, его книги изданы почти на двух десятках языков народов многонационального Союза.

Ахунов не тяготился документальными формами литературных сочинений, в которых нельзя перевирать факты, ошибаться в фамилиях, инициалах, оценках и выводах, Так, в перерывах между романами он написал документальные книги «Ардуан батыр», «Поездка в Олуяз», «На земле Тукая», «Куда несут крылья», сборник эссе о собратьях по перу «Как загораются звезды», в которых он вопреки печальной традиции возносить писателей только после того, как они расстанутся с этим миром, сказал добрые, подбадривающие слова о них при жизни. По моим наблюдениям, в последние годы жизни Ахунов пришел к убеждению, что в документальных формах можно сказать больше, чем в вы-



Сулдан уңга: Клара Булатова, Гамил Афзал, Гариф Ахунов

мышленных сочинениях. В последние годы он написал книгу о трудолюбивых мастерах полей своего родного района – это «Открытая книга Арской стороны». Загоревшись любопытными и поучительными страницами жизни ветерана Тимерхана Бурханова, он посвятил ему документальную повесть, которую так и назвал «Увиденное и прожитое Тимерханом».

Аптеки и больницы Ахунов не жаловал, микстурами и пилюлями не увлекался. С врачами предпочитал общаться в неофициальной обстановке. Однажды ему предложили прооперировать желудок, но он сбежал из палаты, чем впоследствии очень гордился: вот, мол, какой я – сильней хворей и недугов! Однако в другой раз его настигла черная мгла предательской катаракты, опасность навсегда остаться во мраке ночи. Хирургическим вмешательством все завершилось счастливо, а он, едва оправившись от болезни, разродился документальной повестью «Зеница ока», которую посвятил чудодеям-офтальмологам, возвращающим людям свет солнца.

В литературном обиходе существует выражение «главная книга». Сколько бы писатель ни написал произведений, он всегда живет ожиданием, что главная его книга впереди. Ахунов свою главную книгу написал. В течение сорока с лишним лет в пять утра он садился заполнять толстую амбарную книгу дневника, в которую заносил все, что произошло накануне. Начинал с погоды, кончал записями: с кем встречался, о чем говорил, что думал. В отличие от мемуаристов, которые спешат сообщать миру о каждом своем чихе, эти сведения составляли писательскую и гражданскую тайну его жизни. При жизни Ахунова эти житейские откровения не видела ни одна живая душа. Надеюсь, настало время, когда эти дневниковые записи можно обнародовать.

*Марсель Зарипов,*
писатель, публицист, заслуженный работник культуры РТ

# Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы язылуга 50 ел тулды

9 октябрьдә Казанның Габдулла Тукай музеенда классик язучы Гариф Ахуновның иң танылган әсәре – «Хәзинә» романына багышланган кичә узды. Ул Татар әдәбияты музее мөдире Альбина Әбсәләмова һәм шагыйрә Наилә Ахунова тырышлыгы белән оешкан «Татар язучылары балалары» клубы эшчәнлеге кысаларында үткәрелде.

«Хәзинә» романы узган гасырның 50–60 нчы еллардагы Татарстан нефтьчеләре тормышын тасвирлый. Билгеле булганча, быел Татарстанда кара алтын – нефть ятмалары табылуга 70 ел тула. Сүз шушы ике вакыйганы бәйләп алып барылды.

Гариф Ахунов 50 нче еллар ахырында бер төркем татар язучылары белән Әлмәткә күченеп килә, биредә алар Татарстан Язучылар берлеге бүлеген төзиләр, бу яклар өчен яңа бер тормыш – нефть чыгару җәелә башлавын, моның кешеләр язмышын ничек үзгәртүен күзәтәләр, әсәрләрендә тасвирлыйлар. Шул еллардан Әлмәттәге олпат язучыларыбыз бар татар халкында танылу алды. Гариф Ахунов, Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал исемнәре генә ни тора!

«Хәзинә» романына килгәндә, аның язмышы бик бәхетле. Укучылар аны яратып кабул итәләр. Бүгенге көндә китап 17 мәртәбә басылган, гомуми тиражы 6 миллионнан артып киткән, ул дистәләрчә телләргә тәрҗемә ителгән, роман зур экраннарга нәфис фильм буларак та чыкты.

«Хәзинә» романы, Әлмәттәге Татарстан Язучылар берлеге бүлеге тарихы, язучы Гариф Ахунов турында истәлекләр белән кызы Наилә Ахунова, Рафаил Төхфәтуллинның улы Рөстәм, шагыйрь Наил Касыймов, Гариф Ахуновның тормыш иптәше Шәһидә Максудованың туганы Марсель әфәнде чыгыш ясадылар. Кичәгә килүчеләр арасында Казанның Гариф Ахунов исемен йөртүче урамында урнашкан 35 нче гимназиядән 8 нче сыйныф укучылары да бар иде. Мәктәп хезмәткәре Эльвира Минеева сүзләренчә, мәктәпләрендә укучыларга татар әдәбиятына, гомумән, мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләргә тырышалар. Бигрәк тә Гариф Ахуновның иҗатына игътибар бирелә – балалар мәктәпләре урнашкан урамның нинди исем йөртүен яхшы белеп үсәргә тиешләр, дип ассызыклады Эльвира ханым.

*Әлфия Миңнуллина,*
журналист
*2013*




ТР Фәннәр академиясе китапханәсендә Ахуновлар әдәби династиясе китаплары күргәзмәсе. 2012

# Нефтьчеләргә-һәйкәл-куйды

Шигърият белән яшьтән үк кызыксынганга күрә, узган гасырның алтмышынчы елларында Әлмәтнең «Строймеханизация» трестында эшләгән чакта каланың «Хезмәт байрагы» каршындагы әдәби берләшмәгә йөри башладым. Газета белән ул вакытта талантлы журналист Бари Вафин җитәкчелек итә иде. Бу утырышларны ашкынып көтеп алам, анда минем кебек каләм тибрәтүче төрле һөнәр ияләре дә, биредә яшәп иҗат итүче Гариф Ахунов, Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Гамил Афзал кебек күренекле язучылар-шагыйрьләр дә килә. Без алар хөкеменә үзебезнең иҗат җимешләребезне тәкъдим итәбез, аларның фикерләрен ишетәбез. Язган әйберләребезнең уңышлы һәм кытыршы якларын әйтеп бирәләр, мактаган сүзләре йөрәгебезгә сары май булып ята, кытыршылыклар өчен дә каты бәрелмиләр, ипләп кенә кимчелекләребезне күрсәтәләр. Безгә аларның фикерләре, нинди булуга карамастан, файдага иде.

Гариф Ахунов белән тәүге очрашуым да шул «Хезмәт байрагы» редакциясендә булды. Ул кара алтын чыгаручыларга багышланган «Хәзинә» романы өстендә ничек эшләгәне, нефтьчеләр янына культбудкаларга барулары, алар янында куна калып, һөнәрләренең барлык нечкәлекләрен белергә омтылганнары хакында, кайбер кызыклы мизгелләр турында бәйнә-бәйнә сөйли иде. Бу сөйләшү-аралашулар, әлбәттә, бер очрашу белән генә чикләнми. Кабат очрашкач, Гариф Ахуновтан тагын булачак әсәре хакында сораштырабыз, геройларның язмышлары нинди борылыш алачагы турында кызыксынабыз. Шуңа күрә дә романның дөнья күрүен түземсезлек белән көттек. Әлбәттә, язучы безгә тәфсилләп сөйләгән барлык эпизодлар да кермәгән, бу табигый хәл.

«Хәзинә» романы бәхетле язмышлы булды, ул киң катлау укучылар арасында популярлык казанды. Гариф Ахунов үзенең бу әсәре белән Татарстан нефтьчеләренә һәйкәл куйды.

*Рәис Кашапов,*
язучы

# Яңа-үрләргә!

1951 елның яз айлары иде. Мин, күләмле генә өйрәнчек бер кулъязмамны күтәреп, Казанга, «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә килдем. Өмет һәм шүрләү белән дөп-дөп килүче йөрәкне басарга тырышып, ишекне ачтым. Бүлмәдә мине чандыр гына гәүдәле, алка-алка эре кара бөдрә чәчле, ачык йөзле бер егет каршылады. Егетнең, шаян сүзләр кыстыра-кыстыра, бик гади сөйләшеп китүе минем каушавымны бик тиз басты. Мин әйтерсең әллә кайчангы танышымны очраткандай булдым.

Бу егет хәзер инде күренекле татар совет язучысы, Тукай бүләге лауреаты, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, СССР Югары Советы депутаты Гариф Ахунов иде.

Ул вакытта Гариф Казан дәүләт университеты студенты һәм бер үк вакытта «Совет әдәбияты» редакциясендә дә эшли иде. Редакциядә эшләүнең никадәр мәшәкатьле, бөтен көчеңне һәм вакытыңны ала торган хезмәт икәнлеген үз җилкәмдә яхшы белгәнлектән, мин гаҗәпкә калдым. «Вузда уку үзе генә дә бик авырдыр, өстәвенә никадәр катлаулы редакция эше! Ничек өлгерә икән бу егет?» – дим. Күп тә үтмәде, Гариф мине тагы да гаҗәпкәрәк калдырды. «Үсү юлы» альманахында аның «Галләм сорау бирә» дигән хикәясе басылып чыкты, газета-журнал битләрендә бер-бер артлы әдәби тәнкыйть мәкаләләре күренә башлады. Баксаң, Гариф Ахунов үз җилкәсендә ике дә түгел, өч йөк күтәреп бара икән: уку, эш һәм тагын да авыррагы – иҗат.

Язучы Гариф Ахунов биографиясе табигать биргән талантның аерылмас юлдашы, зарури шарты булган хезмәт сөючәнлек, чыдамлык һәм өлгерлек мисалларына гаять бай.

Язучының бу асыл сыйфатларының тамырлары шактый тирәннән башлана.

Чабаталы авылны олы юлга алып чыгу өчен киеренке көрәш барган утызынчы еллар. Сыйнфый көрәш кискен, рәхимсез, әледән-әле кулак образлары шаулый, ялкыннар кабына. Бу олы көрәш Арча районының кечкенә генә Өчиле авылын да читләтеп үтми. Шушы көрәштә авыл өчен янып-дәртләнеп йөргән коммунист Ахунҗан кулак ярченнәре тарафыннан ерткычларча үтерелә.

Әнә шулай алты яшьлек Гариф апасы һәм энесе белән ятим калалар.

*Атадан бала яшь кала,*
*Күп эшләрне башкара,–*

дип җырлый халык. Гарифка да бик яшьли күп эшләрне башкарырга туры килә. Мәктәптә укыганда ук әтисе башын салган колхоз кырларына эшкә йөри ул. Ә җиде классны тәмамлагач, бөтенләй җиң сызганып, колхоз игенчеләре сафына баса.

Бөек Ватан сугышы башлана. Имәндәй ир-егет игенчеләр сөялле кулларына сабан тоткасы урынына винтовка, автомат ала. Авылда иген үстерү хатын-кызлар һәм үсмер малайлар кулында. Алар арасында уналты яшьлек Гариф – иң өлгере, җитезе. Әнә шул өлгерлеге, җитезлеге өчен аны бригадир итеп куялар. Ләкин халыкка ипи генә түгел, җан ризыгы да кирәк. Иң авыр чакларда да һәрвакыт шат күңелле була белгән Гариф бу вазифаны да үз өстенә ала. Клуб мөдире булып, авылдашларының сагышлы күңелләренә дәртле җыр, ялкынлы шигырь сүзләре өләшә ул.

Язмыш егетне төрлечә сынавын дәвам итә. Соңрак Гарифка маляр пумаласы да тотарга туры килә.

Ниһаять, Бөек Җиңү салютлары яңгырый. Һәр буш минутында кулына китап алган, әдәбиятны, сәнгатьне бала чагыннан ук өзелеп яраткан Гарифка да парта артына утырырга вакыт җитә. Һәм егет үзенә хас омтылыш, үтә тырышлык белән белемен күтәрә башлый. Башта Арча педагогия училищесын тәмамлый, аннары бөек Володя Ульянов укыган Казан дәүләт университетының изге ишекләрен ачып керә. Монда тагын шуны өстәми булмый: уку еллары да гел тырыш хезмәт белән бергә үрелеп бара аның. Җәйге яллары үзенең яраткан һөнәре – малярлык хезмәтендә үтә, соңрак, студент чакта ук, «Совет әдәбияты» журналында эшли башлый. Шушы еллардан алып аның әдәби иҗат юлы башланып китә.

Иҗат юлы... Никадәр катлаулы юл ул. Үтә кыен да, дөньяда һичнәрсәгә алыштыргысыз ләззәтле-шатлыклы да. Бу юлда язучыны якты үрләр дә көтә һәм һич көтелмәгән борылыш-сикәлтәләренә, җаныңны ашардай уңышсызлыкларына да юлыгасың. Киң сулышлы, искиткеч эшчән Гариф Ахунов, боларның һәммәсен җиңә-җиңә, менә егерме биш ел буе үз юлын ярып, алга баруда дәвам итә. Әйтергә кирәк, бу юлда да җилкәсендә бер генә вазифа – үз иҗаты йөген генә күтәреп бармый ул. 1956 елда Әлмәткә күчеп килгәнче, Гариф студент елларында ук башлаган хезмәтен «Совет әдәбияты» журналында дәвам итә. Әлмәткә килүгә, ул үз тирәсенә яшь иҗат көчләрен туплау, аларны иҗади үстерү буенча зур эш алып бара. Аннары Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлегенә җитәкчелек итә.

Оста оештыручы, энергияле язучыны тиздән Казан үзенә чакырып ала. Анда ул башта Татарстан Язучылар союзының җаваплы сәркатибе, аннан «Казан утлары» журналының баш редакторы була, ә Татарстан язучыларының соңгы съездында республика әдипләре,



Гариф Ахунов, Рафаил Төхфәтуллин һәм Әдип Маликов. Әлмәт, 1952

Гариф Ахуновка зур ышаныч күрсәтеп, аны правление председателе итеп сайлыйлар. Гариф шулай ук РСФСР Язучылар союзы правлениесе члены да.

Әнә шулай, төп үз иҗатыннан тыш тагын берничә йөк күтәреп барган хәлдә, Гарифның алтын юбилее да килеп җиткән. Инде менә, чак кына тын алып, өзлексез хәрәкәт-омтылышларны үтеп, бу юлга күз салып алырга да вакыт.

Язучының иҗатын иң баштан аның китаплары күрсәтә. Гариф Ахунов татар һәм рус телләрендә чыккан унтугыз китап авторы хәзер. Романнар да, повестьлар да, хикәяләр дә, очерклар да, пьесалар да, әдәби тәнкыйть һәм публицистика әсәрләре дә болар. Жанрлар төрлелеге язучының киң колачы, күпкырлы таланты турында сөйләсә, «Хәзинә» романы һәм «Чикләвек төше» повесте Тукай бүләгенә лаек булу – бу әсәрләрнең халык күңеленә аеруча хуш килүен матур күрсәтә.

Күптән түгел Әлмәт якларына Свердловск киностудиясе осталары һәм бер төркем Татар дәүләт академия театры һәм бүтән театрлардан да артистлар килеп төштеләр. Болар Г. Ахуновның «Хәзинә» романы буенча нәфис фильм иҗат итәләр икән. Шулай итеп, Әлмәт җирендә туган роман буенча илебез экраннарына Әлмәт җирендә үк нәфис фильм да туа. Монысы инде бер автор өчен генә түгел, бөтен татар совет әдәбияты һәм сәнгате өчен гаять куанычлы хәл!

Кыска гына язмада язучы күп еллар буе иҗат иткән барлык әсәрләргә дә азмы-күпме тәфсилләбрәк тукталырга мөмкин түгел. Ләкин Г. Ахуновның барлык әсәрләренә дә хас төп тема, үзәк юнәлешне күреп алу кыен түгел. Язучы бөтен иҗаты белән хезмәт кешесенә дан җырлый, ә индустрия кешеләре, нефтьчеләр образларын тудыруда ае-



Наилә Ахунова, Рөстәм Төхфәтуллин һәм Әнвәр Маликов. Әлмәт, 2012

руча илһамланып иҗат итә. Бүген шуны әйтүе күңелле: олы сүз остасы Г. Ахунов иҗатындагы бу төп юнәлеш нәкъ менә Әлмәттә яшәп иҗат иткән елларыннан башланды. Язучы нефтьчеләр белән тыгыз аралашып, буровойларда кунып, булачак геройлары белән дуслашып яшәве нәтиҗәсендә башта нефтьчеләр турында бер-бер артлы очерклар, хикәяләр, «Артышлы тау буенда» дигән повесть язды. Аннары киң колачлы «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» романнарын иҗат итте. Бу ике роман арасында тагын әле «Хыялый Хәйрүш егетләре» повесте дөнья күрде. Әлмәт дәүләт драма театры Г. Ахуновның «Чулпы җыры» һәм «Утлар яна учакта» дигән драмаларын сәхнәләштерде. Болар барысы да язучының Әлмәттә никадәр бай һәм кирәкле иҗади тормыш белән яшәгәнлеген бик матур күрсәтеп торалар.

Г. Ахунов Әлмәттән киткәч тә, иҗатындагы төп юнәлешне – замандашларыбызның хезмәт белән данлыклы образларын булдыруда армый-талмый уңышлы эшли. «Чикләвек төше» повесте үзенең ялкынлы, чын сәнгатьчә иҗат ителгән коммунист Халикъ Саматов образы белән укучылар күңелен яулап ала. Бу әсәр буенча Татар дәүләт академия театры куйган спектакльне дә тамашачылар яратып кабул итәләр. «Ардуан батыр» повестенда язучы беренче бишьеллык батырларның киң планлы образларын тудыра. Андагы вакыйгалар утызынчы елларда барса да, бу әсәр гаять актуаль яңгырый. Кама гиганты төзелешендә әллә кайдан күрерлек зур хәрефләр белән «Безнең әтиләребез Магнитка төзеделәр, без КамАЗ төзибез» дип язып куелган. «Ардуан батыр» повесте әнә шул буыннар эстафетасының матур яңгырашы булып тора.

Язучының тагын бер әсәренең исемен атыйсы килә. Ул – «Ил кызы» романы. Эпик полотнолы әсәр. Монысы әле укучыга таныш түгел. Язучы аны яңарак төгәлләде. Әнә шулай Гариф Ахунов үзенең илле яшен тагын бер зур иҗат җимеше белән каршылый. Димәк, аның каләме һаман да ару-талуны белми, аның иҗат ялкыны гел дөрләп яна. Шул уңайдан бер хатирә искә төшә.

1962 елның гыйнвар айлары иде. Тымызык кына ябалак кары да төшкәләп торган гаҗәеп матур бер көнне Гариф белән икәүләп шәһәр паркына чаңгыда йөрергә чыктык. Икебез дә эш өстәле артыннан гына кузгалганга, башлар авырайган, тәннәр ватылган. Әмма кышкы салкынча һава, аяклардагы чаңгылар үзенең шифалы көчен тиз күрсәтте. Узыша-шаярыша чаңгы шуып йөрибез. Шулай да, парк әйләнә икеме-өчме тапкырлар узгач, минем сулышлар буа башлады. Чаңгы таякларыма авырлыгымны салып хәл алып торганда, Гариф выжт итеп янымнан узып китте, аның «Әйдә, калышма!» дигән шаян-көр тавышы гына колагыма эленеп калды.

Ул арада сирәк ябалак кар шактый куерып ява башлады, чаңгы эзләрен ак мамык юрган каплады.

– Кайтырга да вакыттыр? – дидем мин, Гариф яңадан әйләнеп килгәч.

– Юк әле, малай, көне нинди бит! Тәнгә сихәтләрне күбрәк алып кайтыйк, – диде Гариф һәм, яңа яуган кар өстендә яңа эз – үз эзен салып, чаңгыларын тагы да киңрәк алдыра-алдыра шуып китте.

Ул вакытлардан бирле инде менә ничә еллар үтте, ә шушы күренеш символик бер мәгънәсе белән минем күз алдыма бик еш килә дә баса: ак кар өстендә яңа эз салып, армас-талмас чаңгычы алга, гел алга омтыла, сулышлары киң, түземлек-чыдамлыгы җитәрлек чаңгычының.

Шулай яңа эзләр салып, юллар ярып, яңадан-яңа үрләр яула, каләмдәш дустыбыз!

*Рафаил Төхфәтуллин,*
язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

# Утлар-сүнми-учакта

Гариф белән кайда гына, нинди генә шартларда күрешсәң дә, аның белән тормышның нинди генә хәлләре турында сөйләшсәк тә, миңа рәхәт иде, күңелем тынычлана иде. Якындагы һәм ерактагы киләчәк көннәрем яктырак күренә иде, яшисе, эшлисе килү теләге яңара, көчәя, чын мәгънәсендә канатланып китә идем мин.

Без Әлмәттә таныштык. 1964 елда Казан консерваториясен тәмамлап, мине, яңа музыка училищесы директоры итеп, Әлмәткә җибәрделәр. Ул вакытта Әлмәттә иң зур зал нефтьчеләрнең Техника йортында иде, һәм төрле конференцияләр, концертлар, спектакльләр шушы залда үткәрелә. Ә сәхнә артындагы бер бүлмәдә Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге урнашкан. Ниндидер концерттан соңмы, әллә берәр җыелыш булды микән, мин язучылар бүлмәсенә кердем. Бүлмәдә кешеләр байтак. Арадан берсе, елмаеп килеп, миңа кулын сузды:

– Мәсгут, сине барыбыз да беләбез, мин Әлмәт язучылар оешмасы рәисе Гариф Ахунов булам, таныш булыйк, – диде.

Шуннан соң Гариф мине бүлмәдәге кешеләр белән таныштырып чыкты. Хәтерем ялгышмаса, анда ул көнне Әдип Маликов, Гамил Афзал, Сәет Кальметов, Юныс Әминов, Саҗидә Сөләйманова, Рафаил Төхфәтуллин, Клара Булатова, Энҗе Мөэминова, Шамил Бикчурин, Мәхмүт Хәсәнов һәм башка тагын кемнәрдер бар иде. Танышып чыккач, Гариф мине үз бүлмәсенә алып керде, сөйләшә-сөйләшә, эш урыны белән таныштырды. Стена буена урнашкан пыяла шкафларда Әлмәт язучыларының китаплары тезеп куелган. Күземә таныш китап чалынды – ул «Яшьлек яме» иде. Мин аны студент елларымда бер-ике мәртәбә бик яратып укып чыккан идем. Алып карарга рөхсәт сорадым. Кулыма тоттым да, Гарифка карадым: алдымда шушы, мин яраткан китапның авторы Гариф Ахунов елмаеп тора иде. Үзенең китабы белән мине әсир иткән язучы янәшәсендә торуыма ышаныр-ышанмас, дулкынланып, сөенеп куйдым… Безнең дуслык шулай башланды.

Шуннан соң, күп тә үтмәде, мине Әлмәт театры җитәкчеләре «Утлар яна учакта» дигән спектакльгә музыка язарга чакырдылар. Пьесаны Гариф Ахунов язган икән. Бу инде Гариф белән тагын да якынрак аралашу дигән сүз иде.

Спектакль нефтьчеләр тормышына багышланган. Мин төрле җырларга, биюләргә музыка язарга тиеш идем. Җырларның шигырьләрен Саҗидә Сөләйманова язган. Режиссер сораган музыкаль бизәлешләр нотага салынгач, Гариф Ахунов, Саҗидә Сөләйманова, балетмейстер Марат Камбулатов, режиссер Габдулла абый Йосыпов һәм мин, театрга җыелып, җыр-көйләр белән таныштык. Хуплап каршы алдылар һәм спектакльгә тагын да музыка өстәргә кирәк дигән фикергә килделәр. Спектакльдә төп рольләрне бик талантлы яшь актриса Луиза Солтанова (Гүзәлия) һәм җырга оста, моңлы тавышлы артист Рафаил Сабиров (Сәлахи) башкарачак иде.

Премьера шаулап үтте… Ул чакта Гариф шатлыгыннан очынып йөрде, йөзеннән елмаю китмәде. Әлбәттә, һәммәбез сөенештек. Әле бүген дә шул «Утлар яна учакта» спектакленә язылган «Нефтьчеләр маршы», «Гүзәлия җыры», «Сәлахи җыры» («Йөрәк

җыры» дип тә әйтәләр) яңгыраганда, күз алдыма һәрвакыт, елмаеп, шатланып, Гариф килеп баса.

...Көннәрдән бер көнне телефон чылтырый. Гариф чакыра. Кердем Язучылар берлегенә.

– Менә, Имаш, бер шигырь яздым, шуны көйгә салып булмасмы? Укып чык әле,– ди Гариф.

Җир шарында тынычлыкны саклау өчен сугышка каршы төрле чаралар үткәрелгән чак. Гарифның бу әсәре шушы темага багышланган булып чыкты. «Аурупада калды шагыйрьләр» дип исемләнгән шигырь. Ул шигырь мине тетрәндерде, һәм мин: «Тешем үтсә, тырышып карыйм»,– дип, Гарифның бу иҗат җимешен алып киттем. Күпмедер вакытлар уйланып, хисләнеп, пианино янында моңланып йөри торгач, бер җыр сыманрак әйбер оеша башлады. Авыр туды бу җыр. Чөнки темасы да, шигырь авторы Гариф дустым да зур җаваплылык йөклиләр иде миңа.

Көй шактый түгәрәкләнгәч, бер җай табып, мин аны Гарифка җырлап күрсәттем. Ул сөенеп рәхмәт әйтте һәм җырны халыкка чыгарырга фатиха бирде. Менә байтак еллар инде мин аны сәхнәдән җырлап йөрим, репертуарымнан төшермим, тыңлаучылар һәрвакыт алкышлап каршы алалар. Күрәсең, Гарифның йөрәгеннән кайнап чыккан сүзләр, хисләр халыкның күңел түрендә яткан уй-фикерләрен, нечкә хисләрен кузгатмый калмыйдыр. Гариф белән бергәләп төрле очрашуларга барганда да, мин бу җырны җырламый калмый идем, чөнки Гариф шуны тели һәм соңыннан миңа гел рәхмәт әйтә иде. Бу җыр минем Гариф белән иҗади дуслыгымның шаһиты булып, уй-хисләребезнең уртак җимеше булып яши.



Гариф Ахунов укыган Арча районы Казанбаш авылы мәктәбендә очрашу. 2005

1981 елда Татар дәүләт драма һәм комедия театры Гариф Ахуновның «Хәзинә» романы буенча «Кошның да үз оясы була» дигән спектакль әзерләде. Спектакльнең музыкаль бизәлешен башкаруны, Гарифның киңәше буенча, миңа тапшырдылар. Җырларга шигырьләрне әлеге роман буенча пьеса эшләгән шагыйрь Мансур Шиһапов язды. Режиссерлар Фәрит Хәбибуллин белән Мансур Шиһапов иде. Беренче премьера көнне, беренче тәнәфестә үк, минем янга Әлфия Афзалова йөгереп килде дә: «Иртәгә үк миңа менә әле яңа гына яңгыраган җырның сүзләрен дә, көен дә язып бир, Имаш! Күңелне актарып чыкты бу җырыгыз», – диде. Шунда ук Гариф һәм башка таныш тамашачылар, шул җыр өчен рәхмәт әйтеп, кулымны кыстылар. Спектакльдә Мөнәвәрә ролен уйнаучы Ләлә Миңнуллина җырлаган «Туй күлмәге» дигән моңлы җыр иде ул. Аны Әлфия Афзалова да, башка җырчылар да концертларында еш башкардылар. Халык күңеленә хуш килгән җыр тууга үзенең романы сәбәпче булуына Гариф бик сөенде һәм, җырны кайда гына ишетсә дә, «Безнең җырны яраттылар бит, Имаш!» – дип, минем белән шатлыгын уртаклаша иде.

Гариф белән театр дөньясындагы иҗади дуслыгыбыз яңадан Әлмәт театрында дәвам итте. 1983 елда анда Константин Фединның «Ошибка Анны» дигән пьесасын Гариф Ахуновның ирекле тәрҗемәсендә «Мәхәббәт хакына» дигән исем белән сәхнәгә чыгардылар. Гариф белән режиссер Зәкия Туешева музыка язарга мине чакырдылар. Бу спектакльгә җыр сүзләрен Гариф үзе язды. Татарстан радиосыннан еш кына Әлфия Афзалова башкаруында яңгырый торган «Кемгә салыйм башны таңнарда» дигән җыр шушы спектакльдән.



Казанбаш авылы мәктәбендә Гариф Ахунов юбилеена багышланган бәйрәм. Сулдан уңга: Мәсгут Имашев, Шәһидә Максудова, Наилә Ахунова, Борис Вайнер, Факил Сафин. 2005



Дуслар: Нургали Миңнеханов белән Гариф Ахунов. Казан. 1978

...Минем бер юбилеем якынлашып килгән көннәрдә туган ягымнан – Пермь өлкәсенең Барда районыннан – телевидение кешеләре килеп төште. «Мәсгут абый, сезнең турыда район телевидениесе тапшыру эшли. Казандагы дусларыгыз белән сөйләшеп, аларны төшереп алырга иде ниятебез», – диделәр. Күп иҗади дусларым белән рәттән, мин, әлбәттә, Гариф Ахуновны да атадым. Атадым да, үзем кыенсындым, чөнки аның иҗат өчен бик кадерләп файдалана торган вакытын минем турыда сөйләүгә сарыф итәчәген уйлап алдым. Ләкин телефоннан чылтыраткач, Гариф бик теләп риза булган, һәм... Барда телевидениесендә аның, мине зурлап, искиткеч матур сүзләр белән, җылы хисләр белән сөйләгән истәлекләре бүген дә сакланадыр.

Шул көннәрдән соң бераз вакыт үткәч, Гариф үзе миңа чылтырата: «Карале, Мәсгут, нишләп синең хакта Бардада гына белергә тиешләр, син Казанда яшәп иҗат итәсең, Татарстан да күбрәк белсен синең кем икәнлегеңне, мин синең турыда очерк язарга булдым, күрешик әле, сөйләшик», – ди. Берничә мәртәбә күрештек.

Аларга килгән саен, Гариф та, Гөлшәһидә ханым да үтә дә җылы, кунакчыл, якты йөз белән каршы алалар, чәйсез җибәрмиләр. Гариф, ни генә эшләсә дә, иҗат итсә дә, өй эшләрендә дә Гөлшәһидә ханымның хуплавын көтә һәм, һәрвакыт аның киңәшенә мохтаҗ икәнлеген сиздереп, соңыннан: «Рәхмәт, әнисе!» – дип сөекле хатынына рәхмәт әйтергә онытмый иде. Бер килүемдә үзе ясаган рәсемнәрен күрсәтте Гариф. Ул үзенең туган авылын рәсемгә төшереп алуына бик сөенә иде. Гомумән, Гариф яратып, сокланып, ялкынланып сөйли иде. Бер яктан, ул туган ягы белән, икенче яктан, балаларының – Рәшит белән Наиләнең уңышларына сөенеп, алар белән горурланып яшәде. Бәхетле кеше иде Гариф һәм беркайчан да беркемнән дә моны яшермәде. Киресенчә, булган шатлыклары-сөенечләрен башкалар белән дә уртаклашырга, башкаларның да күңелен күтәрергә тырыша иде.

Шул арада Гариф дустым, миннән бер олы шәхес ясап, мактап, минем хезмәтемә, иҗатыма бик олы бәя биреп, мәкаләсен гәзиттә дә бастырды, һәм, үзенең атаклы кешеләребез турында язган очерклары арасына мине дә кертеп, китап чыгарды. Минем өчен бик зур мәртәбә бу, ул китап безнең гаиләдә Гарифның якты истәлеге булып саклана. Гарифның искиткеч җор сүзле, оста тамада булуын да әйтми китү мөмкин түгел. Ул еш кына минем хакта да бер мәзәкне сөйләргә ярата иде. Ә мәзәк «Утлар яна учакта» спектакленең премьерасыннан соң Гарифлар өендә оештырылган банкетта булган бер хәлгә бәйле иде.

Ул банкетта мин гомеремдә беренче мәртәбә «урындыкларсыз кунак»та булдым. Бәйрәмдә катнашасы дус-ишләрнең чамадан тыш күп буласын абайлап, хуҗалар өстәлләрне стена буена (бигрәк тә почмакларга) терәп куйганнар да, урындыкларны җыеп алганнар – барыбыз да аяк өстендә. Бары тик бер кечкенә бүлмәдә арыганда ял итәргә куелган берничә урындык. Өстәлләрдәге сый-нигъмәтнең исәбе-хисабы юк, кайсы өстәлне ошатасың, шунда барып авыз ит. Ә Гариф белән Гөлшәһидә ханым, бүлмәләрнең әле берсенә, әле икенчесенә кереп, һәркемне аерым-аерым кыстап-сыйлап йөриләр...

Мин бер почмактарак, шифоньер янында урын алып бастым, янымда – артистлар. Беренче рюмкамны бушаттым да, аны өстәлгә илтеп куйдым. Минем кулым буш икәнне Гариф күреп алган. Йөгереп килеп, миңа икенче рюмка тутырып тоттырды. Ул янымнан киткәч, мин рюмканы тулы килеш, сузылып, шифоньер өстенә куйдым. Бераздан тагын Гариф килеп җитте... Кичә дәвамында шушындый хәл берничә мәртәбә кабатланды. Иртәгесен Гариф телефоннан чылтыратты:

– Карале, Имаш, кичә син бездә шифоньер тирәсендәрәк йөрдең, күрмәдеңме, кем шифоньер өстенә рюмкалар тезеп куйды икән? – ди.

Мин әйтәм:

– Мин тездем, – дим.

Рәхәтләнеп көлә Гариф. Соңыннан да, мине күргән саен: «Шаккатырдың бит, малай», – дип, шушы очракны искә төшереп, күп еллар көлеп йөрде. Менә бүген дә шул турыда кызык итеп сөйләп алды.

...Гариф белән озак еллар дәвам иткән иҗади дуслыгыбызның соңгы җимеше – аның инициативасы белән, аның сүзләренә язылган «Туган авылым – Казанбашым» дигән җыр. Бу җырны без Арча районы Казанбаш авылы колхозының юбилее уңаеннан яздык һәм аны шул тантаналы бәйрәм көннәрендә авыл клубында хатыным Фатыйма белән халыкка җырлап та күрсәттек.

Ә мин концерт вакытында да, башланганчы да, тәнәфестә дә авыл кешеләренең Гарифны танып (ул шушы авылда мәктәптә укыган икән), аны ихтирам итеп, зурлап берәм-берәм килеп исәнләшүләрен, хәл-әхвәл сорашуларын сокланып күзәттем: һәм үземнең шушындый ачык күңелле, игътибарлы, шәфкатьле, кешеләрне сөендереп яшәүче Гариф һәм Гөлшәһидә ханым белән дус булуыма сөендем.

*Мәсгут Имашев,*
композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

# Путник
## *Гариф Ахунов*

Совсем юный путник спешит с маленьким узелком за плечами в большую человеческую жизнь. Он еще не знает, что в его узелке лежит «клад».

А пока весенний воздух арской дороги несет запахи сырости, испарений земли, прошлогодних трав и откуда-то тянет дымом горящей соломы.

Вот и прошел он весенний лес своих первых юношеских рассказов, а в поле аксакалы уже по пояс взрастили, как хлеб, свои яркие произведения.

Миновала пора сенокоса. Отгремели сабантуи... Щемящая непроходящая тоска по родному дому заставляла его вновь и вновь мысленно возвращаться на свою родину.

Что вынашивало его сердце? Как готовился он к первому серьезному экзамену на духовную зрелость и мастерство?

Пришла пора развязать узелок.

Долго он сидел молча, вспоминая детство, как, выбегая вместе с друзьями под потоки дождя, кричал, захлебываясь от восторга, заклиная: «Дождик, дождик, перестань...».



Г. Тукай һәйкәле янында Шигърият бәйрәме. Сулдан уңга: Әхсән Баян, Гариф Ахунов, Фәрит Яхин, Лена Шагыйрьҗан, Ольга Левадная. 1997

И вдруг из-за спины появилась Мунавара со сползшей на плечи косынкой, внимательно всматриваясь в его озаренное вдохновением лицо, как бы спрашивая: «Долго ли мне сидеть у окна, подставив руки под нежаркие лучи солнца? Душа моя волнуется без моего любимого Арслана…».

Он-то знал, что в глубине еще теплого пепла в угасающем очаге вспыхивает жаркая искра, и подуй мощный и свежий ветер – тотчас превратится та искра в большое и глубокое пламя; согреет оно не только двоих, но всех, кто близко прильнет к нему, – щедрое, радостное, счастливое.

Счастье… Говорят, иногда несчастье – лишь его предвестник…

С болью в сердце отвечает он Мунаваре: «Вы – два путника на разных берегах широкой, неистовой реки. Вы так близки и так далеки друг от друга. Каждый в этой жизни пытается найти свой клад. Одним это удается, другие об этом даже не подозревают, а третьи проходят мимо… Поспеши домой, тебя ждут твои дети!»

Впереди еще долгий творческий путь к тому, самому главному, слову, которое скажет он своему народу. И не ошибся автор, говоря, что «Дочь Волги» написать мог только он, потому что думал о романе и днем и ночью, переживал его как личную судьбу.

Не спал и Габбас-мулла, сон бежал от него. Он прислушивался, не раздастся ли в доме долгожданный звук, голос только что появившейся на свет жизни – Нурии…

И раскроется нам изнутри, через неповторимый образ «Дочери Волги», жизнь татарского народа начала XIX века.

Поднялся земляк Тукая и ушел неслышно, оставляя нам ответы на главные вопросы своего времени.

*Ольга Левадная*
*2005*



Наилә Ахунованы ТР Язучылар берлегенә кабул итү көне. Сулдан уңга: Мәдинә Маликова, Нәҗибә Сафина, Наилә Ахунова, Гариф Ахунов, Әхсән Баян, Роза Кожевникова, Мөдәррис Әгъләмов, Ольга Левадная. 1997, апрель

# Большая-лыжня-писателя

Иногда в жизни самое незначительное событие становится событием огромной важности.

Был январь 1962 года. На улице тихо и спокойно, блистая хлопьями, шел снег. Мы с Гарифом Ахуновым вышли в городской парк на прогулку. На снег ложилась ровная лыжня. Мы оба перед этим долго и кропотливо трудились за письменным столом. Естественно, после этого голова стала тяжелой, а уставшее тело выло, требуя отдыха. Зимний воздух и лыжи быстро сделали свое дело. Мы вскоре повеселели. Каждая новая минута приносила нам бодрость духа и свежесть ума. И я даже не заметил, когда мы пошли по четвертому кругу. Вскоре мне стало тяжело дышать, и я через десяток метров остановился совсем. В это время Гариф на большой скорости проскочил мимо меня.

– Айда, Рафаил, не отставай, – кричал он.

А хлопья снега становились большими и более тяжелыми, наша лыжня спряталась под белым одеялом. Гариф, сделав новый круг, остановился.

– Пора возвращаться, Гариф, – ответил я ему.

– Нет уж, малай, день-то какой чудесный! Надо побольше набрать этого удивительного целебного воздуха, – возразил он и снова широкими плавными шагами, проложив на свежем снегу новую лыжню, пошел вперед.

С той поры много воды утекло, много лет прошло, а эта символическая картина со всей ясностью и величием часто вспоминается: на мягком пушистом снегу, оставляя новую лыжню, неустанный лыжник стремительно идет все дальше и дальше. Его дыхание ровное, глубокое. Выдержки и выносливости у лыжника, кажется, хватит на многие поколения. Да, оставить в литературе свой след может лишь тот, кто имеет неисчерпаемую выдержку, огромную выносливость и самобытный неповторимый талант художника. Эти качества к человеку приходят, в первую очередь, в результате каждодневного кропотливого труда. А Гариф Ахунов с ранних лет осознал цену трудового пота. Он сразу же после окончания семилетки начал свою трудовую деятельность. В годы Великой Отечественной войны этого расторопного и старательного юношу односельчане назначили бригадиром полеводческой бригады. Позже ему пришлось работать заведующим клубом.

Когда же отгремели орудия войны, Гариф решил учиться. Сначала окончил Арское педагогическое училище, затем историко-филологический факультет Казанского университета. К этому необходимо добавить: Гариф учился и работал. Во время летних каникул молодой человек шел на стройки города, украшал новые квартиры для горожан. Трудолюбивого, талантливого парня заметили в журнале «Совет әдәбияты» и пригласили на работу. Вот тогда-то и начался большой творческий путь писателя. Этот путь оказался тернистым. Были моменты, которые требовали глубокого дыхания, неимоверной старательности. Но упорно преодолевал Гариф неровности этого пути, и всегда шел дальше. Мне кажется, он, как тогда, в парке, не признавал усталости. Я в этом глубоко убедился в пору нашей с ним совместной работы в Альметьевске.




1958–1968 елларда Гариф Ахунов яшәгән Радищев урамындагы 20 нче йортка мемориаль такта куелу. Әлмәт. 2006, октябрь



Теперь, когда пришел его юбилей, можно оглянуться и посмотреть вокруг. Что же сделано? Труд писателя, прежде всего, в его произведениях. А Гариф Ахунов – автор 19 книг, выпущенных на татарском и русском языках. Среди них несколько романов, повестей, рассказов, очерков, пьес и критико-публицистических произведений. Их читают и хорошо знают. Гариф Ахунов известен всесоюзному читателю так же хорошо, как и татарскому. За роман «Клад» и повесть «Ядро ореха» писатель удостоен премии имени Габдуллы Тукая, а это еще раз доказывает, что произведения Гарифа Ахунова близки народному духу.

Вот таким трудом наш Гариф Ахунов отмечает свое пятидесятилетие. Становится ясным, что творчество таланта не имеет предела. Руководитель Татарской писательской организации, депутат Верховного Совета СССР Гариф Ахунзянович Ахунов выполняет трудную и ответственнейшую работу. Несмотря на занятость, его перо выводит все новые и новые произведения. Наш знакомый лыжник все еще в пути. Он прокладывает все новую и новую лыжню.

*Рафаил Тухватуллин,*
«Знамя труда». – 1975. – 17 сентября

# Друг-нефтяников

Гариф Ахунов пришел в литературу с молодежной темой. Его первая повесть «Краса юности» была встречена читателями с большим интересом. Уже тогда стало ясно, что в татарской литературе появился художник с большим талантом. Однако, известным прозаиком Г. Ахунов стал в нашем городе. В Альметьевске наметился новый поворот в его творчестве. Здесь он нашел будущих героев произведений. Гариф Ахунов писал очерки о трудовых буднях нефтяников в столице нефтяной Татарии – Альметьевске. И вот появился новый роман «Клад» – роман о становлении нефтяной промышленности в республике.

Книга подкупает жизненной правдой, горячей заинтересованностью в судьбах героев, знанием характера современного рабочего, влюбленностью автора в руд нефтяников. Герои Г. Ахунова разные по судьбам и характерам люди, но всех их объединяет основное отношение к труду, как главному в жизни человека. Сейчас это самый популярный роман среди молодежи.

Второй роман Ахунова «Хозяева» также посвящен жизни нефтяников Татарии, т.е. он как бы продолжает начатый разговор в романе «Клад».

Здесь мы вновь встречаемся с героями – Арсланом, Файрузой, мастером Дияровым. Еще две повести Ахунова «Парни – мечтатели Хайруша» и «Куда несут крылья» затрагивают нефтяную тему.

Г. Ахуновым создано около двадцати книг. Яркие произведения талантливого татарского писателя пользуются большим успехом у читателей. Они по праву получили заслуженное признание поклонников литературы.

*Д. Маликов,*
заведующий городской библиотекой № 2 г. Альметьевска
«Знамя труда». – 1975. – 17 сентября

# Язучы-юбилее


Шәһәр җәмәгатьчелеге, әдәбият сөючеләр Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, СССР Югары Советы депутаты, күренекле совет язучысы Гариф Ахуновның 50 еллыгын зурлап билгеләп үттеләр.

Әлмәтлеләр бик хаклы рәвештә Гариф Ахуновны үз якташлары итеп саныйлар. Биредә ул озак еллар яшәгән, язучы буларак формалашкан. Бораулаучылар, нефть чыгаручылар белән бергәләп ул йөзләрчә чакрым юл үткән, җир асты хәзинәләренә илтүче авыр юллар таныш аңа. Аның иң яхшы әсәрләре дә биредә – девонны буйсындыручылар арасында язылган. Шуңа күрә язучының юбилеена йөзләрчә әлмәтлеләр – нефтьчеләр, бораулаучылар, төзүчеләр килгән иде. Алар юбилярга үзләренең эчкерсез рәхмәтләрен һәм теләкләрен белдерделәр.

Күренекле совет язучысы, егермеләп китап авторы Гариф Ахуновның иҗади эшчәнлегенә багышланган әдәби музыкаль кичәне шәһәр партия комитетының икенче секретаре Ә. К. Гыйматдинов ачты. Ул язучының күп милләтле совет әдәбиятына керткән зур өлеше турында сөйләде. Аның китапларын рус, украин, азәрбайҗан һәм башка телләрдә укыйлар. Совет әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән Татарстан Язучылар союзы правлениесе рәисе Гариф Ахуновны СССР Югары Советы Президиумы Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде. Бу хәбәрне залдагылар кул чабулар белән каршыладылар.



Гариф Ахуновның 50 еллык юбилеенда. Әлмәт, 1975



ТАССР КУЛЬТУРА МИНИСТРЛЫГЫ

МИНЗӘЛӘ

татар дәүләт драма театры

48 нче сезон (1935—1982)

ПРОГРАММА

ГАРИФ АХУНОВ

РӘШИТ АХУНОВ

ИКӘҮДӘН ИКӘҮ ГЕНӘ

Моңсу комедия 2 бүлектә

Режиссер— ЛИНАР САДРИЕВ

Художник-- СӘЙДӘШ МӨХӘММӘТШИН

Композитор— РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе ХӨСНУЛ ВӘЛИУЛЛИН

Минзәлә. 1982 ел.

Шәһәр партия комитеты бюросы, хезмәт ияләре депутатларының шәһәр һәм район Советлары башкарма комитетлары исеменнән иптәш Гыйматдинов юбилярга тәбрикләү адресы тапшырды.

Республиканың күп меңле нефтьчеләр армиясе исеменнән чыгыш ясаучы «Татнефть» берләшмәсе начальнигы урынбасары Ү.Г. Саттаров, язучыны юбилее белән котлап, аңа тәбрикләү адресы тапшырды. «Хәзинә» романы авторының нефтьчеләргә якын торуын тагын бер кат исбатлап, юбилярга бораулау вышкасы макеты бүләк итте.

Юбилярга «Татнефть» берләшмәсе, нефть, газ һәм химия промышленносте эшчеләре профсоюзы өлкә комитетының Почёт грамотасы тапшырылды.

Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге җитәкчесе Әдип Маликов республиканың нефть ягы әдипләре исеменнән тәбрикләү адресы тапшырды, Әлмәт язучылары иҗатына даими игътибары өчен эчкерсез рәхмәтен белдерде.

Язучыны Лениногорск шәһәре, «Татнефтестрой» берләшмәсе, «Дуслык» нефть үткәргече һәм Әлмәт драма театры, Татарстан Рәссамнар берлеге, бораулау эшләре идарәсе вәкилләре, укытучылар тәбрикләде. Ә Ленин орденлы «Әлмәтнефть» идарәсе коллективы Г. Ахуновны идарәнең почётлы нефтьчесе итеп кабул итте, исемен коллективның Почёт китабына кертте.

– Барлык бу бүләкләрне, минем адреска әйтелгән җылы сүзләрне мин киләчәккә аванс буларак кабул итәм, – диде Гарифҗан Ахунҗанович. – Кырыс һәм назлы мөгамәлә миңа рухи көч өстәгән өчен, эшче сыйныфына язучы рәхмәтемне белдерәм!

Кичәнең икенче бүлегендә концерт булды, язучының яраткан җырлары яңгырады. Шәһәр һәм район үзешчәннәре аның пьесаларыннан һәм романнарыннан өзекләр укыдылар.

Фойеда Гариф Ахунов әсәрләреннән китап күргәзмәсе оештырылган иде. Юбиляр-язучы һәм шулай ук Әлмәт язучылары килгән тамашачыларга үз китапларына автографлар язып бирделәр.

*К. Волгина*

«Хезмәт байрагы». – 1975. – 23 сентябрь

# «Хыялый-Хәйрүш-егетләре»

Гаҗәеп бер кырыс шигъриятькә ия ул нефтьче оператор хезмәте. Кәккүкле урман аланнарында, иген исе аңкыган кырларда чәчәкле сукмаклар буйлап атлый оператор. Җир маен чыгаруда аңа акыллы автоматлар, куәтле насослар ярдәм итә. Шигърияте аның әнә шулардан тора. Ләкин без, кырыс шигърият, дидек. Әйе, кырыслыгы да җитәрлек. Кояшлы җәйдән соң көзге былчыраклары, буранлы кышлары, каты ташулары җитә. Монда инде оператор скважиналарга таба чәчәкле сукмаклар буйлап түгел, юлны үзе ярып атлый. Гел автомат кнопкаларга басып кына да чыгармыйлар нефтьне. Кулга бик еш көрәген, ломын, балтасын да алырга туры килә. Ул арада һич көтелмәгән аварияләр килеп чыга да, оператор, майлы җиңе белән маңгай тирен сөртәсөртә, шунда көнне төнгә ялгап җибәрә.

Гариф Ахуновның «Хыялый Хәйрүш егетләре» дигән яңа повесте әнә шул кырыс шигъриятле хезмәт кешеләре турында сөйли. Повесть авторның шулай ук нефтьчеләргә багышланган берничә хикәясе һәм очерклары белән бергә күптән түгел аерым китап булып басылып чыкты.

Китап тышлыктан башлана. Ә тышлыкта менә мондый күренеш. Аланда туй мәҗлесе гөрли. Яшь кияүнең кулында яшь агач үсентесе. Ак күлмәкле яшь кәләш тә уйчан гына шунда бөгелгән. Бик үк гадәти хәл түгел, шулаймы? Туй мәҗлесе аланда, ә кияү белән кыз туйда ук агач утыртмакчылар.

Әйе, гадәти хәл түгел, ләкин бик матур күренеш бу. Повестьны укый башлагач ук шуны беләбез: әлеге шигъриятле хезмәт кешеләренең – Хыялый Хәйрүш җитәкчелегендәге нефть чыгаручылар бригадасының уртак тантанасы, уртак шатлыгы икән бу туй. Кияүне – Җәүдәт Галиәхмәтовны бригада егетләре үзләре нефть институтына укырга җибәргәннәр, аңа дүрт ел буе акчалата ярдәм итеп торганнар. Инде менә Җәүдәт дипломлы инженер булып кайткан, өйләнеп, өр-яңа тормыш башлап җибәрмәкче. Кәләш тә шушы ук бригадада өйрәнчеклектән баш оператор булып үскән Гүзәлия икән. Үз араларындагы ике яшь йөрәкнең тормышларындагы бу зур вакыйгадан коллектив ничек инде читтә калсын!

Хыялга бай бригадирның егетләре дә бу яктан җитәкчеләреннән калышмыйлар. Туй мәҗлесен тар бүлмәдә түгел, аланда, карт имән төбендә үткәрергә булалар.

– Уйлаштык-уйлаштык та, – ди бригадир, – шундый фикергә килдек... Яшьләр бәхетләрен тустаганнан башламасыннар, көрәктән башласыннар. Шуңа күрә, дуслар, сез бүгенге туегыз хөрмәтенә, Җәүдәтнең институтны тәмамлап кайту истәлеге итеп, безнең аланга нәни бер имән утыртыгыз.

Дус яши, матур яши бу бердәм, эшчән һәм шат күңелле коллектив. Инде үз инженерлары Җәүдәт тә кайткач, нефть чыгаруны автоматлаштыруда яңа зур планнар, хыяллар белән янып яши.

Бригаданың эше белән, Җәүдәтнең язмышы белән коллективтан тыш тагын ике кеше кызыксына: нефтьче пенсионер Талип карт һәм промыселның хәвефсезлек инженеры Гыймран Нуришанов. Талип карт Җәүдәт язмышында, бригада эшендә үзе гомерен ба-




гышлаган зур эшнең матур дәвамын күрсә, Гыймранның бу кызыксынуы бүтән нигезгә корылган. Милекчелек тәмам канына сеңгән бу хәйләкәр кеше, яшь инженерга төрлечә «яхшылык» эшләгән булып, аны үзенең эгоистик максатлары өчен файдаланырга тели. Гыймранның исәбе Җәүдәтне, бригададан аерып, промыселда зуррак эшкә урнаштырырга һәм аның канаты астында пенсиягә кадәр үз урынын нығытып куярга. Шул ук вакытта, яшь инженерның талантыннан файдаланып, төрле «яңалык тәкъдимнәре» исәбенә кесәсен дә калынайтырга тели ул. Шуларга өстәп, Талип картка күптәннән килгән яшерен үчен дә кайтарасы бар.

Шушы нигездә повестьның төп конфликты башлана. Югарыдан күренгәнчә, конфликтның кара өлешен Гыймран алып килә. Гыймранның кире образ икәнен без аның әсәргә беренче килеп керүеннән үк сизеп алабыз. Детальләргә игътибар итик. «Дәү битле бу агай» үзенә оператор егетләр сузган портсигардан «бер папиросны кулында әвәләп авызына капты, икенчесен, кара көнгә дип, колак артына кыстырды». Егетләр Гыймраннан үзләре бик яраткан карт имәннең тарихын сөйләүне сорыйлар. Шул чак «мин аның күзләрендә әллә нинди усал очкын елтырап китүен күрдем. Ләкин очкын шундук сүнде, йөнтәс кашлар аның күзен янә беркәп куйдылар».

Күренә ки, бу детальләрдән хәвефсезлек инженеры Гыймранның шактый хәвефле кеше икәнлеген сизенү кыен түгел. Нәкъ әнә шулай кыен булмаганга күрә, безнең автор белән бәхәсләшәсе килә дә. Ни өчен дигәндә, күзгә бәрелеп торган начар кешенең начар эшләрен фаш итү әллә ни кыен түгел бит! Шуңа күрә әсәрнең эчке пружинасы йомшара, вакыйганың гыйбрәт көче кими һәм, барыннан да бигрәк, образлар укучыны ышандырмый башлый.

Чыннан да, шушы дус һәм нык коллектив бу хәвефле хәвефсезлек инженерының, әйтелгәнчә, күренеп торган начар кешенең, үз араларына килеп тыкшынуына ничек юл куйды соң әле? Коллективның горурлыгы һәм өмете булган Җәүдәтне бу кеше ничек бик тиз үзенең мәкерле ятьмәсенә эләктерә алды?!

Кире образны бу рәвештә кара буяулар белән сурәтләү аркасында әсәрнең ышандыру һәм гыйбрәт көче бик нык кимүе турында бездә күптәннән сөйләнеп киленә. Күрәсең, әдәбиятка тормышыбыз үзе куйган таләптер бу. Күзгә күренеп торган мещан, бюрократ, карьерист ишеләрне җәмәгатьчелек болай да бик тиз фаш итә хәзер. Ә менә андыйларның бик оста төренгән матур маскаларын ертып ыргыту шактый кыен нәрсә. Халкыбыз бу катлаулы көрәштә әдәбияттан зур ярдәм көтә.

Г. Ахуновның яңа повесте турындагы сүзне матур гына башлап та, авторның кире образ тудырудагы кимчелегенә китереп терәгәч, «бу повесть уңышсыз икән» дигән фикер тумасын. Повесть, гомумән, матур тәэсир калдыра. Бригада егетләренең, кызларының көр күңелле дуслыгына, хыял, шатлык һәм армас омтылыш белән матур итеп яши һәм эшли белүләренә сокланып укыйсың әсәрне. Ә инде Гыймран образының кимчелегенә мин бигрәк тә шуның өчен басым ясап тукталдым: кире образны болай чекерәеп торган кара буяулар белән сурәтләү – безнең гомуми кимчелегебез.

*Рафаил Төхфәтуллин*
«Социалистик Татарстан». – 1966. – 9 гыйнвар

# Әлмәт–Казан–Уфа

Әлмәттә эшләүче татар язучылары, шагыйрьләре безнекеләрне бик җылы каршы алды. Әлмәт бүлекчәсе күптән түгел генә ачылса да, монда үзара дус, талантлы язучылар коллективы тупланып өлгергән икән. Менә теленнән дә, кулыннан да килә торган Гариф Ахунов. Зур энергияле бу әдип һәм оештыручы кайчан йоклый икән? Кичтән, кунаклар йокларга яткан- да, уяу кала һәм таңнан аяк өстендә була. Йөзендә ичмасам бер тамчы йончыганлык билгесе күренми! Аның «Хәзинә» романы белән бөтенсоюз укучысы таныш. Хәзер бу



Гариф Ахунов кызы Наиләнең туенда башкорт киемендә. Казан. 1979, 22 сентябрь



Башкортстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре. Гариф Ахунов кияү белән кәләшне котлый. Уфа. 1988

язучы шул ук нефтьчеләр тормышыннан «Хуҗалар» исемле яңа роман тәмамлау алдында тора икән. Ә шул арада пьесалар, Татарстан нефтьчеләре турында башка әсәрләр дә язган. Җәй көне ул, Башкортстан Язучылар союзы идарәсенең чакыруы буенча, яшь язучыларның республика семинарында катнашты. Яшьләрнең әсәрләрен укып тикшерүдә аның киңәшләре төпле һәм файдалы булды.

*Зөбәрҗәт Купаева-Исәнголова*
«Кызыл таң».– 1967.– 12 ноябрь

# Нефтьчеләр-турында-фильм

Свердловск киностудиясе күренекле татар язучысы Г. Ахуновның «Хәзинә» романы буенча нәфис фильм экранлаштыра башлады. Фильм киң экранлы, төсле булачак.

Сценарий авторы – В. Потоцкий, режиссёры – О. Воронцов, оператор – А. Лесников.

Төп рольләрдә – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актерлары Г. Шамуков, В. Минкина, Д. Ильясов, Р. Шәрәфиев, шулай ук Мәскәү һәм Нальчик театрлары артистлары.

Хәзер Урал кинематографистлары Әлмәт һәм Лениногорск промыселларында фоторәсемнәр ясыйлар. Бу эшне алар августта төгәлләргә уйлыйлар.

Татарстан нефтьчеләре эше һәм тормышы турында яңа фильм киләсе елда кинотеатр экраннарында чыгачак.

*М. Габдрахманов*
«Хезмәт байрагы». – 1975. – 8 август




Гариф Ахуновка автограф белән бүләк ителгән китаплар. Арча әдәбият һәм сәнгать музее фондларыннан

# Хөрмәтле-Гариф-Ахунҗанович!

Әлмәттә яшәгән елларда Сез газетабызның тугрылыклы дусты һәм киңәшчесе идегез. Сезнең нефтьчеләр турында язган күп кенә хикәяләрегез, очеркларыгыз беренче тапкыр «Хезмәт байрагы» газетасында басылдылар. Сез шулай ук Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеген оештыруда да, рус әдәбиятчылары берләшмәсенең эшен яхшыртуда да зур активлык күрсәттегез. Сезнең уңдырышлы нефть мәйданнарында язылган әсәрләрегез үзләренең тормышчан булулары белән безне шатландыралар.

Бүген без, «Хезмәт байрагы» газетасының редколлегиясе, Сезне 50 яшь тулган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз! Сезгә яңа биеклекләр, сәламәтлек һәм олы бәхет телибез!

*«Хезмәт байрагы» газетасы редколлегиясе*
«Хезмәт байрагы».– 1975.– 17 сентябрь



Гариф Ахунов. 1973

# Нефтьчеләрдә-кунакта



Гариф Ахунов һәм 1980–1990 елларда «Татнефть» берләшмәсе генераль директоры булып эшләгән Әкълим Мөхәммәтҗанов

18 сентябрьдә «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең икенче район инженерлык-технология службасында күренекле язучы, Г. Тукай исемендәге премия лауреаты, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Гариф Ахунов иҗатына багышланган тантаналы җыелыш булды.

Җыелышта нефтьчеләрнең яраткан язучысының иҗаты турында РИТС-2 начальнигы Шәһит Таипов чыгыш ясады. Ул Гариф Ахуновның Әлмәттәге тормышы һәм шул чордагы иҗаты турында сөйләде. «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» романнары өчен язучыга җылы рәхмәтләр әйтте.

Аннары смена начальнигы, Ленин ордены кавалеры Шәйхеразый Хәбибуллин, нефть чыгару операторы Хәмзә Мансуров, «Нефтяник» совхозыннан партоешма секретаре Мөдәррис Ибраһимов, өлкән инженер-технолог Вагыйз Сабитов, Октябрь революциясе ордены кавалеры Пётр Утнюхиннар сүз алдылар. Алар барысы да Гариф Ахуновны яхшы беләләр, тынгысыз язучыны промыселларда еш күрәләр иде. Һәм алар, табигый ки, аның белән горурланалар һәм язучыны «Безнең Гариф» дип атыйлар. Алар шулай ук язучыга Бөек Ватаныбыз иминлеге хакына иҗади эшчәнлегендә тагын да зуррак уңышлар теләделәр.

РИТС-2 операторлары һәм инженер-техник работникларының тантаналы җыелышында язучы Гариф Ахунов Почётлы нефть чыгару операторы итеп сайланды. Талантлы каләм остасы туган партиябезнең XXV съезды хөрмәтенә удар вахтага басты.

Гариф Ахунов, Татарстан Язучылар союзының барлык членнары да бердәм төстә РИТС-2 коллективына автографлары белән үз китапларын җибәрергә булдылар. Бу китаплардан службаның нефть чыгару операторлары, инженер-техник работниклары өчен махсус «Язучылар китапханәсе» оештырылачак.

Тантаналы җыелыштан соң да язучы нефтьчеләрнең күптөрле сорауларына җавап бирде.

*Г. Кашапов*

«Хезмәт байрагы».– 1975.– 20 сентябрь

# Утлардан-алып,-суларга-салып

Гариф абыйның кырыкка да җитмәгән яшь, дәртле чагы. Көндәлек тормышта ул бик гади, гел шаян сүзләр сөйләп, яшь язучыларның күңелен күтәреп җибәрүче күңелле кеше. Яшьләр аны бик ярата. Әлмәт юлын да гел без генә таптамыйбыз. Еш кына үзе дә безнең янга килеп чыга. Ул елларда Лениногорскида яшь һәм башлап язучылар без дүртәү: Ш. Бикчурин, Н. Мадьяров, Җ. Рәхимов һәм мин. Ләкин юмор кушып сөйләшергә яраткан Гариф абый безне:

– Нихәлләр, карт һәм яшь язмаучылар? – дип сәламли. – Ник язмый ятуыгызны бик җитди кенәгәгә теркәргә килдем, – дип куркытып та ала.

Ул килгәч, башта без берләшмә членнарының барын да җыеп, гөр китереп утырыш ясап алабыз. Аннары инде Шамил Бикчуринга кунакка кайтабыз. Әдәби кичә дәвам итә, гармун алып сыздырып та җибәрәбез. Гариф абыйның җыры аның бер: «Бишле лампа якты яна, эчендә мае булса...» Көе дә бер – «Арча» көе. Безнең дә яраткан көй бу. Чөнки мин дә, Нәҗип Мадьяров та Арча якларыннан. Бер Шамил абый гына Миңнебайдан. Әмма «бишле лампаның якты януына» ул да каршы түгел. Шамил абыйның өч бүлмәле квартирасы тараеп китсә, урамга чыгабыз. Минем кулда бер дигән чех аккордеоны. Лениногорскида сыздырып җибәрсәң, моңы Әлмәттә яңгырый.

Гариф абыйның, баш күтәрми, «Хәзинә» романын язган чоры. Аның килүенең сәбәбе дә, безне тикшерүдән бигрәк, үзенә бераз ял бирү. Атналар буе өстәл артында утырып тәмам талчыккач, җилләнеп кайту максаты белән килә. Бөек Толстой, мин каретада барганда, кунакта-балда булганда да, хәтта сөйгәнемне кочканда да язасы әсәрләрем, андагы персонажларым турында уйлыйм, дигән. Бу сүзләр, күрәсең, бар иҗат кешеләренә дә кагыла. Гариф абый урамнан күңелле генә җырлап барган көйгә, шып туктап, куеныннан «бригадир кенәгәсе»н суырып чыгара. Калын гына бер дәфтәр ул.

– Романымны төгәлләргә бернәрсә җитеп бетми иде, менә хәзер башыма килде, – дип, шул дәфтәренә нәрсәдер теркәп куя. Ә безнең анда-монда эш юк, әйттерәбез генә:

*Әйдә, дуслар, әйтик әле,*
*Әйтик әле, дүрт булсын.*
*Егет сөймәгән кызларның*
*Ике күзе ут булсын.*

Бу турыда Гариф абый үзе ничек уйлый торгандыр, минемчә, «Хәзинә» романы менә шулай «әйттереп» йөри торгач кына туды. Аның артыннан без «Хуҗалар»ны күрдек. Шулай бик тату бер иҗади гаилә булып яшәп ятканда, Гариф абыйны янәдән Казанга чакырып алдылар. Г. Ахуновны Казанга җибәрүне сорап, аның урынына шагыйрь Равил Фәйзуллинны тәкъдим итеп, Татарстан Язучылар союзы идарәсеннән Мирсәй ага Әмир килгән иде. Гомуми җыелышлар узгач, мәсьәлә инде хәл кылынгач, «Нефтяник» кунакханәсенең иркен генә бер бүлмәсендә Гариф абыйлар иң якын дуслар өчен генә саубуллашу кичәсе җыйдылар. Әллә ни еракка да китмиләр, бер уйласаң, Казанга гына. Кайгыларыбызны да, шатлыкларыбызны да барып уртаклашырга өйрәнгән бу гаиләгә без бик күнеккән идек. Инде хәзер, аерылышу сәгатьләре җиткәч, бик ямансу булып

китте. Кичә ахырына таба кайбер шагыйрәләребез Шәһидә апаны кочаклап, елашып та утырдылар әле.

Казанга күченеп киткәнгә карап, Гариф абый Әлмәт якларын онытмады. Еш кына килеп чыга торды. Бүлек эшен һәрчак игътибар үзәгендә тотты. Күп авторларга үзләрен танытырга, әйберләрен журналларда бастырырга, китап итеп чыгарырга ярдәм итеп торды. Әмма бүлекне ярата, анысын яшереп булмый. Кайсы ана үз баласын сөйми? Һәм моның өчен ананы гаепләргә ярыймы соң? Әлмәт бүлеген Гариф абый ачты, беренче җитәкчесе булды, тату коллектив туплады. Шуңа күрә Гариф абый бу бүлекнең язучыларын да бик якын күрә. Әйтик, Ш. Бикчуринның «Каты токым»ын бастыруга ул гаять зур көч куйды. Романның журнал вариантын әзерләгәндә, Шамил абыйны Казанга чакырып китереп, аны «Казан» кунакханәсенең бер бүлмәсенә бикләп куйды. Кичтән килеп, ашата-эчертә, әзер битләрне машинкага ала. Аннары тагын да өстеннән бикләп китә. Мин дә күрше бүлмәдә генә. Әмма Шамил абый белән телефон аша гына сөйләшәбез. Ә тартырына сигаретларны урамга чыгып, тәрәзә аша бирәм. Шул рәвешчә, Гариф абый аны ун көннәр чамасы эшләтте. Ул чакта Г. Ахунов «Казан утлары» журналының баш редакторы иде.

Гариф абый минем дустым, дисәм, бу ничектер әдәпсезлек булыр. Ул миннән яшькә дә шактый өлкән кеше. Әмма миңа карата һәрчак гаять ярдәмчел булды. Мин аны барыбыз өчен дә бик кадерле, татар әдәбиятын тагын да баету, зурайту, ныгыту өчен җанын фида кылырга әзер торган акыллы кеше, күркәм остаз итеп таныйм. Әдәбият шундый кешеләрсез үсә, алга бара алмый. Әле соңгы елларны гына, «Тугрылык» дигән җыентыгымны нәшриятка тапшыргач, инде барысы да уңай хәл ителде дип торганда, нindидер тоткарлык килеп чыкты. Анысы да бик гадәти хәл. Дөнья дигәнең – көрәш мәйданы. Тормыш



Сулдан уңга: язучы Вазыйх Исхаков (Уфа) хатыны һәм кызы белән, Шәһидә Максудова, Наилә Ахунова, Гариф Ахунов. 1965



Сулдан уңга: Әхтәм Фәтхетдинов, Дамир Гарифуллин, Альберт Хәсәнов, Үзбәк Саттаров, Лидия Старшинина, Гариф Ахунов, Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов. Әлмәт, 1982

кыенлыкларны, каршылыкларны җиңеп барганда гына ямьле. Ә минем китап чыкмау алдында. Мондый чакны Гариф абый каршына бармый, тагын кемгә барасың?

Бүлмәсенә кереп, хәлне сөйләп бирдем.

– Кая, алып төш әле җыентыгыңны, мин дә карап чыгыйм, – диде.

Беләм, аның миннән башка да эшләре муеннан. Үзенең «Идел кызы» романын язасы бар. Союз эшләре күпме! СССР парламент делегациясе составында Һиндстанда, Африка илләрендә булып кайтты. Әмма ул күбебезгә үрнәк булырлык бик оешкан кеше. Минем җыентыкны да ике-өч көн эчендә карап чыгып, аңа бик җылы рецензия язган. Җыентык шунда ук производствога китте.

Хәзер һәр китапның ахырына редактор белән бергә эчке рецензентның фамилиясен куюю тәртипкә кереп килә. Минем дә җыентыкка Гариф абыйның фамилиясен куйдырасым бик килгән иде. Ләкин ул әдәпле генә итеп баш тартты. Минем аптырашта калуымны күреп, әгәр китап ахырында минем исем торса, җыентыгыңа объектив бәя булмас, мактарга тырышырлар, ә сине анда күсәк белән дөмбәслисе урыннар да бар, диде елмаеп.

Ә менә «Сөенеч» дигән повестьлар һәм хикәяләр җыентыгымны ул рецензиягә нәшрияттан үзе сорап алган. Ул рецензияне мин каләмдәшемнең яңа әсәрләрем турында фикер уртаклашуы дип укыдым. Бик объектив, таләпчән һәм дусларча җылылык, теләктәшлек белән иң изге хисләрдән чыгып язылган иде ул рецензия.

Безнең газиз башкайларны утлардан тартып алып, язгы ташуларга салган чаклары күп булды инде Гариф абыйның. Үз итмәде, иш итмәде дип үпкәләрлекне калдырмады бер дә. 1980 елның язында КПСС Үзәк Комитетының чираттагы Пленумыннан соң ул Әлмәткә безнең белән киңәшмә уздырырга килде. Совет язучылары алдында торган бүгенге проблемалар турында ныклап сөйләшү булды.

Икенче көнне иртән Гариф абый мине үз номерына чакырып кертте. Нәрсә өстендә эшләвемне, хәл-әхвәлләрне сораштырды. Аннары үз артыннан ияртте. Гариф абый ялгыз гына йөрергә гомумән яратмый. Башта без Рафаил Төхфәтуллинга сугылдык. Ул авырып тора икән. Аның хәлен белеп, байтак кына вакыт янында утырып чыктык.

*Альберт Хәсәнов,*
язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре
*1987*

# Мой-Альметьевск

В Альметьевск впервые я приехал зимой 1953 года. В качестве специального корреспондента газеты «Татарстан яшьлэре» я был послан за материалами о молодых нефтяниках и строителях. Как раз в эти дни прошел I республиканский слёт молодых нефтяников. Точнее, слет прошел не в Альметьевске, а в Бугульме. В те годы столицей нефтяников считалась Бугульма, объединение «Татнефть» располагалось тоже там. Жаркие споры молодежи вперемешку с шутками и смехом в поездках в переполненных автобусах, а потом их критические выступления на слете дали мне, молодому журналисту, очень богатый материал о кипящей жизни этих краев.

Лето 1959 года. Я очень старательно сдаю выпускные экзамены на Высших литературных курсах в Москве. В один из этих дней пришло письмо из Альметьевска от писателя Гарифа Ахунова. Я с Гарифом и раньше переписывался, но это письмо заставило задуматься. «Вот и твоя учеба заканчивается, давай переезжай к нам в Альметьевск, будем вместе дружно жить, читать и обсуждать наши произведения», – писал Гариф.

В народе есть поговорка: «Земля, где живешь, ближе земли, где родился». В слова «земля, где живешь» народ вкладывает и такой смысл: «земля, где работаешь, где проливаешь пот». Очень правильные эти слова.

Я в Альметьевске написал 7 повестей, много рассказов и очерков, печатаются мои статьи, в Альметьевском драматическом театре поставили мою пьесу. Это – подтверждение моих слов «земля, где проливал пот». С моими друзьями по перу Г. Ахуновым, А. Маликовым, Г. Афзалом, С. Кальметовым живем рука об руку в творческой дружбе. И среди нефтяников, и среди строителей у меня много друзей. Самыми первыми друзьями были мои земляки. Они – приехавшие в эти места из арских краев, как только забили первые нефтяные фонтаны в Татарстане, и начавшие работать, закатав рукава, буровик Ягфар Шамсутдинов, геофизик Энгель Закиров – стали моими первыми нефтяниками-наставниками и друзьями. Дружеское отношение и мудрые советы Героев Социалистического Труда Курбана Валиева, Ахата Губайдуллина и других нельзя вспоминать без глубокого уважения.

Да, я сейчас могу по настоящему назвать Альметьевск своим городом.

Мы уже совсем привыкли, что знаменитый нефтепровод «Дружба» начинается с Альметьевска. Нас уже особенно не удивляет, что мы постоянно направляем руководящие кадры и специалистов в Министерство нефтяной и газовой промышленности СССР, в Тюмень, в Мангышлак, в Белоруссию. Но людьми Альметьевска я никогда не перестаю восхищаться. Славную работу перечисленных выше ветеранов-нефтяников достойно продолжают молодые мастера-нефтяники – Герои Социалистического Труда Г. Хазиев и Д. Нурутдинов, мастера А. Хабибуллин, Е. Онишко и многие другие, и не только продолжают, но и добиваются новых трудовых успехов. Обычно для альметьевцев вчерашние трудовые показатели не являются пределом, они из месяца в месяц, из года в год добиваются новых трудовых высот. Как не восхищаться, как не гордиться ими!

*Рафаил Тухватуллин*

# Альметьевск – город, окрыливший мечты

18 сентября 2012 года исполнилась 87-я годовщина со дня рождения моего отца, Гарифа Ахунова (1925–2000). Её отметили и в Альметьевске, в вечерней школе № 1, и в Арске, в областной библиотеке – вручением премии его имени в пятый раз юным талантам Арского района, и в Казани…

Народный писатель Республики Татарстан, лауреат Государственной премии РТ имени Г. Тукая, почётный академик АН РТ, видный государственный и общественный деятель, автор более 50 книг – так написано о нём в справочниках и энциклопедиях. И это далеко не все его регалии и достижения. Именем Гарифа Ахунова названы улицы в Казани и в Альметьевске, в Кукморе и в Арском районе…

Мне хочется остановиться на очень важном для его творчества периоде биографии, потому что он связан и со мной тоже, а именно – об альметьевской эпопее. И задуматься о том, как важно в жизни быть «романтиком большой дороги» и не бояться оставить налаженный быт – для творческого человека. Такой выбор мой отец сделал в 50-е годы и уехал на «целину» – в Альметьевск, где в окрестностях нашли мощные залежи татарской нефти.

Двенадцать лет в Альметьевске стали для него годами творческого становления. Время, проведённое среди татарских нефтяников (1956–1968), оказалось важнейшей вехой в жизни и творчестве. Ему было важно самому быть в гуще событий, он дневал и ночевал на буровых, чтобы увидеть всё изнутри, собирая материалы о героических делах добытчиков «чёрного золота» для статей, очерков и рассказов, для создания широкого эпического полотна – романа «Клад» («Хазинэ»), который вышел в Таткнигоиздате в 1963 году, а в 1973 году был удостоен самой высокой литературной награды – респуб-



Шәһидә Максудова балалары Рәшит һәм Наилә белән. Әлмәт, 1963




Язучы Гариф Ахуновка һәм шагыйрь Гамил Афзалга мемориаль librarian такталар. Әлмәт, Радищев урамы, 20 нче йорт

ликанской премии имени Габдуллы Тукая. Эта книга Гарифа Ахунова впоследствии стала настольной книгой нефтяников, она переводилась на языки народов СССР, по её мотивам на Свердловской киностудии был снят одноимённый фильм, главную роль в котором сыграл тогда ещё совсем молодой, с буйной шевелюрой, знаменитый Александр Филиппенко; созданы спектакль, радиопостановки...

В татарской прозе не так много значительных произведений, посвящённых современному рабочему классу, в том числе и нефтяникам. Поэтому ещё более возрастает значение романа Гарифа Ахунова, первому изданию которого в следующем году исполнится 50 лет. Очень хотелось бы, чтобы к этому времени вышло достойное издание книги «Клад» в издательстве «Рухият», чтобы в Альметьевске состоялся вечер, посвящённый этому событию... Ведь мой отец, помимо прочего, был и организатором местного отделения Союза писателей, которому на следующий год также исполнится 50 лет! Гариф Ахунов был удостоен и звания «Почётный нефтяник» ОАО «Татнефть». Какое у отца счастливое лицо в кадрах старой кинохроники...

Сам он об этом писал так в статье «Альметьевск – колыбель моей жизни»: «Альметьевск – город, окрыливший мечты моей юности. Альметьевск – самая главная опора в моей писательской работе... Я окунулся в среду нефтяников. За двенадцать лет жизни в Альметьевске я написал и опубликовал десять книг. Годы самого высокого напряжения, самых пламенных чувств...»

Я бережно храню одно из изданий «Клада», которое мне подписал папа своим чётким красивым почерком: «Дорогой моей дочери от искренне любящего её отца – на память и с пожеланиями найти свой клад в жизни»...

Все мы родом из детства. Я родилась в Альметьевске, с ним у меня связаны самые ранние, самые солнечные воспоминания... И люблю приезжать сейчас, у меня здесь есть друзья и ученики. Второй год существует альметьевский филиал моего литобъединения «Белая ворона» (которому уже шестнадцатый год), им руководит молодая талантливая поэтесса Екатерина Аничкина. Наша семья дружит с сыном папиного земляка, замечательного писателя Рафаила Тухватуллина, семьёй народного поэта Татарстана Гамиля Афзала, которая живёт в нашей бывшей квартире на улице Радищева, 20. И я очень рада, что на этом доме сейчас висят мемориальные доски Гарифу Ахунову и Гамилю Афзалу. В Альметьевске есть улицы, названные их именами, они тоже расположены рядом. И я благодарна руководству города и местной писательской организации, которые бережно хранят память о тех, кто внёс весомую лепту в историю Альметьевска...

*Наиля Ахунова*
*2012*

# Открытие-музея-имени-Гарифа-Ахунова в-Альметьевске

Сбылась давняя мечта… В городе Альметьевск, где я родилась, открылся музей, который носит имя моего отца – народного писателя РТ Гарифа Ахунова (1925–2000).

Для нашей семьи и для Альметьевска произошло значимое и радостное событие: 21 декабря 2013 года на ул. Гафиатуллина, 28 в помещении вечерней школы № 1 открылся Музей истории литературного движения г. Альметьевск имени Гарифа Ахунова – в год 60-летия города. Там представлены раритетные фотографии, рукописи, письма и книги альметьевских писателей, а также вещи, символизирующие становление старейшей школы города, которая отметила своё 55-летие. Мой отец был одним из организаторов и первым руководителем Альметьевской писательской организации, которой недавно исполнилось 50 лет. Здесь он прожил с семьёй более 10 лет, написал свой знаменитый ро-



Ахуновлар гаиләсенең кунакчыл йорты. Сулдан: Шәһидә Максудова, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов; уңнан икенче Рафаэль Төхфәтуллин, Наилә Ахунова, Гариф Ахунов. Әлмәт, 1960 еллар

ман «Клад», который много раз переиздавался, переводился на разные языки, был экранизирован, а также повести, рассказы, очерки. Альметьевск – родной город, где прошло моё детство. Символично, что музей стал подарком к его юбилею.

...Он мне долго снился, когда мы в 1968 году переехали в Казань. Его дворы, где так удобно было прятаться в кустах во время игры в «казаки-разбойники» и в прятки, в вышибалы или штандар, когда сердце отчаянно колотится и вот-вот выскочит, в «фантомаса», в которого играли поздно вечером, в темноте, – это важное условие, чтобы было страшнее. Весенние субботники, когда выходили всем миром убирать снег, а малышня вроде нас пускала кораблики из щепок и палочек и долго бежала за ними... Помню, как зимой заливались два катка – для взрослых и ребятни, они и сейчас сохранились, что удивительно. Летом рано утром всех будил пионерский горн, и дети выбегали на зарядку. В памяти навсегда остались походы на «Неуловимых мстителей» за 10 копеек в соседний кинотеатр, кофейные сладкие кубики в виде рафинада, мороженое в стаканчике с кремовой розочкой сверху, первомайские шумные демонстрации, незабываемые ёлки в Доме техники и науки, где работали мои родители, костюм снежинки, сшитый руками мамы, новогодние подарки, фантики от которых хранились годами, газировка с двойным сиропом... Симпатичный одноклассник Серёжа, которого ставили со мной в пару на уроках танцев, занятия по акробатике, когда так весело кувыркаться на матах, детский сад с манной кашей комками и с пенками в молоке, откуда я в конце концов сбежала. Слёзы из-за первой школьной тройки, снежные крепости в парке нефтяников рядом с домом и игры в войну, Урфин Джюс и Страшила, Незнайка и Чиполлино, сказки народов мира, ни с чем не сравнимый запах школьной библиотеки, целый абажур привезённых папой московских конфет мне на день рождения, бабушка, рьяно оберегающая меня от дворовых мальчишек, дёргающих за косички, фото, где я сияющий октябрёнок, и другое, более раннее, где рядом со мной такая же щекастая кукла, красивые и нарядные родители. А в парке нефтяников до сих пор крутится Колесо обозрения...

Спасибо всем, кто помог осуществить этот проект, особенно разработчикам нашего музейного проекта, ставшего победителем Республиканского Молодёжного форума под патронажем Президента Республики Татарстан Р. Н. Минниханова – преподавателю русского языка и литературы Елене Кильдюшевой и Екатерине Аничкиной, руководителю альметьевского филиала ЛИТО «Белая ворона», а также коллективу вечерней школы № 1, администрации и общественности города Альметьевска. Музей уже активно работает, там проводятся экскурсии и мероприятия, он постоянно пополняет свои экспозиции...

*Наиля Ахунова*
*2013*

## В нефтеграде – новый музей

В последнюю декаду 2013 года, ознаменованного юбилеями – 70-летием татарстанской нефти, 60-летием Альметьевска, 50-летием создания Альметьевской писательской организации – здесь, в нефтеграде, произошло еще одно событие: открытие музея истории литературного движения г. Альметьевск имени Гарифа Ахунова.

Музей открылся в старейшем учебном заведении города – вечерней (сменной) общеобразовательной школе № 1, которой, кстати, исполнилось 55 лет.

Идея открытия музея исходила от поэтессы, бессменного руководителя литературного объединения КГМУ «Белая ворона», заслуженного работника культуры РТ Наили Ахуновой, дочери Гарифа Ахунова – одного из создателей писательской организации, автора культовой книги о нефтяниках «Клад».

– Несколько лет назад на фестивале «Во имя жизни», посвященном творчеству инвалидов, я познакомилась с молодой альметьевской поэтессой Катей Аничкиной, – рас-




Әлмәтнең Гариф Ахунов исемендәге әдәби хәрәкәт тарихы музеенда очрашу. 2014

сказала она. – Я вела мастер-класс, который посещали она, Гульнара Миранова и другие творческие ребята-колясочники.

Мы подружились, особенно с Катей, я, как говорится, взяла ее под свое «крыло». Она стала членом нашего литературного объединения «Белая ворона». Вскоре здесь, при вечерней школе, которую окончила Катя и где русский язык и литературу преподает прекрасный педагог и патриот своего города Елена Кильдюшова, был организован филиал нашего литературного объединения, названный «Белое перо».

Одновременно у нас появилось желание создать при школе музей истории литературного движения г. Альметьевск имени Гарифа Ахунова.

Руководителем филиала ЛИТО КГМУ в Альметьевске Екатериной Аничкиной и педагогом Еленой Кильдюшевой была разработана концепция музея. Оформив проект, они подали заявку на участие в Республиканском форуме молодёжных инноваций-2012 под патронатом Президента РТ Рустама Минниханова. Из 1044 проектов победителями стали 9 проектов. Первыми, кого поздравил Президент с победой, стали авторы проекта «Музей истории литературного движения г. Альметьевск имени Гарифа Ахунова», представлявшие номинацию «Технология добра».

Вот так – собственными силами, старанием и верой в успех была рождена эта общественная инициатива. Она получила высокую оценку руководства и общественности города, писателей и поэтов, учащихся и студентов, участвовавших в церемонии открытия музея.

Среди тех, кто всеми силами способствовал рождению музея, – директор вечерней школы Наталья Кононенко, дети известных писателей – Наиля Ахунова, Рустем Тухватуллин и др.

Общими усилиями здесь собраны интересные экспонаты. Со старых фотографий смотрят любимые писатели и поэты – Гариф Ахунов, Сажида Сулейманова, Адиб Маликов, Рафаил Тухватуллин, Гамиль Афзал, Дмитрий Матвеев, Иван Винокуров и др. Здесь же – подлинные афиши, предметы быта 50–60-х годов, книги с личными автографами, письма, газетные и журнальные публикации.

Глубоко символично, что музей зародился в стенах вечерней школы, или, как ее называли раньше, – школы рабочей молодежи, где учились или преподавали любимые писатели и поэты – властители дум молодого нефтеграда.

Здесь ждут пополнения экспонатов, а это значит, что музей будет развиваться.

*София Гарифуллина*
«Нефтяная газета» (Альметьевск)
13.01.2014



# III-бүлек.-СОҢГЫ-БҮЛӘК

# Котлау

Хөрмәтле Гариф Ахунҗанович!

Җитмеш еллык бәйрәмегез уңаеннан Сезне – республикабызның олы әдибен ихлас күңелдән котлыйм! Саулык-сәламәтлек, бәхет, киләчәктә дә бетмәс-төкәнмәс иҗат ләззәте телим!

Җир йөзендә кеше дигән олы хәзинә бар һәм аның тумыштан чишмә суыдай саф күңеле бар. Язучыларның, гомумән сәнгатькәрләрнең төп вазифаларыннан берсе – әнә шул күңел сафлыгын-пакьлеген саклау, аны рухи баету, әхлаклык тәрбияләү. Саный китсәң, ул вазифалар диңгездәге тамчылар саны кадәр. Чөнки әдәбият-сәнгать үзәгендә бөтен барлыгы белән кеше тора, ә сәнгатькәрнең иҗат кыры – халык тормышы; Гариф Ахуновның иҗат кыры – татар халкы тормышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге. Менә шуңа күрә ул иҗат күпьяклы, киң колачлы. Шуның өчен дә Гариф Ахунов – халык язучысы.

Гариф Ахунов геройлары дигәндә, күз алдына җиң сызганып, кайда гына, кем генә булып эшләмәсен, хезмәтеннән тәм табып, аңа яңа ямь биреп, тырышып эшләүче хезмәт кешесе килеп баса. Шунысы кыйммәт, ул образлар язучының үз образы белән тәңгәл килә. Мин белгән Гариф Ахунов һәрвакыт шөгыльдә, эшчән, актив, туры сүзле, зур абруйлы, халкыбызның олы мәхәббәтенә чын-чынлап лаеклы мәшһүр каләм остасы.

Хөрмәтле Гариф Ахунҗанович!

Сезнең югары талантыгыз белән сугарылган, дистәләрчә телләргә тәрҗемә ителгән, берсеннән-берсе матур роман, повесть, драма әсәрләрегез, республикада әдәби процесс барышын җентекләп өйрәнеп язган мәкаләләрегез, менә дигән тәрҗемәләрегез, иҗтимагый тынгысызлыгыгыз болар. Сез яулаган биеклекләр, үрләр. Биеклектән биеклеккә атлап, Сез бөеклеккә барасыз. Шушы изге хезмәтегез өчен олуг рәхмәт әйтеп, мин Сезгә – халкыбыз өчен җан атып яшәүче һәм эшләүче кодрәтле иргә ак юл телим.



Чын күңелдән сөйләшү: Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Гариф Ахунов юбилее. Сулдан уңга: С. Шәймиева, М. Шәймиев, Г. Ахунов, В. Лихачев. Казан, 1995

*Минтимер Шәймиев,*
Татарстан Республикасының беренче Президенты
*1995*

# Күпне-күтәбез!

Гариф Ахуновка илле яшь тулуын уйлый башлауга, ни өчендер, быел гына туып, халык арасына бик тиз таралган бер җырның сүзләре искә төшә:

*Менә без дә үсеп җиттек, әни!*

Әйе, без бергә диярлек башлаган идек. Юлга бергә чыктык. Күмәкләшеп, иңнәрне иңгә терәп, бер булып... Шул иптәшләребезгә дә илле тула башлады! Башка бик күп өлкәләрдә юлдашларына караганда күбрәк эшләгән, күбрәк хезмәт куеп өлгергән кебек, монда да безнең арада иң өлгере ул булып чыкты. Гариф иллене тутырды. Без дигәндә, мин монда күп санлы университет шәкертләрен күз алдында тотам.

Юбилей хатирәләр көне дә ич ул!..

Әйе, сугыштан соңгы авыр, читен еллар иде. Сугыштан соңгы сөенечле, бәхетле, эчкерсез бирелгәнлек белән сугарылган өметле еллар. Хөкүмәтебез сугышның иң хәтәр чагында, кырык дүртнең көзендә, Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге оештырып җибәрде. Шушы бүлек бик тиз арада шигырь-хикәя белән җенләнгән яшьләрне үзенә тартты.

Ул елларда студентларның мохите бик чуар иде. Алтышар-җидешәр ел иңнәреннән солдат шинеле төшмәгән мыеклы агайлар янына әле генә мәктәп партасы арасыннан чыккан сары чебешләр кереп утырды. Завод-фабрикаларда, колхоз ызаннарында бишалтышар ел хезмәт итеп, дөньяның ачысын-төчесен үз җилкәләрендә татыган апалар чәчләрен бантиклап үргән яшь кызыкайлар белән укый башладылар. Аерма зур – берәүләр дәреслекләрдә язылганны яттан белсә, икенче берәүләр аны бөтенләй онытып, тормыш фәнен бик яхшы үзләштергәннәр иде. Шул елларда безнең остазларыбыз – гаять таләпчән кафедра җитәкчесе Рабига Афзаловна Хәкимова, иңендә тау чаклы хәзинә, тел байлыгы күтәреп йөргән зирәк профессорыбыз Латыйф ага Җәләй, укытучыларыбыз М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Кашшаф, Ш. Рамазанов, Б. Яфаров, Д. Сафин, М. Тарасов – шул чуар яшьләрне ныклы бер коллективка берләштерә алдылар, өлкәннәр өчен дә, яшьләр өчен дә уртак интереслар таптылар.

Университет аудиторияләре гөрләп торган гаҗәеп чор иде ул!

Әдәбият түгәрәге атна саен диярлек үзенең ялкынлы утырышларын уздыра, агитбригадалар сәфәр чыгып китә, ул диспутлар, тамак карлыкканчы бәхәсләшүләр дисеңме, бар да бар иде! Университет шәкертләренең күз өстендә кашы булган атаклы «Әдәби сүз» газетасы болын хәтле булып чыга...

Гариф иң әүвәл, дусты Яхъя Халитов белән бергә, иптәшләре, чордашлары арасында әнә шул газетаның җаны – художнигы буларак танылды. Студент халкы, гадәттә, күп яктан бер-берсенә охшаш була. Тик Гарифның шул чакта ук аерылып торган сыйфатлары да бар иде: ул бер чакта да башкаларга салынмады, аркаланмады, үз көнен үзе күрде. Искиткеч тырыш, эшкә һәм укуга чиксез бирелгән, пөхтә, вәгъдәчел, кием-салымы җыйнак, чибәр егет иде. Төпле, уйчан, җитди кеше иде. Аның үз иптәшләренә булган игътибары аерата күзгә ташлана иде. Язучы булам дип, чәч туздырып, кул болгый-болгый шигырь укып йөрмәде ул. Акрын гына, уйсу җирдән тын гына бәреп чыккан чишмә

кебек, студент ишләре арасыннан сызылып кына килеп чыкты. Килеп чыкты, күзгә дә ташланды.

Башта хикәяләр, очерклар туды. «Яшьлек яме» повесте белән Гариф үзенең йөрәк серен ачты, яңа язучы пәйда булды.

Шуннан бирле күпме сулар аккан, татар әдәбияты белән Гариф Ахунов күпме юллар узган.

Ниһаять, «менә без дә үсеп җиттек, әни!»

Әни сүзе нинди мәгънәдә алынган иредә? Нинди киңлектә? Гарифны тудырган газиз әнкәсе – дүрт ятим баланы тол килеш карап үстергән Бибинур апа гына күздә тотыламы? Әллә язучыны тудырган, аңа тел ачкычы биргән Казан артымы? Аңа канатлар куйган университетмы әллә? Аны тәрбияләгән Язучылар оешмасы, аның остазларымы? Гарифның дөньяга карашын киңәйткән, аны язучы буларак халык арасына алып чыккан Татарстан нефтьчеләреме? Әллә шушы мәгънәләрнең барын берләштергән туган илебез, туган халкыбызмы?

Илле яшь тулганда, аның каршына килеп, хезмәттән ныгыган кулларыбызны илле ел буе заман белән бергә бәхетле һәм бәхетсез секундларны санаган йөрәгебезгә куеп, еллар чаларткан башыбызны иеп әйтер сүзләр бар. Бар, бик бар!

Дөрес, Гарифның иҗаты турында «соңгы зур хөкем»не чыгарырга иртә, бик иртә. Гадәттә, язучы үзенең «иң-иң мөһим, иң-иң газиз китабы» язылмаган дип йөри. Бу очракта исә без язучылар да, аның күп санлы укучылары да Гариф Ахуновның «иң-иң шәп... иң-иң тирән эчтәлекле... иң-иң кабатланмас китабы алда» дип саныйбыз. Бу китапның язылачагына без моңарчы да шикләнмәдек һәм безнең хөрмәтле юбилярыбыз үзенең ярты гасырын, бәйгеләрдә узышкан егет кебек, ак тулпар өстендә «Идел кызы» романының беренче китабын язып бетереп каршылый. Үзенә таләпчән, гомер уртасында инде кыек агарга ярамаганлыгын бөтен күңеле белән сизгән автор буларак, үтә зур җаваплылыкны тоеп кына, бу романны бастырып чыгарудан тыелып калды. Байтактан күреп киләбез инде без бу әсәрне. Әлмәттә чакта ук, моннан җиде-сигез ел элек, күзгә чәчрәп торган эре, тәэсирле хәрефләр белән язылган роман юлларын калын-калын амбар кенәгәләрендә күргән идек. Күңеле ачылып китеп, дуслар белән аралашырга, язылачак әсәрләр турында очынып сөйләргә яратучан Гариф романның аерым эпизодларын укып та күрсәткән иде. Ул байтактан шушы әсәр геройлары белән яши, халык арасында йөргәндә, әңгәмәләрдә җор сүз, кызыклы фикер ишеткән чакта, тиз генә куен дәфтәренә теркәп куя, хәтер сандыгында туктаусыз үсә, ачыклана барган роман юлларына урнаштыра бара.

Гадәттә, юбилей тантанасы вакытларында язучының үткән эшенә күбрәк игътибар юнәлтеп, авторның язылган, таралган әсәрләре хакында сүзне күбрәк алып баралар. Нигә соң без бүген әүвәл башлап аның яңа язылып килгән әсәренә мөрәҗәгать иттек?

«Кырык яшь – яшьлекнең картлыгы, илле яшь – картлыкның яшьлеге», – дигән Виктор Гюго. Илле яшь, шул яктан караганда, барлык кеше өчен, бигрәк тә иҗат әһелләре өчен аерата мөһим сызык икән. Игътибар итегез – монда Гюго ун ел араны бәясез калдырган. Кырык яшендә кеше яшьлеге белән саубуллаша, кырык белән илле арасында кеше чынлап торып сынау, яңарыш чоры кичерә. Аның дөньяга карашы, теге яки бу мәсьәләләргә мөнәсәбәте тәмам ачыклана... Эшлекле кеше яшьләрчә җиң сызганып хезмәт итә башлый!.. Хезмәт аны яшьлегенә алып кайта! Кайта алмаса, бу кешенең һәлакәте... Илле яшьтә кеше акыл утырткан, сабырлык, зирәклек туплаган иң егәрле, иң көчле эшче була!

Егерме биш ел эчендә байтак романнар, повестьлар, хикәяләр иҗат иткән, үзен ялкынлы публицист, менә дигән тәрҗемәче, редактор, җәмәгать эшлеклесе итеп танытып

өлгергән Гариф Ахуновның кырык яше белән эшлекле хушлашып, илле яшен, нәкъ менә Гюго әйткәнчә, яшьләрчә башлап җибәрүе безнең барыбыз өчен дә куанычлы күренеш. Без егет чагыннан ук белгән тыйнаклык, эшкә бирелгәнлек, «яхшыга бал авыз, яманга явыз» булган сыйфатларын ул хәзер дә югалтмады, «изге эшкә – бал авыз, яманлык күрсә –бик явыз» булып ныгыды.

Моны раслау өчен, әлбәттә, язучының иҗатына мөрәҗәгать итәргә генә кирәк. Әйдәгез, иң киң таралган, Гарифка язучылык исемен китергән «Хәзинә» романына күз салыйк. Менә романның үзәк персонажларыннан берсе Лотфулла Дияров, нефть чыгару остасы, Куйбышевтан Татарстанга кайтырга җыена. Мин монда бу вакыйганың тарихи дөреслеккә ифрат та хас килүен, башка якларын да әйтмим. Кайчандыр эш эзләп, бәхет эзләп чыгып киткән кешеләрнең нефть осталары булып туган туфракларына кайтулары үзе дә игътибарга лаеклы факт. Шушы беренче карашка гади генә эпизодны Гариф зур бер тантанага, һәр мизгеле эчке мәгънәгә ия булган зур вакыйгага әйләндерә. Лотфулла Дияровны озату өчен Куйбышев нефтьчеләре зур бер кәрван оештыралар. Җиһазларын төяп зур-зур машиналар барса, үзен, хәләл җефетен һәм сигез баласын утыртып, Кәлимәткә кадәр автобус җибәрәләр. Озатырга бөтен бригада, дуслары, ахирәтләре җыела.

Куйбышевтан Кәлимәткә нефть чыгару остасы, моңарчы гел күченеп, ягымлы якларда, әйбәт кешеләр арасында яшәсә дә, ничектер үзенең соңгы оясын ныклап корып бетермәгән кеше кайта. Туган иленә кайта. Куйбышевтан шулай олылап, хөрмәтләп озатканнар, туган җирендә ничек каршы алырлар? Кәлимәттә, иске булса да, аның өе бар, нигезе бар, иле, көне, теле бар. Гариф озату моментын тантаналы, югары стильдә хәл итсә, Кәлимәттә каршылауны тагын да уңышлырак, калку итеп, күзгә бәрелеп торган ачык буяулар белән тасвир итте. Иң элек – туып үскән җирнең газизлеге, үзе ил кайгысын кайгыртып йөргән чакта буш һәм нәүмиз булып торган йорты Лотфулла останың җанын айкап ала. Ләкин монда да аңа сагышланып утырырга юл калдырмыйлар. «Дияровларның җилкапкасы турына ике машина – бу юлы Кәлимәт машиналары килеп туктады. Аларның берсенә йортны ремонтлау өчен кирәкле материаллар, икенчесенә кузов түбәсеннән кешеләр төялгән иде», – ди автор.

Бер көн дигәндә, Лотфулланың йортын төзәтеп, мичен чыгарып ташлыйлар. Миңа аерата төнлә кайтып китмичә эшләүләре ошый. Автомашиналарның фара яктысында туктаусыз хәрәкәт иткән бу төнге эшчеләргә карата Лотфулла оста күңелендә генә түгел, укучы күңелендә дә рәхмәт хисләре уяна, үзеңне сафрак, баерак, яхшырак хис итә башлыйсың.

Озатучыларда да, каршы алучыларда да Гариф өчен бик кадерле уртак сыйфат бар – бу аларның яхшы күңеллелеге. Кешеләрдә яхшылыкны эзләү, аны нәкъ менә гомернең кискен минутларында таба белү, шул яхшылыкны җырлау, яхшылыкка соклану – Гариф Ахуновның төп иҗат принцибы. Дөрес, бу изге юлдан кереп киткәндә дә белеп эш итәргә кирәк, чама хисен һич тә онытырга ярамый. Яхшылыкны җырлауны гади төчеләнү белән алыштыруың, чыннан да, бал авыздан балавызга әйләнеп, эреп-җебеп төшүең дә ихтимал! Юк, Гариф андый юлны сайламый. Чөнки тормыш аллы-гөлле сукмаклардан гына тормый, җәмгыятьтә төрле-төрле кешеләр яши. Әйтик, «Хәзинә» романында ике машина яктысында әкияттәге баһадирлар кебек тантаналы өмәдә эш оеткан риясыз ир-егетләрне лапас караңгылыгыннан, кулларын кушырып, Шәвәли карт күзәтеп тора. Шәвәли заман өчен куркынычлы көчкә ия булган зат түгел. Алар да кеше. Лотфулла Дияровлар тормышына әнә шул бәрәкәтле хәзинә – нефть тудырган үзгәрешләр генә түгел, караңгы чырайлы Шәвәлиләрне яшәтүче шартлар да йогынты ясый. Чөнки җир бер, тормыш бер, гомер икесенең дә бер чорга туры килгән.



Аяз Гыйләҗев, Наилә Ахунова, Шәһидә Максудова. Г. Тукай музеенда Г. Ахуновны искә алу. Казан, 2000

Әле шулай гынамы сиңа, җирдә Лотфулла белән Шәвәлинең нәсел-токымын дәвам иттерүче мут егет Булат белән чая кыз Фәйрүзә дә бар, картлар берни сизми калганда, алар уртак малай – Тансыкны алып кайтып та өлгергәннәр!.. Катлаулы ул тормыш дигәнең, беркатлы мәдхия укып кына, кешеләрне гел-гел мәйданда йөртеп кенә аның чын диалектикасын ачып бетерә алмассың.

Шиксез, яхшы белән яман көрәшендә гаделлек өстенлек ала бара һәм аның шулай кирәклеген Гариф җай килгән саен шәрехләп бара, ассызыклап язарга ярата. Кәлимәт кешеләренең канына шактый еллар тоз салган Җилкуар Тимбик белән бер вакыйганы искә алмый китү мөмкин түгел. Гомеренә берәүгә дә бер тиенлек яхшылык күрсәтмәгән, очраклы рәвештә кулына власть алган бу кеше ниләр генә кыланмый! Шәмаилләргә ата, ураза тотучыларны колхоздан кудыра, эчеп-исереп, колхозның нәсел айгырын яндырып үтерә. Көннәрдән бер көнне шушы әкәмәт кешенең (ә ул бу тормышта бер дә очраклы рәвештә пәйда булганнардан түгел) өе кара тузан туздырып җимерелеп төшә. Тантана итәме авыл халкы? Чалгыларын күтәргән, тырмаларын тоткан агай-эне, хатын-кызлар печән өстендә, уттай эш вакытында болын уртасында җыйналалар да киңәшләшәләр: «Йә, нишлибез? Тимбикне йортсыз яшәтәбезме?» Авылның атаклы балта осталары Тимбиккә йорт бурыйлар, миччеләр мич чыгара. Бөтен авыл өй котлау мәҗлесенә килә! Һәм шуны карап торган Тимбик, кичерешләренә чыдый алмыйча, халык аягына егылып җан бирә.

Менә бу Гариф! Үзе! Бу эпизодларда аның бөтен барлыгы, бөтен күңеле ачылып, ярылып ята. Ләкин бу эпизод та болай гына, халык бөеклеген раслаучы эпизод кына булып кала алмый. Әле Тимбикнең улы Кәрим бар, әтисенең кара күләгәсеннән котылыр өчен,



Наилә Ахунова туенда тамада Г. Ахунов монгол киемендә. Казан, 1979, 22 сентябрь

аңа байтак тырышырга туры киләчәк. Әнә шул тырышулар, кара исемнән котылырга маташулар ахыр чиктә Кәримне дуамаллыкка илтәчәк, һәлакәткә китерәчәк...

Үзенең төп фикере җигелгән эпизодларны автор саран, әмма мастерларча кырыслык белән, күңелләргә үткәзерлек итеп, хәтердә мәңгегә уелып калырлык көч белән тасвирлый...

«Менә без дә үсеп җиттек, әни!»

Шәүкәт Галиевнең үткенлеге белән мине таң калдырган мондый юллары бар:

*«Халкым!», «Халкым!»*
*дигән сүзләреңне*
*Уңга-сулга сибеп талпынма.*
*Синең әйтү генә җитми әле –*
*«Улым!» дисен сиңа халкың да!*

Гарифның халыкка булган мөнәсәбәте ачык булган кебек, халкыбыз да аңа булган мөнәсәбәтен көн кебек ачык белдерде.

Ул Лауреат.

Ул Депутат.

Ул Атказанган.

Халык улы булуның никадәрле мактаулы һәм җаваплы икәнен беләбез. Гариф та моны белә. Димәк, без аңардан бик күпне көтә алабыз, күпкә өметләнәбез.

*Аяз Гыйләҗев,*
Татарстанның халык язучысы
*1975, сентябрь*

# В-расцвете-творчества

Было знойное, засушливое лето 1947 года. Нас, выпускников Арского педучилища, отличников учебы, заснял фотокорреспондент «Красной Татарии». Снимок был опубликован в номере от 13 июня. Эта вырезка из газеты до сих пор хранится у меня как дорогая память о юношеских годах. Никто и не предполагал тогда, что один из выпускников через четверть века станет известным писателем, видным общественным деятелем, автором нескольких солидных романов, повестей и пьес. Вот он в центре снимка, юноша в потертом пиджаке, с присущей ему улыбкой и ясным взглядом, – Гариф Ахунов.

Нет, я не собираюсь утверждать, что пятьдесят лет – пора юношества. Знаем: она бывает, когда тебе двадцать... Время – объективное явление, оно не зависит от желания отдельных людей, земной шар вертится, и с каждым его оборотом вокруг солнца детям природы прибавляется год жизни. Это происходит помимо нашей воли, независимо от наших желаний. Но есть одна возможность в распоряжении человека, возможность, зависящая от него, и только от него: выбор цели, которой он посвящает свои силы и стремления. Узнав, что Гарифу Ахунову исполняется пятьдесят лет, я подумал почему-то именно об этом.

Впрочем, были тому причины.

Мы родились с ним в одном районе, между нашими деревнями то колыхалось синее льняное поле, то сказочно-волнисто перекатывались на летнем ветру пшеничные колосья. Выйдешь на ниву нашего колхоза, пройдешь эту волшебную сине-зеленую черту и увидишь маленькую деревню Учили. Уже само название («Учили» в переводе значит «Трехдомный») манило нас своей лиричностью, а места – тишиной...

Там родился и ходил в школу чернявый мальчуган, бойкий на язык, но с задумчивостью в глазах – Гариф Ахунов. Рано лишившись отца (организатора колхоза, он был убит в тридцатые годы), он рано познал крестьянский труд: ведь он был старшим среди братьев и сестер. Прошло детство, и в 1946–1947 годах мы вновь оказались с ним вместе, в одном классе Арского педагогического училища. Суровые были времена, из полусотни учащихся лишь девять смогли закончить учебу. Среди этих выпускников был и Гариф. Вокруг него всегда кипела студенческая жизнь. Он не умел оставаться без дела, весь был в движении, рисовал, мастерил, рассказывал веселые истории.

Гариф любил литературу, по этому предмету он получал только пятерки. Когда в общежитии училища разгорался начатый им спор на литературную тему, жизнь как-то сразу становилась интереснее.

Затем Ахунов был направлен на учебу в университет. А когда, демобилизовавшись из флота, я приехал в Казань, его имя уже было известно среди литературной общественности. Появился подающий надежды прозаик и вдумчивый критик. При встрече он рассказал, как им была написана первая повесть «Краса юности»: разбросав 20–30 блокнотов, он говорил о том, как собирал материал, какие слова записывал в блокноты, какие герои от кого «произошли». Я подумал тогда: этот человек уже нашел свой путь в жизни, посвятив себя художественному творчеству.


С тех пор прошло уже более двадцати лет. Все это время Ахунов работал удивительно много, выпустил десятки книг, написал сотни статей и очерков, тысячи раз выступал в больших и малых аудиториях. Два солидных романа – «Клад» и «Хозяева», повести «Ядро ореха» и «Ардуан батыр» полюбились читателям. В театрах республики ставились его пьесы, он вел большую творческую работу в киностудии.

Сам из массы народной, он и героев своих произведений находит лишь в ней. Пройдя солидную школу в нефтяных районах республики, Ахунов стал первопроходцем «нефтяной целины» татарской литературы.

Писатель знает и любит своего героя – человека труда, нашего современника, рассказывает о нем с большой художественной правдой. Вместе с ним в произведения Ахунова вошли горячее дыхание нашей жизни, пафос созидания, новые характеры – сильные, мужественные... Именно поэтому романы и повести писателя стали нужными и близкими читателям, получили у них заслуженное признание.

Гариф Ахунов не только литератор. Он и общественный деятель, депутат Верховного Совета СССР, председатель правления Союза писателей Татарии. Его страстное слово публициста звучит на страницах книг и в газетах, на читательской конференции в сельском районе и на предприятиях Казани, он выступает на собраниях трудящихся в Москве, Краснодаре, Тюмени... Как же при такой ежедневной занятости найти время для творческой работы? Но каким бы напряженным ни был день, пять часов ежедневно Ахунов уделяет литературному труду. Это для него – закон. Ведь литературное произведение – не только взлет фантазии художника. Это замысел, разработанный тщательно, детально, многосторонне. Самым хорошим произведением для писателя является то, которое еще в голове, еще не написано. Ахунов очень дорожит временем. И лишний раз подтверждает одну очень важную закономерность: не в отрыве от общества рождается и развивается талант. Творческий успех приходит только тогда, когда художник творит в тесной связи с обществом, с его заботами.

...Мы знаем, что Гариф Ахунов завершает в эти дни новый роман. По некоторым отрывкам, появившимся в печати, можно сказать, что это произведение о том, как пришла к революции женщина, какое участие в ней она принимала. Очень возможно, что в год своего пятидесятилетия писатель порадует издателей, положив им на стол свою законченную рукопись. Надо надеяться, что это произведение



Халык язучылары

Татарстан Республикасы

Президенты Указы

«Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән өчен: язучы **Ахунов** Гарифҗан Ахунҗан улына, язучы **Гыйләҗев** Аяз Мирсәет улына, язучы **Мәһдиев** Мөхәммәт Сөнгать улына «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты**

**М. Ш. ШӘЙМИЕВ.**

Казан, Кремль,
1993 ел, 24 декабрь.

Гариф АХУНОВ

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ



«Өч баһадир». Өч дус: Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Гариф Ахунов. Балтач, 1994

станет серьезным явлением в татарской прозе. Ибо юноша силен в двадцать лет, поэт может быть сильным в любом возрасте, а для прозаика пятьдесят лет – самая плодотворная пора.

Обо всем этом я подумал, глядя на снимок, опубликованный в «Красной Татарии» двадцать восемь лет назад...

*Мухаммет Магдеев,*
народный писатель Республики Татарстан
*1975, сентябрь*

# Миңа-ансыз-күңелсез

Гариф абый Ахунов турында үзе исән чакта да уйлана идем мин. Уйларымның кайберләрен үзенә дә әйткәләп тордым. Ул йә сүзләремне уенга борып кычкырып көлә, йә кызып-кызып бәхәсләшә, йә минем белән килешкәндәй итә иде.

Гариф Ахуновның кем икәнен аңлар өчен, ул туып үскән заманны, аның кеше буларак чыныккан, язучы буларак формалашкан чорга күз салырга кирәктер.

Гариф абый кече яшьтән үк ятим калган кеше. Ятимлек төрле кешедә төрлечә эз калдыра. Берәүләрне ул кырыс итә. Кагылып-сугылып йөрүләр аның кешеләргә ышанычын киметми, ул үзен үзе якларга өйрәнә. Алар хәтта зур дәрәҗәләргә ирешсәләр дә, күп нәрсәгә шикләнеп карыйлар. Мин, мәсәлән, Габдулла Тукайның – шундый бөек талантның кырыслыгын шуннан күрәм. Хәтта аның чын мәхәббәткә ышанып ук җитмәве, шуның аркасында хатын-кызлардан читләшүе ятимлек нәтиҗәседер дип аңлыйм.

Кемнәрнедер ятимлек яраклашырга мәҗбүр итә.

Алар, тормышта югалып калмас өчен, кемнәргәдер сыеналар, әти-әниләреннән алып өлгермәгән күңел җылысын бүтәннәрдән эзлиләр, аларга тиңләшергә тырышалар. Мондый ятимнәр үзләре дә кемнәрнедер сыендырырга, аларга яхшылык эшләргә тырышалар. Гариф абыйда, минемчә, шул сыйфат бар иде. Еш кына ул дәрәҗәле язучылар белән аралашуын кат-кат сөйләргә ярата иде. Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Мостай Кәрим, тагын бүтәннәр белән бер табында утыруларын, аларны зурлап тостлар әйтүен, аларның Ахуновны мактауларын тәмләп сөйли иде. Алар сөйләгән мәзәкләрне репертуарында саклый иде. Миңа калса, әлеге язучыларның, талантларыннан бигрәк, биләгән дәрәҗәләре күбрәк сокландыра иде сыман Гариф абыйны.

Мин бу хакта бер тапкыр Гариф абыйның үзенә әйттем:

– Мин дә аларны хөрмәт итәм, сез бит үзегез дә бәләкәй кеше түгел, аларга табынасыз, нигә, аларны күтәргәндә, үзегезне түбән төшерәсез? – дидем.

Болай турыдан ярганга үпкәләр дигән идем, үпкәләмәде Гариф абый, көлмәде дә, бәхәсләшмәде дә. Бераз уйланып торганнан соң:

– Ятимлектәндер ул. Мин бит ятим үстем, – диде.

Ятимлек, ул үскән чактагы тормышның авырлыгы Гариф абыйда яшәргә тырышу сәләтен нык тәрбияләгән. Ул гына түгел, кыен ашап үскән аның яшьтәшләре дә тешләретырнаклары белән тормышка ябышып яшәргә өйрәтелгәннәр иде. Гаҗәеп тырыш кеше иде Гариф абый, җыелышларда да язып утыра иде ул хәтта. Гариф Ахунов язып калдырган көндәлек дәфтәрләрнең иге-чиге юктыр. Киләчәктә кемнәрдер алардан бик оста файдаланырлар әле.

Мәскәүгә съездларга баргач, без җыелышып бәйрәм итеп ала идек. Бәхәсләшеп, бер-беребезне макташып, мәзәкләр сөйләп, төн урталары узганын да сизми кала идек. Икенче көнне барыбыз да аңгы-миңге урын өстендә ятканда, Гариф абый, иртәнге сәгать биштә өстәл янына утырып, әллә ничаклы язган була иде инде. Без торып азапланганда, сызгырынып, елмаеп-көлеп йөрер иде.



Гариф Ахунов белән Туфан Миңнуллин. 1984

Эшсез йөргән Гариф Ахуновны мин белмим. Хәтта ул, кешеләр белән сөйләшкәндә дә, вакыт-вакыт онытылып китә, эшләнәсе эше турында уйлый, әңгәмәдәшен тыңламый-ишетми башлый иде. Аның кебек тырыш язучылардан мин Габдрахман Әпсәләмов, Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллинны гына беләм. Ни кызганыч, яшьләребезнең күбесенә алардагы тырышлык җитенкерәми. Гариф абый бәйрәм итәргә ярата иде. Әмма эш хисабына бәйрәм итмәде. Туктаусыз кайнап торган казан иде ул.

Гариф Ахунов буыны әдәбиятка сугыштан соң ук килеп керде. Илнең хәлсез чагы. Язучыларның һәм язучы булырлык татар яшьләренең күбесе сугыш кырында ятып калган. Сугыш алдыннан гына татар әдәбиятының шактый талантлары атылган, атылмаганнары лагерьларда. Утыз җиденче елның кара күләгәсе ил өстендә өркетеп йөри. Сталин үзе үлсә дә, өрәге яши. Дөньяга хак сүзне әйтергә тиешле иҗат кешеләре идеологик кысаларга кысып кертелгән.

Шул шартларда кулларына каләм алган яшьләр, алга-артка, уңга-сулга карангалап, идеологик хата китмәсен дип, һәр җөмләне кат-кат уйлап-тикшереп карарга мәҗбүр ителгән. Узыныбрак китеп, кыюрак фикер әйтсәләр, дошман дигән ярлык тагалар да язганнарын сызып ташлыйлар.

Талантлы язучылар бәргәләнә. Күбесе яраклаша. Шәхес юкка чыга. Бертөсле уйламасалар да, бертөсле язучылар күбәя, матбугатны бертөсле әсәрләр басып китә.



Гариф Ахунов белән Туфан Миңнуллин

Әнә шул өркетелгән язучыларның бертөсле әсәр язуы сиксәненче еллар ахырына хәтле диярлек дәвам итте. Хрущевның шәхес культын тәнкыйтьләве бераз вакытка төннекне ачса да, җанга сеңгән курку хисе барыбер бетмәде.

Заманның шушы фаҗигасе, әлбәттә инде, Гариф абыйны да читләтеп үтмәде. Тормышында да, иҗатында да. Кирәгеннән артык сак булды ул.

Ил өстендә демократия җилләре искәч, Гариф Ахунов ачылып китте. Ул, «Идел кызы» романын язып, татар әдәбиятына искиткеч образ – Габбас мулла образын бүләк итте.

Ифрат юмарт кеше иде Гариф абый. Без, җыйнаулашып, еш кына аның кесәсен бушата идек. Кешеләрне сыйлаудан тәм таба иде ул. Ярдәмчел кеше дә



Татарстанның һәм Башкортстанның күренекле язучылары белән. Сулдан уңга: Гариф Ахунов, Әсгать Мирзаһитов, Гөлшат Зәйнашева, Әнгам Атнабаев, Туфан Миңнуллин, Марат Кәримов, Илдар Юзеев

иде. Аның ярдәме белән шактый гына язучылар фатирлы булды, китапларын чыгардылар.

Мин Союзда рәислек иткәндә, Гариф абыйның миңа мөнәсәбәте үзгәрмәде, элеккечә дустанә булып калды. Шуның өчен мин аңа рәхмәтле булдым. Күңеле белән чиста кеше иде ул, хөсетлек юк иде аңарда, астыртынлык юк иде.

Гариф абыйсыз күңелсез миңа бу дөньяда. Аның тозлы һәм тозсыз мәзәкләре җитми. «Туп-туп кына басып килә көмеш тояк тулпар атым» дип җырлаганда, «һә-ә-й!» дип кычкырып җибәрүләре, безнең гаиләдә биш язучы бар, дип наив мактанулары, минем берәр язганым күңеленә хуш килгәндә шылтыратып котлаулары, юктан да кызык табып, рәхәтләнеп көлүләре җитми. Заман кырыслана бара, әдәбият тирәсендә ертлачлар күбәйгәннән-күбәя, «җүләрләр» кимегәннән-кими, шул чакта Гариф абыйны сагынам. Миңа ошаган һәм мин кабул итеп бетермәгән яклары белән сагынам мин аны. Ни генә булса да, безнең аралар ихласлыкка корылган иде, без бер-беребез белән уйнамадык.

*Туфан Миңнуллин*
Татарстанның халык язучысы
*2001, февраль*

# Ул-шәхес-иде

Олы шәхес дип һәр тарафтан җитлеккән, мәгънәле, милләтенә, нәселенә, гаиләсенә бирелгән камил кешегә әйтәләр. Гариф Ахунов турында сүз чыкканда, аны искә алганда, нәкъ менә шул билгеләмә телгә килә. Мәсәлән, мин аның кебек төрле буын, язмыш, холык кешеләре белән тиз мөгамәлә урнаштыра, уртак тел таба алган, тиз арада «үз кеше» булып китә белгән башка язучыны хәтерләмим. Беренче шигырен, хикәясен күтәреп килгән каләм тибрәтүче, әле генә лаеклы ялга чыккан полковник, авыл игенчесе, шахтадан туган ягына кайтып килүче күмер чабучы, үз ялганына үзе ышанган балыкчы дисеңме, Гариф абый һәммәсенең күңеленә ачкыч ятатыр, хәлен сорашыр, шаяртып алыр, кирәк чакта юату җөмләсен кыстырып кую әмәлен табар. Җиңел адымлы, терекөмеш кебек хәрәкәтчән, яңгыравык тавышлы Ахунов дигән дустыбызның арабыздан китүенә һич кенә дә ышанасы килми. Аның җанлы сыны күз алдында, күңелдә, хәтердә.

Менә ул җыелышта сикереп торыр да як-якка сибелеп төшкән, артык мөстәкыйльлеккә чыккан чәчләрен тәртипкә китереп алыр һәм:

– Егетләр, дуслар, миндә башкачарак фикер бар бит әле,– дип сүзен башлап, уен, ниятен дәлилләп, ачыклап бирер, ашыкмыйча, берәүне дә рәнҗетмичә, үз фикерен үткәрергә тырышыр иде.

Аның уңай сыйфатларын атый-саный китсәң, олы бер китап язарга кирәк булыр. Иң әүвәл аның каләмдәшләренә булган мөнәсәбәтен генә алыйк.

Кулына бәяләү өчен йомшак, зәгыйфь әсәр килеп керсә дә, Гариф абый каләм иясенең түшәмен, сәләт дәрәҗәсен чамалап, күтәрелеп бәрелмәс, авторның күңелен җәрәхәтләмәс. Җайлап, ипләп кенә дөньяда башка һөнәрләр барлыгын, кызыклыгын искә төшерер. Әдәби эзләнүдә кызыклы фикер, борылыш, гомумән, үсеп китәрдәй оеткы тапса, ул кызганмыйча киңәшләрен бирер, ярдәм кулын сузар. Әсәрен бастырып чыгарырга ярдәм итәр. Әдәбият бусагасын атлаган сәләтлерәк кеше әйберен ашык-пошык әвәләп китерсә, ул чакта Гариф абыйдан яхшы сүз көтмә дә, үпкәләмә дә.

– Карале, дускаем, әсәрең әйбәт кенә буласы икән, ашыккансың. Вакыйгаларыңның очы очка ятмый. Сүзләрне – карлыгачларны – уйлап бетермичә очыргансың,– дип тезеп китә.– Ат дагалаганда бака ботын кыстыра, димә, менә мин, «Тын Дон»ны тәрҗемә иткәндә, Шолоховның бер җөмләсе белән ике көн утырдым. Мәгънәсен биреп кенә булмый бит. Эчтәлеге килеп чыкса, сәнгатьчә матурлыгы югала. Ә син кабалангансың, алай килешми. Салкында тунны төймәләгәндә генә ашыгу килешә.

Гариф абыйның тәнкыйте ничек кенә җайсыз, усал булып, автор эчтән генә сыкранса да, риза була, аек дәлилләре белән килешә. Чөнки ихластан, изге ният булсын, татар әдәбиятының олы абруен төшермәслек әсәр өстәлсен, дип әйтелгән тәнкыйть ул, май чүлмәге кебек, тышыннан күренеп тора. Иҗат әһеле тәнкыйтьнең йөрәктән, әсәрне яхшырту өчен әйтелгәнен кешенең рухын сындыру өчен, ачу белән чыгарылганыннан тиз аера.



Утырганнар (сулдан уңга): Флүс Латыйфи, Рәдиф Гаташ, Рашат Низамиев, Хатыйп Миңнегулов, Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баян, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин; басканнар (сулдан уңга): Харрас Әюпов, Ркаил Зәйдулла, Шәүкәт Галиев, Миркасыйм Усманов, Зиннур Хөснияр, Тәлгат Галиуллин. Казан

Гариф абыйның тормышын да, иҗатын да башка берәү белән бутау мөмкин түгел, һәр очракта ул кабатланмас шәхес булып кала алды. Әдәби очрашуларда, кичәләрдә аларны – өч дусны – Г. Ахунов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗевне бергә еш күрергә мөмкин иде. Бу – табигый. Талант һәрвакыт үз ишенә тартыла. Алтмышынчы еллардан алып бу өч сүз остасы татар прозасының, өлешчә драматургиясенең дә әйдәп баручы йөзен билгеләүче язучылар буларак танылдылар. Һәркайсы авыр, кабатланмас тормыш юлы узган, какканны-сукканны җитәрлек татыган. Ә инде И. Гази, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, А. Расих, Ф. Хөсни кебек олы затларыбыз дөньяны калдырып киткәч, әдәбият дилбегәсе алар кулына күчә. Иҗатлары да, үзләре дә бер-берсенә охшамаган, әмма уртак максат, рухи биеклеккә омтылыш, милләт киләчәге өчен җан атып яшәү каләм ияләрен якынайта. Миңа алар өчесе бергә туры килгән очракларда юлдаш булгаларга туры килде. Бу хакта язып чыкканым да булды. Гадәти, шул ук вакытта мәгънәле, дустанә һәм кинаяле сөйләшүләр, башкалар өчен сәеррәк тоелырга мөмкин булган төрттерүләр. Аларны якыннан белмәгән кеше берни аңламый.

Татар халкы тудырган бу өч олы шәхеснең үзара аралашуындагы ихласлыкка, кешелеклелеккә, тулы ышануга, бер-берсен чеметкәләп, сәнгатьчә камиллек үрләренә әйдәп бара белүләренә сокланмый мөмкин түгел. Бераз шаяртып, җиңелчә көлешеп, күңелләрен ял иттереп, рухларын тазартып алганнан соң, халкыбыз тарихын дөрес өйрәнү, бәяләү, әдәбият мәйданының халәте, яшь көчләр турында югары кимәлле,

җитди сөйләшүләр башлана. Өчесен дә бер үк дәрәҗәдә татар халкының яшәү рәвеше, үз язмышына битарафлыгы, киләчәге, туган тел язмышы борчый.

Гариф абый, урамнарга ташып чыгып, шигарьләр күтәреп кычкырышып йөрмәсә дә, милләте өчен кайгыра, аның уңай якларын күреп шатлана, үзен тиешле югарылыкка куя белмәве өчен борчыла, гарьләнә иде. Ул татар халкының олы әдәбиятына гашыйк, аңа бирелгән, нәфис сүзнең кешене рухи сәламәтләндерә алырлык көченә ышанып яши иде һәм, депутат буларак та, Язучылар оешмасының җитәкчесе булган вакытта да әдәбият әһелләренең матди хәлен күпмедер рәтләү өчен барысын да эшләргә тырышты. Ә инде яңа темага керешү, әсәр язу аның өчен шатлык, сөенеч чыганагы гына түгел, ә яшәү рәвеше, терелткеч дару да иде. Аның күңеле, сизгер сейсмограф кебек, тормыш җилләрен, замана кыйбласын сизеп, шатлану, тетрәнүләрен тоеп тора. Чынлыкка дөрес бәя бирә белгән кеше буларак, милли аңның, бердәмлекнең хәзерге дәрәҗәсендә тулы азатлыкны сугышып алып булмасын аңлый иде. Явызлыкны акыл, фәлсәфи, әхлакый өстенлек белән генә алдырып булганын ул сиземли. Шуңар да ул яшьләрне туктаусыз укырга, эзләнергә, кыюрак булырга чакырып торды.

Демократия җилләре исеп һәм фикер иреге чоры килгәч, Г. Ахунов иҗаты тирәсендә бәхәсләр дә булып алды. Әдәбият дөньясында бу табигый хәл. Сүз сәнгате фикер төрлелегеннән башка яши дә, үсә дә алмый. Язучылар оешмасы коридорында, төрле редакцияләрдә, үзара аралашуларда мондыйрак сораулар ишетелде: «Кара алтын табучылар турында, аларның хезмәтен романтик бөеклеккә күтәреп, болай илһамланып, «Хәзинә», «Хуҗалар» кебек романнарны язу кирәк булдымы икән?» «Идел кызы» романы исемен аклыймы? Аның каһарманы мондый яңгыравык атамага лаекмы?»

Төрле суларны айкаган, көфер фикерләрне чайкаган дулкыннар ярларына катып, аек акыл өстенлек ала башлагач, мондый сорауларны бирүчеләр азайды. Гариф Ахуновның тирән уйлар, җитлеккән тойгы-кичерешләр белән иҗат ителгән әсәрләренең алга карап, заман сулышын тоеп язылган икәнлеге, вакыт чигенгән саен, тулырак ачыла бара. Һәр әдәби әсәрнең үз вакыты, үз сәгате була. Әйтик, бүген Мирсәет Ардуанов турында да, нефть чыгаручылар хакында да Ахунов әсәрләрендәгечә язып булмый. Хәзергәчә яшәсә, әлеге хәлләр, вакыйгалар, батырлыклар турында Гариф абый да башкачарак язар иде. Ләкин сәнгатьчә югарылыкта иҗат ителгән әсәр, үзәккә алынган вакыйгаларга карап, мөнәсәбәт, кыйбла үзгәрү белән, үзенең кыйммәтен югалтмый. Һәр чор әдәби әсәрне үз сәнгатьчә әзерлегеннән, иҗтимагый ихтыяҗыннан, сәяси тормышыннан чыгып бәяләргә тиеш. Әдәбиятның үзенчәлеге дә шуннан гыйбарәт. Татарстан нефте гөрләп аккан чорда олы каһарманнар, фидакарь шәхесләр туа; тетрәнүләр, шатлыклар, фаҗигаләр, бәхетләр – һәммәсе аяк астында. Күпмедер вакыт узганнан соң, ул чорда яшәгән кешеләрнең батырлыгы урынсыз, үзләрен аямыйча эшкә бирелүләре елмаю уятыр, булсын дип үрсәләнүләре көлке тудырыр. Ләкин укучы үзен шул чорга куя белергә тиеш. Әйтик, Г. Ибраһимов белән Г. Исхакыйның гасыр башында язылган әсәрләрендә, хәзерге яшәешебез белән чагыштырганда, сәерлекләр азмыни? Зыя хәзрәтнең мунчада скрипка уйнаулары, ирнең өч хатын белән интегүләре сәер, гаҗәп түгелмени? Мәсьәләгә икенче яктан килик. Берзаман кара алтын катламнары суырылып бетәр, табигатьнең кояш җылысы, ай нуры, битум кебек байлыкларын эшкә җиккән адәм балалары Татарстан нефте, шул чорда яшәгән ихлас һәм дуамал кешеләр турында мәгълүматны шул китаплардан гына алыр. Татарстан нефте, башка мөстәкыйль илләрдәге кебек, төп халыкка әллә ни бәхет алып килмәде, тирә-юньне пычратты, табигатьне начар якка үзгәртте, дип әйтүчеләр табылыр. Бу сүзләрдә хаклык барын таныган хәлдә, шуны искәртәсе килә: юллар төзелде, яңа калалар күтәрелде, һәм кемнәрдер (шул исәптән шул эш белән шөгыльләнүчеләр) нефть акчаларының рәхәтен бик яхшы татыды, ниш-

лисең, Ходай Тәгалә адәм балаларын тигез яратмаган шул. Ә «Хәзинә», «Хуҗалар» һәм «Идел кызы» романнары әдәбият тарихында калачак әсәрләр. Соңгы романның төп каһарманнарыннан берсе шактый үзенчәлекле, кабатланмас шәхес булып чыкты. Сүз Габбас мулла хакында бара.

Ясалма күннән эшләнгән кара кепкасын бастырып кигән Гариф абыйның җыйнак гәүдәсе офыкта күренүгә, язучылар йорты тирәсендәгеләрнең берсе, сүзне башкалар авызыннан тартып алып, хәбәр бирә:

– Җәмәгать, шауламагыз, Габбас мулла килә.

Шул кушамат Ахуновка чәер кебек ябышты. Чөнки Габбас мулла «Идел кызы»ның бер герое гына булмыйча, Гариф Ахунов прозасы ачышларыннан берсе булды. Язучы еш кына әдәбият тарихына бер әсәре, бер образы белән кереп кала. Гариф абый каләменнән төшкән башка характерларны да кимсетмәстән, Габбас мулла образының үзенчәлекле, кабатланмас кеше булуын искәртәсе килә. Ул үз сыйныфы кысаларына, кабул ителгән, күнегелгән күзаллауларга, кагыйдәләргә сыешып бетмәгән хәзрәт булып чыкты. Татар әдәбиятында, бигрәк тә динсез совет чорында, руханиларны артта калган, томана, үз мәнфәгатьләреннән башканы белмәгән, еш кына җенси азгын комик затлар, шымчылар итеп сурәтләү модага кергән иде. Без шул гадәткә, дөресрәге, гадәтсезлеккә күнеккән идек инде. Дин әһеле милләтне артка сөйрәүче, мәдәниятне санга сукмаучы, ач күзле булырга тиеш. Аның бар кайгысы – корсак тутыру. Гариф абый каләме тудырган Габбас мулла бөтенләй башка калыптан сугылган. Ул дин хезмәтчеләренә мөнәсәбәтне үзгәртеп, офыгыбызны киңәйтеп җибәрде. Габбас хәзрәт дөньяга карашы, үзен тотуы, хакимият даирәләренә мөнәсәбәте белән әзер кысаларга сыймый, еш кына үз сыйныфында кабул ителгән кагыйдә-тәртипләрне боза, чыгымчы ат кебек ватып-җимереп чыга. Аңа җәмгыятьнең катгый кануннары тар: яңа хакимият шартларына җайлаша алмыйча бәргәләнә, тәртәгә тибә, чыгырдан чыга. Ул баш иеп, мескен кеше булып, һәр нәрсә белән килешеп яшәргә теләми, аның гыйсъян йөрәге, тынгысыз җаны ирек, мөстәкыйльлек таләп итә. Әлбәттә инде, кешене почмакка куып керткән, тулы буйсынуны таләп иткән совет җәмгыяте, шул исәптән якын кешеләре, андый бунтарь, үзсүзле, үзфикерле кешене кабул итмиләр, аны рәнҗетәләр, җәберлиләр. Җәмгыять белән башимәс шәхес арасындагы конфликтның кем файдасына хәл ителәчәге мәгълүм иде. Шәхес сытыла, имгәтелә, юкка чыгарыла. Башка мохиттән булса да, совет җәмгыяте өчен җайсыз кешене Б. Пастернак доктор Живаго образында тудырды, шул әсәре өчен, акчасын алып, рәхәтен күрмәсә дә, әдәбият өлкәсендәге Нобель исемендәге премиягә лаек булды.

Гариф Ахунов Габбас мулла образына җир йөзендәге тәртип, шәхес иреге, уйлы кеше белән өстән көчләп тагылган кануннар, кыскасы, җәмгыять белән аның бер әгъзасы арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турындагы уйлануларын салган дигән тойгы-хис кала. Шигърияткә гашыйк, үзе дә иҗатка хирыс Живаго образында тәнкыйтьчеләр Борис Пастернакның үзе белән уртак чалымнар тапсалар, ни өчен Габбас мулла образына Гариф абый күңелендә йөрткән кайбер «көфер» фикерләрне салмаска тиеш иде. Бәлки әле, Гариф ага үзе дә, Габбас мулла кыйбласында торып, аның белән килешеп, хәтта үзенең җәмгыятькә мөнәсәбәтен, сәясәтне бәяләвен каһарманына йөкләгәндер, үз уй-хисләрен аның авызына, язмышына салгандыр. Әдәбият дөньясында андый хәлләр дә булып тора.

1999 елның сентябрь урталарында мине көтмәгәндә авыр чир аяктан екты. Сәламәтлекнең артык кадерен белмичә, көне-төне эшләп, дөнья куып йөрүнең очы күренде, бер елга якын әдәби хәрәкәттән, яраткан укыту эшемнән, дусларымнан аерылып тордым.

Инде аякка басып, язучылар йортында күптән күрешмәгән каләмдәшләрем белән беррәттән, Гариф абыйны да очраттым.

– Тәлгат, нихәлләр, – дип кочаклап алды, авызын киң итеп җәеп. – Чирләп алдыңмы? Борчылма, чират җиткәндер, берәүне дә калдырмый, барыбызны да вакыт-вакыт тикшереп тора Ходай Тәгалә.

– Булды шул, Гариф абый, – дим, гаепле кеше сыман.

– Үз төсеңә кайтып барасың. Элеккеге бюрократ Галиуллинны хәтерләтәсең инде. Тик аякта калган бугай. Бетәр анысы.

– Анысын үзем сорап алдым. Алтмышны узгач, безнең нәселгә бераз аксамыйча килешми. Галиулла бабам беренче Герман сугышында аягына төзәлмәс яра алган. Әти Нәбиулла карт икенче Герман сугышыннан чатанлап кайткан, берничә елдан соң аягын калдырган. Миңа да бик төз булып, уклау йоткандай арка катырып йөрү килешми дип, герман ботинкасы – «Саламандер» алып кидем дә, ул аякны кырды, – дип шомартам.

Минем шаяртуның бәясен аңлаган Гариф абый, коридорны тутырып шаркылдап көлде дә, аркадан сөеп: «Молодец, терел, син әле безгә кирәк», – дип, үзен ашыгып көтеп торган шагыйрьләр янына юл алды.

Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин авызыннан «иң юмарт язучы» дигән бәяне алган Гариф абыйны кесәләре һәрвакыт Фантомас башы кебек такыр яшь каләм тибрәтүчеләр түземсезләнеп көтеп алалар һәм беркайчан да ялгышмыйлар. Гариф абыйлары бу юлы да аларны хурлыклы үлемнән коткарып кала.

Гариф абый, аңлавымча, гомере буена табигатьнең иң югары казанышын – кеше дигән затны аңларга тырышып яшәде. Аның каләме тудырган әсәрләрне, аларның каһарманнарын гына күз алдына китерик. Күбесе үз көнен үз хәләл көче белән күрә торган хезмәт кешесе. Шул ук Ардуан батырны алыйк. Бу затның физик һәм рухи җегәре ачылып, актарылып китүдә режимның катнашы зур түгел, ди автор. Хакимият тик кешегә үзен кызганмыйча эшләү өчен шартлар гына тудыра, дуамалларны ирештереп, хуплап, җелекләрен суырып тора. Әлмәт якларында нефть бәреп чыгып, иҗади хезмәт өчен мөмкинлекләр ачылгач, Гариф абый шул тарафларга юл тота. Андагы алдынгылар турында илһамланып язса да, ул халык байлыгын, җир байлыгын ерткычларча суыруны хупламады, кеше дигән затны олылады, башкарган бөек эшләренә соклануын яшермәде. Бу соклануы татар теленең нәфис сәнгати чаралары ярдәмендә укучыга җиткерелде.

Гариф Ахунов тел бизәкләренә ифрат сизгер шәхес иде. Берәр матур сүз, яңарак чагыштыру ишетсә, шуны көннәр буенча кабатлап йөрер иде. Иҗатында ул купшы, нәфис сүзләр эзләми. Халык телендәге иң гадәти сүзләрдән яңа гыйбарә-сынландырулар үреп, аларны, тәсбих төймәләре тезгәндәй, матур, пөхтә җөмләләргә үстерә. Аларның нәфис бизәкләренә сокланып, читкәрәк китеп озын-озак итеп карап, тәэсирләнеп тора. Шундый олы зат булып ул күңелдә мәңгегә урнашып калган.

Тәлгат Галиуллин,<br>әдәбият галиме, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе

# Якты-кеше-иде

...Бервакыт ул мине кызык итте, күңелгә рәхәтлек тудырып, яхшы мәгънәсендә кызык ясады. 1987 елның октябрь ахырында, ноябрь башында без – Гариф Ахунов, Әхмәт Гадел һәм мин – Минзәләгә командировкага бардык. Баруны ул вакытта Язучылар берлегендә эшләүче Әхмәт оештырды. Төп максатыбыз – Минзәлә театры коллективы белән очрашу, театрның бүгенге репертуары белән танышып, фикерләр әйтү, бүгенге татар драматургиясенең хәле турында сөйләшү-аралашу иде. Эш моның белән генә бетмәде. Хуҗаларыбыз безнең килүдән киңрәк файдаланып калырга ниятләгәннәр: Минзәлә педагогия училищесында студентлар белән, Бикбау авылы колхозчылары һәм мәктәп укучылары белән, Татарстанның 50 еллыгы исемендәге колхозның терлекчеләре белән очрашулар оештырдылар. Әлбәттә, боларның үзәгендә бу якларны, андагы кешеләрне яхшы белгән, мондагы кешеләргә нык таныш Гариф Ахунов торды. Без исә: Әхмәт Гадел шигырьләр укып, мин бүгенге театр һәм драматургия турында сөйләп, аңа булдыра алганча ярдәм итәргә тырыштык. Узып кына барышлый булса да, авыл кибетләренә дә сугылдык: ниләр бар? Китаплар бармы, сатыламы? Бер кибеттә Гариф абыйның күзе зур вазага төште. 80–90 сантиметрлы матур ваза. Карыйбыз, ул аны ала ук башлады. Ун сум ул вакытлар өчен зур бәһа. Мин әйтәм: «Гариф абый, Казанда беткәнмени инде вазалар, эзләсәң, әллә нинди матурларын табып була ич, – дим. – Менә, ике куллап күтәреп йөр инде», – дип көләм. Дәшми, алды. «Бир, күтәрешеп йөрим, ярдәм итим», – дигәч тә, бирми. Фермада терлекчеләр белән очрашу тәмамланыр алдыннан, Гариф абыебыз әйтмәсенме: «Хөрмәтле дуслар, сезнең алда, сезнең исемнән мин бер күңелле вазифа үтәмәк булам. Әле шушы көннәрдә генә безнең каләмдәшебез һәм дустыбыз, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, Казан университетының әдәбият кафедрасы мөдире Азат Әхмәдуллин профессорлык исемен алды. Ел башында ул, Алма-Атага барып, докторлык диссертациясен яклап кайткан иде, инде менә профессор булды. Әйдәгез, аны шушы иҗат уңышы белән котлап, шушы көннең билгесе итеп, аңар бүләк тапшырыйк!» – ди һәм минем кулыма вазаны тоттыра. Хәйран калам. Шулкадәр игътибарлы, мәгънәле булырга кирәк бит! Инде вазаны ике куллап кочаклап йөрүче мин булып калдым. Казанга кайтканда, самолетта да мин аны кадерләп кенә алдыма куеп, кочып кайттым, юлдашларымның астыртын гына елмаешып утыруларына һич исем китмәде. Юл буе бу дәрәҗәле һәм мәртәбәле кешенең, олы язучының игътибарлы, кече күңелле булуына сокланып-уйланып кайтам. Ә инде өйдә хатыным Фирояның ах-вах килеп гаҗәпләнүләрен язып тормыйм...

Хәер, Гариф абыйның холкындагы мондый сыйфатлар минем өчен бөтенләй дә билгесез дип тә әйтеп булмый. Аны мин күптәннән беләм. Әле 1951 елның сентябрендә Шәһидә апа белән алар мине туйларына чакырганнар иде. Аңарчы белмәгән-күрмәгән яшь бер егетне туй кадәр туйга чакыруның төп хикмәте – мин ул чорда студентлар арасында гармунчы буларак танала башлаган идем. Дүрт бармак белән генә аккордеонда уйныйм. Ни өчен шулай, аккордеон биш бармак белән уйнала торган уен коралы бит? Тальян һәм хромка гармуннарында уйнап үскәнгә, минем өчен шулай уңайрак иде. Үзенә күрә төрле бию көйләрен дә маташтырам. Туйдан хәтердә калганнары әллә ни күп түгел: яшь килен белән кияүнең чибәрлекләре, пөхтә-матур киемнәре, мәҗлестәгеләрнең үзләрен



Ризван Хәмит, Гариф Ахунов, Ринат Мөхәммәдиев, Шәһидә Максудова, Аяз Гыйләҗев, Шәүкәт Галиев, Азат Әхмәдуллин. Казан, 1996

бик тәртипле тотулары, күңелле итеп утырулары, фатир алдындагы мәйданчыкка чыгып биюләре һәм... бик тә тәмле ашның бер генә тәлинкә бирелүе (ә без бит авыл малае – ике-өч тәлинкәсез тамак туймый!). Менә шул туйда гармунчы булуым мине бу гаиләгә якынайтты. Гариф абый да, Шәһидә апа да аны һич кенә дә онытмадылар, җае чыккан саен, «ул безнең туйда гармунчы иде» дип, гел искә төшереп тордылар.

Студент Гариф Ахуновны искә төшерерлек икенче очрак – аның диплом яклавы. Хәтерлим, университетның төп бинасындагы зур гына бер аудиториядә булды ул. «Яклауга керергә һәркемгә ирек» дигәч, беренче курстан без – берничә студент – «ничек була икән ул?» дип кызыксынып, шунда кердек. «Гомәр Бәширов әсәрләренең теле» дигән темага 5 нче курс студенты Гариф Ахунов диплом яклады. Туенда үзен бик басынкы тоткан, аз сүзле егет бу юлы үзенең яшь, яңгыравыклы тавышы, очынып сөйләве белән хәтеремдә уелып калды. Мин гомерем буена яклауда дипломант үзен шулай тотарга тиештер дигән үрнәк алып калдым.

Әйткәнемчә, «туйдагы гармунчы»сын Гариф абый гомере буе онытмады. Аның бер чагылышы турында алда сүз булды инде. Ул аны бер генә юбилееннан да калдырмады, мөһим эшләргә тартырга тырышты.

...1974 елның июнендә без бер төркем язучылар: Риза Ишморат, Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, режиссер Равил Тумашев, тагын берничә театр эшлеклесе Уфага татар һәм башкорт драматургиясе турында киңәшмә уздырырга барган идек. Киңәшмәнең иң кызган вакытында мине «Казаннан» дип телефонга чакырып алдылар. Гариф Ахунов икән. Ул – бу вакытта Татарстан Язучылар берлеге рәисе. Телефоннан: «Әгәр сине язучыларның әдәби фонды рәисе итеп сайласак, син ничек карыйсың, ризамы?» – дип сорады. Җәмәгатьчелек тәртибендә башкарыла торган бу эш бик җаваплы. Әдәби фондка язучыларның ялын оештыру, сәламәтлеге турында кайгырту (ягъни ял һәм иҗат йортларына, курорт-санаторийларга җибәрү), материаль ярдәм күрсәтү, вафат бул-

ган язучыларның гаиләләренә ярдәм итү һ.б. мөмкинлекләр бирелгән: «Аккош күле»ндә язучыларның Әдәби фонд карап тора торган дачасы да бар. Аңарчы аның рәисе булып Афзал Шамов кебек күренекле шәхесләр эшләгән. Менә шул җаваплы эшкә Гариф абый тәвәкәлләп мине тәкъдим итәргә уйлаган, партия өлкә комитетын да күндергән булып чыкты. Әдәби фонд рәисе булып мин ике дистә елга якын эшләдем, шул арада өч идарә рәисе алышынды. Бу күренекле язучылар һәм кабатланмас шәхесләр белән иңгә-иң торып эшләү миңа күп нәрсә бирде. Мин бигрәк тә Гариф абыйдан күп нәрсәгә өйрәндем. Әле җитәкчелек тәҗрибәм дә зур түгел (ул чорда мин Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында директорның фән эшләре буенча урынбасары). Кешеләр белән аралашуда, хезмәткәрләргә эш кушуда, таләп итә һәм кул астындагыларны эшләтә белүдә мин Язучылар берлеге рәисенең эш стиленә карап өйрәндем. Гариф абый һәрчак эшчән һәм хәрәкәтчән, максатчан, кәеф-холкы тигез, һәркемгә дустанә. Хәтере яхшы, вактөякне дә онытмый, аларның кешеләр язмышы белән бәйле икәнен исеннән чыгармый, идарәдәгеләрдән дә шуны таләп итә. Бик төгәл итеп, иренмичә, һәр көнне хатирә дәфтәре алып бара. Урынына, вакытына карап, эш төрен үзгәртә белә: сәгать 5 тән торып 9–10 нарга кадәр өстәл артында утырып иҗат белән талчыккан кеше, идарәгә килеп, һәртөрле хуҗалык һәм оештыру эшләренә кереп чума... Ул арада кайдадыр чыгыш ясарга кирәк, укучылар белән очрашулар көтә, югары оешмалар көн дә мең төрле йомышлар белән тинтерәтәләр, төрле справкалар кирәк һ.б. Әле генә бик җитди Гариф абыебыз икенче караганда ихластан көлә, шаярта, аңарда һич тә саекмас мәзәкләр һәм гыйбрәтле хәлләр әллә никадәр. Шуларны сөйли... Ә нинди дипломат! Партия өлкә комитеты секретарьлары, Союз күләмендә танылган язучылар Сергей Михалков, Мостай Кәрим, Рәсүл Гамзатов, Давыт Көгелтинев кебекләрдән алып гади кешеләргә кадәр ул дустанә мөнәсәбәттә. Җитәкчеләр ул чорда бик һавалы, каршы әйткәнне яратмыйлар, серкәләре һич тә су күтәрми, һәр мәсьәләдә, эштә үзләрен соңгы инстанция дип саныйлар... Бүген искә төшереп гаҗәпкә калам: Гариф Ахунов әллә нинди олы җитәкче белән дә үз дәрәҗәсен белеп сөйләшә, үз сүзен үткәрә белә, ярым шаярту рухында сөйләшү рәвешен саклый...

Партия өлкә комитетындагы бер сөйләшүне хәтерлим. Идеология бүлеге секретаре М. Ф. Вәлиев бүлмәсендә Язучылар берлеге рәисе, Г. Ибраһимов исемендәге институтның ике вәкиле (директорның фән буенча урынбасары һәм тарих бүлеге мөдире Җ. И. Гыйльманов), тагын бер-ике кеше утыра. Нинди уңай белән чакырылганбыздыр, инде хәтерләмим (берәр юбилей сәбәбе белән булдымы икән инде?!). Бераздан сөйләшү институт җитәкчелеге өчен җайсыз юнәлешкә кереп китте. Секретарь институт хезмәткәре Әбрар Кәримуллинның кулъязма хәлендәге бер хезмәте, ул институтта укылганмы, аның буенча фикер алышынганмы икәне турында сораша башлады. Аннары инде институт җитәкчелегенең «чиле-пешле хезмәтләр» язылуга юл куюы өчен тәнкыйтьләргә үк (дөресрәге, әрләргә) кереште. Авторның үзен чакырып, аның үзенә әйтелергә тиешле таләпләр куя башлады. Әрләү инде иң югары ноктаrange менеп җитте... Шул вакытта тыныч-сабыр тавыш белән Гариф Ахунов сүзгә катнашмаса һәм аны кичектергесез мәсьәләләргә һәм бурычларга борып җибәрмәсә, ул тагын күпме дәвам итәр дә, ни белән тәмамланыр иде, билгесез. Кыскасы, сөйләшү алга таба үз эзенә төште.

Шундый иде Гариф абый, дипломат була белә иде, еш кына гадилек, беркатлылык артына яшеренеп, җитди, авыр чишелешле мәсьәләләрне дә хәл итә, обстановканы йомшарта, үзе теләгән юнәлешкә алып керә белә иде...

Кыскасы, зур талант иясе генә түгел, күңеле белән саф, якты кеше иде ул. Һәм күңелләрдә шулай булып саклана да.

*Азат Әхмәдуллин,*
әдәбият галиме, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе
*2001, 28 март*

# Сәнгатькәрләрнең-зур-дусты

Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов, әдәбият һәм сәнгать дөньясындагы дуслары, күп меңләгән укучылары күңелендә тирән эз калдырган, туган илебезне һәм халкыбызны бөтен җаны белән яраткан, әдәбият һәм сәнгать әһелләренә һәрьяклап хәерһах булган олуг шәхес буларак, әле киләчәктә дә бик озак еллар буена үзен сагындырып яшәр. Без аның иҗаты белән әле үткән гасырның илленче елларында хикәяләре, публицистик мәкаләләре, очерклары аша таныша башлаган идек. Еллар үтү белән, аның укучылар тарафыннан хуплап каршыланган «Хәзинә», «Хуҗалар», «Идел кызы» романнары, «Чикләвек төше», «Яшьлек яме» повестьлары киң яңгыраш алды. «Хәзинә» әсәре буенча Свердловск киностудиясендә төшерелгән фильм илебез экраннарына чыкты. Аның әсәрләре буенча куелган спектакльләр дә тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителде. Ш. Камалның «Акчарлаклар» повесте буенча инсценировка авторы да Гариф дустыбыз иде. Бу спектакльдә театрыбызның күп корифейлары уйна-



Сибгат Хәкимнең иҗат кичәсендә катнашучылардан бер төркем. Беренче рәттә (сулдан уңга): Гариф Ахунов, Шәһидә Максудова, Сара Садыйкова, Сибгат Хәким, Фәхри Насретдинов, Наҗия Теркулова, икенче рәттә (сулдан уңга): Миңгол Галиев, Ринат Таҗетдинов, Вафирә Гыйззәтуллина, Айрат Арсланов, Нәфисә Васыйлова, Заһид Хәбибуллин, Дания Нуруллина, Бикә Рәхимова, Николай Беляев, Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев. Казан, 1976



Гариф Ахунов К. Тинчурин театрында нәфис сүз остасы Айрат Арслановны 60 яшьлек юбилее белән котлый. Казан. 1988


ды, спектакль Татар дәүләт академия театрының алтын фондына кереп калган уңышлы постановкаларының берсе булды. Г. Ахуновның нефтьчеләр тормышыннан алып язылган беренче спектаклендә буровойда эшләүче нефтьче егетләрнең берсен уйнау миңа да насыйп булган иде. Әйе, Гариф Ахунов сәхнә кешеләре белән – драма театрында эшлиләрме алар, эстрада сәнгатендәме яки җыр һәм бию ансамблендәме, шулай ук кино, радио, телевидениедә хезмәт итүчеләрме – дусларча самими мөгамәләдә була белә иде. Шәхсән минем үземә Г. Ахунов белән республикабызның районнарында, илебезнең төрле төбәк шәһәрләрендә, башкалабыз Мәскәүдә уздырыла торган төрле әдәби очрашуларда, юбилей тантаналарында еш булырга туры килә иде. 1972 елда Ворошиловград өлкәсендә, 1980 елда Каракалпакстанда үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә катнашканыбыз бүгенгедәй хәтеремдә саклана. Минем шәхси архивымда Гариф дустыбыз белән бергә төшкән дистәләрчә фоторәсемнәр саклана, ул рәсемнәр, төрле елларның хатирәләре буларак, күз алдына Г. Ахуновның күпкырлы иҗади һәм җәмәгать эшчәнлеген китерәләр. Туксанынчы елларның урталарында мин эшләгән филармония бинасына, бер папка тотып, Гариф килеп керде. «Менә, Айрат, сиңа кайбер шигырьләремне китердем, шуларны радиога яздырасы иде, радио редакторлары белән сөйләшенгән», – ди.

Мин бик рәхәтләнеп риза булдым. Бераздан ул шигырьләр радиодан яңгырадылар. Гариф дустым, тапшыруны тыңлагач, тирән рәхмәтен белдереп миңа шалтыратты.

Без Г. Ахуновның пьесалары өчен язган дистә ярым җыры барлыгын беләбез. Күренекле композиторларыбыз Х. Вәлиуллин, Б. Мөлеков аның пьесаларына музыка яздылар. Әлмәттә яшәгәндә, М. Имашев та аның пьесаларына музыка язды. Ф. Әхмәтов, З. Хәбибуллин, Ә. Шәрәфиев тә шигырьләренә көйләр яздылар. Ләкин Гариф җырларын популярлаштыру ягында тормады. Без Гариф дустыбызның шигырьләре күп икәнен белә идек. Ул миңа үзенең шигырьләрен китергәч: «Нигә син шигырьләреңне матбугатка бирмисең?» – дип сорадым. Ул болай дип җавап бирде: «Шигырьне мин проза телен чарлау өчен язам, шигырь ул тирән мәгънә тыгызлыгына, образлы язуга өйрәтә, мин шигырьне бастырып чыгарыр өчен язмыйм». Ә бит аның ике томлыкка җитәрлек шигырьләре булган.

Шагыйрь С. Хәким шикелле үк, Гариф Ахунов та күп санлы сәнгать әһелләре турында матур-матур мәкаләләр язган автор. Шундыйлардан җырчылар И. Шакиров, Р. Билалова, Ш. Әхмәтҗанов, драма актрисасы Г. Ибраһимова һ.б. турындагы мәкаләләре бар. Минем иҗатыма багышлап та күләмле мәкалә язган иде. Сәнгатьле сүз жанры турында үз вакытында саллы хезмәт иде ул. Бу кыска язмада Гариф Ахуновның сәнгать эшчәннәре белән киң элемтәсен язып бетерү мөмкин түгел. Без барыбыз да аның сәнгать кешеләре хакында әйткән җылы сүзләре өчен бик рәхмәтлебез. Бу язмамны Г.Исхакый бүләге лауреаты, язучы Рафаэль Сибатның бик мәгънәле сүзләре белән тәмамлыйсым килә: «Гариф Ахунов дигән әдип бервакытта да юмор-елмаюны, ирония-чеметүне, сарказм-ачы көлүне һәм, иң-иң мөһиме, яхшы күңелле булуны, шатлык-сөенечкә тулып торуны, кешеләргә карата ягымлылыкны вә кояши оптимизмны онытмый».

*Айрат Арсланов,*
Татарстанның һәм РСФСРның халык артисты




Гариф Ахунов исемендәге мәктәп музеенда Г. Ахунов китаплары. Әлмәт, 2013

# Чувствовать-биение-сердца-народа

У каждой эпохи, у каждого времени бывает свой талантливый писатель, всей душой чувствующий биение сердца народа, проницательный, зоркий, в совершенстве владеющий стихией родного языка. Примеров тому много, есть они и в татарской литературе. Мне кажется, именно таким писателем является Гариф Ахунов, чье творчество ярко и точно отражает сегодняшний день, жизнь Советской Татарии.

Пришедший в литературу в пятидесятые годы, Гариф Ахунов сейчас один из ведущих писателей. Он не одинок, рядом с ним в одном строю трудятся его сверстники, собратья по перу. Среди них – А. Гилязов, Л. Ихсанова, А. Баянов, Н. Фаттах, Р. Тухватуллин, М. Магдеев, М. Хабибуллин и другие, занявшие в современной литературе видное место. Это поколение уже вошло в пору творческой зрелости.

Творческий путь Ахунова характерен для послевоенного поколения. Детство, совпавшее с трудными годами войны. С малолетства тяжелый крестьянский труд, потом школа, учеба в техникуме... Юношеская влюбленность в литературу, мечты, надежды, поиски своего пути... И вот теперь мы видим Гарифа Ахунова в передних рядах нашей литературы. Его трудолюбие, неустанные творческие искания, богатое воображение, способность работать в разных жанрах, смелое стремление к созданию широких эпических полотен свидетельствуют о больших возможностях писателя.

Обратимся же к творческой биографии Гарифа Ахунова.

Он родился в 1925 году в деревне Училе Арского района в крестьянской семье. Рано лишился отца. Пламя ожесточенной классовой борьбы, которая развернулась в первые годы коллективизации, коснулось и семьи Ахуновых: первого председателя колхоза, организованного в деревне Училе, коммуниста Ахунзяна (отца Гарифа) варварски убивают кулаки. Этот трагический факт на всю жизнь запечатлелся в душе будущего писателя. Он трансформировался и получил отражение во многих произведениях Г. Ахунова. До 1940 года Гариф учится в сельской школе. Затем работает в колхозе. Поступает в Арское педагогическое училище, где испытывает первые увлечения литературой. Жизнь тех лет, стремления, мечты были воссозданы им позднее в автобиографических рассказах, вошедших в книги «Мы родом из Арска» (1979), «Когда зажигаются звезды» (1980).

Любовь к литературе полностью завладела юношей. В 1947 году он становится студентом историко-филологического факультета Казанского государственного университета и в 1952 году успешно его заканчивает. В пору студенчества он пробует свои силы в литературном творчестве, пишет стихи, рассказы, статьи.

Его первая повесть «Краса юности» (1955) посвящена жизни студенчества. Это – первое серьезное испытание, первый опыт, и уже он показал силу таланта молодого автора, наблюдательность, умение воссоздавать жизненные характеры в жизненных ситуациях. Это было первое произведение писателя, оно строилось в основном на биографическом материале, его герои – друзья юности автора. В этой повести писатель нарисовал яркие, запоминающиеся картины студенческой жизни. Уже первое произведение Г. Ахунова показало, что в литературу пришел талантливый писатель. Повесть сразу обратила на

себя внимание критики. Вдохновленный первым успехом, Г. Ахунов целиком уходит в литературное творчество и журналистскую работу. Много сил отдает работе в журнале «Совет эдебияты» (теперь «Огни Казани»). Один за другим выходят в свет его очерки, рассказы, критические статьи. Но писателем владеет мысль о создании широкого эпического полотна, в котором он мог бы раскрыть великие дела эпохи, показать ее людей. Для этого ему нужен жизненный опыт, нужно самому быть в гуще событий, увидеть изнутри и понять их общественно-политические и духовные движущие силы. И Гариф Ахунов приходит к верному решению – в 1956 году он едет в центр татарской нефти Альметьевск. Годы, проведенные им в Альметьевске среди нефтяников (1956–1968), оказались важнейшей вехой в жизни писателя, это были годы его творческого созревания. В Альметьевске организуется отделение Союза писателей Татарии, его ответственным секретарем становится Г. Ахунов. Сплотить молодые литературные силы, направить внимание писателей на героический труд нефтяников – Ахунов целиком посвятил себя этой задаче. Сейчас в Альметьевском отделении работает большой коллектив талантливых писателей, и в этом, безусловно, есть немалая доля труда Г. Ахунова.

Писатель ищущий, с острым политическим пером, Г. Ахунов очень активен и в общественной жизни. С 1969 года он – член КПСС. Был делегатом XXV и XXVI съездов партии, II, III, IV съездов писателей РСФСР, V, VI и VII съездов писателей СССР. Начиная с 1974 года и по сей день он работает председателем правления Союза писателей Татарии. Депутат Верховного Совета СССР девятого и десятого созывов, член пленума обкома партии, один из секретарей правления Союза писателей РСФСР и СССР. Член редколлегий газеты «Литературная Россия» и журнала «Волга». Часто выступает с проблемными статьями о современной татарской литературе. За активную работу в области развития



Арчада Гариф Ахуновка һәйкәл ачу. Туфан Миңнуллин чыгыш ясый. 2004

советской литературы Г. Ахунов удостоен почетного звания «Заслуженный работник культуры РСФСР». Альметьевские нефтяники присвоили ему высокое звание почетного нефтяника Альметьевска. В 1973 году за роман «Клад» и повесть «Ядро ореха» он награжден Государственной премией ТАССР имени Г. Тукая.

Становление Г. Ахунова как писателя, формирование его как художника, его поистине творческий взлет связаны с Альметьевском, когда он жил среди нефтяников. Здесь он, деревенский парень, открыл для себя новый мир, увидел героические дела добытчиков черного золота – нефти. Об этом сам Гариф Ахунов сказал в статье «Альметьевск – колыбель моей жизни»: «Альметьевск – город, окрыливший мечты моей юности. Альметьевск – самая главная опора в моей писательской работе, самая большая радость, город, ставший колыбелью моей жизни... Я окунулся в среду нефтяников. За двенадцать лет жизни в Альметьевске я написал и опубликовал десять книг. Годы самого высокого напряжения, самых пламенных чувств приходятся на этот период – альметьевский. Вот потому я с чувством безграничной гордости и называю Альметьевск колыбелью жизни и хочу, чтобы он становился все прекраснее, жил, глядя вперед, в светлое завтра».

И конечно же, первый и главный итог того «высокого напряжения», о котором говорит писатель,– это роман «Клад». Разумеется, прежде чем создать «Клад», роман в нашей литературе новаторский, там же, в Альметьевске, писатель переживает период поисков, создает рассказы, очерки. Выходят в свет повесть для детей «За горой Артыш», пьеса «Огонь горит в очаге» и другие произведения. Деревня Калимат из «Клада» и его герои впервые появляются именно в них. В них писатель поднимал и важные, актуальные проблемы. Однако самой большой удачей писателя, безусловно, стал его роман «Клад». И дело не только в умении писателя поднять и раскрыть серьезную тему, но прежде всего в том, что он сумел раскрыть в эпическом произведении исторические перемены в жизни народа, воздействие духа нового времени на внутренний образ жизни татарской деревни, на крестьянскую психологию, показать процессы обновления.

Главные герои романа «Клад» – простые люди: одни еще не так давно трудились на колхозных полях, другие – представители рабочего класса, прошедшие большой жизненный путь. Всех их объединяет одно желание и один святой долг: дать стране нефть и тем самым усилить ее мощь, украсить жизнь людей новой радостью, счастьем. В романе «Клад» убедительно показаны рост социального сознания народа, пафос творческого созидательного труда, его пронизывают идеи социалистического гуманизма, коллективизма и интернационализма.

Изображая труд нефтяников, их жизнь, Г. Ахунов не увлекается показом производственных процессов, рассказом о разной технике и орудиях труда, его прежде всего интересуют судьба Человека, процесс социально-психологических изменений, происходящий в его родном народе.

Соответственно этому трактуется главная идея романа, словно бы закодированная в его названии. Что такое «Клад»? На первый взгляд, конечно, речь идет о борьбе за нефть – «масло земли», об использовании этого богатства на благо народа, страны. Но такое объяснение было бы неполным и неточным. Главная идея романа выражена словами одного из его героев, старого мастера Лутфуллы-абзыя: «В газетах мы называем нефть «черным золотом». Золото. Значит, клад. Но разве только нефть наше богатство? А люди разве не клад? Ведь люди тоже клад... Если разобраться, не будь людей – и дело бы стояло. А клад так и остался бы кладом лежать в земле...». Да, самое главное – это люди. И задача литературы никогда не сводилась к тому, чтобы описывать машины, с помощью которых происходит в данном случае открытие нефтяных богатств, их разработка, она заключается, прежде всего, в художественном изображении человека и его мира. Г. Аху-

нов не увлекается, как бывает в некоторых наших произведениях, техницизмами, живописанием картин производства, он рисует живые характеры, и на каждой странице его романа чувствуется волнение автора, его тревога за судьбы героев.

Особенно четко прочерчены в романе судьбы двух семей – Шавали и Лутфуллы. Сюжетные линии и главный конфликт развиваются в основном вокруг этих семей. Изображая два резко противоположных характера, писатель широко пользуется приемом контраста: упрямый, грубый, косный Шавали и человек передовых взглядов, добрый, отзывчивый Лутфулла; смело выступившая против старого уклада, трудолюбивая, смелая, прямая в любви Файруза – и мягкосердечная, тихая, не способная бороться за свои права, за любовь, оторвавшаяся от общественных дел Мунэвера; Арслан и Карим – с диаметрально противоположными взглядами на жизнь и на труд.

Герои «Клада» проходят тяжелые жизненные испытания. И во второй части «Клада», в романе «Хозяева» мы встречаемся с ними уже в ином качестве, теперь они и духовно поднялись на новую ступень – они уже хозяева своей жизни, своей судьбы.

Главный герой второй части романа – начальник нефтедобывающего управления Арслан Губайдуллин. В прошлом деревенский парень, ставший настоящим нефтяником, выросший до уровня руководителя. Автор достоверно изображает то, как закалялся его характер, как рождалась принципиальность в борьбе за новое и справедливое. Арслан – руководитель нового типа, требовательный к себе и к товарищам, прямой, отзывчивый, твердо верящий в прекрасное будущее, способный бороться за него до победы.

В романе четко проводится мысль о неразрывной связи поколений – она явственно прослеживается на образе Лутфуллы Диярова. «Кто же они – хозяева?» – думает Арслан на торжественном вечере по поводу присвоения старому нефтянику Лутфулле Диярову звания Героя Социалистического Труда. Арслан от души поздравляет своего учителя. «Какие только хозяева не появлялись в стране... – говорит он. – Но настоящим хозяином страны на веки вечные был и останется народ. Такие, как Лутфулла Дияров, не жалеющие себя, не требующие для себя многого, самоотверженные люди, работающие от души, – вот кто они, хозяева...».

В татарской прозе не так много значительных произведений, посвященных современному рабочему классу. Здесь можно вспомнить романы И. Гази «Обыкновенные люди», А. Абсалямова «Огонь неугасимый», Э. Касимова «Чулман – река внуков», А. Баянова «Огонь и вода», Ш. Бикчурина «Твердая порода» и несколько повестей. В этой области писателям, кажется, пока еще не хватает и смелости, и опыта. И поэтому еще более возрастает значение «Клада» Г. Ахунова, романа не просто производственного, но прежде всего психологического, в котором во главу угла ставятся проблемы нравственные.

Нравственно-этические проблемы стоят и в центре повести «Ядро ореха». Это прежде всего проблема личной ответственности. В повести фактически два действующих лица: совсем неопытная девушка Рокия, выросшая в семье, где процветала психология мелкого мещанства, и добрый, честный, прошедший нелегкую школу жизни юноша – лейтенант милиции Халик Саматов.

Перед нами встает история любви с ее сомнениями, колебаниями. Уже выйдя замуж за Халика, Рокия первое время смотрит на него недоверчиво, она мучается, все еще не в силах расстаться со старыми родительскими представлениями. Но жизнь берет свое – Рокия наконец понимает правоту мужа и встает вместе с ним на борьбу против бюрократизма, равнодушия, карьеризма, бесчеловечности, которые, к сожалению, еще бытуют в нашей жизни. Против обывательства и мещанства.

Критика часто классифицирует литературу по тематике: писатель современной темы, писатель исторической темы, производственный роман, исторический роман. Однако,



Гариф Ахунов ТР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залында чыгыш ясый. 1981

как показывает жизнь, такая классификация достаточно условна. Но какого писателя не волнует история его страны, его народа? Вот и Г. Ахунов, ярко выраженный представитель современной темы в литературе, обращается к истории. Именно в ней ищет он истоки героизма своего народа, с такой яркостью и убедительностью воспетого им в романе «Клад». И вполне закономерно, что после «Клада» появляется повесть «Ардуан-батыр», замечательный памятник героям первых пятилеток.

«Ардуан-батыр» – историко-документальная повесть. Она обращена к истории возникновения в 30-е годы Березниковского химкомбината. Автор повествует об удивительных делах строителей нового мира, об их героизме, вере в высокие идеалы, о том, как закалялся и рос новый человек, преодолевая трудности. Есть в повести и документы, и воспоминания. Помогает понять основную идею произведения очерк К. Паустовского об Ардуанове. В Березниках герою труда Мирсаиду Ардуанову воздвигнут памятник. За что? Вот на это дает ответ повесть. Современник Мирсаида – старый рабочий Коновалов говорит писателю: «Ардуан-батыр был творцом, как те же Маяковский, Чайковский или ваш национальный герой Джалиль. Только он творил не поэму, не симфонию, а новую эпоху, новый мир, мир социализма. Вот за что поставили ему памятник!». Сказано очень точно. Памятник герою труда. Памятник созидателю новой жизни.

Героизм – явление историческое. Его национальные и общественные корни уходят глубоко. Увидеть эти «корни», найти истоки героизма советских людей – таково постоянное стремление Гарифа Ахунова. Движимый этим стремлением, он принимается за историко-революционный роман «Дочь Волги». Первая книга этого романа, задуманного как многоплановая эпопея, очень быстро пришла к читателям и уже заняла видное место в современной прозе, еще раз продемонстрировав рост таланта писателя.

Исторические события, изображенные в романе «Дочь Волги», охватывают период бурных незабываемых лет. Страдания трудового люда в 1906–1917 годах под царским гнетом, растущее недовольство, первые искры борьбы, Великий Октябрь, гражданская война и затем сложный период строительства нового мира, волны перемен в духовной жизни общества. События гражданской войны на Каме и Волге и прежде отражались в произведениях татарских писателей – Г. Ибрагимова, К. Наджми, И. Гази. Г. Ахунов не повторяет своих предшественников, он по-новому подходит к событиям гражданской войны. Есть в романе и образы исторических личностей – бойцы знаменитой дивизии Азина, воевавшей против белых, революционер Мулланур Вахитов, связанный с борцами из Агрыза, Салауша, Елабуги.

Однако в первой части романа «Дочь Волги» автор не ставит перед собой задачу изображения исторических личностей в широком плане. Мулланур Вахитов, Шаймордан Ибрагимов и другие появляются лишь эпизодически. Вероятно, эти образы полнее будут раскрыты в последующих частях романа-эпопеи.

Новый роман Г. Ахунова «Дочь Волги» – еще одно доказательство развития жанра эпического романа, он уверенно вписывает в опыт советского историко-революционного романа новую страницу, отличающуюся ярким национальным своеобразием.

Гариф Ахунов находится в самой гуще жизни и внимательно следит за переменами, происходящими в ней. И говорит о них по-своему: его творчество глубоко самобытно. Безусловно, проза Гарифа Ахунова родилась не на пустом месте. У него есть свои учителя, коллеги по перу. В его крупных произведениях последних лет ощутимо живое влияние традиций великой многонациональной советской литературы, и это естественный и положительный факт. В своих записях Г. Ахунов говорит о влиянии на него творчества Г. Баширова. И о воздействии на его творчество Г. Ибрагимова, К. Наджми, об учебе у них языку, стилю и композиции. Писатель неоднократно признавался, что в изображении сложных и противоречивых сторон жизни, ее суровой правды он опирается на творчество Михаила Шолохова, которого много переводил. И это естественно. Ведь продолжать литературные традиции – это значит не повторять их, а раскрывать в них новые страницы, новые грани. Творчество Г. Ахунова служит доказательством тому.

*Хасан Хайри*,
литературовед, заслуженный деятель науки Республики Татарстан

# Его-позабыть-нельзя

Настоящему писателю не надо долго рассказывать о себе, только назвать свое имя – и люди скажут: «Знаем, это писатель». В 50-е годы Гариф Ахунов заявил о себе как автор рассказов и повести «Краса юности» – о студенческой жизни, которые вышли отдельным изданием в 1956 году и – нашли путь к сердцу читателей. Кроме того, в это время Гариф Ахунов писал рецензии и статьи о произведениях известных писателей – о поэме С. Баттала «По столбовой дороге», о произведениях Ибрагима Гази, творчестве Г. Баширова, М.Джалиля, Ш. Маннура, Э. Давыдова и многих других.

В 1957 году Г. Ахунов был принят в члены Союза советских писателей. Кроме того, он занимался и переводами на татарский язык русских авторов. Им был переведен роман В. Закруткина «Плакучая станица», «Педагогическая поэма» А. Макаренко, «Тихий Дон» М. Шолохова и др.

На заседании правления Союза писателей Татарии его избирают председателем нашего союза, а я в это время стал работать литературным консультантом и одновременно руководил русской секцией. С Гарифом Ахуновым у нас установились тесные служебные и дружеские отношения. Он поддерживал русскую секцию, которая в то время насчитывала 20 членов Союза писателей СССР. Башкирский поэт Мустай Карим как-то сказал, что такой секции нет в других республиках Поволжья.

С рекомендацией Г. Ахунова произведения русских авторов беспрепятственно принимались в Таткнигоиздате и выходили отдельными книгами, получая при выходе в свет положительные рецензии.

К нам часто приезжали писатели из Москвы и Ленинграда, литераторы соседних республик. Они любили у нас бывать, чувствуя искреннее гостеприимство. У Гарифа Ахунова была добрая душа, однако он не терпел распущенности и разгильдяйства и мог поставить на место любого.

Мы работали с ним дружно и слаженно, – и не было намека на какой-либо раздор в Союзе писателей. Он был депутатом Верховного Совета СССР и как депутат оказывал всемерную помощь тем, кто к нему обращался.

И если действительно душа человека бессмертна, то я постоянно ощущаю его присутствие: и в нашем Союзе писателей, и на даче, где мы часто встречались летом. По сей день я не могу осознать, что его нет в живых, он всегда и всюду с нами.

*Геннадий Паушкин,*
писатель, заслуженный работник культуры РСФСР

# Заман-кешесе

Нәшриятта редактор булып эшләгәндә, өстәлемә «Яшьлек яме» дигән кульязма китереп куйдылар. Бу Гариф Ахуновның беренче зур әсәре икән. Берздан ул үзе дә күренде. Дулкынланып торган кара чәч, текә маңгай, көләч йөз, чыгынкы күзләр, таза гәүдә, нурланып торган ачык чырай. Пулеметтан аткандай кызу сөйләшә. Ул тиз-тиз бу повестьның журналда басылып чыгуын, әмма үзе белән укыган бер яшь язучының әсәргә карата дәгъвалар белдерүен сөйләп алды. Өлкән язучылар тегене бик тиз үз урынына утырттылар, ди.

Китап басылып чыкты. Әмма автор никтер күренмәде. Соңыннан мин аның гаиләсе белән Әлмәткә – нефть чыккан якка күчеп киткәнен ишеттем. Күпмедер вакыт үтте.

Әлмәт төбәгендә бик зур нефть ятмалары табылуы хакында газеталар ярыша-ярыша язалар. Җәй көне мин дә Әлмәт янындагы туган авылыма кайттым. Искитәрлек хәлләргә тап булдым. Урам тулы зур йөк машиналары иләмсез мөгезборыннар шикелле үкерә. Авылның дүрт ягына да язын вышкалар утырталар, ди. Нефть көнкүрешкә дә керә башлаган. Аш пешерү өчен казан астына ягу беткән. Өйалдында ике керосинка янып тора. Бензинга тоз кушып та керәчингә экономия ясыйлар.

Төнлә ишегалды яп-якты. Буровой утлары яктырта икән. Безнең бакча артындагы үр өстенә өч вышка куеп, җирне тишә башлаганнар. Иртән мин тизрәк шунда ашыктым. Йа Хода, нинди могҗиза бу! Бер скважинадан нефть бәреп чыккан. Нефтькә ияреп килгән газы, йөз метр арырак зур ут – ялкын чүмәләсе булып янып тора. Күрергә килгән хатын-кыз, карчык-корчык, иреннәрен кыймыл-кыймыл китереп, белгән догаларын укыйлар. «Әстәгъфирулла, тәмуг утымы әллә бу?» – диләр. Мин тимер баскычлы озын вышка астындагы буровойга таң калып карап торганда, кемдер исемемне әйтеп дәште. Алдыма карасам, буровой ишек төбендә Галим Газизов басып тора. Яшьтәш. Без аны кара-чутыр дип йөртә идек. Ул ком гарәбе төсле кара-кучкыл чырайлы, гаҗәп ипле, җайлы егет. Помбур булып эшлим, диде. Рөхсәт ителмәсә дә, ул мине буровойга алып керде. Әле раствор килеп җитмәү сәбәпле, бораулау туктаган чак, ди. Галим миңа биредәге инструмент, приборлар буенча ликбез үткәрә. Менә идәндә, бума еландай, турбобур сузылып ята. Башында крокодил авызын хәтерләткән эре теш-шорошкалы долото. Теш-шорошкалары арасыннан аксыл сыекча агып чыга. Шушы турбина-долото каты токымнарны кимерә-кимерә тишә, ди. Турбобурның эчендә төрле фигуралы турбина колаклары. Көчле насослар махсус измә-растворны зур басым белән шул турбинага куалар һәм долотоны тиз әйләнергә мәҗбүр итәләр икән.

Икенче көнне килгәндә, буровой ишеге төбендә саргылт курткалы бер кеше чалкан егылып ята иде. Нәрсә бу? Аның башы-чырае тирәсендә берәү нәрсәдер эшли. Борынына нашатырь спирты иснәтә, учы белән колакларын уа. Шунда ашыгыч ярдәм машинасы килде. Аңын җуйган бурильщикны носилкага салып алып та киттеләр. Сөйләделәр, бораулау вакытында скважинадан газ чыгып агуланган икән. Измә куучы насосларның нинди басым белән эшләвен дә шул вакытта күрергә туры килде. Насосның шлангысында булавка башы чаклы тишек хасил булган. Шуннан сызылып чыккан измә агынтысы

такта щитны үтәли тишкән. Бик куркыныч нәрсә икән. Кешегә эләксә, урталай кисә дә ташлый, ди. Кыскасы, тау токымнарын бораулау бик катлаулы, хәвефле эш икән.

Берникадәр вакыттан соң Гариф Ахуновның «Хәзинә» романын редакцияләргә куштылар. Ул әсәр нефтьчеләр тормышы турында булып чыкты. Менә шунда минем нефть эшләре буенча ликбез үтүем бик ярап куйды. Гадәттә, кулъязманы эчке рецензия белән бирәләр. Әмма рецензия юк иде. Моның хикмәте бераз соңрак беленде.



Җәйге ямьле көннәрдә. Утырганнар сулдан: Лирон Хәмидуллин, Гариф Ахунов, Марс Шабаев; басканнар сулдан: Дания Хәмидуллина, Фирүзә Хәсәнова, Шәһидә Максудова, Роза Камалова, Роза Шабаева, Наил Касыймов. Яшел Үзән районының «Идел» бакчачылык ширкәте. 1995

Әсәр кул тимәгән өр-яңа материалны эченә ала. Бездә сәнәгать темасының традициясе юк диярлек. Аңа характерлы тәгъбирләр, сәнәгать детальләренең татарча исемнәре, терминнары да ташка үлчим генә. Шуңа күрә автор барча сурәтләү тәгъбирләрен, сәнәгатькә кагылышлы үзенчәлекле сүзләрнең татарча әйтелешләрен тулысынча үзе иҗат итә. Әсәр тукымасында бу яңалыкларга образ-характерларның бик үк гадәти булмаган төсмерләрдә, укалы итеп тасвирлаулар өстәлә. Әсәрнең үзәгендә бурильщик Кәрим Тимбиков, киң җилкәле, таза, гөрес-мәрес гәүдәле, төксе чырайлы, кырыс холыклы, тулы кеше. Җайлашуны белми, үзенә дә, иптәшләренә дә бик таләпчән. Бу вакытларда тау токымнарын бораулау сәнәгатендә рекордлар кую модага кереп бара иде. Башлыклар ашыктыра. Йөз миллион тонна нефть чыгару өчен бораулау бригадалары ярыша. Тимбиков, иптәшләре белән карусыз эшләп, җиңүләр яулый. Аның булдыклы, эшчән һәм максатка омтылышлы, нык холыклы булуын тиз чамалап алалар. Бурильщиклыктан мастер итеп күтәрәләр. Аның вак-төяк гөнаһларына да күз йомалар. Чөнки ул эшне тиешле темплар белән алып барырга сәләтле. Газеталарга мактап язалар, радиодан да хуплау сүзләре яңгырап тора. Башлыклары Тимбиковны герой итәргә лаек дип санavailableлар. Һәм бу бик нигезле, урынлы. Чөнки аның бригадасы бораулау буенча рекорд арты рекорд куя. Аңа юл ачып торалар... Чыннан да, Тимбиков эш процессыннан дәртләнеп көч-илһам ала. Бу халәт аны бар көчен беткәнче эшкә бирергә рухландыра. Юк, бу, башны җуеп, дан-шөһрәт артыннан куу түгел. Ник дигәндә, Тимбиков ихластан һәр эшне булсынга эшли. Хәйләсез, артык исәпсез. Эчкерсез хезмәт белән тормышны яхшыртырга, тәрәккый иттерергә омтылыш булуына ышанасың. Биредә эш ул – көч һәм тир түгү генә түгел, авыр эшне яратып эшләүдән кеше канәгатьлек таба. Зур осталык, виртуозлык эшне җиңеләйтә. Эш авырлык чыганагы гына түгел, ә шатлык, күтәренкелек чыганагы да. Шулай хезмәт поэзиясе төсмерләнә. Гадәттә эстетиканы сүз нәфислеге, табигать күренешләренең матур сурәтләнүендә күрәләр. Әмма бу әсәрдә автор хезмәт процессы эстетикасын тудыруга ирешә.

Буровойда таза, көчле кешеләр хезмәт итә. Алар арасында ихлас, чын кешеләрчә иптәшлек мөнәсәбәтләре. Авыр эштә кешелеклелек бик мөһим. Бер-берсенә салынмыйлар, берсе өлешенә икенчесе керү турында уйларына да килми, шәхси мәнфәгатьләрен берсе дә алга чыгармый. Мастер Тимбиков аларны авыр хезмәт кимәлендә сынаган, тәрбияләгән. Үзара җайлашып эшлиләр. Шул сәбәпле эш көйле тәгәри. Әмма табигать сюрпризлар ясарга һәвәс. Турбобур каты токымны җай гына тишеп барганда, кинәт токым тишелә һәм инструментны кыса, сыта. Күпме генә тартсалар да җибәрми. Моны нефтьчеләр телендә «прихват» диләр. Кыскасы, авария. Бу аварияне төзәтү бик мәшәкатьле, айга сузылуы мөмкин. Өмет иткән рекордларың түү-түү! Нишләргә? Бер әмәл кулланып карыйлар, юк, токым инструментны ычкындырмый. Икенче ысулны ходка куеп сыныйлар, әмма көткән нәтиҗә юк. Өченче, дүртенче әмәлләр дә берни бирми. Тимбиков тәвәккәллеккә барырга карар кыла. Батыр йөрәкле булуы, җаваплылык хисе аны шуңа этәрә. Барча иптәшләрен буровойдан чыгара. Идарә пульт-тормоз рычагы артында үзе генә кала. Дизель-моторларны соңгы чиккә хәтле эшләтеп, бер ыргым ясап, инструментны тартып алырга итә. Юк. Аннары барча мотор көчләрен бергә кушып тарттыра... Вышка, станоклар дыр-дыр килеп тора. Тимбиков үзе турында уйламый, бары эш, рекорд турында борчыла. Бу югары әхлаклылык билгесе түгелмени? Үзеннән-үзе хәтергә килә: дошман доты, ут бөркеп, һөҗүмне туктата. Шунда бер тәвәккәл йөрәклесе, алга ыргылып, ут ноктасын күкрәге белән каплый. Һөҗүм дәвам итә. Тимбиков батырлыгы да шуңа тиң бит! Тимбиков тагы бер омтылыш ясый. Артык көч килүдән корыч та чыдамый. Бер инструмент детале өзелеп, тормоз рычагы артына баскан Тимбиковның башына килеп төшә һәм...

Әмма Тимбиковны корбан дип әйтергә тел әйләнми. Юк, ул авария корбаны түгел. Чөнки бу адымга намус кушуы буенча, иптәшләренә җиңеллек китерү өчен, аек аң белән бара. Тормыш алдында, Ватан алдында изге бурычын үтәү өчен бара. Иҗтимагый мәнфәгатьне үзенең һәлак булу ихтималыннан өстен куя. Бу физик батырлык белән бергә бөек әхлакый фидакарьлек, кешелеклелек! Бу – заман образы, шул билгеле заманның үзенчәлекләрен үзендә туплаган, заманны аңлатучы образ иде.

Бу нефтьчеләр тормышында була торган фаҗигале факт. Андый хәлләр аз булмады. Катлаулы хезмәт, яңа техника. Ә каты токымнар, җир асты дөньясы көтелмәгән хәлләр тудырып кына тора. Шушы куркыныч эштә кешеләрнең үзләрен ничек тотуларын, нинди булып ачылуларын тасвирлаганда, язучының эчке рухы, күренеп тормый торган дөньясы да чагыла. Бу билгеле нәрсә. Чөнки кеше икенче кеше турында фәкать үзеннән чыгып кына фикер йөртә. Үзеннән чыгып кына кешегә бәя куя. Гариф үзе кыю, батыр, тәвәккәл кеше булганга күрә генә Тимбиковның халәтен аңлаган һәм җете итеп тасвирлаган. Ә үзе куян йөрәкле, сакчыл, ватанпәрвәр булмаган кеше Тимбиковның тәвәккәллеген бары ахмак тәвәккәллек, кирәксез эш дип карар иде. Һәм язучы буларак бу һәлакәтле хәлне тасвирларга алынмас иде. Алынган очракта да бары тик факт буларак теркәп кенә үтәр иде. Үзе батыр, кыю булмаган язучы батырлыкны, тәвәккәллекнең эчке рухын аңлый алмый. Андый нәрсә аңа бирелмәгән. Ни хәл итәсең... Һәр авария, әлбәттә, эшчеләргә сабак була. Алда ялгышлар ясамаска кисәтә. Әмма тәвәккәл таш яра дигәндәй, эштә кыю, зиһенле булу лязем. Әгәр эштә кыюлык, тәвәккәллек булмаса, ачышлар булмас иде, прогресс туктар иде. Патриотлык ул тыныч тормышта да бик кирәк сыйфат. Гариф, язучы буларак, шуны дәгъва итә. Аның эчке рухы кыю, һәрчак прогресска омтылучан. Шушы теләк идеясен ул ышандырырлык, җанлы образлар аша тасвирлап бирә.

Гариф беркемнең кулы тимәгән тау чаклы өр-яңа материал эшкәртә. Яңа сәнәгатьнең нигезләрен иҗат итә. Күпме өр-яңа тәгъбирләр, сүзләрне әдәби әйләнешкә кертә. Өр-яңа

сәнәгать сферасында яңа эшче образлары тудыра. Үзләренең эчке рухлары, кайгы-шатлыклары белән... Бу авторның тәвәккәллеге, бөтен җанын биреп эшләү нәтиҗәсе! Моны ничек җиңү димисең? Мин «Хәзинә» романы турындагы бәямне «Гариф, син җиңүче!» дип язып җибәргәнмен. Гариф моңа бик сөенгән, чөнки романга эчке рецензия язган тере классик язучы шушы әсәрне тар-мар иткән булган. Бу хакта Гариф «Йолдызлар калка» дигән әсәрендә дә телгә алып үтә.

«Хәзинә» Гарифның бик бәхетле әсәре булды. Эчтәлеге, язылышы белән заман рухына туры килде. Кимчелекләрне куертмавы, образлар психологиясенең заман таләп иткән якты шәкел буенча сурәтләве, бар игътибарын хезмәт ярышына юнәлтүе заманга аваздаш иде. Хәер, әтисенең кулаклар тарафыннан үтерелүе аны бала чагыннан ук үзенә хас-холык табигатьле итеп формалаштыргандыр. Билгеле инде, әсәр язу намус эше. Ләкин заманга яраклашу өчен Гарифка шәхси намусын богауларга туры килмәгәндер. Чөнки аның эчке рухы, шат-күтәренке характеры заманга бик туры килә. Бу җәһәттән аның холык-фигылендә бернинди каршылык юк. Гарифның һәр эштә һәркем белән ярышучан һәм узучан табигате, һәм иҗтимагый шартлар аны әдәбиятта каршылыксыз сукмактан китәргә этәргәндер. Бу сукмак совет әдәбиятының магистраль юлы дип атала. Ул юл әдәби уңышка һәм дәрәҗәгә китерә. Гарифның якты акылы моны дөрес чамалаган булырга тиеш.

Шушы юлдан читкә тайпылмаганнар гына иҗтимагый дәрәҗә-бәхеткә ирешә. Гариф башта ук заманча программаланган заман кешесе иде. «Хәзинә» романы белән дә шуны тагын бер кат раслады. Ул иҗтимагый байлыкны да татыды. СССР Верховный Советы депутаты булды. Бер мөддәте тулгач, икенче мөддәткә сайланды. Әлбәттә, мондый дан-дәрәҗә аңа үзен һич аямый көн-төн язучылык һәм иҗтимагый эшләрдә кайнаганга бирелде. Гариф дан-дәрәҗәдән төшмәде, бәхетле мул тормыш белән яшәде. Бик популяр булды. Ничә еллар буе президиумнарда утырды, чәче дә шунда агарды. Дан-шөһрәт эчендә заман иркәсе булып гомер кичерде.

Нинди югары дан-дәрәҗәгә ирешсә дә, Гариф иптәшләренә, каләмдәшләренә, таныш булмаган гади кешеләргә булышудан туктамады. Киресенчә, депутат вәкаләтләрен дә шул эшкә җикте. Судларга барды, инстанцияләр ишеген какты. Аның бүтәннәргә ярдәм кулы сузарга әзер торган юмарт холкы үзгәрмәде. Кимсетелгәннәргә булышудан җан азыгы таба, эчке канәгатьлек кичерә, үзен чын кеше итеп тоя иде. Берәрсен бәладән йола алса, шуңа балаларча сөенә, чыраенда бәхет нурлары балкый иде.

Ул үз каләмдәшләрен, язучыларны авыр хәлләрдән коткара иде. Чөнки язучы күпме генә сәләтле булмасын, ул яклауга мохтаҗ. Хикмәт идеологик четереклектә генә түгел. Хәер, күп каршылыклар шуңардан килсә дә, хикмәт шунда, художество әсәре ул иң яклаучысыз әйбер. Аны теләсә кем бетереп ташлый ала. Моңа белем дә, хәбәрдарлык та кирәк түгел. Ә төгәл фәннәрдә мондый иркенлек юк. Анда катгый формула, кагыйдәләр. Нәфис сүз продуктын ышыклаучы, аралаучы кагыйдә-тәртип эшләнмәгән. Теләсә ничек аңла, теләсә ничек фикер йөрт. Хәреф таный торган, бүтән бернинди белеме булмаган кеше әсәрне укый да пыр туздыра. Аның сүзенә колак салучылар табыла. Мондый ситуация өстән әдәбиятка басым арткан, фикерле сүзне кыскан вакытларда килеп туа... Җитмешенче елларда сталинизмны реанимацияләү көчәйде, кайбер яшь, кыю язучыларны, дөреслекне әйтергә маташучыларны диссидент дип атап, аларга халык нәфрәтен төбәлдерүләр китте. Бездә дә, шул шаукымга бирелеп, кулъязмаларны тоткарлый башладылар. Аерым язучыларны идарә утырышында тикшерү, талку ешайды. Әдәбият күгендә болытлар куеруын шуннан чамалыйсың, кулъязма керә торган бүлекләргә баш итеп «мәчтүрә»ләрне куялар. Яшь язучыларның әсәрләре өчен Гариф «мәчтүрә»ләр белән күп көрәште. Башта ул кайбер сәләтле «мәчтүрә»ләргә олы юлга чыгарга булыш-

ты. Әсәрләренең текстларын эшләде, төзәтте. Китап итәрлек төскә китерде. Язучылар союзына керергә юлламалар бирде. Әмма олы юлда бераз көч туплагач, оятларын югалтып, битләренә یыштыр ябып, шул «мәчтүрә»ләр Гарифның үзенә ябырылдылар. Донос оештырдылар.

Язучылар арасында төрле кеше бар. Әнә берсе, күзлек артына посып, зәһәр елмаеп, «мәчтүрә»ләр белән чышын-пышын килгән була. Донос язарга шул этәргеч сүз әйткәндер. Көнчелеге йөзенә чыккан. Аның да президиумда түрдә утырасы килә. Берәүләр өчен ул ярыйсы кеше, икенчеләр өчен хыянәтчел зат. Әмма яраклаша, җор сүзләр әйтеп көлдерә. Рәхәтләнеп яши. Астыртын эшләрен күпләр белә, әмма фаш итә алмыйлар. Чөнки төп йорт белән тыгыз элемтәдә ул...

Менә чираттагы корбан. Бер язучыны әсәренә сюжетны фәләннән алгансың, дип талкыйлар. Иптәшен батырырга дигәндә, татар инде ударник. Моның сере нәрсәдә соң? Бер сере шунда: татарга өстән басым бик көчле. Аны кысалар, үткәне белән котын алалар һәм каләмдәшенә ташланырга мәҗбүр итәләр. Биредә зур язучылар, тере классиклар төймәдән дөя ясыйлар, тегене әллә нинди гөнаһларда гаеплиләр. Язучыны кичәге дуслары да якламый, куркып, авызларына су капкандай утыралар. Союздан чыгарырга дигән сүзләр яңгырагач, моңарчы чыдап торган Гариф күтәрелә. «Мин судта утыраммы, әллә язучыларның иҗади утырышындамы?» дип башлый ул сүзен каты итеп. Хөкемчеләрнең сабын куыгы кебек «дәлилләрен» бер-бер артлы юкка чыгарып ташлый. Охшаш сюжетлар була ул. Ләкин шул сюжетны язучы ничек үзенчә индивидуаль җанлы образлар белән баета, тәэсир итәрлек художество әсәре тудыра. Бөтен хикмәт шунда. Сюжетларның кабатлану теориясе бар. Сюжетта охшашлык гаеп санала алмый. «Анна Каренина» романының сюжет сызыгы «Красное и черное» романында шәйләнә. Икесе ике төрле, бер-берсеннән нык аерылып торган классик әсәрләр...

Гариф тагы бик күп мисаллар китерә. Язучының бер гаебе булмавын исбат итә. Өстәгеләргә ялагайланып, кайбер җитәкчеләрнең вакчылллануын, иптәшне гаепләп, очко эшләүләрен Гариф йөзләренә бәреп әйтә. Тегеләр шым була. Язучы өстенә өелгән нахак гаеп алып ташлана.

Каләм ияләре нәзберек халык. Индивидуалистлар. Бик тиз хәтерләре калучан, сүз күтәрә алмаучан. Лениногорск шәһәрендә яшәп иҗат итүче яшь язучы, үз әсәренә өлкән язучының начар рецензиясен алгач, бик ачуы килә, күтәрелеп бәрелә. Рецензентны сүгеп, хурлап язып җибәрә. Моны идарәдә тикшерәләр. Язучы-рецензент яшь әтәчкә җәза бирүне таләп итә. Бу инде яшь язучыга юллар бикләнә дигән сүз. Әмма, тегенең бәхетенә, һәрчак ярдәмгә ташлана торган кыю Гариф бар. Ул тора да: «Мин ул яшь язучыны беләм, бик өметле ул, шахтада эшләгән, күпне күргән. Моны ул ачулы минутта белештерми язып ташлаган. Мин яшь язучы өчен рецензенттан түбәнчелек белән гафу үтенәм...» – ди-ди ихлас күңелдән сөйли. Гарифның эчкерсез сүзләрен кем аяк астына сала алсын? Рецензент язучы йомшый, тегене гафу итә. Аңа юл ябылмый кала... Кем шулай, барча гаепне үз өстенә ала-ала, кешене бәладән йола алыр иде? Шәһидә әйтер иде: «Андый тиле бер Гариф кына», – дип. Чөнки безнең тигез булмаган тормышта яхшы кеше булу кимчелек. Берәрсенә яхшылык эшләсәң, үзеңә бәла булып төшә. Мондый хәлләрне Гариф күп кичерде. Ләкин аның һәркемгә игелекле холкы һаман яхшылык эшләргә омтылып торды. Әйтерсең лә аның эчендә якты кояш, шуның нурын бүтәннәргә өләшергә ашыга иде.

Ул мине язмыш тарафыннан кыерсытылган дип санады. Һаман кагып-сугып йөрткәннәрен күреп, мине үзенең химаясенә алды. Сугыш турында язган әсәрләремне чыгаруга булышты. Инстанцияләрдә үзенең ныклы сүзе белән яклады. Текстка каләм

төртмәде, әмма идеологик киртәләрне узу җайларын тапты. Язганнарыма шикләнеп карыйлар, энә күзеннән үткәрәләр. Әйткәнемчә, әдәби әсәр иң яклаучысыз җисем, җирдә үсеп утырган үлән кебек. Теләсә ничек тапта. Минем әйберләрне башлыча «мәчтүрә»ләрдән таптаталар иде. Мине таптаганның кайсын Язучылар союзына алалар, кайсысының рәсемен газетага бастырып чыгаралар. Башлар күпне кичерде. Миңа тенденциоз караш яшәде. Күпләр минем белән сөйләшергә, минем янга утырырга курыкканда, Гариф искиткеч кешелеклелек күрсәтте, минем әсәрләргә уңай бәя бирде. Бу зур батырлыкка тиң чыгыш иде. Язучы өчен тенденциоз караш бик авыр ул. Моны үз башында татыганнар гына белә.

Без күп аралашмадык. Бакча сезонында бер-ике тапкыр утырыш уены ясап ала идек. Гариф кайчак, ихласланып: «Син киребеткән, җайлаша алмыйсың, шуңа бәхетең юк», – дип ачуланып ташлый иде. Мин каршы бер сүз әйтә алмыйм. Чөнки дөрес әйтә, шайтан алгыры. Дөрес сүзгә җавап юк.

Гарифның шундый дәрәҗәләргә ирешүендә Шәһидәнең дә тырышлыгы зур булган булырга тиеш. Гариф исә бик еш: «Шәһидәдә тимер логика, ул хәлләрнең астарын алдан күрә белә!» – дип сөйли иде. Шәһидәне гел мактый иде. Яратып мактау бар, куркып күккә чөю бар. Һәр ир хатынынннан бераз курка инде. Аны олылау, баш иту йөзеннән. Бу кимчелек түгел. Ир белән хатынның яратуда, хисләрдә махмырламыйча яшәү формасы.

Бакчада ауган койманы рәтләгәндә, такта-токта кадаклап маташканда, Гариф шунда ук булышырга килеп җитә иде. Ул безгә генә түгел, бөтен тирә-күршегә булыша иде. Аның кулы тимәгән йорт, каралты калмагандыр. Дөнья булгач, арада кайвакыт төрле каршылыклар да килеп чыга иде. Ләкин без аны озакка сузмыйбыз, берни дә юк кебек, тагы табындаш уенына керешәбез. Тагы тирәнгә кермәскә тырышып сөйләшәбез. Сүз четерекле тема чытырманына юнәлмәсен өчен, Гарифның сыналган әмәле бар. Ул җыр суза. «Көмеш тояк тулпар атым»ны һәрчак яратып җырлый. Аңа ярдәмгә Шәһидә кушыла. Аннары «Хан кызы, ишегең ач!» китә. Яисә, шаянга күчеп, «Минем әти төлкече, төлке аулап йөрүче...»не сыздыра. Ул да түгел рус халык җырларының кылын тарта: «Миленький ты мой, возьми меня с собой, там в краю далеком назовешь меня женой... Милая моя, взял бы я тебя, в том краю далеком есть у меня жена!..» Җырның азагы фаҗигале, ләкин өметсезлек аһәңе белән өмет уята.

Бервакыт бакчада өй кырыендагы эскәмиядә сөйләшеп утырганда: «Бер дошманың синең турында, аны барыбер парнаска кертмиләр, дип әйтте», – диде. Үзе, уңайсызлангандай, аяк астыннан нечкә чыбык алып сындыргаларга тотынды. Мин ни әйтергә белмәдем. Соңыннан уйлана торгач төшендем: мине гомер буе әдәбиятта бер исемлектә дә телгә алмыйлар бит! Хәерле булсын, язмыш аша атлап үтү безнең кулдан килми.

Тормыш, көн дә алышынып, кешеләрнең кәефләрен үзгәртеп тора. Барыбыз да шартлы мохит балалары. Шартларга карап үзара мөнәсәбәтләр дә үзгәрә. Аралар салкыная, каш җыерып йөрисең. Әмма бераздан җылы дулкын килә. Кашлар языла, телгә җылы сүзләр килә. Шулай бер салкынаеп, бер җылыга тиенеп гомерләр кичерәсең. Бер без генә түгел, күпләр шул кимәлдә көн итәләр.

Соңгы вакытларда Гариф, авыру булуга карамастан, язды да язды. Бер минут эшсез тормады. Әллә ничә документаль повесть бастырып чыгарды. Аның эшчәнлегенә гаҗәпләнмәгән кеше юк иде. Аңа каян энергия килә, дип шаккаталар. Андый карусыз эшчән кешене «эштә янды» диләр. Гариф та нәкъ шулай булды.

Эскәмиядә утырганда, мамык төргәгедәй ап-ак чәчле башын ике учына алып, тын гына уйга кала. Тирән, авыр итеп сулап куя, уфтана... Шул минутларда үзенә якынлашып килгән Газраилнең аяк тавышы колагына ишетелде микән әллә? Бу пошманлы



Казанның М. Горький урамында. 1986

кыяфәте белән ул дөнья кайгысын үзе белән алып китәргә җыенган ниндидер әүлияне хәтерләтә иде.

Бер тымызык иртәдә әүлия кебек тын гына дөньядан китеп барды ул.

Аның вафатыннан соң ачык тойдым: күңелемдә ниндидер бушлык хасил булды. Ниндер җитми, ниндидер үкенеч сава эчемне. Барып җитте: Гариф үзенең кешелеклелеге, җан юмартлыгы, эчкерсезлеге белән күңелдә урын алган икән. Менә шул эчтә, үзәктә сулкылдап тора икән...

Алыштыргысыз кеше булмый, диләр. Юк, дөрес түгел! Мәрхүм Гарифны беркем дә алыштыра алмый инде. Гариф кебек һәркемгә яшәү өмете өстәп торучы әүлия зат бүтән булмас, юк, булмас! Андый затлар кабатланмыйлар.

*Хисам Камалов,*
Татарстанның халык язучысы

# Ул-гүя-терекөмеш-иде

Ул вакытта мин Баулыда шофер булып эшли идем. Район газетасына сирәк-мирәк хикәяләр яза башладым. Җитмәсә, мине кинәндереп, хикәяләрне газетада бастыра тордылар. Бу мәсьәләдә миңа яңа гына Казаннан университет тәмамлап район газетасына эшкә килгән Шәйхелислам Садретдинов ярдәмгә килде. Миндәге язучылык оеткысын күрдеме, аңа кеше буларак ошадыммы – белмим, әмма без бик тиз дуслашып киттек. Күп тә үтми, мине редакциягә эшкә чакырдылар. Мин куркыбрак булса да ризалаштым. Минем хикәяләрем газетада ешрак күренә башлады. Шул вакытта көтмәгәндә безнең редакциягә язучы Гариф Ахунов килеп керде. Әлбәттә инде, яшь язучылар санында йөргән Шәйхелислам һәм минем белән әңгәмә булды, соңыннан без өчәүләп минем квартирага кайттык. Хатын эштә, мин чәй куеп җибәрдем, тиз генә өстәл хәстәрләдем, һәм чәй янында әңгәмәбез әдәбият турында булды. Гариф абый безнең хикәяләр һәм ары таба булган хыялларыбыз турында кызыксынды. Үзенең шушы нефть төбәгендә яшәгән яшь язучыларны барларга һәм, үзәк көнләшерлек итеп, Әлмәт язучылар бүлеген күтәрергә теләве турында ялкынланып сөйләде. Чәй өстәлен калдырып, без минем зал кебек зуррак бүлмәгә күчтек, әле булса хәтеремдә: Гариф абый утырмады, ишекле-түрле йөри-йөри сөйләде дә сөйләде. Ахыр, кая, язган әйберләрегезне күрсәтегез әле, дип, сорау алырга җыенган укытучы сымак, безнең якка күз ташлады. Шәйхелислам куеныннан кулдан язган хикәясен тартып чыгарды, мин, ни әйтергә белми, түрдәге язу өстәлемә күз төшереп алдым. Гариф абый, алаймы дигәндәй, өстәлдә яткан, яңа гына тәмамланган, ләкин әле хәтта машинкада бастырылмаган повестьны эләктереп алды да, берничә битен укуга: «Менә нәрсә, Мөсәгыйт туган, мин синең бу повестеңны кунакханәдә укырмын, иртәгә барысын да сөйләшербез. Килештекме?» – диде.

Килешми буламы, без Шәйхелислам белән икебез дә баш кактык һәм яңадан өстәлгә таба кузгалдык.

Тик сәер хәл, Гариф абый иртәнге якта редакциягә килмәде. Без өйләгә кадәр көттек тә ул туктаган кунакханәгә шылтыраттык. Авырып-фәлән китмәгәнме, янәсе. Ләкин кунакханә абыстае безгә, Гариф Ахунов атлы язучыгыз, газета редакторы Әлмәткә барасы булды да, шуның машинасына утырып китте, диде.

Әнә шулай мин Гариф абый белән беренче тапкыр Баулыда таныштым. Ләкин язмыш безнең яшәү җебен шунда ук бәйләп куйган булган икән. Ул, Әлмәткә китүгә өч көн үтмәде, редакциягә шылтыратты. «Егетләр – Мөсәгыйт, Шәйхи туганнар, мин сезнең әсәрләрне укып чыктым, машинкага бастырырга бирдем. Кыскасы, мин сезнең әйберләрне журналга җибәрергә булдым. Мин инде журналда утырган проза бүлегендә эшләүче сабакташым Яхъя Халитов белән сөйләшеп тә куйдым, ул миңа, әсәрләрегез кулына керү белән, укырга ышандырды. Көтегез!»

Әнә шулай яңа оешкан Әлмәт язучылар бүлегенә үзе теләп диярлек гаиләсе белән үк күчеп килгән Гариф абый мине Баулыда чакта эзләп тапты һәм «Унсигезенче яз» дигән беренче повестемны аякландырып җибәрде. Ул гынамы, мин КХТИга имтиханнар биргән идем, мине, аннан китәргә өндәп, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә күчәргә димли башлады. Һәм теләгенә ирешә. Тагын бер елдан

мин, чынлап та, ул теләгән университетның читтән торып уку бүлегенә имтихан бирдем. Минем өчен яңа дөнья башланды.

Гариф абый гаҗәеп киң күңелле, бигрәк тә яшь язучыларга ярдәмчел, елгыр хәтерле, җитез зиһенле, һәр чыгышын көлке-юмор белән тәмамлый торган әдип иде. Кулыннан повестем узуга, ул мине Әлмәт бүлегенең һәр җыелышына чакыра башлады, һәм инде мин дә, Әлмәткә килгән саен, кунакханәгә түгел, якын туганыдай, туп-туры аның квартирасына килә идем. Шунда аның тормыш иптәше һәм әдәби юлдашы Шәһидә апа белән таныштым. Шәһидә апа кай ягы беләндер минем әниемне хәтерләтә иде, хәтта холкыфигыле белән дә. Йомшак кына сөйләшә, әдәбияттан да бик әйбәт хәбәрдар, Гариф абый белән бер группада университетта укыганнар һәм, декабристларның сөйгән затлары кебек, Гариф абый белән Әлмәткә килгән. Әйтергә кыям, Шәһидә апа чын мәгънәсендә язучы иде, хәтта матур-матур повестьлар һәм истәлекләр дә язды, русчадан танылган язучыларның хикәя-повестьларын тәрҗемә итте. Тик Гариф абыйның үтә җаваплы эштә булуы аркасында (моның янына ике баласы, олыгаеп килгән әнисе бар иде), ул күңеле тулы хыялын үз укучыларына җиткерә алмады – вакыты җитмәде бугай. Гариф абый СССР Верховный Советы депутаты, СССР, РСФСР Язучылар союзлары идарәләренең секретаре да булып йөрде. Гариф абый балаларын да әдәбиятка тартырга тырышты. Улы Рәшит тә әтисенең романнарын тәрҗемә итте, кызлары Наилә исә бүгенге көнгәчә искитмәле шигырьләр яза, китап артыннан китап бастыра.

Ә Әлмәттәге җыелышлар болайрак хәтердә калган.

Әлмәт бүлегенә Нефтьчеләр сараеннан бер бүлмә биргәннәр иде. Зур да, кечкенә дә түгел. Әмма Гариф абый, киң күңелле кеше буларак шуңа да риза булып, бүлекчә белән идарә итә башлаган иде. Хәер, Әлмәттәге Язучылар бүлеге Гариф Ахунов тырышлыгы һәм талантлы җитәкче, шагыйрь Зәки Нури хәер-фатихасы белән ачылды. Мең рәхмәт аларга.

Минем хәтеремдә аеруча бер җыелыш истә калган. Иң әүвәл бүлеккә Гариф абый белән



Азнакайда әдәбият түгәрәге утырышы. Уртада Г. Ахунов, М. Хәбибуллин, М. Хәсәнов. 1967

без килдек, чөнки мин Гариф абыйларда кунган идем. Аннары Рафаил Төхфәтуллин белән Гамил Афзал килеп керделәр. Гариф абый, гадәттәгечә, бүлмә буйлап йөри. Күп тә үтми, Әдип Маликов белән җәмәгате Саҗидә Сөләйманова ишек шакыдылар. Ахыр, бераз көттеребрәк, Азнакайдан баһадир гәүдәле Мәхмүт Хәсәнов килеп керде. Килеп керде дә, түргә узып, тулы булмаган шешәне, шап иттереп, өстәлгә куйды.

– Җәмәгать, кичерә күрегез, шешә тулы түгел, килгәндә машина карга батты, күтәреп алып чыгарга туры килде, шулхәтле йөкне үз җилкәмдә алып чыккач, бераз кәгеп куярга туры килде. Калганын инде, Гарифҗан, син кара.

– Булыр анысы, булыр, Мәхмүтҗан, тик чәй эчү җыелыштан соң булыр, – диде Гариф абый җитди рәвештә.

– Менә сиңа яңа роман китердем, Гарифҗан. Юлда килгәндә яздым. Исеме да– «Юллар, юллар».

– Шуннан башлыйлар аны, Мәхмүтҗан, – диде Гариф абый. Гомумән, ул ярата иде яңа әсәр китергән әдипләрне. Гариф абый һаман арлы-бирле йөренә. Мәхмүт артыннан ук бүлеккә килеп кергән Шамил Бикчурин түзмәде:

– Менә ичмасам язучы, Мәхмүтне әйтәм, юлда күргән фаҗигасен юлда ук язган да. Ә син, начальник булдым дигәч тә, бер күтеңә урын тап инде, Гарифҗан. Ни өчен без сиңа түрәләр утырырлык ялтырап торган өстәл сатып алдык! Гарифҗан, дим, безнең белән утырып сөйләш әле, – диде.

– Булды-булды, утырыштык, – диде Гариф абый һәм үзенең зур булмаган өстәле янына барып утырды. Чынлап та, кем генә бүлмәгә килеп кермәсен, Гариф абый арлы-бирле йөрүдән туктамады, ниһаять, Шамил әйткәч, бераз уңайсызлык тоеп булса кирәк, өстәл артына кереп утырды. Шунда Гамил Афзал телгә килде:

– Гарифҗан, әйдә аякларны алышабыз. Минем гел утырып кына торасым килә. Син дә утырып сөйләшергә гадәтләнерсең, – диде.

– Булды, җәмәгать, башладык. Мин бик шат барыгызның да килүегезгә. Башта сезне, хөрмәтле әдипләр, соңгы көннәрдә бүлектә булган яңалыклар белән таныштырам.

Иң әүвәл ул Рафаил Төхфәтуллинның яңа басылган повестен мактады, Гамил Афзалның соңгы шигырьләренә тәмам таң калдым, дип кинәнде, Шамил Бикчурин безнең төзүчеләргә канат куйды, хәтерем ялгышмаса, ул бүген «Каты токым» романын тәмамлап ята. Уңышлар телик аңа. Саҗидә турында әйтеп тә торасы юк, соңгы айда казанлыларны көнләштерерлек шигырьләр бүләк итә. Гомер юлдашы Әдип тә тик ятмый, истәлекләр күтәреп чыкты. Мәхмүт юлда ук роман язган әнә, ягъни юлда ук бер романлык материал җыйган. Үзем дә тик тормыйм, яңа роман язып ятам. Ләкин мин әле безнең төбәктә тагын бер яшь каләм иясен таптым. Ул Баулыдан – Мөсәгыйт Хәбибуллин. Ул безгә повесть китергән иде, мин аны Казанга җибәрдем. Проза бүлегендә утыручы Яхъя Халитов, журналда басачакбыз, дип ышандырды.

– Каян-каян? – дип сорады Мәхмүт Хәсәнов.

– Баулыдан.

Мәхмүт Хәсәнов миңа карап алды да, урыныннан торып, килеп кулымны кысты.

– Күчеп кил Азнакайга, Мөсәгыйт туган. Азнакай киләчәктә Татарстанның көнчыгыштагы башкаласы булачак.

Көлештеләр.

Ләкин сәер хәл, күп тә үтми язмыш мине Азнакайга китерде. Азнакайга күчеп килгәч тә, Гариф абый безне ташламады. Бер тапкыр хәтта өлкән язучылар белән Азнакайга килде. Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Сафа Сабиров кебек аксакалларны мин беренче тапкыр Азнакайда күрдем. Азнакайда Гариф абый яшь язучыларның зур җыелышын уздырды. Җыелыш район газетасының (Мәхмүт белән мин эшләгән бинада)«Маяк»



Казанның Новаторлар урамында Гариф Ахуновка мемориаль такта ачу. 2000

редакциясендә узды. Әйтергә кирәк, район газетасы редакторы Ибраһим абый Дәүләтшин (мине редакциягә чакырып алучы) гаҗәеп дәрәҗәдә әдәбиятны ярата, редакциягә язучыларны тартырга тырыша иде. Шул елларда яңа гына армиядән кайткан Марсель Галиев тә беренче хикәя-шигырьләрен район газетасында бастырды һәм актив рәвештә яшь язучылар түгәрәгенә йөри башлады. Шул ук вакытта минем сабакташым (без аның белән университетта бер группада укыдык) Әнәс Исхаков та шигърият оеткысын «Маяк» газетасыннан алды.

Ике елдан мин, шәхси сәбәпләр аркасында, гаиләм белән Таҗикстанга киттем. Анда Рудаки исемендәге мәктәптә балаларга тарих фәне укыттым. Өч-дүрт елдан мине шул ук Гариф абый һәм Зәки Нури Казанга Татарстан Язучылар союзына эшкә чакырдылар. Мин инде күптән Казанга кайтырга хыялланып йөри идем, бу тәкъдимне бик теләп кабул иттем. Чөнки бу елларда инде минем берничә повестем, иң мөһиме «Чоңгыллар» романым укучыларга барып ирешкән иде. Һәм мине шул елда СССР Язучылар союзына әгъза итеп алдылар. Казанда янә Гариф абый кул астында аның ярдәмчесе булып эшләргә туры килде. Язмышымдыр инде, мин Ибраһим Гази, Афзал Шамов, Мирсәй Әмир, Зәки Нури рәис булып эшләгәндә дә ярдәмче булып калдым. Хәтта Туфан Миңнуллин рәис булганда да хәзерге яңа Татарстан Язучылар берлеге бинасын ремонтларга туры килде. Мин горурлана алам, рәисләр ярдәмчесе булып эшләгәндә, югарыда әйткән рәис-язучылар, дөньяларын онытып, тәгаен язучылар турында аталарча кайгыртып эшләделәр, авыр чакларда, кулларыннан килгәнчә, һәммәсенә дә ярдәм кулы суздылар, шул исәптән гел алар янында булган мин дә, көчемнән килгәнчә, яшьләргә дә, өлкәннәргә дә ярдәм иттем. Ә Гариф абый шулар арасында аерым урын алып тора, чөнки ул мине, колагымнан тартып диярлек, язучы итте. Кылган игелекләре өчен аңа һәм хатыны Шәһидә апага мең рәхмәт.

*Мөсәгыйт Хәбибуллин,*
Татарстанның халык язучысы

# Кордашым-Ахун

Университетның татар бүлегендә без бер заманда укыдык, әдәбиятка да бер чордарак бастык. Ул, миннән беркадәр олырак булса да, укырга бер елга соңрак керде. Беренче очрашу-танышу ничегрәк булгандыр, хәзер инде онытылган. Шунысы нык хәтердә калган: ул безнең кебек «апщежития»дә – тулай торакта тормады, университет ишегалдындагы бер катлы авыл өендә марҗада фатирда торды. Агач өйнең ярты-сын биләгән бүлмәдә аның белән тагын бер-ике студент тора иде, шуларның берсе чуаш егете иде бугай.

Бервакыт ул мине үзенең шул өенә алып керде. Беркадәр мактанып, горурланып, Ахун миңа үзенең картиналарын күрсәтте. Иңе бер, буе бер метр ярым чамасы булган катыргы кәгазьләрдә ачык төстәге буяулар белән төрле күренешләр сурәтләнгән. Яшел камышлар арасында йөзеп йөргән аккошлар да, зәңгәр болытлар да, ерактагы тау ар-тыннан чыгып килгән кояш та, кемгәдер, нәрсәгәдер төзәп ук атучы сугышчылар да бар иде кебек ул картиналарда.

Кыскасы, монда миңа бер нәрсә мәгълүм булды: әдәби иҗат белән кызыксынучы Ахун – Гариф Ахунов – рәсем сәнгате белән дә мавыга икән. Минем кебек үк, дип әйтер идем, дөрес булмас. Чөнки Ахун яшь ягыннан гына түгел, кайбер башка яклары белән дә ул чактагы Нуриханнан олырак, аңлырак һәм остарак булган. Укудан буш вакытла-рында ясаган картиналарын ул базарга чыгарып сата һәм шуның белән әзме-күпме акча эшли икән! Без, җүләр, университет түләгән фәлән сум стипендияне тиенләп тотудан башкасын күз алдына да китерә алмыйбыз.

Ләкин, дөресен әйткәндә, ул елларда Ахун гына түгел, бүтән студентлар да ничектер акча эшләү әмәлен табалар иде. Мин беренче курста укыганда, мәсәлән, башка группа студентлары Иделдә баржадан утын, карбыз, арпа бушатырга, аерым кешеләргә утын кисәргә йөриләр иде. Безнең белән бер бүлмәдә торган Фикрәт Табиев – булачак обком секретаре, илче һәм министр – шундый эшләрдә йөрүчеләрнең иң активларыннан иде.

Адәм баласына чын иҗат, күрәсең, кул кушырып утырмыйча, яшьтән үк үз көнеңне үзең күрергә өйрәнүдән башланадыр. Эзләнүче, табучы, үз тамагын үзе туйдыручы кеше һәрвакыт алга омтыла һәм ахыр чиктә барыбер теләгенә ирешә. Тиешле шартлары бул-са, махсус мәктәпләрдә укыса, Ахуннан, бәлки, атаклы рәссам чыгар иде. Кырыгынчы-илленче еллардагы университет студенты Гариф Ахуновтан рәссам түгел, язучы чыкты. Татарның, Татарстанның горурлыгы – Арча ягы улыннан атаклы, киң колачлы, шигъри җанлы каләм остасы чыкты.

Иҗат кешесе булса да, аңа озак еллар түрәлек вазифаларын да башкарырга туры килде. Язучы булган түрә кеше, җитәкче кеше үз бүлмәсендә иҗат эше белән генә шөгыльләнеп утыра алмый. Вакытның күпмедер өлешен ул рәсми кабинетта кешеләр кабул итеп, телефоннан сөйләшеп уткәрә, кирәк булса, үзеннән олырак түрәләр ал-дына барып баса, төрле җыелышларда, очрашуларда, тантаналарда, юбилейларда, мәҗлесләрдә катнаша. Аңа анда төрле сүзләр сөйләргә, кемнедер тәнкыйтьләргә, кем-



Гариф Ахунов, яшь җырчы Муса Маликов һәм Светлана Захарова. Казан, 1991

недер мактарга, якларга туры килә. Боларның һәркайсына да өлгерергә һәм шул ук вакытта языла башлаган яңа әсәреңне дә онытмаска кирәк.

20–30 ел буена Гариф Ахунов татар әдәбиятының, Татарстан язучыларының җитәкчесе һәм абруйлы вәкиле булды. Менә шундый тыгыз, тынгысыз шартларда үзе өчен дә вакыт табып, ул романнар да язды, хикәяләр, пьесалар, истәлекләр дә язды. Аның төрле темага язылган рецензияләрен, мәкаләләрен әйтеп-сөйләп бетерерлек түгел.

Әдәбиятта, сәнгатьтә аны кызыксындырмаган бер генә әсәр дә, бер генә шәхес тә юк иде сыман. Газета-журнал битләрендә, радио-телевидение чыгышларында бик күпләргә карата ул үзенең тәнкыйди-җылы сүзләрен әйтте. Җитәкче буларак та, гомумән язучы буларак та, Гариф Ахунов башкаларга карата ярдәмчел һәм кечелекле булды. Бу уңайдан мин, мәсәлән, Нурихан Фәттахка РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелүнең турыдан-туры аның тырышлыгы белән эшләнгән эш булуын әйтмичә кала алмыйм.

Аның тагын бүтәннәрдә сирәк очрый торган кайбер башка сыйфатлары да бар иде. Мәҗлесләрдә ул, тапкыр сүзләр әйтеп, берәр яңа мәзәк сөйләп, кешеләрне көлдерергә ярата иде. Аннан соң прозаик Гариф Ахунов, белеп, аңлап, шагыйрьләр турында сөйли ала һәм, кем турында гына сөйләмәсен, хәтердән аның шигъри юлларын кабатлый торган иде.

*Нурихан Фәттах,*
Татарстанның халык язучысы

# Әдипне-юксыну

Гариф Ахуновның вафатыннан соң шактый вакыт узды. Тик аның хатирәләре һич сүрелми, әдип телләрдән төшми. Академия театрында нинди генә тантана, кемнең генә иҗат кичәсе узмасын, аның исемен, аңа бәйле берәр вакыйганы, аның мәзәк итеп сөйләрлек тапкыр сүзен мотлак искә төшереп китәләр. Ул шулчаклы якты җанлы гүзәл кеше иде ки, аны онытырга, күздән җуярга мөмкин түгел.

Гариф Ахунов – үзенең шәхесе һәм иҗаты белән XX гасырның икенче яртысын тотырып торган затларның берсе. Көләч, ачык йөзле, хәрәкәтчән, тапкыр, җор телле, эшлекле, кешелекле әдип иде ул. Ул янып яшәде, янып иҗат итте, ул тоташ янды. Арабыздан көтмәгәндә тиз китеп барды. Фани дөньядан бакыйлыкка киткәндә, аның яше кечкенә түгел иде.

Мин аның кайнар чыгышларын, каршыдашлары белән бәхәстә китергән утлы дәлилләрен тыңлаганда, кашларын ук җәясе кебек даими киерелгән хәлдә күреп, ул озак яшәмәс, дигән курку кичерә идем. Бервакыт үзенә дә әйттем: «Гариф абый, бар нәрсәне болай кайнар йөрәгегез аша үткәрү Сезнең иҗат көчегезне аладыр». Әмма ул башкача яши белми иде. Ул үз-үзен аямый эшләтүче Гариф Ахунов иде. Тукай әйтмешли, көчләрен кара көнгә саклый алмады.

Язучылар берлеге рәисе булганга, аның бөтен яшәеше күз алдында узды. Әдәби ел йомгаклары икән, игътибар белән тыңлый һәм язып бара, мәсьәләләр куя, бәхәсләшә. Аның еш кына, җәһәт-җәһәт атлап, өлкә комитетына, Министрлар Советына яисә Югары Совет Президиумына ашыкканын күрәсең: яшь язучыларга фатир юллап йөри. Бер генә рәис тә язучылар өчен аның чаклы торак алып бирә алмагандыр.

Иҗат оешмасының нәүбәттәге корылтае бара. Байтак әдипләр рәисне алыштыру уенда. Урынына киләсе язучы да хөрмәтле, абруйлы шәхес. Әмма мин Гариф абыйны алыштыру өчен җитди сәбәп күрмим. Фикеремне янәшәмдә утырган Әхмәт Исхакка сөйлим. Ул: «Кави Нәҗмидән соң бу чаклы эшлекле рәиснең әле булганы юк. Мин иптәшләргә дә: «Үзен калдырыйк, иске чабата аякны авырттырмый», – дидем, тыңламадылар...» – ди.

Без – 50 нче еллар студентлары. Беркадәр фикер ирекге биргән XX съезд узган чор. Университетның татар филологиясе бүлегендә иҗади фикер тормышы гөрли. Әдәбиятта дөнья күргән һәр үткен әсәр без яшь филологларның күңелен җилкетә, җанлы бәхәсләр, кызу фикер алышулар туктамый. Тынгысыз әдәби түгәрәк җитәкчеләре, яңа әсәрне уртага салып тикшерү өчен, язучының үзен чакыралар. Нурихан Фәттахның «Сезнеңчә ничек?» романы, Әмирхан Еникинең «Йөрәк сере» повесте шушындый кайнар анализ һәм бәяләмә аша үтте.

Менә Гариф Ахуновның «Яшьлек яме» повесте буенча фикер алышабыз. Язучы ул чакта «Совет әдәбияты» журналында эшли иде. Аны беренче күрүебез. Түгәрәкнең әйдәүче көчләре әсәр каһарманнарын кызып-кызып «яклый», Айрат Гыйльмине сүгә. Мондый кайнарлык һич тә очраклы түгел: андый персонажлар арабызда ук бар, һавалы карьеристлар да, тыйнак, саф күңелле авыл балалары да җитәрлек. Түгәрәк җитәкчесе

Ибраһим ага Нуруллин канәгать елмаеп утыра.

Ниһаять, Гариф Ахуновның үзенә нәүбәт җитә. Ул чыгышын нечкәрәк тавыш белән шаян сүздән башлап китте:

– Гадәттә: «Кайчан һәм ни өчен тудыгыз?» – дип сорыйлар. Мин аларга болай җавап бирәм... – ди.

Студентлар көлешә. Ибраһим ага да елмая.

Яше бездән олырак Казбек Гыйззәтовның күзе үткен,ерактан күрә. Ул, миңа иелә төшеп: «Менә бу язучы бик перспективалы», – диде. Аның күрәзәсе тормышта расланды.

Гариф Ахунов әдәбиятның үзәгеннән баручы язучы булып китте. Әсәрләре әдәбиятта, сәхнәдә шаулады. Әмма мине чын мәгънәсендә сөендергәне һәм тирән тетрәндергәне аның «Идел кызы» романы булды. Әсәр каһарманнары: ягымлы, лирик табигатьле Нурия, фаҗигале Габбас мулла, төзәлмәс явыз Бүре Бадул озак вакыт телләрдә йөрде.

Язучылар берлегенең проза секциясендә роман турында фикер алышу булды. Гомәр ага Бәширов әсәрдәге догалар бирелешендә кимчелекләр барлыгын әйтте. Фатих ага Хөсни язучының осталыгына сокланып сөйләде. «Галимҗан Ибраһимовтан соң мондый колачлы тарихи әсәр, ай-һай, булдымы икән?!» – диде ул. Әмирхан ага Еники, ни гаҗәп, хәтәр сүзләр әйтте. Мулла һәм попларны марш бастырып биеткән милиционер кыз Наҗия сурәтенә бәйләп, ул: «Бу роман Октябрь революциясен дискредитацияли торган әсәр», – диде. Совет идеологиясеннән байтак таяк алган бөек әдибебез советка ихлас тугры иде.

Ул чакта яшь гыйльми хезмәткәр – мин дә чыгыш ясадым. «Әсәрнең чын кыйммәте аның безне озак сагындырган затлы эпик проза стилен яңартуда», – дидем. Гариф ага үзе стиль мәсьәләсендә М. Шолоховның «Тихий Дон» романын үрнәк итеп китерә иде.

Әдип әдәбият үсеше, сәнгать дөньясы өчен тирән кайгырту белән яшәде. Әдәбиятта олы талантлар хакында хөкем йөртәме, яшьләрне үстерү мәсьәләсен күтәрәме – һәр очракта ул үзен хуҗаларча җаваплы хис итә иде.

Өлкән әдипләребездән йә Гомәр ага Бәширов, йә Әмирхан ага Еники аның хакында кайчак кискен сүзләр ычкындыралар. Бәхәс кызулыгы белән әйтелгән бәя еш кына хаксыз да була. Әмма Гариф Ахунов үзе сокланган бу сәнгатькәрләргә карата фикерен үзгәртми, беркайчан да алар турында яман сүз әйтми. Ул олы җанлы, киң күңелле шәхес булып калды. Нәкый Исәнбәт һәм әле телгә алып узган классикларыбыз хакында аның бөтен бер шәлкем мәкаләләре дөнья күрде.

Гариф абый табигате белән гадел кеше иде. 1984 елның феврале. Мәскәүдә Язучыларның үзәк йортында Кол Галинең 800 еллыгына багышланган бөтенсоюз тантанасы бара. Юбилей комиссиясе рәисе – күренекле рус язучысы Анатолий Иванов. Президиумда Егор Исаев, Сергей Иванов, Георгий Ломидзе, партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре Мирзаһит Вәлиев, өлкән шагыйребез Сибгат Хәким, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов, нәшрият директоры Гарәф Шәрәфетдинов, ТӘҺЛИ директоры Яхъя Абдуллин, профессорлар Нил Юзиев, Миркасыйм Госманов, фән кандидатлары Шакир Һабилов, Фазыл Фасеев һәм мин утырабыз. Докладны Министрлар Советы рәисенең беренче урынбасары Мансур Хәсәнов ясады. Аннары зур концерт булды. Минем музыкасын Нәҗип Җиһанов язган «Йосыф-Зөләйха» җырым яңгырады. Кул чабып, торып баш ияргә мәҗбүр иттеләр.

Аннары Язучылар йортының банкет залында мәҗлес булды. Бервакыт тост әйтергә сүз нәшрият директоры Гарәф абый Шәрәфетдиновка бирелде. Гарәф абый китап нәшриятының Кол Гали дастанын бастырудагы эше хакында сөйләде, зур хезмәт куйган Ф. Фасеев, М. Госманов, Р. Даутов, Т. Хаҗиәхмәтовлар хезмәтен тәкъдир итте. Исемнәре аталган затлар, берәм-берәм чыгып, мәҗлес каршында баш иделәр. Шул-

чак исемнәрне санап бетергәч, Гариф абый, миңа ишеттермәслек итеп, Гарәф абыйга: «Нурмөхәммәтне, Нурмөхәммәтне әйт!» – ди. Мансур Хәсәнович тиз эләктереп алды: «Әлбәттә, Нурмөхәммәт», – ди. Г. Ломидзе сүзгә кушылды: «А как же, он у нас в ИМЛИ защитился, его книга находится у меня в шкафу!» Шулай итеп, Гариф абый минем 1979 елда ук басылган монографиямне телгә алырга мәҗбүр итте.

Гариф ага гаять батыр рухлы әдип иде. 1979 елда «Социалистик Татарстан» газетасында минем Дәрдемәнд турындагы мәкаләм басылып чыкты. Сыйнфый яктан үтә уяу бер кеше өлкә комитеты секретаре М. Вәлиевкә шикаять язган. Менә тотынды дөньяның астын өскә китерү, газета җитәкчеләре йокысын җуйды, шагыйрьнең иҗатын өйрәнәләр. Шәмси Хамматов җавап әзерли. Сүз хәтта аны эшеннән алу турында барган.

М. Вәлиев, Г. Ахуновка шылтыратып, фикерен сораган. Әдип мәкаләдә куркыныч бер нәрсә дә юклыгын, шагыйрь мондый мөнәсәбәткә лаек икәнен әйтте. Шау-шу шуның белән тәгәлләнә. Бу хакта Гариф ага соңрак үзе дә язып чыкты.

Күпкырлы әдип әдәби барышыбызда иң актив эшләгән тәнкыйтьчеләрдән булды. Аның абруйлы фикере Равил Фәйзуллин, Ренат Харис кебек шагыйрьләрне шигъриятнең кабатланмас күренеше итеп тәкъдир кылуда, бәлкем, хәлиткеч рольне уйнагандыр. Бу өлкәдә, мөгаен, аның күз алдында Әхмәт Фәйзи һәм Фатих Хөсни сыннары торгандыр. Аның тел төбеннән шул аңлашыла иде.

Үткен күзле, батыр рухлы, киң күңелле бу әдип каләмдәшләренең мөһим казанышын беренче булып күтәреп ала, яклый, югары бәяли торган иде.

Шәйхи Маннур «Агымсуларга карап» дигән автобиографик повестен «Казан утлары»на күтәреп бара. Беркадәр вакыттан мөхәррир Гариф Ахуновның фикерен сорый. Ачы теле белән бик күпләрнең хәтерен калдырган язучы курка-курка сорый. Гариф ага аңа русча итеп: «Выдающийся әсәр язгансыз!» – ди. Шәйхи Маннур, ышанып бетмичә, шактый вакыт аңына килә алмый тора.

Гариф аганы мин, һич курыкмыйча, галим иде, дим. Ул, безнең алты томлы «Әдәбият тарихы»бызның баш редколлегия әгъзасы буларак, һәр бүлекне җентекләп укый, һәр утырышка килә һәм тирән анализ бирә. Монда да ул әдәбиятның кайгыртучан хуҗасы булып эш итте.

Минем үз язмышымда да Гариф ага якыннан катнашты. Язучыларның әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышы икән, йә шигърият, йә тәнкыйть буенча доклад әзерләүне йөкли. Хезмәтемне игътибар белән укый, хуплау фикерен әйтә, матбугатта язып чыга. Сөйләү, киенү рәвешенә чаклы бернәрсә дә аның дикъкатеннән читтә калмый. Үзе дә рәссам булганга, улларымның рәсемнәрен күзәтә, хуплый, фикерен җәмәгатьчелеккә җиткерә.

Ул – туган телнең уяу сакчысы. Хилафлыкка гамьсез генә түзеп тормый, чатнатырып әйтә. М. Ш. Шәймиевнең, Президент булып сайлангач, халык алдында ант итү тантанасында татарча саф һәм матур итеп сөйләвен Гариф абый мөһим өстенлеге буларак билгеләп үтте.

Кыскасы, бу гүзәл шәхесне шагыйрь һәм язучылар, рәссам һәм артистлар, музыкант һәм журналистлар, галимнәр һәм дәүләт эшлеклеләре, киң җәмәгатьчелек әле бик озак сагынып искә алыр.

*Нурмөхәммәт Хисамов,*<br>
әдәбият галиме, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе<br>
*2004*

# Зураеп-калу

***

*Яшәсен! –*
*ирләрнең, кеше рәнҗетми,*
*якты хәтер калдырганы.*

Ни-нәрсәдән мәхрүм калганыңны югалткач кына аңлыйсың. Исән чакта, теге дә, ул да, бу да, мин дә дигәндәй, кайчандыр бер-беребездән мәңгегә аерылачакны белсәк тә, ул вакытта хис-тойгы әле шактый томанлы, абстракт, югалтуның ачы хәсрәте сәгате суккач кына йөрәккә төшә икән. Гариф абый Ахунов үлемен ишеткәч тә шулай булды.

Гыйбрәтле хәл: берәүләр киткәч, алар хәтер офыгы томанында шундук эреп югалалар, берәүләр, киресенчә, тагын да зураеп, күңелеңне билиләр; шәхеснең яшәештәге бәндәлеге онытыла, мәңгелеккә дәгъва иткән изге эшләре, олылыгы гына кала. Гариф абый Ахунов бакый дөньяга җиңел күчте дип беләм. Озаклап хаста булып үзе дә интекмәде, бүтәннәргә дә борчу салмады. Үлемнең табигый, Яшәүнең үзгә дәвамы икәнен раслагандай, тыныч кына китеп барды. Һәм, әйтергә кирәк, Бөек Күчештән соң аның исеме, рухы фани дөньялыкта зураеп, үсеп калды. Бу зураю, үсү күп меңләгән кешеләрнең күңелләре, сыкрау-әрнүләре, сагыну-сагышлары аша зураю булды. Озаккамы?

***

*Яшәсен! –*
*егетләрнең бик түбәннән*
*күтәрелеп дан алганы.*

Соңгы ярты гасырлык татар әдәбиятын Гариф Ахуновсыз күз алдына китерү кыен. Язган әсәрләре, китаплары буенча да, әдәби хәрәкәтне оештыруда кылган гамәлләре буенча да. Аны, мөгаен, татар совет әдәбияты классигы дип атау дөрес буладыр. Шушы чор сәяси тормышны, әдәби барышның бөтен позитив һәм негатив яклары чагылыш таба аның иҗат эшчәнлегендә. Бер яктан, Г. Ахунов шул чор идеологиясенең күндәм хезмәтчесе (КПСС съездлары делегаты, СССР Югары Советы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе секретаре...), икенче яктан, татар милләте, татар әдәбияты мәнфәгатьләрен армый-талмый кайгыртучы фидакарь халык улы булды (зур полотнолы әсәрләр авторы, Әлмәт Язучылар оешмасын оештыручы, йөзләгән яшь каләм ияләренә фатиха бирүче, татар әдәбиятын башка халыклар арасында үтемле пропагандалаучы, ару-талуны белми иҗат итүче...). Әле санап әйтелгәннәрнең һәрберсе турында бит-бит тәфсилләп язып булыр иде. Әмма андый хаҗәт юк: Гариф Ахунов бик билгеле шәхес һәм аның эшчәнлеге дә халыкка яхшы мәгълүм.

Кояш астында үз урыныңны алып, җирдә ышанычлы нык басып яши алу, шуңа өстәп, зур хезмәтләр һәм шанлы исем калдыру, һай, җиңел түгел бу дөньяда! Г. Ахунов – түбәннән күтәрелгән шәхес. Ятим балачак, сугыш уты өткән яшьлек... Югалып калырга, сынарга, бозык юлдан китәргә бөтен шарт килгән... Әмма Гарифҗан Ахунҗан

улы югалыр өчен яратылмаган булган шул. Үзәк ныклык, үҗәтлек, черәшеп эшли алу, халыкның киләчәгенә ышану, сүз кодрәтенә табыну аны олуг әдип иткән. Төрлесе булган гомерендә, төрлесе кичерелгән. Зиндан сәкеләре дә күрелгән, патша табыннарында да утырылган...

***

*Яшәсен! –*
*дус-ишләрнең көнләшмичә*
*якын итә торганнары.*

Гариф Ахуновның дуслары күп иде. Кайбер өнәп бетермәгән кешеләрнең дә, асылда, аның шәхесен танытмас итәрлек дәлил-дәгъвалары юк иде шикелле. Егетлек, ихласлык, юмартлык, ярдәмчеллек хас иде аңа. Бу сыйфатлар күпләрне әсир итәрлек асыл сыйфатлар шул. Шәхсән минем үземә дә утыз елдан артык Ахунов мохитендә яшәргә насыйп булды. Әдәбиятка ныклап аяк басуда аның шифалы йогынтысын нык сиздем. Хәтта күпмедер дәрәҗәдә әдәбиятта ул кичкән хезмәт юлын үтәргә туры килде. Әлмәт Язучылар оешмасы, Татарстан Язучылар берлеге, «Казан утлары» журналы... Бер үк постларны диярлек биләдек. Ул – алданрак, миңа соңрак насыйп булды бу миссия. Киңәшләшеп, ярдәмләшеп, әдәбиятыбыз тәрәккыятле милләтләрнекеннән ким булмасын дигән ният белән эшләргә тырыштык. Шөкер, кайбер игелекле эшләр башкарылды дип уйлыйм. Хәер, аның кешелеклелеген тойган, хәер-фатихасын алган, олылау сүзен ишеткән каләмдәшләр бер мин генә түгел, алар бихисап. Кемнәр турында гына язып чыкмады да, кемнәр турында гына зур-зур трибуналардан сөйләмәде Гариф абый! Йөзләгән-йөзләгән мәкаләләр, иҗат портретлары, рецензияләр, тәкъдим-рекомендацияләр... Бүгенге Язучылар берлегендәге йөз илледән артык каләмдәшләребезнең, ихтимал, яртылабы теге яки бу формада аның булышлыгын тойгандыр дип уйлыйм. Каләмдәшләр генәме соң? Артисты да, рәссамы да, игенчесе дә, нефтьчесе дә...



Гариф Ахунов «Дядя Степа» – Сергей Михалков белән дус иде. Казан, 1984

***

*Яшәсен! –*
*исәннәрнең үлгәннәргә*
*чардуган кора алганы.*

6 июньдә Гарифҗан Ахунҗан улын Арчаның татар зиратында җирләп кайттык. Моннан нәкъ ике ел элек без – «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре – әдипнең туган авылы Өчиле җиренә барып, табын корып утырган идек. Ул авыл инде юк, кайбер нигез урыннары гына беленеп тора. Әмма зират исән калган. Гариф абыйга бик моңсу иде бугай. Аның тау итәгеннән ургып аккан чишмәгә озак карап торганы хәтердә калган. Кайткач, куен дәфтәренә шигырь сыман мондый юллар язып куелган:

## *Сәхрәләргә чыккан идек бер...*

*Бу җирләрне яд итәргә*
*Төркем булып килдек каладан.*
*...Авыл күптән беткән.*
*Тау битендә*
*Зират та чишмә калган.*

*Яктык учак. Кыздырдык шашлык.*
*Тостлар яңгырады телдән телгә күчеп.*
*Янда бөтерелә иясез бер көчек.*
*Фанилыкны искәртә талгын җил исеп*
*Зират ягыннан.*

*...Бу адәмнәрнең дә күбесе юк дип була.*
*Йөрсәләр дә монда ашап-эчеп.*

...Арча зиратын үзенең калку урынында калдырып, Казанга кату юлында сагышлы, борчулы уйлар биләде күңелне. Әдәбиятыбызның Арча җиреннән чыккан имәндәй баһадир әдипләре китеп бетеп бара. Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Г. Ахунов, Ф. Миңнуллин... Боларсыз татар прозасын күз алдына китереп буламы соң? Биш-алты ел элек кенә бергә аралашып йөргән идек бит әле!.. Аларны кемнәр алыштыра? Аларныкы кебек тормыш тәҗрибәсе һәм тел байлыгы булган яңа буын язучыларыбыз бармы?

Әле күптән түгел генә дөньякүләм мәшһүр әдипләр, төрки халыкларның уртак горурлыгына әверелгән язучылар Ч. Айтматов белән О. Сөләйманов, Казанда булып, татар язучылары белән очраштылар. Кызыклы гына әңгәмә булды. Шунысы да сискәндереп куйды, бәй, бу зур затлар белән аралашкан, бер-берләре белән кочаклашып күрешерлек язучыларыбыз юк дәрәҗәсендә икән. Янә Гариф абый искә төште. Ул арада булсамы!

***

*Яшәсен! –*
*ирләрнең, көчле булып та,*
*сабыйлыгын җуймаганы.*

Гариф Ахунҗан улы Ахунов безнең күңелләрдә сабый күңелле, көчле ихтыярлы ирегет булып калды.

*Равил Фәйзуллин,*
Татарстанның халык шагыйре
*Аккош күле, 2000, 28 июнь*

# Гариф-Ахунов-белән-бер-сәяхәт

Гариф ага Ахунов – кырык елдан артык дәвердә минем иң күп аралашкан язучыларымның берсе. Безнең арада сер бүлешүләр дә, киеренке сөйләшүләр дә, минем хаксыз чакларым да булды, әмма бер-беребезгә булган ихтирам һәрвакыт өскә чыга килде. Мин аңа һәр очракта ага итеп карадым, ә ул мине тиңдәш дәрәҗәсенә күтәрергә шулай ук җай таба белде.

Миңа Гариф абый белән бергә Мәскәүдә дә, Казанда да, Советлар Союзының башка төбәкләрендә дә олы әдәбият-мәдәният бәйрәмнәре оештыруда һәм аларны үткәрүдә катнашырга туры килде. Гариф абыйның партия өлкә комитетында, Министрлар Советында, язучылар, галимнәр, чит илләрдән килгән делегацияләр алдында, авыл клубларында, мәктәпләрендә ясаган чыгышларын хәтерлим. Аңа иң җаваплы җыелышларда, партия конференцияләрендә, Россия язучылары съездларында трибуна бирәләр иде, һәм ул һәрвакыт аудиторияне тотып тора торган сүз әйтә иде. Аның иң мәртәбәле мәҗлесләрдә телле яшен сыман ялтыраган тамада чаклары да, «Туп-туп кына басып килә...» дип, меңенче тапкыр җырлаулары да, ияген күккә чөеп: «Һа-а!..» диеп көлүләре дә, матәм җыелышларында елатырлык итеп хушлашу сүзләре әйтүләре дә күз алдында тора. Әле булса мин аның яңгыравык тавышын ишетәм кебек...

Халык «Ун тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр күр!» ди. Бәлки, ул хаклыдыр... Ләкин барыбер маңгай күзе күргәнне күңел күзе аша кичермәсәң, ялгышуың бик ихтимал. Хәзер Гариф ага Ахунов безнең арада юк... Үзенә һәм әдәбиятка, дусларына карата әйтелгән кайбер хаксыз фикерләргә дә җавап кайтара алмый ул – ягъни үзенең безнең хәтерләрдә калган образына яңа төсмерләр дә кертә алмый, булганнарын да яшерер чарасы юк... Һәм мин аңа фәкать күңел күзем белән генә карый алам. Ә күңел күзе ул бөтен нәрсәне берьюлы берләштереп күрсәтүче күзлек кенә түгел, ә кешенең төп сыйфатларын вактөяктән аерып алып үлчи торган әхлакый бизмән дә...

Гариф ага Ахунов безнең республикада әдәби тормышны оештыручыларның иң активы булды дисәм, ялгышмам дип уйлыйм. Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, идарә рәисе, «Казан утлары» журналының баш редакторы булып җәмгысе егерме елдан артык эшләве моның һәркемгә дә күренә торган тышкы, рәсми ягы булса, үз иҗатының эстетик, әхлакый, сәяси юнәлеше – бусы язучының асылы – шул еллар татар әдәбиятының зәвыгына сизелерлек йогынты ясадылар. Бу йогынтыны һәр язучы, әдәбият галиме, һәр чор үзенчә билгеләр... Ләкин шунысы бәхәссез – үзәге ныклы, көчле шәхесләрнең генә әдәбият мәйданында үз эзен калдырырга хәленнән килә. Социалистик реализм теориясе, сәнгатькә партиячел караш чәчәк аткан, хезмәт темасы байрак булып җилфердәгән чорларда язган әдипләрнең иҗатларына хәзер ревизия ясарга омтылу сизелә. Гариф аганың күпкырлы иҗаты, минемчә, бу шаукымны Галимҗан Ибраһимов, Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Атилла Расих иҗатлары кебек үк уңышлы узар.

Мин язучыларны, аларның башка сыйфатларын читкәрәк куеп торып, тырышларга һәм иренмәүчәннәргә бүләм. Тырышлар башлаган эшләрен, әллә нинди каршылык-




1975 елның 8 маенда язучылар белән Печищи авылына, Янка Купаланың әдәби музее ачылышына бару. Беренче рәттә, сулдан өченче Гариф Ахунов

ларны җиңә-җиңә, максатларына таба алып баралар. Иренмәүчәннәр исә, язылачак әсәрләргә кирәк булып куюы бар дип, теләсә нинди шартларда материал туплыйлар. Гариф абый менә шушы олы сыйфатларның икесенә дә ия язучы иде. Гомумән, ул барлык әсәрләрен дә персонажлары мохитен, тарихи документларны тирәнтен өйрәнеп яза иде. Моның бер мисалы итеп мин Гариф абыйның бер сәяхәтен сурәтләп үтәм.

Гариф ага Ахунов «Идел кызы» романын яңа гына башлаган елларда, кыш көннәренең берсендә, без аның белән Ульяновск өлкәсенә, мин дөньяга килгән Кәшә авылына кайттык...

Бу авылның гаҗәеп кызыклы кешеләре турында мин аңа сөйләштергәли идем, һәм ул, бер дә иренмичә, минем сөйләгәннәрне куен дәфтәренә теркәп тә куя иде. Яза торган романы «комга терәлде» микән, әлеге язмалар бик вакытлы исенә төште микән, Гариф абый миңа Кәшәгә барасы килүе хакында әйтте, һәм мин әлеге сәяхәтне оештырдым. Гариф абый ул чакта Язучылар берлеге рәисе иде, ә мин – мәдәният министры урынбасары.

Кәшә халкы СССР Верховный Советы депутатын һәм үзенең якташын матур каршы алды. Буранлы көн булуга карамастан, клубка халык та шактый җыелган иде. Гариф абыйга сораулар да күп булды. Ул аларга һәрвакыттагыча елмая-елмая, үзенең әсәрләреннән һәм үзе тәрҗемә иткән М. Шолохов китапларыннан кызыклы мисаллар китерә-китерә җавап бирде. «Хуҗалар», «Ардуан батыр» турында берничә бик конкрет һәм төпле сорау булды. Әле күптән түгел генә авторына Тукай премиясе китергән бу әсәрләр әдәбият сөючеләр телендә иде. Гариф абый алар турында аеруча тәфсилләп, дулкынланып сөйләде. Бер нефтьченең төнлә, ялгышып, күршесенең пешкән итен ашавы хакындагы эпизодны укып, залны озак кул чаптырды. Күренеп тора, сораулар язучының күңеленә хуш килгән. Минем болай да күтәренке кәефем тагы да күтәрелеп китте – сораулары аша якташларым авылның, халыкның чыннан да кызыклы, зат-



Казанның Профсоюз урамындагы А.С. Пушкин булган Перцев йорты янында язучылар белән. 1987

лы булуын күрсәттеләр. Мин шул вакытта тагын бер мәртәбә куанычның горурлыкка әверелүен тойдым...

Шулчак Гариф абый көтелмәгән бер эш эшләде. Ул залга мөрәҗәгать итеп, болай диде:

– Сез миңа сорауларны мулдан яудырдыгыз. Мин аларга рәхәтләнеп җавап бирдем. Хәзер мин дә сезгә бер-ике сорау бирим әле... Менә Ренат миңа Казанда сезнең авылдагы Ләлек, Мамык, Чыбыркы һәм шундыйрак кызыклы кушаматлар турында сөйләде... Тагын нинди кушаматлар бар? Алар кайдан килеп чыккан? Менә шулар турында сөйләмәссезме?

Зал шаулап көлеп алды. Кемдер: «Ә нәрсәгә кирәк ул сиңа?» – дип кычкырды. Гариф абый шунда үзенең «Идел кызы» дигән роман язуы турында сөйләп китте. Кемдер: «Алай булгач сүләмибез...» – дип кычкырды. «Сүлик – китапка кереп калыйк...», «Ничек язма келидер бит әле...» – дигән тавышлар да яңгырады... Очрашу шактый сузыла башлаган иде инде. Кичәне йомгаклап, «Ярар, үзебез сүләрбез!» дип, «Волга» колхозы рәисе Харис ага Газизов безне кичке чәйгә алып китте...

Кичке чәй бик күңелле узды. Катнашучылар арасында, авыл, колхоз, партия оешмасы җитәкчеләреннән тыш, заманасында «Чаян» редакциясендә фельетончы булып эшләгән Галимҗан Насыйров (Шадра) һәм аның даими партнерлары булып шаяртучылардан минем абзам – укытучы Әнвәр Фәезов, Исмай Насыйров (Кәнәч) һәм тагын берничә укытучы бар иде. Алар Гариф абыйга кайбер кызыклы кушаматларның тарихын сөйләделәр. Көлә-көлә тиргә баткан Гариф абый шунда: «Сезгә, егетләр, төрек солтанына Кәшә мишәрләре хаты язарга гына кирәк мондый тел белән...» – диде. «Беренчедән, Төркиядә күптән инде солтан юк!» – диештеләр тегеләр. «Икенчедән, без, Гариф брат, мишәр тегел...» – дип, яңа бәхәс кузгаттылар... Гариф абый, хуҗаларны үпкәләттем,



Борынгы Болгар җирендә Япония телевидениесе фильм төшерә. Уртада япон язучысы Сакио Комацу. Роберт Миңнуллин, Гариф Ахунов аңа татар халкы тарихын сөйлиләр. 1986

ахры, дип борчылып, дөньядагы бик күп атаклы татарларның мишәр булуы хакында, бүгенге көндә Татарстан җитәкчеләре арасында да мишәрләрнең байтак булуы хакында сөйләде.

– Безнең беренче секретарь Табеев, мишәрләрне «высший сорт татар», дип әйтә! – дип юатырга тырышты Гариф абый һәм, теманы кискен борып, юморга бай Кәшә халкы өчен матур тост күтәртте... Гариф абый оста итеп көлдерә дә, матур итеп көлә дә белә иде һәм, иң мөһиме, үзе дә иң кырыс шаяртуларны да егетләрчә күтәрә иде...

1978 елда «Идел кызы»ның беренче китабы басылып чыкты. Анда Кәшә материалларының урын алуы бүген дә минем күңелемне җылытып тора. Гариф абыйның Кәшәгә тагын бер барып кайтасы килә иде. Бу хакта аның миңа әллә ничә тапкыр әйткәне булды. Мин дә берничә мәртәбә теге сәяхәтне кабатларга вәгъдә бирдем, ләкин ул вәгъдәләр, кызганыч ки, үтәлми калдылар һәм искә төшеп сызландыра торган үкенечкә әйләнделәр.

*Ренат Харис,*
Татарстанның халык шагыйре
*2001, июнь*

# Гомерең–озын,-картлыгың-кыска-булсын

Хөрмәтле Гарифйән!

Бездә, Башкортстанда, сине бик тә үз күргәннәр, исемеңне тутырып, җылы итеп, Гарифйән, диләр.

*Чөнки Синең ил бәһаләр*
*Юнең бар,*
*Йөрәкләрне били торган*
*Җаның бар.*

Син яшәгән җитмеш елның, Гарифйән, яртысыннан күбрәген, күзгә-күз карашып, сүзгә-сүз куешып, иҗади сулышларыбызны тоешып, байтак-байтак шәраб коешып, араларга салкын җил җибәрми, күләгә төшерми, тату яшәдек. Шул заман эчендә Сиңа карата минем күңелем суынмады. Син соңгы егерме биш елда булып узган минем түгәрәк даталарымда, йортымны олылап, табыннарымны ямьләп, мәҗлесләрдә тамада булдың. Озын сөйләсәң дә, бозык сөйләмәдең, мине мактасаң да, оялырлык итеп, чама-



Гариф Ахунов (уңнан беренче) – ике чакырылыш СССР Югары Советы депутаты. 1980 еллар



Гариф Ахунов дусты – шагыйрь Мостай Кәрим (Уфа) белән. 1976

сыз мактамадың, хәтта үтереп мактаганда да мактап үтермәдең. Мин дә сиңа карата бүген үземне шулайрак тотармын.

Беренче очрашкан чакта ук Син без җырлаган җырга кушылдың:

*Тып-тып кына басып килә*
*Көмеш тояк тулпар атым...*

Ул чакта Синең иҗатыңның тулпары, ышанычлы итеп, тып-тып басып, татар әдәбиятына, күпмилләтле зур совет әдәбиятына кереп бара иде инде. Әмма Синең иҗат тулпарың бәйгеләрдә ярышып кына даннар һәм бүләкләр алмады. Дөрес, бәйгеләрдә дә ул күп вакыт ал бирмәде. Ул тулпар, асылда, татар әдәбиятының чабыш аты да, сабан аты да, йөк аты да, гаскәр аты да булды һәм була килә. Ярыш мәйданында ул ап-ак күбеккә батса, буразнада ул кап-кара тирләрен түгә.

Хәзер өченче затка күчеп, «Син» диясе урында «ул» дип сөйләячәкмен.

Тел төбем шуңа бара: мондый иҗатчыларның җырына да, зарына да халыкның төрле-төрле катлаулары колак сала, йөрәгенә һәм аңына кабул итә. Һәркем үзенең рухына таныш азыгын таба.

Гариф Ахунов татар әдәбиятында үз урынын күптән раслады. Аның әсәрләре, милли ызаннарны үтеп, бүтән тарафларга, урыс теле ярдәмендә бүтән илләргә, бүтән телләргә барып җитте. Татар халкы хакында, татарның рухи булмышы хакында вак сүз сөйләп, дөнья алдында милләтенең дә, үзенең дә дәрәҗәсен төшермәде. Эреләнми генә эре сүз сөйләде, сөйләп килә.

«Ызан» дидем дә, әллә ничек ямансу булып китте. Пётр I Аурупага тәрәзә куйганнан соң, өч гасырга якын гомер үткәч, бөек илдә халыклар, милләтләр, әдәбиятлар, сәнгатьләр арасында биек-биек коймалар хасил булды. Нигездә, ул коймаларны каты бәгырьле, йомшак зиһенле политиклар һәм аларның мәнсез яраннары һәм иярченнәре койды.

Бу җәһәттән язучыларның мөкатдәс бурычы шулдыр димен: әлеге коймаларны берьюлы гына җимереп булмаса да, һич югында, капкалар тишәргә, капкалар ачарга кирәк. Гариф Ахунов кебекләрнең иҗаты, шәхесе, эшмәкәрлеге әнә шул капка ачучылар хезмәтен үтәргә бурычлы. Чөнки дөнья күрмәгән, дөньяга күренмәгән адәм – надан, бичара. Дөньяны күреп тормаган, дөньяга күренеп тормаган әдәбият, сәнгать, фән бөек куәткә ирешә алмаячак. «Үзебез генә...» дип лаф ору – җитлекмәгәнлек билгесе. Коймалар коелганчы ирешелгән казанышлар турында уйласак, сез минем бу борчылулы сүзләремнең раслыгына ышанырсыз.

Хөрмәтле җәмәгать!

Бу мәҗлескә мин сезгә, татарларга, Гариф Ахуновның нинди язучы икәнен бәйнә-бәйнә сөйләп төшендерергә килмәдем. Белеклеләр болай да беләләр. Белмәгәннәр өйрәнеп белерләр. Рухларын, аңнарын баетырлар.

Мин 70 е генә тулган энемне, зур бәйрәме белән котлап, кочакларга гына килдем. Бер генә теләгемне әйтәм: гомерең озын булсын, Гарифҗан, картлыгың кыска булсын, Гарифҗан!

## *Казан*

Нишләп әле шулай килеп чыкты? –
Үзем дә һич аңламыйм, Казан.
Газиз исемеңне тәүге тапкыр
Шигырь итеп ак кәгазьгә язам.

Ә бит сиңа хәйран калганнан соң,
Ярты гасыр нинди гомер акты!
Килгән саен урыным түр башында,
Җаным-тәнем сый-хөрмәткә батты.

Төннәрендә йолдызларың, Казан,
Җемелдәшеп күзләремә бага.
Идел дулкыннары, иркә итеп,
Ярны түгел, йөрәгемне кага.

Булды еллар, шигырьләрем синдә
Канатланды, һаваларга ашып.
Рухым исә Камал сәхнәсендә
Үкседе дә, шатланды да шашып.

Урамыңны күп таптадым, Казан,
Кызмача һәм... хәтта аек баштан.
Берчак капыл күз чагылып китте
Тимбикова атлы яшь Кояштан.

Туфрагыңа баскан саен, Казан,
Яна... туңа... минем бәгырьләрем.
Бәгыремдә яши икән дуслар,
Бәгыремдә дуслар каберләре.

Туфан, Фәйзи, Хәким, Ахун, Риза –
Уннар, йөзләр күз алдымнан уза...
...Җирдә һаман ак бураннар туза,
Күкләр һаман, күкрәп, яшен сыза.

Таушалмаган Сөюемне, Казан,
Пышылдарга сиңа бүген базам.
Данлы исемеңне мәңгелеккә
Дога итеп язам: Казан... Казан...

*Мостай Кәрим,*
Башкортстанның халык шагыйре

# Гариф-Ахунов

Гариф абыйны хөрмәт белән, зурлап искә алмаган укучы да, язучы да юктыр шикелле тоела миңа. Мәскәүдәге М. Горький исемендәге Әдәбият институтына барырга җыена идем. Ул вакытта Язучылар берлеге Бауман урамында иде. Гариф абый янына киттем. Кабул итү бүлмәсенә барып кердем. Сәркәтибе машинкада эшләп утыра.

– Гариф абый үзендәме? – дип сорадым исәнләшү белән.

Гариф абыйның бүлмәсе ачык иде. Сәркәтибе җавап биргәнче:

– Үземдә, үземдә, кем анда? – дигән тавыш ишетелде кабинеттан.

Аның кабинеты янына барып, эчкә үтми генә җавап бирдем:

– Мин идем, Гариф абый.

– Кер, әйдә. Уз, ник басып торасың ишек төбендә ятим малай шикелле. Йә, сөйләп җибәр...

– Шул инде... Направление... Мәскәүгә...

– Яхшы, энем, – диде Гариф абый. – Хикәяләреңне укыдым, каләмең өметле күренә, бирербез. Әле бик ашыгам, Совминда көтәләр, иртәгә иртүк синең эшне хәл итәрбез.

Танылган язучы, депутат кеше алдында югалып калганмындыр, күрәсең, борылып чыгу ягына атладым.

– Син кайчан китәргә җыенасың Мәскәүгә? – дигән сорау ишек төбенә барып җиткәндә куып тотты мине.

– Бүген китә идем, Гариф абый, – дидем мин, борылып.

– Бәй, туктап тор әле, энем, ник аны башта ук әйтмисең? – дип, урыныннан кузгалды Гариф абый. – Эшләремне туктатып торыйм әле алай булгач. – Шулай дип кабул итү бүлмәсенә чыкты да: – Боларны соңыннан эшләп бетерерсең, менә бу егеткә фирменный кәгазьгә направление язып бирик әле... – диде сәркәтип кызга.

Шулай итеп, мин кереп направлениене кулыма алганчы, ун минут чамасы вакыт үткәндер, бәлки.

– Уңышлар телим, энем, сынатма! – дип, кулымны кысып фатихасын бирде Гариф абый.

Менә шулай, үзенең ашыгыч эшен дә калдырып, беренче чиратта кеше турында кайгырта торган олы йөрәкле, изге хисле әдип, алыштыргысыз шәхес иде Гариф абый. Аның урыны, һичшиксез, җәннәттә булыр, моңа минем иманым камил.

***

Ул заманда Әдәбият институтына кергәндә беренче тур – комиссия каршында әңгәмә. Аны узып имтихан тотарга рөхсәт алдым. Яхшы гына билге җыйдым. Аннан комиссия каршында тагын бер сөйләшү. Мин кергәч, институт ректоры Владимир Пименов направлениене кулына алды да: «Сезнең начальник сине укырга алырга боерган», – диде. Ул елны язган әйберләреңне алдан җибәреп конкурста катнашканнан соң, СССРдан драматургиягә ике генә кеше чакырылган иде. Ленинградтан – Александр Сеплярский һәм Казаннан – мин. Психолог комиссиясен дә узгач, ниһаять, укый башладык. Ва-

кыт уза, уку бара. Ә күңелем белән Гариф абыйның Мәскәүгә килеп чыгуын теләп йөрим. Һәм ул очрак килеп тә җитте. Татар, казах, башкорт язучылары һәм галимнәре Мифтахетдин Акмуллага багышланган зур кичәгә җыелдылар. Колонналы залда халык шыгрым тулы иде. Татар язучылары беләләр, ләкин халык тәгаен белми торгандыр, бәлки. Акмулланы казахлар «безнең язучы», башкортлар исә «безнеке генә» дип тарткалашты бит инде. Ниһаять, трибунага Гариф абый чыкты. Кыска, ләкин төпле сөйләде, ә чыгышын: «Сезнеке түгел, безнеке дип тарткалашырга кирәкми. Мифтахетдин Акмулла өч тугандаш халык: татар, башкорт, казахларның уртак шагыйре, уртак әдибе», – дип бетерде. Шул вакыттагы алкышлар колонналы залда моңа чаклы алай яңгырамагандыр, шәт. Барсының да нервлары тынычланды, сүрән йөзләрдә дә тыныч елмаю барлыкка килде. Гариф Ахунов чыгышына каршы бер сүз дә әйтүче булмады. Әйтеп тә булмый иде.



Гариф Ахунов. Казан. 1979

Гариф абыйның киләсен белгәнгә, мин утыз сигез сум илле тиен стипендиянең утыз сумын махсус саклап тоттым. Акмулла кичәсе тәмам булуга, урамга чыктым. Көтеп торам. Ниһаять, Гариф абый белән Гөлшәһидә апа күренделәр. Исәнләшеп, кул биреп күрештек.

– Йә, укулар ничек бара? – дип кызыксынды Гариф абый.

– Бик яхшы бара, Гариф абый, укыйм, язам. Виктор Розов та, Инна Вишневская да иҗатымнан ризалар.

– Анысы турында ишеттем, – диде Гариф абый, – молодец, сынатма.

– Сез кая чаклы кайтасыз, Гариф абый, мин сезне илтеп куям.

– Гостиницага кайтабыз, хәзер троллейбус килеп җитсен дә...

– Гариф абый, мин махсус көтеп торам, сезне такси белән илтеп куярга...

– Юк, рәхмәт, энем, мин Гөлшәһидә белән троллейбуска утырып кайтам. Кеше арасында йөрергә яратам бит мин, – диде ул, мине телсез калдырып. Чөнки мин бөтен СССРга билгеле, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, депутатның троллейбуска утырып йөрүен күз алдыма да китерә алмый идем. Троллейбус килеп туктады. Алар троллейбус ишегенә кадәр култыклашып бардылар да, утырып та киттеләр.

Казан урамнарында троллейбус тукталышында утырган кешеләрне күрәм дә, шул хәл күз алдыма килә. Мәскәү урамы. Тукталыш. Троллейбуска Гариф ага Ахунов кереп бара. Гөлшәһидә апа белән.

*Эсфир Яһудин*,
драматург

# Һәйкәлләр-нидән-ярала?

Гариф абыйның мәдәният фонды рәисе булып эшләгән чагы. «Идел кызы» романы буенча куелган «Габбас хәзрәт» телевизион спектаклен худсоветка күрсәтеп, мактау сүзләре ишеткәч, шәп кәеф белән аулак бүлмә эзләп, Язучылар берлеге урнашкан бинага – Мөштәри урамына барышыбыз. Кесәләр кабарынкы, кулларда да төргәкләр...

...Лядов бакчасына кергәч, Гариф абый туктала да, Максим Горький бюстына карап: «Һәйкәлләр нидән ярала?» – дип сорый.

Мин, аптырап калуымнан, уйлап та тормыйча, әзер җавабымны бирдем.

– Таштан!

– Бер сүзең белән ничә хата җибәрдең!..– диде ул һәм, якындагы эскәмиягә утырып, сабак бирә башлады: – Беренчедән, мин синнән: «Һәйкәлләр нидән ярала?» – дип сорадым. «Нидән ясала?» – димәдем. Аннары һәйкәлләр таштан түгел, граниттан яисә мрамордан булалар. Таш таш инде ул. Аның эресе бар, вагы бар, чуары бар, известнягы дигәндәй, һәйкәл ясарлык таш булмыйдыр. Гранит яки мраморны эшкәртеп була. Таш шомара гына йә күкселләнә. Һәйкәл гранит йә мрамордан уеп, яки чокып ясала. «Ярала» түгел, «ясала».

– Гариф абый, әгәр тәгаен без карап утырган бюст турында сүз барса, ул чуеннандыр яисә бронзадан коелгандыр?! Уелган, димим – коелгандыр, дим. Күңелең булдымы?

– Булмады шул, энем. Син «коелган» белән «уелганны» белсәң дә, «ялралган»ны белмәдең. Яралгысыз берни дә булмый. Ә һәр яралгының асылында, нигезендә мәхәббәт ята! Һәйкәлләр мәхәббәттән генә ярала.

– ?

– Шулай! Син минем романымны яратмаган булсаң, бу спектакльне куя алмаган булыр идең. Бу спектакль минем романга һәйкәл куюга тиң. Моның өчен рәхмәт сиңа.

Инде «коелган» белән «уелган»ның, «яралган» белән «ясалган»ның аермалары турында... Синдә алар барысы да ясалган сыманрак күренә, саклан бу йогышлы чирдән,– дип, миндәге җитешсезлекләрне санап китте ул.

Озак сөйләде. Тыңладым, бүлдермәдем. Ул шуны сизде дә:

– Дәшми генә утырган кешенең күңеле башкада була, әйдә, кайтышып беттеләр бугай,– дип, мине бүлмәсенә алып кереп китте. Төн буе сөйләшеп чыктык.

Хәзер менә, ничә еллар үткәннән соң, шушы эпизодны искә төшердем дә уйга калдым: күп булмаса да, спектакльләр дә куела, кинофильмнар да чыга тора, ә ник соң ахырда чын күңелдән, дустанә сөйләшеп утырулар юк?

Әллә соң хәзерге сәнгать әсәрләре, чынлап та, яралгысыз гына ... ясалалармы? Яралгы җитлеккәч туарга тиеш, ә тугач, тавышы-өне булырга тиеш. Ник бер спектакльнең, ник бер тамашаның өне чыксын! Тып-тын! Әйтерсең лә берни булмаган, берни тумаган...

...Тып-тын, Гариф абый, сөйләшеп утырырга син дә юк, ичмасам. Әллә инде үпкәләдең шунда, әллә инде тыңлаучыларың кимегәнгә җәберсендең – иртә киттең, вакытсыз киттең, һич көтмәгәндә, уйламаганда...

...Әйе, җаның тынгылардан мәхрүм иде шул, алны-ялны белми күк айкадың, җирләр гиздең, сулар кичтең, вакыт синең өчен кол иде...

...Син бит хәтта тәмам сүнеп, күмерләнгән күңелләрне дә өреп ялкын кабыза белә идең, «өф-өф» итеп җылытып, күбәләкне терелткәндәй, иң пассив кешеләрне дә иҗтиһатка күндерә торган идең. Кеше хәсрәтләре белән хәсрәтләнеп, кеше шатлыклары белән шатлана ала идең. Син, кемнең дә булса хаксызга рәнҗетелүен белсәң, башка чара табалмаудан, аның әрнүләрен үзеңә алып, күңелен дәваларга тырыша идең. Моңа ышанмаучылар да бар иде, көлеп караучылар да. Син аларга үчле түгел идең, ачу саклamый идең, һәркем үз бәхете өчен үзенчә көрәшә, дип, дошманнарыңа да философларча карый идең, планнарың зур иде, хыялларың чиксез иде.

«Иде», «идең»...

«Иде» дип узган заманда язу минем өчен аерата авыр. Чөнки мин Гариф абыйга бурычлы калдым, һәм җитди бурычлы, һәм мәгънәви. Әүвәл шул турыда язып узмасам, башка хатирәләремнең табигыйлегенә хилафлык килер кебек. Әйе, мин аңа зур бурычлы калдым. «Идел кызы» романы буенча «Габбас хәзрәт» дигән күп серияле спектакльдән соң телевидениегә һәм авторлар исеменә күп кенә хуплау хатлары килгәч, Гариф абый, дәртләнеп, романның дәвамы буенча да телевизион спектакль төшерү нияте белән янып йөри башлады.

Очрашкан чакларда сүз гел шул турыда бара. Гариф абый үзенчә отышлы эпизодларны уйнап-сөйләп күрсәтә, кайсы рольгә нинди артист кулай булыр иде, кайсы эпизодны кайда төшерү отышлы булыр иде – берсе дә читтә калмый.

Гариф абый бер генә нәрсәне исәпкә алмый – бу эшнең миңа һәм аңа гына кызыклы булуын, телевидение җитәкчелегенә борчу һәм мәшәкатьтән башка нәрсә китермәгәч, аларның бу хыяллар турында ишетергә дә теләмәвен искә алмый иде. Сүз уңаенда әйтеп узмый булмый, 40 ел буе телевидение экраннарында күрсәтерлек ни дә булса куелган һәм төшерелгән икән, алар турында сөйләгәндә, җөмлә башында «благодаря» сүзе түгел, ә «вопреки», «несмотря» дигән сүзләр күбрәк әйтелер иде.

Әйе, шулай булуга карамастан, экраннарда татар язучыларының күп әсәрләре җанланды. Гариф абый моның нинди зур әһәмияткә ия булуын бик яхшы аңлый һәм безнең телевизор аша күрсәтелгән бик кечкенә генә тамашага да зур эш итеп карый, чын күңеленнән куана, рухы күтәрелеп, яңа тәкъдимнәре белән килә иде. «Идел кызы»ның дәвамын төшерү тәкъдиме дә аның, үз әсәрен күрсәтергә теләүдән бигрәк, репрессия чорында татар халкының никадәр зур югалтуларга, генетик үзгәрешләргә китерерлек зәгыйфьләндерелүләргә дучар ителүен җанлы образларда күрсәтү мөмкинлеген тоюыннан иде.

Кызганычка каршы, хыяллар хыял килеш калды, тәкъдим тәкъдимнән узмады. «Идел кызы»ның дәвамына тотына алмадык.

...Үзгәртеп корулар, хәбәрдарлык һәм тизләнеш чорлары башланды.

...Габдулла Тукайның бөтен тормышын эченә алган телевизион фильм төшерү мөмкинлеге ачылды. Чаллы шәһәрендәге бер оешма спонсор булырга ризалашты. Энергиясе ташып торган Гариф абыйны мин, булачак фильмның авторларыннан берсе итеп, хезмәттәшлеккә-соавторлыкка чакырдым. Ул шатланып риза булды, һәм без дүрт кеше – Гариф Ахунов, Әхәт Гаффаров, Ризван Хәмид, Әхтәм Зарипов – сценарий язарга утырдык. Сценарийның үзенә тигән өлешен иң алдан һәм билгеләнгән срогына Гариф абый язып тапшырды. Әхәт Гаффар аванс акчасын гына алды да эш башында ук дистанциядән чыкты. Ә Ризван Хәмид – мәсьәләгә артык җаваплы каравы аркасындамы, башка сәбәпләрдәнме – сценарий язу эшенә озак керешми йөрде, ул нидер язып китергән чакта инде спонсор булырга тиешле оешмабыз күптән шартлап янган, кешеләре кайсы

кайда таралышып поскан, шартнамәгә кул куйганчы, Татарстаннан чыгып тайган булып чыкты.

Шулай да ул вакыттагы радио һәм телевидение буенча дәүләт комитеты рәисе Илгиз Хәйруллин, спонсорыбыз югалса да, авторларга түләү мөмкинлеген тапты һәм без Тукайның Уральскига киткәнче тормышын эченә алган фильмны төшерергә тотындык. Бу эштә Гариф абый сценарий авторларыннан берсе булып кына калмады, ул, артистлар белән бергә экспедицияләргә чыгып, фильм-спектакль төшерү процессының эчендә кайнады. Үзенең абруйлы исеме белән безгә фильм төшерү урыннарын әзерләшүдә, әйбер-әсбаплар табышуда зур ярдәм күрсәтте. Ул хәтта, кирәк чакта, массовкаларда төрле халык вәкилләре булып рольләр уйнарга да ризалаша һәм уйный иде. (Мәсәлән, Кырлайда чакта Габдулланың ат саклап болында кунуы эпизодында әкият сөйләүче бабай булып Гариф абый үзе төште.)

Алай итеп, болай итеп, этеп-төртеп, тартып-сузып дигәндәй, фильмны Тукайның тууына 110 ел тулу көннәренә өлгерттек.

Бу турыда «Мәдәни җомга» гәҗитендә зур гына мәкалә басылып, безнең эшебезгә яхшы һәм уңай бәя бирелде. Шулай булса да:

*...бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым, –*

дигәндәй, Тукай турындагы фильмны төшерүне дә без дәвам итә алмадык. Сүздә «нигә төшермисез?» дип сорасалар да, гамәлдә бу бездән көлү иде. Әгәр эшне чынлап та дәвам итүне теләгән кеше булса, иң башта, режиссерны чакырып: «Фильм төшерүне дәвам итәр өчен ни кирәк?» – дип сорар иде. Без, әлбәттә, ни кирәген әйткән булыр идек. Ләкин бездән, алай сорау урынына, чәчмәгән басудан уңыш кына сорый башладылар.

Аннары эш бүлмәбездән кудылар, халыктан җыеп юнәткән борынгы күлмәк-ыштаннарны, камзул-җиләннәрне «оприходовать итәбез» дип үзләштерделәр дә, ахырда милли кием-салымнарыбыз, җиһазларыбыз белән «идарә» итүче тәһарәтсез марҗалар аларның кайсын кая таратып, югалтып бетерделәр. Хәзер алардан «Тукайга дип әзерләнгән костюмнар кая?» – дип сорасаң, «А кто такой Тукай?» – дип көләрләр генә. Шуларның барысын да якыннан күреп, белеп, аңлап йөргән Гариф абый, татар әдәбиятының йөзек кашлары булган язучылардан кул куйдырып, «Тукайсыз да калабызмыни?» дигән ачык хат бастырды. Моңа да бернинди дә реакция булмады. Шулай итеп, Тукай турында фильм төшерү планнары ярты юлга җиткәндә җимерелде. Эш тукталды.

Очрашкан чакларда Гариф абый, мине пассивлыкта гаепләп, төрле киңәшләре белән Тукай турындагы эшне дәвам итәргә димли, бер булмаса – бер булыр дип, сценарий өстендә эшләүдән тукталмаска күндерергә тырыша иде.

1995 елның көзендә хөкүмәт карары белән Гариф абыйга 70 яшь тулу уңаеннан юбилей кичәләре уздырылды.

Г. Камал театрында уздырылган бәйрәм кичәсенең сценарий авторы һәм режиссеры булуны Гариф абый тәкъдиме белән Язучылар берлеге миңа йөкләде. Кичә матур узды, диделәр. Гариф абый үзе дә бик канәгать калган иде. Аңа аеруча ошаганы «Идел кызы» романы буенча куелган фильм-спектакльдән фрагментлар булды дисәм – һич арттыру булмас.

Соңгы елларда сәхнәдә әсәрләре бармагангамы, әллә башка сәбәпләрдәнме – үзе язган каһарманнарның җанлы образларын сәхнәдә күрү аңа үтә дә кызыклы һәм тансык иде. Бу турыда ул кичәне йомгаклау нотыгында да басым ясап әйтте. Бу кичәдән соң без тагын очрашкалый башладык. Шундый очрашуларның берсендә Гариф абый миңа үзенең «Этләр патшасы» дигән повесте буенча телевизион фильм төшерергә тәкъдим ясады. Ишеткәнем булса да, повестьны укыганым юк иде, укып фикеремне әйтергә 20–30 көн вакыт сорадым.

– Син аны бер кичтә укып чыгасың, укый башласаң, туктамаячаксың,– диде ул, кистереп, һәм шулай булды да.

Повесть бик мавыктыргыч һәм ихлас телдә язылган, актуальлеге дә узгынчы-очраклы түгел – кешеләр язмышына нигезләнгән.

– Ошады! –дидем мин.

– Алайса утыр, яз сценариен!

– Һәй, Гариф абый, әле язган сценарийларны кая куярга белмим, барыбер тиз генә куелмаячак.

– Анысы минем эш,– диде ул, бәхәскә урын калдырмыйча.

Зур өметләр һәм татлы хыяллар белән сценарий язарга утырдым. Җиңел генә башкарып чыгармын дигәнем ничектер авыр барды. Өч айда бетерәсе эш алты айга сузылды.

[…] Гариф абый сүзендә торды, ә мин һаман шул сценарий буенча фильм төшерә алганым юк. Аның сәбәпләре әллә ни еракта да түгел, әлеге дә баягы шул финанс мәсьәләләренә генә килеп терәлә. Исән булса, ихтимал, Гариф абый моны аңлаган да булыр иде, бәлки әле спонсорлар табышуда да ярдәм итәр иде. Сүз ул турыда түгел. Сүз кешенең кешегә бурычлы калуы турында.

Бурычны кеше исән чакта түләү фарыз. Түләнмәсә, ул бурыч бурыч кына түгел, ниндидер бер янау, олы гөнаһ, куркыныч йөк, менә-менә китереп сугасы афәт, җәза кебек икән. Гомерем булып, исән-сау шушы эшемдә эшләсәм, мин ул сценарий буенча фильмны куярмын да, ләкин аның белән генә Гариф абый рухы каршында йөзем агарырмы? Шикләнәм. Инде күңелемдә олы йөк булып яшәгән гаебемне таныдым, гөнаһларымны ачтым, шулай булгач, бәлки, аның белән бәйле кайбер хатирәләрем белән уртаклашырга ярыйдыр?

– Юк, – ди Гариф абый, әллә кайдан, ерактан бармак янап.– Истәлекләр сөйләргә хакың юк! Хакыңны түлә! Шуннан соң сөйләрсең дә, булдыра алсаң, язарсың да.

– Миннән генә торса икән…

– Синнән генә торганы шул: уйлан һәм вөҗдан газабы кичер. Бурычыңны түләгәндә, күңелең пакь булырга тиеш. Бурычны «котылам» дип түгел, «тотылам» дип түләргә кирәк. Җаваплылыкка тотылам, дип. Шул җаваплылыктан курыкмаганда гына бурычың түләнгән булыр!..

...Курыкмыйм, Гариф абый, җаваплылыктан курыкмыйм!

...Шулай дип үзенә әйтә алыр идемме, юкмы – белмим, әмма аңа булган бурычым турында дөресен язгач, миңа ничектер җиңелрәк булып китте, һәм Гариф абый шәхесенә кагылышлы кайбер фикерләрем белән уртаклашасым килү теләге туды.

...Гариф абый, шиксез, Совет хакимияте тәрбияләп үстергән, Совет системасына нык яраклашып, аны яхшы аңлап, аннан яхшы файдаланып, аңа тугрылыклы хезмәт тә иткән, әмма үз йөзен югалтмаган, бик ачык күңелле күренсә дә, чын хисләрен тирән яшерә белгән беркатлы тәвәккәл кеше иде.

Мин яңа заман башлануны ни өчендер Чернобыльдәге атом электростанциясендәге авариягә бәйлим. Шундагы шартлаулар нәтиҗәсендә беркайчан да үзгәрми төсле тоелган яшәү-эшләү-хезмәт итү кагыйдәләре үзгәрде. Тимер-бетоннан булган социализм дигән бинабыз кинәт чатнады, түшәмнәрендә ярыклар хасил булды, күктәге йолдызлар күренде, чык тамчыларыннан нигезе җебеде, кыегайды, тышкы яктан шомартылып сыланган гына булып чыкты. 70 ел буена бу бинаның җимерелмәс булуына ышандырырга тырышсалар да, эчтән нидер буласын көтеп йөрүебез беркем өчен дә сер булмагандыр. Ул көн килде.

Әлбәттә, идеология фронтында иҗат итүчеләр шул җимереләчәк бинаны мәңгелек дип җырларга тиешләр иде. Һәм шулай җырладылар да. Дөресрәге, шулай җырладык.




Арча педагогика көллиятендә Гариф Ахуновка багышланган конференциядә китаплар күргәзмәсе. 2015

Унисонга җырласак та, һәркемнең үз тавышы тавыш иде. Мактаулы заманыбызның иң мактаулы чорында да Гариф Ахунов «Чикләвек төше»н язды. Бу яңа сүз, кыю адым иде. Кире герое райком секретаре булган ул повестьны бастыруга нинди көчләр, нинди хәйләләр кирәк булгандыр, ләкин повесть басылып кына калмады, хакимият бу повесть өчен Гариф Ахуновка Тукай бүләге бирергә мәҗбүр булды.

1972 елның көзендә Г. Камал театры «Чикләвек төше»н сәхнәгә куйды. Инсценировка авторы мин идем. Гариф абый иҗаты белән якыннан танышуым шунда башланды да. Анары «Идел кызы» романы буенча «Габбас хәзрәт» фильм-спектакле өстендә эшләгәндә, бу танышлык хезмәттәшлеккә әверелде. Татар халкына Октябрь революциясе алып килгәннәрнең чын асылын үзгәртеп корулар башланганчы ук язып чыккан беренче автор буларак, Гариф Ахунов аерым мактауга лаек булса, образларының камиллеге, вакыйгаларның чынбарлыкка нигезләнгән булуы белән икенче мактауга лаек. Әйе, «Идел кызы»н язуы да батырлык иде, кыюлык, фидакарьлек иде. Гариф абый кебек шәхесләрне руслар «человек поступка» диләр. Аның иҗаты, гомумән, поступоклар тезмәсеннән тора. Иҗаты гына түгел, бөтен тормышы, яшәве.

Казандагы эшләре гөрләп барганда Әлмәткә китеп баруын гына алыйк. Поступокмы? Поступок! Совет җәмгыятендә ирешергә мөмкин булган бөтен дәрәҗәләргә ирешкәч, шул җәмгыятьнең хакимнәренә тел тидерү түгел, шик белдергән өчен дә күп язучылар иленнән куылган яисә ирегеннән мәхрүм ителгән бер заманда каһарманы Совет чынбарлыгын кабул итә алмыйча асылынып үлгән роман язу поступокмы? Поступок!

Һәм Гариф абыйның бу «поступок»лары хакимият өчен поступок булып тоелмаслык итеп оста эшләнде. Хакимият аны яратты, үстерде. Ул шул яратуга күнекте, яраклашты...

Әлеге дә баягы үзенең «Этләр патшасы» повестен телевидениедә куйдырасы килүе дә система уенында җиңеләсе килмәү поступогы түгел идеме икән?

Гариф абый вакыйгаларның уртасында кайнарга, күзәтүче генә түгел, катнашучы булырга, катнашып, вакыйгалар агышына тәэсир итәргә, мөмкин булса, үзенчә үзгәртергә тырыша иде. Гомеренең соңгы елына кадәр Г. Ахунов катнашмаган әдәбиятка, мәдәнияткә кагылышлы берәр мәҗлес яки җыелыш булдымы икән? Юктыр. Мәктәп чакырса – мәктәптә, колхоз чакырса – колхозда, төрмәгә кирәк булса – төрмәдә дә ул чыгышлар ясый. Сүзен дә таба, җаен да, тәмен дә. Ул һәркайда, ихлас беркатлылык белән, үзе инанган хакыйкатькә өнди. Күп чак ышандыра. Аның ышандыру көче шунда: ул «мин беләм» позициясеннән түгел, «әйдәле, бергәләп җавап эзләп карыйк!» позициясеннән чыгып сөйләшә. Гел алга бару белән мавыкмый, чигенергә дә өлгерә, читкә дә чыгып керә. Нәтиҗәдә тыңлаучылар аңа әсир! Тыңлаучылар гына түгел, укучылар да, тамашачылар да.

Әйе, Гариф абый иҗаты белән генә түгел, ният һәм гамәлләре белән дә үзенә тиз әсир итә, әсир итеп кенә калмый – гашыйк итә торган сыйфатларга ия зат иде.

Үзем сынаганнардан тагын бер генә сыйфатны искә төшереп узасым килә: Гариф абый кешегә яхшылык эшләүдән ямь һәм тәм таба, мәшәкатьне үзе эзләп ала, һәр эшне җиренә җиткереп, ахырынача башкарып чыгарга ярата иде һәм шулардан юаныч таба торган оптимистик холыклы кеше иде.

Озак еллар Язучылар берлеге рәисе булып эшләгәч, бар кешегә дә кояш булып балкымавы да мөмкин. Кайбер чакларда ялгышып куюлары да ихтимал. Шунысы факт: Гариф абый Ахунов ялгышларына ябышып ятып, үзе белеп тирән гөнаһлар кыла торган кеше түгел иде, мәрхүм. Ул гафу да үтенә, гафу итә дә торган зыялы зат иде. Акыл белән кылганнары фәкать яхшылык кына иде. Шулар аңа савап булып иңсен. Амин.

Әгәр мин сынчы булсам, Гариф абыйны агымга каршы ишүче ишкәкче итеп ясар идем. Үзе алга бара, карашы арттагыларда. Һәм бу караштa мәхәббәт очкыннары, өмет, ышаныч!

Хәер, без бит инде беләбез: һәйкәлләр нидән ярала? Мәхәббәт яки нәфрәттән!

Гариф абый! Нәфрәтләнергә синең генә хакың бардыр. Ә бездән сиңа бары тик мәхәббәт һәм... сагыш кына. Бик юксынабыз сине. Бик юксынабыз.

*Әхтәм Зарипов,*
режиссёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

# Ярты-гомер-бергә

Гариф Ахунов белән беренче танышлыгым, әлбәттә, иҗаты аркылы булды. Студентлар, яшьләр тормышына багышланган «Яшьлек яме»н безнең, Орск шәһәре татар китапханәсе тирәсенә тартылган бер төркем яшьләрнең, аеруча кызыксынып укыганыбызны хәтерлим. Илленче елларда татар әдәбиятында заман яшьләре тормышыннан алып язылган тулы канлы әсәрләр юк дәрәҗәсендә иде бит. Сугыштан соңгы ул дәвердә әле барыбызга да якын булган көндәлек тормышны түгел, сугыш вакыйгаларын тасвирлаучы әсәрләр өстенлек итә иде. Казанга килеп эшли башлаган елларымда шул ук авторның «Совет әдәбияты» журналында басылган «Хәзинә» романын уку исә тагын бер шатлык тудырган, күптәнге якын танышың белән очрашу хисен уяткан иде. Аннары инде повесть, романнарын көтеп алып укырга күнегелде. Китап киштәмдә татарча һәм русча басылган китаплары өсте-өсте өстәлә барды. Алар арасында мөхтәрәм авторның миңа һәм гаилә әгъзаларыма бүләк ителгән китаплары да ишле генә. Китабы басылу сөенече белән уртаклашырга да бик һәвәс кеше иде ул. Дусларына һәм каләмдәшләренә үз китапларын да, аның тырышлыгы белән нәшер ителгән классик әдипләребез җыентыкларын да бүләк итәргә, сөендерергә ярата иде. Аның «Хәзинә», «Идел кызы» романнарын бүген дә мин еш кулга алам, аның иркен сулыш белән иҗат итү алымнарына төшенергә теләгәндәй, кат-кат укыйм. Ул иҗат иткән, әсәрләрендә гәүдәләндергән образларның күпчелегенең саф рухлы, якты йөзле яхшы кешеләр булуы күңелгә нур өсти, аны сафландырып, яктыртып җибәргәндәй була. Аларны укыган мизгелдә күз алдына, нурлы йөзен балкытып, мәрхәмәтле карашын төбәп, автор үзе килеп баскан кебек тоела башлый.

Татар әдәбияты вә мәдәниятенең күренекле бер вәкиле буларак танылган Гариф Ахунов үзе яулаган югарылыкка фәкать үз көче, үз тырышлыгы белән генә ирешкән. Ятимлекне сылтау итеп, тормыш баткаклыгына кереп батмаган. Төрле киртәләрне кичеп, табигать биргән олуг сәләтен, талантын түкми-чәчми үзе саклаган, үстергән. Хәер, әбиләребез әйтмешли, мәрхәмәтле фәрештәләрен ачуландырмыйча, һәрдаим аларның изге канатлары баш очында җилпенеп торуы сәбәпледер, яшь егет авыр тормыш юлында һәрчак яхшы күңелле изге затларга тап булган. Аның күңел талпынуын, өмет-омтылышларын сиземләгән андый кешеләрнең ишле булуын да әйтергә кирәктер. Үзе һәрвакыт Казанбаш авылындагы җидееллык мәктәп коллективын, аеруча әдәбият укытучысы, элекке хәлфә Бәдри Хәстиевне җылы хисләр белән искә алыр иде, мәрхүм. Рәсем ясарга, инша язарга сәләте сиземләнгән Гарифҗанга алар өстәмә йөкләмәләр биргән, булышкан, күңелен үсендерергә тырышканнар. Мәктәптән соң Арча педагогия училищесында да ул хәерһах күңелле кешеләр кулына – чын педагог-тәрбиячеләр кулына эләгә. Ләкин ике ел анда укыганнан соң, Бөек Ватан сугышы башлана, аңа берничә ел колхозда һәм Себер төзелешләрендә эшләргә туры килә. Сугыштан соңгы авыр елларда Казан дәүләт университетында татар филологиясе бүлеге ачыла. Гариф Ахунов һәм аның булачак хатыны, язучы Гөлшәһидә Максудова, шагыйрь Мәхмүт Хөсәен, язучы-тәрҗемәче Яхъя Халитов һ.б. шул бүлекнең өченче уку елына «эләккән» иң

бәхетле кешеләрдер, мөгаен. Бүлекнең ачылган көннәреннән анда белем алучы беренче бәхетлеләр арасында без шулай ук татарның байтак кына күренекле шәхесләрен – укырга кергәнче үк әдәби иҗат юлын сайлап, башлангыч әсәрләрен бастырырга өлгергән булачак профессор Ибраһим Нуруллинны, Татарстанның халык язучылары Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗевләрне, күренекле шагыйрь Зәет Мәҗитовны, халык шагыйре Әхсән Баянны һәм башкаларны күрәбез. Гариф Ахуновны да бик зур юлга алып чыга бу коллектив. Университетта уку елларында ул беренче хикәясен һәм татар әдәбиятына багышланган мәкаләләрен яза. Аннары шул «багаж» белән «Совет әдәбияты» журналына эшкә алына. Өлкән каләмдәшләренең җылы мөнәсәбәтен тоеп җигелеп эшли, күп яза...

Әдип Гариф Ахунов белән шәхсән танышуыбыз алтмышынчы еллар урталарына туры килә. Ул вакытта мин Хәсән Сарьян, Әмирхан ага Еники, Шамил Рәкыйпов һәм башка кайбер әдипләр белән аралаша башлаган идем, «Татарстан яшьләре» газетасына хәбәрләр язгалыйм. Кечерәк бер очеркымны мактап, үрнәк мәкаләләр стендында да шактый вакыт тоттылар...

1965 елның кыш урталары иде. Татарстан язучыларының әдәби ел йомгаклары көннәре. Ике көнгә сузылган ул җыелышта катнашмадым, төп эшемнән китә алмадым. Җыелыш тәмамланган көн булгангадырмы, әллә шуннан соңгысымы, эштән соң, кич белән Хәсән Сарьяннар фатирына барып чыктым. Бәлки, очрашырга алдан вәгъдәләшкән булганбыздыр, анысын хәтерләмим. Мин килгәндә, Бутлеров урамының тау астына төшеп киткән тарафына өч тәрәзәсе чыккан түр бүлмәдә өч-дүрт ир гөрләшеп сөйләшеп утыралар иде. Ул вакытта «Совет әдәбияты» журналы мөхәррире булган Газиз Мөхәммәтшин гына миңа таныш. Аның янәшәсендә, өстәлнең йорт хуҗасына каршы ягында, җитез хәрәкәтле, җор телле, ачык йөзле берәү утыра. Ялыкмыйча сөйләвен дәвам иткән шул кешегә ымлап, Сарьян:



Мәскәү язучылары белән очрашу. Беренче рәттә дүртенче – Гариф Ахунов. Казан, 1970 еллар



Гариф Ахунов хатыны Шәһидәнең 70 яшьлек юбилеенда туганнары һәм дуслары белән. Казан, 1996

– Гариф Ахунов үзе була, – диде.

Ул кичтә бик озак һәм күңелле утырылды. Төп әңгәмә әле генә узган әдәби ел йомгаклары, андагы докладлар, аерым чыгышлар тирәсендә барды, билгеле. Яңа танышым да ул зур җыелышта нотык сөйләгән икән. Аның да уңышлы өлешләрен кайта-ката искә алдылар. Ул вакытта Г. Ахунов язучыларның Әлмәт төбәге оешмасы җитәкчесе иде. Тәгаен хәтерләмим инде, мөгаен, аның докладыы шул төбәк язучылары эшчәнлегенә багышланган булгандыр. Гариф Ахуновның әдәбият мәйданындагы колачлап йөзә башлаган еллары. Газиз белән Сарьян да аннан калышмаска тырышалар. Газиз Мөхәммәтшинның әле яңарак кына «Без әле җирдә яшибез» повесте басылып чыкты. Әдәбият сөючеләр аны яратып кабул итте. Сарьянның да кызыклы хикәя китаплары, әдәбиятка кагылышлы мәкаләләре чыгып тора. Өстәлендә соңрак зур шау-шу кузгатачак «Нокталы өтер» повестеның кульъязмасы. Аның аерым бүлекләрен тәмамлап, кайбер язучыларга укып та күрсәткән. Бик хуплаганнар. Шушы кышта ул повестьны язып тәмамларга нияте бар.

Әмма ул кичтәге мәҗлеснең төп мотивы буларак, минем күңелдә түбәндәге сүзләр уелып калган:

– Татар әдәбиятын әйдәп баручылар сафына без – кырык яшьтәгеләр чыгабыз. Хәзер бездә көч. Безгә, тормышның вак-төягенә әһәмият бирмичә, юк-бар белән мавыкмыйча, җиң сызганып эшләргә дә эшләргә, көн-төн язу өстәлләребездән аерылмаска кирәк! Тәүбә!.. Тәүбә!.. (Гариф абыйга, чынлап та, ул елда кырык яшь туласы булган, калганнары аңардан дүрт яшькә яшьрәкләр иде.)

Әйе, ул көнге сөйләшү, төртмә сүзләр әйтешү, көлешү-шаярышулардан соң күңелгә сеңгән төп фикер булып әнә шул гыйбарәләр калган. Ул чакта бергә утырдаш булган әдипләрнең барысы да диярлек максатларына ирештеләр. Тәүбәләрендә нык тордылар.

Аеруча зур биеклеккә күтәрелгән, әдәбият өлкәсендә иңләп-колачлап йөзгән кеше Гариф Ахунҗан улы Ахунов булды, билгеле. Аның «Хәзинә», «Идел кызы» кебек зур әсәрләре, татар әдәбиятына һәм аның олуг шәхесләренә багышланган күп санлы хезмәтләре мәңгемәңге арабыздан китмәстер, мөгаен.

Шуннан соң озак та үтмәстән, язмышларыбыз безне кабат очраштырды. Без бергә эшли башладык. Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты мәрхүм Гариф ага Ахунов белән утыз елдан артыграк вакыт якыннан аралашып яшәдек. Татарстан Язучылар берлегендә иңгә-иң куешып байтак кына эшләдек. Эш барышында төрле хәлләр булгандыр, әмма ләкин зурдан кубып ачуланышканыбызны, бер-беребезгә карата усаллык, хөсетлек кылуларны хәтерләмим. Тормыш тәҗрибәсе зур, масаючан холыкка ия кеше иде ул. Язучылар берлеге идарәсе рәисе, СССР Югары Советы депутаты, СССР һәм РСФСР Язучылар берлеге идарәләре секретаре булуына карамастан, каләмдәшләрен дә, хезмәттәшләрен дә һәрчак ачык чырай белән кабул итәр, дустанә сөйләшер. Үзен синең белән тиң, тигез тотарга тырышыр. Күңел юаткыч шаян сүзләр табып, үзе үк башлап шаркылдап көлеп тә куйгалар иде.

Миңа аның белән бергә күп мәртәбәләр үз җөмһүриятебез түрәләре һәм Мәскәүдәге Язучылар берлеге, китап нәшриятлары җитәкчеләре белән очрашуларда, җитди генә әңгәмәләр барышында катнашырга туры килгәне бар. Алар белән дә ул кайберәүләр кебек бик үк мескенләнеп сөйләшмәс, тарихта зур абруе булган татар әдәбияты вәкиле икәнлеген тоеп һәм тойдырып, әңгәмәдәшенә әйтәсе фикерен ярып әйтер иде. Бигрәк тә Мәскәү түрәләре белән очрашулар барышында, гадәттәгечә, алар алдына үтенеч белән барган чаклардагы сөйләшүләр шактый истә калган. Кайвакытларда аңа, ярым шаярган булып яисә җитди төстә, «татар әдәбияты тоткан урынны онытып бетермәгез» кебегрәк җөмләләр кулланырга да туры килүенә үзем шаһит. Шундый сөйләшүләр, уртак тел табарга тырышулар нәтиҗәсендә Татарстан Язучылар берлегенә Зәки Нури белән Гариф Ахунов җитәкчелек иткән вакытларда ел саен диярлек СССР Әдәбият фонды акчасына берничәшәр яңа фатир алуга ирештеләр дә. Ә аңа ирешү өчен башта үзебездә берничә айга сузылган оештыру эшен башкарырга, республика һәм шәһәр җитәкчеләре бусагасын күп тапкырлар таптарга туры килә иде. Без еш кына республика һәм шәһәр җитәкчеләренә, план бүлекләренә, «Татстрой» идарәсенә һәм башка оешмаларга бергәләп, Гариф абый югары дәрәҗәле депутат булганлыктан кабул ителәчәгебезгә өметләнеп бара идек. Ул елларда иҗтимагый оешмалар исәбенә алыначак фатирны төзелеш планына кертү өчен төрле дәрәҗәле ундүрт түрәнең рөхсәт имзасы кирәк була иде. Шул документларны күтәреп баргач кына, Мәскәүдә эш башында утыручылар белән сүз башларга мөмкин иде.

Язучы, рәссам һәм композиторларның үзебез оештырган «Идел» бакчачылык ширкәтендә дә Гариф абыйлар белән бер йорт аша күршеләр булдык. Ул ширкәтнең беренче казыгы кагылуга 2000 елның яз башында утыз беренче сезон киткән иде. 1990 еллардан башлап Ахуновлар гаиләсе җәй айларының төп өлешен шушы бакчада уздырдылар. Гөлшәһидә ханым, төп бакчачы буларак, җиләк-җимеш, яшелчә түтәлләрен эшкәртә, утый. Гариф абый, Идел буе әрәмәлегендәге кошлар сайравын тыңлый-тыңлый, шул түтәлләргә су сибәр, картайган агач ботакларын кискәләр, йорт-койма тирәсендә анымоны рәтләгән булып йөрер иде. Шул арада күрше-күлән белән әңгәмәләшеп алырга да онытмый. Татарстанның халык язучысы Хисам ага Камалов, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатлары – шагыйрьләр Гөлшат Зәйнашева, Марс Шабаев, Татарстанның халык артисты, композитор Фасил Әхмәтов, күренекле композитор Мирсәет Яруллин, байтак еллар мәдәният министры урынбасары булган Мөҗип Низамиев – аның якын фикердәшләре, яраткан әңгәмәдәшләре иде. Элегрәк елларда күршеләребез,

халкыбызның танылган шагыйрьләре Нури Арсланов, Зәки ага Нури, кичләрен ишегалдында ут ягып, учак яны «җыеннарын» оештырырга һәвәс булдылар. Зәки ага, ярым шаярган кыяфәттә: «Партизан учагына җылынырга килегез», – дип, юл-аллеялар буйлап кичке бакча хозурлыгына сокланып, саф һава сулап йөрүчеләрне еш кына койма аша чакырып калыр иде. Бала-чага чыр-чуы тынмыйча, ул учак тирәсендәге кызып-кызып сөйләшү, кычкырып көлү авазлары туктамас. Һәм арада иң кызып сөйләүче, алмагач чәчкәләре сибелеп коелырдай итеп яңгыратып көлүче Гариф абый Ахунов булыр иде. Мөгаен, саф күңелле, эчкерсез кеше генә шулай итеп көлә ала торгандыр. Хәер, учак җылысына җыелган ул шәхесләрнең күпчелеге – ике «озын Нури» да, буйга һәм сүзгә алардан һич калышмаган танылган рәссам Лотфулла Фәттах та, андый урыннарда сүз артыннан кесәгә кермәүче, күңеле тулганда кичке бакчаны яңгыратып «Азамат»ны җырлап җибәргәләүче Сарьян дус та эчкерсез, садә җанлы затлар иделәр, мәрхүмнәр, урыннары оҗмахта булсын. Көннәр, кайвакыт төннәр буе япа-ялгыз утырып эшләүче иҗат кешесе өчен ара-тирә шулай бергә җыелып, уйнап-көлеп гәпләшеп алу чын ял итү үрнәгедер.

4 июнь иртәсе. Гариф абый, гадәтенчә иртүк торып («тургай» бит ул), өч литрлы сөт бидоны белән якындагы коедан су ташырга керешә. Һавага кыргый гөләп, ясмин чәчәкләренең хуш исе таралган чак. (Мәрхүм Хәсән Сарьян кое каршындагы койма буйларына кыргый гөләп, Фәрваз Миңнуллин бакча читенә ясмин куагы утыртып калдырганнар иде.) Картларча вак-вак атлап су китереп йөргән Гариф ага кое юлында очраган Мөҗип күршесенә: «Алтынчы бидон... көн буена җитәчәк», – дип рапорт биреп китә.

Безнең гаилә казна эшендә көн уздырып йөргәнлектән, бакчага ял көннәрендә генә килә. 3 июньдә дә анда көн урталарына гына барып ирештек. Үз мәшәкатьләре булганлыктан, бакчага сирәк йөргән улыбыз Булат гаиләсе белән килгән иде. Кичкә табарак Даниям әйтә:

– Әйдәгез, кое якларыннан да әйләнеп килик. Гариф абыйлар белән дә Булатның күптән күрешкәне юк, – ди.

Шәһидә апасын ул байтак еллардан бирле, якын күреп һәм яшь аермасын истә тотып, «кайнанам» дип йөри. Бакчада булган вакытларда һәрчак күрешеп, хәл белешеп торалар...

Кояш һаман саен түбәнгәрәк тәгәри, ә минем әле алмагачларга агу сибәсем бар иде. Аларга инде корт төшкән, яфраклары бөтәрләнә башлаган. Бүген сибелмәсә, ул эш тагын бер атнага кичектереләчәк. Шул сәбәпле:

– Мин бара алмыйм... Иртәгә барып күрешермен, – дип, эшләп калдым. Алар киттеләр.

Сәгать ярымлап сөйләшеп утырганнар. Булатның иҗаты, киләчәк планнары белән дә кызыксынган Гариф абый. Аның «Идел», «Казан утлары», «Аргамак» журналларында дөнья күргән мәкалә һәм очерклары белән Гариф абыйның элек-электән танышып барганлыгын белә идек. Улыбызның иҗаты, бигрәк тә тарих өлкәсендәге эзләнүләре аның күңеленә хуш килә. Ул үз оныгының уңышларын күргәндәй сөенүләрен очрашканда да, телефон аша да белгертә тора иде. Шул кичтәге сөйләшү-күрешәләр соңгысы булган икән. Вафатына бер ел тулган көннәрдә Булат, Гариф агасына хөрмәт йөзеннән, аның соңгы китабын – «Тимерханның күргән-кичергәннәре»н – русчага тәрҗемә итеп чыгарды.

Икенче көнне, чәйлек-ашлык су китергәннән соң, бераз хәл алырга дип яткач, Гариф абый бик сабыр гына мәңгелеккә күчеп китә. Беренче булып бу хәбәрне без ишеттек.

Сәгать уннар тирәсендә уртак күршебез Марс Шабаев койма аша безгә кычкыра:

– Гарифка нәрсәдер булган, керегез әле! – ди.

Йөгерешеп кердек. Гариф абый эш өстәле янәшәсендәге кушеткага сузылып яткан, тыныч кына ята сыман. Соңгы бер-ике елда ул, гадәтенчә барыбыздан да иртә торып, йорт тирәсендә вак-төяк эшләр эшләп керер дә, иртәнге чәйне эчкәннән соң, шулай ятып торыр иде...

Төш күреп изрәп йоклый диярсең, чалкан яткан гәүдәсендә бернинди үзгәреш тә сизелми. Без кергәндә, әле кул җылысы бар иде шикелле, әмма ләкин сулаганы тоелмый.

Гөлшәһидә дә:

– Авыз тирәсенә колагымны куеп та тыңладым, сулышы юк кебек, – диде.

Ул арада берничә бакча аша булган Йолдыз ханым да килеп керде. Пенсиядәге врач, мәрхүм композиторыбыз Фасил Әхмәтовның җәмәгате. Ул да тыңлап пульсын тикшереп карады. Йөрәк эшчәнлегенә көч-куәт өстәүче уколын да кадады.

– Пульс тибеше сизелми, тизрәк хастаханәгә... – дип боерды.

Шул ук минутта, ярдәмем кирәксә, мин әзер, дип, Туфан Миңнуллинның баҗасы Җәмил дә машинасы белән килеп җитте. Аның арткы утыргычын тигезләбрәк куеп, өчәүләп Гариф абыйны шунда кертеп салдык. Шәһидә апасы янына иптәшкә Дания дә утыргач, Гариф Ахуновны алып та киттеләр. Каләмдәш остазыбызны шау чәчәктә утырган бакчалар уртасында озатып калдык. Соңгы бер елда Гариф абый физик яктан нык бирешкән кебек күренсә дә, һич тә зарланмас иде. Көз, кыш айларыннан бирле дусише һәм Гөлшәһидә ханым аны хастаханәгә кереп, бераз хәл җыеп чыгарга димләсәләр дә, ул: «Картлыкны җиңә торган дәва юк», – дигән рәвештәрәк җавап бирә килде. Яздан башлап: «Бакча һавасы үзе дәва», – дип тә әйтер иде. Соңга табарак ул язу өстәле янында да озак утыра алмаган, гадәти көндәлек язмаларын авырлык белән тутыргач, яңа килгән газета-журналларны уку белән чикләнгән. Үлемнең кичектергесез булуын һәммәбез дә белә, һәммәбез дә аның килүен көтә. Ләкин Газраил һәрвакыт көтмәгәндә, кинәт кенә баш очында пәйда буладыр шикелле. Аның килүен кемнәрдер куркып, сыкрап, икенче берәүләр фәлсәфи тынычлык белән кабул итәләр. Алар авызыннан җанны әрнеткеч соңгы сыкрау авазларын ишетмисең. Әйе, һәркем ул соңгы мизгелне үзенчә каршы ала шул. Гариф Ахуновның якты дөнья белән саубуллашу мизгеле дә изгеләрчә булды. Аның районадашы, якын каләмдәше һәм берничә ел бергә Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә эшләгән урынбасары Фәрваз Миңнуллин да бу дөнья белән шулай якты итеп, ирләрчә саубуллашу үрнәген күрсәткән иде.

Сүзгә оста, язуда бик өлгер кеше иде Гариф ага Ахунов. Язучылык эшендә олы остаз, бакчачылыкта беренче ярдәм кулы сузучы, кече күңелле, башкаларга карата бик игътибарлы, хәерһах кеше булды. Ятим үскән, күп нужа күргән шәхес. Шунлыктан кеше хәленә керә белә, ярдәм кулы сузарга әзер тора иде. Бүгенге көн әдипләре, шагыйрьләре, башка төр сәнгать әһелләре арасында аннан фатиха алмаган, аның киң колачлы иҗат йогынтысын тоймаган шәхесләр аз түгелдер, мөгаен. Бердәм рәвештә кабатлыйк: теге дөньяда да Гариф Ахуновның урыны җәннәт түрендә булсын. Ул моңа һәр тарафтан бик лаек шәхес иде.

*Лирон Хәмидуллин,*
язучы, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

# « Ну,-малай!»

Талантлы язучы, ялкынлы публицист һәм тәнкыйтьче, кайнар йөрәкле Гариф Ахунов минем күңелемә туры сүзле, эчкерсез, ярдәмчел кеше буларак кереп калган. Көләч йөзе, киң елмаюы белән ул үзенә тартып тора иде.

Гариф Ахунов арабыздан кинәт кенә мәңгелеккә китеп барды. Әмма ул башлап җибәргән игелекле эшләр әле бүген дә дәвам итә. Ике генә мисал. СССР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында гыйльми сәркатип булып эшләгән еллар. Гариф Ахунов – Язучылар союзы рәисе. Мәскәүдә аспирантура тәмамлап, безнең институтта кече фәнни хезмәткәр булып Әмир Мәхмүдов эшли башлады. Беренче көннәрдән үк диярлек ул, уңайсыз гына елмаеп, һаман бер үк мәсьәләне алдыма китереп куя. Аңа фатир кирәк, ишле гаилә, берсеннән-берсе кечкенә балалар. Яшәү шартлары бик тә начар. Мин бары тик гыйльми сәркатип. Квартира белән тәэмин итү минем кулдан килә торган эш түгел. Ләкин ул турыда артык уйлап тормыйсың бит, ничек тә ярдәм итү ягын карыйсың. Бу очракта да алай сугылдым, болай бәрелдем. Ничек тә эш барып чыкмагач, киттем Язучылар союзына – Гариф абый янына. Ни дисәң дә, Әмир Мәхмүдов шигырь дә яза бит әле. Гариф үтенечне кире какмады, фатир алырга дип чиратта торган язучылар исемлегенә кертте, хәтта Союз члены булмаса да. Яшь галим, яшь шагыйрь гаризасына уңай күрсәтмә куйган икән, димәк, Гариф аның киләчәгенә ышанган һәм ялгышмаган. Ничә еллар узгач, Гарифның бәрәкәтле резолюциясе үзенекен итте: филология фәннәре докторы, Язучылар берлеге әгъзасы Әмир Мәхмүдов фатирлы булды.

Икенче мисал. Берничә еллар элек Гариф миңа сөекле язучыбыз Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр җыентыгы әзерләргә тәкъдим иткән иде. Ни өчен дисәң, үз вакытында ул минем Габдрахман Әпсәләмов иҗатына багышланган диссертация яклау утырышында катнашты, саллы гына чыгыш та ясады. Истәлекләрнең күп өлеше язылды, ләкин җыентык басылмый калды. Ни могҗиза, уйламаганда Г. Әпсәләмовның тууына 90 ел тулу уңае белән җыентык әзерләнде һәм басылып та чыкты. Авторларның күбесе, шул исәптән Гариф үзе дә мәрхүмнәр. Аларның Г. Әпсәләмовка карата булган күңел җылылыгы, ихтирамы архив папкаларында йомылып калмады, күп санлы укучыларга барып җитте. Шулай итеп, Гариф башлап җибәргән бу күркәм эш тә ярты юлда ятып калмады. Җыентыкның дөнья күрүе – ике олы шәхеснең истәлегенә якты бүләк.

Көеп, янып яшәде Гариф. Ул битараф кеше түгел иде. Күңелдә уелып калган кечкенә генә эпизод. Танылган язучы Аяз Гыйләҗевнең тууына 70 яшь тулу уңае белән үткәрелгән тантаналы кичә. Г. Камал театрының фойесында кинәт кенә каршыма Гариф килеп чыкты. Һәм яшен тизлеге белән: «Гөлсинә, син ул мәкаләне үзең яздыңмы?» – дигән сорау бирде. (Сүз «Шәһри Казан» газетасында Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган «Ул әле драматург та» дигән мәкалә хакында бара.) Мин бу сораудан аптырап калдым һәм, үзем язмый, кем язсын, дип җавап бирдем. Гариф: «Ну, малай...» – дип сузып кына әйтте дә, капылт кына китеп тә барды. Бер мизгел, бер җөмлә, ә тәэсире һаман да күңелдә. Язучының бу сүзләрендә игътибар да, эчкерсезлек тә һәм сүз белән әйтеп бетереп булмый торган аңа гына хас кешелек сыйфатлары да чагыла. Ул якты кеше иде, әсәрләре дә якты. Күптән түгел миңа «Хәзинә» романын яңабаштан укып чыгарга туры килде. Мин хәйран калдым. Бу роман чыннан да татар әдәбиятының хәзинәсе бит! Әсәрдә бер генә ясалма образ, бер генә уйдырма фикер юк. Барысы да чын, тормыштагыча гади һәм мәгънәле.

Ихтыярсыздан Гарифның үз иҗаты турында «...Ну, малай!» дип әйтерлек монографик хезмәт дөнья күрсә иде, дип уйлап куйдым.

*Гөлсинә Мөхәммәдова*
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

# Узган гомер – истәлек!

Чәчләреңә көмеш кар төшкән булса да, йөрәгеңә кырау төшмәгән, әле күптән түгел генә «Күз нурым» дигән бер тында укып бетерерлек гаҗәп матур әсәр язган идең бит, Гарифҗан Ахунҗанович! Нишләп шундый артык каударланмыйча, бәхилләшмичә, гадәттәгечә эшлекле кыяфәт белән генә китәргә булгансыңдыр, анысы беркем аңламаслык тирән серме, язмыш шаукымымы, бер Алланың үзенә генә мәгълүмдер инде...

1950 еллар. Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап, Биектау районының Мүлмә мәктәбендә эшләгән заман. Ул чакта сугыштан соңгы еллар кырыслыгы үзен һәрдаим сиздереп торса да, кешеләр, шул исәптән мәктәптә укучылар да гаҗәп актив, күп белергә, күп укырга омтылалар иде. Укымышлы кешеләргә, гыйлем ияләренә тартылалар, күңелләрне очсыз-кырыйсыз хыял били... Нәкъ шул чорда мәктәпкә язучылар килә икән дигән хәбәр, яшен тизлеге белән таралып, һәммә кешене дулкынландырды, кызыксыну соң дәрәҗәдә һәркемне киеренке хәлгә куйды...

Кунак килсә таптыра, ат урынына чаптыра дигәндәй, аларны каршылау, кайда, кемгә урнаштыру мәшәкате һәркемнең, аеруча мәктәп администрациясенең үзәк мәсьәләсенә әверелде.

Кыш фасылы, авыл өйләре артык зур түгел, аларның һәммәсен бергә алып бару мөмкинлеге юк. Ниһаять, хәбәр конкретлашты, язучылар өчәү икән: Нур Гайсин, Мөнир Мазунов һәм Гариф Ахунов.

Директор, завуч, әдәбият укытучылары, киңәшләшеп, кунакларны урнаштыру мәсьәләсен хәл иттек. Шул авылда үз йорты белән яшәүче әдәбият укытучысы Сабира апа Вәлиева иң беренче: «Нур Гайсин минем институт буенча сабакташым, үзем алып китәм», – диде. Директор Мөнир Мазуновны сайлады, ә мин Гариф Ахуновны кунак итәргә тиеш булдым. Ул чакта без әнием белән зур бер йортта яшибез.

Халкыбызның борынгыдан килгән гадәте буенча, һәркайсыбыз кунакларын алып кайтып, заманына күрә хәлдә барынча сый-хөрмәт күрсәткәннән соң, мәктәптә очрашулар башланды. Үз чиратында мәктәп укучылары да һөнәрләрен күрсәтергә, каләм осталары алдында шигырь сөйләргә, биергә, җырларга ашкынып тордылар.

Икенче көнне аларның программасында авыл халкы белән очрашу, сөйләшү планлаштырылган икән.

Кич яңадан өйгә кайткач, Гариф Ахуновның әнием белән озын-озак сөйләшеп утыруына хәйран булдым. Әнием – Ләбибә Закир кызы Әхмәтҗанова – зыялы гаиләдә үскән, заманы өчен шактый мәгълүматлы укытучы булганлыктан (әлбәттә, ул чакта пенсиядә), тиз сөйләшеп киттеләр. Кунак аның карамагында...

Минем исә үз мәшәкатем, иртәгесе көнгә дәресләргә әзерләнәсем, дәфтәрләр тикшерәсем бар.

Мин иртән гадәттәгечә 7 дә торсам, кунактан җилләр искән. «Кунак кайда?» – дип соравыма әнием: «Иртән дүрттә үк торып фермага китте, анда да сыер савучы кызларны авызына караткандыр, бер дә сөйләшеп сүзе бетми», – ди.

Мин 7.30 да мәктәпкә барырга урамга чыкканда, күршедә яшәүче савымчы кызлар белән, әллә кайчаннан белешкәндәй, үз кешеләрчә сөйләшә-сөйләшә, безнең кунак иртәнге чәйгә кайтып килә. Әнием исә аны, күптәнге танышы сыман, коймак пешереп көтеп тора...

Көне буе колхоз тормышы белән танышып йөргәннән соң, клубта авыл халкы белән берлектә әдәби-музыкаль кичә уздырдык.

Мин Гариф Ахуновның тынгысызлыгын, һәр эшкә артык җитди каравын, сүз остасы буларак һәркем белән тиз уртак тел таба ала торган кече күңелле, олы җанлы кеше булганлыгын шунда ук аңлаган идем. Шул карашым гомергә үзгәрмәде. Соңыннан мин дә, ул да Казанга кайткач, күп мәртәбәләр очраштык. Мин Россия Мәгариф министрлыгы каршындагы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының Татарстан филиалында эшләгәндә, мәктәптә әдәбият укыту программасының яңа проектын төзегәндә, аның үз иҗаты турында сөйләшергә, киңәшләшергә, шул ук вакытта бик күп төрле әдәбият-сәнгать, мәгърифәт турында гәп корырга туры килгәне бар. Өстәвенә без Гариф Ахунов, Шәһидә Максудовалар белән бергәләп Ялтада иҗат йортында ял иткәндә дә очрашып, соңыннан гаилә дуслары да булып киттек. Алар икесе дә гаҗәеп мәгълүматлы, тыйнак, һәркемгә карата үтә игътибарлы, ихтирамлы кешеләр иде. Шәһидә ханым да әдәбиятны тирән аңлаучы, шигърияткә гашыйк кеше булганлыктан, безнең сөйләшер сүзләребез анда да, юлда кайтканда да, соңыннан Казанда очрашканда да бетеп тормый иде.

Мүлмәгә килгәндә, Гариф Ахунов әдәби журналда эшли иде. Мәктәптә дә, клубта да «Яшьлек яме»н укыган халык аны чын язучы итеп кабул итте. Шул очрашудан соң озак та үтмәде, заман рухын тоеп яшәгән яшь язучының гаиләсе белән Әлмәт якларына китүе мәгълүм булды. Матбугат битләрендә Гариф Ахуновның нефть төбәгендәге хезмәтләре, ул якларда укучылар белән очрашуы, кара алтын табучы фидакарь хезмәт кешеләре, аларның уйларын, тормыш-көнкүреш хәлләрен, гаилә шартларында үзара мөнәсәбәтен, иң әһәмиятлесе – шәхеснең уй-фикерен, кичереш-хыялларын сурәтләгән, шул ук вакытта социаль җирлекне, шул төбәкнең тарихын чагылдырган әсәрләре дә күренә башлады. Гариф Ахунов һәрвакыт күптөрле эш башкарырга сәләтле, хезмәт сөючән, эзләнүчән шәхес иде, тырыш, һәр адымында җаваплылык хисе тоючан җитди һәм шул ук мизгелдә җор күңелле булып күз алдына килә ул...

Шунысы аеруча хәтердә калган. Гариф Ахунов үзенең тырышлыгы нәтиҗәсендә нинди генә уңышларга ирешсә дә, үзе – мин беренче күргәндәгечә – һәркемгә яктылык өләшүче, бар кеше белән дә елмаеп сөйләшүчән гади, киң күңелле шәхес булып кала алды.

Еллар дәвамында тынмас дәртле дә, ярсулы да, моңлы да, самими җыр сыман гомер хатирә итеп кенә бирелгән, күрәмсең...

*Гөлчәчәк Әдһәмова,*
Татарстанның һәм РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы

# Яшьлек-яме

Безнең яшьлекнең яме иҗат иде. Гариф Ахуновның яшьлеге иҗатта – канатлы иҗатта үтте. Аның яшьлеге безнең барыбызга да үрнәк булырлык дәртле, мул уңышлы иде.

Гариф Ахунов... Минем яшьлек, минем иҗат яшьлегем Гариф Ахунов исеме белән бәйле булды. Без әдәбият мәйданына Гариф белән бер чорда килдек. Ул прозага, мин поэзиягә. Әдәбиятка бик канатланып, бар дөньяны яулап алырлык булып ашкынып килдек. Һәм, әйтергә кирәк, Гариф Ахунов чынлап та үзенең якты, уңдырышлы иҗаты белән бөтен дөньяны яулап алды кебек. Ул әдәбият, сәнгать дөньясында һәм республикабыз тормышында үзенең актив эшчәнлеге белән барыбыздан да аерылып торды.

Безнең яшьлек Казанның үзәгендә – Бауман урамы, 19 нчы йортта – Матбугат йортында үтте. Соры төстәге мәһабәт бу бина тыштан караганда күңелле тәэсир калдырмый шикелле. Әмма ләкин аның эчендә әдәби иҗат гөрли, тормыш кайный иде. Вуз бетереп килгән бер төркем яшь әдәбиятчылар, бу бинаны шау-гөр китереп, нәшриятта, газета-журнал редакцияләрендә эшлиләр, язалар, иҗат итәләр. Тукай клубында кичәләр уздыралар, җыелышларда катнашалар, бәхәсләшәләр, концертлар куялар, җырлыйлар, бииләр – ду киләләр. Гариф бу әдәби ыгы-зыгының барсының да үзәгендә.

– Кызлар!.. Повестемның исеме үземә ошамый... Укып чыгып, исем табышыгыз әле!.. Удачный матур исем тапкан кешегә бер коньяк куям!..

– Давай, мин укып карыйм!.. – дип, мин кулъязмасын алдым. Һәм шул көнне үк яшьләр тормышын чагылдырган бу повестьны укып чыктым да, Гарифка «Яшьлек яме» дигән исем тәкъдим иттем.

Гариф «Яшьлек яме» дигән исемне бик яратты. Шулай итеп, аның беренче әсәре, яшьлегенең яме булып, зур иҗат юлын башлап җибәрде.

Әйе, ямьле яшьлек, матур яшьлек, күкрәп, яшьнәп торган еллар!..

Яшьлегем генә түгел, минем бөтен иҗат тормышым Гариф Ахунов белән якыннан аралашып, аның белән җылы мөнәсәбәттә яшәп үтте. Гариф гаҗәп дәрәҗәдә эчкерсез күңел белән аралашучан кеше иде. Минем аны үз гомеремдә бер тапкыр да караңгы чырайлы, ачулы кыяфәттә күргәнем булмады. Ул һәрвакыт ягымлы елмаеп йөрер иде. Һич һаваалануны белми торган күркәм холыклы кеше. Мин күп мәсьәләләрдә аңа таяна, аның ярдәмен тоя идем. Ул кешегә бервакытта да начарлык эшләмәде. «Илле җыр» исемле китабымны дөньяга чыгарганда, китабыма кереш сүз язды, җырларыма югары бәя бирде. Бу китабым өчен хөкүмәтебез Г. Тукай исемендәге премия биреп зурлады. Гариф Ахунов, Тукай премиясе бирү комитеты әгъзасы буларак, минем кандидатурамны яклап чыгыш ясаган, бу турыда миңа комитет әгъзалары әйтте.

Иҗатта гына түгел, тормыш-көнкүрештә дә Гариф Ахунов һәм аның гаиләсе белән аралашып яшәдек. Әле гаилә корып, беренче бәбиләребезне тапкан елларда ук, бер-беребезгә кулдан килгәнчә ярдәмләшә идек. Бервакыт Гариф кечкенә уллары Рәшит өчен бала караваты эзлим, һич кенә дә таба алмыйм, дип сөйләнеп торды. Сугыштан соңгы авыр еллар, бала караваты гына түгел, бик кирәкле башка әйберләр дә табып бул-



Гариф Ахунов (уңнан өченче) «Азат хатын» редакциясендә иҗади очрашуда. Казан, 1986

мый торган чор иде. Минем кызым Асия бераз үсә төшкәч, караваты кирәкми башлаган чак иде, мин Гарифка кызымның караватын бирдем. Бу турыда гел искә төшереп көлешә идек.

Гариф шигърияткә гашыйк прозаик иде. Үзе дә шигырьләр яза, яраткан шигырьләрен яттан сөйләп йөри иде. Бер кичне без, Укытучылар йортында сайлау эшләренә багышланган ниндидер утырыштан чыгып, Профсоюз урамы буйлап кайтып барабыз. Гариф дәртләнеп Саҗидә Сөләйманова шигырьләрен сөйли. Менә нинди шигырьләр бар бит, ди. Фикерләр тирән, хәтта юл араларында да фикерләр бар, ди. Мин, кызыгып: «Минем шигырьләремне дә яттан сөйләсәң иде»,– дидем. «Мин синең җырларыңны җырлыйм», диде дә кычкырып: «Менәргә иде Урал тауларына!..» – дип җырлап җибәрде. «Тукта! – дим,– сайлау участогыннан эчеп чыкканнар дип уйламасыннар»,– дим... Җырларга да һәвәс иде бит ул. «Көмеш тояк тулпар атым!..» дип җырлап җибәрүләре гел колакта чыңлап тора.

Гарифлар озак еллар Әлмәттә яшәделәр. Гариф Язучыларның Әлмәт бүлеген ачу, бүлекне оештыру эшләре белән Әлмәткә башта берьялгызы гына китте. Гаиләсен чакырып хәбәр җибәргәч, мин аның хатыны Шәһидә ханым белән улы Рәшитне поездга утыртып озатып калдым.

Идел буенда, матур бер аланда, иҗат хезмәткәрләренең бакчалары бар. Безнең йортлар күршеләр дип әйтерлек, бер-берсенә якын гына. Гарифларның йортлары зур түгел, җыйнак кына. Әмма матур. Гариф аны үз куллары белән диярлек төзеде. Аның тыйнак булганлыгы шушы бакча йортыннан да күренә. Шулкадәр танылган, халыкның мәхәббәтен казанган, озак еллар Татарстан Язучылар союзы рәисе булган Гариф Ахунов, башка язучылар «престижный» яңа йортларга, ике-өч катлы коттеджларга күчәкүчә «интеккәндә», үзенең «хрущевка»сында һәм бакчасындагы түренә сәке ясап куелган, авыл өе кебек кенә йортында рәхәтләнеп яши бирде.

Ахуновлар гаиләләре белән тыйнаклар. Шәһидә ханымның, мин «персидәтел» хатыны дип, борын чөйгәнен күргәнем булмады. Татар хатыннарына хас булганча гади генә, үзебезчә.

Бакчада Гарифлар белән тату күршеләр булдык. Гариф бакчасында җиң сызганып, гади крестьян кебек көрәк тотып эшли, җирдә казына, балта-чүкечен уйнатып, каралты-курасын төзекли, физик хезмәттән соң иҗат эшенә чума иде.

Әҗәл аны көтмәгәндә безнең арабыздан алып китте. Ул рәхимсез көнне барыбыз да бакчада идек. Бакчачыларның җыелышы булырга тиеш иде.

Җәйге матур иртә иде. Кояш балкый, сандугачлар сайрый. Җыелыш башланыр алдыннан кемдер Гарифның вафат булуын әйтте. Бу сүзне ишетү барыбызга да бик авыр булды.

Һәм Гарифны соңгы юлга озатып, берничә көн узгач... бакчага килсәм... Гарифҗан йорты ягыннан кәккүк сайраган тавыш ишетелә... Гарифларның бакчасында үскән каенга кунган булса кирәк... И сайрый-сайрый... Сайрамый, ахры, өзгәләнеп кычкыра. Гадәти кәккүкләр бит бер-ике кычкыра да туктый. Ә бу кәккүкнең туктарга исәбе юк!.. Шаккатып, күзләремә яшьләрем килеп тыңлап торам. Шундый ямансу, шундый моңсу! Гарифның бакчасына җаны кайткандыр... Җаны шулай өзгәләнгәндер... Китәсе килмидер...

Гариф төскә-биткә дә чибәр, холкы белән дә күркәм чын татар ир-егете иде!

*Гөлшат Зәйнашева,*
шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе
*2001, 11 март*



Шәһидә Максудова һәм Гариф Ахунов. 1950 еллар

# Гариф-абыйның-күңел-җылысы

Аның безне калдырып китеп баруы минем өчен бөтен көченә автострада буйлап барган автомашинаның, кинәт идарәсен югалтып, юлдан тирән дәрьяга очуы сыман хәтәр хәл булды. Дөрес, мин аның бераз авырганын-сырхаулаганын белә идем инде, әмма авыруының бу кадәр тирәнгә китә торган Газраил уены дип уйламый идем, чөнки Гариф абый үзенең авыр да, фаҗигале дә хәлен һич сиздерми иде.

Ул, без беренче тапкыр очрашкан ерак 1968 елның көзендәге кебек, көләч йөзле, дәрманы ташып торган оптимистик рухлы, картаюның ни икәнлеген белмәс гүзәл шәхес иде. Ул вакытта аңа нибары 43 яшь тулган булган. Ә миңа ул үземнән бик күпкә өлкәнрәк кебек тоелды. Әйе, ул чакларда ук инде язучы Гариф Ахунов бик күп иләкләр аша үткән зирәк акыллы, талантлы кеше иде. Талантның да әле ниндие! Үтә дә шәфкатьлесе, миһербанлысы, мәрхәмәтлесе! Кешегә ярдәмгә килү, дусларча киңәш бирү аңа Аллаһы Тәгаләнең үзеннән иңдерелгән төсле. Хөсетлек, көнләшү, үч алу дигән сыйфатлар бу кешедә гел булмады, дисәк тә, дөреслеккә туры килер иде. Әйе, кайбер яшьтәшләренә, дусларына үпкәләгән чаклары аз булмады аның, әмма аларның аткан ташына ул яхшы аш белән кайтарды. Бу аның әсәрләре тирәсендә кайчак кайнаган бәхәсләргә карата булган мөнәсәбәтендә дә ачык чагыла иде.

Шуны әйтим, Гариф абый белән безнең аралашу –кешелекле зур дуслык, ләкин без аны беркайда да игълан итеп йөрмәдек, үзара сөйләшкән-гәпләшкәннәрне ни ул, ни мин дөньяга чәчмәдек. Тора-бара безнең дуслыгыбыз гаилә дуслыгына әверелде, мөмкин булганча без бер-беребезгә ярдәмләшеп яшәдек, әмма ярдәм сорап ул да, мин үзем дә бер-беребезне артык йөдәтмәдек. Ләкин дистәләгән яшь язучылар арасында мин дә аның шәкерте булып саналырга хакым бар дип исәп итәм. Ул миңа мөмкин булган кадәр ярдәм итте. Гариф абыйның өндәве буенча, аның киңәшен тотып, мин Түбән Камадан Казанга күчеп килдем. Мине Язучылар берлегенә әгъза итеп алучыларның берсе дә ул иде. Аның рәислегендә булды бу хәл. Чөнки Гариф абый белән Гөлшәһидә апага, бөтенесен булмаса да, үзем күрсәтергә кирәк дип тапкан әсәрләремне күрсәтмичә калдырмый идем. Һәрхәлдә, аларның киңәше минем өчен хәлиткеч була иде.

Ул үзе дә яңа гына язган әсәрен, миңа күрсәтмичә, минем фикеремне тыңламыйча, кемгә дә булса укырга бирмәде, матбугатка чыгармады.

Җитмешенче еллар азагында минем Мәскәүдәге студент бүлмәмә Гариф Ахунов үзе килеп керде. Брянск шәһәренә әдәбият бәйрәменә барышлый хәл белергә керүе икән. Сирәк-мирәк булса да минем яныма, якташларның хәлен белергә, татар-төрки язучылары керә иде. Әмма Татарстан Язучылар берлеге рәисенең менә шулай кулына гади генә портфель тотып килеп керүен, дөресен әйтим, мин күз алдыма да китермәгән идем. Кунакны түргә утырттым, үзем чәй әзерләргә кухняга йөгердем. Яныма студентлар кергәли: «Кем ул кунагың?» –дип сорашалар, «Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов! –дим горурланып.– Хәлемне белергә кергән!» Исләре китеп: «О-о-о-о!» –диләр торакташларым.

Чәйләр эчтек, Гариф абыйның портфеленнән чыккан Казан күчтәнәчләреннән дә авыз иттек. Аның әле иртәгәсен генә китәсен белдем дә: «Бездә генә кунып кит, Гариф



Г. Тукай музеенда Гариф Ахуновны искә алу кичәсе. Казан, 2010

абый, әллә кая мосафирханәләр эзләп йөрмә»,– дидем. Ул риза булды. Шулай сөйләшеп, минем шигырьләрне укып утырганда, балкар егете Мөхәммәт Гөккиланы керде. Татар телен су эчкәндәй белгән, Гариф абыйның кем икәнлеген әсәрләрен укып таныган бу егет тәкъдиме белән без Гариф абыйны төрки-кавказ студентлары белән күрештерергә булдык. Гариф абый рәхәтләнеп ризалашты, минем бүлмәмдә җыелышкан идек, аннан ары, бүлмәгә кешеләр сыймый башлагач, лифт каршындагы «пыяла бүлмәгә» кереп утырыштык. Гариф абый борынгы һәм совет чоры татар-төрки әдәбияты һәм әдипләр турында сөйләде, аның белән чикләнмичә, таҗик, дагыстан, гөрҗи, әрмән әдәбиятларыннан да мәгълүмат бирде. Үзе ял итәргә туктагач: «Кая, егетләр, хәзер сезнең җимешләрегезне дә татып карыйк! Әйдә, Әхмәт, дилбегәне син кулыңа ал инде!» –диде. Мин татар егете Вагыйф Басыйров исемен атадым, украин, рус телләрендә яза, дидем. Мәһабәт егет аягына торып басты: «Гариф абый, гафу итегез, ана телемдә мин сөйләшәм генә, үзем Славутада яшим, Украинада. Мәктәптә украинча укыдым, татарча сөйләм телен генә беләм»,– диде дә украин, рус телләрендә шигырьләрен укыды. Гариф абый аны да, кумык Атау Атаевны да, казак кызы Баянсылуны да дикъкать белән тыңлады. Йөзендә уйчанлык, нindидер моңсу елмаю иде төсле.

Кунаклар таралгач, миңа рәхмәт әйтеп, Гариф абый: «Искиткеч зур эш башкардың, энем Әхмәт. Мондый мөшәвирә безнең халыкларга бик кирәк. Киләчәктә Казанда төрки халыкларның әдәбият бәйрәмнәрен үткәрергә кирәк»,– диде. Әйе, җитмешенче, сиксәненче елларда мондый әдәбият бәйрәмнәре күп үткәрелде.

Гариф абый зур сәяси сизгерлеккә дә ия кеше иде. Аның эш сәләте дә зур, чагыштыргысыз зур иде. Шул ук Брянск шәһәренә барасы төндә, таң алдыннан сәгать өчләрдә торып, ул гаҗәеп көчкә ия чыгыш та язган иде. Андый чыгышларны Гариф абый тиз

һәм тәэсирле итеп яза белде. Моның серен мин Мәдәният министрлыгында эшләгәндә аңладым: тиз һәм үтә дә көчле йогынты ясарлык чыгыш язу өчен бик зур эрудиция сорала. Мәдәни һәм әдәби, тарихи һәм сәнгати белемең булганда гына Ахунов ясый алган тәэсири көчкә ирешергә мөмкин.

Без Гариф абыйның да, минем дә туган-үскән якларда еш булгаладык. Якташлар белән сөйләштек, шулай мин – аны, ул мине аңлый алдык, бер-беребезгә карата ихтирам, хөрмәт артты.

Язучыларның XVIII корылтаенда ул берлекне тулаем саклау, язучыларның авыр матди хәлен җиңеләйтү турында чыгыш та әзерләгән иде, әмма үзара килеп чыккан низаг, кайберәүләрнең эшне авантюристик юлдан алып китәргә маташуы әдипнең кәефен кырды. Кыскасы, Гариф абый, бар түземлеген җыеп, күзәтүче хәлендә утырырга тырышты. Әмма берлекнең киләчәге, язучыларның киләчәге аны бик борчыды. Корылтайдан соң ул үзен уңайсыз тойды, чөнки «эшсез калу», иҗтимагый эштән читләшү аны картайтты сыман. Ләкин ул мәйданга яшь көчләр килергә тиеш икәнлеген дә анык аңлады.

Язучы бөтен көчен «Идел кызы» трилогиясенең өченче китабын язуга туплады. Очрашкан-күрешкән чакларда ул миңа теге йә бу башламнан өзек сөйләр иде. Ул шулай киләчәк романын күңелендә яза, алмаз эшкәрткән кебек эшкәртә, аерым детальләрен камилләштерә иде. Ошыймы-ошамыймы, дигән сорау бирми иде ул...

Гариф абый «Идел кызы» трилогиясенең соңгы өченче китабын төгәлләү турында хыялланды. Төрле тетрәнү-типрәмнәргә бай тормышы, каты авырулар, күз нурларының сүнә баруы олуг әдипне бу зур һәм үзе мөһим дип санаган эштән бер генә минутка да туктата алмадылар. Хатыны – шагыйрә, язучы һәм тәрҗемәче, гомерен тулысынча иренә, гаиләсенә багышлаган Гөлшәһидә ханым Максудова – олуг язучы янына якын дусларын да сирәк кертә башлаган иде. Чөнки Гариф абыйның эше тыгыз, вакыты тар. Бик күп, бик мул максулатлы эшләде ул соңгы елларда.

Гомумән, Гариф абыйның иҗади сәләте бик зур булганлыктан, 18 сәгать эшләү аның өчен норма иде. Саны бик авыртмасын өчен, Гөлшәһидә апа аңа бик матур йомшак күпчек тә тегеп җайлап куйган. Дөрес, озак утырып эшләгәннән соң, гәүдә арый, тән сызлый башлый. Ләкин Гариф абый үзенә аерым шартлар таләп итмәде. Аның хәлендә, аның дәрәҗәсенә ирешкән язучылар үзләренә әллә нинди фатирлар булдырдылар, күпләре берничә фатирга ия була алды. Әмма Ахунов гомере буе шул «хрущевка»сында яшәде. Гадел һәм гади кеше иде, мәрхүм. Ул фәкать язучыны, коллегасын кайгыртучы иде. Язучылардан олысы-кечесе, яше-карты ул рәис булып эшләгән көннәрне һаман да сагына төсле. Аның белән сөйләшүе дә, фикер алышуы да рәхәт иде, диләр. Ә бөтен СССРны таң калдырган бильярдны, Татарстаннан үрнәк алып, башка Язучылар берлекләре дә булдырды. Шахмат уены да гаҗәеп киң таралган иде Ахун заманында! Һәм язучылар берлеккә теге йә бу үтенеч белән генә түгел, аралашу, ял итү –дөнья хәлләрен белеп кайту өчен дә киләләр иде. Өлкәннәргә дә, яшь буынга да нурлы караш, ярдәм кулы һәрвакыт әзер иде. Нури Арслан, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Мөхәммәт Садри, Зәки Нурилар олы һәм матур, киң күңелле зыялы халык иде аның янында; Мирсәй Әмир, Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур, Фатих Хөснилӛр тиң итеп, үзләренең җитәкчесе итеп таный иделәр аны.

Гариф Ахунов эшләгән чорда Тукай клубы да гөрләп торды. Композиторлар, рәссамнар, сәнгать әһелләре килә иде шигъри кичәләргә. Мин хәзер Гариф абыйның нинди тарту көченә ия булганлыгын ныграк аңлыйм. Гаҗәеп аурага ия булган икән ул безнең нурлы рәисебез! Нурлылык, тарту көче аның иҗатына да күчте. Нинди генә әсәрен алма, кечкенә генә мәкаләдән алып эпопеяларына кадәр нур, җылылык оптимистик рух сирпеп торалар. Кара аның Чишмәбайларын, Тимерханнарын, Ардуан

батырларын – нинди энергия, нинди көч аларда, ә Габбас хәзрәтнең үз кыйбласына инануы?! Дөньяның ул теләмәгән икенче якка борылуын күреп, хәтта үзенә кул сала, ләкин баш ими, мескенләнми.

Нинди генә матур манзаралар, нинди генә мөнәсәбәтләр, нинди генә характерлар, образлар тудырмаган олуг әдибебез?! Аларның барысы да тере, исән сыман күз алдында торалар, яшәү асылына төшенергә ярдәм итәләр.

Гариф Ахунов – гаҗәеп талантка ия тылсымлы сурәтче. Бәлки, аңа икенче таланты – рәссам булуы да ярдәм иткәндер? Әлбәттә, монда һичнинди шөбһә булуы мөмкин түгел. Шуңа күрә дә, минемчә, аның әсәрләре кинодраматургларга киң мөмкинлекләр тудырды, кинотасмаларга ятты. Әйе, Татарстанда дәүләт киностудиясе булса, аның әсәрләре кинофильмнарга әйләнерләр иде. Мондый эпопеялар рус язучыларында булган тәкъдирдә инде күптән нәфис фильм булып экраннардан халыкка ирешә барды. Кинокомитет төзелгәч, без бу турыда хыялланган идек, әмма комитет комитет кына булып калды шул, зур кинога бирешә алмады… Ә бит нәфислек мәҗлесендә Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еникиләр кебек сүз осталары, даһи язучылар күп иде.

Дөрес, мин халкыбызга аларның икесен – Г.Ахунов белән Ә. Еникине кинотасмаларга төшереп калдыра алдым, әмма А. Гыйләҗев, М. Хәсәнов алдында минем дә, кинокомитетның да бурычы зур төсле.

– Аллаһы Тәгалә аңа карата үтә дә миһербанлы булды. Гаҗизлек юллары белән бер тотам газизлеген дә бүләк итте. Дөньяда адәм баласының башына килә торган язмыш бүләкләреннән әз-әзләп тә, муллыгы белән дә өлеш чыгарды, иншалла! Красноярск краенда да, Мәскәү Кремлендә дә булырга язды әдипкә. Илебезнең йөзләгән милләт вәкилләре белән ул уртак тел таба алды. «Йолдызлар калка»дан гайре үзе сөйләгәннәреннән беләм, аны танышлары ярата иделәр. Ә инде аның белән сәфәргә барырга туры килгән чакларда, аны якын итеп әллә каян күреп исәнләшә, хәл-әхвәл сораша иде совет әдипләре. Алар өчен ул «Гариф дорогой» иде. Елмаеп, матур гына, күңелле итеп кенә хәл белешер, гәпләшер иде. Аның ахири дусларын саный калсаң, йөзләгән сәхифә тутырып булыр иде төсле. Рәсүл Гамзатов, Мостай Кәрим, Наҗар Нәҗми, Кайсын Кулиев, Әсһәд Мохтар, Давыт Көгелтинев – Урта Азия, Кавказ, Украина, Балтыйк буе, Себер, Ерак Көнчыгыш язучылары аны ихлас күңелдән ярата, ихтирам итә иде; һәм ул һәрвакыт үзәктә булыр, җан җылытыр, күңел күтәрер иде. Татарның яхшы данын Г. Ахунов дөнья буйлап таратты. Сөймәгәннәрне сөйдерде, белмәгәннәргә белдертте, танытты. Холкы шундый иде аның: кешеләр белән тиз аралашып китә иде. Һәммә кеше аны үзенеке саный башлый иде. Ләкин шуны да әйтеп үтү зарур: Гариф абый кешене дә кайгырта белде. Игелекле эшен күреп куана да, үз күңелен күтәрә дә белде. Күпме язучы аның рәислегендә фатирлы булды! Рәислек иткән соңгы елында гына да без аның белән СССР әдәби фондыннан 120 мең сум акча ала алдык, хәзерге акча бәрәмлегенә күчерсәң, чама белән 250 миллион сум була ул. Күпме иҗат йортына юллама алынды ул елларда, күпме кешегә ярдәм күрсәтелде…

Яраткан дусны, авыр чакта атаңдай таяныр кешеңне югалту ифрат та авыр. Бу Аллаһы Тәгаләдән үзеңә иңгән дикъкатьләү авазы да сыман. Игътибарлы булыйк берберебезгә, якыннарны, дус-ишләрне рәнҗетүдән ерак торыйк. Каләмдәшләребезгә игътибарлы булыйк, алар өчен Гариф Ахунов куанган кебек куаныйк, ул ярдәм иткән кебек ярдәм итик.

Бер-беребездән җан җылысын кызганмыйк. Моны бездән Гариф Ахунов хатирәсенә тугры булу хисе дә таләп итә.

*Әхмәт Гадел,*
шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

# Хәтер-офыкларында

Гомер юлында кемнәр белән генә очрашмыйсың да, нинди язмышларның гына шаһиты булмыйсың? Берәүләр, күз алдыннан югалу белән, бөтенләйгә оныты- ла, икенчеләр исә, тормыш чылбырының бик мөһим бер буыны булып, күңелдә тирән эз калдыра, әледән-әле хәтер офыгында терелеп, «ул юлдан китмә, менә бусына борыл» дигән сыман, сиңа юнәлеш-кыйбла күрсәтеп тора. Гариф абый да минем өчен, мөгаен, нәкъ шундый шәхесләрдән саналырга хаклыдыр.

Юк, минем бу мөнәсәбәтем аның иҗатыма һәрвакыт теләктәш вә хәерһах булуы, Язучылар берлегенә кабул ителгәндә, иң беренче тәкъдимнамә бирүе яки шигырь-поэ- маларымны бәйнә-бәйнә өйрәнеп, республикабызның иң мәртәбәле газетасы «Ватаным Татарстан»ның бөтен бер битен тутырып мәкалә язуы аркасында гына түгел. Г. Ахуновта кешеләрне үзенә тартып тора торган нindидер бер тылсымлы ачкыч бар иде шикелле. Аның белән аралашкан кешеләр, нинди генә даирәдән, нинди генә милләттән, нинди генә һөнәр иясе булмасын, шунда ук уртак тел табалар, бераздан инде, бик күптәнге танышлар кебек, иркенләп сөйләшеп китәләр иде. Ачык йөзе, ихлас елмаюы, үз-үзен гаять тәрбияле тотуы әңгәмәдәшләрен шулай әсир итә торган булгандыр, күрәсең.

Мин Гариф абыйны әле ул зур-зур романнар, повестьлар, сәхнә әсәрләре язганчы, СССР Верховный Советына кат-кат депутат булып сайланганчы, КПСС съездларына делегат булып барганчы, язучы буларак илкүләм дан яулаганчы ук та белә идем.

Без, илленче еллар уртасында Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбият бүлегендә укучы студентлар, лекция-семинарларга әзерләнүдән бигрәк, язучы халкы тирәсендә чуалуны артыграк күрә, кайсы каләм остасының булса да күзенә чалынып, газета-журналларда алар фатихасы белән берничә шигырь бастыру ягын карый идек. Һәр җомга кичендә Тукай клубына эләгергә тырыша идек. Иҗат секцияләрендә катнашып, анда берничә кәлимә сүз кыстыру исә... анысы инде хыялның да аръягы булгандыр. Шундый утырышларның берсендә Гариф абыйның кемнедер яклап, чәчрәп чыгуы истә калган. Кемнеңдер нindидер әсәре тикшерелә иде бугай. Бүлмәдә утызынчы еллар зилзиләсен исән-сау кичкән «тәнкыйть генераллары» утыра. Ә Гариф абый, аргумент арты аргумент китереп, тегеләр яклаган фикерләрнең нигезсезлеген исбат итә. Утырышның нәтиҗәсе ничек булгандыр – анысы истә калмаган. Әмма Гариф абый үз фикерен шулай ялкынланып яклавы белән ул чакта яшьләрнең зур ихтирамын казанган иде. Шуннан соң без аның хикәяләрен генә түгел, тәнкыйть мәкаләләрен дә даими укый торган булып киттек. Хәер, ул эшләгән «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналын без болай да бер тышлыгыннан икенчесенә кадәр җентекләп укый идек. Г. Ахуновның И. Гази, Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, М. Әмир, С. Баттал кебек танылган язучылар турындагы төпле, нигезле мәкаләләре ул вакытта әдәбият капкасы төбендә таптанучы яшьләрнең күп кенә сорауларына җавап та бирә иде.

Ә аның «Яшьлек яме» дигән повесте нәкъ менә без көткән әсәр булып чыкты. Чөнки ул, язучы хыялына манчылган булса да, нәкъ менә факультетыбызда әле берничә ел элек кенә булган реаль вакыйгалар, безнең реаль укытучыларыбыз турында иде. Без әсәрнең теге яки бу каһарманын нәкъ менә алар арасыннан эзли идек.




Гариф Ахунов Татарстан Республикасының бәйсезлеге турында декларация кабул ителүнең 5 еллыгына багышланган тантаналы җыелышта чыгыш ясый. Казан, 1995

Берзаман Гариф абыебыз әллә кая китеп югалды. Баксаң, ул Әлмәт якларына, нефтьчеләр арасына барып урнашкан икән. Остазы Ибраһим Гази аңа тормышны тормыштан өйрәнергә киңәш иткән. Ул елларның җимеше күз алдында – «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» романнары аны олы язучылар рәтенә бастырды.

Бу әсәрләр хакында кайберәүләр әле Гариф абый исән чакта ук буза куптарырга, аның иҗат принципларын кире кагарга маташып карадылар. «Производство темасы» дигән төшенчәне алар технологик процесслар, һөнәри терминология, шәхеснең бөтен эш-гамәлен тулаем җәмгыять мәнфәгатьләренә буйсындыру дип аңлыйлар һәм үз фикерләренә дәлилне дә, бу катлаулы процессларның эченә кереп тормастан, нәкъ менә шундый әсәрләрдән эзлиләр иде. Хәлбуки, Г. Ахунов әсәрләренең каһарманнары, билгеле бер һөнәр ияләре, дорфа итеп әйтсәк, эш атлары булудан бигрәк, олы язмышлы, ярата һәм дошман күрә белгән, вакыт-вакыт хаталанган, кайсыдыр сөйкемле, кайсыдыр җирәнгеч, әмма тере, җанлы кешеләр иде. Шуңа күрә әдәбият сөючеләр аларны якын танышлары, күршеләре, туганнары белән чагыштырып укыдылар, бу кешеләр арасында үзләренә охшаганнарын эзләделәр, берәүләргә симпатия белән, икенчеләренә нәфрәт белән карадылар. Бу, асылда, реалистик әдәбиятның үзенчәлекле тантанасы иде.

Әлмәт төбәге элек-электән талантлар тупланган, зур иҗат мөмкинлекләре булган як. Анда Татарстан Язучылар берлегенең бүлекчәсен оештыру зыялыларыбызның күптәнге хыялы иде. Ләкин бар нәрсәгә кысылырга яраткан Мәскәү үз фатихасын тиз генә бирергә теләмәде. Ниһаять, тарткалаша торгач, рөхсәт бирмичә булдыра алмады. 1963 елның мартында бүлекчә рәсмиләштерелгәч, иҗади коллектив туплау, яшь әдәби көчләрне эзләп табу һәм аларга тиешле юнәлеш бирү кебек җаваплы вазифа да Гариф Ахунов җилкәсенә төште. Шул чорда Лениногорск каласында телестудия ачылып, аның гөрләп эшләп китүе нефть төбәгенең иҗат көчләре өчен дә өстәмә мәйдан булды.

Мин, ул елларда телевидениедә эшләгән кеше буларак, Гариф абый белән якыннан нәкъ менә шунда таныштым. Язучылар зәңгәр экран белән бик тиз дуслаштылар – атна саен диярлек Лениногорскига кунакка килә торган булдылар. Өстәвенә монда алар якын иткән Шамил Бикчурин да эшли иде бит әле.

Казаннан нефть төбәгенә берничә көнгә, хәтта бер-ике айга командировкага килеп, кара алтын чыгаручылар турында очерклар, хикәя вә шигырьләр язарга маташкан каләм ияләре дә байтак иде ул елларда. Ләкин ул «гастролерлар»ның язганнары укучы күңелен яулый алмый иде шул! Ә менә Г. Ахунов, М. Хәсәнов, Р. Төхфәтуллин, Ш. Бикчурин кебекләр бу җирләргә кендекләре белән береккән, әсәрләренең каһарманнары белән күршеләр булып яшәгән, бәйрәмнәрдә, туйларда гына түгел, бернинди сәбәпсез дә мәҗлестәшләр булган, дуслашып, дошманлашып, янәдән татулашып, араларны дипломатик тел белән генә түгел, сүгенү сүзе белән дә ялгый, җайлый алган тормышчан, реаль, аларны аңлардай үз кешеләр иде. Шул елларда, кинооператор ияртеп, буровойдан буровойга, промысел идарәсеннән скважиналар ремонтлау цехларына туктаусыз чапкан телевизион журналист буларак кистереп әйтә алам: нефтьчеләр, хәер, бер алар гына микән, аларга мәдхия яудырган һәр кәгазь кыштырдатучы каршында да өзелеп төшмиләр, телләре, серләре теләсә кем алдында чишелми иде. Гариф абый алар белән уртак тел таба алган сирәк бәхетлеләрдән булды.

Әлбәттә, моңа аның үзенең үтә гадилеге, кешеләр белән бөеренә таянып, вәкарь белән түгел, ә аларны яратып, тиң күреп сөйләшүе дә сәбәпче булгандыр. Шуңа күрә аның үзен дә ихтирам итәләр иде – мин моңа бик күп тапкырлар инандым.

Гариф абыйның Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып эшләгән еллары мин Габдулла Тукай исемендәге клубта директорлык вазифаларын башкарган чорга туры килде. Бик күптәннән үзем ихтирам иткән кешенең шундый җаваплы урында нәтиҗәле эшләве күпмедер дәрәҗәдә минем намуслы яки ялкау булу-булмавымнан да тора иде. Тик нәрсәдән башларга? Клубта «җомга»лар үтүдән туктаган, ара-тирә оештырылган очрашуларга халык юньләп йөрми... Кыскасы, кырык эш кырык җирдә кырылып ята. Гариф Ахунов һәм аның урынбасары Фәрваз Миңнуллин белән мәсьәләне уртага салып сөйләшкәч, Тукай клубының элекке данын кайтару буенча мөһим чаралар билгеләдек. Активистлар эшкә җигелде. Пропаганда җайга салынды: радиода, телевидениедә, газета-журналлар редакцияләрендә дуслар байтак, чыгыш ясарга телисеңме, информация бирмәкче буласыңмы – рәхим ит, дип кенә торалар. Хәтта Таһир Ильясов исемле фотограф та безнең уңышка үз өлешен кертте. «Әдәби җомга»ларда катнашкан әдипләр, шагыйрьләр, артистлар белән бергәләп фоторәсемгә төшәргә клубка килгән кайсы гына тамашачы атлыгып тормый иде икән?

Берничә айдан язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубы шаулап-гөрләп эшли башлады. Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Х. Туфан, Б. Урманче, Г. Шамуков, Н. Даутов, Н. Җиһанов, С. Кудаш, М. Кәрим, С. Садыйкова, Г. Кайбицкая кебек зыялыларыбыз белән бергәләп төшкән сурәтләр меңләгән әдәбият сөючеләрнең гаилә альбомнарын бизәде. Ә иң мөһиме – иҗат көчләренең халык белән арасы якынайды, аңлашу даирәсе киңәйде. Гариф абый Язучылар берлегенең бу тармагында эшләрнең шулай җанланып китүеннән бик канәгать иде. Аннан инде минем вак-төяк гөнаһларым булган вакытларда да авыр сүз әйтми торган булды. Үзе кебек үк эшлекле, сүздә торучан, ышанычлы кешеләрне ярата иде ул! Мине Башкортстанның халык шагыйре Мостай ага Кәримгә тәкъдим иткәндә дә ул, миңа яхшы мөнәсәбәтен күрсәтергә теләп:

– Безнең Тукай клубының генеральный директоры шушы була инде, – дип шаяртты.

Иртәгәсен Гариф абый белән Шәһидә апа Уфа кунагын безнең өйгә алып килделәр. Мостай ага хатыным Мәдинә Маликова әсәрләрен дә, минем шигырьләрне дә әйбәт белә икән.

– «Беренче мәхәббәт» дип, «Зәңгәр күлмәк» дип мәҗлесләрдә синең җырларны җырлап утырабыз икән әле, – диде ул, шау-гөр килеп.

Табын тирәсендәге сөйләшүләр ничектер эчкерсезрәк була – бер-береңнән тел яшермисең. Безнең әңгәмәдә дә бөтенесе – сөенечлесе дә, көенечлесе дә – ачыктан-ачык иде. Мостай ага сугыштан соңгы чорда Казанга күчеп төпләнергә дә булган икән. Әмма безнең кайбер язучылардагы тар күңеллелек, хөсетлек, көнчелек күңелен шөбһәләндергән.

– Бар шул бездә шундый начар чир... бар... бар... – дип килеште Гариф абый да, борчылуын белдереп.

Кем кем, ә ул Язучылар берлеге дигән үтә чуар, һәркем үзен даһи санап йөргән коллективта хәлләр ничек икәнен һәммәбездән дә яхшырак белә иде. Аның үзе өстеннән дә югары органнарга шикаять арты шикаять яудырганнары беркем өчен дә сер түгел иде. Нишлисең бит, французлар әйтмешли – се ля ви! – һәркемгә дә ярап бетеп булмый.

Гариф абый үзе барча каләмдәшләренә – олысына-кечесенә тигез карарга тырыша иде. Талантлы әсәр дөнья күрүгә, үз шатлыгын йә матбугат битендә, йә авторның үзенә җиткерергә ашыкты ул. Иҗат потенциалы булган яшьләргә шартлар тулыру өчен теләсә нинди кабинетлар ишеген дә шакырга әзер иде. Гомумән, Гариф Ахунов рәислек иткән елларда Татарстан Язучылар берлеге шаулап-гөрләп торды. Мәскәү нәшриятлары татар авторларының әсәрләрен бик теләп тәрҗемә итәләр һәм бастырып чыгаралар, башка республикалардан һәм өлкәләрдән генә түгел, чит илләрдән дә иҗат әһелләре өзелеп тормый, әдәбият-сәнгать бәйрәмнәре, яшь шагыйрьләр фестивальләре, һәртөрле киңәшмә-семинарлар зур уңыш белән үтә иде. Гариф абый коллективны зур бурычларны хәл итүгә юнәлтә, берлектәге сәламәт көчләргә таяна белде. Аның иҗат эшләре буенча урынбасары Фәрваз Миңнуллин, яшь һәм чит өлкәләрдәге авторлар белән эшләү өчен җаваплы Илдар Юзеев, хуҗалык мәшәкатьләрен үз җилкәсенә алган Мөсәгыйт Хәбибуллин, әдәби фонд директоры Лирон Хәмидуллин, матур әдәбиятны пропагандалау бюросында, Тукай клубында, «Идел» альманахында, әдәби консультация бүлегендә эшләүчеләр ул елларда Гариф абыйның фикердәшләре дә, ышанычлы ярдәмчеләре дә булдылар. Берәр язучының юбилей тантанасы үтәме, секциядә нинди дә булса яңа әсәр тикшереләме, кемнеңдер китабы нәшриятка яки берәр автор язучылар берлеге әгъзалыгына тәкъдим ителәме – олы яисә бәләкәй бер генә вакыйга да игътибардан читтә калмый, һәркемгә җитәкчелекнең тәбриге, җылы котлау сүзе барып ирешә иде. Ераклардан килгән кунакларны аэропортларда каршылап, кунакханәләргә урнаштыру, ашату-эчертү якларын кайгырту, илкүләм зур чаралар үткәрелгәндә исә икешәр-өчәр көн буе кизү торулар, бәлкем, турыдан-туры безнең хезмәт вазифаларына кермәгәндер дә, ләкин бу эш... кирәк иде. Татар әдәбиятын пропагандалау өчен, башка тугандаш әдәбиятлар вәкилләре белән бәйләнешләрне ныгыту өчен кирәк иде. Гариф абый, эшлисе эшләре тавык чүпләп бетерә алмаслык булса да, әдәбиятыбыз офыкларын киңәйтү буенча һәр мөмкинлектән файдаланырга тырышты... Безгә, яшьләргә дә, ул һәрвакыт шул олы хакыйкатьне төшендерә килде.

Соңгы еллардагы илкүләм үзгәрешләрне Гариф абый шактый сагаеп каршылады. Зиһененә бала чактан коммунист әтисенең кулаклар тарафыннан үтерелүе тирән яра булып уелган, гомере буе бер иманга гына инанган кеше буларак, ул үз-үзенә хыянәт итә алмый иде. СССР таркалгач, кичәге карашларыннан ваз кичеп, үткәндәге һәрнәрсәне пычрата башлаган ялган коммунистларга ул җирәнеп карый иде. «Коръәндә монафыйклар дигән сүз бар бит, болар да нәкъ менә шундый икейөзле бәндәләр инде, Әхмәт дустым», – дигән иде ул бер үзара сөйләшү вакытында. Ә үзенең намусы керсез, фикерләре какшамаслык, инануы нык иде аның. Шуңа күрә дә гомеренең соңгы елларында иман алыштыруны кирәк санамады ул.

*Әхмәт Рәшит,*
шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

# Тургай-кебек-таңнан-торып

Каникул вакытларында Казанга экскурсиягә килгәнегез булса, Татарстан Язучылар берлегенә дә керәсез булыр, кадерле укучылар. Зур-зур тантаналар шаһиты булган Тукай клубында язучыларның чыгышларын да тыңлаганыгыз бардыр. Җәмәгать эшләре белән йөргән чагы яки иҗат командировкаларындагы вакыты туры килмәсә, андый кичәләрнең күбесендә Гариф абыегыз Ахуновны да очраткансыздыр. Ләкин Казан ерак, гадәттә берүзең генә теләсә кайчан барып йөреп булмый. Андый күңелле экскурсияләргә эләгү бәхете дә һәркемгә тими. Ә язучыларны күрәсе килү теләге кайсыбызда гына юк икән. Китапларын яратып укыйбыз бит, бигрәк тә калын китапларны, тиз генә аерылып булмый торганнарын. Геройлары белән дуслашып бетәбез, соңыннан да истән чыкмыйча, гел безнең белән яшиләр алар.

Гариф Ахунов исеме белән басылып чыккан уннарча роман һәм повестьларны, йөзләрчә хикәя, очерк, истәлек һәм мәкаләләрне дә яратып укыганыгыз, ә бәлки ул язган пьесаларны сәхнәләрдә уйнауларын күргәнегез һәм, һичшиксез, язучының «Хәзинә» романы буенча эшләнгән нәфис фильмны караганыгыз булгандыр. Менә шушы танылган прозаик һәм драматург, әдәби тәнкыйтьче һәм журналист, бик күп җәмәгать эшләре башкаручы каләмдәшебез турында сөйләп бирү җиңел түгел. Бер минуты да бушка әрәм үтмәгән гомерендә Гарифның башыннан сөенечле дә, нәфрәтле дә күп хәлләр узган. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз дигәндәй, ул иген игәргә дә, балта тотарга да, маляр булырга да, язучы булырга да өлгергән. Туган илебезнең аркылысын буйга йөреп, хәтта чит илләргә дә чыгып, күп кешеләр белән аралашкан. Шуларның барысын да җыеп, кыска гына әйтеп булырмы, иң кирәклесе торып калмасмы? Гариф минем замандашым, каләмдәшем, аның турында күп беләм, яхшы аңлыйм да кебек үзе. «Казан утлары» журналында ул баш редактор, ә мин җаваплы секретарь булып озак еллар бергә эшләдек. Әлмәт язучыларының җитәкчесе, Татарстан Язучылар союзы идарәсе секретаре һәм берничә елдан соң аның председателе булгач та, Гарифның бөтен эшчәнлеге безнең күз алдында узды.

Сез урта буйлы, хәрәкәтчән җиңел гәүдәле, агарып килә торган куе чәчле кешене күз алдына китерә аласыз. Бик мөлаем карашлы, ачык йөзле кеше ул. Фикерен төрлечә уйларга юл калдырмыйча, туры итеп әйтер, башына берәр уй төшсә, тик кенә тора алмыйча, уйларының артыннан җитешергә тырышкандай, бүлмә буйлап йөренә башлар.

Гарифның әсәрләрендәге геройлар да аның үзе кебек: сүлпәнлекне белмиләр. Ә хәрәкәт бар җирдә тормыш бар, көрәш бар, геройларның характерлары ярылып ята. Димәк, без яратып укый торган китап бар дигән сүз. Нефтьчеләрне һәм игенчеләрне, беренче бишьеллык батырларын һәм бүгенге көн яшьләрен сурәтләсә дә, илебезнең данлы тарихын яки хәзерге тормышны язса да, геройларын ул актив көрәшчеләр итеп бирә. «Чикләвек төше» повестендагы Халик Саматов һәм «Ардуан батыр» әсәрендәге Ардуан образларын хәтерлисездер әле. Чын мәгънәсендә без күрергә теләгән көрәшчеләр бит алар. Авырлыкларга бирелмиләр, дошманнарның астыртын янаулары да, эшләрендә вакыт-вакыт уңышсызлыкларга очраулары да үзләре сайлаган көрәшчеләр юлыннан яздырмый



аларны. Бу кешеләр, үзләренең рәхәте өчен яшәүдән бигрәк, кеше бәхете, илебезнең иминлеге өчен тырышалар. Һәм шушы сыйфатлары белән укучыга бик якын, кадерле булып күренәләр. Ир-егетнең шундый ук асыл сыйфатларын без «Идел кызы» романындагы шаукымлы Шәяхмәт, укытучы Шәрифҗан образларында да күрәбез. Коточкыч җәзалар да, хәтта үлем дә куркытмый аларны. Шәрифҗанның соңгы минутларында палачына әйткән сүзен генә искә төшерик.

– Бераү дә мине Совет властеннан баш тарттыра алмый!

Бу образны тудырганда, Гариф утызынчы елларда кулаклар тарафыннан үтерелгән әтисен күз алдында тоткандыр, әтисе Ахунҗанның иң матур сыйфатларын, аның уй-хыялларын, тормышка ашырылмый калган эшләрен үзенең геройлары аша укучыларына җиткерергә теләгәндер кебек.

Гариф Ахуновны олы язучы итеп ил күләменә таныткан беренче әсәр «Хәзинә» романы булды. Язучы озак еллар Әлмәт нефтьчеләре арасында яшәп, шул тормышның эчендә кайнап, өйрәнеп, тәмам белеп җиткергәннән соң язды аны. Тырыш хезмәт бушка китмәде, укучылар яратты әсәрне, Казанда да, Мәскәүдә дә басылып чыкты, аның буенча нәфис фильм төшерелде. Шушы романы өчен язучы республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты булды. Берсеннән-берсе уңышлы әсәрләре, эшкә һәрвакыт әзер торучы кешелеклелеге белән ул укучыларының олы ихтирамын һәм мәхәббәтен казанды. Г. Ахуновны республикабыз җәмәгатьчелеге СССР Верховный Советына ике тапкыр депутат, партиянең XXV, XXVI съездларына делегат итеп сайлады.

Арча районының бәләкәй генә татар авылыннан чыккан ятим малай танылган язучы, ил алдында торган зур эшләрне хәл итүдә катнашкан җәмәгать эшлеклесе булып җитеште. Ул ни хакында гына иҗат итмәсен, аның әсәрләре үз биографиясеннән, тормышның үзеннән алып язылган. Аңа тынгысызлык, ару-талуны белми торган тырышлык хас. Тургай кебек таңнан торып эшкә тотына ул. Әле сәгать биш кенә. Сабыйларның әле тәмле йокы вакыты, таң алды тынлыгы. Шул тынлыкта китаплар белән шыплап тутырылган кечкенә бүлмәдә өстәл лампасы кабына. Торып юынган, бер чынаяк куе кайнар чәй эчеп алган язучы ак кәгазь каршына килеп утыра.

*Ләбибә Ихсанова,*
язучы, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре

# Мул-җимешле-иҗат

Дөньяда шундый кешеләр була – үзләренең гүзәл образы, якты хатирәсе белән алар һаман да башкаларның күңелен яктыртып яши кебек, ә инде алар белән бергә яшьнәп, якыннан аралашып, йөрәк җылысын тойганнарына исә моны һич тә оныту мөмкин түгел. Гариф Ахунов нәкъ менә шундый шәхес иде. Халык – аны, ә ул – үзенең туган халкын чын күңелдән яраткан, аның теле, мәдәнияте, мәгърифәте, гореф-гадәтләре, рухи мирасы өчен янып яшәгән Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм Г. Исхакый исемендәге әдәбият премияләре лауреаты, Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар дуслыгы орденнары иясе, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре. Халык тарафыннан яратып укыла торган 5 роман, 16 повесть, 1400 ләп тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләр авторы, ялкынлы публицист һәм мәшһүр җәмәгать эшлеклесе. Ул СССР Югары Советына ике тапкыр халык депутаты булып сайланды. Ун елдан артык Татарстан Республикасының Язучылар берлеге рәисе, СССР һәм РСФСР Язучылар оешмасы сәркатибе булды. Гариф Ахунов, кайда гына эшләсә дә, татар әдәбиятын үстерү, аны яңа биеклекләргә күтәрү теләге белән ялкынланып янып яшәде.

Г. Ахунов – XX гасыр тудырган үзенчәлекле шәхесләрнең берсе, ә кеше, үз чорының, әйләнә-тирә мохитнең җимеше, диләр. Чын иҗат үзен чор тудырган каршылыклар бердәмлегендә раслый. Дәүләт күләмендә югары дәрәҗәләр билгәндә дә, Г. Ахунов үз алдында да, башкалар каршында да һәрвакыт намуслы булып кала алды.

Үзе исән вакытта ук милли әдәбиятыбызның бай тарихында мәшһүр урын алган талантлы әдип, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең барысын да үз иткән, алар турында эчкерсез кайгыртып яшәгән, әдәбият дөньясында күпләргә ихлас күңелдән зур ярдәм күрсәткән, яшь язучыларның шактыен кулларыннан җитәкләп әдәби-иҗат мәйданына алып кергән бу киң күңелле, олы йөрәкле, көләч йөзле, шаян күзле, җор күңелле һәм бер үк вакытта гадилек һәм бөеклеккә ия шәхес турындагы истәлекләрем яшьлек хатирәләренә барып тоташа. Гариф Ахунов белән без Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында бер елларда укыдык, дус булып яшәдек. Әдәбият дигән сихри дөньяга Гариф шаулап-гөрләп үткән студентлык елларыннан соң, без укыган факультетны тасвирлап язган «Яшьлек яме» исемле повесте белән яшь чабышкы ат сыман ыргылып килеп керде. Аның бу әсәренә мин республика газетасында бик уңай бәяләмә язган идем. Гариф аңа бик рәхмәтле булды, әле мәшһүр язучы булып танылгач та еш искә төшерә иде. Шуннан башлап иҗат чоры бергә үтте. Яшь язучы әдәби иҗат үсешендәге «Юллар чатында» тукталып калмады, армый-талмый һаман алга, югарыга таба үрләде, татар укучыларына берсеннән-берсе матур романнар, повесть һәм хикәяләр, драма әсәрләре бүләк итеп, милли әдәбиятны гүзәл иҗат җимешләре белән баетты. Бөек якташлары – татарның тарихи шәхесләре Г. Курсави белән Ш. Мәрҗани, Г. Тукай һәм Г. Камалның әдәби-мәдәни традицияләрен уңышлы дәвам иттереп, өлкән һәм аннан соңгы буын каләм осталары Г. Бәширов, М. Мәһдиев һәм башка язучылар белән бергә XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты үсешенә зур өлеш кертте.



Татарстанда Чуваш республикасы көннәре. Сулдан икенче Мансур Хәсәнов, алтынчы Дания Дәүләтшина, Гариф Ахунов. Казан. 1986, май

Гариф Ахуновның олы талант, иҗат куәте һәм әдәби осталык белән сугыралган тылсымлы каләменнән 55 китап дөнья күрде, аларның күбесе 15 телдә нәшер ителде. Бу – сирәк шәхесләргә генә насыйп була торган бәхет, табигый талант һәм тырыш иҗат хезмәтенең тыгыз үрелүенең гүзәл нәтиҗәсе иде.

Әдипнең иҗат учагында янган утлары яктысында туган фәлсәфи һәм эстетик уйланулары тәнкыйть мәкаләләренә күчте, аның әдәби әсәрләре белән бергә, алар да ерак илләрдә, төрле җирләрдә таралып-сибелеп яшәгән милләттәшләребезнең күңелендә тирән яңгыраш тапты.

Халкыбызның дөнья әдәбиятына органик кушыла баруында да Г. Ахуновның хезмәте бәяләп бетергесез. Р. Тагор, М. Шолохов әсәрләренең татар укучысына барып ирешүе, А. Островский һәм Н. Погодин пьесаларының татар сәхнәсенә менүе дә аның тәрҗемәләре аша башкарылды. Шул ук вакытта Г. Ахуновның күп еллар дәвамында рус язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итү өстендә эшләве аның үзе өчен дә зур остаханә ролен үтәвен әйтергә кирәк.

Г. Ахуновның иҗаты идея-тематик яктан да, сурәтләү алымнары белән дә, язу осталыгы җәһәтеннән дә гаять бай, тирән һәм күпкырлы. Язучы, беренче карашка гадәти булган тирә-юньдәге тормыш күренешләренә өр-яңа яктан караш ташлап, һич көтелмәгән проблемалар күтәрә, мөһим нәтиҗәләр ясый һәм образлы, халыкчан тел, үзенчәлекле стиль, әдәби алымнар белән тасвирлый белә. Ул үзе яшәгән чор, замандашлары турында бай әдәби мирас калдырды. Киләчәк буын укучылар аның әсәрләре аша без яшәгән дәвернең бөтен катлаулылыгын, әчке каршылыкларын танып белер, серләренә төшенергә тырышыр, фикер йөртер. Әдип, тормышның төп байлыгы булган хезмәт, иҗат кешеләренең образларында заман билгеләрен калку сурәтләп, Татарстан һәм та-



Г. Тукай туган көне, Казанда шигърият бәйрәме

тар халкының язмышы өчен бик актуаль, шул ук вакытта гомумкешелек өчен мөһим проблемалар күтәрде. Бу гүзәл әсәрләр театр сәхнәләренә күчте, нәфис фильм һәм спектакльләр булып экраннарга чыкты.

Г. Ахуновның үзе өчен дә, аның иҗаты өчен дә хезмәт кешеләре, аларның күңел дөньясы, ил, туган җир язмышыннан аерылгысыз хәзинә булса, халык өчен, татар дөньясы өчен аның тормышы, иҗаты үзе – олы хәзинә.

Гариф алты яшендә ятим кала. Аның әтисе 30 нчы елларда Сталин диктатурасы, большевиклар хакимияте тарафыннан авыл халкына көчләп тагылган сыйнфый көрәшнең корбаны була. Дүрт бала ялгыз ана кулында кала. Авыр балачагы турында Гарифның күңелендә төрле-төрле уйлар, фикерләр, хисләр һәм тәэсирләр кайный. Алар хакында кешеләргә сөйлисе килә: ул, башлангыч класста укыганда ук, шигырьләр, хикәяләр яза башлый. 7 нче класстан соң Арча педагогия училищесында уку еллары. Гарифның нәфис сәнгатькә сәләте балачактан ук ачыла, ә инде үсмер елларында ук, акварель рәсемнәр, плакатлар язып, гаиләгә матди ярдәм күрсәтә башлый.

Булачак язучының балачагы, үсмер еллары ил, халык язмышының авыр чорына туры килсә дә, Арча ягының Өчиле авылы тирәсендәге гүзәл табигать аның күңеленә үзенең тылсымлы көчен иңдергән булырга тиеш. Артык биек тә булмаган серле таулары, Г. Тукай сокланып һәм җырлап туя алмаган кара урманнары, матур аланнары, күкрәп үскән иген кырлары, салам, такта түбәле пөхтә йортлары, яшел чирәмле урамнары белән үзенчәлекле татар авылларына бай Казан арты төбәге – милли мәдәниятебезгә Г. Бәширов, С. Хәким, М. Мәһдиев һәм башка зыялы, олуг шәхесләрне биргән җир. Алар сулаган һаваны сулап, шул ук көмеш чишмәләрнең челтерәвен тыңлап, җиләкле тау итәкләрендә күктә уйнаган тургайларны күзәтә-күзәтә тәэсирләнеп, киләчәккә хыяллар кору, серле урман авазлары, тал тирәкле Казансу буйларында кошлар сайравы, һичшиксез, малай вакыттан ук Гарифның күңелендә нечкәлек, шәфкатьлелек, гүзәллек, камиллеккә омтылыш уяткандыр.

Сугыш елларында Гариф бригадир, клуб мөдире булып эшли; сугыш беткәч, училищены, ә 1952 елда университетны тәмамлый. Студент елларында ук аны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы баш мөхәррире Гази Кашшаф эшкә чакыра. 6 ел буе Гариф очерк, хикәя, повестьлар редакцияли. Бу елларны «язучы булырга өйрәнү вакыты» дип атавы белән ул бик хаклы иде. Ул үзен чын язучы итеп таныткан әсәрләрен Әлмәттә яшәгәндә, Татарстан Язучылар оешмасының Әлмәт бүлеген җитәкләгән елларда иҗат итте. Монда ул гаиләсе белән ун ел яшәде. Нефтьчеләр тормышы Гарифның тынгысыз, дәртле табигатенә, күңеленә бик тәңгәл килә иде. Ул батыр, кыю, булдыклы

хезмәт кешеләрендә үз әсәрләренә лаеклы персонажлар таба, илһамланып яза да яза. Әлмәттә аның 10 китабы туды.

1962 елда КПССның Татарстан өлкә комитетының мәдәният бүлеге мөдире булып эшләгәндә, миңа Уфага Башкортстан язучыларының съездына Татарстан язучылары делегациясе җитәкчесе булып барырга туры килде. Делегация составында мәшһүр шагыйрь Х. Туфан, шагыйрь Г. Хуҗиев, әдипләрдән Риза Ишморат, Рәисә Ишморатовалар бар иде. Делегациягә мин шулай ук Әлмәт язучылары җитәкчесе Гариф Ахуновны да алырга кирәк дип санадым.

Ул чакта Башкортстанда үткән тыгыз программадан торган бер атна – татар-башкорт әдәби мөнәсәбәтләре хакында мосахәбәләр, фикер алышулар, бәхәсләр, укучылар белән очрашулар, Башкортстан язучыларыннан Сәйфи Кудаш, Наҗар Нәҗми, Мостай Кәрим, Муса Гали һ.б. талантлы шәхесләрнең өйләрендәге кунак мәҗлесләрендә катнашулар Гариф Ахуновны тагын да ныграк аңларга, аның язучы буларак кына түгел, әдәби хәрәкәтнең эчендә кайнаучы, оештыручы буларак та сәләтен күзалларга ярдәм итте. Ә моның, билгеле, язучының киләчәктә оештыручы, җитәкче, җәмәгать эшлеклесе буларак үсешенә тәэсире булмый калмады.

1963 елда Г. Ахуновның «Хәзинә» романы дөнья күрде. Ул үзенең әсәрен кара алтын – нефтьне күздә тотып кына «Хәзинә» дип атамады. Аның өчен төп хәзинә кешеләр, нефть чыгаручылар иде. Свердловск шәһәре киностудиясе 1977 елда Татарстан нефтьчеләре турындагы бу роман буенча фильм төшерде.


1968 елда Гариф Ахунов Әлмәттән яңадан Казанга әйләнеп кайтты. Ул башта Татарстан Язучылар берлегенең сәркатибе, аннары – 1971–1974 елларда – «Казан утлары» журналының баш редакторы булды, ә 1974 елдан 1984 елга кадәр Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып эшләде.

Бу еллар Г. Ахуновның язучы буларак өлгереп җиткән, иҗатының чәчәк аткан чоры иде. Нәкъ шушы чорда язылган «Чикләвек төше» повесте һәм элегрәк иҗат ителгән «Хәзинә» романы өчен әдипкә 1973 елда республиканың әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге югары бүләге – Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Язучы иҗатының иң югары ноктасы булган, бай эчтәлекле, тирән мәгънәле, XX гасыр башындагы катлаулы һәм каршылыклы социаль вакыйгаларны колачлап язуы ягыннан киң панорамалы, зур күләмле «Идел кызы» эпопеясы да нәкъ шушы чорга карый.

Ике китаптан торган бу романның төп геройларының язмышы, илебез тарихында тирән эз калдырган драматик, трагик хәлләрне Г. Ахунов искиткеч осталык белән тасвирлый. Шулай ук әдипнең 1998 елда басылып чыккан, республикабызда танылган шәхес Тимерхан Борһановка багышланган повестен да билгеләп үтәргә кирәк.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып эшләгәндә, Г. Ахуновның оештыру, җитәкчелек, кешеләр белән эшләү сәләте тагын да киңрәк ачылды. Ул республикада әдәбимәдәни тормышны оештыручыларның, әйдәп баручыларның иң активы иде дисәм, һич тә арттыру булмас. Ул елларда мин, республика җитәкчеләренең берсе буларак, фән, мәгариф, мәдәният, сәнгать өлкәләрен, сәламәтлек саклау һәм социаль мәсьәләләрне алып бара идем. Миңа, Тукай-Кырлай мемориаль музеен төзегән, бу эш белән даими җитәкчелек иткән чакта, Арча якларына, Тукай-Кырлайга күп йөрергә туры килде. Еш кына минем белән бергә Гариф дус та бара иде. Машинада без аның белән тормыш хакында, әдәбият-мәдәният мәсьәләләре турында әңгәмәләр кора идек. Кайвакытта безгә Бакый ага Урманче да кушыла иде. Әйе, ул еллар... Алга куйган максатларга ирешү юлында дәртләнеп, илһамланып эшләгән еллар...



Гариф Ахунов бакчада. 1995

Ниһаять, Г. Ахуновның кайбер шәхси сыйфатлары хакында.

Ул, табигать тарафыннан бирелгән, әти-әнисеннән бүләк ителгән талант иясе булу өстенә, чын татарларга хас тыйнак, гаять эшлекле, ярдәмчел табигатьле шәхес иде. Кайбер кешеләргә хас булган, бигрәк тә соңгы елларда нык ачылып киткән мин-минлек, көнчелек һәм хөсетлек, башкаларның намуслы исемен таптап өстенлеккә чыгу, югарыга таба үрләү, хәзерге тәгъбир белән әйткәндә, амбициозлык аңа бөтенләй ят нәрсә иде.

Гариф иҗатта да, җәмәгать эшчәнлегендә дә, гаилә тормышында да үзен бәхетле кеше итеп санады. Моның сере, бер сәбәбе, әлбәттә, тормыш иптәше Шәһидә ханым кулында иде дип саныйм.

Шәһидә Максудова, минем белүемчә, затлы, тәрбияле гаиләдән чыккан кыз. Ул Казан университетының тарих-филология факультетында Гариф белән бер курста, Г. Тукай исемендәге стипендияне алып укыды. Ә университетны тәмамлагач, иҗат эше белән шөгыльләнде, бер дигән тәрҗемәләр эшләде. Гариф белән бергә алар, тату гаилә корып, 49 ел буе матур гомер кичерделәр, бик талантлы Рәшит исемле егет һәм Наилә исемле кыз үстерделәр, өч оныгы белән куанып яшәделәр. Олуг әдип, талантлы язучының сүнмәс иҗат ялкыны чәчкән очкыннар аның гомер юлдашы Шәһидә ханымга да, балалары һәм оныкларына да төшкәндер, күрәсең.

Әдәбият һәм сәнгатькә гашыйк, туган халкына хезмәт итү максаты белән яшәгән бу гаилә өчен һәрвакыт иҗади очыш халәтендә булу – аларның яшәү рәвеше иде.

*Мансур Хәсәнов,*
әдәбият галиме, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе

# Кадерлеләр-генә-хәтердә

Кеше хәтерен хаклый белгәннәр кадерле була, дип әйтсәм, дөрес булыр. Гариф Ахунов минем өчен гаять тә кадерле кеше иде. Нәкъ менә кеше хакын хаклый, кеше кадерен белгәне өчен хәтердә ул минем. Кем-кем турында, әмма Гариф абый турында истәлекләр дә, әйтер сүзләр дә, онытылмас хатирәләр дә бетәсе түгел.

Иң беренче очрашуым моннан утыз еллар элек булды. Мин ул вакытта Татарстан Язучылар берлеге каршындагы матур әдәбиятны пропагандалау бюросында эшли идем. Пропагандалау булгач, язучылардан иҗат төркемнәре төзеп, районнарга, халык белән очрашуларга чыга торган идек. Башта ул Әлмәттән килеп йөрде. Аннары, «Казан утлары»нда эшли башлагач, язучылар партоешмасының секретаре итеп тә сайладылар аны. Иҗат төркемнәре белән йөреп кайтканнан соң, мин, Гариф абый янына кереп, авыл халкының тормышы, язучыларның хәле хакында сөйләшеп утыра торган идем.

Шушы сөйләшеп утырулар, очрашулар бервакытны бигрәк тә эшлекле төс алды. Гариф Ахуновның нефтьчеләр тормышыннан алып язылган «Хәзинә», «Хуҗалар» романнарын халык ярата. Мин бераздан Күчмә театр директоры булып күчтем. Сөйләшеп утыруларның берсендә мин Гариф Ахуновка аның «Хәзинә» романы буенча спектакль куяр өчен сценарий язарга теләгем барлыгын әйттем. «Әй, энем, «каты чикләвек» булып чыкты ул «Хәзинә». Романы шәбен шәп тә бит, сценарий өчен баш бирми әле ул. Юмагулов та язып карады (ул елларда Г. Камал исемендәге театрда, Башкортстаннан килеп ирле-хатынлы Юмагуловлар эшләп киткән иде). Аяз дустым да алынып карады (Аяз Гыйләҗевне ул Аяз дустым дип йөртә торган иде). Ошатмадым мин бу сценарийларны», – диде ул. Мин алай да сценарийны үзем аңлаганча эшләдем дә, Гариф абыйга күрсәттем. Бик игътибар белән укып чыкты. Аннары болай диде: «Бу бит бик зур әсәр. Син шуның умыртка сөяген тапкансың. Барлык эшче каһарманнарны бер учак тирәсенә, чишмә буена җыйгансың. Чишмәсе – «Туй күлмәге» җыры».

Мин «Хәзинә» романы буенча сценарийны өч вариантта язып карадым. Язган бер вариантны Гариф абыйга күрсәтеп барам. Ул аларны иплəп кенә, үз алдына сыза-боза төзәтә. Мин, яртылаш кыскартылган язмаларны алып китеп, тагын эшлим. «Булды бу, Мансур!» дигәнче эшләдем. «Кошның да үз оясы була» дигән исем белән спектакль премьерасы уйналды. Күчмә театрның үз бинасы юк иде бит әле. Әлеге спектакль премьерасы өчен Г. Камал театры бинасын алуга ирештем. Гариф абыйның беренче рәттә дулкынланып, сөенеп, Мөнәвәрә – Ләлә Миңнуллина уенын ятатып карап утыруларын хәтерлим әле. Аннары әлеге спектакльне Свердловскида уздырылган конкурска да алып бардык. «Сәхнәдә эшчеләр темасы» дигән конкурс иде ул. Диплом алып кайттык.

Гариф Ахуновка үзенең чәчмә әсәрен җанландырып сәхнәдә күрү кызыклы иде, артистлар белән аралашу кызык иде. Аның җор тел белән, мәгънәле итеп сөйләшүе, шаяртулары артистларның күңелен күтәрә иде. Гариф Ахунов өчен бернинди вак-төяк булмый торган иде. Әйтик, «Кошның да үз оясы була» дигән спектакльдәге «Туй күлмәге» җырының көен яздыру белән дә ул бик кызыксынып торды. Аның киңәше белән җырчы, композитор Мәсгут Имашевтан яздырттык. Әлеге пьесаны ул соңыннан улы Рәшиттән урысчага да тәрҗемә иттерде әле.

Дөнья булгач, кеше дигәнең төрле хәлләргә дучар була. Тәкъдир минем белән дә усал уен уйнады. Елдан артык суд тикшерүләре барды. Миңа карата 29 томлык эш ачылды. Шактый гына гаепләүләр тупланган иде анда. Ниһаять суд. Шушы судка мин җитәкләгән сиксән кешелек коллективтан килеп гадел сүз әйтүче, дөреслекнең күзенә караучы табылмады. Бердәнбер Гариф абый – республикабызның гына түгел, ул вакыттагы Советлар Союзының абруйлы кешесе – юк вакытын бар итеп, судка килде. Гариф Ахунов ул вакытта төрле бүләкләр иясе, СССР Югары Советы депутаты, Язучылар берлеге рәисе иде. Гариф абыйны күргәч, судья аңа сорау бирде:

– Сез кем буласыз?

– Язучы Гариф Ахунов мин.

– Андый язучыны белмим.

– Язучы Гариф Ахуновны да белмәгәч, энем (судьяга ул энем дип эндәште), син нишләп судья булып торасың да, татарның Мансур Шиһапов кебек булдыклы улларына хөкем чыгарып утырасың?

Шунда суд башланды. Театрдан килгән бер егет белән кыз, «Кошның да үз оясы була» дигән спектакльнең сценариен без яздык, дип баралар. Шунда Гариф абый дипломатыннан сценарийның мин язган, үзе сызгалап-бозгалап бетергән вариантларын тартып чыгарды да: «Менә моны күрәсезме? Без бу сценарийны Мансур Шиһапов белән икәү яздык. Хәрефләре очып-очып киткән язу Шиһаповныкы булыр», – диде. Судья: «Минем янга ике метрдан якынрак килергә ярамый, чигенегез», – ди. Гариф абый исә үзенекен куәтли: «Энем, син еразтан укый алмыйсың, шуңа күрә якын килдем», – ди. Судья текстны алмакчы була, Гариф абый исә: «Энем, мин бу язуларны әле Мәскәүгә дә алып барам», – дип, кулындагы кәгазьләрне киредән дипломатына салып куя. Шул арада миңа да дәрт өстәргә ара таба. Янәсе, кайгырма, бер сине генә түгел, Шолоховны да плагиатлыкта гаепләп маташканнар.

Судта ул әле тагын ике сәгатькә якын сөйләде. Аның бөтен сөйләгәненнән әнә шул мине Шолохов белән тиңләве хәтеремдә уелып калган. Ул миңа яшәү дәрте өстәде. Аннары Гариф Ахунов минем хәлне белергә дә гел килеп йөрде. Бер ул гына түгел, Мөхәммәт Мәһдиев тә, артистлар Равил Шәрәфиев, Вафирә Гыйззәтуллина, Габдулла Рәхимкулов, Сафьян Ибраһимов та киләләр иде. Очрашуга рәсми рөхсәт алу өчен, бу килүләрне тоткыннарга мәдәни хезмәт күрсәтү итеп рәсмиләштерә торганнар иде. Тоткыннар Гариф абыйны гаять тә яраттылар. Чөнки ул алар белән иң беренче очрашуда ук сүзне: «Сезгә «иптәшләр» дияргә ярамый, диделәр миңа. Ләкин мин сезгә барыбер «иптәшләр» дип әйтермен, иптәш булмый сез кем буласыз ди тагын?» – дип башлады.

Гомер булгач, уникe елны дүрт елда тутырып, мин дә кайттым. Кайтуга ук төрле яктан әйбәт-әйбәт эш урыннары тәкъдим итә башладылар. Шиһапов булдыра ул дигән исемем, яхшы даным эшлекле даирәләрдә таралып өлгергән, күрәсең. Монда да Гариф Ахуновның кулы уйнамады микән? Гариф абый тәкъдиме белән мине Язучылар берлеге рәисе урынбасары итеп эшкә алдылар. Шул сәбәпле Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев белән бәйләнешләрем тагын да ныгыды, теге еллардагы кебек итеп, халык арасына чыгып, очрашулар үткәрүләрне кабаттан тергезеп җибәрдек. Шундый очрашуларның берсе Балык Бистәсе районының Балыклы Чүкәй авылында булган иде. Шунда баргач, Гариф абыйның, өйдән өйгә кереп, минем якташларымның аш-суны тәмле әзерләүләренә, чисталык-пөхтәлек яратуларына сокланып йөргәнен хәтерлим. 1995 елның маенда туган авылым Яншыкка да бергә кайттык әле без. Клубта җыелган халыкның мине алкышлавына сөенеп, ул болай дигән иде: «Менә шулай, Мансур энем, «Чит илдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул» дигән мәкаль бар. Күрәмсең, син үз илеңдә дә солтан». Аннары авылның мәчетенә кереп чыктык, чишмә буена төштек. Сиреньнәр чәчәк аткан вакыт иде. «Синең җырларың шушы чишмә буенда язылгандыр инде, җыр чишмәсенең серләрен син менә шушында ачкансыңдыр», – дип, һәр нәрсәгә сокланып, хозурланып йөргән иде.



Журналист Марина Сажина Гариф Ахуновтан интервью ала. 1995

Аннары сентябрь аенда республика халкы Гариф Ахуновның 70 яшьлеген зурлап бәйрәм итте. Үз бәйрәмен бөтен кеше өчен дә күңелле итә белә торган иде ул. Г. Камал исемендәге академия театрында аны зурларга җыелган халыкның һәрберсенә ул үз исеме язылган ручкалар, блокнотлар тараткан иде. Туган авылы Өчилегә кайтып, Шәһидә апа белән парлашып җигүле атка утырып әйләнгәннәр иде. Болар хәзер бөтенесе хатирә генә булып калды.

Истәлекләр китабына кертеп калдырасым килгән тагын бер нәни генә деталь бар. Әйткәнемчә, язучылар белән сәфәрләрдән урап кайта торган идек. Андый сәфәрләрдә кайбер язучыларның, дипломатларын кулыма тоттырып: «Бар әле, Мансур, шушыны тутырып алып чык әле», – ди торган гадәтләре бар иде. Гариф Ахунов беркайчан да, берни дә кыстырып кайтырга яратмады. Кайтышлый машинаны берәр гастроном янында туктатырга сорый торган иде. «Шәһидә апаң белән сөйләшеп утырырлык берәр күчтәнәч алып чыгыйк әле», – дигән булыр иде. Шәһидә апаны исә ул аерым бер хөрмәтләү белән хөрмәтләде, аерым бер ярату белән яратты. Сәфәргә чыгып киткәндә дә, кузгалган машина тәрәзәсеннән башын тыгып, уенын-чынын бергә кушып: «Шәһидә апагызга сәлам әйтегез, яме», – ди торган иде. Берәр киңәш сорасаң да: «Ярар, иртәгә мин моны Шәһидә апаң белән киңәшләшеп эшләрмен», – булыр иде җавабы. Юк, бу сүзләр ул үзе мөстәкыйль карар кабул итә алмаганнан яисә башында нинди дә булса конкрет фикер булмаганнан түгел, бәлки хәләленең безнең алда абруен күтәрәсе килүдән иде. Бу җәһәттән дә ул безгә үрнәк булды.

*Мансур Шиһапов,*
шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

# Җор-телле-әдип

Гариф абый җор телле, ачык күңелле, шаян кеше иде. Сүземне дәлилләп, әдәби мохиткә киң мәгълүм булган бер мәзәкне искә төшерим әле.

Вакыйга СССР заманында Уфада булган булса кирәк. Дусты Гариф Ахуновны янәшә утыртып, Мостай Кәримнең затлы «Волга»да шәһәр буйлап җилдерүе икән. Менә берзаман боларны гаишник туктаткан да йөртүчедән документын сораган, имеш. Мостай Кәримнең (шулай ук Гариф абыйның да) СССР депутаты булган чагы, ул шуны раслаучы таныклыгын түш кесәсеннән каударланмыйча гына тартып чыгарган да аклы-каралы тәпәч иясенә сузган. Гаишник, таныклыкка күз төшерүгә, үрә катып честь биргән һәм «шофёр» янында утырган Гариф абыйга сез кем буласыз инде, дигән сораулы карашын төшереп алган. Гариф Ахунов аңа болай дип сүз каткан, имеш:

– Если у меня шофёр депутат Верховного Совета СССР, то тогда кем буду я?

Гариф Ахуновнын холкын ача, характерын билгели һәм тапкырлыгын күрсәтә торган мәзәк-хатирәләр бихисап. Шуларга ике мисал. Аларны «Татар теле» дигән атаклы шигырь авторы, гомумән, татар-башкорт дөньясында киң билгеле шәхес, күренекле шагыйрь Наҗар Нәҗми кәгазьгә теркәп калдырган. Беренче истәлеккә тукталыйк:

«*Хәсән ага Туфанның 70 яшьлек юбилее* (димәк, 1970 ел була инде. – *Л.Л.*). *Котлаулар беткәч, аңа сүз бирделәр. Юбиляр трибуна артына басты да сүз башлады:*

*– Кадерле татарларым!..*

*Зал гөж килеп кул чапты. Моның сәбәбен аңламый калган, президиумда утырган КПСС өлкә комитеты секретаре Мөҗәһит Вәлиев рәислек итүче Гариф Ахуновтан:*

*– Что? Что он сказал? – дип сорады. Ахунов шунда ук җавап бирде:*

*– Кадерле батырларым! – диде.*

*Татарча бик үк шәп белмәгән М. Вәлиев тынычланды булса кирәк*».

Наҗар аганың икенче хатирәсе мондыйрак:

«*Мәҗит Гафуриның йөз еллыгы. Шул көннәрдә генә Мәскәүдән миңа «Ветеран 2-ТА» («ТА» – танк армиясе) дигән медаль җибәргәннәр иде һәм мин шуны тагып алган идем.*

*Агыйдел буенда оештырылган табын башланыр алдыннан кул чайкап торган бер урыс язучысы: «Что за медаль? Что это значит «ТА»? – дип сорады миннән. Янәшә торган Гариф Ахунов шунда ук җавап бирде:*

*– «ТА» – «Татарская армия», – диде*».

Гариф абый белән чын-чынлап танышуым 1984 елның август башында, Маркиз утравында булды. Гариф Ахуновның, Язучылар берлеге рәисе кәнәфиен калдырып, рәислек эшен Туфан Миңнуллинга тапшыруына ике айдан аз гына артык вакыт узган чак иде шикелле. Маркиз утравына безне – утызга якын кешене, ягъни Сибгат Хәким белән Гариф Ахуновны, Эльс Гадел, Рәшит Имаш, Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Рашат Низами, Җәүдәт Миңнуллин, Алмаз Хәмзин, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Айрат Садыйк һәм мин бахырыгызны, янә биш-алты туган-тумачаны, яхта яллап, минем туган көн хөрмәтенә бер җилләнеп кайтыйк әле, дип, Равил Фәйзуллин алып барган иде. Ике язучы очрашса – шундук гәпләшергә тотына, өч язучы җыйналса – мәҗ-

лес башлана дигәндәй... Утызлап каләм әһеле һәм сәнгатькәрне туплаган утрауны, кем әйтмешли, шуннан соң күз алдына китереп карагыз инде. Учак тергезгән, казан аскан, балык чистарткан, бәрәңге-мазар әрчегән арада, утраудан кемдер – төпсез кәнәфи, арадан кайсыбыздыр тимер «А» хәрефе (җиде-сигез килограммлап булгандыр) табып алды. Шуннан соң и китте, и китте көлеш, үзара үртәшү... Шаяртырга, бер-берсен чеметкәләп алырга, үртәргә язучы халкына куш инде син... Бу юлы тө‍рттерү, дусларча үртәү «объект»ы Гариф абый Ахунов булды. Олысы-кечесе дигәндәй, Гариф абыйның рәислектән «котылуы»на ишарә ясарга омтылды: имеш, күрегез, Гариф абыйның бүгеннән кәнәфие – шушы төпсез утыргыч булыр, имеш, Гариф Ахуновның утрауга киләсен әллә кайчан ук белеп, кемнәрдер тимер «А» хәрефен (Ахуновка – ым!) махсус калдырган, имеш, һ. б., һ. б... Дача өчен шәп нәрсә бу, өстенә такта кисәге куеп, ял итеп утырырсың, дип – төпсез кәнәфине, монда Ахунов яши дигәнне аңлатып, ерактан ук күренеп торыр, мә, капка өстенә беркетерсең, дип, тимер «А»ны Гариф абыйга тоттырдык...

Без бөтен утрауны яңгыратып, бар дөньяны дер селкетер чиккәчә җиткереп күпме генә хахылдасак-хихылдасак та, арабызда рәхәтләнеп, башын артка чөеп, тәмләп көлүче кеше, ахыр чиктә, барыбер Гариф абый үзе булып чыкты. Күп каләмдәшләребездән аермалы буларак, юморны аңлаучы, аны бар вөҗүде белән кабул итә алучы шәхес иде шул ул.

1997 елда (аен-көнен хәтерләмим) Гариф абыйның кызы Наилә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булды. Ахырдан китапханә бүлмәсендә күркәм генә мәҗлес оештырылды. Анда Гариф абый үзе, хатыны Шәһидә апа, кияүләре Борис Вайнер һәм, әлбәттә, кызлары Наилә дә бар иде. Наиләне котлау башланды, аңа, Гариф абыйга бәйле матур-матур тостлар әйтелде. Менә бер мәлне сүз дилбегәсен әдәби фондның ул чактагы директоры Данил Салих үз кулына алды:

– Иптәшләр! – диде ул. – Монда җыйналган кадерле кунаклар! – диде. – Хөрмәтле Гариф ага! – диде. – Мин – литфондта яңа кеше. Әле менә шушы көннәрдә генә зиратка кабер ташлары кайтарттым. Эш бара, әйе... Мактанып әйтүем түгел... Вафат булган язучыларыбызны онытмыйбыз, әйе...

Данилның сүз сөреше дөрес юлдан китмәгәнен ишетеп торган мәҗлес халкы дәррәү көләргә тотынды. Мәҗлестәгеләрнең нигә көлгәннәрен башта аңышмыйча торган Данил, Наиләне котлыйсы урынга ятышсызрак сүзләр ычкындыруын шундук аңлап, үзе дә көлү мәрәкәсенә кушылды. Гариф абыйның исә шулхәтле көлүдән күзләреннән яшьләр бәреп чыкты хәтта:

– Маладис, энем! Күптән болай көлгәнем юк иде, – дип, Данилның кулын кысты ул...

Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш әсәрләре белән беррәттән, Гомәр Бәшировның «Сиваш» белән «Намус»ын, Әмирхан Еникинең «Исәнме, иптәшләр!» белән «Рәшә»сен, Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар»ын, Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»ен, Мирсәй Әмирнең «Агыйдел»ен, Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап» белән «Муса»сын, Нәби Дәүлинең «Җимерелгән бастион» белән «Яшәү белән үлем арасында»сын, Фатих Хөснинең «Йөзек кашы»н, Атилла Расихның «Ике буйдак» белән «Бәхет орлыклары»н, Рафаил Төхвәтуллинның «Авылдашым Нәби»ен, Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»ен, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары»н, Нурихан Фәттахның «Сез кемнәр?» белән «Сызгыра торган уклар»ын, Шамил Бикчуринның «Каты токым»ын, Барлас Камаловның «Сарсаз кызы Сәрия»сен, Газиз Мөхәммәтшинның «Йөрәктәге эзләр»ен, Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы»н, Вакыйф Нуруллинның «Шинельсез солдатлар»ын, Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала»сын, шулай ук Нәкый Исәнбәт, Адлер Ти-

мергалин, Габделхәй Сабитов, Миргазиян Юныс («Занзибар зәңгәр болытлар артында»), Әхсән Баян, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мәхмүт Хәсәнов, Фаил Шәфигуллин әсәрләрен һәм, әлбәттә, Гариф Ахуновның «Хәзинә»се белән «Идел кызы»н укып үскән буын без. Гариф ага, барыннан да бигрәк, «Идел кызы» романы белән дан казанды. Аның бу әсәре әдәби хәзинәбездә чын мәгънәсендә үзенең лаеклы урынын тапты.

Мин автобиографик әсәрләр укырга яратам. Заманында (1978 елда) Гариф Ахуновның «Без бит Арча яклары» дигән китабыннан күңелем бик хуш булган иде. Гариф абыйның күп еллар дәвамында көндәлек алып барганлыгы күпләргә мәгълүм. Көндәлекнең бер өлеше узган гасырның туксанынчы елларында «Идел» журналында басылды шикелле. Әдипнең ул көндәлек дәфтәрләре дә берәр вакыт аерым басма китап булып дөнья күрер әле, дип ышанам.

Миңа берничә мәртәбә Гариф абыйларның Новаторлар урамындагы фатирында кунакта булырга туры килде. Үз гомеремдә беренче тапкыр аларда чын көнбагыш маенда кыздырылган йомырка тәбәсенән авыз иттем мин. Ул тәбәне Гариф ага үзе кыздырган иде (Шәһидә апа өйдә юк чак). Аның тәмлелеген, үзенчәлекле исен мәңге онытасым юк. Вакыт-вакыт шундый тәбә кыздырган чакта, Гариф аганы искә төшереп, үзалдыма елмаеп куям. Тыйнак табын янында гәпләшеп утырган чаклар, якты хатирә булып, күңелемне кузгатып ала. И ул кадерле минутлар, гүзәл мизгелләр…

Гариф абый белән Шәһидә апа мине уллары Рәшиткә охшата иде. Күрешкән, очрашкан мәлләрдә дә, телефон аша хәбәрләшеп алган чакларда да алар икесе беравыздан: «И-и-и, Рәшитебезгә тач охшагансың инде! Коеп куйган Рәшитебез!» – димичә калмый иде…

2000 елның 5 мае. Җиңү көне алдыннан бер төркем сугыш ветеранын Язучылар берлегенә чакырганнар иде. Котлаудан соң аларның берәм-сәрәм, икәү-өчәү булып баскычтан төшеп килүләре әле дә күз алдымда тора. Гариф ага, ахыргарак калып, яшь каләмдәше Марат Закир (ул әфган сугышында катнашкан егет) белән бергә гәпләшеп торганда, әңгәмәгә мин дә кушылып, без өчәү бергә фотосурәткә төштек. Бу вакытта Гариф аганың вафатына нәкъ бер ай вакыт калган булган…

Тарихи мизгелне хәтеренә салган ул фоторәсем, ни кызганыч, миндә юк. Бәлкем, безне сурәткә алучының үзендә яисә кемдә дә булса сакланадыр. Карыйсы, күрәсе иде ул фотоны…

…Гариф абыйның мәңгелек йортка күчкәненә күпмедер вакыт узгач, Шәһидә апа безнең өйгә шылтыратты. Телефон трубкасын хатыным Фидания алган иде:

– Шәһидә апа бу, сине сорый, – диде ул миңа.

– Безгә килеп кит әле. Гариф абыеңның пәлтәсен сиңа бирәсем килә. Аның төсе итеп сакларсың! – диде Шәһидә апа. Аннары:

– Без бит сине Рәшитебезгә охшата идек, – дип тә өстәде.

Мин пәлтәне барып алырга вәгъдә бирдем. Әмма… Ваемсызлыгым аркасында, баруымны сузып йөрттем. Һәм… соңга калдым. Көннәрдән бер көнне Шәһидә апа да бакыйлыкка күчте – Гариф ага янына китеп барды. Урыннары, иншаллаһ, оҗмах түрендәдер… Шулайдыр… Шулай булырга тиеш…

Гариф абыйның җырлавына шаһит булган кеше мин. Күп мәртәбәләр. Шул хакта шигырь язган идем. Гариф ага турындагы сүземнең ахыры шул шигырь булыр, мөгаен:

Хәтерлим, булды минем дә
Ис китеп тыңлаганым:
Гариф ага Ахуновның
«Хан кызы»н җырлаганын –
Бүген дә, әйе, күңелдә
Ис китеп тыңлаганым...

Хәтерлим, булды күп тапкыр
Җырлавын тыңлаганым:
«Минем әти – аючы...» дип,
Хисләнеп җырлаганын –
Әле дә, әйе, хәтердә
Шаккатып тыңлаганым...

Хәтерлим Гариф аганың
Үз җырын тыңлаганым:
«Якты көн, илһам бир миңа...»
Дип балкып җырлаганын –
Исемдә, әйе, исемдә
Ис китеп тыңлаганым...

Бүген дә гүя ул мине
Каршылый ишектән үк:
«Түргә уз!» дигән сүзләрен
Әле дә ишетәм күк –
Гүя ул, кочаклап алып,
Каршылый ишектән үк...

Бүген ул җырлыйдыр кебек
Яңгыратып Күкләр катын:
«Тып-тып кына басып килә
Көмеш тояк – тулпар атым... Һәй!..
Көмеш тояк – тулпар атым...» –
Җырлавын ишетәм гүя
Һәм тыңлыйм шаклар катып...

Тыңлыймын шаклар катып...

*Ләбиб Лерон,*
шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе
*2015, 13 сентябрь*




Арча районы Казанбаш урта мәктәбендә Гариф Ахуновка багышланган конференциядә. 2015, 21 октябрь

# Бөек Тукайның солтанатлы каләмдәше

Гариф абыйның күңеле үтә күренмәле тирән, зур бер түгәрәк күл кебек иде. Җәйрәп яткан көмеш күлдә һәрчак алтын балыклар йөзәр. Рухны сафландырып, пакьләндереп, яңартып җибәрү өчен гадел, игелекле, вөҗданлы, талантлы җаннарга суын язгы ташу чорында да чип-чиста, кышның чатнама суыкларында да җылы һәм йомшак тотар иде Гариф абый дигән затлы шәхесебез.

Ходай Тәгалә Гариф абыебыздан сөйкемлелеген дә, йөз ачыклыгын да, эчкерсезлеген дә, кече күңеллелеген дә, юмартлыгын да, акыл-фигылен, гыйлемен-уңганлыгын, үткенлеген-җитезлеген, затлылык-зиһенлеген, сәләт-талантын да җәлләмәгән, аңа «мә сиңа!» дип көрәп биргән иде.

Гариф Ахунов иҗатта да, җәмгыять тормышында да гаять киң колачлы һәм үтә актив булган олы шәхес иде. «Соңарып килгән бәхет» – хикәя, «Яшьлек яме», «Чикләвек төше» – повестьлар, «Хәзинә», «Идел кызы» – романнар, «Хыялый Хәйрүш егетләре», «Икәүдән-икәү генә» – пьесалар авторы, Тукай турында күп серияле телефильмнар сценариен язучыларның берсе, үзе өчен генә язган бер шүрлек шигырьләр (соңгы елларда газета-журналлар аларны бастыра башлаган иде), Михаил Шолоховның «Тын Дон» романын тәрҗемә кылу... 10 ел дәвамында СССР Югары Советы депутаты, СССР һәм Россия Язучылар берлеге идарәләре секретаре, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булган, ил вә республика тормышының унҗиде өлкәсендә... зур-зур һәм җаваплы эшләр алып барган, ару-талуны белмәс тынгысыз һәм олы җанлы кеше дә Гариф Ахунов иде.

Әлбәттә, мондый киңкырлы шәхеснең бар эшчәнлеген кыска гына мәкаләләрдә чагылдыру адәм баласының кулыннан килә торган нәрсә түгел. Мин Гариф абыйның соңгы еллардагы гап-гади көндәлек тормышыннан кайбер факт, вакыйга, детальләргә генә тукталмакчы булам. Туган ягы Арчага, аның талантлы кешеләренә искитмәле матур мөнәсәбәте, соңгы сулышына кадәр үз әсәрләре геройлары белән бергә яшәве турында фикерләремне әйтергә телим. Әдип тормышының бу яклары аның иҗатына гашыйк меңнәрчә укучыларына гына түгел, кайберләре хәтта иң якын иҗатташ дусларына да билгесез. Ваклана, гадиләштерә, дип уйлый күрмәгез. Бөеклекнең төбендә һәм нигезендә нәкъ менә шул гади нәрсәләр ята.

Бар иде шундый заманнар: язучылар фәкать үз журналлары гына итеп санаган «Казан утлары»на журналист халкын якын да китермиләр иде. Шул гаделсез, кырыс елларда бу басмада минем исем-фамилиям ике мәртәбә күренеп алды. Сочида үсә торган атаклы «Дуслык» агачы турында кыска-кыска гына новеллаларым һәм «Минсалих бәхете» дигән очеркым чыкты. Гариф Ахунов журналның баш редакторы чагында иде бу. Шуннан соң без шактый еш очраша, бер-беребезне якын күреп сөйләшеп йөри башладык. Гариф абыйның дуслыкны эшлеклелек сыйфатларына нигезләп корырга ратуын тиз абайлап алдым. Идарә рәисе итеп сайлангач, ул Язучылар берлеге эшен шактый үзгәртте. Шул чак аңа оештыру эшләрен алып баручы кеше дә кирәк булып чыкты. «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Шәмси Хамматов ул урынга мине кодаларга тотынды. Гариф абый да бу тәкъдимне хуп күргән иде. Мәсьәлә КПСС өлкә комитеты-



Гариф Ахунов (уртада) хатыны Шәһидә һәм Татарстан Язучылар берлеге ветераннары белән. Казан. 2000, 5 май (язучының исән чагындагы соңгы сурәте)

на барып җиткәч, минем Язучылар берлеге әгъзасы булмавым ачыклана һәм бу эшнең очы югала. Соңга таба моның сәбәпләрен сораштырып йөрүне кирәк санамадым. Чөнки Язучылар оешмасында эшләргә ашыкмый идем. Менә шушы очрак Гариф Ахунов белән Мәгъсүм Гәрәевнең чын дуслыгын ныгытты һәм гомерлек итте. Үндүрт-унбиш ел без Арча юлларын бергә таптадык, республика буйлап бер сукмактан йөри идек. Тормыштагы теге яки бу вакыйгалар турында фикерләребез күп вакытта тәңгәл килә иде.

Туып үскән Арчасын, якташларын үлеп ярата белүенә исләрем-акылларым китеп сокланып йөрим. Арча табигатенең таң калырлык матурлыклары, урман-кырлары, елга-күлләре – гүя берсе дә һичкайчан булмас төсле, таңланып тоела иде бугай аңа. Без Арча якларында, хәер, бөтен Казан артында була торган бәйрәм-тамашаларга бергә барырга яратабыз. Гариф абый, халык алдына чыгып баскач, үзенең Тукай якташы булуы белән горурланып яшәвен әйтеп куяр. Арча кешеләренә, бик тә ягымлы һәм йомшак итеп, туганнарым, дип эндәшер. Ул туган-үскән җире халкы тормышы белән яши, мондагы һәр шатлыкны үзенеке шикелле итеп уртаклаша белә, якташларына кулдан килгән ярдәмне күрсәтеп тора. Тукай Ватанын бик җентекләп, якыннан күрү хас аңа. «Без бит Арча яклары» дигән китабын 1951–1978 елларда язды. Арчалыларны, әтиәнисе, апасы-энесе, балалары кебек якын күреп, зурлап тасвирлап бирде. Китапның соңгы бүлегендә Гомәр абый Бәширов, Сибгат абый Хәким, Рафаил Төхвәтуллин һәм Мөхәммәт Мәһдиевнең иҗат портретларын язган иде.

«Татарстан хәбәрләре» газетасының 1993 елгы 13 август санында минем «Арча җиренең ачык китабы» дигән күләмле очеркым чыкты. Ул игенчеләр тормышыннан иде. Икенче көнне иртән сигез тулганчы ук Гариф абый эшкә килгәнемне көтеп тора.

Гадәттәгечә, матур итеп күрештек, аннан бүлмәгә кереп утырдык. Гариф абый сүз башлады:

– Син, Мәгъсүм, безнең Арча ягын бик олылагансың, яңа образын тудыргансың. Бу газетада гына калырга тиеш түгел. Без моны документаль повестька кадәр үстерик...

Бер ел дигәндә, очеркны повесть итеп яздык, һәм ул «Казан утлары» журналында дөнья күрде. Гариф абыйның үтә дә эшсөяр кеше икәнен белә идем. Повесть язганда аның бу сыйфаты бүтән яклары белән дә ачыла төште. Иртәнге биш тулганчы, телефоннан хәлне белә, күпме язганны сорый. Кешегә ихтирам, олылау, хөрмәт, игътибар күрсәтә белүче игелекле җан иде Гариф абый. Әлеге повестьның бер бүлеге минем туган ягым Питрәчкә багышланган. Аны яза башлар алдыннан болай диде:

– Безнең Арча якларында күп йөрибез, Мәликә апа, Гәрәй абый кырларын да бергә карап кайтасы иде...

Моның өчен кулай көн кирәк иде. 1993 елның 18 сентябрендә Питрәч районының Күн авылына бөтен республикада игенчелек эшенә җитәкчелек итүче кешеләр җыеласы. Шул көнне барасы иттек. Иртәдән яңгыр явып торса да, авырсынмыйча юлга чыктык. Манма суга батып кайтсак кайттык, әмма аннан сукрану сүзләре ишетмәдек.

– Авыл кешесенең авыр хезмәтен үзең аша үткәргәндә, язуы җиңелрәк була, – дип, күңелләрне күтәреп алды ул.

Туксан җиденең юл өзегендә Биектауның ул чордагы башлыгы Җәүдәт Миңнеәхмәтов безне районга чакырды.

– Халыкның бераз эше кимегән чак. Язгы кыр эшләре алдыннан композиторлар Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев, Әнвәр Бакиров, җырчыбыз Клара Хәйретдинова, бездән чыккан язучылар турында истәлекләр сөйләп китсәгез иде, – диде башлык.

Ун көн йөрдек. Коркачыкта очрашу алдыннан кисәттеләр: авылда төрмәдән кайткан кешеләр күп, дипломатия телендә сөйләшергә тырышыгыз.

Клуб халык белән шыгрым тулы. Сәхнәдә без икәү, утырып кына сөйләшергә булдык. Тегеләрнең берсе ошатып бетермәде бугай безнең бу гамәлне, ризасызлык белдерде. Гариф абый май канаты белән сыйпап куйды тегене:

– Җәмәгать, басып сөйләсәк, нәчәлникләр дип белерсез. Утырып гәпләшсәк, кунакка килгән кебек булабыз, бер-беребезгә ямьсез, тупас сүзләр әйтүдән тыелабыз, – диде.

Зал рәхәтләнеп бер көлеп алды. Соңыннан ир уртасы теге кеше, безнең янга килеп, Гариф абыйга кулын бирде. Бик тә җор телле икән.

– Мин шаяртмакчы идем, Гариф абый, барып чыкмады. Фәрештәдер синең затың, тумышың!

Гариф абыйның балаларча куануын күрсәгез иде.

Сөйләү дигәннән, ул сүзгә, юморга бик һәвәс иде. 1996 елның 15 мартында Казан циркы бинасында Арча хакимияте, Тукаебызның тууына 110 ел тулу уңаеннан, зур кичә үткәрде. Башта ук Гариф абыйга сүз бирделәр.

– Арча төбәге беркайчан да безнең йөзгә кызыллык китермәде, халкы мул итеп иген үстерә, терлек-туарын көр итеп асрый белә. Казан базарларында сокландыргыч ярминкәләр үткәрергә оста, әдәбият-сәнгатьне яклау ягыннан башкаларга үрнәк. Тукай байрагын бөтен Татарстанга күренерлек итеп җилфердәтә. Без шушы кичәдә утырган минутларда Арча ягында яңа бер Тукай тусын! – дип, залның рухын күтәрә, тамашачыларның җанын җылыта әдип.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның Гариф Ахунов янына килеп, котлап кулын кысуы әле дә булса күз алдымда тора.

– Арча маркасын тота beləсең инде, Гариф абый. Минем сүзләрне дә әйттең, чыгыш ясаудан азат иттең...

Арча кичәсендә генә шулай түгел, башка җирләрдә дә Гариф абый, шулай уены-чыны белән: «Кем, энем, сезнең яклар да бик матур, талантларга бай. «Арчадан кала» дип өстәсәң, чынбарлыкка күбрәк туры килер»,– дип шаяртып куяр иде. Арчада зур-зур мәҗлесләрне бик күңелле итеп алып барулары. Кайберәүләрнең сүзләре бик матур килеп чыкмый. Гариф абый беркайчан да андыйларның йөзен ертмый. Киресенчә, мактап: «Сезнең алтын сүзләрне көмеш кыршау белән беркетеп куярга рөхсәттер»,– дип әйтергә ярата иде.

Арчага 1999 елның 26 мартында янә бардык. Бу безнең бәйрәмгә зурлап соңгы мәртәбә кайтуыбыз булган икән. Гариф абый үз кояшының тәмам батар чагы җиткәнен сизенгән булса кирәк. Төн утырып шигырь язган. Машинада шуны редакцияләп алдык, һәм мәдәният сараенда укып күрсәтте. Арчасы, авыл кешеләре белән бәхилләшүе, хушлашуы шушы булган икән. Юбилейларының берсендә башкортлар бүләк иткән затлы чапанын музейга биреп калдырды. Шигырьнең төп нөсхәсен миңа биргән иде. Менә ул.

## *Туган якка мәдхия*

И туган як, туган як,
Җанга газиз булган як.
Ятим үстем Тукай күк,
Җылытты тик туган як.

Исән чакта кайтып калыйм,
Күз йомылгач кайталмам.
Мин бит синең үз балаң, дип
Әйталмам мин, әйталмам.

Арчаларга кайтам әле,
Арча юллары такыр.
Безнең эшләр, еллар узгач,
Туган якларга кайтыр.

*1999, 25 март*

Гариф абый Ахунов чын егетләрнең дә солтаны, бөек Тукайның солтанатлы каләмдәше, якташы иде. Ул мин белгән бөтен гомерен егет булып яшәде. Берәүне дә борчымыйча, бакый дөньяга да тыныч кына, егетләрчә китеп барды.

Вафаты алдыннан васыятьләрен дә үз авызыннан ишеттем. 19 апрельдә Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Арча хакимияте башлыгы урынбасары Ринат Фазлыйәхмәтов белән дүртәүләп фатирына бардык. Чәй эчә-эчә, өч сәгатькә якын иркенләп сөйләшеп утырдык. Ул һәрвакыттагыча ачык йөзле, кече күңелле, сүзгә һәвәс Гариф Ахунов иде. Үлеменә ике көн кала, кичке сәгать тугызда телефоннан чылтыратты. Егерме минутлап сөйләштек. Ярты сәгатьтән телефоныбыз янә бер мәртәбә чылтырап алды. Монысын да Гариф абый эшләде: «Үтенечләремне җиренә җиткерә күр. Бөтен ышанычым синдә»,– дип искәртте. Каләмдәшләре турында кайгыртуы, борчылуы иде, кешегә игътибарлы булырга кирәклеген соңгы сулышына кадәр онытмады. Соңгы мәртәбә халык арасына чыгуы 2000 елның 5 маенда булды. Язучылар йортында өлкәннәр Бөек Җиңүнең 55 еллыгы уңаеннан мәҗлескә җыелган иде.

Ә 6 июнь көнне Ахунҗан улы Гарифҗан абыйны васыяте буенча Арча зиратына илтеп җирләдек. Гариф абый, шигырендә язганча, эшләре белән генә түгел, үзе дә мәңгелеккә туган ягына кайтты.

Мин Арча якларында әле дә еш булам. Барган саен, Гариф абый янына зиратка кереп чыгам. Җан дустым белән серләшкәндә, Илдар Юзеевның Гариф Ахунов вафаты уңаеннан язган шигыренең соңгы юлларын искә алам.

*Туфрак җылы-йомшак булыр*
*Туган-үскән ягыңда.*

*Оҗмах кошлары сайрасын*
*Анда да һәр таңыңда.*

Рухыңа догам булып ирешсен!

***

...Тагын Арчага кайтабыз. Бу кайтуыбыз 2000 елның 3 ноябрендә, җомга көнне иде. Мин аның белән соңгы тапкыр телефоннан җомга кичендә сөйләшкән идем, 2 июньдә.

...Көллиятнең җыелышлар залы. Яшь егетләр, яшь кызлар. XX йөз татар әдәбияты Ахунын ярата яңа буын. Кем ничектер, мин бу залда Гариф абый Ахунов җаны белән очраштым. Уйламаганда-көтмәгәндә, халык белән шыгрым тулы залда күбәләк пәйда булды. Кызыл канатларына яшел җепләр сузылган. Күбәләк, очып барып, сәхнә түренә куелган Гариф Ахунов портреты рамына куна. Аннары мамыктан да йомшак канатлары белән микрофоннарны сыпырып оча, кызларның, егетләрнең башларыннан сыйпап үтә, колакларына нидер пышылдый сыман. Иңбашыма килеп кунды. Саташаммы әллә? Төш күрәмме? Күз алдыма Гариф абый килеп баскан кебек булды. Гүя нидер сөйли. Карале, мәйтәм, сабый чагымда әнием, Лаешта 12 муллага имтихан биргән Мәликә абыстай, юкка гына сөйләмәгән икән! «Улым, изге кешеләрнең җаны туган нигезенә, торган-эшләгән җиренә, бик якын күргән кешеләре янына күбәләк булып кайтыр,– дип искә ала иде.– Кара аны, өйдәге күбәләкләргә тиясе түгел, әби-бабаларың, әтиең, өлкән апа-абыйларың җаны ул. Безне күрәселәре килеп кайткан. Әйтер сүзләре бардыр...»

Әле иртәнге якта гына без, өлкәннәр, Казанбаш мәктәбендә сабый чакларыбызга кайтып килдек. Мәктәпкә беренче елын килгән бәләкәйләр дә, югары сыйныфларда укучылар да бар иде анда. Балалар безгә Гариф абыйларының язганнары буенча аның авылда яшәгән чакларын уйнап күрсәттеләр. Әдипнең бәрәңге сату вакыйгасын да керткәннәр чыгышларына. Озак еллар Казанбаштагы «Известия» колхозы рәисе булып торган Социалистик Хезмәт Герое Мирбат Хәстиевнең хатыны Рәсилә ханым шушы ике шәхеснең дуслыгын искә төшереп алды. Менә мондый чакта мәктәп балаларына Ахуновның зур язучы турында лекция кирәкми. Шушы мохиттәге вакыйгалар белән кузгат син аларның күңелен. Мин беләм андый очракларны, шуларны сөйләттеләр. Гариф абый Ахуновның Хәстиев колхозыннан ике рам кәрәзле бал алып, Парижга, ЮНЕСКО офисына җибәрүе вакыйгасы да балалар күңеленә хуш килде.

Илдар Юзеев та сүз сөрешенә үтә сизгер. Көллият залында Гариф абыйның укытучылары – «Әлифба» китабы авторлары Рәмзия апа Вәлитова белән Сәләй абый Вәгыйзов та утыра. Рәмзия апа шәкерте Гарифның сабак чорларыннан гыйбрәтле бер өзек сөйләде. Илдар «Әлифба»ның «А»дан башлануын шәп отып ала. Арча, Ахунов... «Арчаның «А»дан «Я»га хәтле кешеләре бар да талантлы. «Я» дигәннән, бүгенге кунак Альберт Яхинны күздә тотам. «Чаян» журналы редакторы иде»,– дип, бөтен мәҗлесне кузгатып, җанландырып җибәрде шагыйрь.

Арча талантлары үткен, тапкыр. Илүсә Садвокасова өлкәннәр ярата торган җырны башлады. Сәләй абыйның дәрт-дәрман бар икән әле. Җырга кушылды:

*Әле дә син бар әле дөньяда...*

Һәм Казанбашта, һәм көллияттә Гөлшәһидә ханым, музейларга кую өчен, Гариф абый Ахуновның шәхси әйберләрен калдырды. Бәйрәмне оештыручыларга ихлас күңелдән рәхмәтен белдерде.

*Мәгъсүм Гәрәев,*
журналист, язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе
*2000, 10 ноябрь*

# Юлларның-кояшлы-ягыннан

Безнең гомер юлларыбыз кара урманнар аша уза. Сукмакларның бер ягына кояш төшсә, икенче ягы күләгәдә кала. Берәүләр күләгәле яктан, карашын аска төбәп, моңаеп атласа, икенчеләр кояшлы яктан, башын күтәреп, елмаеп бара.

Гариф абый Ахунов юлларның кояшлы ягын яратты. Күкне болытлар каплаган чакларда да, ул тирә-юньне елмаюы белән яктырта белә иде шикелле. Дөньяның матурлыгына кинәнеп яши, вак-төяк, чүп-чарын күрми, көйсезлекләрне бирешмичә үткәреп җибәрә иде ул һәм шушы нурлы дөньясына башкаларны да әйдәп кертә иде. Бәхетемә күрә, каләм тибрәтә башлаган чорымда ук миңа ул –Гариф абый очрады.

Минем «Азат хатын» журналында эшләгән чагым иде. Журналда хикәяләргә конкурс игълан ителде. Конкурс ябык иде, шуңа күрә аңа редакция хезмәткәрләренең дә катнашу мөмкинлеге булды.

Менә нәтиҗә чыгару көне килеп җитте, жюри баш редактор Асия Хәсәнова бүлмәсенә кереп бикләнде. Без күрше бүлмәдә көтеп утырабыз. Йөрәкләр дөп-дөп тибә. Берзаман ишек ачылып китте, елмаеп, очынып, Гариф абый килеп керде дә ике куллап минем кулымны кысты:

– Котлыйм, чын күңелдән котлыйм, – диде. – Без беренче премия биргән хикәя, конвертын ачкач, синеке булып чыкты. Ләкин, – ди, үзе һаман көлә, – әгәр синең хикәя икәнен белсәм, мин аңа беренче премияне бирдерми идем. Әнә Ибраһим абый әйткән иде, беренчесен беркемгә дә бирмик, арада яхшырак ике хикәянең икесенә дә икенче премия бирик, дигән иде. Ә мин, беренче премия дә була, дип язып чыктык бит, сүзебездә торыйк, дидем. Ләкин син болай гына язарга тиеш түгел. Син яхшырак язарга тиеш идең! Тел ягыннан эшләп җиткерелмәгән хикәяң! Шуңа күрә авторы син икәнен алдан белгән булсам, беренче премияне бирүгә мин дә каршы чыккан булыр идем.

Язучы, кагыйдә буларак, тәнкыйть сүзен бик авыр кабул итә. Ибраһим абый Газиның бер сүзе бар иде: «Тәнкыйть кирәкле шәй, ләкин ул якаң астына салынган гөберле бака кебек чиркандыра». Әмма Гариф абыйның тәнкыйть сүзе минем куанычымны киметмәде, чөнки ул аны җиңел итеп, якын итеп әйтте. Шул ук вакытта сүзе үтемле дә иде. Аны Ибраһим абый Гази да җөпләде:

– Хикәянең теле кытыршы, – диде.

Чыннан да, минем ул хикәям иҗади казанышым була алмады, ул фәкать, андый ярышларда язучылар аз катнашканга күрә генә, арадан сайлап алынган иде. Ике зур остазымның әйткән сүзләрен мин беркайчан да онытмадым, гомерем буе әсәрләремне кат-кат эшләргә, шомартырга, телен чарларга, Гариф абый әйткәнчә, кашын-күзен төзәтергә тырыштым.

Ул «Казан утлары» журналында баш редактор булып эшли иде, мин редакциягә маҗаралы, ягъни детектив повесть күтәреп килдем. Әсәрне басарга әзерләгәндә, Гариф абый белән берничә тапкыр сөйләшкәнебез хәтердә. Андый очракларда редакторлар белән сөйләшү шактый читен була, чөнки, әлбәттә инде, әсәрнең кимчелекләре табылмый калмый, редактор төзәтергә куша, ни өчен алай түгел, болай икәнен озаклап аңлата.



Талантлар һәм аларга баш иючеләр. Гариф Ахунов автограф бирә. Яр Чаллы. 1980

Автор исә, ничек бу минем башка килмәгән икән, дип эчтән кимсенә. Ә менә Гариф абый үзен шундый теләктәш, үз итеп тота, ачык, көләч сөйләшә, кимчелекләрне күрсәткәндә дә, сиңа хөрмәт белән, җиңел итеп әйтеп бирә, аның яныннан иҗатка дәрт артып, күңел күтәрелеп кайтып китә идең дә җиң сызганып эшкә керешә идең. Хәтерлим, мин бу повестька лаеклы исем таба алмый иза чиктем, тапканы уңышсыз иде, редакциядә аны ошатмадылар. Гариф абый бераз гына уйлап торды да, гадәтенчә бөтен йөзе, күзләре белән елмаеп: «Әйдәгез, «Адашканга юл кайда?» дип куйыйк»,– диде. Исем, чыннан да, әсәрнең асылын чагылдыра иде. Редакция хезмәткәрләре дә ошаттылар.

Повесть ноябрь санында, Гариф абый үзе ялда чакта басылып чыкты. Мин бик куандым, чөнки журнал минем әсәр белән ачылган иде. Ләкин бер нәрсә исәпкә алынмаган икән: ноябрь башында – Октябрь бәйрәме, журнал –коммунистлар партиясе матбагасы, шулай булгач, алгы битләрдә фәкать коммунистлар партиясен мактау, революциягә дан җырлау тиеш иде. Редакция хезмәткәрләре, иҗат әһелләре буларак, сәясәттә борынны җил уңаена гына тотарга артык сәләтле кешеләр түгел. Алар, беренче чиратта, журнал укучы өчен кызыклы булсын, дип уйлаганнар, шуңа күрә мавыктыргыч сюжетлы әсәрне алга куйганнар.

Сәясәт тукмагы безнең башларны ел йомгакларына багышланган язучылар җыелышында дөмбәсли башлады. Бер-бер артлы берничә кеше, трибунага күтәрелеп, минем «идеясез» повестьны һәм журналның Октябрь бәйрәменә багышланырга тиешле санын шундый «җилбәзәк» әсәр белән ачып җибәргән редакцияне каты тәнкыйтькә дучар иттеләр.

Ярсый-ярсый, әсәрдән озын-озын өзекләр укып тиргиләр, миңа хәтта утыз җиденче елларның бозлы җиле китереп бәргәндәй тоела башлады. «Менә шушындый җыелышлардан соң каләм осталарының кайберләрен Черек күлгә алып киткәннәрдер»,– дигән уй чалынып узды баштан. Әйтергә кирәк, андый җыелышларның һәркайсында партия өлкә комитетының идеология буенча секретаре трибунада утыра торган иде. Кыскасы, заманалар утыз җиденче елгы кебек куркыныч булмаса да, ышанычсыз кешеләр рәтенә кереп калуың бик ихтимал иде. Минем нервлар ычкынган булган, күрәсең, нишләгәнемне хәтерләмим, әмма Кояш Тимбикова сөйләде: «Зал тып-тын,– ди,– әйтерсең һәммәсе

сулыш алудан туктаган, трибунадан синең повестьны сүккәннәре һәм синең «хи-хи-хи» дип хихылдап көлгәнең генә яңгырап тора». Ә мин көлгәнемне хәтерләмим!

Ярый, таралдык тәнәфескә, төшке актка. Берәр сәгатьтән тагын җыелдык. Беренче булып трибунага Гариф Ахунов күтәрелде. Кулында журнал. Ул минем повесть турында сөйли башлады. Журнал битләреннән өзекләр укып: «Менә, күрәсезме, һәммәсе ап-ачык күз алдына килеп баса, бик матур тасвирланган. Нигезле, ышандыра»,– дип, повестьның журналда урын алырга лаек икәнен исбат итте.

Ә бит ул, мин ялда идем, дип, үз өстеннән җаваплылыкны төшерә алган булыр иде. Яисә, кайчакта журналда йомшак әсәрләр дә уза шул, башка алай эшләмәбез, дия ала иде. Тәнкыйть белән чыгыш ясаган, инде танылган язучыларның сүзен юкка чыгарып, хәтерен калдырмаса, үзе өчен әйбәтрәк булыр иде, мөгаен. Мин кем идем әле ул чакта? Башлап язучы гына, журналда да икенче генә күләмле әсәрем басылган иде. Мине алай ук аяк терәп якламаса да, аны аңларга булыр иде.

Юк шул, Гариф абыйның холкы, тегендә-монда каранып, моны әйтсәм ни булыр да тегене дәшми калсам яхшырак булмасмы, дия торган түгел иде. Ул һәрвакыт дөреслекне кычкырып яклый иде. Ә дөреслек, аның өчен, сәләте булган һәр кешенең уңышларын күрү, кимчелекләреннән сак кына арындыру, аны мөмкин кадәр канатландыру, очындыру, дәртләндерү иде. Чөнки үз көченә ышанган, зур эшләр башкарачагына ышанып, канатланып иҗат иткән талант иясе генә матур әсәрләр тудыра ала.

Тагын шунысы мине гаҗәпләндерде: шул кыска гына вакыт эчендә, төшке ашка бирелгән бер сәгатьтә, журнал актарып утырырга каян вакыт тапты икән ул? Белгән һәркем әйтер, Ахуновның ялгызын күз алдына да китереп булмый, аның тирәсендә өермәдәй халык бөтерелә торган иде, бу тәнәфестә дә сүз кушучылар җитәрлек булгандыр. Менә шундый мохиттә ул минем повестемны күздән кичереп, аннан иң уңышлы өземтәләрне сайлап алырга ничек өлгерде икән? Автор буларак, мин үзем дә моны эшли алыр идем микән әле.

Әдәбиятка килгән һәммә каләм иясенең әсәрләрен укып бара һәм аларны шулхәтле төгәл хәтерендә калдыра иде ул. Мин моңа хәйран калам.

Гариф абый минем өчен әдәбиятта чын-чынлап олы абыем кебек булды. Үзе Язучылар союзы председателе булып сайланганда, мине идарәгә тәкъдим итте. Ә минем союзга кабул ителгәнемә дә ике генә ел иде бит әле. Шуннан соң дүрт ел узгач, чираттагы съездда мине идарәгә сайлауга каршы чыгучылар булды. Гариф абый, биек трибунага чыгып, тагын бөтен зал каршында мине яклады: Маликова – идарәдә кирәк кеше, ул тырышып эшли, диде.

Мин СССР һәм РСФСР язучыларының съездларында катнаштым, анда да делегация составына мине Гариф абый Ахунов тәкъдим итте. Зур даирәләрдә аралашу, төрле халыкларның язучыларын күреп сөйләшү минем рухымны нык баетты, карашымны киңәйтте, иҗатка рухландырды.

Аның миңа эшләгән яхшылыкларын бәяләп бетергесез һәм барысын да сөйләп чыгып булмый. Шул ук вакытта мин аның каршында башка язучылардан аерылып та тормый идем. Беләм: ул, миңа ярдәм иткән кебек үк, башка бик күпләрне колагыннан тартып диярлек үстерде. Аның шифалы күз нурлары яктысында, аның күңел җылысыннан куәт алып, әдәбият бакчасында бик күп гөлләр чәчәк атты. Мин фәкать җөмләдән берәү генә һәм, әйтергә кирәк, бу – минем өчен бигрәк тә кадерле. Димәк, ул мине, чыннан да, сәләтле язучы дип санаган, миңа, чыннан да, зур өметләр баглаган. Ул моны минем хакта язган зур мәкаләсендә дә яхшы әйткән иде. Аның каләм ияләренә мөнәсәбәте һич тә төчеләнүгә кайтып калмады. Дөреслекне йөзгә бәреп әйтә торган иде. Әдәби ел

йомгакларына багышланган бер җыелышта миңа проза әсәрләре хакында доклад ясарга туры килде. Шунда мин Шамил Бикчуринның «Каты токым» романы турында шактый гына тәнкыйть сүзләре әйттем. Бу юлы инде Гариф абый сәхнәдән миңа каршы чыкты, ачык дәлилләр белән романның уңышларын, кыйммәтен дәлилләде. Соңыннан минем үзем белән аерым гына да бу хакта сөйләште. Каләмдәшләремнең әсәрләренә ачыграк күз белән каравымны, тирәннән уйлап бәя бирүемне тели иде ул.

Ул миңа күп тапкырлар тормыш сабагы да бирде. Беркайчан да онытмам, мин бер Мәскәү язучысын каршы алырга өлгермәдем, соңардым. Ә ул кунак кайчан киләсен миңа гына хәбәр иткән, миңа гына ышанган иде.

Чабып килсәм, поезддан халык төшеп, таралышып бетә язган... Әллә көтеп торамы дип өметләнеп әйләнгәләдем –юк... Бәхеткә, Гариф абый бар иде дөньяда. Ул кунакның кайчан, нинди поезд белән киләсен үзе белешкән, улы Рәшит белән икәүләшеп килеп, вагоннан кул биреп төшергәннәр, машинага утыртып алып киткәннәр.

Ул мине шелтәләмәде. Фәкать:

– Берәрсен каршы алырга кирәк булганда, мин вокзалга ярты сәгать алдан киләм,– диде.– Шулай итсәң, уңайлы була.

Төгәллек – корольләрнең ихтирамы, диләр. Бу алтын сыйфат Гариф Ахуновның шәхесен тагын бер яктан бизи иде.

Бер уйласаң, бу кеше ничек һәммәсенә өлгерде икән дип хәйран каласың. Мисалга, мин «Кызыл Ай» җәмгыятенең җитәкчесе булгач, ул миңа бу эшемдә дә теләктәшлек күрсәтте. Хуплады. Алай гына түгел, ярдәм итү мөмкинлеген дә тапты. Ул бу эшкә хәтта бөтен гаиләсен җәлеп итте. Безгә килгән шактый мохтаҗлар Ахуновлар биргән киемсалымны куана-куана киделәр. Гариф абый белән Шәһидә ханымның кызлары Наилә, оныклары Ида безгә даими ярдәм китереп торалар. «Кызыл Айга» ярдәм итүче мондый гаилә – язучылар арасында бердәнбер, һәм алар кылган бу игелек Ахуновлар гаиләсен бөтен мактау сүзләреннән ачыграк тасвирлый.

Без язучылар оешмасында күп еллар бергә кайнап яшәдек, эш-иҗат турында гына түгел, яшәешнең төрле яклары хакында ныклап сөйләшергә туры килгән чаклар да булды. Берзаман шундый шәхси бәхәсләр кузгалган җыелышта Гариф абый минем хактагы сүзне бик кыска тотты:

– Мәдинә күп яза, вак-төяк белән ыгы-зыгы килергә вакыты юк,– диде.

Ә миңа исә:

– Мин сине бик яхшы беләм,– диде.– Вакланма.

Ә бит мин, тегене әйтәм дә моны сөйлим дип, күп сүзләр әзерләп килгән идем. Әмма Гариф абыйны тыңламый булдыра алмадым, сөйләмәдем, тыелдым. Суынгач аңладым: вакланмавым, дәшми калуым дөрес булган.

Җыелышта бәхәс шуның белән туктатылды.

Була шулай: көнкүреш ваклыклары бугазга баса, юкка гасабиланулар җанны талкый, шул чакларда Гариф абыйның сүзе искә төшә: «Вакланма».

Үзе ул беркайчан да ваклана белмәде. Аның китапларына, очерк-мәкаләләренә, кылган гамәлләренә бер күз салу җитә: эшләрнең зурысын, җаваплылыкның олысын үз җилкәсенә күтәрде ул. Якты йөзле, туры сүзле, ару белмәс пәһлеван булып саклана ул күңелемнең түрендә.

Аны белгән һәркем әйтер: бәхетле кеше иде Гариф абый, һәм шул бәхетенең нурлары белән башкаларның тормыш юлын да яктырта белә иде.

*Мәдинә Маликова,*
язучы, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре

# «Чикләвек-төше»-безнең-авыл-турында

Гариф Ахунов, безнең район кияве буларак, әгерҗелеләргә бик кадерле. Үзенең әсәрләре өчен кыйммәтле чыганакларны ул безнең яктан табып кына тора. Шуларның берсе – «Чикләвек төше» повесте. Анда Әгерҗе районы Исәнбай авылында булып үткән вакыйгалар тасвирлана. 1970–1971 елларда язылган бу әсәренең кайсыбер прототиплары әле дә булса исәннәр. Әсәр чын реализм белән сугарылган. Андагы тарихи фактлар һәркемгә аңлаешлы, таныш. Авыл тормышын яхшыртуда көчен кызганмаган, колхозны алдынгы итүдә зур өлеш керткән колхоз председателе, утызмеңенче Халикъ Саматов (чынлыкта безнең белүебез буенча – Халит Хәйруллин) турында хатыны Рокыя күзлегеннән сөйләтеп, автор бик уңышлы алым кулланган. Укучылар Рокыя белән бергә дулкынлана, уңышлары өчен сөенә, авыр хәлгә төшкәндә бергә кайгыра да. «Чикләвек төше» повестенда сурәтләнгән җитәкче Саматов үзенең кыюлыгы, чикләвек кебек тиз генә ватылмаган, төшенә зыян китермәслек рухи ныклыгы белән укучының күңелендә хөрмәт уята. Ирексездән әкренләп аны ихтирам итә башлыйсың.

Әсәрдә сөйләнгәнчә, 1955 елда «Кызыл таң» колхозы – Тазабай авылында хәлләр бик җиңелдән булмый. Соңгы ике ел эчендә биредә колхоз председателе булып райбашкарма председателе эшләгән, аны прокурор алыштырган, ниһаять, МВД киеме киеп, укалы погон таккан Халикъ Саматов килеп төшә. Колхозда әйле-шәйле бер полуторка, ике «газик» кына була. Биш мең ике йөз илле гектар җире исә бик күпләрдән санала. Биш йөз хуҗалык. Иген уңышы – гектарыннан биш центнер ярым. Хезмәт көненә ике йөз грамм ашлык. Акчалата бер тиен дә юк. «Тазабайлар урлашалар. Майларына чыдаша алмаганнармы? Һич. Ашарга юк – урлыйлар, мал-туарга юк – урлыйлар. Җан асрыйсылары килә», – дип, менә шундый чынбарлыкны язып калдыра Гариф Ахунов, кызгану катыш. «Җан асрыйсылары килә!» – дигән нәтиҗә чыгара язучыбыз.

Чынлыкта бу минем туган авылым – Исәнбайдагы тормыш хәлләре. Сабый бала гына булсам да, хәтерлим – бер елны колхоз председателенең, җиде бала атасы Нурмөхәммәт абыйның, утырган каз астыннан, чуманнан табылган өч-дүрт килолап арыш өчен, башы төрмәгә тыгылды, шунда үлеп тә калды. Безнең күршедәге җиде-сигез яшьлек Фәгыйлә белән Фәһимнең әнисе Нәгыймә апаны да төрмәгә яптылар. Ат арбасында берничә кило ашлык табылган икәнлеген белдек. Әтиләре сугыштан кайтмаган иде, ике баланы балалар йортына озаттылар. Халык икенең берсе дип яшәде шул. Безнең якта уңдырышлы кара туфраклар юк, көлсу туфракта әллә ни үсмәгәндер. (Гариф Ахуновның үзенә дә бу фаҗигале хәлләр күптәннән таныш икән шул. Алты яшеннән әтисез үскән Гариф, сугыш елларында колхоз кырыннан бер күтәрәм бәрәңге алып кайтканы өчен, ирегеннән мәхрүм ителә. Яшүсмер егетнең өч ел гомере хезмәт белән төзәтү лагеренда уза.)

«Чикләвек төше» әсәрендәге МВД киеме кигән председатель турында да: «Саматов ул, овчарка эте кебек, кайда чит нәрсә ятканны исеннән сизеп таба», – дип сөйли башлыйлар. Саматов та урлашуны тыя, шул ук вакытта колхозчыларның тормышын яхшырту юлларын да эзли башлый. Бу авыр хәлдән ничек чыгарга? Башта җитен үстереп, ике йөз илле мең саф табыш алып, спецсчет дигән статьяга кертеп җибәрәләр. Сыерлар

өчен клевер чәчеп, сөт тапшыруда районда беренче урынга чыгалар. Авылны электрлаштыралар, радио кертәләр. Колхозчыларга инде хезмәт көненә бер килодан ашлык бирә башлыйлар, акчалата да түләү була. Җиде ел эчендә колхозны миллионер дип саный башлыйлар.

Ләкин сөенеч белән кайгы янәшә йөри икән шул. Алтмыш икенче елны яз бик матур килә. Игеннәр күкрәп үсә. Арыш басулары дугалы ат күмелерлек була. Тугыз көн тула дигәндә, арышны урып бетерәләр. Ләкин бодай урырга керешкәч, яңгырлар көн саен ява башлый. Ярты көн ява, ярты көн аяз. Комбайнчылар көн аязганны каравыллый. Менә шул вакытта көн-төн юеш кием белән басуда йөреп, Саматовка бик каты салкын тия. Ул хастаханәгә кереп ятарга мәҗбүр була. Ашлыкны череттең дип, аны эшеннән алалар. Колхозчылар Саматовны яклап калдырмакчы булсалар да, югарыда утырганнар аларны җиңә, җыелышка үзләре белән авыл хуҗалыгы буенча югары белеме булган алмаш та алып килгәннәр. Түрәләр халыкка аңлатып та куя: илдә колхозларның текә күтәрелүе илле өченче елдан бирле бара, Үзәк Комитет, ел саен авыл турында сөйләп, ике пленумның берсен авыл хуҗалыгына багышлаган. Тазабай авылында барган алга китеш тә партиянең дөрес юл күрсәтүе нәтиҗәсе икән.

Гариф Ахуновның «Чикләвек төше» исемле әсәрен әле колхозлар исән чагында укыган идем. Күңелемдә нинди фикерләр тууын хәтерләмим. Ә менә быел укыгач, колхозлар юкка чыккач, авыл халкы төрле якка таралып бетә язгач: «Их, менә тагын авылларны күтәрергә хөкүмәт утызмеңенчеләрне җибәрсен иде!» – дип куйдым. Инвесторларга синең электрың-радиоң, клубың бармы-юкмы – барыбер! Ашлыгын төйи дә китә – басуыңда бер кило ашлык калдырмас. Бүген, Гариф Ахунов исән булса, авылдашларым хакында нәрсә әйтер иде икән? Элеккечә җәлләп, җан асрыйсылары килә, диярме? Шуңа өстәп, авыл халкының кешечә матур итеп яшәргә хакы бар, дигән нәтиҗәгә килер иде кебек тә тоела.

Әсәр хезмәт кешесенә зур ихтирам белән язылган. Юкка гына «Чикләвек төше» повесте авторның «Хәзинә» романы белән бергә 1973 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булмагандыр. «Чикләвек төше» әсәрендә җитәкче Саматовның гына түгел, авылдашларымның да рухи ныклыгы, төрле авыр шартларда җан асрый белүләре, председательгә үзләренең файдалы киңәшләрен биреп, рәхәт яшәргә омтылулары, гади чынбарлыктан алынып, шул ук вакытта сәнгатьчә матур итеп сурәтләнгән.

«Чикләвек төше»н укып бетергәч тә, битләрен яңадан актарып, аннан күпмедер вакыт аерыласы килмичә торылды. Гариф абыйга рәхмәтемне белдерәсем килсә дә, соң инде. Язучы китә, аннан кат-кат укырлык язган әсәрләре кала. Гариф Ахуновның да иҗаты әле тиз генә онытылмас, киләчәк буыннар аңа игътибарлы булырлар, дип ышанасы килә. Аларда татар халкының фаҗигале язмышы да, гасыр явызлыкларына каршы тора алучы көчләре дә, гүзәл яңалыкка, алгарышка омтылулары да – барысы да тормыштан алып язылган. Ә тормышчан әсәрләрнең гомерләре озын була!

*Гөлзадә Әхтәмова,*
шагыйрә,
Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия лауреаты

# Сиңа-килдек,-Остаз!

1997 ел. 50 яшьлек бәйрәмем уңаеннан туган авылым Кече Кирмәнгә язучылар килде. Ул вакыттагы район башлыгы Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин кунакларны бик җылы каршылады. Халык язучылары Гариф ага Ахунов, Илдар ага Юзеев белән дустым Зөлфәт, сабакташым Шаһинур Мостафин, үзебезнең җырчы Миңгол Галиев, Харис Нигъмәтҗанов җитәкләгән халык уен кораллары ансамбле туган җиремә, авылдашларга баш иделәр. Олы юлдан шактый читтә урнашкан авылның бәхетле көннәре иде бу. Гариф ага мин Язучылар берлегендә калдырган 28 хикәямне укып килгән икән.

– Болар – уймак хикәяләр, мин бик гаҗәпләндем, – диде ул, мәдәният йорты сәхнәсенә күтәрелгәч.

Моңа кадәр шигырь китаплары чыгарган һәм прозада сынаучы гына кеше буларак, олы язучыдан мондый сүз ишетү мине канатландырып җибәрде. Кычытканнар, бөтнекләр, бәрәңге бакчалары, хайваннар арасында мәш килеп яшәгән авторны колагыннан күтәреп халыкка күрсәтү иде бу. Минем кебек, бер сүз көтеп, башкаладан читтә, хәтта Татарстаннан читтә яшәп иҗат итүче авторларның яклаучысы, затлаучысы иде шул Гариф ага Ахунов.

Шәһидә апа белән гел кунакка чакырдылар. Киң күңелле хуҗалар яшәүче өйләрендә миңа да берничә тапкыр булырга туры килде.

Дүрт елдан соң тагын остаз янына килдем... васыяте буенча туган җире – Арча зиратына күмелгән Гариф абыема Язучылар берлеге, Мәдәният министрлыгы, Арча хакимияте затлы кабер ташы куйдырганнар. Баш иярга, дога багышларга, туган җире, туган халкының йөрәк җылысын тоярга баруыбыз.

Район хакиме Алмас Нәзировның гел саф татарча сөйләшүе, үзе күптәннән аралашып яшәгән Гариф агасына хөрмәте һәрдаим сизелеп тора. Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, берлек каршындагы Аксакаллар шурасы рәисе Мөсәгыйт Хәбибуллин, халык шагыйрьләре Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Нурмөхәммәт Хисамов, «Кызыл Ай» җәмгыяте президенты Мәдинә Маликова, шушы вакыйга мәшәкатьләре эчендә кайнап яшәгән язучы Шаһинур Мостафин Арча зиратында Гариф Ахуновның кеше, язучы, СССР күләмендәге дәүләт эшлеклесе буларак олы гамәлләрен искә төшерделәр.

Мин горурланып һәм гаҗәпләнеп тыңлап тордым. Дистәләрчә кеше башкарып чыга алмаслык эшләр майтарган Гариф абыебыз. Үзенең мәктәбе, дистәләгән шәкертләре булган остаз ул. 240 язучы гаиләсен фатирлы иткән берлек рәисе, шәрәфле академик, драматург, рәссам. Мәскәүдә ел саен татар язучыларының 30–35 китабын бастыруга ирешкән Гариф Ахунов бит ул!

Шәһидә апаның ныклыгына куандым. Олы рәхмәтен дә җиткерде. «Үземә калдырылган җирдә басып торам, миңа Гарифҗан янына килү бер дә куркыныч түгел. Ходай шулай насыйп итсен», – дип әйтергә дә көч тапты. Гариф ага рухына догалар укылды.

Гариф ага каберенә язучыларыбыз Мәгъсүм Гәрәев, Мәгъсүм Насыйбуллин, Җәүдәт Дәрзаман, Галимҗан Гыйльманов, «Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев,

галим Фәрит Хатипов, фоторәссам Мидхәт Шакирҗанов канәфер чәчәкләре салдылар.

Остазымның эчкерсезлек белән яшәлгән олы тормышына, изге рухына багышлап, Ходай Арча җирен ап-ак карга төрде. Көне буе сафлык эчендә йөздек. Көне буе сүз остаз турында барды. Илдар ага Юзеев хәтерли: «Берсендә кайсыдыр районга барабыз, автобус кибеткә туктады. Кердек, анда гармуннар саталар икән. «Син гармунчы бит, әйдә әле, гармун сайла, Илдар!» – дип эндәште Гариф абый. Бер искиткеч тавышлы гармун сайладым, ә Гариф абый, акчасын түләп, миңа аны бүләк итте».

«Татарстан Язучылар берлегендә бергә эшләгәндә, Вьетнам, Кытай, Һиндстан, Төркия, Франция язучыларын каршы алдык! – ди Мөсәгыйт Хәбибуллин. – Иң зур түрә янына кергәч тә, мәзәкләр сөйләп, мәсьәләләрне үз файдасына хәл итә иде ул», – дип искә алды.

Мәдинә ханым Маликова Ахуновның яшьләргә бик игътибарлы һәм ихтирамлы булуын ассызыклады.

Үзенең матди ягы турында аз уйлаган, күпләр җитешә алмаслык йөкне зарланусыз тартып барган Гариф Ахуновның Арча педагогия көллиятендә музеен ачу турында да җитди сөйләшү булды. Алмас Нәзиров төгәл вакытын да билгеләгәч, бу изге эшнең барып чыгасына шик юк. Арчалылар үз кешеләрен зурлый белә, ә үлгәннәрне зурлаудан да изге гамәл юктыр.

Арчалылар халыкны уята, тиешле рухи югарылыкта тота беләләр. Ике атна саен ике күмәк хуҗалык район үзәгенә килеп ярминкә үткәрә. Бу исә хуҗалыклардагы уңышларны күрсәтү, райүзәктә яшәүчеләрне очсыз азык белән сөендерү генә дә түгел, ә ярминкәгә килгән хуҗалыкларга караган авыллар, мәктәпләр, музейларның район халкы алдында исәп-хисап тотуы да икән. Бай тарихлы Арча авылларының горурлыгы булырдай зыялыларны да, хезмәт кешеләре – укытучылар, игенчеләр, терлекчеләрне дә лаеклы бәяләү, хәтерне яңарту, бүген яшәп ятучы буыннарга гыйбрәтле тәрбия бирү дә икән.

Йөрәгемдә җан эреткеч, Арча төбәгендә бу элек-электән шулай булгандыр дигән кайнарлык сиздем. Замананың ямьсез һөҗүмнәренә каршы торучы рухи көч эзләүне сиздем. Юкка гына татар әдәбиятының иң күренекле язучылары бу яктан түгелдер. Алга таба да бу шулай булыр, халкыбыз, киләчәгебез исән калыр дигән өмет уяна...

*Рафаил Газизов,*
шагыйрь, Татарстанның атказанган укытучысы

# Три-дня-с-Гарифом-Ахуновым

Однажды в июле 1984 года мне позвонил Гариф Ахунов:

– Слушай, ты не засиделся в своей квартирке? Мхом не оброс?

– А что?

– Да, может, двинем куда-нибудь вместе? Дня на три, а то и на недельку? В сельские просторы! Воздухом подышать, на мир поглядеть? Глядишь, и очерк какой-нибудь сообразим для газеты. Слышал, сейчас, говорят, урожай убирают. Ты видел когда-нибудь, как убирают урожай?

– И куда ты предлагаешь поехать?

– В Спасский район, то есть в Куйбышевский. У меня там друг. К нему!..

Гариф Ахунов в то время занимал должность председателя правления Союза писателей Татарии, друзья у него – с его-то общительностью – были везде, в каждом районе. Ну Спасский так Спасский, какая разница? И почему бы не рвануть в деревенские просторы в самом деле?

И вот уже «Метеор» летит по Волге. Позади бурлит, буквально кипит вода. За рыбой, поднятой волной, с отчаянным пронзительным криком охотятся чайки. Жара, июльский зной, вода нестерпимо блестит, как стекло.

На правом берегу Волги, вдоль которого мы идем, тянутся разрезы напластований – вверху коричневая глина, ниже белый известняк, серые доломиты. Венчает разрезы тонкий слой почвы. Если сравнивать ее с огромными мощными пластами нижних слоев земли, почвенный слой не толще лезвия ножа. Настолько мал, хотя природа создавала его миллионы лет. Однако он, этот пласт, и кормит человека. Собственно, мы и летим на «Метеоре» по Волге в Болгары, край древних булгар, чтобы увидеть, как этот пласт и человек сосуществуют друг с другом сегодня.

Когда-то я был геологом, что-то в памяти еще осталось, и я рассказываю Ахунову о том, что проплывает перед нами. Потом мы переходим на левый борт, рыжее яркое солнце бьет в глаза, ветер треплет волосы на голове Ахунова, по его лицу плывет блаженная улыбка:

– Люблю воду. Волгу люблю. Пишу сейчас роман «Дочь Волги». Мне приятен этот человек. Среди писателей не так уж много людей, с которыми мне было легко и просто.

Надо сказать, в советское время такие поездки были вполне обычным делом. Конечно, власти держали нас под бдительным присмотром, на страже была не столько официальная цензура, сколько бесчисленная рать всякого рода редакторов, внутренних рецензентов издательств, прочих чиновников, однако при всем этом писатели были влиятельной и значимой силой в обществе, власти с нами считались, в какой-то мере, возможно, даже побаивались и в большинстве случаев, если возникала, скажем, нужда в решении каких-то бытовых неурядиц, всегда шли навстречу. И, естественно, литераторы были желанными гостями всюду. Везде нас встречали как самых «важных» гостей, как «высокое начальство». Причем порой возникали смешные ситуации.



Гариф Ахунов Татарстан Язучылар берлеге террасасында каләмдәшләре белән. Казан, 1988

Я помню свои поездки по Таймыру – мы приземлялись на вертолете в дикой зимней тундре то возле стойбища ненцев или манси, то неподалеку от буровой. Накануне в Надыме нас накормили чем-то вкусным, но непотребным, у всех что-то случилось с желудком, и вот едва вертолет заглушил лопасти возле чумов, как дюжина писателей, один известнее другого, бросились врассыпную в тундру. Не получилось достойной встречи. С изумлением смотрели на нас заполярные аборигены.

В памяти ночевки и бесконечные разговоры и в запрятанных в заснеженных горах поселках добытчиков олова в Хабаровском крае, посещения гигантских алюминиевых заводов в Красноярске. Не забыть и иссушающую жару и ровный монотонный и днем, и ночью зной туркменской пустыни, хотя дело происходило в начале октября, встречи с пограничниками на границах с Афганистаном и Китаем. Везде обильные застолья, нескончаемые разговоры, речи. Неизгладимым в памяти осталось и неторопливое, подробное путешествие по сельской Литве, их колхозы представали тогда как необыкновенные видения или райские сады (никогда уже там не будут жить так)... Или по аулам и селениям горной части Башкирии...

В конце пятидесятых – начале шестидесятых прошлого века, отыскивая сюжеты и накапливая живые впечатления для романа «Клад», который Ахунов тогда писал, он дневал и ночевал на буровых промыслах юго-востока Татарии. Нечто подобное пережил и я, но уже в конце шестидесятых и начале семидесятых, когда на земле вокруг старых Набережных Челнов развернулось гигантское строительство комплекса заводов – три пьесы, целая трилогия, родились тогда у меня после поездок на Каму. Почему я теперь вспоминаю все это? Мы многое знали, многое видели. Литераторы в те годы были информированными людьми. Мы знали не понаслышке, чем дышит промышленность. Мы видели своими глазами то, что происходило в русской или в татарской деревне, и что



Гариф Ахунов, Сибгат Хәким һәм Диас Вәлиев Алабугада Марина Цветаева кабере янында. 1982

происходило с самим человеком, с его душой. Знали, как живет народ и куда движется страна.

После переворота в 1991 году вдруг в одночасье исчез куда-то многомиллионный читатель, ушла в небытие огромная, бескрайняя, в одну шестую мировой суши, разноязыкая держава, в которой мы жили, и словно как-то сразу усохла, повяла, стала почти невидимой или несуществующей значимость художника в обществе. Мы все внезапно обнищали. Наше слово перестало что-либо значить. В начале девяностых годов у меня, например, не стало даже денег на проезд в трамвае. Да и теперь вот уже семь с лишним лет я не могу по издательским делам поехать даже в Москву. На какие шиши? Но тогда, в июле 1984 года, только очень внимательный взгляд глубокого, дотошного наблюдателя мог бы обратить внимание на едва заметные признаки грядущего надлома. Мы были еще неискушены, излишне доверчивы, и страна лежала у наших ног как огромная земля еще не лишенной невинности надежды. Мы могли поехать с Гарифом Ахуновым куда угодно – хоть на Камчатку или на остров Сахалин. Нам вручили бы в бухгалтерии проездные, суточные, оплатили бы все расходы. Но мы мчались на «Метеоре» в Болгары. Обычная рядовая поездка. И в самом деле, почему бы на короткое время не отключиться от маеты за письменным столом? Не обновить впечатления?

«Метеор» пришвартовывается к дебаркадеру в затоне «Болгары». У трапа нас встречает Николай Гурьев, первый секретарь Куйбышевского райкома партии, хозяин района. Коренастый, среднего роста, энергичный, с доброй улыбкой на широком лице, изрядно обгоревшем на солнце. Объятия, восклицания. И Гурьев, и Ахунов чем-то похожи – оживлены, общительны.

– Три дня я целиком в вашем распоряжении, – говорит Гурьев. – Ваш гид. Сейчас с дороги перекусим слегка, а потом в путь!

Однако в райцентре он не удерживается, чтобы не завести нас в картинную галерею, что находится во Дворце культуры. Бродим по залу, смотрим на полотна Сергея Лывина, Виктора Куделькина, Александра Родионова, Валентина Карамышева, Эрота Зарипова, скульптуры Виктора Рогожина... Что-то приобрели куйбышевцы, а что-то подарили им и сами художники. Живописные портреты красавицы-доярки, рабочего свинофермы, вожака крестьянского восстания 1861 года Антона Петрова, групповой портрет крестьянок... Сейчас, когда я пишу этот очерк, я думаю мимоходом, что никогда уже живописцы с таким интересом и тщанием не будут писать людей из простого народа... Похваставшись картинной галереей, как не похвастаться районной библиотекой? Николай Гурьев затаскивает нас с Гарифом Ахуновым и туда. Здание новое, много книг. Но не это главное. Изюминка в том, что здесь имелись редчайшие книги XVIII и XIX веков. В Спасском уезде в старину было немало богатых дворянских и княжеских усадеб, от них остались ценнейшие книги о земле, о народах Азии, подшивки некоторых широко известных российских газет и журналов, в том числе, например, полная подшивка «Искры».

– Смотри-ка, какой фолиант! Не поднимешь, – удивляется Ахунов, с уважением поглаживая ладонью по переплету тяжеленной старинной книги конца XVII века.

– Специалисты из Казани приезжают и даже из Москвы, чтобы полистать все это, – не скрывая удовлетворения, говорит Гурьев.

После обеда в поселковом ресторане секретарская «Волга» мчит нас уже по полевым дорогам. Сколько было в тот день встреч и разговоров – с комбайнерами, с водителями машин, стариками, старухами, агрономами, бригадирами!

*Сиңа нәкъ кырык яшь тулган көнне рифма-ритм дигәннәренә (ягъни ул үлчәүләргә сыеша алмый) иелми-бөгелми язган багышлама*

Яланаяк килеш тә,
Чабата киенеп тә,
Ташлы сукмаклардан да,
Буразна буйлатып та

Атладың армый-талмый,
Ай-вайларга карамый,
Мәрмәр заллар үткәнче,
Дом пичәткә җиткәнче.

Инде сиңа кырык яшь,
Күпне кичерде ул баш.
Каләмең дә чарланды,
Шәйдә дә чаяланды.

Тагын кырык кат кырык ел
Каләмеңне нык тотып,
Шәһидә белән җитәкләшеп
Яшә, атла үрдән үргә,
Мыексыз* дустым минем!

Вә башка барлык изге теләкләрне теләп,
*Рафаил Төхфәтуллин*
*1965, 18 сентябрь*

***

Әгерҗенең төнге урманында
Ядкяр-истәлекләр алыштык.
Юмарт табигатьле Гариф Ахун
Бүләк итте миңа галстук.
Төннең үткәнен дә сизми калдык,
Нуры төште йөзгә ал таңның.
Ал галстук таккан, учак яккан
Балачакка мине кайтардың.
Зыялылар өчен, Гариф туган,
Чорлар һаман авыр булдылар.
Әтиемне допрос алган чакта,
Галстугы белән будылар.
Син дә кайчагында боегасың,
Әйтмәсәң дә, Гариф, беләм бит:
Яра булып калган йөрәгеңдә
Бандит дучар иткән ятимлек.
Сулыш алулары авырая,
Төшкә генә керә иркенлек,–
Зыялылар түгел, галстуклы
Зыялылар итә өстенлек.
Муеннарны кайчак бушаттылар,
Кайчагында каты кыстылар.
«Килер еллар гүзәл булыр» дигән
Зур хыяллар җилгә очтылар.
Их, чабасы килә ап-ак кардан,
Галстукны ташлап җилләргә!
Балачагын бигрәк сагынган, дип
Сүз әйтмәсләр бездәй җүләргә.
Иркенлек тә киңлек. Рәхәт монда.
Саф һавада җиңел тын алдык.
Күпме генә безне бусалар да,
Буылмадык, бик күп сыналдык.
Якты сагыш белән сагынырбыз
Кышкы карурманның ак карын.
Каләмемне ак урманга манып
Язган җырым булсын ядкярем...

*Илдар Юзеев,*
Татарстанның халык шагыйре
*Әгерҗе*
*1999, март*

* Мыексыз – ягъни кара мыегы кара төндә рәхимсез кыркылган.

## *Син калдырган юллар*

*Гариф Ахуновның 75 еллыгына*

Идел өсләрендә көзге томан,
Безнең офтанулар түгелме?
Кояшы да сирәк күренә шул,
Елмаюлар, Гариф, сүрелде.

Яңа гасыр, яңа өметләр дип,
Киләчәкне яшьләр көтәләр.
Яңа дуслар безнең булмас инде,
Иске дуслар, Гариф, китәләр...

Безнең гасыр безнең язмыш иде,
Нәкъ без кирәк идек аңарга, –
Сүрән күңелләрне җылытыйк дип,
Бергә-бергә, Гариф, янарга.

Егерменче гасыр даһиларын
Туздырды да, китте алып та.
Без аларга фикердәшләр идек,
Безнең чордаш иде Алыплар.

Гамәлдә гел сине юксынабыз,
Бәйрәм түрендә дә син кирәк:
Моңсу чакларны да күңеллегә
Куяр идең, Гариф, син көйләп.

Идел өсләрендә язгы томан,
Күтәрәләр уйлар-дулкыннар.
Якты булсын син калдырган еллар,
Синдәй, Гариф, көләч булсыннар!

*2000, 17 октябрь*

## *Хәтер ташы*

Сиңа әйтер җылы сүзләребез
Әйтелделәр микән барсы да,
Эчтән йоткан үкенүләр булып,
Яңгыр ява кабер ташына.

Матәм җире – фани дөнья чиге,
Һәркем үз вөҗданы каршында.
Кара кайгыларны күмә-күмә,
Карлар төшә бәгырь ташына.

Салкын җиргә җылы язлар килер,
Яшәү киләчәккә ашыга.
Яңа гөлләр, тагын күтәрелеп,
Башын ияр хәтер ташына.

*Шәүкәт Галиев,*
Татарстанның халык шагыйре
*2000, ноябрь*



Сулдан уңга: Шәүкәт Галиев, Рафаил Төхфәтуллин, Энҗе Мөэминова, Шамил Бикчурин, Гомәр Бәширов, Зәки Нури, Саҗидә Сөләйманова, Сәет Кальметов, Гариф Ахунов, Әдип Маликов. Әлмәт

## *Сагынамын*

Сагынамын Гариф Ахунов чорын –
Шаулап-гөрләп торган чакларны!
Язучылар йорты гел кайнады –
Дөрләп торгач хис учаклары...

Гариф ага, җан җылысын биреп,
Җанландыра белде һәр эшне...
Һәрбер сүзе – алтын бәһасе лә,
Һәрбер сүзе – тормыш дәресе!

Кызганмады күңел яктысын ул –
Мулдан сипте аны тигезләп...
Бер уйласаң, Гариф ага күңеле
Кояш белән гүя игезәк!

***

«Яшьлек яме»н йөрәгендә саклап,
Ул «Хәзинә» тапты гомерлек.
«Идел кызы»н бик яратты үзе –
«Чикләвек төше»нә тиң күреп!

«Хуҗалар»ын җирнең эзләде ул,
Һич калмады алар артыннан.
«Хыялый Хәйрүш егетләре»н дә
Очратты ул «Юллар чатында».

«Канатлар кая илтә?» – дип сорагач,
Әйтте әдип: «Дусларым янына!
И кадерле Туган як, Син барга
Йолдызлар яктырак кабына!»

«Без бит Арча яклары!» – дип, һәрчак
Горурланып яшәде ул – Тургай!
Аның кебек асыл затлар җиргә
Йөз елга бер килә, диләр... Шулай!!!

Гомер буе моңын сипте Илгә,
Таңнар аткач, мәңгелеккә күчте...
Үзеңнән соң Илаһи Нур калды –
Мәңге сүнми торган Йолдыз төсле!

***

...Сагынамын Гариф ага чорын –
Шаулап-гөрләп торган чакларны.
Язучылар йорты гел кайнады –
Дөрләп торгач хис учаклары!

Язучылар йорты... Нигә тынлык?
Ишетелми шат-көр авазлар...
«Учакларны дөрләтегез!» – диеп,
Безгә дәшә Гариф агалар...

Безгә дәшә Аяз Гыйләҗевләр,
Безгә дәшә Илдар Юзиләр...
Иҗат утын сүндермәскә кушып,
Прометейдай безне күзлиләр –
Таләпчәннәр, рухи тереләр!!!

*Шаһинур Мостафин,*
шагыйрь, Татарстанның атказанган
мәдәният хезмәткәре

## *Ялгышмам*

*Гариф Ахуновка*

Ялгышмам, мин сине «кояш» дисәм, –
Йөрәгеңнән җылы бөркелә...
Кем әйталсын, синең йөрәк җылың
Җылытмады, диеп, бер көн дә.

Ялгышмам, мин сине «кояш» дисәм, –
Күңелеңнән ак нур бөркелә...
Кем әйталсын, күңел нурларыңнан
Нур алмадым, диеп, бер көн дә.

Ялгышмам, мин сине «кояш» дисәм,
Ялгышмам, мин сине «дус» дисәм.
Синдә минем атам-анам теле,
Тукай теле – алмаз тел исән...
Һич ялгышмам, сине «дус» дисәм...

*Сафуан Мулла-Гали*
шагыйрь

## *Гел игелек кылдың кешеләргә...*

Камал театры моңсу бүген –
Матәм җыены... Гариф аганы
Озатабыз, дуслар, мәңгелеккә,
Хәсрәтемнең юктыр азагы...

Баш очында саклап торам Аны,
Фәрештәләр җилпи канатын...
Гариф ага, әсәрләрең укып,
Әткәм кебек күреп яраттым!

Тыныч кына ятасың Син үзең,
Йөзләреңдә – серле яктылык...
Исән чакта шаулашмыйча гына
Эшләдең Син бик күп яхшылык!..

Хәзер инде барлык гамәлеңне
Искә төшерәләр дусларың...
Гел изгелек кылдың кешеләргә –
Җирдә Синең юктыр дошманың!..

Гөлшәһидә ханым – янәшәңдә,
Йөзкәеңнән алмый күзләрен:
«Телгә килмәс микән Гарифҗаным,
Әйтмәс микән соңгы сүзләрен?!»

Наиләң дә шунда, киявең дә,
Барча якыннарың кайгыда...
...Васыятеңне үтәп, үзеңне без
Озатабыз Туган ягыңа!

Мөхәммәт Мәһдиевләр көтә анда,
Фәрваз Миңнуллиннар... Барчасы!
...Арчасына китә Ил Агасы,
Ялварса да Казан: «Калсачы!.»

*Равил Гозәиров*

шагыйрь, Татарстанның атказанган
мәдәният хезмәткәре

## *Тургай*

*(Гариф Ахуновка)**

Төн йокысын йокламыйча,
Кояш чыкканчы торып,
Ил агасы эшен башлый,
Беренчеләрдән булып.

Ул үзен «Мин тургай» диде,
Сайрар кош булгангамы,
Тургай белән бергә торып,
Эшкә тотынгангамы?

Тургай бит һич тә сайрамый
Агачка кунып кына.
Бер минут та үткәрмидер
Сайрамый торып кына.

Сокландыргыч тавыш белән
Сайрый ул оча-оча.
Нәни канатларын кагып,
Җиһанны коча-коча.

Чынлап та мин Ил агасын
Тиңлим шушы тургайга.
Ару-талуны белмичә,
Шундый эшчән булганга.

Тургайның дәртле аһәңе
Әсәрләренә күчкән.
Әнә, күктә тургай сайрый,
Ул да уянган күптән.

*Сәрия Бикмөхәммәтова*

шагыйрә

* Бу шигырь Гариф Ахунов исән чагында ук язылган иде.

## *Гариф Ахунов урамы*

Һәрбер урам – үзе җанлы тарих:
Бакый ага, Сибгат, Исәнбәт…
Мең истәлек сөйли һәрбер тәрәз.
Искә алганда без – исәннәр!

Шаян сүзең, ачык якты йөзең
Нурга күмә иде дөньямны.
Салкын кышта менә кабат уздым
Елмаюың калган урамны.

Җылы карашыңның яктысына
Күпләр сыйды – шаһит мин аңа.
Ихлас җаның коштай канат какты,
Син үпкәсез идең дөньяга.

Урамнардан урамнарга узам…
Синең урам… Менә тамаша!
Туп-туп басып тулпар аты килә –
Син яраткан җырдан кар аша…
Урам, буран күзләр камаша!

Бу тулпар ат – әллә Парнас аты?
Сине эзләп чыккан урамга.
«Язылмаган аның җыры калды!..»
Ат югалды кереп буранга.

Тәрәзләрдә утлар – сүзләр сыман.
Йортлар гүя синең китаплар…
Бу йортларда үскән Арсланнар*
Исемеңне мәңге кабатлар!

…Моңлы Казанымның урамнары
Меңәр еллык гомер юллары!
Алар, озын хәтер җебе сыман,
Бәйләп тора милләт улларын!

*Наил Касыймов,*
шагыйрь



## *Памяти родителей*

Душе не надо хлеба,
Душе не надо зрелищ.
Ей нужно только небо
И тишь укромных лежбищ.

Душой любимы звуки
Родной татарской речи,
Что от тоски и скуки
Легко тебя излечат.

Приеду тихой ранью
Я в Арскую глубинку,
Где на окне герани,
А за окном – рябины.

Где речка так же вьется,
Бежит среди холмов,
Где сердце громче бьется
И закипает кровь.

От зова наших предков,
Дыхания земли,
Где свою приют последний
Сородичи нашли.

*Наиля Ахунова*

* «Хәзинә» романындагы төп геройга ишарә.



# IV-бүлек.-ИСТӘ -ҺАМАН-ДА-ИСТӘ

# Җаны-кош-булып-кайтты

Беренче май бәйрәме көннәрендә мин бакчада – дачада булдым. Халык юк диярлек иде, күршеләрдән Марс Шабаевлар гына килгән. Бакчада эшләп йөргәндә, моңарчы ишетелмәгән кош тавышын ишеттем. Ул «һөд-һөд-һөд» дип әллә ничә тапкыр кычкыра да туктый. Шул кош безнең каенга да, алма агачларына да кунып кычкырды. Алмагачта күреп калдым: саескандыр, күкедер чаклырак кош икән. Инде мин өйгә кереп чәй эчеп утырганда, әлеге кош тәрәзә каршындагы агачка килеп кунды, күзем туйганчы, күңелем булганчы хәйраннар калып карап утырдым: башында кикриге бар, томшыгы нәзек кенә, озын, бераз кәкрәеп тора, үзе куе итеп ясалган сөтле чәй төсендәрәк, канатын җәеп җибәргәндә, аркылыга буй-буй карасы бар. Күңел дигәнең сәер бит ул, мин: «Әллә?! Әллә?!» – дип уйлап куйдым. Сез мине аңлагансыздыр инде... Күбәләк күрсәк, шулай дибез бит! Күңелгә юаныч иңгәндәй була.

«Һөд-һөд-һөд» дип кычкырган кошны 75 яшемә җитеп күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде бит! Нигә безнең бакчага килгән, тәрәзә каршына ник кунган? И күңел! Бигрәк боек, бигрәк җәрәхәтле чагың шул! «Һөд-һөд» дигәннән... Гарифҗан мәңгелеккә китәр



Гариф Ахунов хатыны Шәһидә һәм оныгы Ренат белән дачада. 1977

алдыннан, инде китеп баргач, күке килде бакчага, каеннарга кунып кычкырды, әйләнә-тирәдәге агач башларына кунып кычкырды, һаман-һаман безнең бакча өстендә очты, безнең бакча өстендә кычкырды. Моңа ни дисең? Аңарчы без күке тавышын наратлыктан гына ишетә идек, сөенә идек әле ишетсәк!

Әллә ниләр килә башка... Иң беренчесе – яратканмын икән! Бер җан, бер тән булып беткәнбез икән! Хәзер минем җаным түгел, кабыгым гына яшәргә калды инде – шулай тоям үземне. Аннан... Гарифҗанны мәңгелеккә озаткан көннәрдә яшьләй дә, олыгаеп та киткәннәр, аларның тол хатыннары булды күңелдә – кеше хәлен үз башыңа төшкәч кенә беләсең икән ул! Тау ишелгән төсле булып ишелде аларның хәсрәтләре күңелемә – бик күп, бик күп. Зөһрәләр калды бит боегып, Таһирлар китеп баргач. Бар сораганым Ходайдан – сабырлык!

*Якты көн, сабырлык бир миңа*
*Гомеремә җитәрлек, –*
*Шатлыгымнан шашынмаслык,*
*Кайгымны юк итәрлек!*
*Кайгымны юк итәрлек!*

Бу җырны Гарифҗан язган иде. Көен – Фасил Әхмәтов. Ул елларда әле «И Ходай!» дип язарга ярамый иде, шуңа Гарифҗан якты көнгә ялварды. Руслан Дәминов җырлый иде, Зөһрә Сәхәбиева да җырлый. Хәзер... Гарифҗан да юк, Фасил да, Зөһрәнең Таһиры – Хәйдәр дә... Ничекләр түзде, ничекләр исән калды икән Зөһрә?

Быел менә, 2001 елның 21 сентябрендә, Гарифҗан белән туйлар ясап өйләнешкәнгә илле ел тулыр иде, ягъни алтын туебызны үткәргән булыр идек. Бер гомер – озын гомер! Кулга-кул тотынышып, барысын бергә кичкәнбез – шатлыгын да, кайгысын да. Күпме



Гариф Ахунов хатыны Шәһидә белән. 1976



Гариф Ахунов хатыны Шәһидә белән Аккош күлендә. 1990 еллар

китап язылган, дәрәҗәләр алынган, дус-иш табылган, югалтылган! «Ә барыбер яхшылык җиңә яманлыкны!» дигән уйда калдык без Гарифҗан белән. Гомер азагына табарак килгән нәтиҗәле уйларның икенчесе шул!

Илле ел – гаиләбез гомере, ә бөтен бер гомерне язып буламыни?! Без бит әле – 1947 елның август айларында университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтихан тотып йөргәндә күрешкән, танышкан кешеләр, бергә-бергә лекцияләр тыңлап, имтиханнар тотып, бәйрәмнәр үткәреп йөргән кешеләр дә. Дүртенче курсларда инде кызлар-егетләр парлаша башлады. Безнең группадан иң беренче булып Дания исемле кызга Мәхмүт Хөсәен өйләнде, аннан Розалина Сабирова Ибраһим Нуруллинга кияүгә чыкты, аннан без өйләнештек, аннан Яхъя Халит белән Сания Сибгатуллина өйләнештеләр. Өчәр тапкыр туйлар ясап өйләнүчеләр бары без булдык. Гарифҗан, минем кулны сорап, димме инде, Маһирә апа белән Хәсән абый (җизни) янына үзе керде. Рөхсәт булгач, туйга әзерләнү башланды. Инде туйсыз гына үткәрик, дип караган идем, кая ул! Ахунов та булсын, туйсыз да өйләнсен! Апам белән җизнәмә рәхмәт! Сеңлесен шулай туйлап биргәнгә! Туйның беренчесен 1951 елның 21 сентябрендә Кремль урамы, 21 нче йортта уздырдык – сабакташларыбыз белән, икенчесен – олылар, туган-тумача белән, инде өченчесен – авылда Октябрь бәйрәме көннәрендә. Мәхмүт Хөсәен дә кайткан иде туйга, гармунчыбыз ул булды, ә Казанда гармунчы Азат Әхмәдуллин иде. Алдарак язган идем бит, бер гомерне ничек язып бетереп булсын, дип. Менә шул-шул...

Яшәп киттек шул йортның 17 нче квартирасында – Советлар Союзы Герое Павел Яковлевич Гурьяновларның бер бүлмәсендә. Эшкә «Дом печати»га йөгерәбез. Гарифҗан – «Совет әдәбияты» журналының секретаре, мин – «Пионер каләме» журналының хатлар бүлеге мөдире. 1953 елның 24 октябрендә Рәшит туды, безне квартирадан чыгардылар, ул елларда квартира табулар бик читен иде. Ибраһимнар, Яхъялар, без, Рашат Гайнанов-

лар, Зәет Мәҗитовлар – барыбыз да квартирасыз идек, эзләп, күченеп күпме интектек. Без әле аферист хатынга да юлыктык, бәясен-акчасын алдан алды да куып чыгарды кыш уртасында, бала белән без урамда калдык. Ярый әлеге дә баягы апам бар, ул Федосеев урамында квартирага кертүче бер әбине – Евдокия Алексеевнаны тапты. Рәшиткә өч яшьләр иде, ул әбине «мама-апа» дип атый иде, апамны – «әни-апа».

Шул кыйшык идәнле кечкенә генә бүлмәне (250 сум түләп яши идек, утын алып, электрга түләп, керосинкада пешереп) Бауман райисполкомы безгә язды. Бу хәл 1957 елда булды. Гарифҗанның иҗатында Әлмәт чоры башланган иде инде, без Әлмәткә күчеп киттек. Квартираны Нил Юзиевларга калдырдык. Ул еллар: «Исән калсаң, шул җиткән!» – дип яшәгән еллар иде бит. Уйлап кына кара: беребезнең бер торыр почмагы юк, өйләнешкән булабыз, бәбиләр алып кайткан булабыз! И тормыш... кырмыш!

1957 елдан 1968 елга чаклы Әлмәт чоры. Бик яраттым мин Әлмәтне! Гарифҗан нефтьчеләр яныннан кайтмый. «Хәзинә» романын, очерклар яза, Язучылар союзының Әлмәт бүлеген ачарга йөри, элек Казаннан Әлмәткә йөри иде командировкага, хәзер Әлмәттән – Казанга, Мәскәүгә. Ярты гомере юлда үтте аның. Тормыш ритмы да шуңа көйләнде – озатам-каршылыйм, чемоданын бушатам, юылган-үтүкләнгән кием-салым белән тутырам. Ул арада – 1959 елның 12 июнендә – кызыбыз Наиләне дә алып кайттым. Бакча участогы алдык, аны да карыйм, килә Казаннан кунаклар: Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Габдрахман Әпсәләмов, Аяз Гыйләҗевләр. Тагын бик күп, бик күп язучылар булды квартирабызда. Ул беренче катта, язучыларның Әлмәт бүлеге урнашкан «Дом техники»га якын гына иде. Мәскәүдән М. Луконин, Тельпугов, «Правда»дан Кошечкиннарның да булганы бар.




Гариф Ахунов көндәлеге

Әлмәт чоры... Бик күңелле, эшлекле үтте ул чоры Гарифҗанның. Күпме очерк язды ул нефтьчеләр турында! «Хәзинә», «Хуҗалар», «Юллар чатында» дигән китаплары басылып чыкты, ике-өч пьеса язды, аларны сәхнәгә куйдыруда мәш килде. «Тихий Дон»ның ике китабын тәрҗемә итте.

Гамил Афзаллар килде Башкортстаннан, Рафаил Төхфәтуллиннар Кенәрдән, Юныс Әминовлар Әгерҗе якларыннан; Әдипләр, Фазыллар, Сәетләр; без шау-гөр килеп, ярдәмләшеп яшәдек; Саҗидәләр, Сәетләр, Марсельләр союз члены булды. 1968 еллар башында Гарифҗанны Казанга Язучылар союзына эшкә чакырдылар, менә шунда кайбер дусларның эче пошты. «Вәт, малай, киләсе килгәндә килә, китәсе килсә китә!» диптер инде, киткән чакта озатырга да килмәделәр.

Димәк ки, Әлмәт чорында китаплар язылды, бакча үстерелде, Наиләбез туды, Рәшит сигезенче сыйныфны, рәсем мәктәбен тәмамлады. Гарифҗан белән минем кырык яшь тулу юбилее шунда үтте. Гарифҗан коммунистлар партиясенә керде, ул чорда безнең күпләребез билетсыз коммунистлар идек, коммунизм идеясе бик тә мавыктыргыч һәм ымсындыргыч бит.

Гаиләдә ул бик йомшак күңелле кеше иде. Без өйләнешеп тора башлауга, авылдан энем килде, ул дүртенче сыйныфны тәмамлаган иде, бездә – әлеге герой квартирасында торып калды (бөтенебез бер бүлмәдә яшәдек), сүз әйтмәде, бәгырькәем. Аннан, Рәшитне карарга дип, әни килде. Егерме җиде ел бергә яшәдек, ник бер авыр сүз әйтсен!

Мин дә каенанам белән, апасы, сеңлесе белән дус булдым. Аларның өе янды. 1964 елларда «Хәзинә» китабы типографиягә тапшырылган иде инде. Гарифҗан гонорарын – 10000 сумны тулаем аларга бирде. Бик зур, бик матур, җиде-сигез тәрәзәле йорт салып керделәр. Өйләренең зурлыгын, яктылыгын кайтып күргәч, утырып җыладым. Сөенечтән дә, көенечтән дә.

Юмарт иде, ышана иде кешегә, ярдәмчел иде. «Әти дә шулай булган минем, бер пот оны булса, сорап кергән кешегә ярты потын биреп чыгара торган булган», – дияр иде. И гомерләр! Үткән дә киткән! Бик авыр, күңелне авырттыра, үзәкне өзә торган нәрсә икән ул истәлекләр! Кая карама, кулыңа нәрсә тотма, барысы да аны хәтерләтә. Ул җырлар! Халыкныкы да, авторларныкы да – барысы да минем хәсрәтемне әйтеп җырлыйлар төсле. Яңа шул әле күңел ярасы, әле ябылмаган, җөйләнмәгән...

Әлмәттән 1968 елның августында кайттык. Гомернең Казан чоры башланды. Шулай ук китапларын язды. Татарстан Язучылар союзының башта секретаре, аннары председателе, «Казан утлары» журналының баш редакторы, культура фонды председателе булды. Ике тапкыр СССР Югары Советы депутаты булып сайланды. Шунда мин Мәскәү театрларына йөреп калдым (мине дә ияртеп бара иде сессия вакытларында).

Гарифҗан таң кошы иде, ягъни иртән сәгать биштә тора иде, шулай итеп кенә яза алды ул китапларын. Бар белгәне эш булды: «Унҗиде вазифам бар», – дип сөйләр иде. Китаплары басылып чыгу гаилә өчен зур шатлык иде. Һәр китабын миңа язып бирә торган иде.

Гомер итә-итә бер-береңң арасында иң татлы сүз булып әтисе, әнисе дип эндәшү кала икән. Бу сүзләрдә бөтен гомер чагыла.

Гариф Ахуновның 50, 60, 70 яшьлек юбилейларын хөкүмәт зурлап үткәрде, инде 75 ен үзеннән башка гына билгеләп үттек. 50 ел гомер эчендә китаплар язылган, балалар укып чыккан, аларны башлы-күзле иткәнбез, бакчалар үстерелгән, йортлар салынган – эш белән узган гомер. Үз көчебез белән, җан тырмашып, тырышып яшәлгән. «Ходайга шөкер!» дим. «Исән калсак, шул җиткән!» дип яши башлаган буын бит без.

Гарифҗанның ярты гомере юлда үтте. Кая гына барса да, озатып кала, каршы ала идем. Хәзер инде сагынып яшәргә генә калды...

*Шәһидә Максудова,*
язучы, тәрҗемәче

***Гульшахида***

# Я-и-город-белокаменный-(«Минем-кала-алуым»)

*(Отрывок из повести)*

*Повесть Гульшахиды* [*] *рассказывает о судьбе деревенской девочки Назии. Героиня повести приехала в Казань с мечтой стать настоящим художником. А пока что она готовится поступать в училище, занимаясь как «вольный слушатель» в художественной школе... Повесть во многом автобиографична, прототипом одного из действующих лиц, профессора Нурмухаммата Галикаева, стал Гариф Ахунов...*

*Кстати, эта повесть в переводе Рашита Ахунова вошла в сборник лучших прозаических произведений для юношества татарских писателей, изданный в Москве на русском языке в 1983 г.*

Август, сентябрь, октябрь, ноябрь, декабрь... Пять месяцев... Пять месяцев живу я в городе, большом и каменном, далеко-далеко от мамы, папы, от сестры моей Руфии, от всех. Соскучилась ужасно. Так хочется их увидеть, если б вы знали!

Бывало, только наступит рассвет, и мы уже на ногах, хлопочем по домашним делам, толковые и несуетливые. А потом хлопают двери, и все четверо на все четыре стороны. Мама – в школу, мы с Руфией – в соседнюю деревню, тоже в школу: отец, взгромоздившись на велосипед, катит в лесничество. А вечером он привозит какой-нибудь причудливый кусок дерева или древесной коры, затейливо переплетенный корешок и непременно спрашивает:

– Назия, глянь-ка. Этот корень ничего тебе не напоминает?

Я начинаю вертеть деревяшку так и сяк, поначалу ничего особенного не вижу, но потом проявляются или цапля одноногая, или медведь, или еще что...

Однажды Руфия, взяв такой узловатый корешок в руки, радостно воскликнула:

– Папа, да это же Шаяхмат-бабай!

И точно, со стола будто смотрел на нас согбенный, подслеповатый старичок с кривой палкой в руке.

Да, уже прошло пять месяцев... То ли уж тетушка Гульджихан недолюбливает мои стиляжные платформы, то ли «гаврош» тот самый, замысловатый ей не приглянулся, но как-то, придя домой, она мне говорит:

– Ты, Назия, бросила бы работу да взялась бы покрепче за учебу. Тебе ведь, деточка, не только рисование – русский язык еще надо сдавать.

---

[*] Шаида (Гульшахида) Абдрахмановна Максудова (1926–2009) – писатель, переводчик, член Союза писателей РТ. Родилась 29 ноября 1926 года в д. Уразаево Агрызского района Татарской АССР. Окончила татарское отделение филфака КГУ, училась в одной группе вместе с Гарифом Ахуновым, потом они поженились. Работала учительницей, журналистом, библиотекарем, библиографом... Переводила прозу русских и тюркоязычных писателей на татарский язык. Долгие годы заведовала библиотекой Союза писателей РТ. Ушла из жизни 7 февраля 2009 г. после тяжелой болезни. Похоронена рядом с Гарифом Ахуновым (1925–2000) на татарском кладбище в Арске.

О своей болезни я не пишу родителям ни слова. Решаю, что после декабря, в каникулы, съезжу домой, потом уж уйду с работы, а в школу буду ходить и с третьим, и с четвертым классами.

Откровенно говоря, я очень рада, что не поступила в училище осенью. Как бы я там училась! Что у меня за душой было – неумелые рисунки да свидетельство за восьмой класс.

Когда в каникулы приеду домой – будет о чем рассказать.

Забавного, что ни говори, было немало. Но я не обо всем расскажу. Ну, как я, положим, скажу про себя и про Рустема?

Однако рассказать все-таки будет о чем.

Однажды вышла такая история. Тетушка Гульджихан обожает кошек и котов. Дома у них живет черная, как уголь, и блестящая, как сапог, кошка Мурка. Каждый год она приносит котят. Их надо как-нибудь пристраивать. Одного я унесла Светлане в школу. Спрятала за пазуху, жду Светлану, что-то она запоздала. Садимся за мольберты, а ее все нет и нет. Пока я раскладываю кисти да краски, котенок умудряется удрать у меня из-за пазухи. Ну, думаю, пропала моя головушка, разгон будет – о-ла-ла! И что вы думаете? Наталья Карловна становится вся такая умиленная, кричит:

– Ой-ей-ей! Какая прелесть! Кыс-кыс-кыс! – И пытается поймать котенка.

А тот пускается куда-то под мольберты, под стулья. Мы бросаемся его ловить. Мебель летит, вода льется – светопреставление! Наконец, когда котенок начинает ужасающе громко протестовать, отчаявшись вытащить одну из своих конечностей из-под конечности кого-то из нас, его ловят и торжественно вручают преподавателю.

Оказывается, на этом деле не одна тетушка Гульджихан помешана. Наталья Карловна, к примеру, аж помирает от любви к кошачьим отпрыскам. Мне, естественно, ни од-



Арча Сабан туена – бөтен гаилә белән. Казан. 1978, июнь

ного слова лихого не говорится. Чем не весёлая история? Приеду домой – обязательно расскажу.

Еду домой на поезде «Казань – Киров». Арск, Кукмор, Можгу я вижу во второй раз. Земля белая-белая, а снег какой-то неровный, волнистый. Березовые рощи вдали едва заметны, словно дымком затянуты. Интересно, можно ли подобрать этот, чуть напоенный голубым, легкий и дымчатый цвет? А еще есть в нем красноватые искры. Красиво и удивительно воздушно. Ели на бескрайней белизне кажутся особенно темными, даже черными. Все шесть часов я сижу у окна, смотрю и не могу оторваться.

В Агрызе стоит трактор из колхоза, на нем добираюсь до соседней деревни, оттуда ножками до Кульбая. По скрипу снега под ногами соскучилась – ужас! С каждым шагом, с каждым шагом всё больше посвойски и дружелюбней скрипит он!

Наши все дома, как-никак под Новый год.



Шәһидә Максудова Кара Борын кушаматлы мәчесе белән. Казан, 1978

– Отпросилась? – спрашивает отец, поздоровавшись.

– Раньше отпустили. Велят медный кувшин да пару лаптей привезти, – добросовестно шевелю я замерзшими губами.

– Инструмент лапотный, кочедык там или еще что не надобно?

Вот всегда так. То ли шутит, то ли нет – непонятно.

Я и вправду не сказала родителям ни слова о своей болезни. Не хотелось беспокоить.

Все же, приехав из деревни, чувствую себя не в своей тарелке. Тело здорово, да душа не совсем. Я начинаю злиться, что не могу не думать о Рустеме, и потому, видимо, из обычной веселой, насмешливой Нажюк постепенно превращаюсь в отчаявшуюся глупенькую девчонку. Мне начинает казаться постылым даже мир моих рисунков, и это очень пугает меня.

Спасает же прежнюю Нажюк приехавшая в Казань выставка юной художницы Нади Рушевой, ушедшей из жизни в семнадцать лет. Прочитав об этом в газете, я бегу в музей изобразительных искусств.

Первый раз в музее так много народу и такая тишина. Строгое молчание сотен людей само по себе рождает определенное состояние души и готовит к чему-то большому, значительному.

Учителем Нади, ее наставником был академик Ватагин. В месяц раз она шла к нему с толстой папкой рисунков. Учитель-академик – это, конечно, не шутка! Но академик академиком, а ученик должен быть художником. Я вот полгода работаю по советам Натягунина. Из хроменького состояния вышла. Пишу акварелью. Мне уже подчиняется фломастер. А вот о темпере, офорте я имею понятие лишь по книгам... Работать, работать, засучив рукава, невзирая ни на что. Эти мысли проносятся в моей голове, когда я осматриваю первый зал, детские рисунки Рушевой. Но второй зал меня потрясает. За-



Гариф Ахунов хатыны Шәһидә һәм улы Рәшит белән. 1993

быв все, я погружаюсь в прекрасное, созданное моей тезкой. В 16 лет Рушева иллюстрирует «Войну и мир». Я перечитывала роман у Нурмухаммата-абый, и ее рисунки к этой грандиозной эпопее для меня чудесное откровение.

Надя создала свою Пушкиниану. Пушкин живет в душе ее, воплощаясь в каждой огненной и нежной линии. И этот Пушкин мне ближе, чем на портретах великих художников. Меня притягивают по-детски заостренный рот Пушкина, светлое облако легких кудрей – у других оно темное, это облако! Я ощущаю почти физически Надину смелость, решительность. Я раздосадованно спрашиваю у себя: «Почему я не пишу Тукая? Почему эта мысль даже не приходила мне в голову? Почему мне никто из старших не посоветовал сделать это? Почему бы мне не воплотить вот в таких же легких непрерывных линиях, в таком же светлом, радостном ключе моего любимого поэта – синеглазого Такташа? Надя Рушева рисовала богов любви и смерти. У нас нет подобных богов, понятия мои о них весьма отвлеченны, но есть же на свете Галиябану и Халил, Юсуф и Зулейха, носившие в себе большую любовь и знакомые мне с детства. Я вновь спрашиваю себя: как Рушева смогла так влиться в мир прекрасного? Отец у Нади – музыкант, мать – балерина, дед был художником. Ее подготовленность, следовательно, не ограничивается художественной школой, понимание прекрасного идет к ней от поколения к поколению, Надя живет в мире музыки, в мире танца. В пятнадцать лет она едет в Варшаву. В пятнадцать лет я впервые покидаю свою деревню. В пятнадцать лет я впервые встречаюсь с городской жизнью, непосредственно с искусством, о котором знала только по книгам. Передо мной еще дел – непочатый край! Вместо того, чтобы фанатически отдаться работе, я хожу разобиженная на Рустема Галикаева, жалкие слова произношу: он, мол, меня не замечает, он меня не признает. Да зачем ему меня признавать, он же пока недосягаем для меня: на гитаре играет, на фортепьянах, музыку со всего мира на магнитофон записывает. А если говорить без дураков, он же всю библиотеку отца-профессора прочитал, в том числе такое, о чем я и понятия не имею. Я должна догонять его, догонять безостановочно, и перегнать, и заставить его самого бежать за мной...

Устав от мыслей, я бреду по залу и вдруг застываю у автопортрета Рушевой. Я вспоминаю свой автопортрет! Вот почему Натягунин хвалил меня. Получается, я тоже в какой-то миг достигла Надиного мастерства, сумела перенести на ватман душу. Это окрыляет меня.

Я читаю отзывы о выставке Нади Рушевой. Меня бесконечно волнуют слова зрителей, их восхищение Надей, оценка академика Ватагина: «Я имею счастливую и ответственную возможность наблюдать развитие необычных способностей Нади Рушевой в тече-

ние одного года. Я вижу, что как художник она растет не по дням, а по часам. Ее рисунки далеко выходят за пределы «детского творчества», но и среди взрослых художников едва ли многие могут поспорить с легкостью ее техники, чувством композиции, с остротой ее образов, с ее творческим восприятием мира». И другие художники говорят о безупречности пропорций ее рисунков, легкости ее техники и изумляются прекрасным душам всех без исключения ее героев. «У нее даже бабы-яги и черти какие-то святые», – поражаются художники.

Надя очень рано усвоила технику акварели, темперы, офорта, мастерство ее в этих областях быстро росло, но особенностью ее всегда оставалась легкость линии, сразу, без подготовки и поправок проведенной карандашом или цветным фломастером. В переходный период, на что часто сетуют художники, у нее не замечается никакого спада, мечта ее по-прежнему звонка и чиста, и вот, совершенствуясь изо дня в день, в семнадцать лет... она умирает от кровоизлияния в мозг.



Яхшы кәеф: Гариф Ахунов улы Рәшит белән. 1995

Сглатывая подступившие слезы, выхожу из музея. Клянусь себе никогда не предавать тезку, продолжить начатое ею дело...

К нам приходит весна... Ветра еще морозны, но не холод несут, а свежесть, хмельную и бодрящую. Талые и мутные воды, выступившие на лед Казанки, будоражат душу какой-то новой радостью.

Вспоминаю полноводную Каму, голубоватую прелесть весенних лесов, чуть печалюсь и, подпоясавшись, бросаюсь на последний штурм.

Это моя последняя атака, выполнение клятвы, данной моей тезке – Наде Рушевой. Собрав все силы, не оглядываясь, не разбрасываясь по сторонам, я должна идти только вперед. Так мне наказывает учитель мой Натягунин. После того как я посетила выставку Рушевой, пишу портрет профессора Галикаева. Я стараюсь выполнить его так, как мне давно уже мечталось: на одном дыхании, смелой непрерывной линией. Для этого я целую неделю наблюдаю за профессором. Договариваюсь с ним на воскресенье, и мы остаемся одни в пустой, затаившей дыхание квартире. Профессор позирует. Поняв всю ответственность свою, я робею, теряюсь, в голове рой самых разных мыслей, не потому ли фломастер двигает не рука, а мое сердце.

Портрет я заканчиваю в двадцать минут. Мне кажется, что это очень короткое время, но «доводить» его я не хочу. И боюсь, что появятся лишние линии, попортят, забьют композицию. [...]

*Перевел с татарского Рашид Ахунов*

# Золотое слово, серебряный кушак

У него был заразительный смех, ясный взгляд и открытая улыбка человека, которому нечего скрывать и который больше всего хотел бы, чтобы вы улыбнулись вместе с ним.

Мало в чем так ярко проявляется личность, как в чувстве юмора, – и, может быть, в бытовом чувстве юмора более, нежели в собственном литературном. А пошутить Гариф Ахунов любил – неважно, проводил ли он в этот момент серьезное собрание, играл в бильярд или сидел за праздничным столом. Он был веселый человек, которого частенько поручаемые ему обязанности тамады не то что не обременяли – он выступал в этой роли с видимым удовольствием, и, вероятно, именно поэтому у него все так хорошо, практически профессионально, и получалось.

У всякого тамады есть любимые шутки. Помимо непременных «Позвольте мне опоясать ваше золотое слово серебряным кушаком» и т.п., это часто были короткие истории про друзей, и прежде всего про Расула Гамзатова – личности во многих отношениях легендарной и по числу рассказываемых апокрифов сравнимой с известными остроумцами Михаилом Светловым и Фаиной Раневской – скажем, о том, что ответил Расул некоей пожилой даме, обидевшейся на сравнение женщин с то приплывающими, то уплывающими от мужчин рыбками...

Друзей своих он любил нежно. «Если ты выстрелишь в прошлое из пистолета, будущее выстрелит в тебя из пушки», – процитировал я ему как-то гамзатовского Абуталиба – и сразу почувствовал, что любое доброе упоминание о его товарищах, их книгах и мыслях ему в радость.



Гариф Ахунов белән Шәһидә Максудова. 1991

Что касается легенд и быличек, рассказываемых давно уже о самом Гарифе Ахунове, то их тоже немало. Приведу только одну: будучи в Казани, Сергей Михалков будто бы сказал между делом Ахунову, что московские улицы чище казанских. «В Москве, – незамедлительно отреагировал Гариф абый, – дворниками татары работают...».

Иногда трудно сказать, почему память сохраняет те, а не иные характерные подробности речи близкого человека. «Спасибо за помощь слаборазвитым странам», – говорил обыкновенно Гариф Ахунович, когда ему помогали в каких-то мелочах – исправить пишущую машинку или принести от колодца воды на даче, и сейчас эта немудрящая шутка тоже кажется значи-

тельной – и потому, что человека с нами уже нет, и потому, что ты более отчетливо, чем раньше, понимаешь ее не просто как «дежурную» остроту, но и как проявление чувства собственного достоинства. Которое не позволяет похвале или благодарности быть чрезмерными – даже в устах человека, ни на благодарность, ни на похвалу другим никогда не скупившегося.



Наилә Ахунова ире – язучы Борис Вайнер һәм кызы Аида белән әтисе Гариф Ахунов һәйкәле янында. Арча, 2011

Имелись у него и излюбленные литературные примеры, что называется «из писательской кухни». Вот один из них, на тему «Как делается юмор». Герой рассказа едет в поезде и укладывается спать на ночь. «Можно написать, – говорит Ахунов, – так: «Мне было холодно, и я укрывался газетой», – и ничего смешного в этой фразе не будет. А можно: «Мне было холодно, хотя я укрывался газетой», и одно это маленькое словечко совершенно меняет окраску предложения».

В 1969 году в Казани побывал знаменитый итальянский сказочник Джанни Родари. Как многое понравилось у нас, и в числе этого многого – то, что сказал ему в одной из бесед Гариф Ахунов: «джан» означает «душа». Так вот, чтобы сказать такую приятную и глубокую вещь душевному человеку Джанни Родари, нужно было самому быть очень живым и душевным человеком. Не случайно многие из авторов этой книги вспоминают независимо друг от друга и даже независимо от самого характера их реальных взаимоотношений с Гарифом Ахуновым говорят о нем: «Мне его сегодня очень не хватает...».

О каждом ли из нас, когда мы уйдем, скажут то же?

*Борис Вайнер*
писатель, заслуженный деятель искусств РТ

# Истә -һаман-да-истә

Гарифҗан Ахунов... Без аның белән кан кардәшләр дә түгел, профессиональ яктан коллегалар да булмадык. Гади кеше өчен зур әдип-язучы бүтән кешеләрдән, дуслардан ничектер ераграк, өстенрәк тора. Ләкин минем өчен ул бер якын туганым кебек иде. Бер яктан, ул минем икенче буын туганым Шәһидә Максудованың ире, тормыш иптәше, гаилә башлыгы булса, икенче яктан, тормышны бик яхшы аңлый торган зур әдип. Яшьтән үк ярым ятим бала була ул, тормышның авыр эшләренә җигелә, кыенлыкларын кичерә, ләкин бирешми, максатларына ирешә. Үзе теләгән Казан университетының филология факультетын тәмамлый, яза башлый. Беренче китабы – «Яшьлек яме»ндә үзе яшәгән дәверне, замандашларын, аларның яшәешен, характерларын, хезмәтен, катлаулы мөнәсәбәтләрен һәр яктан анализлый. Нәтиҗәдә – безнең алдыбызда заманыбызның киң сурәте, картинасы ачыла, үзебезгә үзебезне аңларга да ярдәм итә. Аның әсәрләре матур сәнгатьчә тел белән язылган, бик җиңел укыла, анда нечкә күзәтүләр дә, тирән фикерләр, юмор да бар. Гариф Ахунов үзе дә юмор белән сөйләшә иде, һәм бу әңгәмәләр бик күңелле тәэсир калдыра иде. Г. Ахуновның юбилейларында булганда, якын кешеләренең, дусларының чыгыш-тәбрикләүләрендә ишеткәнем бар, ул киң күңелле, миһербанлы җитәкче, ышанычлы иптәш, чын дус булган, күп кешеләргә иҗат эшләрендә, тормышларында ярдәм иткән.

Менә шундый олы, күпкырлы талантлы язучы, ачык-көләч йөзле, саф күңелле, ярдәмчел кеше булып минем күңелемдә кала бирә Гарифҗан Ахунов. Минем аңарга ихтирамым бик зур.

*Гөлнар Газизова*



Гариф Ахунов туганнары һәм гаилә дуслары белән хатыны Шәһидәнең юбилеенда. 1996

# Мои-воспоминания-о-писателе-Гарифе-Ахунове


Шел уже третий послевоенный год.


Шәһидә Максудова (уртада). 1940

Наша семья – мама, папа, братишка и я – снова жили в нашем любимом сером доме № 21 с тремя балконами, что напротив Главпочтамта. В годы войны в нашем доме был госпиталь. С огромным трудом родителям удалось вернуться в нашу двухкомнатную квартиру с паркетными полами и резными дубовыми дверями с матовыми стеклами (которые к нашему возвращению оказались выкрашенными белой масляной краской). В 1947 году у нас жила и заканчивала 10-й класс мамина сестра Шаида апа. Потом она стала студенткой отделения татарского языка и литературы знаменитого Казанского государственного университета.

Помню ее скромной, хрупкой, невысокого роста девушкой с великолепными густыми темными вьющимися волосами до плеч, которые мы с ней иногда заплетали в толстые короткие косички. Мы с братом любили ее как нашу старшую сестру.

Однажды Шаида апа попросила у мамы разрешения собрать свою студенческую группу на какой-то праздник. По-видимому, это был праздник 7 ноября, было уже холодно. И один из молодых люде пришел в черных валенках. Забегая вперед, скажу, что это




Максуди нәселе (Шәһидә Максудова ягыннан) 5 гасырга якын исәпләнә һәм 12 буыннан да ким түгел



Шәһидәнең әнисе Йөзлекәй Максудова Гариф Ахунов гаиләсендә яшәде



«Йөзлекәй әби белән Кара Борын кушаматлы мәче портреты». Гариф Ахуновның хатыны Шәһидәнең туган көненә бүләк ителгән рәсеме. 1996, 29 ноябрь

был поэт Махмуд Хусаин, который отличался от остальных небольшим ростом и необыкновенной подвижностью, хотя был старше своих однокурсников. Он был одет в военную форму с брюками-галифе. Помню Розалину с восточным разрезом глаз, Резеду с длинными русыми косами, маленьких черноглазых Алмазию и Альфию, хохотушку Санию, улыбчивого белозубого Василя, высокого рыжего Яхъю, очень красивого Роберта, скромного черноволосого Гарифа Ахунова. Как мне показалось, там уже намечались парочки. И на самом деле, супругами стали потом Сания и Яхъя Халитовы, Алмазия и Фазыл Фасеевы, Гариф абый и Шаида апа. Застолье их было скромным, но в то время нам, еще юным школьникам, показалось шикарным: винегрет, селедка, вкусные белые плюшки, розовые пряники, бутылки с газированной водой (и не только с водой!). Молодежь веселилась, шумела, и мы с братом были счастливы, что нас не прогоняли.

Никогда не забуду, как маленький Махмуд Хусаин в своих больших валенках в одно мгновенье взлетал на наш венский стул и очень артистично читал свои стихи «Чебиләр», крутясь волчком и шумно хлопая себя по бокам. Я смеялась до слез и одновременно переживала: как бы он не свалился, продавив наш венский стул.

Гариф абый отличался не только ладной фигурой, но и светлой улыбкой и притягивающей добротой, которую не могли не почувствовать не только мы с братом, но и мои родители. Гариф абый с Шаидой поженились на IV курсе. Помню, на невесте было белое свадебное платье из китайского шелка, которое сшила наша милая и скромная портниха Нина Михайловна, что жила с дочерью в Пассаже.



Казанның медицина көллиятендә Гариф Ахунов, композитор Мәсгут Имашев һәм Наилә Ахунова белән иҗади очрашу. 1997

После свадьбы молодожены поселились по соседству, и мы продолжали общаться.

Вскоре родился их первенец Рашидик, которого я любила, как младшего братика, несколько раз водила его в фотостудию в Пассаж. Очень страдала, когда племянник болел, и уже тогда, будучи ученицей 9-го класса, мечтала стать врачом-педиатром. Рашид очень быстро научился говорить и удивлял всех своей грамотной татарской речью, сказками о Ходже Насретдине. Несмотря на тяжелое материальное положение и отсутствие своего жилья, в этой семье всегда царили хорошее взаимоотношение, уважение друг к другу. В их доме жило счастье.

Очень тяжело я перенесла разлуку с ними, когда Гариф абый предложили переехать в город нефтяников Альметьевск – возглавить Альметьевское отделение Союза писателей Татарстана. В дальнейшем я убедилась, насколько благотворными оказались эти десять лет как для семьи Ахуновых, так и для становления Гарифа абый как писателя.

Будучи студенткой третьего курса Казанского медицинского института, я попросилась на летнюю производственную практику в Альметьевск. После их холодной частной квартиры по улице Федосеевской в Казани двухкомнатная квартира на улице Чехова со всеми удобствами показалась мне такими хоромами! Однажды я услышала, как пятилетний Рашид, едва дождавшись с работы отца, взахлеб рассказывает ему: «Знаешь, папа, Наиля апа пожарила картошку, и мы с ней вдвоем съели почти всю сковородку! Знаешь, если посмотреть на Наилю апа со стороны, ее рот кажется очень маленьким, а когда ест – столько в него влезает, ужас!». Мы хохотали до слез...



Маһирә Максудова – Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы прототибы. 1927

Гариф абый часто приезжал в Казань. Больше всех его приезду, пожалуй, радовался мой отец – Хасан. Они искренне любили и уважали друг друга, как родные братья. Иногда по вечерам Гариф абый просил отца спеть что-нибудь старинное, и папа под аккомпанемент мамы на фортепьяно с большим вдохновением исполнял «Кара урман» или «Затунакай». (Когда отец уже был на смертном одре, он только Гарифу абый позволил побрить себя.)

Постепенно библиотека Ахуновых пополнялась и собственными книгами писателя, который с 1957 года стал членом Союза писателей СССР. Некоторые его произведения переводились на русский и другие языки. Мне было очень приятно, когда Гариф абый попросил меня помочь перевести его небольшой рассказ на русский язык. Тогда я, будучи в декретном отпуске, жила на даче с родителями в поселке Нагорный. Гариф абый ежедневно приезжал к нам туда, стараясь, правда, особенно не утруждать будущую маму.

Еще в Казани Гариф абый и Шаида апа познакомили меня с курсантом КВАТУ Назымом Мустафиным – младшим братом журналиста Фазыла Мустафина, семья которого тоже жила в Альметьевске. После того как я закончила медицинский институт, мы с Назымом поженились. А через год мы гостили в Альметьевске уже с сынишкой. Помню приветливых Фазыла абый и его жену Санию апа – прекрасную хозяйку и мать троих детей. Как прекрасно мы проводили время за городом, на дачах Мустафиных и Ахуновых! Между взрослыми бегали и резвились дети Мустафиных – Равиль, Фарида и Фарид и Ахуновых – Рашид с Наилей – голубоглазой, с пшеничными волосами девчушкой, которой тогда шел пятый год.

Большое впечатление на меня произвело знакомство с мамой Гарифа абый – Бибинур апа, с его сестрами Гайшой, Сажидой и младшим братом Ризваном. Помню их большую, светлую избу в шесть окон в маленькой (одна улица и несколько домов) деревеньке Училе под Арском. Расположена была деревня на пригорке рядом со старинным кладбищем, где уже давно никого не хоронили. Возле дома росли большие кусты черемухи и калины. Двор и улица поросли травой, потому что скотина там не ходит, ее сразу загоняют в хлев. Училинцы пили ключевую воду, а Казанку переходили вброд, чтобы выйти на шоссейную дорогу, ведущую в сторону Арска.

Особо следует отметить искреннее и теплое отношение Гарифа абый как к своим родным, так и к родственникам Шаиды апа, в частности, к ее матери Юзликай тутай. До сих пор в его кабинете висят портреты двух милых старушек – Бибинур и Юзликай в одинаковых позолоченных рамах.

Судьба моя сложилась так, что мне пришлось работать врачом-педиатром в разных городах нашей страны – Владимире, Оренбургской области, Сызрани. И всегда мне не

хватало рядом дорогих Шаиды апа и Гарифа абый, их дружеской поддержки, мудрого и доброго совета по простым и непростым житейским вопросам. Шаиду апа Бог также наделил литературным талантом: она член Союза писателей. После смерти мамы Шаида апа, оставаясь для меня старшей сестрой, в какой-то степени заменила мне родную маму и своей врожденной мудростью поддерживала меня в самые трудные минуты жизни.

Так случилось, что Гариф абый и Шаида апа еще раз сыграли решающую роль в моей личной жизни, познакомив меня с башкирским писателем Вазихом Исхаковым – тогда пятидесятилетним вдовцом. Они когда-то познакомились в Москве на литературных курсах писателей и стали дружить семьями. У В. Исхакова тогда уже были книги о Муллануре Вахитове, Хусаине Мавлютове, он работал над рукописями книг о генерале Чанышеве, Иване Зенцове.

Вазих познакомил меня не только с прекрасной и благодатной башкирской землей, но и с творчеством замечательных поэтов и писателей Башкортостана – Мустая Карима, Назара Наджми, Ангама Атнабаева, Александра Филиппова, Фарида Исангулова, Гилемдара Рамазанова, Шарифа Биккола, Роберта Баимова и многих других. Некоторые из них, в том числе и семья заслуженного художника и скульптора Башкортостана Зильфата Басырова, стали нашими близкими семейными друзьями. Как жаль, что многих общих друзей уже нет в живых, как и самих Гарифа Ахунова и Вазиха Исхакова. А их сближало очень многое: трудное голодное детство и юность, стремление учиться, ребячество, огромное чувство юмора, любовь к исторической литературе. Оба были непревзойденными тамадами, любили детей и молодежь, часто выступали в сельских и городских школах, клубах и т.д.

Невозможно еще раз не отметить необычайную широту души Гарифа абый, его особенный магнетизм. Их дом всегда был полон гостей. Однажды я была свидетелем совершенно неожиданной встречи-экспромта. Ахуновы жили на улице Новаторов в «хрущевке». Позвонил Гариф абый: «Шаида, я везу гостей, накрывай на стол. Всё». Шаида апа немного растерялась, попросила меня остаться, и мы засуетились. Через некоторое время пришел Гариф абый в сопровождении шестерых азербайджанских писателей. На столе выстроилось несколько разных бутылок, а скромное меню пополнилось закусками, фруктами. Один из гостей, многозначительно оглядев «апартаменты», бросил реплику: «Да, сразу видно, что Ахуновы живут только на свою зарплату». Возразить было нечего. А встреча получилась интересной: ели, пили, спорили, музицировали.

А я вновь и вновь не переставала удивляться терпению и мужеству Шаиды апа, которая в любое время суток всегда была готова без всяких возражений встретить любое количество гостей в своем хлебосольном доме.

Свой роман-трилогию «Дочь Волги» Гариф Ахунов вынашивал много лет. Я очень горда тем, что свою книгу он посвятил моей маме – Магире Абдрахмановне Максудовой. Она успела незадолго до своей кончины подержать в руках первую книгу романа. Мама стала прототипом главной героини – Нурии Уразаевой, а Габбас хазрат – это мой дед Габдрахман мулла, о трагической судьбе которого родители рассказывали нам еще с детства. Разумеется, очень много о своем трудном детстве и юности Гарифу абый рассказывала Шаида апа, многое он узнал из рассказов и мемуаров моих родителей. Помню, как однажды, будучи у нас в Уфе, Гариф абый сказал, что Вазих тоже одобрял эту глобальную тему и роман «Дочь Волги».

Жаль, что он не успел написать третью книгу.

Не верится, что Гарифа Ахунова, народного писателя, уже нет в живых, но люди такого масштаба не умирают в сердцах и памяти людей, которые шли с ними по жизни.

*Наиля Тукаева*

# Заметки-на-кленовых-листьях

## *Премия Гарифа Ахунова вручается юным талантам Арского района*

В Центральной библиотеке в Арске в пятый раз состоялось вручение премии имени Гарифа Ахунова (1925–2000), народного писателя РТ, лауреата Государственной премии имени Габдуллы Тукая, видного государственного и общественного деятеля, в области литературы и искусства – молодым талантам Арского района.

На праздник собрались педагоги, библиотекари, учащиеся, приехали казанские писатели, заместители председателя Союза писателей РТ Дамир Салихов и Вакиф Нуриев, я, а также редактор сайта «Культура и искусство в Татарстане» Елена Сунгатова, которые первым делом возложили цветы на могилу моих родителей...

Встреча прошла в очень тёплой, почти домашней обстановке, зал был переполнен. Награждения лауреатов премии имени Гарифа Ахунова чередовались яркими музыкальными и танцевальными номерами, поэтическими выступлениями самих лауреатов. В этом году их девять. Самой младшей Диляре Булатовой восемь лет, она занимается в Арской школе искусств, надо отметить, что у девочки прекрасные внешние данные и артистизм, она замечательно читает стихи на татарском языке. Несмотря на столь юный возраст, у неё уже много творческих достижений. Также всех взволновало выступление родной сестры лауреата в номинации «Публицистика» Айнура Галимова, который не смог лично присутствовать на церемонии награждения из-за тяжёлой болезни, приковавшей его к инвалидному креслу. Невзирая на серьёзные проблемы со здоровьем, он – пятикурсник КФУ, активно печатается в газете «Шахри Казан». Очень понравился присутствующим и ансамбль юных гармонистов в национальных костюмах, вообще, все выступления были запоминающимися... Лауреатов, участников праздника и гостей поздравили заведующая местным РОНО Рина Бадриева, а также зав. отделом культуры Ильнур Кутдусов и директор Арского музея литературы и искусства Ринат Фазлиахметов. А на память, по уже сложившейся традиции, в дар организаторам праздника и библиотеке были преподнесены книги с автографами гостей, а также все сфотографировались рядом с портретом Гарифа Ахунова работы известного художника Эрота Зарипова, друга писателя.

*Наиля Ахунова*
*2012*

# *Ветер с Казанки*

Кто мог подумать, что мы попадём в водоворот «бермудского треугольника» между социализмом с «человеческим лицом» и «диким» капитализмом? В «чёрную дыру» во времени и пространстве – без названия? И что не всем дано выплыть... А наши родители верили в светлое будущее, и им – идеалистам-романтикам, уже прошедшим, казалось, самые тяжёлые довоенные, военные и послевоенные времена: голод, войну, репрессии, разруху, нужду – пришлось потом труднее всего... Но они не озлобились и не ушли в себя...

Многие тепло вспоминают моего отца с его доброй, неповторимой улыбкой, 18 сентября 2015 года ему исполнилось бы 90 лет...

* * *

Наш диалог длился почти полвека и оборвался на полуслове.

«Жизнь прошла как не было, не поговорили...». Теперь придётся договаривать стихами, воспоминаниями, посвящениями. Когда уходит земля из-под ног – цепляешься за любую соломинку. И эта спасительная соломинка – стихи. Она их любила, знала множество наизусть, изредка читала свои, была не только талантливым поэтом, но и прозаиком, и переводчиком. С пониманием и сочувствием относилась к моим попыткам творческого самовыражения, была их первым читателем и критиком.

Любила наш сад возле Васильево, где летом многочисленные хвори словно покидали её, наслаждалась многоцветьем посаженных ею цветов, закатным небом, дымком самовара, пением птиц на рассвете: всё это, возможно, напоминало ей родные Агрызские края, детство в деревне Уразаево, юность, когда она работала сельской учительницей в суровые годы войны; делала вкуснейшее желе из красной и чёрной смородины, варенье из крыжовника, калиновую пастилу...

Всю долгую зиму мама ждала прихода летних дней, а в 2009 году не дождалась: морозная февральская ночь забрала её с собой в полнолуние.

Она похоронена на тихом татарском кладбище в Арске рядом с папой, на его родине, где бережно чтят память земляка. Парк и одна из арских улиц названы его именем, учреждена премия для молодых дарований Арского района, которая вручается в день его рождения – 18 сентября; в музеях и школах есть мемориальные экспозиции, где на многих фотографиях рядом с ним мама...

Отец посвятил ей немало прозаических и стихотворных строк, где называл её «моя счастливая звезда». Родители счастливо прожили вместе полвека и сейчас покоятся рядом, в окружении рябин, которые они так любили.

P. S. Это предисловие к моей книге стихов «Ветер с Казанки», она стала лауреатом Республиканского конкурса «Лучшая книга-2011», который проводят Министерство культуры РТ, Национальная библиотека РТ и ОАО «ТАТМЕДИА».

P.P.S. 16 августа 2011 года я получила сигнальные экземпляры своей книги стихов «Ветер с Казанки», посвящённой родителям. Она вышла в Татарском книжном издательстве, в неё вошло и это эссе с их фотографией, моей любимой, снятой в 1963 году в Альметьевске...

*2011*



Гариф Ахунов: «Минем иң зур казанышым – гаиләм!» 1993

## *Письмо из Арска*

«Спасибо, вам, дорогая Наиля, столько нового узнаю от вас. Сейчас буду гуглить, искать все названные вами фамилии, читать стихи и восторгаться людскими талантами. Недавно была в арской библиотеке, и тут на выставке на глаза попалась ваша книга «Ветер с Казанки». Я очень обрадовалась, такое шикарное издание, приятно взять в руки, с вашим замечательным автографом: «Я люблю Арск». Я тут же попросила выдать мне все ваши книги, какие есть, но, к сожалению, других книг не оказалось. Пришла домой и сразу начала читать, это было нечто. Стихи прекрасные и очень близки мне по духу, про природу, про любовь, про Арск, про своих родителей. Особенно меня потрясли ваши стихи, посвященные матери. Моей мамы нет уже 10 лет, ушла она от нас в 67 лет, добрейший души человек была, ангел. Жизнь была у нее непростая. И лежат наши мамы – ваша и моя – на одном кладбище. Так что каждую вашу строчку о матери пропустила через свое сердце. Стихи искренние, трогательные. Первый раз читала стихи и вникала в смысл, а затем по новой стала читать, обращая внимание на форму, стихи у вас разные по форме и жанру, и верлибр, и хокку. Я, может быть, впервые серьезно вчитывалась в хокку и осознавала прелесть застывших образов. Спасибо вам за доставленное удовольствие.

*С уважением, Резеда Сафина (Арск)*
*25.07.2013*

# Молитва

Воскресный майский день. Пригревает солнце. Весьма ощутимо, хотя утром прошёл дождь. Мы едем в Арск. Становится уже жарковато. На татарском кладбище в Арске сухо, хотя по пути – по оврагам и обочинам – там и сям попадаются небольшие островки нерастаявшего снега. Идём по знакомой тропинке мимо могил... Вот и пришли. Ставим корзины с цветами возле памятников на родительских могилах. Долго молчим. Прилетает пара белых бабочек-капустниц. Покружившись над нами, они улетают, потом снова прилетают... Пока я прибираюсь, солнце начинает основательно припекать. Прошу мужа сходить за Сарвар апа. Мы с ней дружим, она помнит моих папу и маму. У неё загорелое лицо и голубые, несмотря на преклонный возраст, глаза. 13 января 2013 года ей уже будет 80 лет... Белоснежный платок, повязанный по-татарски, подчёркивает свежий загар. «Приехали?» – спрашивает она и обнимает меня. Сарвар апа не слышит после дорожной аварии, но мы почти всегда понимаем друг друга. На плече у неё грабли. Но я уже успела прибраться. И она читает «дога» – молитву. А затем приглашает в гости к себе, её дом недалеко от кладбища, напротив мечети. На дорожку нам дочери хозяйки, Гульфия и Ильсия, заворачивают кучтэнэч – горячие, с пылу-жару эчпочмаки и беккены...

# Листая семейный альбом

Иногда начинаешь перелистывать жизнь как фотоальбом: мелькают лица, события, города – некоторые уже не помнишь, а некоторые врезались в память навсегда...

... Альметьевск, я на черно-белом фото, годовалая, щекастая и ушастая, на руках красивой, смеющейся мамы...

...Вот мне отец привозит из Москвы много-много конфет в красивых фантиках: «Мишка на Севере», «Красная шапочка», «Белочка»... Я радуюсь и обнимаю папу. Мне лет шесть. Мы с ним высыпаем конфеты в матерчатый оранжевый абажур и выносим во двор. Детвора налетает стайкой, вскоре идём домой налегке...

... А вот мы с любимой Юзликай эби возвращаемся из магазина. Мне года три-четыре. В авоське у неё разные продукты, в том числе и моё любимое шоколадное масло, она угощает меня им прямо на улице. Я вся перепачкалась, но счастлива. Я чувствую, что бабушка любит меня больше всех. Мы смеёмся-заливаемся...

...Вот я катаюсь на катке для малышей в нашем дворе, а брат на катке для взрослых играет в хоккей...

...А вот в парке за домом малышня играет в войну. Там намело огромные сугробы, и мы роем глубокие пещеры и ходы, настоящие катакомбы...

... А это мы на демонстрации с родителями, мне нравится кричать «Ура!» и махать ярким флажком, потом к нам приходят гости, вкусно пахнет мамиными пирогами, а бэлиш у нее просто объеденье...

... Я на новогодней ёлке со своим первым классом в Доме техники нефтяников, мама мне сшила чудесный костюм снежинки и в косички вплела пышные банты...

... А это мы уже переехали в Казань. Я, кажется, единственная с толстой косой ниже пояса среди моих одноклассниц с короткими стрижками...

... О, выпускной вечер в художественной школе: отец пришел вместе со мной, он счастлив, у него сияют глаза: у меня аттестат с одними пятерками по всем предметам. Папа, деревенский мальчуган, с малолетства мечтал выучиться на художника и всю жизнь любил рисовать в свободную минуту...

...Вот первый жених просит у моей мамы благословения, а она отвечает, что я ещё слишком молода...




Арча станциясендәге татар зираты. Гариф Ахунов (уртада), Шәһидә Максудова (сулда), Г. Ахуновның апасы Гайшә Ахунова (уңда) каберләре

...А вот будущий муж просит моей руки у папы, а он мудро отвечает, что выбор за мной. И улыбается... Кстати, мои родители потом ни разу об этом не пожалели...

## *Навещаю родителей*

На кладбище тихо. Островки оттаявшей земли укрыли живым ковром бабочки. Всех цветов и размеров, от мотылька до махаона. За воротами небольшого татарского кладбища в Арске снег там и сям таится по оврагам, ветер по-апрельски свеж, а здесь – царство бабочек. Это зрелище завораживает. Вдруг две белые бабочки взлетают прямо передо мной и летят, словно указывая путь...

*Папиной улыбкой*
*улыбнулся подснежник*
*На его могиле.*

*Осколки воспоминаний*
*пытаюсь склеить*
*слезами...*

*Воспоминания бесконечны:*
*перебираю чётки*
*всю ночь.*

# Рябина-с-улицы-Гарифа-Ахунова

18 сентября 2013 года я ездила в казанскую новую школу № 35 на улице Гарифа Ахунова, 10а в «Солнечном городе» вместе с подругой – журналисткой Еленой Сунгатовой. Там мы отметили неформально и символически день рождения папы в школе с директором и учителями – чаепитием с конфетами, вареньем и мёдом. Нам провели интересную обстоятельную экскурсию по всему зданию и кабинетам, Елена Сунгатова взяла интервью, сделала снимки школы и её окрестностей для фоторепортажа на своём сайте «Культура и искусство в Татарстане». Я подарила комплект авторских книг нашей семьи для библиотеки и информационного центра, рассказала о родителях...

Школа современная, светлая, с интересной архитектурой. Она открылась здесь 2 сентября 2013 года при участии первых лиц республики. Ребята учатся в одну смену, работают кружки и секции. Сегодня мы застали собрание родителей первоклассников, занимающихся спортивными и бальными танцами, которое вёл известный тренер Ревгат Тибаев.



2008 елның 4 июнендә Казанда Гариф Ахунов урамын ачканнан соң утыртылган миләш янында. Сулдан уңга: Илфак Ибраһимов, Наилә Ахунова, Зилә Вәлиева, киноактер Александр Филиппенко (Мәскәү), Туфан Миңнуллин, Рәкыйп Гаффар



Кстати, возле дома № 10, недалеко от школы, растёт рябина, которую 4 июня 2008 года мы посадили вместе с министром культуры РТ Зилёй Валеевой, популярными артистами Шаукатом Биктемировым и Александром Филиппенко, а также Туфаном Миннуллиным, Борисом Вайнером, Мусагитом Хабибуллиным и другими известными писателями на открытии улицы Гарифа Ахунова, она очень подросла за это время...

*Наиля Ахунова,*
поэтесса, заслуженный работник культуры РТ,
лауреат премий С. Сулеймановой и М. Горького




# V-бүлек.-АРЧА-ДАҺИЕ

# Арча-даһие-Гариф-Ахунов

Арча – данлыклы Казан артының үзәге.

Арча – бөтен татар дөньясының сөйләм һәм әдәби телен саклаган төбәк.

Арча – татар халкының тарихын аннан башка күз алдына китереп булмый торган «Ак як», татар милләтенең этник нигезен ачып салучы мәдәни феномен да ул.

Арчаның 1000 елдан артык тарихы бар. Халкыбызның тарихи, мәдәни, сәяси һәм икътисади традицияләре гасырлар дәвамында безнең җирлектә үсте һәм ныгыды.

Арча төбәгендә Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларыннан башлап формалашкан мәгърифәт һәм мәдәният бөтен татар мәдәниятенең нигезен тәшкил итә.

Казан арты, бигрәк тә аның үзәге булган Арча-Әтнә яклары, татар мәгърифәтенә һәм мәдәниятенә искиткеч күп шәхесләр биргән. Арча ягыннан гына да 60 лап язучы, 50 гә якын мәгърифәтче, 100 ләп фән әһелләре һәм 100 дән артык мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре чыккан. Болар барысы да Арча ягының искиткеч зур мәгърифәтле һәм мәдәниятле як булуы, аның олы тарихы хакында сөйлиләр.

Арча ягы шәхесләре мәгърифәт, мәдәният һәм сәнгать өлкәсенең күп тармакларында беренчеләрдән булулары белән дә сокландыралар. Габденнасыйр Курсави – ислам дөньясында дини реформаларга нигез салучы дин әһеле һәм мәгърифәтче, Шиһабетдин



Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Мостай Кәрим һәм башкалар

Мәрҗани – татар тарих фәненә, Габдулла Тукай – яңа татар әдәбиятына һәм теленә, Рәхмәтулла Әмирханов – татар сатирасына нигез салучы, беренче татар календаре бастыручы, Галимәтелбанат Биктимерова – хатын-кыз шагыйрәләрнең берсе, Галиәсгар Камал – татар драматургиясенә һәм театрына, Мәхмүт Галәү – татар тарихи романына һәм тарихи драмага нигез салучы, Хуҗа Бәдигый – татар халкының табышмак, такмак һәм такмазаларын беренче булып җыйнаучы һәм тәртипкә салып бастыручы. Халык язучыларыбыз Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиевләр һәрберсе үзләре генә дә Арча данын еракларга таратырга җитәр иде.

Әлбәттә, без, арчалылар, барыбыз да үзебезнең Тукай якташлары булуыбыз белән горурланабыз.

Габдулла Тукайның «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул» дигән сүзләренең нәкъ безнең Арча ягына кагылуын горурлык белән кабул итәбез. Чын мәгънәсендә районыбыз мәгърифәте, мәгарифе, мәдәнияте һәм икътисады елдан-ел үсә, районыбыз көннән-көн ныгый һәм матурая.

Гариф Ахунов – XX гасырның күренекле язучыларыннан берсе. Ул иҗат иткән дистәләрчә повесть, роман, очерклар һәм йөзләгән публицистик әсәрләр аны үзе исән вакытында ук классик язучы итеп таныттылар. Гариф ага Ахуновның иҗади эшчәнлегенә бәя бирү – әдәбият белгечләре эше. Ләкин без әйтә алабыз – Арча укучысы Гариф Ахунов әсәрләрен көтеп алып, зур кызыксыну белән, күңел биреп укый, ул иҗат иткән геройларны ярата, алар язмышы белән яши. Гариф абый, әтисе шикелле, һәр эштә дә әйдәп баручы, лидер иде. Ул актив тормыш һәм иҗат юлы үтте. Аңа 6 яшьтә әтисез калу җиңел булмагандыр. Туган авылы Кечкенә Өчиледә колхоз рәисе булган Ахунҗан абый 1931 елда вәхшиләрчә үтерелгәннән соң, яшь Гарифҗан ниләр кичергәнен үзе генә беләдер. Бәлки бу очрак кечкенә Гарифның аңын, фикерләвен, тормышка карашын үзгәрткәндер. Кечкенә Өчиледәге вакыйга бөтен Арча районы, Казанбаш ягы халкын кайгыга батырган, аларны берләштергән. Ахунҗан абый, Казанбаш авылындагы туганнар каберлеген башлап җибәргән олы шәхес буларак, арчалылар хәтерендә саклана. Күренекле драматург Кәрим Тинчурин да Кечкенә Өчиледәге вакыйгалардан читтә кала алмый һәм аны үзенең «Кандыр буе» пьесасына да кертә. Пьесада Ахунҗанның үтерелүе дә, Кечкенә Өчиле авылы да – барысы да тормыштагы үз исеме белән алынган.

Гариф Ахуновны язучылыкка Казанбаш авылы мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәнифә Абдуллина тәрбияләгән булса, үзешчән рәссам итеп Һидият Зыятдинов һәм Хәмзә Закировлар үстергән. Ул гомер буе аларга рәхмәтле иде.

Гариф Ахуновка табигый сәләте, аңы, тапкырлыгы һәм белеме иҗат сәхнәсенең түренә узарга, сәяси тормышның үзәгендә кайнарга мөмкинлек бирде.

Ул искиткеч дәрәҗәдә эшчән иде, үзен аямыйча соңгы сулышына кадәр җәмгыятебез өчен, яшь язучылар өчен, туган як кешеләре өчен борчылып яшәде. Ул күңеле белән һәрвакытта да безнең арада булды.

Гариф абый бөек шәхесләргә генә хас эчкерсез һәм талымсыз иде. Шуңа күрә дә ул бөек, көчле, шәхес, патриот. Ул туган ягын, арчалыларны яратты. Ел саен район алдынгыларын котлау кичәләренә, сабантуйларына кайта иде. Районыбыз уңышларына сөенә, казанышлары белән горурлана, кимчелекләргә көенә, җитешсезлекләргә борчыла иде.

Ул Арча турында, арчалылар турында начар сүзләр ишетергә теләмәде. Андыйларга турыдан-туры кискен рәвештә җавап бирә иде, һәм аның җавабы һәрвакытта да урынлы, үткен һәм нигезле иде. Ул «Казанбаш уңганнары» исемле очерк-истәлеген дә, казанбашлылар турында ямьсез бер мәкалә чыккач, җавап формасында язды. Гариф абый җанытәне белән арчалыларга ышана, аларның беркайчан да йөзгә кызыллык китермәүләренә инана иде.



Язучылар аллеясы. Арчада Туган тел көне. 2009, апрель

Гариф абый Ахунов язучы-публицист, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Мәгъсүм Гәрәев белән «Арча җиренең ачык китабы»н язып, арчалыларга бүләк итте. Аларның Арча игенчеләрен олылап «Солтанатлы Арча җире», «Арча – Татарстан игенчеләренең башкаласы» дигән бәяләмәләре гәзит битләренә күчте. Гариф абый авыл эшчәннәренең хезмәтен симфоник музыка, симфоник поэма, симфоник концерт белән тиңләде. «Икмәк симфониясе»н Арча игенчесе үзе яза, үзе башкара дип нәтиҗә ясады. Шуңа күрә дә Арчаның «Икмәк симфониясе», «Крестьян апассионатасы», «Яшел апассионата» бөтен республикага ишетерлек булып яңгырады.

Менә шундый иде безнең Гариф абыебыз, яклаучыбыз, яратучыбыз, әтиебез, аксакалыбыз!

Без Гариф Ахунов васыятьләренә тап төшермәслек итеп яшәргә һәм эшләргә тырышабыз.

Бөтен эшләребезне бөек якташыбызның үлмәс исеменә лаек булырлык итеп башкару, Арча җиренең данын тагын да арттыру – иң олы максатыбыз. Гариф Ахуновның:

*Мәңге тере, мәңге үлмәс*
*Классиклар, даһилар.*
*Гасырлар узганнан соң да,*
*Безнең белән яшиләр,* –

дигән дүртьюллыгы нәкъ менә үзе турында язылган кебек.

*Алмас Нәзиров,*
Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры,
2006–2014 елларда Арча муниципаль районы башлыгы

# Соңгы-бүләк

Алтмышынчы еллар башында мине Арча районына райбашкарма комитеты рәисе итеп җибәрделәр. Гариф Ахунов Арчаның Өчиле авылында туган, ә мин – Мөслим егете. Әмма Гариф белән тиз арада якташларга әйләндек. Якташлык хисе алга таба олы дуслыкка әверелде, һәм без гаилә дуслары булып яши башладык.

Шулай беркөнне Гариф Ахунов миңа болай ди: «Тимерхан дус, син миңа бик охшыйсың бит әле, характерың да, кешелек сыйфатларың да минеке кебек. Мин синең турыда китап язам әле». Мин аңа үземнең тормыш юлымны сөйләп бирдем. Ахунов бик игътибар белән тыңлады, язып та барды һәм: «Синең бала чагың минеке кебек ятимлек һәм фәкыйрьлек белән үткән икән», – дип куйды. Без Гарифҗан Ахунҗанович белән бер елда туган да әле, аерма ике генә ай.

– Ун елдан артык Әлмәттә яшәдем, әмма Мөслимгә барып чыгарга туры килмәде. Инде Мөслимдә туып үскән, шунда яшьлеген үткәргән, эшләгән һәм укыган, акылфигыль формалашкан Тимерханның туган-үскән төбәген күрергә тиеш мин, – диде ул миңа һәм, туксан икенче елның июлендә Мөслимгә килеп, район үзәгендә, Олы Чикмән, Вәрәшбаш (мин туган авыл), Иске Вәрәш, Ольгино, Шуган авылларында һәм башка урыннарда булдык. Гариф Ахунов Мөслимнең табигатен, кешеләрен бик ошатты. (Казанга кайту белән үк, «Без, татарлар, яшибез әле...» дигән зур күләмле очерк язып, «Татарстан хәбәрләре»ндә бастырды да). Ул район үзәгендә халык белән очрашу үткәрде, инде яза башлаган «Тимерханның яшьлеге» дигән документаль повестеның беренче бүлекләрен укыды һәм кешеләргә шундый сорау бирде: «Бу язманы китап итеп бастырырга буламы инде, төзәтмәләр яки дөреслеккә туры килми торган урыннары юкмы?» – диде. Залда утыручылар барысы да: «Дөп-дөрес, озакка сузмагыз», – диделәр. Әлеге по-





Гариф Ахунов туганнары һәм гаилә дуслары белән: Светлана Тукаева, Рөстәм Тукаев, Тимерхан Борһанов, Наилә Тукаева, Шаһидә Максудова, Асия Борһанова, Наилә Ахунова. Казан, 1990 еллар азагы

весть басылып чыккач, Ахунов мондый автограф калдырды: «Аллага шөкер, яшибез әле болай булгач».

«Тимерханның авыл юллары» исемле икенче повесте «Казан утлары»нда басылып чыккач, ул мондый сүзләр язып куйган иде: «Тимерхан дус, синең 70 яшьлегеңдә мин, көнен көнгә туры китереп, беренче китапны бүләк иткән идем. Инде менә нәкъ туган көнеңдә икенче повестьны бүләк итәм. Азаккы өченче повестьны язарга да Ходай Тәгалә насыйп итсен. Гариф Ахунов. 11 июль, 1996 ел». Ходай насыйп итте үзе, 1999 елның февраль аенда «Тимерханның эзләнүләре» дигән өченче повесте «Казан утлары»нда дөнья күрде. Бу уңайдан Гариф болай дип язды: «Менә, кадерле укучым, Тимерхан Борһановның тормыш юлы турындагы өченче повесть тәмамланды. Мин аңа юлыгуыма, алай гына да түгел, аның белән бергә бөек Тукаебызга музей салуның шаһиты булуыма шатланам. Мин бик күп повестьлар, хикәяләр, очерклар, романнар, әдәби портретлар яздым, пьесаларымны куйдырдым, урысчадан җиде роман тәрҗемә иттем, классик пьесаларның тәрҗемәләрен эшләдем, тематик фильмнар өчен сценарийлар иҗат иттем. Әмма бер шәхескә багышланган өч повестьны беркайчан да язганым юк иде әле. Тимерхан Борһановның тормышы егерменче гасырның барлык вакыйгаларын сыйдыра».

Соңыннан өч повесть «Тимерханның күргән-кичергәннәре» дигән аерым китап булып чыкты, бу аның илле бишенче китабы һәм үз гомерендә соңгы китабы булды. Ә минем өчен соңгы бүләге иде.

Әлбәттә, бу китап миңа үзем турында язылуы белән генә кадерле түгел. Анда Татарстан тарихының тулы бер чоры сурәтләнде, халык арасыннан 170 кешенең образы бар иде. Ул кешеләрнең күбесе әле дә исән һәм олуг язучыбызны күңел түрләрендә саклыйлардыр.

*Тимерхан Борһанов,*
хуҗалык эшлеклесе

# Близкий-сердцу-родной-край

У Гарифа Ахунова есть замечательные стихи о родном крае. Разве появились бы прекрасные чувства в сердце прославленного писателя, если бы он не ощущал гостеприимства, уважения и теплого отношения арчан, руководства района по отношению к себе?

Еще при жизни Гариф Ахунов был дорогим гостем в Арске, наставником для юных писателей. Встречи со школьниками, учащимися профессиональных училищ, населением в родном краю вдохновляли его на новые творческие работы. Он писал повести, романы, критические и публицистические материалы, в его сердце рождались стихотворные строки, свои чувства он также изображал и на рисунках, Г. Ахунов являлся и выдающимся общественным деятелем. Его произведения ставились на сценах театров, по ним снимались фильмы.




Арча районы Казанбаш урта мәктәбендә Гариф Ахуновны искә алу кичәсендә. 2010

К счастью, есть кому продолжать дело известных писателей. Такое чувство, что Гариф Ахунов жив, вот-вот с улыбкой на лице выйдет на сцену и лично вручит талантливой молодежи награду, потому что его душа всегда с нами.

Участие на мероприятии главы муниципального района Алмаса Назирова, народного поэта Роберта Миннуллина, председателя Союза писателей Рафиса Курбана, поэтессы, дочери Г. Ахунова Наили Ахуновой, поэта-земляка Наиля Касимова сделало его более торжественным. Алмас Назиров, хорошо понимающий мир писателей, как это было отмечено и гостями из Казани, сказал:

– Произведения передаются из поколения в поколение, молодые достойно продолжают дело своих предшественников. Наш район славится своими писателями. Габдулла Тукай, Гумер Баширов, Гариф Ахунов, Мухаммат Магдиев...– это наши маяки, указывающие путь молодому поколению.

Родной язык, посредством тебя доводим до народа все, что на душе... Всех взволновало стихотворение Лены Шакирзян «Родной язык» в исполнении ученицы третьего класса гимназии № 5 Диляры Булатовой.

*Родной язык...*
*Горше, чем полынь,*
*Слаще, чем мед.*

*Румия Надршина*,
журналист



Гариф Ахунов Казан дәүләт консерваториясендә. 1988

# Музейда-якташыбыз-истәлекләре

Арчаның Әдәбият һәм сәнгать музее 1995 елның 26 апрелендә ачылды һәм бүгенге көндә Казан арты тарих-этнография музееның әдәбият-сәнгать бүлеге буларак эшли. Гариф Ахуновка багышланган экспозициядә Әлмәт шәһәрендә бергә яшәп иҗат иткән язучы дуслары бүләк иткән ике тумбалы өстәл һәм урындык урнаштырылган, шулай ук якташыбызның барлык әсәрләре һәм кулъязмалары, үзе ясаган картиналар, тормыш юлын чагылдырган фотосурәтләр, төрле елларда бүләк ителгән сувенирлар, газета-журналлардан истәлекләр һәм башка әйберләр тупланган.

Гариф абый Ахунов, музейга үзе язган әсәрләрен бүләк иткәндә, аларның һәркайсына киләчәктә дә зур әһәмияткә ия булырлык фикерләр язып калдырган.

Туган ягы – Арча районы кешеләре һәм аларның уңышлары белән горурлану хисләре ачык чагылган истәлек язмалары аның эчке кичерешләрен аңларга мөмкинлек бирә.

«Хәзинәләр эзләп Арчадан киткән идем, «Хәзинә»мне Арчага кайтарам. Арчаның Әдәбият-сәнгать музеена хөрмәт белән якташыгыз Гариф Ахунов. 12.04.95» дип язган якташыбыз 1963 елда чыккан «Хәзинә» романына, ә «Без бит Арча яклары» китабы тышына «Арчаның Әдәбият-сәнгать музеена бүләгем. Бу китап тулаем Арча турында.



Дачада (сулдан уңга): шагыйрь Наил Касыймов, Гариф Ахунов һәм композитор Фасил Әхмәтов. 1995



Арчада Гариф Ахунов исемендәге паркта чыршылар утырткannан соң. 2005

Мин, якташыгыз, Сезнең 1990 еллардан башланган зур, таң калырдай уңышларыгызга чиксез шатланам. Гариф Ахунов. 12.04.1995» дигән истәлек язылган.

1959 елда дөнья күргән «Юллар чатында» китабы тышына Гариф абый: «Бүләк ителми!» дип язылган булса да, Арчаның Әдәбият һәм сәнгать музеена бүләк итәм. Гариф Ахунов. 12.04.95» дип истәлек язган, ә «Габбас хәзрәт» китабына: «Арча әдәбият-сәнгать музеена башкортча чыккан китабымны бүләк итәм. Минем өчен иң кадерле булган Арча районы халкына Татарстанда гел беренчелекне телим. Бәхетле булыгыз, туганнарым! Гариф Ахунов. 27 апрель, 1997. Арча» дип язган.

Гариф Ахунов үзе исән чакта ук үзләренең гаилә китапханәләреннән ике йөздән артык китапны музейга тапшыра, аларның күбесендә күренекле язучыларның яки каләм тибрәтә башлаган яшьләрнең истәлек язмалары бар.

«Шигырьнең җылысын кул белән түгел, йөрәк белән сизә торган Гариф исемле егеткә Шәйхи Маннурдан. 2.12.54. Казан» – бу истәлек автор тарафыннан язылып, аның шигырьләре һәм истәлекләре тупланган «Туган ягым» дип исемләнгән җыентыгында саклана.

«Минем үтә кыюсыз, үтә зәгыйфь поэтик тавышымны әткәм чүкесе тавышы кебек көчле итеп дөньяга фаш иткән шагыйрь табигатьле дустыбыз Гариф!

«Ефәк яулыгым»ны Сиңа истәлек өчен бүләк итәм. Әгәр мин бу китапчыгымны язу белән игътибарга лаеклы берәр эш эшли алган булсам, анда син хаклы рәвештә үзеңнең дә хезмәтең бар дип хисапла!

Китапның соңгы битенә күзгә чалынмый торган итеп кенә язылган «Синең исемең миңа һәрвакыт әнә шул хезмәттәшлекне хәтерләтеп торыр. 1 май, 1962 ел» дип үзенең истәлеген яза шагыйрә Энҗе Мөэминова.

«Шәһидә һәм Гарифка – сезгә үзләшеп, сездән көнләшеп, Ә. Атнабаев. 3.VI.66.Тәтешле» дигән язма Әнгәм Атнабаевның «Туган туфрак» китабында урын алган.

«Гариф илә Шәһидә дуслар!

Алла боерса, без дә яңа пьесалар язарбыз әле дип, искеләрен чыгарып ятабыз. Китапка кергән беренчесе сезне хәтерләтә. Яңавыл, Тәтешле якларында мин аны көн дә бер картиналап сезгә укып йөргән идем.

Сезгә, зур бәхетләр теләп, Әсгать Мирзаһитов. 1968, 22/XI. Уфа» дип, очрашуларын искә алып, автор үзенең «Пьесалар» китабын бүләк иткән.

«Хөрмәтле Гарифҗан якташ! Бу китапның камилләшүенә синең акыллы киңәшләрең бик зур ярдәм итте. Рәхмәт сүзләре белән Г. Бәширов. 17.XI.77» дип язылган якташыбыз – Татарстанның халык язучысы Гомәр ага Бәшировның «Җидегән чишмә» китабында.

«Гүзәл син Хәят» дип исемләнгән пьесалар җыентыгына «Кадерле дусларым Гөлшәһидә, Гариф! Сезне чын күңелдән якын күреп, җитмеш яшьлек япь-яшь егет Риза Ишморат. 14.X.73» дип, Р. Ишморат истәлек сүзләре язган.

«Үрләрдә имәннәр шаулый» китабының алгы битенә «Гариф Ахуновка. Таныш булганнан бирле дошманнар булмадык, тормышның бик шау-шулы елларын бергә-бергә эшләп үттек, безнең гомерләр бик мәгънәле булды. Исән-саулар булып, күп эшлик әле. Гамил Афзал. 1 октябрь, 1981 ел. Әлмәт» дип язып, бергә эшләгән елларын искә алганнар.

«Хөрмәтле Гариф абый! Гел шулай бергә-бергә, кулга-кул тотынышып яшәргә дә яшәргә иде. Мөдәррис Әгъләмов. Гыйнвар, 1991» – бу истәлек язмасы шагыйрьнең «Мин әйттем...» шигырьләр җыентыгында язылган.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Гариф абый Ахуновны, шулай ук Гөлшәһидә апаны һәр каләм иясе үз иткән, аларның ярдәменә таянганнар, фикерләрен аңлап кабул иткәннәр, озак еллар иҗади дуслыкта яшәгәннәр.

Минем үземә дә Гариф абый белән берничә тапкыр очрашырга, аларның гаиләләре белән аралашырга туры килде. Гариф абый рәссам Эрот Зарипов белән 1998 елның 25–26 май көннәрендә районга килде. Үзе укыган Казанбаш мәктәбендә, туган авылы Кечкенә Өчиле җирләрендә, Сурнар урманчылыгында һәм Казансу елгасы башланган урында булдык. Ә икенче көнне Яңа Кырлай һәм Кушлавыч авылларындагы Габдулла Тукай, Арчада Әдәбият һәм сәнгать музеенда, үзәк китапханәгә бардык. Ул көннәрдә кызыклы очрашулар, әдәбият сөючеләр белән әңгәмәләр күп булды. Казанбашта Гариф Ахуновның үзенең якын дусты – Социалистик Хезмәт Герое Мирбат Хәстиев белән очрашуы истә калган. Ул вакытта мин аның әдәбиятны һәм сәнгатьне тирән аңлавына, гадилегенә, һәркем белән тиз аралаша алуына, шаян сүзле булуына сокланып йөргән идем.

Гөлшәһидә апа һәм Гариф абый Ахуновлар, алдан күреп, музейга үзләре исән чакта ук булышып, иҗатларына бәйле материалларны тапшырып бардылар. Алар Арчаны, районыбызны бик яраттылар, халкыбызны хөрмәт иттеләр.

Бүгенге көндә аларның кызлары Наилә Ахунова безнең музей белән элемтәне өзми, әти-әнисенең һәм үзенең иҗатына бәйле яңа экспонатлар бүләк итеп, музей фондларын һәрдаим баетып тора.

Еллар үткән саен, Гариф Ахунов иҗаты белән кызыксынучылар артканнан-арта бара, без дә аның иҗатын өйрәнүне дәвам итәбез.

*Шәфигулла Гарипов,*
Казан арты тарих-этнография музее директоры урынбасары

# Арчалар-хәтерендә

Мин Гариф абый белән 1974 елда Арча район Советы башкарма комитетының мәдәният бүлеген җитәкли башлагач аралаша башладым.

Ничектер беренче очрашудан ук безнең арада иркен, җиңел бәйләнеш барлыкка килде. Гариф абый бик эреләнмичә, миңа туганнарча карап, үзенә җәлеп итте. Андый мөгамәлә булганда, аралашырга да, сөйләшергә дә, эшләргә дә җиңел бит.

Гариф абый белән миңа мәдәният бүлегендә генә түгел (1974–1980), ә бәлки район Советы башкарма комитеты рәисенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары булып эшләгәндә дә (1981–2002) күп мәртәбәләр очрашырга туры килде. Мөгаен, аның белән иң күп аралашкан кеше Арчада миндер. Чөнки безнең очрашулар Арчага кайткач кына түгел, ә бәлки Казанда да күп була иде. Аның белән киңәшләшү, фикерләшү җиңел иде, анда яшьләргә әтиләрчә карау, аларга ярдәм итәргә тырышу, киңәшләрен бирү сәләте көчле иде. Шуның белән ул үзенә тарта да иде. Гариф абыйның башлап язучы яшьләргә ярдәм итәргә тырышуы шуннан килгәндер. Һәм ул бу өлкәдә күп эшләде. Аның яшь язучыларны үстерүгә керткән хезмәте әлегә кадәр тиешле дәрәҗәдә бәяләнеп кенә бетмәгән.

Без шуңа күрә дә районда минем тәкъдим белән утыз яшькә кадәрге каләм осталары өчен Гариф Ахунов исемендәге район хакимиятенең премиясен булдырдык. Бездә һәр яңа әйбер авырлык белән керә бит. Бу премияне дә кертеп җибәрү процессы ике елга сузылды. Һәм, ниһаять, 2008 елда Г. Ахунов премиясе булдыру хакында район Советының карары кабул ителде һәм положениесе эшләнде. Алты ел эчендә бу бүләкне кырык җиде яшь каләм һәм сәнгать остасы алды. Аларның күпчелеге татар филологиясе һәм журналистика белгечлеге буенча укуларын дәвам итәләр. Беренче булып Г. Ахунов исемендәге премияне алган Рөстәм Галиуллин Язучылар берлегенә дә кабул ителде.

Быел Г. Ахунов премиясенең, Казан арты районнарын да кертеп, географиясен киңәйтү карала. Хәзерге вакытта бу мәсьәлә чишелү алдында. Киләчәктә премияне республика дәрәҗәсенә кадәр күтәрергә кирәктер.

Бу – безнең Гариф Ахунов истәлегенә эшли ала торган иң зур чараларның берсе.

Шул уңайдан Гариф абыйның язучыларның тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуга керткән хезмәтен искә төшерер идем. Чөнки Гариф Ахуновның бу изге гамәле дә онытылып бара. Аның шикелле язучыларны тораклы итә алган бер генә Союз рәисен дә мин белмим. Ә Гариф абый, башкалар шикелле, үзен карамады, ул шул Новаторлар урамындагы хрущёвкада калды. Мөмкинлекләре булса да, ул квартирасын «престижный»га да алыштырмады, коттедж да төземәде. Тукай премиясе алгач та, премия акчасын үз мәнфәгатьләренә тотмады, ә бәлки Арчадагы туганнан туган энесенә йорт салып бирде.

Тагы шуны да әйтер идем: Г. Ахунов Язучылар союзында эшләгәндә, Татарстан Язучылар берлегенең авторитеты искиткеч дәрәҗәдә үсте. Гариф Ахуновның үзенең дә СССР һәм Россия Язучылар союзында абруе зурдан иде. Шулай булмаса, Казанга, Арчага Мәскәү һәм союздаш республикалар язучылары ел саен диярлек күпләп килеп тормаслар иде.




Арчада Язучылар аллеясында Гариф Ахунов һәйкәле янында. 2005

Г. Ахунов ел саен районыбызның хезмәт алдынгыларын котлау чараларында, Сабан туйларында, Г. Тукайга багышланган шигырь бәйрәмнәрендә катнашып килде. Аларда матур чыгышлар ясый иде, районыбызның уңышларына сөенә иде, аның хезмәт сөючән халкын ярата иде, алар белән горурланып, зур итеп котлый иде. Аның бу чараларда катнашуы район халкына да зур бәйрәм була иде. Шуны да әйтергә кирәк: Арча һәм арчалылар турында ниндидер начар сүз ишетелсә яки язылса, андыйларга тиз генә «отпор» бирә иде. Безгә сүз тидерүчеләрне, начар яктан күрсәтергә теләүчеләрне аның җене сөйми иде. Шуңа күрә дә арчалылар Гариф абыйны үзләренеке итеп, дус итеп, иптәш итеп кабул итә белә иде. Ә ул үзе дә Арча турында, аның кешеләре турында никадәр матур мәкаләләр, повестьлар язды. Аның соңгы илле бишенче әсәре дә Арча кешесе Тимерхан Борханов турында иде.

Миңа 2 нче республика клиник больницасында (элеккеге обком больницасы) Гариф абый белән өч атна ике кешелек палатада бергә дәваланырга туры килде. Һәм шунда мин язучы халкының хезмәте ансат түгеллегенә инандым. Гариф абый һәр көнне иртәнге сәгать өчтә тора, сәгать алты-җидегә кадәр яза. Көн саен көндәлек тутыра (аның ул көндәлекләрен өйрәнеп, китап итеп чыгарырга кирәктер. Рәшит һәм Наилә Ахуновалар бу эшне үзләре яки башка кешегә биреп эшләтергә тиешләр дип саныйм). Гариф абый врачлар, сестра, санитаркалар, авырулар белән аралашканда яңгыраган халык әйтемнәрен, канатлы сүзләрне, онытканчы, үзенең көндәлегенә язып куя. Шуңа күрә дә аның повесть-романнарын укырга җиңел, чөнки ул безнең телдә, Казан арты, гади халык телендә язылган.

Г. Ахунов хөрмәтенә Арча әдәбият һәм сәнгать музеенда язучыга багышланган экспозиция бар, Казанбаш мәктәбендә музей эшли, Арчадагы төзүчеләр микрорайонындагы урамга, паркка язучыбыз исеме бирелде. Аның бюсты Арчаның үзәк мәйданында, халык язучылары аллеясында урын алды. Казан шәһәренең «Кояшлы город» микрорайонындагы иң матур проспектка Гариф Ахунов исеме бирелүгә дә арчалылар бик шат булдылар. Гариф Ахунов исеме «Бөек Тукай Ватаны син, Арча», «Арча ягы зыялылары» китапларына да алтын хәрефләр белән язып куелды. Гариф Ахунов исеме Арча халкы өчен, Арча укучылары өчен бик якын, һәм ул арчалылар хәтерендә озак еллар сакланачак.

Әтисенең иҗатын пропагандалауда мин аның кызы Наиләнең хезмәте зур дип әйтер идем. Нәкъ әтисе шикелле кызу канлы Наилә әтисеннән кешегә ярдәм итү, аны ярату, бигрәк тә бу тормышта авыр ситуациядә калган балалар һәм яшьләргә ярдәм итү сәләтен күп итеп алган. Ул җитәкләгән «Белая ворона» әдәби берләшмәсе никадәр яшьләргә әдәбият ишеген ачты, аларны әдәбият юлыннан җибәрде. Гариф абыйның исемен мәңгеләштерү, аның иҗатын өйрәнү һәм пропагандалау максатыннан Әлмәттә Г. Ахунов музее оешу да аның борчылып йөрүе җимеше дип беләм. Сүз уңаеннан мин арчалылар исеменнән әлмәтлеләргә Гариф Ахуновка ун ел нәтиҗәле эш шартлары булдырганнары өчен, шулай ук Рафаил Төхфәтуллинны да сыйдырганнары өчен рәхмәт әйтәм.

Казан музейларындагы Гариф Ахуновка багышланган әдәби кичәләрнең башында да Наилә тора. Аңа бу юнәлештә армый-талмый эшләргә Аллаһы Тәгалә тазалык һәм көч бирсен. Наилә шикелле, әтисенең иҗатын пропагандалаучы Арчаның тагын бер кызы бар. Ул – Мөхәммәт абый Мәһдиев кызы Гәүһәр. Наиләнең укучысы Альбина Әпсәләмова да бабасының иҗатын саклауда, бүгенге көн укучысына җиткерүдә актив эш алып бара. Якташыбыз, Әлмәттә яшәүче Рөстәм Төхфәтуллин да әтисенең иҗатын пропагандалау буенча зур эш башкара.

Гариф абый гаиләсендә мин үз кеше идем. Алар мине үз балалары шикелле кабул итәләр иде. Бу гаилә искиткеч кунакчыл. Кайчан, кем белән булсаң да, үз итеп кабул итә беләләр иде алар. Хәзер инде Наилә һәм аның гаиләсе миңа әтиләре урынына калган дус итеп карыйлар, нindидер проблемалар чыкканда, минем белән киңәшәләр. Наилә һәм Бориска бик зур рәхмәт әйтәсем килә һәм аларга озын гомер, иҗат уңышлары телим! Гариф абый белән Шәһидә ханым да бу теләккә кушылырлар иде. Гариф абыйның да, Шәһидә ханымның да мәңгелек йортларында тыныч йоклауларына иманым камил. Чөнки алар кешегә начарлык эшли белмиләр иде һәм аны эшләмәделәр дә, аларның күңелләре саф һәм чиста иде.

Арчалылар хәтерендә алар юмор сөюче киң күңелле, кешелекле язучылар булып калдылар.

*Ринат Фазлыйәхмәтов,*
Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре

# Хатирә

Алдымда Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның бер кочак китаплары. Мин аларны инде кат-кат укып чыктым... Күп санлы әсәрләр иҗат итүче белән якыннанрак танышасым килеп, язучыга шалтыраттым. Бер күрешү – үзе бер гомер, ди халык. Дөрестән дә, шулай икән. Гариф ага белән Гөлшәһидә апа мине ачык йөз белән каршы алдылар. Бу киң күңелле кешеләр белән аралашып китү бер дә авыр булмады, киресенчә, икесе дә бик ихтирамлы, җайлы вә гадиләр икән.

Бу йортка мин бер генә тапкыр килмәдем. Язучы белән сәгатьләр буе сөйләшеп утырдым. Сөйләшкән саен сөйләшәсе, аның турында күбрәк беләсем килә. Ә Гариф аганың сөйләр сүзләре күп иде. Ул миңа үзенең катлаулы тормыш юлы турында да, язучылык эше турында да күп сөйләде. Һәр сөйләгәне күңелгә сеңеп бара. Болар миңа бик кирәк иде, чөнки әдипнең проза әсәрләрен өйрәнеп, диссертация язарга җыенам.

Күп еллар үтте, диссертация дә язылды. Тик Гариф ага гына бу якты дөньяда юк инде... Әмма үзеннән соң бик күп истәлекләр калдырды...

Ул үткән юлларны күз алдымнан кичерәм...

Гариф Ахунов кечкенәдән үк бик кызыксынучан, тырыш бала була. Биш яшеннән ятим калса да, тормыш авырлыклары аны куркытмый. Күрше авыл мәктәбенә йөреп белем ала, матур итеп рәсемнәр ясый, киләчәктә рәссам булырга хыяллана. Бәхетенә, юлында изге кешеләр очрап тора. Иң беренчеләре – Гариф абыйның укытучылары. «Эш яратырга, тырыш булырга, гаделлеккә өйрәттеләр», – ди ул алар турында. Беренче мәртәбә чын язучы Әхмәт Гыйматов белән очрашуын, бу очрашуның үзендә зур тәэсирләр калдыруын да сөйләде Гариф ага.

Булачак язучы мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлый һәм имтиханнарсыз Арча педагогия училищесына укырга керә. Икенче мәртәбә чын язучылар белән шунда очраша. Тәнкыйтьче Гали Халит җитәкләгән түгәрәккә йөри. Шунда беренче хикәяләрен яза башлый. Ләкин 1942 елны укуын өзеп торырга туры килә.

Сугыш беткәч, Арча педагогия училищесына кабат кайтып керә. Ул вакытта монда элекке укытучыларыннан Рәмзия Вәлитова («Әлифба» авторларының берсе) гына калган була. Тәҗрибәле, тирән белемле бу мөгаллимә татар телен сакларга, яратырга, хөрмәт итәргә өйрәтә. «Ана телебезнең байлыгын аңлатуда чамадан күп көч куйды... Әдәби хезмәт өчен һава кебек кирәкле тел нечкәлекләренә беренче ныклы нигезне без аңардан алдык», – дип искә ала әдип.

Арча педучилищесыннан соң Г. Ахунов Казан дәүләт университетына юл тота, тарих-филология бүлегенә укырга керә. Сугыштан соңгы авыр еллар, икмәк карточкага гына бирелә. Дәүләт биргән йөз сиксән сумга ашарга, киенергә, уку әсбаплары алырга кирәк. Студент егеткә тормышны ялгыз алып барган әнисенә дә булышырга кирәк, чөнки колхозда хезмәт көненә берни дә бирелми. Г. Ахунов «читтән торып укырга кирәк» дигән фикергә килә. Ләкин бу уеннан аны якын дуслары тотып кала. «Гариф, син укуыңны ташларга ашыкма. Башлавы ансат аны, дәвам итүе кыен», – ди аңа чуваш егете Коля




Гариф Ахунов укыган Арча районы Казанбаш авылы мәктәбендә очрашу. 2005

Ермашин һәм ул Гариф абыйга көн саен бер кружка тары ярмасы биреп бара. Әнә шул «дуслык ярмасы» аны университетта саклап кала.

Университетның соңгы баскычында ул җиң сызганып әдәбият эшенә керешә. Күзәтә, эзләнә, өйрәнә. Бәхетенә, ышанычлы, туры сүзле, таләпчән кешеләр очрап тора. Алар Гариф абыйга һәрчак ярдәм итеп, язучылык эшенә туры юл күрсәтәләр. Әдәбият кебек серле дөньяга язучы әнә шулай аяк баса.

Г. Ахунов «Совет әдәбияты» журналында эшли башлый. Әдәбиятка җитди адымнар шунда ясала. Башта тәнкыйть мәкаләләре языла. Булачак язучыда «Кешенекен тәнкыйтьләү ансат, ә менә үзең язып кара» дигән фикер туа. Башта очерклар, аннан хикәяләр языла. Яныңдагы тәҗрибәле кешеләр аның уңышларын хуплыйлар, кимчелекләрен күрсәтәләр, яхшы киңәшләр бирәләр. Эшкә дәртләндерүче бу кешеләрнең берсе – Гази Кашшаф, икенчесе – Ибраһим Гази була. Аталарча кайгырткан бу кешеләргә Гариф Ахунов бик рәхмәтле, чөнки мондый кешеләр булганда, көннән-көн күңел үсә, эшләү дәрте көчәя. «Атаклы һәм гаять кешелекле әдип Гази ага Кашшаф кулы астында эшләп, мин җаваплылыкка, үз-үземә тәнкыйть күзе белән карый белергә, иптәшләрем белән хезмәттәшлек итәргә, теләсә нинди кара эштән баш тартмаска, иң кыен чакта да язудан туктамаска өйрәндем», – ди Гариф ага. Аңа йә фән юлын, йә нәфис әдәбиятны сайларга кирәклекне дә Гази ага Кашшаф күрсәтә. «Әгәр фән юлын сайлыйсың икән, син бүгеннән аспирантурага керергә тиеш, әгәр нәфис әдәбиятны сайлыйсың икән, бүгеннән син тормыш эченә чумарга тиеш», – ди ул.

Гариф абый матур әдәбият юлын сайлый һәм Әлмәт якларына юл тота. Анда инде, белгәнебезчә, зур эшләр башкара. «Әлмәт – минем язучылык эшемдә иң зур булыш-



Арчаның Үзәк китапханәсендә Гариф Ахуновны искә алу кичәсендә очрашу. 2005

чым, иң зур сөенечем, гомер бишегем булган шәһәр... Мин нефтьчеләр арасына чумдым. Кешеләр арасына... Иң зур илһам, иң кайнар тойгылар белән яшәгән елларым әнә шул чорга – Әлмәт чорына туры килә», – ди ул. Башта очерклар, мәкаләләр, хикәяләр, пьесалар языла. Аннан инде «Хәзинә», «Хуҗалар» романнары туа. Бу романнар татар нефтенең яшьлегенә мәдхия булып тора...

Гариф Ахунов ару-талуны белми яза да яза. «Этләр патшасы», «Идел кызы» һ.б. әсәрләре туа. Төрле жанрдагы әсәрләрен язган арада күптөрле җәмәгать эшен дә башкара. Әмма нинди генә урыннарда эшләсә дә, нинди генә эшләр башкарса да, холкын үзгәртми: ачык йөзле, кешеләр белән аралашучан, ярдәмчел булып кала. Ул безнең күңелдә дә шулай саклана.

Районыбызда Г. Ахунов премиясе булдырылды. Һәр елны әдипнең туган көнендә яшь иҗатчылар бәйгесе уздырыла. Бу көннәрдә олуг язучыбызны искә алабыз, шулай ук төбәгебездәге каләм тибрәтүче яшьләрне барлыйбыз.

*Фәридә Гайфуллина,*
филология фәннәре кандидаты,
Г. Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте укытучысы

# Заман-рухын-яктыртты

Гариф Ахунов – балалар өчен нефтьчеләр темасына проза әсәрләре язуны башлап җибәргән кеше. «Артышлы тау буенда» повесте шул хакта сөйли.

Әсәр бик кызыклы. Автор анда нефть төбәгендәге зур үзгәрешләрне һәм аларның яшь буынга тәэсирен күрсәтә, алай гына да түгел, бу үзгәрешләрне балалар күңеле аша уздырып бәяләргә омтыла.

Язучыны Татарстан җирләренә нефть китергән үзгәрешләр, аның балаларга йогынты ясавы кызыксындыра.

Г. Ахуновның «Артышлы тау буенда» повесте әнә шуңа, нефтьче һөнәренең мавыктыргыч кырыс романтикасын ачуга багышлана, аның хәтта балаларга да тәэсирле булуын күрсәтә.

Повестьның сюжеты кызыклы.

Әсәрнең төп герое – Хәсән. Ул авыл малае. Аның әтисе ат караучы булып эшли. Шуңадыр Хәсән атлар ярата, табигатьнең бер могҗизасы булган атка бөтен күңеле белән тартыла. Хәтта аңа «ат чебене» дигән кушамат та тагалар. Ә беркөнне малай ат өстеннән егылып төшә. Әмма аның атларны яратуы шулкадәр көчле була, хастаханәдән терелеп кайткан көнне үк ул алар янына чаба. Авыл кешеләре: «Башына ат тибеп тә кәнүшни юлыннан туктамады бит», – дип гаҗәпләнәләр.

Кешенең омтылышлары, кем булырга хыяллануы әйләнә-тирәгә дә бәйле. Кайчандыр ат белән кызыксынган Хәсәнне дә, Кәлимәт якларында нефть табылу белән, нефть эше җәлеп итә. Әлбәттә, авыл малае өчен эшче һөнәренә күчү кайбер кыенлыклар белән бәйле. Бигрәк тә аңа күңел каршылыклары комачаулый. Ник дигәндә, ат белән эш иткәндә барысы да гади, аңлаешлы, күңелгә якын кебек. Ә нефтьчеләрнең биек вышкалары, озын-озын торбалары матурлык дөньясына бик үк ятышмый кебек.

Шулай да тора-бара Хәсән күңелендәге шушы киртәләрне атлап чыга һәм нефтьчеләр белән аралашып китә. Аңа нефть җене кагыла. Башта аңа нефтьче булу алай авыр эш түгел, әллә ни укып, өйрәнеп тә торасы юк, тик промыселга эшкә керү бәхетенә генә ирешергә кирәк кебек тоела. Бораулаучы Сәет Хәсәннең «Только кара аны, шаблоннар, обязательно, торба эченнән төшкән булырга тиеш. Без аның белән торбаның брак түгелме, яньчелмәгәнме икәнен тикшерәбез», – дип кисәтүенә каршы: «Шул гынамы?» – ди ул.

Хезмәт тормышта канәгатьләнү генә тудырмый, шатлык кына китерми. Хезмәт ул – иҗат. Иҗат кешесе өчен газаплану, вакыт-вакыт уңышсызлыкларга очрау бик мөмкин. Хәсән белән дә шулай була, аның буровойдагы беренче көне үк уңышсызлык белән тәмамлана.

«Кичә ул нинди бәхетле иде. Шушы юрган астында ничек хыялланып яткан иде. Ә бүген шуларның барысы да кире ягы белән әйләнде. Иртәгә әтисе аның нинди хурлыклы эш эшләгәнен, буровой хәтле буровойны эштән туктатканын белер инде. Иртәгә нинди күз белән буровойда күренергә? Озак микән соң ул шаблонны чыгару? Әллә ул бөтенләй

чыкмыймы икән инде? Нефтьче була, имеш, Габделхәй алдыннан кәпрәеп уза, имеш. Булды менә нефтьче».

Биредә авторның фикере шундый: бала һәрвакыт яңалыкка омтыла, хезмәтнең теләсә нindие түгел, югары техникага корылганы аны үзенә тарта. Ә югары техникага нигезләнгән хезмәт төпле белем сорый. «Шулай, туганкай, синең белән саубуллашырга туры килер инде хәзергә! Техникум! Аңлыйсыңмы, синең урының хәзер техникумда»,– ди Хәсәнгә мастер Афанасий Иванович. Әлеге геройлар эзләнәме, ялгышамы, тик бер нәрсә ачык: аның авырлыкларны җиңеп чыгарга сәләтле икәнлеге, эшкә булган мәхәббәте сизелеп тора.

Биредә хезмәт көчле характер формалаштыру чыганагы итеп күрсәтелә. «Хезмәттә кыенлыклар да, уңышсызлыклар да, шатлык һәм борчулар да читтә калмый» дигән фикер уздыра автор.

Повестьның үзәгенә куелган төп мәсьәлә – авыл малае Хәсәндә нефтьче һөнәренә мәхәббәт уянуы, шул юлга кереп китүдә үз-үзен һәм тирәлек белән каршылыкны җиңә баруы. Тормыш аны төрле хәлләргә куя. Ләкин малай җебеп төшми, үз максатына туры бара.

Биредә автор балалар дөньясын, психологиясен, рухи ихтыяҗларын белеп эш итә. Ул аны чынбарлыктагыча табигый итеп сурәтләргә тырыша. Аның героена балага хас шуклык та, уен-көлкегә һәвәслек тә, шул ук вакытта тормыш турында җитди уйланулар да, юлда очраган киртәләрне үтеп чыгарга сәләт тә бар. Ул хакыйкатькә эзләнүләр, ялгышулар аша килә. Күргәнебезчә, әдип тормышны каршылыклы үсеш процессында чагылдыра. Кыскасы, автор, тормыштагы кискен конфликтларны сурәтләп, чорга хас каршылыкларның кечкенә геройларга ничек тәэсир итүен, анда ничек итеп ныклы характер формалашуын күрсәтә.

Г. Ахунов әсәрендә тагын бер әһәмиятле мәсьәлә күтәрә. Ул – табигатькә мөнәсәбәт.

Артышлы тау буенда бер авыл бар. Табигате матур, суында балыгы, тирә-юнендә җиләк-җимеше мул. Кешеләр дә тыныч кына, булганына куанып көн итәләр. Бу авыл авторның идеалы булып та аңлашыла.

Көннәрдән бер көнне, беркемнән сорап тормастан, иләмсез зур машиналарга төялеп, нефтьчеләр килеп төшә. Матур гына яшәгән авылның тынычлыгы югала. Сулар пычрана, балыклар бетә, урамнарда чирәмнәр актарыла, ашлыклар таптала. Авыл халкыннан беркем дә рөхсәт сорамый, китергән зыян өчен гафу да үтенми. Г. Ахуновны бу хәл борчый. Ул әсәрдә урыны-урыны белән табигатькә саксыз карауның зарары турында кисәтеп бара.

Татарстанда нефть чыгару эшенең башлангыч чорын сурәтләгән «Артышлы тау буенда» повесте җөмһүриятебездәге яңалыкларны, балаларның шушы яңалыкларга мөнәсәбәтен, аларның үзләренә генә хас күңел дөньясын ача.

*Ләйлә Дәүләтярова,*
Арча районы Лесхоз урта гомуми белем бирү мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# Йөрәк-типкәндә-нинди-дә-булса яхшы-гамәлләр-кылырга-кирәк

Халык язучысы, Г. Тукай һәм Г. Исхакый исемендәге дәүләт бүләкләре иясе Гариф ага Ахунов үзенең «Туган якка мәдхия» шигырендә мондый юллар язып калдырган:

*...Безнең эшләр, еллар узгач,*
*Туган якларга кайтыр.*

Белеп сизенгән әдип йөрәге. Арча районында, чыннан да, якташларының исемнәрен мәңгеләштерүне күздә тотып, биниһая зур эшләр башкарыла. Арча – халкыбызга йөзләгән мәгърифәтче, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре биргән як. Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Мәхмүт Галәү, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев кебек классик язучылар – Арча төбәгенең данын еракларга таратучы шәхесләребез. Без исә, язучылар Туфан Миңнуллин, Вакыйф Нуриев, Мөсәгыйт Хәбибуллин, шагыйрь Әхмәт Гадел, журналистлар, тагын бер сөенечле вакыйганың шаһитлары булдык. Ул көнне арчалылар район хакимияте башлыгы Алмас Әмин улы Нәзиров карары белән әдәбият, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә Гариф Ахунов исемендәге әдәбият премиясен районның талантлы яшьләренә тапшыру тантанасына җыелды. Ни өчен нәкъ менә Гариф ага Ахунов? Бу сорауга районның социаль мәсьәләләр буенча хакимият башлыгы урынбасары Надия Мифтахетдинова ачыклык кертте:

– Арча төбәгеннән чыккан күренекле язучыларыбызның һәрберсе үз премиясен булдыруга лаек. Әмма без нәкъ менә Гариф ага Ахуновтан башладык. Чөнки бу затлы кешенең байтак гомере гаиләсе, якыннары турында гына түгел, бәлки туган халкы, аның әдәбияты, каләмдәшләре, сәнгатьнең башка тармакларында иҗат итүчеләр турында кайгыртып узды. Үзе дә, ал-ял белмәстән, хәрәкәттә, иҗатта, оештыру эшләрендә булды. Гариф аганың бик матур сүзләре бар: «Йөрәк типкәндә, – дигән иде ул, – нинди дә булса яхшы гамәлләр кылырга кирәк, кешеләргә яшәве күңелле, мәгънәле булсын». Ул ачык йөрәге белән кешеләргә якын килә белде, шуннан үзе дә көч, илһам тапты, яшәүнең мәгънәсен тирәнтен аңлады.

Чыннан да, Арча җирендә илһам чишмәсе беркайчан да саекмый. Бүген шушы олы мирасны дәвам итәрдәй яшь каләм осталарының, җырчы, композиторлар, рәссамнарның үсеп килүен күрү үзе үк сокландыра. Әмма, иң мөһиме, аларны вакытында таный, барлый белү кирәк. Нәкъ менә шуны күздә тотып, «Иген иккән халык дан-шөһрәткә лаек», «Яңа гасырда яңа адымнар», «Илгә кылсаң игелек», «Җырлыйк әле», «Алтын каләм» бәйгеләре үткәрелә Арчада. Гариф Ахунов исемендәге премия лауреатлары – әнә шул бәйгеләрдә җиңүчеләрнең иң-иңнәре. Чәчмә әсәрләр иҗат итүчеләр арасында премиягә лаек дип табылган Фәнзилә Мостафина, мәсәлән, Мөндеш авылыннан, 11 нче сыйныф укучысы. «Яза алуым белән чиксез горурланам. Гади сүзләр белән генә әйтеп булмый торган хисләрем иҗат җимешләремдә чагыла», – ди ул. Фәнзилә хәтта олпат язучыларыбыз алдында «Кышкы яңгыр» хикәясеннән өзек укырга да җөрьәт итте. Ә Яңа Кишет мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы Чулпан Гобәйдуллинага исә драматургия өлкәсендә зур өметләр баглыйлар. «Язган пьесасын бүген сәхнәгә куярлык», – дип бәяләмә бирде



Гариф Ахунов Арчада үзенең 70 яшьлек юбилей кичәсендә. 1995

аңа язучы Радик Фәизов. (Ул инде күп еллардан бирле яшь каләмчеләрнең «Тукай якташы» түгәрәген җитәкли, шуңа да аларның һәр адымын яхшы белә.) Чулпан, «Яңа татар пьесасы – 2007», «Замана баласы», «Я выбираю жизнь», «Хыялымдагы йорт» конкурсларында катнашып, призлы урыннар да яуларга өлгергән икән инде.

Гариф ага Ахунов рәсем ясарга яраткан, картиналар иҗат иткән. Шуңа да районның иң матур почмагы – Сурнар урманчылыгында туып үскән Фирүзә Гыйззәтуллинага нәкъ менә рәсем сәнгате номинациясе буенча премия тапшыру бик урынлы булды. «Арча ягы, данлы Тукай ягы» дип аталган төбәк конкурсында дипломнарга лаек булган. Гаилә елы уңаеннан республика бәйгесендә Фирүзәнең «Минем кадерлеләрем» дип исемләнгән картинасын бертавыштан беренче урынга лаек дип билгелиләр һәм аны күргәзмә-конкурсның афишасында файдаланалар.

Шигырь язучылар да күп Арча төбәгендә. Наилә Харисова инде үз юлын сайлаган: КДУның экономика факультетында белем ала. Әмма аның әдәбиятка, сәнгатькә булган мәхәббәте кимеми. Ә Хәсәншәех авылы кызы Азалия Вәлиева «Кайтаваз» дигән китапчык чыгарырга да өлгергән. Аның шигырьләре «Без Тукай оныклары» җыентыгында да урын алган. Казанның 1000 еллыгына багышлап уздырылган «Я к вам пишу» бәйгесендә дә призлы урынга лаек була ул. Пөшәнгәр башлангыч мәктәп, балалар бакчасында педагог-оештыручы булып эшләүче Рания Галәветдинова исә «Җыр-моңнар, шигърият Ватаны син, Арча!» дип исемләнгән шигырь конкурсында беренче урынны ала.

Заманында Гариф ага Ахунов публицистика жанрында да каләмен сыный, һәм ул аңа шактый зур уңышлар да китерә. I дәрәҗә әдәбият премиясе публицистика жанрында ирешкән уңышлары өчен Наласа авылы егете Рөстәм Галиуллинга бирелде. 2008 елда аның Татарстан китап нәшриятында беренче китабы – «Гипнозчы малай» дөнья күрә, һәм ул Татарстан Язучылар берлегенә тәкъдим ителә. Бүген аспирантурада укучы, «Шәһри Казан» газетасында бүлек мөдире булып эшләүче Рөстәм: «Әгәр Арча районы



Арчаның әдәбият һәм сәнгать музеенда Гариф Ахунов почмагы: язучының эш өстәле, язу машинкасы, үзе ясаган «Туган авылым» картинасы, китаплары, сурәтләре...

җитәкчелеге талантларны барламаса, вакытында күреп алып ярдәм итмәсә, без мондый уңышларга ирешә алмас идек», – дип, бик дөрес бәя бирде.

Аның фикердәшләре күп иде залда. Туфан абый Миңнуллин да дулкынлануын яшермәде:

– Хисләргә күмелеп утырам әле мин. Кайвакыт милләтебез өстендә кара болытлар куерганын күреп, күңел төшеп киткән вакытлар булгалый. Ә монда, дөньяга ишетелерлек итеп: «Без әле исән! Ашыкмагыз, господа!» – дип әйтәсе килә. Арча ягы безнең өчен бик кадерле. Мондый чаралар бөтенләрне дә үз артыннан ияртергә тиеш. Бу бәйгене республика күләменә дә күчәр дип уйлыйм мин, – диде ул.

Мөсәгыйт ага Хәбибуллин, гадәтенчә, сүзен тарих чоңгылларына алып китте. Заманында Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиевләр белән Арча якларын үз итеп йөргән әдип тарихыбызны, телебезне саклау буенча башкарган эшләре өчен Арча җитәкчелегенә бик тә рәхмәтле. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, Сеҗе авылы егете Вакыйф Нуриев та Арча хакимияте башлыгы Алмас Нәзировка Рәхмәт хатын әнә шул уңайдан тапшырды. Әмма мирасны саклау эшен балаларың, оныкларың дәвам итмәсә, барыбер дә ниндидер бушлык булыр иде. Бу җәһәттән Гариф аганың кызы Наилә ханымның эшләрен санап бетергесез. Җиңүчеләргә Гариф аганың китапларын да бүләк итте ул. Ә аның лирик шигырьләрен тамашачыларга шагыйрь Әхмәт Гадел үз тәрҗемәсендә җиткерде.

Гариф аганың шигырендә язылганча, эшләре генә кайтмаган туган төбәгенә, ул үзе дә хәләл җефете Шәһидә ханым белән шушында, үз туфрагында. Аның премиясенә лаек булучы яшьләр өлкән язучылар белән Арча зиратына юл тоттылар. Кабер өсте чәчәкләргә күмелгән. Гариф ага белән Шәһидә ханым рухына дога укыгач, аллы-гөлле чәчәкләр тагын да артты. Бу күренешкә бигрәк тә Наилә ханым сөенде: «Әтиемнең бүген туган көне. Рухы бик тә шатланадыр инде. Ни дисәң дә, бу юлы шундый күп яшьләр – аның дәвамчылары килде бит. Гариф Ахунов исемендәге премия лауреатлары!» – диде ул зур горурлык белән.

Кемдер Илдар Юзеевнең Гариф Ахунов вафаты уңаеннан язган шигырен искә төшерде:

*Туфрак җылы-йомшак булыр*  
*Туган-үскән ягыңда.*  
*Оҗмах кошлары сайрасын*  
*Анда да һәр таңыңда.*

*Фәния Әхмәтҗанова*

«Ватаным Татарстан». – 2009. – 23 сентябрь

# Не-оскудела-талантами-Арская-земля

http://art16.ru/reportage/2012/10/01/prisuzhdenie-premiy-im-garifa-ahunova-v-oblasti-literatury-i-iskusstva

27 сентября 2012 года в Центральной библиотеке г. Арска прошла церемония вручения премии имени Гарифа Ахунова (1925–2000), народного писателя РТ, заслуженного работника культуры РСФСР, видного государственного и общественного деятеля, лауреата Государственной премии ТАССР им. Г. Тукая, лауреата премии им. Гаяза Исхаки, почетного члена Академии наук РТ.

Премия была учреждена более 5 лет назад по инициативе главы Арского муниципального района Алмаса Аминовича Назирова. Этот шаг глава района сделал, дабы отдать дань уважения своему знаменитому земляку – Гарифу Ахунзяновичу Ахунову.

Премия им. Гарифа Ахунова в области литературы и искусства молодым талантам Арского района в 2012 году вручалась по следующим номинациям: «Публицистика», «Поэзия», «Проза», «В области культуры».

В библиотеке собрались арчане: учителя, библиотекари, школьники и их родители.

Среди приглашенных гостей – два заместителя председателя Союза писателей Татарстана: Дамир Салихов и Вакиф Нуриев, дочь писателя, руководитель литобъединения КГМУ «Белая ворона», поэтесса Наиля Ахунова. Лауреатов, участников праздника




Арчада Гариф Ахунов һәйкәле янында туганнары, гаилә дуслары һәм язучылар. 2010

и гостей поздравили заведующая местным РОНО Рина Бадриева и зав. отделом культуры Ильнур Кутдусов.

Премии вручали именитые гости. Следует отметить, что по дороге из Казани в Арск, писатели и журналисты посетили местное кладбище, возложили цветы на могилу классика татарской литературы и его жены. Затем прибыли в библиотеку.

В библиотеке собрались арчане (учителя, библиотекари, школьники и их родители).

То, что награждение проходило в Центральной библиотеке Арска, заслуга Наили Ахуновой. Именно по пожеланию дочери писателя, ратующей за то, чтобы в каждой библиотеке нашей республики можно было ознакомиться с наследием классиков татарской литературы, событие произошло здесь, а не на другой площадке города.

В последнее время книги этих авторов редко переиздаются, разве что в библиотечных сериях или собраниях сочинений к юбилеям. Остаётся лишь надеяться на наши библиотечные фонды...

Гариф Ахунов очень любил свою родину, часто сюда приезжал, помогал арчанам, чем мог. Писал о них книги, статьи, очерки. Реально помогал, будучи депутатом Верховного Совета СССР и председателем Союза писателей Татарстана.

Арчане чтут его память. В Краеведческом музее г. Арска есть экспозиция, посвященная Гарифу Ахунову. В Арском музее литературы и искусства, основанном Фазлиахметовым Ринатом Ахметгалиевичем в 90-х годах XX века, среди раритетных личных вещей, фотографий, материалов, посвященных уроженцам этого края – ученым, просветителям, писателям, есть экспозиция Гарифа Ахунова: письменный стол, подаренный ему когда-то на 40-летие альметьевскими писателями, за которым он написал многие свои произведения; пишущая машинка; родословная; картина маслом родной деревни Учили его кисти; портрет бабушки Юзликай, который он написал на день рождения своей жене Шаиде Максудовой, с любовью и юмором; африканская маска, привезенная им из Нигерии; его книги, рукописи...

– Кажется, что они еще хранят тепло его рук, – делится своими ощущениями Наиля Ахунова и продолжает, – Ринат абы – хранитель истории, памяти. Несмотря на свой возраст, а ему уже восьмой десяток, он активно участвует в музейном процессе, является одним из главных советников и экспертов по культуре района, авторитетом в этой области.

Мне очень приятно, как дочери, что памяти моего отца, Гарифа Ахунзяновича Ахунова и моей мамы, Шаиды Габдрахмановны Максудовой уделяется внимание, их помнят. Это очень помогает и поддерживает меня в жизни. Я всегда с радостью приезжаю на землю моих предков, бываю на кладбище, где они похоронены. Ухаживаю за цветами, встречаюсь с Сарвар апа, которая мне помогает ухаживать за могилой моих родителей и читает молитвы. Ей почти 80 лет. Но она бодра духом и не поддается своему возрасту, молода душой. Её дочери также доброжелательны, гостеприимны, как и она. Всегда приглашают на чашку чая, я уношу с собой теплые воспоминания и уезжаю с мыслью снова, как можно скорее, вернуться...

Выступая на торжественном мероприятии, Наиля Гарифовна доверительно сообщила о своей сокровенной мечте: ей очень хочется, чтобы на Арской земле, в Казанбашской школе, где он учился, был создан музей Гарифа Ахунова; сейчас там есть мемориальная экспозиция – уголок памяти. У семьи Ахуновых большой архив, которым поэтесса с радостью готова поделиться с земляками.

*Елена Сунгатова*,<br>
член Союза журналистов РТ,<br>
редактор сайта «Культура и искусство в Татарстане»

# В-Арске-вручили-премию-имени-Гарифа-Ахунова

Остротой своего языка и юмором Гариф Ахунов воспитывал народ. Сегодня в соответствии с постановлением главы района Алмаса Назирова достойным продолжателям дела писателя была вручена премия имени Гарифа Ахунова за успехи в области литературы, культуры и искусства. Ее удостоились учащаяся XI класса Смак-Корсинской школы Айгуль Садриева (из Средней Корсы), студентка Нурсия Минзина из деревни Старый Муй, преподаватель Арского агропромышленного колледжа Лилия Валишина, студия «Город мастеров» (руководитель Н. Хакимова) при Арском Дворце школьников, учащаяся художественного отделения Арской ДШИ Айгуль Хузина, учащаяся музыкального отделения (домра) Арской ДШИ Анастасия Орлова, вокальный ансамбль «Гузелкай» (руководитель Г. Минхаирова) при школе искусств.

Писатели рассказали, каким открытым человеком, любящим людей, мастером слова был Гариф Ахунов.

...Мы с волнением ждали появления на сцене дочери писателя Наили ханум. И вот она перед нами. Такая же простая, добродушная, как и отец... Ее сильно взволновало то, что сразу же по приезде в Арск писатели посетили могилу ее отца и возложили на нее цветы. Она сквозь слезы выразила слова благодарности Сарвар ханум, ухаживающей за могилой, учредителям премии имени Г. Ахунова, организаторам торжества ее вручения и выразила надежду, что в дальнейшем эта премия станет республиканской.

Сценарий был составлен заведующей отделом обслуживания центральной библиотеки Альфией Галимовой. Вела торжество ведущий специалист отдела ЗАГС Миляуша Рахимова. Лауреаты премии имени Г. Ахунова исполнили песни, танцы, рассказали стихи, играли на музыкальных инструментах, ознакомили и с достижениями в области литературы, культуры и искусства района. Это стало прекрасным мероприятием, вдохновляющим на новые творческие дела.

*Румия Надршина*
Арский вестник. – 2013. – 27 ноября



Арчаның яшь талантлары өчен каралган Гариф Ахунов премиясенең яшь лауреатлары. Арча, 2010



# VI-бүлек.-ЙОЛДЫЗЛАР-СҮНМИ

# Якты-эзе,-җылы-сүзе-калды

«...Һәм Ахунов дилбегәне үз кулына алды. Имән урманы буйлап бераз баргач, шофер машинаны камыллы басуга алып кереп китте. Түбәнгә – Казан елгасы уйсулыгына таба җан-фәрманга чаптык. Коры елгалы, берничә агачлы сәеррәк бер урында Гариф машинаны туктатты. Чыктык. Шунда гына көтү йөри икән, бер-ике сыер туп-туры безнең янга килеп басты һәм катып калды. Бераздан машина янына «бүәү-бүәү-бүәү» килеп өч-дүрт ахмак сарык җыелды, Гариф исә әтәтерләнеп йөгеренде.



Сулдан уңга: язучылар Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Мөхәммәт Садри һәм композитор Сара Садыйкова. 1980

– Сибгат абый, менә монысы безнең өй урыны. Сибгат абый, менә безнең өй почмагындагы таш. Менә икенчесе... Сибгат абый, әнә теге карт шомыртны күрәсеңме? Әнә тегесе, әнә төбендә кәҗәләр җыелып ятканы?

Гариф сабый баладай сикеренеп йөрде, йөрде дә, безнең янга килеп:

– Менә балалык вакытым шушында үтте инде минем,– диде.– Мөхәммәтнең эше шәп, аның авылы сакланган, ә безнекен бетерделәр. Әйдәгез, чишмә буен да карыйк әле.

Шулвакыт мин Гарифҗанның күзләрендә яшь күрдем. Сибгат абый берсүзсез нигез ташы янында басып тора иде. Авыр тынлык урнашты. Йөрәгем кысылды, чын йөрәктән Гарифны кызгандым. Бу минутта ул бик ятим, бәхетсез иде. Югыйсә – депутат, делегат, лауреат һәм кайдадыр абруйлы әгъза, секретарь, рәис һ.б. ...»

Бу истәлек халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең «Ачы тәҗрибә» дигән әсәреннән алынды. Әле кайчан гына (моннан биш ел элек, июнь уртасында) Мөхәммәт ага үзе, Казанны һәм бөтен татар халкын ятим калдырып, туган ягына – Арча районындагы Гөберчәк авыл зиратына мәңгелеккә китеп барган иде. Язмыш аяусыз. Инде менә быелгы июнь тагын бер арчалы әдип – халык язучысы Гариф Ахуновны безнең арадан алып китте. Аны да үзенең туган туфрагында – Арчада җирләячәкләр. Бүген җәмәгатьчелек Камал театрында сәгать унда аның белән бәхилләшә.

Әдәбиятыбызга «Хәзинә», «Хуҗалар», «Идел кызы» романнары, «Чикләвек төше», «Яшьлек яме», «Ардуан батыр» кебек повестьлары белән кергән олы әдипнең әсәрләре үзе исән вакытта ук әдәбият дәреслекләренә керде, бик күп чит телләргә тәрҗемә ителде. Озак еллар республика Язучылар берлеген җитәкләгән Гариф Ахунҗан улы әдәбиятыбызны элеккеге СССРның барлык халыклары әдәбияты белән тоташтыручы бер күпер кебек иде.

Авыр туфрагың җиңел булсын, Гарифҗан ага!

Татарстан яшьләре.– № 69.– 2000. – 6 июнь

# Классиклар китә, безне ятим итә

Мәңгелекнең законы шундый: адәм баласы бу фани дөньяга вакытлыча гына килә. Мондый легенда бар: Сөләйман пәйгамбәр 800 ел яшәгән. Үләре алдыннан аңа болай дип мөрәҗәгать иткәннәр, имеш: «Пәйгамбәр, бу дөньядан туйдыңмы?» Җавапны ул түбәндәгечә биргән: «Бу дөньяның бер капкасыннан кергән идем, икенчесеннән чыгып барам»... Чыңгыз хан да Гайнелхәят-Тереклек чишмәсен эзләткән, мәңге яшәү турында хыялланган, диләр. Л. Н. Толстойның да үлем белән һич тә килешәсе килмәгән. Әмма бу мәсьәләдә һәммәбез дә бертигез...

Болар хакында мин татарның иң затлы улларыннан берсе – Татарстан халык язучысы, Тукай бүләге лауреаты Гариф Ахуновны соңгы юлга озаткан минутларда тагын бер кат уйландым. Шулай килеп чыкты ки (бу объектив күренеш, дияр идем), Гариф белән миңа 20 еллап күрше булып, димәк, бик еш күрешеп-сөйләшеп яшәргә насыйп булды.



Җанлы әңгәмә (сулдан уңга): Гариф Ахунов, композитор Нәҗип Җиһанов һәм Татарстан китап нәшрияты директоры Гарәф Шәрәфетдинов. 1983



«Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә (сулдан уңга): язучылар М.Хәбибуллин, Ш.Маннапов, А.Гыйләҗев, С.Хәким, Г.Ахунов, Г.Бәширов, Ф.Мусин. Казан, 1978

Моңа әдипнең хәләл җефете, язучы Шәһидә ханым да сәбәпче диясем килә. Гариф белән Шәһидә 5 ел буе бер группада укыдылар, аннан соң өйләнештеләр һәм, гомергә уртак тел табып, тату гомер иттеләр. Рәшит белән Наиләне (алар да Язучылар берлеге әгъзасы) үстерделәр. Шәһидә Гарифка илһам иңдерүче дә, әсәрләренә бәя бирүче дә булды. Бу гаилә белән күрше булып яшәвем өчен язмышыма мең рәхмәтлемен.

Моннан 8 ел элек якташым, әткәм белән бергә земская школада белем алган күпкырлы талант иясе, язучы, шагыйрь, драматург, публицист, Тукай премиясе лауреаты, халык язучысы Нәкый ага Исәнбәт белән мәңгелеккә хушлашкач, бик озак вакыт күңелемә урын таба алмый интектем. Якын елларда мондый дәрәҗәдә афәт булмас, дип, үземне тынычландырырга тырыштым. Ләкин чынбарлыкның бездә эше юк.

Шулай ук олы талантка ия булган, әдәбият күгебезнең иң якты йолдызына әйләнгән, Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев безне бөтенләй ташлап китте. Мөхәммәт –Гомәр абыйның кияве. Ә без Гомәр абый Бәширов белән озак еллар буе күрше булып, бик дустанә яшәдек. Мөхәммәтне болай да яхшы белә идем дисәм, арттыру булмас. «Гомәр абый факторы» бу якынлыкны тагын да көчәйтте...

Үтә дә кызганыч, «үлем агач башыннан йөрми» ди халык: Мөхәммәт Мәһдиев, озакка сузылган каты авырудан соң, 1995 елның 14 июнендә безне ятим калдырып, фанидан бакыйга күчте... Авыр, бик авыр булды безгә, чөнки, язучы үзе әйтмешли: «Кайбер кешеләр, дөньядан киткәндә, үзләре белән бөтен бер халәт-яшәешне алып китәләр. Ул кеше яшәгән тирәлек озак еллар буе ятим кала...» Чыннан да шулай. Без моны 1999 елның май башында Гомәр абый Бәшировны Татар зиратына илтеп куйганда нык сиздек.

Әмма монысы да соңгысы булмаган икән, затлыдан да затлы тагын бер халык язучысы – Әмирхан ага Еники белән быелның карлы-буранлы февралендә мәңгелеккә ае-



Гариф Ахунов белән Габдрахман Әпсәләмов

рылыштык. Һәм, ниһаять, тагын әйтеп-сөйләп бетермәслек югалтуга дучар булдык: әле генә, 6 июньдә, үзенең васыятенә туры китереп, Гариф Ахуновны туган ягы Арчада җир куенына салдык.

1996 елда Татарстанның халык язучысы, чын мәгънәсендә милләтебезнең йөзек кашы булган Фатих ага Хөсни, күренекне прозаигыбыз, татар әдәбиятында тирән эз калдырган Атилла Расих та безне ятим иттеләр. Әлеге әдипләр иҗатына бәя бирергә алынмыйм, чөнки максатым башкада. Дөрес, мин язган сценарийлар буенча Г. Бәширов, Г. Ахунов, Ә. Еники иҗаты хакында кинофильмнар төшерелде. Г. Ахунов иҗатына багышланган шактый зур күләмле әсәрем «Мирас» журналында басылды. Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Ә. Еники, Н. Исәнбәтнең аерым әсәрләренә бәяләмә белән матбугатта чыгыш ясаганым бар. Бу язучылар белән якыннан аралашкан кеше буларак, һәрберсенең шәхси тормышына кагылышлы мизгелләргә тукталырга телим.

Сүзне Нәкый абый Исәнбәттән башлау урынлы булыр кебек. Бик үк еш булмаса да, якташ буларак, Нәкый абый белән күрешә-сөйләшә идек. Туган якны искә алудан тыш, бүгенге көнкүреш, әдәбият мәсьәләләренә күбрәк урын бирелә иде. Бервакыт Һади Такташ иҗаты хакында сүз чыккач, ул: «Һадиның «кызыл шигырьләренә» карап кына аның иҗатына бәя бирү дөрес булмас. Такташ гомере буе авылга мәдхия җырлады, ә Сталин авылны дошман күрде, шагыйрь моны яхшы белде һәм, коммунистларга ярау өчен, «кызыл әсәрләр» иҗат итте. Әмма 37 нче елларга кадәр яшәсә, властьлар иң беренче аны юк итәрләр иде», – диде.

Нәкый абый –мәгълүм ки, талантлы әдип кенә түгел, бик зур галим дә. Өстәвенә искиткеч тырыш кеше дә иде. Көндезен бер сәгать ял итүен исәпләмәсәк, ул көн буе эшли: укый, яза, архив материаллары белән мәш килә. Соңгы 25 ел гомере, беренче хатыны – Уфа кызы Гөлсем апа үлгәч, бик тә итагатьле җан иясе Нәҗибә апа белән үтте. Нәкый абый озак ел-

лар астма авыруы белән җәфаланса да, Нәҗибә апа аны бик нык карады, дәвалады. Әдип әсәрләренең 35 томлыгын тәртипкә китереп, машинкада басып, әзерләп куйды.

Инде Гомәр Бәшировка килгәндә, аның белән 15 ел буе күрше булып яшәдек. Җәймекышмы, язмы-көзме, салкынмы-җылымы, һәр көнне, төштән соң, икәүләп һава алып йөрдек. Кемнәр, нәрсәләр хакында гына сөйләшмәгәнбез инде... Гомәр абый 10 ел буена Татарстан Язучылар берлегенә җитәкчелек иткән, 10 ел буе СССР Югары Советы, аннан соң Татарстан Югары Советы депутаты булган кеше. Орденнар, медальләр белән бүләкләнгән. Ләкин әдиптә масаю дигән нәрсәнең мыскалы да юк иде. Нәкъ Нәкый абый кебек... Гомәр абый аркылы мин бик күп татар язучыларының «иҗат лабораторияләре» белән, хәтта шәхси тормышлары белән дә таныштым. Шунысы үзенчәлекле: Гомәр абый беркем хакында да һичкайчан авыр сүз әйтмәде. «Тормыш булгач, аның вак-төяге дә була инде. Әмма язучыга бәяне иҗатына карап бирү дөрес» дигәне хәтердә уелып калган.

Гомәр абыйга хас тагын шул нәрсә бар иде: ул үзенең яза торган әсәренә, аның теленә искиткеч таләпчән кеше, ару-талуны белми торган «эш аты» иде. Ул йөз яшькә аз гына җитми дөнья куйды. Үләренә ярты көн калгач, мин аның белән телефоннан шактый озак сөйләштем... Гомәр абый бервакытта да сәламәтлегеннән зарланмады. Бер күзе сукырайгач кына: «Вакытында мөрәҗәгать иткән булсаң, күзеңне саклап калырга мөмкин булыр иде, – диде табиблар. – Икенче күзем дә күрмәс булса, нишләрмен, мин бит укымый, язмыйча тора алмыйм», – дип акрын гына әйткәне истә калган.

Мөхәммәт Мәһдиев хакында да шактый нәрсәләр язарга мөмкин булыр иде. Әмма аңлы рәвештә «киңәеп китмим». Аның өч китабына язган бәяләмәләрдә әйтәсе сүзләремне әйттем кебек. Мөхәммәт, һичшиксез, зур талант иясе иде. Әлбәттә, катлаулы тормыш юлы үткән, властьлар тарафыннан нык җәберләнгән шәхес. 1937 елны аның әтисен бер гаепсез халык дошманы дип аталар... Мөхәммәт белән беренче мәртәбә мин 1960 елның җәендә «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф» журналы) редакциясендә эшләгәндә күрештем. Ул татар теле укытучысының Тукайның «Кәҗә белән сарык» әкиятенә, әлбәттә, «сыйнфый күзлектән чыгып», дәрестә анализ ясавы турында юмореска сыман язма алып килгән иде. Аны укып чыккач рәхәтләнеп көлдем, чөнки үзем дә күптән түгел урта мәктәпнең завучы булып эшләгәндә шундый укытучылар белән «мәш килүемне» искә төшердем. Һәм бу озын буйлы чибәр егеткә: «Бу язмагызны тиздән журналда урнаштырырбыз», – дип вәгъдә бирдем һәм сүземдә тордым... Гомәр абыйның әйтүенә караганда, Мөхәммәт көненә кулдан уртача 18 бит текст яза торган булган. Фән белән ныклап шөгыльләнергә дә вакыт тапкан. Бик тә үкенечлесе шул: Мөхәммәт үз иҗат потенциалының бик аз өлешен генә файдаланып кала алды...

Әмирхан абый белән дә бәйләнеш өзелеп тормады. Моңа, якташ булу өстенә, дөньяга карашларыбыз бертөрлерәк булу да сәбәпчедер. Шунысы хак: Әмирхан абыйда халкыбызга хас иң уңай сыйфатлар, югары әхлак нормалары формалашкан иде... Ул да гомеренең соңгы сәгатьләренә кадәр иҗат итүдән туктамады.

Инде Гариф Ахуновка (18.09.1925–04.06.2000) килгәндә, беренче мәртәбә аның белән 1947 елның сентябрендә очраштым. Ул чакта мин Казан университетының өченче курсында укыйм. Ә Гариф ак колонналы бина бусагасын яңа гына атлап үткән, беренче курс студенты булу бәхетенә ирешкән иде. Онытмыйк: сүз әле генә сугыш беткән бик авыр еллар турында бара...

Гариф кечкенә вакытта аның әтисе фаҗигале рәвештә һәлак була. Авылда һәрдаим ачлык хөкем сөргәнен истә тотсак, Ахунҗан абзый (Гарифның әтисе) балаларының нинди шартларда үсеп аякка басуларын күз алдына китерергә буладыр (Гарифның туган авылы Өчилене Тукай Өчилесе белән бутарга ярамый). Гарифның Өчилесе хәзер юк инде. Шулай да ул, үзе үскән авыл чишмәләренең суын эчәр өчен, шул якка кайтып килә иде.

Татарны һәрчак үтә тырышлык, көн-төн баш күтәрми эшләү, якты киләчәккә өмет итү яшәтте. Бу нәрсә Гарифка турыдан-туры карый.

Сүзебезне раслау өчен, берничә мисал китерик: Гариф (тулы исеме – Гарифҗан Ахунҗанович Ахунҗанов) 1957 елда Әлмәткә күчеп китә, озак еллар нефтьчеләр арасында яши, Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген оештыра, шул оешмага җитәкчелек итә (1963–1968). Казанга кайткач, төрле урыннарда эшли. Ун ел буена Татарстан Язучылар союзына җитәкчелек итә, СССР Югары Советы депутаты була. РСФСР Язучылар союзы секретаре, СССР Язучылар союзы идарәсенең секретаре булып та тора. Моннан тыш та, ул бик күп оешмаларның җаваплы әгъзалары ролен үти. Орденнар белән бүләкләнә, мактаулы исемнәргә лаек була.

Шулкадәр күп санлы җаваплы вазифаларны үтәү өстенә, Гариф Ахунов 50 китап авторы да бит әле! Кем әйтмешли, аларның гранкаларын уку өчен генә дә күпме вакыт сарыф ителгән. Әйе, татар әдәбиятының алтын фондына кереп калырлык монументаль-эпопея характерындагы әсәрләре дә җитәрлек. Аларның кайберләренә нигезләнеп, киноэпопеялар (мәсәлән, «Идел кызы» әсәреннән «Габбас хәзрәт» кинофильмы – әнә шундыйлардан) барлыкка килде... «Хәзинә» романы буенча да нәфис фильм эшләнде.

Әдип йөзләрчә язучыларның иҗат портреты белән таныштырды, бик күп китапларга бәяләмәләр белән чыгыш ясады.

Гариф Ахунов – тормышта искиткеч тыйнак, эчкерсез, киң күңелле шәхес иде. Ул гомер буе хрущевкада яшәде һәм шуннан китеп тә барды. Быелгы 4 июнь иртәсендә әдип үз бакчасында инсульттан үлде. Өенә алып кайткач, аның белән хушлашырга зур түрәләр килде. Әмма аларның машинасы Гариф яшәгән йорт янына үтә алмады, чөнки асфальт юл соңгы мәртәбә моннан чирек гасыр элек салынган, шуңа күрә чокырлар хасил булган иде. Шундук көн-төн асфальт җәйделәр. Югыйсә элек тә, бик еш булмаса да, агай-эне ак миеклар аның фатирында булалар иде...

Бу һич тә арттыру түгел: Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы, академик Гариф Ахунов халык өчен яшәде, аңа хезмәт итте. Үләренә бер-ике көн калгач, Мамадыш районында яшәп иҗат итүче язучы Р. Газизов хакында Язучылар берлеге белән сөйләште...

Шигем юк: татарның күренекле шәхесе, классик язучысы Гариф Ахунов та халык күңелендә мәңге сакланыр.

*Мәхмүт Әхмәтҗанов,*
язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре
*2000, 24 июнь*

# Авыр-югалту

Татар халкы зур югалту кичерә. 4 июньдә Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге бүләк иясе, Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов (Гариф Ахунов) кинәт вафат булды. Рәхимсез үлем арабыздан туган илебезне һәм халкыбызны өзелеп сөюче, бөтен көчен, ихтыярын әдәбиятыбызны һәм иҗтимагый фикер үсешен тәэмин итүгә биргән якын иптәшебезне һәм киң күңелле, гаять кешелекле әдипне тартып алды.

Гарифҗан Ахунҗан улы 1925 елның 18 сентябрендә Татарстан Республикасының Арча районы Өчиле авылында туа. Алты яшендә әтисез калган Гарифҗанны һәм аның өч туганын әниләре тәрбияли. Сугыш еллары булачак язучының язмышында тирән эз калдыра. 1947 елда егерме ике яшьлек Гарифҗан Арча педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Яшьтән үк рәсем сәнгатенә гашыйк егет уку елларында иҗатка тагын да ныграк тартыла, матбугатта аның беренче хикәяләре һәм әдәби тәнкыйтькә багышланган мәкаләләре басыла. Студент вакытында ук аны




Арчада Гариф Ахуновның кабер ташы. 2001

«Совет әдәбияты» журналына әдәби хезмәткәр итеп эшкә алалар. Биредә, биш ел эшләү дәверендә, ул үзенең әдәби осталыгын үстерә, журналның камиллеген, сәнгатьчә югарылыгын тәэмин итүгә зур өлеш кертә.

1956–1968 елларда яшь язучы Әлмәт якларында яши, тормышны, булачак геройларын өйрәнә. Аның тырышлыгы белән биредәге әдәби берләшмә Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегенә әверелә. Биш ел дәвамында Г. Ахунов аңа җитәкчелек итә. Башкалага әйләнеп кайткач, ул «Казан утлары» журналының баш мөхәррире итеп билгеләнә. Аның оештыру таланты аеруча Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә җитәкчелек иткән елларда ачыла. Башта ул җаваплы сәркәтиб, ә 1974–1984 елларда идарә рәисе вазифаларын башкара. Нәкъ шул чорда Татарстан Язучылар оешмасында аеруча эшлекле әдәби иҗат мохите булдырылды, китап бастыру эше җанланды, татар китапларын башка телләргә тәрҗемә итү юлга салынды, Чаллы Язучылар берлеге оештырылды, яшь иҗат көчләре белән эшләү активлашты. Г. Ахунов озак еллар СССР һәм Россия Язучылар берлеге идарәләре сәркәтибе булды, 1974–1984 елларда СССР Югары Советы депутаты буларак та ул үзен ил күләмендә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе итеп танытты.

XX гасыр татар әдәбиятында Гариф Ахуновның зур урыны бар. Әдип хикәя, повесть, роман жанрларын бердәй үз итте, аларның талантлы үрнәкләрен бирде. Аның «Яшьлек яме», «Чикләвек төше» повестьлары, «Хәзинә», «Идел кызы» романнары аеруча киң яңгыраш алды. «Хәзинә» әсәре буенча төшерелгән фильм илебез экраннарына чыкты. Аның әсәрләре буенча куелган спектакльләр дә тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителде. Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен ул сәхнә әсәре итеп эшләде, бу спектакль Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының алтын фондына кереп калды. Г. Тукай турындагы күпсерияле телевизион фильмны экраннарга чыгаруда да аның өлеше зур булды.

Г. Ахуновның әсәрләре рус, төрек, башкорт, украин, үзбәк, казах, кыргыз, белорус, латыш һәм башка бик күп телләргә тәрҗемә ителде. Ул үзе дә М. Шолохов, Р. Тагор, Н. Шундик, Н. Погодин, А. Островский һәм башка күренекле язучыларның һәм драматургларның әсәрләрен татар телендә яңгыратты. Әдип бер үк вакытта кайнар йөрәкле, кайгыртучан табигатьле публицист та иде. Аның әдәби тәнкыйтебезгә керткән өлеше үзе бер җитди казаныш булып хисаплана ала.


Г. Ахуновның күпьеллык намуслы хезмәте ил-халык тарафыннан югары бәяләнде. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнде. 1973 елда аңа, «Хәзинә» романы өчен, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Ул «Татарстанның халык язучысы» дигән шәрәфле исемгә лаек булды.

Без татар әдәбиятының олы бер вәкилен югалттык. Гарифҗан Ахунҗан улы гомеренең соңгы көннәренә кадәр иҗат каләмен ташламады, актык сулышынача әдәбият гаме белән яшәде. Аның язган әсәрләре, таланты, авторның исемен мәңгеләштереп, безнең арабызда кала, алар әле күп буыннарга тормыш дәреслеге, әхлак үрнәге һәм ихлас хисләр гәүдәләнеше буларак хезмәт итәр.

Гарифҗан Ахунҗан улы Ахуновның якты истәлеге рәхмәтле татар халкы күңелендә мәңге сакланыр.

*М.Ш. Шәймиев, Р.Н. Миңнеханов, Ф.Х. Мөхәммәтшин, Ә.С. Гобәйдуллин, И.К. Хәйруллин, Р.М. Миңнуллин, И.Г. Тарханов, К.Ш. Исхаков, И.Н. Сабиров, М.Х. Хәсәнов, Р.И. Вәлиев, Ю.Г. Коноплев, Ф.Г. Галимуллин, Т.Г. Миңнуллин, Р.М. Харисов, А.М. Гыйләҗев, Г.Г. Афзалов, Ш.Г. Галиев, Н.С. Фәттахов, И.Г. Юзеев, Р.Г. Фәйзуллин, В.В. Корчагин, Г.А. Паушкин*

# Кыйссаи-Гарифҗан



Мәҗит Гафуриның 100 еллыгы. 1980

Кичә Татар халкы сөекле улларыннан берсен – язучы Гариф Ахуновны соңгы юлга озатты. Татар гына түгел, ә бәлки Урта Идел халыклары, гомумән, Русиядә яшәгән барча халык аны белә, укый, ярата иде.

...Күк йөзендә миллиардларча йолдыз яна. Шулардан юлчыларга (төньяк киңлектә) маяк булырдае берәү генә: ул – Казык йолдыз. Аннары инде Җидегән йолдыз бар, әлбәттә, өстәп, Киек Каз Юлы.

Татар әдәбияты – халкыбыз рухы өчен тоташлае беләән Киек Каз Юлы ул. Ә шул галактикадагы Тукай, Бабич, Ибраһимов, Такташ, Исәнбәт, Җәлил, Туфан, Фатих Хөсни, Зәки Нури, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Сибгат Хәким, Шәриф Хөсәенов, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиевләр иң якты йолдызлардан.

Инде менә шул кабатланмас язучыларыбызны, сәнгать әһелләребезне үз күңеленә, рухына җыеп, татар халкына юмарт рәвештә өләшеп бирер мәсләктә йөрәген яндырган бөек бер каләм иябезне, шәхесебезне, җор телле, гел көләч була белә торган кешебезне – шәүкәтле Гариф Ахуновыбызны бакыйлыкка озаттык.

Борынгы грек фәлсәфәчесе Сенека: «Яшәү ул – үләргә өйрәнү», – дигән. Ә Гариф ага үз тормышының, иҗатының бөтен үрнәге белән: «Язу – үлемсезлек ул!» – дип яшәде.

Әлхасыйль, сагыш басса – күк күкрәр, җан ташыса – яшен яшьнәр. Чатнаплар торып яшен ялтырады, күңел тәрәзәләрен калтыратып күк күкрәде – татарның халык язучысы Гариф Ахунов вафат булды (урыны җәннәттә булсын). Ә бу әдип татар әдәбияты – шәкертләре өчен үзенә күрә бер мәдрәсә, көллият, дарелфөнүн иде дә, аны белгәннәр өчен (белмәгәннәр өчен дә!) әдәби хәзрәт, имам, казый, ахыр килеп, гомере буена татар халкының тыңлаучан, зиһенле, зирәк бер шәкерте иде.

Әдәби шөгыльчеләр өчен генәме соң? Юк! Игенчеләр, терлекчеләр, эшчеләр, укытучылар, җитәкчеләр өчен дә. Гомерлек шәкертлеге аның җелегендә иде, ә осталыгы аны белгән һәркем тәнендәге йөз мең чакрымлы кан тамырлары, капиллярлары буенча озын-озак агар әле, озын-озак...




1958–1968 елларда Гариф Ахунов яшәгән Радищев урамындагы 20 нче йортка мемориаль такта куелу. Әлмәт. 2006, октябрь

Арыш серкә очырганда басуга чыксак, белеп торыйк: бер серкәсе – Гарифҗан аганыкы. Җир җиләге җыябыз икән, бер бөртеген аның рухына дип авыз итәрбез.

Кем соң ул Гариф Ахунов? Әдип. Хикәяләр, повесть, пьеса, шигырь, романнар иясе. Шул әсәрләре белән халыкларның чәчен чәчкә бәйләгән асыл зат. Күпмедән-күпме халыклар арасында татар халкының тулы вәкаләтле илчесе.

*Җәй башында йолдызлар атылмый,*
*Арттан килгән ядрә – денсезлек!*
*Гариф Ахун дигән континент бар:*
*«Татар бугазы» ннан – Әдрән диңгезлек.*

*Тездән ерып барды Җир шарыннан,*
*Шакшыны яхшыдан аралап.*
*Якты белән кара арасында*
*Шәүләсенә кадәр агарган...*

*Ара тапты аны белгән җаны,*
*Аргамактай чапты да чапты...*
*Инде әнә әйбәт бу адәмне*
*Бүген фәрештәләр кочаклый.*

Болыннарда язын үлән үскән чакта, чәчәкләрне сыйпый-сыйпый, язучы Гариф Ахуновның Йөзлебикәсе һәрберебез өчен хәл алып утырадыр кебек. Кояш чыгышы мизгелендә һәр мәчетебездән күмәк азан әйтелгәндә, сигез мәкамнең берсен аның Габбас хәзрәте әйтәдер шикелле.

Арча төбәгендәге Өчиле авылында дөнья күргән бәп-бәләкәй Гарифҗан шулай, татар халкын биш кыйтгага танытып, каләм иярләренең сандугачы була белде.

Дөнья тәмам тарайган мәл иде. Ә ул исә, мәгърур фанилыгыннан тыйнак бакыйлыгына барышлый, һәммәбезнең күзен ачып китте.

*Әхәт Гаффар*
язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе,
*2000*

# Гарифҗанны-бик-сагынам

Республикабызның Галиәсгар Камал театры бинасында дустым Гариф Ахунов белән соңгы мәртәбә саубуллашырга бик күп халык җыйналган иде.

Гарифҗанның җәсәде бик хәсиятләп, килгән кешеләр йөзенә карап саубуллашып үтеп китәрлек итеп куелган иде. Аны зурлап хушлашырга килгән туганнары, дуслары арасында республика җитәкчеләре, Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев тә бар иде. Бу кешеләр барысы да, чиратлашып, Гарифҗан янында биш минутлык тынлык белән хушлашу каравылында басып тордылар.

Чиратым җиткәч, мин дә аның янында басып тордым, соңгы күрешүебез дип, аның белән исән вакытта булган күп вакыйгаларны башымнан кичердем. Кыска гына итеп булса да, шул фикерләремне язарга уйладым.

Без Гарифҗан белән бер-беребезне күптәннән беләидек. Икебез дә 1925 елгылар, бер районда эшләдек. Республикабызның зур җыелышларында гел очраша идек. Мин Татарстан АССР Югары Советы депутаты, КПСС өлкә комитеты члены идем. Шундый зур җыелышларда Гарифҗанның чыгышларын залдагы кешеләрнең ихлас тыңлауларын күзәтә идем. Һәм ахырдан бу турыдагы фикерләремне үзенә әйтә торган булдым. Шунда сөйләгән сүзләрен чынбарлык мисаллары белән, эшләре, уңышлары белән бәйләп, фикерләребезне уртаклаша идек.

Ул үзебезнең татар халкын, милләтен бик яратты. Хезмәт сөючән, булдыклы кешеләргә гашыйк иде. Үзенең әсәрләрендә дә шуларны яктыртырга тырышты. Татар халкының эшчәнлеген, гореф-гадәтләрен яшь буынга ирештерү юлларын ачыкларга тырыша, аларны яңа әсәрләрдә күрсәтергә омтыла иде.

Шулай бервакыт Мәскәүдә Кремльнең Зур съездлар сараенда СССР төзелүнең юбилей тантанасында зур концерт булды. Шул концертта диктор, латыш артисткасы Зәки Нури шигырен сөйли, дип белдерде. Артистка матур тавыш белән сәнгатьчә чыгыш ясады. Ул сөйләп бетерүгә, Гарифҗан сикереп торып кул чаба башлады. Бу алкышлауны бөтен зал күтәреп алды. Без, Татарстан делегатлары, моңа бик горурландык. Бу бит зур тантанада татар шагыйре Зәки Нуриның әсәре яңгырау иде. Гарифҗан моңа балаларча сөенеп, үзенең иптәшләре арасында горурланып сөйләп йөрде.

Г. Ахуновны СССР күләмендә танылган язучылар да таный, хөрмәтли иде. 1979 елда СССР Югары Советы депутаты булып сайлангач, Гарифҗан, мин һәм очкычлар әзерли торган заводның фрезерчысы Галимулла Әсхәдуллин бергә йөри идек. Аннан беркөнне Кремльдә йөргәндә, карап торуга мөлаем гына, зыялы кешегә охшаган кеше белән кочаклашып күреште Гарифҗан. Үзләре көлешә-көлешә сөйләштеләр, кунакка да чакырыштылар, бүлмә номерларын әйтештеләр. Без аның кем булуын сорагач, аның Мостай Кәрим икәнен, аның белән алар СССР һәм РСФСР Язучылар союзы идарәләрендә әгъза булып, аның җыелышларына бергә йөрүләрен сөйләде. Икенче очраганда, аның белән мине дә таныштырганы исемдә.




Сулдан уңга: язучылар З. Нури, Р. Рәшитов һәм Г. Ахунов Гаграда. 1953



Беренче рәттә (сулдан уңга): Г. Ахунов, Д. Көгелтинов; икенче рәттә (сулдан уңга): Ш. Галиев, Г. Шәрәфетдинов. 1981

Аннан соң ул мине Рәсүл Гамзатов белән дә таныштырды: беркөнне минем башым авыртып тора иде. Шуны Гарифҗанга әйтүем булды, ул мине медпунктка җитәкләп алып та китте. Керсәк, каршыбызга процедуралар бүлмәсеннән берәү чыгып килә. Ул:

– О-о, Гариф! – диде дә Гарифҗанны кочаклап алды.

Мин аны тавышыннан танып алдым. Бу Рәсүл Гамзатов иде. Ул Мостай Кәримгә караганда шаянрак һәм ачыграк икән. Безгә аның белән еш очрашырга туры килде. Очрашканда һәрвакыт исәнләшә һәм шаян сүзләр сөйләшмичә китми иде. Татарлар турында бик югары фикердә, бөек халык ул, дия иде.

Бервакыт Кремльдә утырышлар арасында бер сәгатьлек ял бирделәр. Шунда буфетта Гарифҗанны бер юантык, тәбәнәк кеше чакырып алды һәм, кирәкле әйберләр алып, безне үз өстәленә дәште. Мин килеп утыргач: «Бу кеше колхоз председателе, 35 еллар эшли инде, эше үрнәк, – дип, – ә бу иптәш – балкар халкының күренекле язучысы Кайсын Кулиев», – дип, бер-беребез белән таныштырды. Безнең янга тагын бер кеше килеп утырды. Ул кабардин язучысы Кешоков икән. Алар Кешоковның «Сынган дага» дигән әсәре үз халкы тарафыннан уңай кабул ителмәве хакында сөйләштеләр. Соңыннан мин Гарифҗаннан, нинди әсәр ул, дип сораган идем. Ул китап монда китапханәдә бар, алып укырсың әле, диде, ләкин мин аны алып укый алмадым. Балкар халкын Урта Азиягә хайван вагоннарына тутырып озатулар, аларның анда тончыгып үлүләре, ачлыктан җәфаланулары турында сөйләп күрсәтте. Аның бу хәлгә никадәр ачулы булуын, сәясәтебезнең дөрес түгеллеген ачынып сөйләүләре әле дә күз алдымда.



Гариф Ахунов һәм Фәрваз Миңнуллин «Искра» колхозында Фәйзи Галиевта кунакта. 1981

Гарифҗан үзбәк халкының фаҗигасен ачып салган «Хәмзә» романы авторы, Үзбәкстан язучылары җитәкчесе Яшин белән таныштырды. Бу әсәр буенча күп серияле кино да чыккан иде, мин китапны укып чыккан идем. Сөйләшеп утырганда, Яшинга, сезгә бер зур рәхмәтем бар, дидем. Ул, нинди рәхмәт соң, дип сорады. Мин, Үзбәкстанда балаларны татар укытучылары укытып йөрүләрен, аларның кышлакларда нинди авыр шартларда эшләүләрен тулысы белән күрсәтеп язуыгыз өчен рәхмәт, дидем. Шулай ук Үзбәкстанда беренче тапкыр театрны татар труппасы башлаганлыгын әйткәнсез. Сез безнең халыкның үзбәк культурасын үстерүдә зур өлеш керткәнен күрсәткәнсез, дидем. Роман-газетада чыккан «Живая вода» дигән әсәрендә Шәрәф Рәшидов татар кызы Галияне бозык, әхлаксыз итеп яза. Ә Сез аның фикеренә капма-каршы уңай фикер язгансыз, дидем. Мин Мәскәүдә йөргәндә, Гарифҗан ярдәмендә таҗик язучысы Турсун Задә белән таныштым. Төрекмән язучылары җитәкчесе К. Кербабаев, казах язучысы-тарихчы Олжас Сөләйманов, кыргыз әдибе Чыңгыз Айтматов белән танышу, алар белән күрешү бәхетенә ирештем. Чыңгың Айтматов безнең белән саф татарча сөйләшә иде (әнисе татар булган, ялгышмасам, Нәгыймә исемле бугай). Ул чорда Чыңгызның бик күп әсәрләре дөнья күрде. Аларны халык йотлыгып укыды. Мин үзем дә аның әсәрләрен яратып укып бара идем. Әсәрләре буенча спектакльләр куелды. Гомумән, бу бөек шәхесләр татар халкын бик хөрмәт итеп сөйли торганнар иде. Бәлки, Гарифҗанны үз халкын яратып, аңа мәдхия җырлаганы өчен дә яратканнардыр. Үз халкың турында, шундый дәрәҗәле кешеләрнең яхшы сыйфатлары турында сөйләгәндә, мин дә горурланып утыра идем.

Гарифҗан Ахунов, эшчеләр тормышына багышланган бай эчтәлекле романнар, повестьлар язу белән бер үк вакытта, үзенең күп әсәрләрен авыл эшчәннәренә дә багышлады. Ул авыл тормышын бик яхшы белә иде, чөнки аның яшьлеге авылда үткән. Аерата

Арча районы халкы тормышына багышлап язган әсәрләре белән туган ягы кешеләрен хөрмәтләде. Боларга мисал итеп «Идел кызы», «Без бит Арча яклары», «Йолдызлар калка», «Гомер юлы» әсәрләрен әйтер идем. Г. Ахуновның әсәрләре буенча кинофильмнар төшерелде. Шул уңайдан «Гомер юлы» исемле әсәрен язганда, безнең авылга килеп, унбиш көн буе ару-талуны белмичә көне-төне эшләвен искә төшерәм. Аның, иренмичә, ихластан эшләвен үз күзләрем белән күреп ышандым. Башта ул колхоз тормышы белән танышты: иртән торып, кешеләрнең эшкә барулары, аларның хезмәткә карашын өйрәнү өчен төрле кешеләр белән әңгәмәләр, очрашулар үткәрә, аларны күзәтә иде. Ул аерым кунак йортында яшәде. Иртән чыгып, ишегалларын кардан көри. Үтеп йөрүче кешеләргә сүз куша, шаян сүзләр әйтә, шунда ук сүзне үзенә кирәкле якка бора. Җитәкчеләр турында сораша, белешә. Гади, шаян булгач, кешеләр аңа ияләштеләр. Аның белән ачыктан-ачык сөйләшәләр иде. Кичен колхоз идарәсенә килә, эш йомгаклары, киләсе көндә нинди эшләр башкарырга уйлаулары белән таныша. Нарядның кичтән булуына гаҗәпләнә һәм шатлана иде.

Гарифҗанның язучы буларак икенче бер бик файдалы эшенә мин үзем гомерем буена сокланып яшәдем. Ул, иренмичә, республикабыз халкының көндәлек мәшәкатьләре, сөенечләренә багышлап, газеталарга бик күп мәкаләләр язды. Аерата авыл халкының катлаулы эшләре, язгы чәчү, көзге урып-җыйнау, терлекләрне кышлату, җәйге көтүлектә тәрбияләү хакында күп язды. Республикабызда булган сәяси вакыйгаларны да читтә калдырмады. Ул үзебезнең республикада һәм чит өлкәләрдә булган укучылары белән очрашулар оештырды. Кешеләр белән оста итеп аралаша белде. Яңадан бер ягы – ул яшь язучылар хакында кайгыртып яшәде. Аларның әсәрләрен, иренми укып чыгып, үз фикерләрен язып, әсәрләргә юллама биреп, нәшриятка тәкъдим итте. Күп кенә өлкән язучыларның әсәрләренә бәһа бирде. Башка милләт язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итте.

Ул республикабыз язучыларының уңышлары өчен гел сөенеп яшәде, көнләшмәде. Аларны гел пропагандалап, әсәрләреннән өзекләр укып, халкыбыз талантларын чит милләт кешеләренә күрсәтеп, куанып яшәде. Татар халкының булдыклылыгы белән горурланып, аның тарихы хакында рус язмаларындагы гаделсезлекләргә борчылды.

Ул замандашлары күңелендә үзе яшәгән чорның тормышын, кешеләренең фидакарьлеген җырлаучы зур язучы, шәхес булып озак сакланыр.

*Фәйзи Галиев,*
язучы, РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре


# Светлой-памяти-Гарифа-Ахунова

Писатель приобретает известность и завоевывает авторитет, прежде всего, своим творчеством. У Гарифа Ахунзяновича Ахунова, народного писателя Республики Татарстан, ушедшего из жизни в последнем году XX столетия, – богатое творческое наследие. Произведения Гарифа Ахунова читаются и перечитываются не одним поколением татар, погружая их в историю и современность нашего народа. Достаточно вспомнить его романы «Клад» и «Хозяева», повести «Ядро ореха» и «Ардуан батыр», дилогию «Дочь Волги», переводы на татарский язык произведений А. С. Макаренко, М. А. Шолохова и многие-многие другие, общее количество которых – более полусотни. Гариф Ахунзянович долгие годы возглавлял Союз писателей ТАССР, являлся депутатом Верховного Совета СССР, главным редактором академического литературного журнала «Казан утлары». В 1973 году он был удостоен Государственной премии ТАССР имени Габдуллы Тукая, а в 1993 году – звания народного писателя Республики Татарстан, в 1998 году стал почетным членом Академии наук Республики Татарстан.

В 1998 году – за два года до ухода из жизни Гарифа Ахунова – увидела свет его документальная трилогия «Увиденное и прожитое Тимерханом», посвященная одному из героев



Гариф Ахунов – беренче рәттә сулдан беренче. Казан, 1984



Ихлас сөйләшү: Гариф Ахунов шагыйрь дусты Мостай Кәрим (Уфа) белән. 1977

